# ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ
# ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

КАЗАН · «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ · 2007

УДК 821.512.145.0(1-87)
ББК 83.3(4Тат) я7
М57

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Миңнегулов Х. Й.**

Чит илләрдәге татар әдәбияты/Хатыйп Миңнегулов.— Казан : Мәгариф, 2007.— 399 б.
ISBN 978-5-7761-1712-1

Китапта чит илләрдә яшәп әдәби иҗат һәм матбагачылык белән шөгыльләнгән татар зыялыларының тормышы һәм эшчәнлеге яктыртыла, иҗатларыннан үрнәкләр тәкъдим ителә. Шулай ук «Kazan», «Яңа милли юл», «Азат Ватан», «Яңа япун мөхбире» журналлары хакында да сүз бара. Китап мәктәп укучыларына, студентларга, укытучыларга һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелеккә адреслана.

ISBN 978-5-7761-1712-1 © «Мәгариф» нәшрияты, 2007

## МӨКАДДИМӘ

Бу сүзне яздым да уйланып калдым: ә бит аны киң катлау укучылар аңламый. Шулай да мин «мөкаддимә» сүзен калдырырга булдым. Ни өчен? Мәдәни тарихыбызга, әби-бабаларыбызга хөрмәт, ихтирам йөзеннән. Чөнки Октябрь инкыйлабына кадәр шактый гына китапларыбыз шул сүз белән ачылган. «Кереш», «Сүз башы» дип язу, нигездә, соңгы дәвер күренеше генә. «Мөкаддимә» (мөкаддәмә) сүзе гарәп, фарсы телләрендәге басмаларда хәзер дә иркен кулланыла. Төрекләр исә соңгы дәвердә «цnsцz», «ilk sцz» атамаларына өстенлек бирә.

Кереш-мөкаддимәнең төп вазифасы китап хакында аерым мәгълүматлар, гомуми юнәлеш бирүдән, аны аңлауга, кабул итүгә җирлек әзерләүдән гыйбарәт. «Сүз башы» үзенә күрә китапка керүдә ачкыч ролен дә уйный.

Иң әүвәл — җыентыкның исеменә аңлатма. «Чит илләр...» төшенчәсе — чагыштырмача тотрыклы күренеш. Шулай да тарихи яссылыкта караганда, ул да үзгәреп тора. Әле кайчан гына «безнең ил» дип йөртелгән Советлар Берлеге империясе бар иде. Инде хәзер аның җирлегендә берничә мөстәкыйль дәүләт яши. Россиядән кала, бу мәмләкәтләр, гәрчә «якын» дип йөртелсәләр дә, инде безнең өчен рәсми яктан чит илгә әверелде. Ә бит бу җөмһүриятләрдә, аеруча Үзәк Азия дәүләтләрендә (Үзбәкстанда, Казакъстанда һ. б.), миллионга якын милләттәшебез гомер кичерә. Алар азмы-күпме китаплар, гәҗит-журналлар чыгарганнар һәм чыгаралар, татар мәдәниятенә дә үзләреннән билгеле бер өлеш кертәләр. «Якын чит илләр»дәге татарларның әдәбиятын, рухи мирасын аерым өйрәнү — махсус проблема. Бу китапта алар хакында әле сүз бармый. «Чит ил» дигәндә, элеккеге СССРдан тыш мәмләкәтләр, иң беренче чиратта Кытай, Япуния, Финляндия, Төркия, Алмания, Польша һәм кайбер башка илләр күздә тотыла. Шунысын да искәртик: этник мәсьәләләр хакында сүз барганда, кайвакыт «чит ил» атамасы урынына «диаспора» терминын куллану да очрый. Бу ике төшенчә үзара якын, әмма алар тәңгәл килми. «Диаспора» нинди дә булса кавемнең тарихи ватаннарыннан, төп җирләреннән читтә яшәүче өлешенә карата кулланыла. Ул күбрәк башка мәмләкәтләрдә гомер кичерүчеләрне үз эченә ала. Әмма диаспора бер ил эчендә дә булырга мөмкин. Мәсәлән, Архангельскида яисә Петербургта яшәүче милләттәшләребез — җирле халык түгел, ә Идел-йорттан күчеп килгән кавем, ягъни диаспора.

Соңгы вакытларда кайбер «акыллы башлар» Татарстанны гына татарларның асыл Ватаны, тарихи җире дип карап, аннан тыштагы милләттәшләребезне диаспора дип күрсәтә башладылар. Әмма бу — тамырдан хата фикер, сәяси саташтыру. Миңа 2004 елның декабрь аенда Төмән татарларының корылтаенда катнашырга туры килгән иде. Шунда өлкә җитәкчеләреннән берсе үз чыгышында Себер татарларына карата «диаспора» атамасын кулланды. Залдагы халык моңа дәррәү каршы төште. Хәтта бер татар зыялысы: «Без монда гомер-гомергә яшәгән халык. Хакыйкатькә тугры калсак, «диаспора» сүзе күбрәк «өлкән туганнарга» карый»,— дип тә ычкындырды. Ахыр чиктә, чыгыш ясаган түрә халык алдында гафу үтенергә мәҗбүр булды. Идел-Урал, Көнбатыш Себер — татарның тарихи Ватаны. Шуңа күрә Башкортстан, Пермь, Чиләбе, Оренбург, Әстерхан, Самара, Төмән, Пенза, Түбән Новгород һәм Идел-йортның башка республика-өлкәләрендәге татарлар һич тә диаспора була алмый. Татарстан исә элек-электән Евразиянең зур киңлекләрендә яшәгән татарларның тик бер төбәге генә.

Төрле сәбәпләр аркасында халкыбызның бер өлеше элек-электән башка төбәкләргә, илләргә күчеп, качып китәргә мәҗбүр булган. Шуңа мөнәсәбәттә аның теге яки бу күләмдә мөһаҗирлек әдәбияты да барлыкка килгән. Сәйф Сараи, Мәхмүд Сараи Гөлестаный, Бәркә Фәкыйһ кебек әдипләрнең инде XIV йөздә үк, Идел буеннан китеп, Мисырда иҗат итүләре мәгълүм. Әмма бу китапта алар турында, элеккеге гасырлар хакында сүз бармый. Хронологик яктан аның үзәген *XX йөзнең беренче яртысы* һәм *урталары* тәшкил итә. Чөнки бу чор — ил тормышының, татар дөньясының кырмыска оясы кебек кайнаган дәвере. Колониаль изелү, сәяси һәм матди кысынкылык, бер-бер артлы булып торган инкыйлаблар, сугышлар, шәхес культы татарны тагын да таратты, илнең һәм җиһанның төрле почмакларына сипте; миллионлаган милләттәшләребез бу коточкыч елларның корбаны булды.

Шунысы гыйбрәтле: милли тәрбия алган татар, кая гына барып чыкмасын, үзенең телен, гореф-гадәтен, китабын, гомумән, үзенең рухи барлыгын, менталитетын үзе исән вакытта сакларга, алдагы буыннарга тапшырырга омтыла. (Әмма, кызганыч ки, бер-ике буыннан соң, кагыйдә буларак, милли инкыйраз, ассимиляция башлана.) Мөһаҗир татарлар оешыбрак, тупланыбрак яшәгән төбәкләрдә мәктәпләр ачылу, гәҗит-журналлар чыгару, китаплар бастыру, спектакльләр кую, әдәби-музыкаль кичәләр оештыру, милли һәм дини бәйрәмнәр үткәрү — болар бар да милли барлыкны, үзлекне саклауга, үстерүгә юнәлтелгән чаралар. Бу төр эш-гамәлләр аеруча Финляндиядә, Алманиядә, Төркиядә, Кытайда, Япуниядә, Польшада күпләп уздырыла. Аларда басылган төрле характердагы татарча китаплар, гәҗит-журналлар (бигрәк тә «Яңа милли юл», «Яңа япун мөхбире», «Белдереш», «Азат Ватан», «Kazan» һ. б.) шул чор укучылары өчен генә түгел, XXI гасыр кешеләре өчен дә кызыклы һәм гыйбрәтле. Алар белән танышу мөһаҗир татарларның тормышын, рухи халәтен, теләк-омтылышларын, милләтебезнең тарихын, яшәешен, ил һәм дөнья хәлләрен күзалларга ярдәм итә. Ватанны, туган җирне сагыну, халыкның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлану, аның бәйсезлеге, бәхете өчен көрәш, ислам динен зурлау һәм хөрмәт итү — чит илләрдәге татар әдәбиятының төп мотивлары. Миллилек һәм XX йөз башы, һәм Совет чоры мөһаҗирлек әдәбиятында да, публицистикасында да үзәк урынны били.

Янә китап исеменә кайтыйк. Сез кулга алган китап «Чит илләрдәге татар әдәбияты» дип аталган. Әмма чынлыкта анда, сүз сәнгате белән беррәттән, көндәлек матбугат материаллары, публицистика, аерым журналлар да карала. Моның берничә объектив сәбәбе дә бар. Мөһаҗирлектәге татар басма сүзенә билгеле бер дәрәҗәдә син-кретизм хас. Анда еш кына әдәби-эстетик як иҗтимагый, сәяси, гыйльми, дини, публицистик башлангычлар белән үрелеп китә, чынбарлык һәм хыялый күренешләр табигый рәвештә кушыла. Бу — бер. Икенчедән, бер үк авторлар төрле жанрларда, төрле тармакларда чыгыш ясыйлар. Мәсәлән, Г. Исхакыйның әдәби иҗатын аның

публицистикасы, журналистлык һәм сәяси эшчәнлеге белән тыгыз мөнәсәбәттә караганда гына тиешенчә аңлап һәм бәяләп була. Өченчедән, күпчелек әдәби материаллар гәҗит-журналларда дөнья күргән.

Башка мәмләкәтләрдәге татар басма сүзе милләттәшләребезнең үз хисабына яшәгән. Аның туу, таралу тарихы да үзгә. Эчтәлегендә, идея-тематикасында да шактый гына үзенчәлекләр бар. Әмма, гомумән алганда, чит илләрдәге татар сүз сәнгате Идел-йорттагы милли әдәбият, күпгасырлык рухи мирас белән аерылгысыз һәм табигый бәйләнешле. Чөнки мөһаҗир авторларның күпчелеге — илдә яшәп, иҗат итеп киткән кешеләр. Алар гомумтатар мәнфәгатьләрен, аның бөтенлеген, бердәмлеген, өмет-идеалларын күздә тоталар, бер үк телдә, бер үк мәдәни-эстетик казанышларга таянып иҗат итәләр. Шуңа күрә, рухи мирас, әдәбият тарихы хакында фикер йөрткәндә, без, Россия, СССР кысалары белән генә чикләнмичә, чит мәмләкәтләрдәге татар сүз сәнгатен, матбугатны да исәпкә алырга бурычлы. Шунсыз безнең фикер-күзәтүләребез тулы һәм хакыйкый булмаячак.

Мәгълүм ки, Совет чорында безгә мөһаҗирлектәге татар китаплары, гәҗит-журналлары юньләп билгеле түгел иде. Чөнки ил чикләре аларга ябык булды, читтәге басма сүз, әдип-галимнәр чын мәгънәсендә чит, хәтта дошман итеп каралды. Бары XX гасырның азакларында, илдә үзгәртеп корулар, демократик хәрәкәт башлангач кына, мөһаҗирлек әдәбиятына юл ачылды. Авырлык, мең мәшәкатьләр белән булса да, без читтәге милләттәшләребезнең тормышы, әдәбияты, матбугаты, кылган эш-гамәлләре белән таныша башладык. Бу юнәлештә Илбарис Надиров, Әбрар Кәримуллин, Тәүфикъ Әйди, Гомәр Таһир, Окан Таһир, Миркасыйм Госманов, Надир Дәүләт, Рокыя Дәүләткилде, Лена Гайнанова, Тәлгат Насыйров, Рөстәм Гайнетдинов, Әхмәт Сәхапов, Фәридә Гаффарова, Римзил Вәлиев, Илсур Мансуров һәм башка милләттәшләребез игелекле эшләр башкардылар. Без фәкыйрегез дә инде 15 елдан артык бу өлкәдә булдыра алган кадәр күзәтү-тикшерүләр алып бара. Эзләнүләр ил эчендә генә түгел, Финляндиядә, Төркиядә, Үзбәкстан, Казакъстан кебек мәмләкәтләрдә дә дәвам иттерелде. Шушы вакыт эчендә мөһаҗир татарларга мөнәсәбәтле йөзәрләгән мәкалә-хезмәт нәшер ителгән. Күпчелеге, әлбәттә, гәҗит-журнал битләрендә. Безнең «Дөньяда сүземез бар…» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап…» (2003) дип исемләнгән китапларда да чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты хакында аерым материаллар бар.

XX йөз татар мөһаҗирлек сүз сәнгатенең, публицистикасының һәм, гомумән, иҗтимагый-сәяси тормышының үзәгендә, әлбәттә, Г. Исхакый тора. Ул — юлбашчы, ул — төп йөкне тартучы, ул — остаз. Аның мөһаҗирлектәге тормышы һәм әдәби-публицистик эшчәнлеге безнең илледән артык мәкалә-публикациядә, шул исәптән 3 китапта гәүдәләнеш тапкан. Шуңа күрә басмада бөек әдипкә махсус урын бирелмәде диярлек. «Чит илләрдәге татар әдәбияты» дип исемләнгән бу китап (аны «Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты» дип тә атарга була) «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» монографиясенең (Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 368 б.) дәвамы итеп каралырга тиеш. Аның төп өлешен безнең моңа кадәр гәҗит-журналларда басылган язмалар тәшкил итә. (Алар, гәрчә аерым кабатланулар булса да, нигездә, үзгәрешсез калдырылды.) Шуның белән бергә, шактый гына материаллар, аеруча әдәби текстлар, публицистик, әдәби-тәнкыйди язмалар өстәлде. Мәсәлән, Сания Гыйффәтнең «Тормыш көзгесе» драмасы, 1937 елда Хельсинкида басылганнан соң, ил укучыларына беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Хәсән Хәмидулла шигырьләренә дә зур урын бирелде.

Китаптагы язмалар беренче карашка төрле-төрле, үзбаш күренәләр. Әмма алар чынлыкта еш кына үзара керешеп китәләр, бер-берсен тулыландыралар. Мәсәлән, «Kazan» журналы хакында сүз барганда, гомумән, татар мөһаҗирлеге, чит илләрдәге татар мәдәнияте, аерым әдипләр турында да шактый гына факт-мәгълүматлар китерелә.

Мөһаҗирлектәге татар сүз сәнгатенең, матбугатының хәзергә безгә мәгълүм өлеше дә вакыт һәм күләм ягыннан шактый киң колачлы. Шуңа күрә бу китапта аны тулысынча иңләү, яктырту бурычы куелмый. Төп игътибар Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Минһаҗ Исмәгыйли кебек әдипләргә, «Яңа милли юл», «Азат Ватан», «Kazan», «Яңа япун мөхбире» шикелле журналларга юнәлтелде. Ә инде Ләбиб Каран, Шаһвәли Келәүле (Илдәр), Исфәндияр Ишгай, Мансур Арсланбәк, Исхак Хәйрулла, Гәүһәр Туганай, Садрый Хәмид, Гайсә Хәкимҗан, Хөсәен Садыйк, Наилә Бинарк һәм башка авторлар хакында хәзергә аерым белешмә-мәгълүматлар гына урнаштырыла.

Шунысын да искәртик: һәркайдагы кебек, мөһаҗирлектә каләм тибрәтүчеләрнең дә язмалары сыйфат ягыннан төрле. Фикри, сәнгати яктан камил юллар, әсәрләр белән бергә, гадәти тезмәләр, тел-стиль һәм ритмик җәһәттән зәгыйфь парчалар, бәхәсле текстлар да очрап тора. Әмма без андыйларны төзәтү, кыскарту, камилләштерү юлына басмадык. Язмалар, тарихи факт, объектив күренеш буларак, нигездә, үзгәрешсез калдырылды.

Мөһаҗирлектәге татарлар, кагыйдә буларак, гарәп графикасын кулланганнар. Әмма илдә XX гасырның 20 нче еллары ахырында бу язу латин графикасы, бераздан кириллица белән алыштырылды. Бу факторлар һәм имла-орфография мәсьәләләреннән оештыручы, үзара яраклаштыручы үзәкнең булмавы мөһаҗәрәттәге басма сүздә дә төрлелекләр китереп чыгара. Шуны истә тотып, гарәп язуындагы текстларны хәзерге графика белән биргәндә, оригиналга мөмкин кадәр тугры калырга тырыштык. Үзгәрешләр хосусый характерда гына.

Мөһаҗәрәттәге татар сүз сәнгате төр һәм жанр ягыннан, идея-тематик җәһәттән гаять төрле. Әгәр дә аның төп асылы нәрсәдән гыйбарәт дип сорасалар, мин аны «сагыну-сагыш әдәбияты» дип атар идем.

## МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ МАТБУГАТЫ

Беркем дә үз ирке белән туган җирен, Ватанын калдырып, чит якларга китеп бармый, аны бу адымга гадәттән тыш хәлләр, җитди сәбәпләр мәҗбүр итә. Монголлар һөҗүме вакытында безнең күп кенә әби-бабаларыбыз Мисыр-Сүриягә, Венгриягә барып чыккан. XII—XV йөзләрдә Кырым аркылы һәм башка юллар белән Көнбатыш Европага эләгеп, тиз арада итальян, француз, немец, испан булып киткән төрки-татар «гаскәри»ләренең, «коллары»ның исәбе-хисабы юк. Явыз Иван походлары, көчләп чукындыру һәм урыслаштыру, Мәскәү һәм Петербург хакимиятенең рәхимсез милли-колониаль сәясәте дә күп меңләгән татарларны, туган җирләреннән кубарып, камгак (перекати-поле) кебек, дөньяның төрле төбәкләренә илтеп ташлады. «Аклар», «әсирләр» составында чит мәмләкәтләргә эләккән милләттәшләребезнең саны да берничә дистә меңгә якын. Һәм, гомумән, Совет чорында ачлык, сугышлар, коточкыч салымнар, репрессияләр, «удар төзелешләр» нәтиҗәсендә татарларның таралышы аның бөтен бер милләт буларак яшәешен һәлакәт дәрәҗәсенә җиткерде. Дөрес, соңгы берничә елда татарда милли үзаң кузгала башлады. Әмма бу гына әле чынбарлыктагы аяныч хәлне үзгәртерлек түгел. Татарның милләт буларак янә туплануы, табигый нормаль халәткә килүе өчен, әле гадәттән тыш күп тырышлык, шактый вакыт кирәк булачак.

### I

Халык тарала икән, аның әдипләре дә тарала. Татар әдәбияты тарихында моның мисаллары бик күп. XIV йөзне генә алып карыйк. Мәхмүд Сараи Гөлестаный, Сәйф Сараи, Мәхмүд ибне Фәттах Сараи, Бәркә Фәкыйһ — болар бит бар да әүвәл Идел-Урал буйларында яшәп, ахыргы гомерләрен Мисыр-Сүриядә үткәргән әдипләр. Колшәриф, Мәүла Колый, Әбелмәних Каргалый, Шәмседдин Зәки, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләрне илһамландырган Өмми Кәмал да (XV йөз) соңгы сулышын Кече Азиядә ала. Казан ханлыгы чоры әдибе Хәсән (Асан) Кайгы — һәм казакъларның, һәм татарларның уртак шагыйре. Чөнки ул, Идел буйларыннан киткәч, казакъ далаларында яши.

Хаҗитархан «нугае» Суфый Аллаяр да (1616—1713), гәрчә ул Урта Азия шагыйре булып танылса да, Идел-Урал буе татарлары арасында да яратып укыла. Аның «Сөбател-гаҗизин»е, әл-Мөкаффәгъның «Кәлилә вә Димнә»се, Гаттарның «Пәнднамә»се, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Сәгъдинең «Гөлестан»ы кебек, татар укучыларын гасырлар буена тукландырып килә. Таҗеддин Ялчыгол (1768—1838), Суфый Аллаяр китабына нигезләнеп, үзенең мәшһүр «Рисаләи Газизә»сен иҗат итә. Бу әсәрнең исә татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту ярдәмлеге буларак кулланылуы да мәгълүм.

XIX—XX йөзләрдә, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң, чит-ят җирләргә киткән, үзгә мәмләкәтләрдә язу-сызу, иҗат эше белән шөгыльләнгән татар әдип-галимнәренең саны бигрәк тә күп. Менә аларның берсе — Муса Акъегетзадә (1864—1923). Татар әдәбиятына «Хисамеддин менла» (1886) исемле мәшһүр роман биргән бу әдип әүвәл туган ягы Чембарда һәм Пенза гимназиясендә укый, бераз вакыт Кырымдагы «Тәрҗеман» гәҗитендә дә эшли. 1887 елда ул Истанбулдагы «Мөгаллими Шаһания» исемле югары уку йортына укырга керә. Аннан соң төрек гаскәри уку йортында урыс теле һәм әдәбияты укыта, 4—5 ел Сүриядә, көнчыгыш Анатолиядә яшәп, эшләп ала. Гомеренең ахырын Истанбулда уздыра, нигездә, Н. Катанов китапханәсенең фондын тәртипкә китерү белән шөгыльләнә. Илгизәрлек, мөһаҗирлек ягыннан аеруча атаклы галим, дин белгече, әдәбиятчы, педагог, ориенталист (шәрыкшенас) Муса Ярулла (Җарулла) Биги (1875—1949) язмышы гыйбрәтле. Ул Казандагы Күл буе мәдрәсәсендә, туган шәһәре Ростовтагы дәүләт лицеенда укый. 1895—1898 елларда Бохарада белем ала. Аннан — Истанбул. Исәбе — инженерлыкка уку. Әмма ул, Муса Акъегетзадә киңәше белән, Мисырдагы атаклы Әл-Әзһәр университетына укырга керә. Күренекле галимнәр белән аралаша. Хаҗга баргач, өч ел гомерен Мәккә вә Мәдинә калаларында үткәрә. Бераздан Һиндстанга юнәлә. Ярты еллап анда яшәгәч, кабат Мисырга кайта. Янә анда укый, гыйльми-педагогик һәм журналистлык эше белән шөгыльләнә. Бу чордагы гарәп гәҗит-журналларында берничә мәкаләсе дөнья күрә. 1904—1925 елларда Россиядә, СССРда яши. Ике дистәдән артык китап бастыра, Петербургта «Өлфәт» гәҗитен чыгара, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә гарәп теле вә әдәбияты укыта. Совет чорында төрле эзәрлекләүләргә дучар була. 1926 елда Мәккәдәге Ислам корылтаенда катнаша. Аннан — Шәркый Төркестан, Әфганстан, Мисыр. 1932—1935 елларда Финляндиядә балалар укыта. Суомидан ул Берлин, Истанбул аша Иранга, Гыйракка, Мисырга килә. Ул илләрдә 2—3 ел гомерен уздыргач, 1938 елда Япониягә, Кытайга бара. Пекинда бераз торгач, Һиндстанга килеп төпләнә. Биредә гыйльми, сәяси, педагогик эш алып бара. Инглиз хакимияте аны сәяси эше өчен Пешавар төрмәсенә утырта. Әмма дөнья мөселман җәмәгатьчелегенең көчле таләбе, җирле халыкның демонстрацияләр уздыруы нәтиҗәсендә, аны хибестән чыгарырга мәҗбүр булалар. Муса Бигинең инде сәламәтлеге какшый: күзләре начар күрә, аяклары тотмый. 1947 елда Истанбулда хастаханәдә дәвалана. Бик күп телләрне белгән, йөзәрләгән китаплар, хезмәтләр авторы, бөтен ислам дөньясының мәшһүр шәхесе Муса Ярулла Биги Каһирәдә вафат була. Аның гарәп мәдәнияте хакындагы хезмәтләре, Әл-Мәгарридән, Хафиздан тәрҗемәләре әдәбият фәне өчен аеруча кыйммәтле. Муса Биги Коръәнне дә татарчага тәрҗемә итә. Шунысын да әйтик: ул — язучы Заһир Бигиевнең бертуган энесе. Аның күп санлы балалары була. Берсе — Фатыйма апа — профессор Габдрахман ага Таһирҗановның хатыны. Икенчесе — Габдерәшид ага — Магнитканы коручыларның берсе (ул анда 1934 елдан бирле эшли), техник фәннәр докторы, профессор, Магнитогорск тау-металлургия институтының корыч кою кафедрасы мөдире, металлургия фәнендә дөньядагы иң зур галимнәрнең берсе. Аның хакында моннан берничә ел элек «Правда» гәҗитендә зур очерк та басылган иде (*В. Кузьмищев*. Прогноз на завтра: живущие по совести // Правда.—1986.—16 апреля). Минһаҗ ага Исмәгыйли сөйләвенчә, Муса Бигинең Әхмәт исемле улы Сталин һәм татарлар язмышы хакында немец телендә китап язган. Шуның өчен авторны төрмәгә утырткannар.

Мөһаҗәрәттәге (читтәге, эмиграциядәге) татар мәдәниятенең берничә төбәге бар: Ерак Шәрык (Кытай, Япуния, Корея), Шәркый Төркестан (Гөлҗа...), Финляндия, Төркия, Алмания, Румыния, Ляһстан (Польша), АКШ һ. б. (Сүз, нигездә, XX гасыр хакында бара.) Харбин, Хайлар, Токио, Нагоя, Гөлҗа, Хельсинки һәм татарлар күпләп яшәгән кайбер башка калаларда татар мәктәпләренең эшләве мәгълүм. (Хәзер — юк.) Төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла, бергәләп милли, дини бәйрәмнәр уздырыла. Безнең халык төрле тамашалар, спектакльләр карарга ярата. Мөгаен, шуңадыр инде, татарлар яшәгән һәр төбәктә үзешчән артистларның күпләгән драма әсәрләрен, аеруча «Беренче театр», «Таһир—Зөһрә», «Галиябану», «Зөләйха», «Җан Баевич» пьесаларын сәхнәләштерүләре билгеле. Куаныч ки, бу традиция әле һаман да Финляндия һәм Америка татарларында дәвам иттерелә. Әле менә 1992 елда Хельсинкидагы милләттәшләребез «Беренче театр» һәм «Асылъяр» драмаларын мәшһүр швед театрының сәхнәсендә уйнадылар (режиссеры — Луара Шакирҗанова). Шунысы кызыклы: Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә (июнь, 1992) «Асылъяр» пьесасы Финляндия үзешчәннәре һәм Г. Камал театры артистлары катнашында Казан сәхнәсендә дә күрсәтелде һәм конгресс кунаклары, тамашачылар тарафыннан уңай бәяләнде (*Асия Юнысова*. Бергә булырбыз әле // Ватаным Татарстан.— 1992.— 26 июнь).

Туган телнең, әдәбиятның һәм, гомумән, мәдәниятнең саклануында һәм үсешендә, милли мәктәп белән беррәттән, вакытлы матбугатның, басма сүзнең гаять зур роль уйнавы бәхәссез хакыйкать. Шуны күздә тотып, читтәге милләттәшләребез дә төрле гәҗит-журналлар чыгарырга тырышканнар. Бу эш аеруча Ерак Шәрык төбәгендә уңышлы барган. Анда 20—40 нчы елларда дистәдән артык татарча гәҗит-журналның нәшер кылынуы мәгълүм (алар барысы да гарәп язуында): «Ерак Шәрык» (Харбин, 1920—1922), «Азад Шәрык» (1923), «Шәкердләр таңы» (Мукден, 1934—1935), «Игланыл хакыйкать» (Токио, 1936), «Шәрык авазы» (Тяньцзинь, 1939—1940), «Япун мөхбире» (Токио, 1931—1932), «Яңа япун мөхбире» (Токио, 1932—1945), «Рәсемләр мәҗмугасы» (Токио, 1937) журналлары; «Мең ел» (Харбин, 1922. Бер саны чыга), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934. Бер саны дөнья күрә), «Чаткы» (Харбин, 1932—1933), «Тәммүз» (Харбин, 1934), «Милли Байрак» (Мукден, 1935—1945) һ. б. гәҗитләр. Болар арасында Гаяз Исхакый тарафыннан нигезләнгән «Милли Байрак» аеруча игътибарга лаек (бу гәҗитнең мөхәррирләре һәм төп авторлары — Рокыя Мөхәммәдиш һәм Ибраһим Дәүләткилде. Болар — хәзерге татар дөньясының мәгълүм заты, Истанбул университеты профессоры Надир Дәүләтнең әти-әниләре). Финляндиядә исә татарча түбәндәге гәҗит-журналлар чыга: «Мәгърифәт» (атналык гәҗит. 16.01.1925—12.04.1925. Кими каласы. Мөхәррире — Хәсән Хәмидулла), «Шималь очкынлары» (1943—1977. Мәҗмуга әүвәл — Кимида, аннан Хельсинкида басыла. Чыгаручысы — Хәсән Хәмидулла), «Белдереш» (1948. Хельсинки. Мөхәррирләре — Гобәйдулла Мортазин, Зиннәт Алкара, Госман Али. Мәҗмуганың бары бер саны дөнья күрә), «Ак юл» (1967—1974. Оулу, Хельсинки. Гәҗитнең 63 саны чыга. Мөхәррире — Садрый Хәмид), «Тавыш» (1967. 1—6 саннар. Оулу. Гәҗитне Садрый Хәмид нәшер итә), «Финляндия ислам мәхәлләсе» (1949. 1—6 саннар. Тампере. Мәҗмуга-бюллетеньне Хәбибрахман Шакир һәм Фатыйх Арат чыгаралар), «Ислам мәхәлләсе» (1950—1951. 11 саны дөнья күрә. Тампере. Бу мәҗмуга — «Финляндия ислам мәхәлләсе» бюллетененең дәвамы), «Мәхәллә хәбәрләре» (1949—1963. Тампере—Хельсинки. Мәҗмуга-бюллетень. Финляндия ислам җәмгыяте тарафыннан нәшер ителә) һ. б.

Алманиядә дә татар телендә берничә гәҗит-журналның нәшер ителүе мәгълүм. Болар арасында Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә чыккан «Яңа милли юл» (23.XII.1928—IX. 1939) журналы аеруча мөһим. Ул, нигездә, Берлинда нәшер ителә. Берничә саны Варшауда да дөнья күрә. Иҗтимагый, сәяси, әдәби, гыйльми характердагы бу журнал — татар тарихының елъязмасы, милли-азатлык көрәшенең штабы. «Яңа милли юл»ның (ул 1930 елга кадәр «Милли юл» исемен йөртә) 136 саны чыга (барлыгы 4 мең бит тирәсе).

Алманиядә янә түбәндәге гәҗит-журналлар нәшер кылына: «Җиһател-ислам» («Ислам дөньясы», «Ислам илләре», Берлин, 1916. Гәҗитне чыгаручылар: А. Идриси, Р. Ибраһим), «Татар иле» журналы (15 көнгә бер чыга. 8 саны дөнья күрә. 1919. Б. Сәйфелмөлек), «Идел-Урал» гәҗите (1942—1944. Кыям Али), «Очар яфраклар» (гәҗит 1947—1948 елларда чыга. Мөхәррире — Абдулла Халикъ Алимзадә), «Азат Ватан» мәҗмугасы (1952—1953), «Милли Байрак» журналы (Мюнхен, 1953) һ. б.*

Мөһаҗир татарларның, Идел-Урал буеннан киткән галим-әдипләрнең төп өлеше — Төркиядә. Әмма шуңа да карамастан биредә татарча чыккан гәҗит-журналлар, китаплар Ерак Шәрык, Финляндия, Алмания белән чагыштырганда азрак. Бу, күрәсең, телләр якынлыгыннан һәм төрекләрнең башка төрки халыкларны төрекнең шивәсе («Казан төреге», «Кавказ төреге»…) дип каравыннан киләдер. Шулай да Төркиядә дә татарча яисә төрекчә-татарча катнаш телдә «Казан төрекләре» тарафыннан нәшер кылынган берничә гәҗит-журнал бар: «Мизан» (1908, Истанбул. Гәҗитнең мөхәррире — Морад бей), «Тәгърифи мөслимин» (Атналык әдәби мәҗмуга. 1910, Истанбул.— Р. Ибраһим вә А. Таҗеддин), «Ислам» (айга ике чыккан әдәби-дини мәҗмуга. 1914, Истанбул.— Н. Сабит), «Ислам дөньясы» (1910.— Казанлы таләбәләр мәҗмугасы. Истанбул), «Тукай бюллетене» (1965—1968, Истанбул) һ. б.

Төркиядә «Казан төрекләре» тарафыннан һәм алар өчен чыгарылган гәҗит-журналлар арасында «Казан» мәҗмугасы мөһим урынны алып тора. Ул 1970—1980 елларда нәшер кылына. Барлыгы — 23 сан. Журнал, нигездә, төрек телендә чыга. Әмма анда әдәби текстлар еш кына әүвәл — татарча, аннан төрекчә бирелә. Журналның авторлары һәм хезмәткәрләре арасында без Әхмәд Тимер, Надир Дәүләт, Мәхмүд Таһир, Наилә Бинарк һәм башка билгеле милләттәшләребезне очратабыз.

Шәркый Төркестанда, Румыниядә, Швециядә һәм татарлар яшәгән кайбер башка төбәкләрдә дә татарча гәҗит-журналлар чыгып алуы мәгълүм. Мәсәлән, Швециядә татарлар икенче бөтендөнья сугышы вакытыннан бирле яши. Сиксәнләп кеше. 1949 елда Стокгольмда «Швециядә дин һәм мәдәният эшләре буенча төрек-ислам» ассоциациясе төзелә. Бераздан «Швеция ислам җәмгыяте» дип үзгәртелгән бу оешма 1967 елда «Безнең фикер» исемле мәҗмуга да чыгарып ала.

Әлбәттә, чит илләрдә чыккан татарча гәҗит-журналлар үзләренең юнәлешләре белән төрле. Мәсәлән, «Яңа милли юл», «Милли Байрак»та сәяси як, Идел-Урал идеясе көчле. Ә инде айга бер мәртәбә чыгучы «Яңа япун мөхбире» журналы күбрәк дини, икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Хәтта аның 30 нчы еллардагы аерым саннарында Идел-Урал идеясенә, Гаяз Исхакыйга каршы материаллар да бар. Мәсәлән, бер мәкаләдә (1934.— № 21.— 49—51 б.) Токио имамы Корбангали хәзрәт белән Гаяз Исхакый арасындагы бәхәсләр чагылыш тапкан.

Эш шунда ки, 30 нчы елларның урталарында Гаяз Исхакыйның Ерак Шәрыкка килүе, милләттәшләребезне милли-азатлык көрәшенә чакыруы, корылтайлар уздыруы, «Милли Байрак»ка нигез салуы бу төбәктәге аерым шәхесләрнең каршылыгына очрый, бәхәсләр тууга сәбәпче була. Бу бәхәсләр билгеле бер дәрәҗәдә вакытлы матбугатка да үтеп керә.

Әмма, нәрсә генә булмасын, чит илләрдәге гәҗит-журналларда аерымлыкка караганда уртаклык, мәсләки якынлык көчле. Ул татар милләтенең язмышын үзәккә куюдан, халкыбызның бүгенгесе, киләчәге турында кайгыртудан гыйбарәт.

Ерак Шәрыкта, гәҗит-журналлар күпләп чыккан кебек, татарча китаплар да шактый гына дөнья күрә. Аларның саны дүрт дистәгә якыная. Бу китаплар, нигездә, Токиодагы «Матбагаи исламия»дә нәшер ителә. Арада Харбин, Мукден, Кобе калаларында чыкканнары да бар.

Ерак Шәрыкта басылган татар китаплары хакында инде без «Шәһри Казан» гәҗитендә дөнья күргән «Милләт бетмәсә, аның теле вә әдәбияты яшәр!» исемле мәкаләбездә (1992, 13 июнь) күп кенә мәгълүматлар биргән идек. Шуңа күрә биредә берничә фактны гына атап китәбез.

Менә минем алда «Кызларга махсус милли шигырьләр» китабы (Токио: Матбагаи Исламия, 1936.— 24 б. Бастырып таратучысы — Мөнирә ханым Сөләймания). Бу уку китабы кереш сүз белән башлана. Анда мондый юллар бар: бу — «кызларымызга уку өчен һәм дини, һәм милли рух бирү өчен сөйкемле бер әдәбият кисәгедер». Китапка матур эчтәлекле милли шигырьләр урнаштырылган: «Кыз балаларның теләге», «Укучы яшь кызга», «Укучы кызлар», «Имтихан алды», «Умарта корты», «Кем бәхетсез?» һ. б. Искәрмәдән күренгәнчә, китаптагы шигырьләрне Мөнирә ханым Сөләймания үзе язган. Аларның үзәгендә — Алланы зурлау, белем-мәгърифәткә өндәү, ата-ананы хөрмәт итү, милләт өчен көрәш һ. б. мотивлар. Үзләренең рухлары, эчтәлекләре белән бу шигырьләр XX йөз башы татар шигърияте белән турыдан-туры керешеп китәләр.

1933 елда Токиода Тукай әсәрләренең биш томлыгы дөнья күрә. Г. Ибраһимов һәм М. Корбангалиләрнең аерым дәреслекләре нәшер кылына. Болардан тыш, башка китапларның да басылуы мәгълүм: *Хөсәен Габдүш*. Дүрт хикәя.— Токио, 1931.— 83 б.; *А. Баттал.* Төрек-татар тарихы.— Мукден, 1938.—155 б.; *Солтан*. Шигырьләр.— Харбин, 1929.— 27 б.; *Исхак Хәйрулла*. Төш.— Харбин, 1922.— 20 б. һ. б.

Татар китапларының чит мәмләкәтләрдә иң күп чыккан урыны — Финляндия. Биредә бер меңгә якын гына милләттәшебез яши. Әмма шуңа да карамастан алар соңгы 50—60 ел эчендә генә дә 100 дән артык китап* нәшер иттеләр**. Мәсәлән, Нижгар ягында туып-үсеп, аннан Финляндиягә киткән Хәсән Хәмидулла (25.XI. 1900—6.XI. 1988) һәм Садрый Хәмиднең (11.X.1905—14.XII. 1987) үзләре язып бастырган китаплары гына да берничә дистә. Аларның күпчелеген оригиналь әдәби әсәрләр, җөмләдән шигырьләр, поэмалар, драмалар тәшкил итә. 70 нче елларда Гәүһәр апа Туганайның (ул 1911 елгы) ике кисәктән торган «Шигырьләр мәҗмугасы» дөнья күрде. Шунысын да әйтик: Гәүһәр апа — тумышы белән Баулы ягындагы Кәрәкәшле авылыннан. Татар мәдәниятен яхшы белә, хәзер дә иҗат эшен дәвам итә. Хөсәен Садыйк (1906—1973), Гайсә Хәкимҗан (1896—1972) һәм Финляндиядә яшәгән кайбер башка каләм әһелләренең дә оригиналь әсәрләре нәшер кылынган. Суомидагы татар китаплары әүвәл гарәп, соңгы елларда латин хәрефләре белән басыла.

Шунысы гыйбрәтле: Финляндиядә гомер кичерүче милләттәшләребез, гәрчә алар аз санлы булсалар да, инде менә 100 ел буена үзләренең телләрен, гореф-гадәтләрен, милли үзлекләрен шактый дәрәҗәдә саклап калганнар. Биредә, әлбәттә, ислам динен тоту, катнаш никахлар булмау белән беррәттән, татар китабының күпләп чыгуы вә укылуы да мөһим роль уйнаган.

Алманиядә, татарча гәҗит-журналлардан тыш, татарча китаплар да дөнья күрә: Программ. Русияле ислам шәкертләренә ярдәм җәмгыяте.— Берлин, 1918.— 12 б.; *Муса Ярулла Биги*. Исламият әлифбасы.— Берлин, 1920 (бу хезмәте өчен автор совет төрмәсенә дә утыртыла); Халык моңнары.— Берлин, 1932.— 16 б.; *Галимҗан Идрис*. Бугаз мәсьәләсе (Нинди итләр хәләл).— Берлин, 1933.— 16 б. 1937—1939 елларда Гаяз Исхакыйның Берлинда дүрт китабы нәшер ителә: «Дулкын эчендә» (70 б.), «Өйгә таба» (88 б.), «Җан Баевич» (70 б.), «Көз» (74 б.). Алманиядә, нигездә Мюнхенда, икенче бөтендөнья сугышыннан соң да берничә татар китабының чыгуы мәгълүм. Алар арасында Г. Тукайның «Шигырьләр» җыентыгы, Т. Дәүләтшинның «Татар әдәбияты», «Татар тарихы», «Татар халык җырлары», Минһаҗның ике кисәктән торган «Шигырьләр» китабы (I—1952; II—1968), Ш. Нигъмәтинең «Шигырьләр»е, шулай ук «Безнең өмет», «Безнең фикер» кебек мәҗмугалар бар (Казан.— 1978.— № 21.—55—56 б.). 1989 елда Алманиянең Висбаден каласында Тамурбәк Дәүләтшин, Ирма Дәүләтшин(а), Сәмих Тизҗанның «Татарча-немецча сүзлеге» нәшер ителде (365 б.). 17 меңнән артык сүзне үз эченә алган бу китап — татар дөньясы өчен уникаль күренеш. Әмма, кызганыч ки, бу кыйммәтле сүзлекнең безнең мәдәниятебезгә кирәклеге хакында моннан ике еллар элек язып чыксак та*, әле хәзергәчә аның илдәге студентларга, татар кешеләренә алдырылганы юк.

Илдә вакытта татарча китаплары белән мәшһүр булган Йосыф Акчура, Садри Максуди, Зәки Вәлиди, Габделбарый Баттал, Абдулкадыйр Инан, Төркиягә күчкәч, үз хезмәтләрен, шул исәптән татар тарихына һәм мәдәниятенә багышланганнарын да, нигездә, төрекчә язалар. Кайберләренең французча, немецча басылган китаплары да бар.

Гомумән, Төркиядә чыккан татарча китаплар бик аз. Боларга шагыйрь Исфәндияр Ишгайның «Җәһәннәмнән котылганнар» җыентыгын (Анкара, 1956.— 65 б.), Әхмәт Ләбиб Каранның «Шиһабеддин Мәрҗани: тормышы һәм әсәрләре» («Таң» матбагасы, 1960.— 79 б.), «Татарларның төп чыгышы» (Истанбул, 1962.— 96 б.)

монографияләрен һәм «Яшь вакытым җырлары» (Истанбул, 1959.— 96 б.), «Төшенчәмнең җырлары» (Истанбул, 1959.— 96 б.) кебек шигырь тупланмаларын һәм тагын берничә китапны кертергә мөмкин.

Кызганыч ки, башка мәмләкәтләрдә чыккан татарча китаплар хакында хәзергә мәгълүматларыбыз бик сыек. 1963 елда Әхмәд Гәрәйнең гарәп язуында ике кулъязма китабы Нью-Йоркта күбәйтеп таратыла. Аларның беренчесе «Ниләр, ниләр, тагы да ниләр» дип атала. Анда шагыйрьнең төрле елларда һәм калаларда (Каһирә, Хартум, Нью-Йорк) язылган берничә шигыре тупланган. Мәсәлән, авторның 1953 елда Күк Нил буенда иҗат иткән «Үрнәк» парчасыннан бер строфа:

Кыр казлары язда Африкадан
Урал якларына очалар.
Безнең илдә җәйдә кунак булып,
Күзгә каршы кире кайталар...

Алга таба шагыйрь кошлар язмышыннан кешеләр язмышына күчә, бердәмлектә, үзара ярдәмдә кыр казыннан үрнәк алырга чакыра: «Чөнки берлек, берлекдә зур куәт, Берләшкәнләр генә яшиләр».

Әхмәд Гәрәйнең Нью-Йоркта чыккан икенче китабы Американың мәшһүр шагыйрәсе Эмилия Дикинсоннан (Emily Diekinson. 1830—1886) тәрҗемәләрне үз эченә ала. Инглизчә һәм татарча текстлар янәшә бирелгән. Тәрҗемәче Америка шагыйрәсе белән Сания Гыйффәт (1899—1957) әсәрләре арасында бераз охшашлык таба һәм, мөгаен, шуңа күрәдер китабының ахырында татар шагыйрәсенең дә өч шигырен урнаштыра: «Тормыш көзгесе» драмасыннан, «Егерме ел элек ил» (Милләт Мәҗлесенең юбилее уңае белән) һәм «Актык теләк».

М. Госманов язуынча, Шәркый Төркестанда да (нигездә, Гөлҗа каласында) берничә татар китабы дөнья күрә. 1935—1936 елларда, мәсәлән, мәктәпләр өчен Малик Биктимеревнең «Җәгърафия» китабы һәм «Туган тел» дәреслек-хрестоматиясе бастырыла. 1947 елда Хәмит Төхфи (ул хәзер Ташкентта яши) тарафыннан Г. Тукайның «Сайланма шигырьләре» нәшер кылына*. Румыниядә, Болгариядә һәм кайбер бүтән илләрдә чыккан татар китаплары хакында кулыбызда конкрет мәгълүматлар юк.

**II**

Чит илләрдә гомер кичергән милләттәшләребез үзара аралашып, керешеп яшәгәннәр. Бер төбәктә чыккан татарча гәҗит-журналлар һәм басма китаплар да татарлар яшәгән икенче төбәкләргә тиз ирешкән, шулай итеп, рухи байлык та тиз арада уртак хәзинәгә әверелгән. Төрле күченүләр булуы да мәгълүм. Мәсәлән, Ерак Шәрыкта (Маньчжуриядә, Япуниядә, Кореяда...) яшәүче татарларның зур өлеше икенче бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә, АКШка, Австралиягә күчеп китә. Варшаудагы Идел-Урал татарлары да сугыш елларында, нигездә, дөньяның төрле төбәкләренә таралып бетә. Шәркый Төркестанда яшәүче милләттәшләребезнең 80 проценты 1954—1959 елларда СССРга әйләнеп кайта (Хәмит Төхфи, Миркасыйм Госманов һ. б.), ә кайберләре Төркиягә, Америкага, Австралиягә юнәлә. Хәзер Шәркый Төркестанда 4 меңләп кенә татарның яшәве мәгълүм.

Читтәге әдипләрнең дә шактые еш күченеп йөрергә мәҗбүр була. Мәсәлән, Гаяз Исхакый Төркиядә, Варшауда, Парижда, Лондонда, Ерак Шәрыкта һәм башка төбәкләрдә яши. Сания Гыйффәтнең дә илдән киткәннән соңгы яшәү географиясе шактый киң: Кытай, Төркия, Финляндия һәм янә Төркия. Ә инде Әхмәд Гәрәй — татар әдипләреннән дөньяны иң күп гизүчеләрнең берседер. Ул Үзбәкстанда туа, икенче бөтендөнья сугышында алманларга әсирлеккә эләгә, аннан — инглизләргә. Бераз вакыт Италиядә яшәп ала. Озак еллар гарәп илләрендә (Мисыр, Судан һ. б.) тора. Аннан — Төркиядә һәм АКШта.

Чит илләрдәге татар әдәбияты, татар матбугаты дип сөйләү — ул шактый дәрәҗәдә шартлы күренеш. Ни өчен? Чөнки бу — мәдәният төбе-тамыры белән татар язмышы, Идел-йорт белән бәйләнешле, ул бары тик бер үк гомумтатар мәдәниятенең үзгә тарихи шартларда яшәеш һәм дәвам ителеш формасы гына. Бу нәрсәләрдә күренә соң?

Беренчедән, чит илләрдә басылган татарча китаплар, гәҗит-журналлар, иң беренче чиратта татар укучыларын күздә тотып, татар кешеләре тарафыннан чыгарылган. Авторларга гына игътибар итегез: Гаяз Исхакый, Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Садрый Хәмид, Шаһвәли Келәүле (Илдәр), Исфәндияр Ишгай, Шиһап Нигъмәти, Гәүһәр Туганай, Әхмәт Ләбиб Каран, Минһаҗ Исмәгыйли һ. б.— болар бит барысы да илдә туып-үсеп читкә киткән кешеләр! Ә кайберләре Идел-йортта яшәгән вакытта ук әдип буларак танылалар. Чит илләрдә туып-үсеп, татарча иҗат иткән каләм әһелләре бик аз. Булганнары да — гаиләдә яисә мәктәптә татар тәрбиясе алган кешеләр. Мәсәлән, күп кенә пьесалар, дәреслекләр, гыйльми мәкаләләр авторы Наилә Бинарк 1940 елда Кореяда зыялы гына татар гаиләсендә туа, татар әдәбиятын укып үсә. Суомида татар балаларын укыта, Төркиядәге «Казан» журналында эшли. Ә инде читтә яшәүче хәзерге милләттәшләребез Гали Акыш, Надир Дәүләт, Фәрит Иделле, Фәридә Бичури, Окан Таһир кебек күренекле затлар, әдәби иҗаттан бигрәк, нигездә, гыйльми-публицистик яисә педагогик эш белән шөгыльләнәләр.

Икенчедән, һәм илдәге, һәм чит мәмләкәтләрдәге татар мәдәниятенең үзәгендә — милләт язмышы, татар халкының тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланулар, татар кешеләренең рухи халәте.

Өченчедән, читтәге әдәбият та меңәр ел буе тупланып килгән поэтик казанышларга, фольклор мирасына нигезләнеп үсә. Идел, Агыйдел, Казан, Сөембикә, Тукай, «Туган тел» — аның өчен дә изге образлар, якын төшенчәләр. Иң мөһиме — бер үк татар язма һәм сөйләмә теле һәм илдәге, һәм мөһаҗәраттәге әдәбият өчен уртак.

Чит мәмләкәтләрдәге һәм илдәге язма мәдәният бер-берсе белән никадәр генә якын, тыгыз бәйләнештә булмасын, алар үзара тәмам керешеп, таңгәлләшеп китмиләр.

Һәм мөһаҗәраттәге, һәм илдәге язма әдәбият үзгә иҗтимагый-тарихи шартларда туа һәм яши. Совет чоры әдәбияты өчен хас булган күп кенә темалар һәм проблемалар (күмәкләшү, хосусый милекчелеккә каршы көрәш,

партия җитәкчелеге, динне фаш итү, «интернационализм» һ. б.) читтәге гәҗит-журналларда һәм басма китапларда бик күзгә ташланмый. Булган очракта да алар башкачарак, тәнкыйди пландарак карала.

Билгеле булганча, Октябрьгә кадәрге татар әдәбиятында һәм вакытлы матбугатта милли-азатлык темасы шактый нык эшкәртелә һәм шуңа нисбәтән тормышта да татарның милли үзаңы зур үсеш ала. Кызганыч ки, Совет чорында, Мәскәү хакимиятенең коточкыч басымы нәтиҗәсендә, бу мөһим традиция өзелеп кала язды. Үз милләтен яратучы, аның тәрәккыяте өчен хезмәт түгүче «милләтпәрвәр», «милләтче» төшенчәләре тискәре мәгънә алды, хәтта илгә, халыкка дошман дәрәҗәсенә күтәрелде. Мөһаҗәраттәге каләм әһелләре исә инкыйлабкача традицияләрне дәвам итеп кенә калмадылар, милли азатлык, татар темасын, яңа сәяси-тарихи вазгыятьне исәпкә алып, тагын да тирәнәйттеләр, тагын да үстерделәр.

Соңгы елларда татарның үзаңы кузгалуда, милли-азатлык хәрәкәте көчәюендә, реаль тормыш белән беррәттән, мөһаҗәраттәге татар әдәбиятының һәм матбугатының да роле зур булды.

Фаҗигале татар тарихы өчен элек-электән туган җирдән, якыннардан аерылу хас. Мөгаен, шуңа күрәдер дә аерылу, сагыну — татар әдәбиятында һәм җыр-бәетләрендә иң эшкәртелгән мотивлар. Чит мәмләкәтләргә эләккән кешеләрдә сагыну тойгылары аеруча көчле. Бу мөһаҗәраттәге һәр каләм иясенең язмасында диярлек күренеп тора. Хөсәен Габдүш хикәяләрен илне, туган җирне сагыну симфониясе дип атарга мөмкин булыр иде. Аның «Үзебез өчен» әсәренең каһарманы Габдулла Сөембикә манарасыннан ничек итеп «орел»ны алуны сөйли дә ахырда моңаеп җырлап җибәрә.

Мөһаҗәраттәге татар язма мәдәнияте, нигездә, гарәп язуында; тел-стиле, лексик составы, грамматик төзелеше белән дә Октябрьгә кадәрге татар әдәби теленә якын тора. Совет чорында телебезгә кергән урыс сүзләре һәм алынмалары анда чагыштырмача аз. Җирле шивәләр дә шактый мул файдаланылган. Төрек теле йогынтысы сизелә. Хәтта Көнбатыш Европа телләренең аерым сүзләре дә төрек аша алынган. Кыскасы, мөһаҗәраттә туган язма истәлекләрдә тел-стиль ягыннан да бүген безгә гыйбрәт, тәҗрибә алырлык урыннар бар.

Мөһаҗәраттәге каләм әһелләренең язмаларында чит-ят җирләр, башка халыклар, аларның тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре дә теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапканнар. Бу яктан аеруча «Яңа япун мөхбире» журналы игътибарга лаек. Аның һәр санында бу мәмләкәткә мөнәсәбәтле материаллар, рәсемнәр бар. Менә журналның 1938 елгы апрель саны (# 61). Ул япуннарның сакура, ягъни чия чәчкәсе бәйрәменә багышланган. Бу хакта мәҗмуганың тышлыгында рәсем, ә 4—7 битләрдә «Япуниядә чия чәчкәсе» дигән махсус мәкалә бар. Язмада сакура бәйрәменең асылы аңлатыла. Мәкалә болай башлана: «Бөтен дөньяда Япуниягә чия мәмләкәте диләр... Япуниядә төрле төсле чәчкәле чия агачының үстерелүе вә һәр йирдә багчаларда тулы булуының меңьеллык тарихы бар…

…Чия чәчкәсе Япуниядә (мәркәздә) апрельнең уннарында ата башлый. Вә бер атна эчендә болыт кеби бөтен офыкны каплый вә дәхи бер атна эчендә коелып бетәдер. Япун самурайлары, үзләренә чия чәчкәсен үрнәк кылып, тормышлар вә чия чәчкәсе кебек күрсәтәчәк матурлыгыңны бердән тулы рәвешдә күрсәтеп, матурлыгың беткәч, мәйдандан югалу кирәк дигәннәр...» (4 б.)

Башка илләр, халыклар, аларның табигате, яшәү рәвешләре, тарихы хакында язмалар еш кына татар күзлегеннән, милләтебезгә мөнәсәбәттә карала. Әмма, гомумән, татар гәҗит-журналлары татарлар өчен генә түгел, ә кайбер башка илләрне, милләтләрне, халыкара вакыйгаларны һәм дөнья тарихи агышын өйрәнү өчен дә билгеле бер чыганак булып торалар. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Финляндиядә» мәкаләсе («Яңа милли юл».— 1937.— № 4—5) — Суоми тарихын һәм Финляндия-СССР мөнәсәбәтләрен тикшерүчеләр өчен дә менә дигән материал. Читтә чыккан татарча басмаларда, нәшер ителү урынына карап, финча, немецча, япунча, полякча, төрекчә язмалар да очрый.

Үзгә мәмләкәтләрдә татарча гәҗит-журналлар, китаплар чыгару эше, милли мәдәниятнең һәм мәгарифнең башка тармакларындагы кебек үк, халкыбызның үзе тарафыннан, үз хисабына башкарылган. Милләттәшләребез арасында Әхмәт Вәли Мәңгәр кебек бай, хәлле кешеләрнең (химаячеләрнең, ягъни спонсорларның) чагыштырмача аз булуы, сәяси киртәләр аркасында милли мәдәният һәм мәгариф эшләрен оештыру гаять авыр бара. (Гаяз Исхакыйның, Хөсәен Габдүшнең гәҗит-журналлар чыгаруга, китаплар бастыруга рөхсәт ала алмыйча, акча, мөмкинлек таба алмыйча өзгәләнүләре үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Әйтергә, язарга теләгән күпме сүз, күпме фикер югалып калган!) Әмма шуңа да карамастан халкыбызның зыялылары, милләтпәрвәрләре, матди, иҗтимагый-сәяси кыенлыкларны җиңеп, татарлар яшәгән һәр төбәктә, һәр илдә диярлек «Ислам», «Казан төрекләре», «Төрек-татар», «Сөембикә», «Тукай» һәм башка исемдәге дини, мәдәни, мәгариф җәмгыятьләре, берлекләре, оешмалары, мәркәзләре төзиләр, шулар ярдәмендә милли һәм рухи тәрбия эше алып баралар.

Чит мәмләкәтләрдәге татар әдәбиятын һәм матбугатын гомуми күзәтү дә шуны күрсәтә: туган тел мохитеннән, туган мәктәбеннән, туган җиреннән, асыл Ватаныннан аерылган мәдәният һәм аның әһелләре озак яшәми, күп дигәндә дүрт-биш дистә елда, икенче-өченче буында инкыйразга, ягъни бетүгә йөз тота. Күп кенә галим-әдипләр, киләчәк вазгыятьне алдан ук аңлап, тиз арада икенче телгә күчеп, үзгә милләт хадимчесе булып та китәләр. Моңа мисаллар читтә генә түгел, элеккеге СССР илендәге татарлар арасында да җитәрлек.

Башка мәмләкәтләрдә татар әдәбияты, татар матбугаты, татар мәктәбе хәзерге көндә яшәми дә, тумый да диярлек. Хәтта моңа кадәр бик күп кенә китаплар, гәҗит-журналлар чыгарган, без уңай яктан телгә ала торган Финляндиядә дә татар милли мәдәнияте бетүгә бара. Чөнки анда да хәзер татар мәктәбе юк, балалар, яшьләр, үзләре дә сизмәстән, кайвакыт финчага күчеп китәләр, татарчаны фин акценты белән сөйләшүче милләттәшләребез арта бара. (Әмма шулай булса да, Финляндия татарларына рәхмәт әйтергә кирәк: алар, ничәмәничә ел буе чит төбәктә яшәсәләр дә, туган телләрен саклап калганнар. Ә безнең милләт мәркәзендә, Казан татарлары арасында үз телләрендә акцент белән генә түгел, хәтта бөтенләй сөйләшә алмаучылар да буа буарлык. Бу — бик кызганыч хәл. Әмма рәхимсез чынбарлык.)

Без «татарлар күп, алар фәлән миллион», «безнең халык бөтен Союзда, бөтен дөньяда яши» дип сөйләргә, хәтта мактанып алырга да яратабыз. Әмма халыкның таралуы, сибелүе һич тә мактана, горурлана торган әйбер түгел. Чөнки ул — милли фаҗига. Таралган, сибелгән халыкның, этник берлек буларак, киләчәге өметсез,— ул иртәме, бераз соңмы барыбер бетәчәк, ассимиляцияләнәчәк, башка милләтләр тарафыннан йотылачак. Ерак мәмләкәтләрдәге татарларны гына түгел, Магадандагы, Санкт-Петербургтагы, Донбасстагы, Кузбасстагы һәм элеккеге Союзның Идел-йорттан башка бик күп төбәкләрендәге татарларны да киләчәктә әнә шул язмыш көтә.

Милләт яшәсен өчен, аның теле, мәктәбе, мәдәнияте, дине, гореф-гадәтләре яшәргә тиеш. Моның өчен исә халыкның чагыштырмача оешып, милли мохит тудырып яшәве, үз язмышына үзенең хуҗа булуы зарури. Озак гасырлар буе бөтен дөньяга таралган яһүдләрнең Израиль дәүләтенә көннән-көн ныграк туплана барулары, совет немецларының Алманиягә күпләп күченүләре — башка халыклар, шул исәптән татарлар өчен дә гыйбрәтле мисал. Бу уңай белән, ирексездән, Гәрәй Рәхимнең «Татар кешесе» шигыре хәтергә килә. Автор татарларның Иделне, үз йортын калдырып, бөтен дөньяга сибелүен тасвирлый да ахырда болай ди:

Болай каңгырып йөрмә,
Кайт син туган илеңә,
Борынгылар түренә.
Бит куй Идел җиленә,
Баш куй Болгар җиренә,
Әйдә, татар кешесе!

* * *

Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты — рухи мирасыбызның мөһим бер өлеше. Ул мәдәниятне һәм әдәби процессны тулыландырып кына калмый, ә халкыбызның рухи тарихын, үткән катлаулы юлын, башка илләр һәм милләтләр белән бәйләнышларын киңрәк, тагын да тулырак, ачыграк итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Анда бүгенге көнгә аваздаш яклар да күп. Шуңа күрә мөһаҗәраттәге язма истәлекләрне өйрәнү, аларны хәзерге укучыларга җиткерү — татар фәне алдында торган мөһим бурычларның берсе.

Чит илләрдәге язма истәлекләрне тудыручыларның күпчелеге катлаулы язмышка ия. Әмма бу хәл аларны гыйльми өйрәнүдә, гадел бәяләүдә киртә булырга тиеш түгел. Чөнки бу шәхесләр үзләре дә, аларның язганнары да хәзер тарихи факт, объектив күренеш итеп каралырга тиеш. Фән исә, билгеле булганча, иң беренче чиратта факт-мәгълүматлар белән эш итә.

Читтәге язма истәлекләрнең әдәби дәрәҗәләре төрлечә. Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүшләрнең талантлы язмалары белән беррәттән, поэтик яктан зәгыйфь ядкярләр дә шактый очрый. Әмма биредә дә бер хакыйкатьне истә тотарга кирәк: теләсә нинди әсәр, китап,— ул нинди генә булмасын, безнең язма мирасыбызның бер өлеше, бер элементы. Шуңа күрә үткәндәге мәдәни ядкярләрне без мөмкин кадәр тулырак, бөтенрәк алырга бурычлы.

*1992*

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ӘДӘБИ-ПУБЛИЦИСТИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Бөек әдипнең тормыш юлы шактый озын, катлаулы, җәя кебек киеренке. Ул, ничектер, дистәләгән кешенең гомерен үзенә җыйган, алар өчен дә яшәгән, эшләгән кебек. Аның тереклегендәге һәр көн атнага, айга тиңләшердәй. Анда куаныч-шатлыклар белән бергә, кайгы-газаплар да, төрмә-сөрген изүләре дә, күчеш-мөһаҗирлек мәшәкатьләре дә, ялгызлык-җирсү сагышлары да җитәрлек. Әмма Гаяз Исхакый Идел-йортта гына түгел, Архангел — Петербургта да, Париж — Берлинда, Варшау — Хельсинкида да, Иерусалим (Кодес) — Каһирә, Токио — Мукденда да, Анкара — Истанбулда да…— барысында да үзе булып, эзләнүчән, горур табигатьле, кыю, халкына тугры милләтпәрвәр булып кала.

Моңа кадәр дә кече Ватаны — Идел-йорттан шактый аерылып торган Гаяз Исхакый 1919 елда олуг Ватаныннан да тәмам китәргә мәҗбүр була һәм 76 еллык гомеренең яртысын диярлек чит-ят җирләрдә уздыра, мәңгелек йортын да еракта таба.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге күпкырлы. Ул — әдип, публицист-журналист, тарихчы, сәясәтче, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, милли-азатлык көрәшенең юлбашчысы, төрки дөньяның абруйлы заты. Бу тармакларны Г. Исхакыйның олы шәхесе, иман-ышанычы, мәсләки кыйбласы үзара берләштереп, табигый бер бөтенлек тудыра.

Г. Исхакый, кайда гына яшәмәсен, иң беренче чиратта әдип булып кала. Ул аны үзенең намус эше, халкы алдында вөҗдани бурычы дип саный. Дөрес, илдәгегә караганда аның мөһаҗирлектә язылган әсәрләре артык күп түгел. Күрәсең, тиешле шартлар булмау, иҗат җимешен бастыру, тарату кыенлыклары да монда билгеле бер роль уйнагандыр. Әмма Г. Исхакыйның бу чордагы әдәби иҗаты, гәрчә күләм ягыннан азрак булса да, идея-эстетик кыйммәте, иҗтимагый әһәмияте белән шактый югары. «Көз», «Дулкын эчендә», «Өйгә таба», «Локман Хәким», «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд»… — боларның һәрберсе тирән мәгънәгә, тарихи-мәдәни яңгырашка ия. Миллилек, гомумән, Г. Исхакый иҗатына хас. Ә инде мөһаҗирлек иҗатында ул тагын да тирәнрәк, тагын да калкурак гәүдәләнеш таба. Автор кавем яшәешен аның рухи көрлеге, мөстәкыйльлеге, хәтер дәвамчанлыгы, милли традицияләргә тугрылыгы белән табигый бәйләнештә карый. «Олуг Мөхәммәд» драмасында әдипнең милли-иҗтимагый һәм сәяси идеаллары аеруча калку гәүдәләнеш тапкан. Автор фикеренчә, урысларның һәм татарларның нормаль, табигый яшәеше бары тик аларның мөстәкыйль дәүләтләре, үзара тигез хезмәттәшлекләре, ихтирами мөнәсәбәтләре белән генә тәэмин ителә ала.

Г. Исхакыйның бу чор әсәрләре драматик вакыйгаларга, гыйбрәтле язмышларга гаять бай. Разыя, Нәфисә, Гөлсем, полковник Тимергалиев, Җан Баевич… — боларның һәммәсе үз холык-фигыле, психологик халәте, тормышчанлыгы белән аерылып тора. Җан Баевич образы хәтта милләтеннән йөз чөереп, космополитизм юлына басучыларның бер тибы рәвешен алган. Локман Хәким — әкияти-мифологик чаралар ярдәмендә тудырылган җыйнама-символик образ. Г. Исхакый мөһаҗирлек чорында, хикәя, повесть, сәяхәтнамә жанрлары белән беррәттән, комедия, драма шәкелендәге әсәрләр дә яза. Хәтта аларга билгеле бер өстенлек тә бирә. Бу, күрәсең, чорның катлаулылыгы, алынган вакыйгаларның эчке киеренкелеге, драматик табигате белән дә аңлатыла.

Мәгълүм ки, Г. Исхакый илдә вакытта ук әдәби иҗатын журналистлык, публицистик эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә алып бара. Төрле гәҗит-журналларда язышa, үзе дә «Таң йолдызы», «Тавыш», «Ил», «Сүз», «Маяк» кебек гәҗитләрнең мөхәррире булып эшли. Г. Исхакый өчен вакытлы матбугат милли яшәеш өчен сулый торган һава кебек зарури. Аның фикеренчә, «Бер халыкның матбугаты — шул халыкның күңелендә җыелып яткан теләүләрнең-арзуларның тәрҗеманы. Бер халыкның матбугаты — шул халыкның эчендә агып йөри торган фикерләр, мәсләкләр, уйлар, төшенчәләрнең көзгеседер» (Ил.— 1913.— 22 октябрь).

Илдән киткәч, Г. Исхакый өчен, мөгаен, иң газаплысы милли матбугаттан аерылу булгандыр. Чөнки аңа үзенең уй-кичерешләрен, тәэсир-мөнәсәбәтләрен гавамга җиткерү өчен мәйдан юк дәрәҗәсендә. Бөек әдип башка телләрдәге аерым гәҗит-журналларда язышырга мәҗбүр була, Төркиядә нәшер ителүче «Төрек йорды» мәҗмугасында да берара эшләп ала. Әмма болар гына Г. Исхакыйның милли матбугатка сусавын баса алмый. Һәм, ниһаять, ул мең кыенлыклар белән «Яңа милли юл» (әүвәл — «Милли юл» исемендә) журналын чыгара башлый. Гарәп хәрефләре белән 1928—1939 елларда Берлинда нәшер ителгән бу мәҗмуга (барлыгы — 136 сан) чын мәгънәсендә елъязма, энциклопедия кебек (бу хакта карагыз: *Х. Миңнегулов.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004). Биредәге материалларның күпчелеге баш мөхәррирнең үзе яисә аның катнашында язылган. Шуңа күрә бу журнал Г. Исхакый тормышының һәм иҗтимагый-публицистик эшчәнлегенең гаять мөһим бер дәверен тәшкил итә. (Әлеге журнал турында тулырак мәгълүмат «Азатлык көрәшенең мөнбәре» мәкаләсендә бирелде.)

Г. Исхакый — татарның өлге рәвешендәге милләтпәрвәре. Әмма «Яңа милли юл» милли кысалар белән генә чикләнми, күп кенә халыкларның күренекле затлары хакында да материаллар урнаштырып бара. Болар арасында урыс, Аурупа, ислам дөньясының әдипләре, галимнәре, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре бар. Мәҗмугада аеруча төрки дөньяга, төркиләрнең рухи кардәшлеген, үзара мөнәсәбәтләрен яктыртуга зур урын бирелә.

1935—1945 елларда Кытайның Мукден каласында «Ерак Шәрык мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе» тарафыннан «Милли Байрак» гәҗите нәшер ителә. Ул — үзенең эчтәлеге, рухы белән «Яңа милли юл» журналының фикердәше, дәвамчысы. Бу аңлашыла да. Чөнки «Милли Байрак» Г. Исхакый тарафыннан нигезләнә, һәм ул аның тәүге мөхәррире дә була.

Билгеле булганча, узган гасырның 20—50 нче елларында Кытайда, Алманиядә, Финляндиядә татарча кайбер башка гәҗит-журналлар да чыга. Аларга да Г. Исхакыйның теге яки бу дәрәҗәдә тәэсире бар. Бу аеруча 1952—1953 елларда Мюнхенда нәшер ителгән «Азат Ватан» журналында ачык күренә. Анда әдипнең үзе турындагы язмалар һәм аның үз мәкаләләре дә урын алган. Татарча гәҗит-журналлардан тыш, Г. Исхакый 30—40 нчы елларда гарәп, төрек һәм кайбер башка телләрдәге көндәлек матбугатта да чыгышлар ясый.

Әдипнең мөһаҗирлектәге гыйльми-публицистик эшчәнлегендә аның «Идел-Урал» китабы мөһим урынны алып тора. 30 нчы елларда француз, инглиз, поляк, япун… телләрендә дөнья күргән бу хезмәттә татар халкының дәүләтчелек һәм этник тарихы, мәдәнияте, колониаль коллыкка төшүе, милли бәйсезлек өчен көрәше, Идел-Урал мәмләкәтен төзергә омтылышы ачык һәм үтемле итеп бәян ителә.

Г. Исхакый,— Тукай белән бергә, яңа дәвер татар әдәбиятының, реалистик сүз сәнгатенең юлбашчысы. Мөһаҗирлектә дә ул үзенең остазлыгын саклап калды. Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Ләбиб Каран, Исфәндияр Ишгай, Минһаҗ Исмәгыйли һәм мөһаҗирлек-
тәге кайбер башка татар әдипләре — Г. Исхакый иҗат мәктәбенең шәкертләре, аның мәсләктәшләре. Аларның тырышлыгы белән XX йөз башы татар әдәбиятына хас булган милли рух, милли идеаллар Совет чоры мөһаҗир сүз сәнгатендә уңышлы дәвам иттерелде, чынбарлыкка тапкыр рәвештә тагын да үстерелде. XX гасыр азагында Идел-йортта милли хәрәкәтнең көчәеп китүендә, әлбәттә, Г. Исхакыйның һәм аның көрәштәшләренең мөһаҗирлектәге рухи мираслары, тәҗрибәләре дә мөһим роль уйнады.

* * *

Туып-үскән җир, милли тел, моң, гореф-гадәтләр инсанның тәненә, җанына сеңә, аның яшәү рәвешен билгели. Г. Исхакый — моның ачык бер мисалы. Ул, туган җиреннән китеп, чит-ят мәмләкәтләрдә яшәсә дә, җаны, күңеле белән һәрчак Идел-йортта, туган халкы янында булды. Бөек әдип татар өчен тырышты, янды, көйде, матди якка кызыгып, туган халкы мәнфәгатьләренә хезмәт итүдән бер карыш та читкә тайпылмады. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә язылган әсәрләре, мәкалә-китаплары — татар рухи мирасының, милли сүз сәнгатенең кыйммәтле бер өлеше. Алар — халкыбызның юлдашы, киңәш-табыш бирүчесе.

*2004*

## АЗАТЛЫК КӨРӘШЕНЕҢ МӨНБӘРЕ

«Яңа милли юл» дөньяның караңгы вә чуалчык юлларында бик күпләргә милли юлын күрсәтә торган Тимерказык йолдызы булып килә алгандыр.

*Гаяз Исхакый*

Инкыйлабтан соң чит илләрдә чыккан татарча гәҗит-журналлар арасында «Яңа милли юл» мөхтәрәм урынны алып тора. Ансыз татарның мәдәниятен, милли-азатлык көрәшен һәм, гомумән, тарихын тиешенчә күзаллап та, бәяләп тә булмый. Ул халкыбызның энциклопедиясе, көрәш елъязмасы кебек. Нәкъ менә шуңа күрә дә татар мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүче чит мәмләкәт галимнәре «Яңа милли юл»га еш мөрәҗәгать итәләр, аны, ышанычлы чыганак буларак, бик теләп файдаланалар. Бездә дә соңгы вакытта аннан аерым материаллар укучыларга тәкъдим ителә башлады. Әмма әле, кызганыч ки, укучыларның гына түгел, күпчелек татар белгечләренең дә «Яңа милли юл» хакында күзаллаулары бик тонык. Шуны күздә тотып, без бу мәкаләдә журнал хакында аерым белешмәләр бирергә, кайбер фикерләр әйтергә җөрьәт итәбез.

«Яңа милли юл» мәшһүр әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый исеме белән тыгыз бәйләнешле. Ул — бу журналны нигезләүче, аның баш мөхәррире һәм төп авторларыннан берсе. Дөрес, мәҗмуганың 1—19 нчы саннарында журналның «мәсьүл редакторы К. Русак» диелгән. Бу — Гаяз Исхакыйның йә үз кушаматы, яисә рәсми якны күздә тотып куелган башка берәр зат. Чөнки журналны оештыручының һәм тәүге саннарыннан ук аны җитәкләүченең Гаяз Исхакый булуы шөбһәсез. Мәҗмуганы чыгаруга шулай ук баш мөхәррирнең «Учительская школа»дан ук якын дусларыннан берсе булган Гомәр Тәңреколый да (Терегулов) үзеннән зур өлеш кертә.

Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакый 1927—1939 елларда, нигездә, Варшау, Берлин калаларында яши. Ерак Шәрыккка да шул чорда, ягъни 1933—1936 елларда сәяхәт кыла, Токио, Кобе, Харбин, Хайлар, Мукден һәм башка шәһәрләрдә була. Бу еллар — эмиграциядәге милли-азатлык һәм сәяси хәрәкәтнең көчәеп, тагын да оешып киткән дәвере. 1928 елның 28 июнендә Варшауда Гаяз Исхакый инициативасы белән Идел-Урал комитеты корыла. Ике елдан соң, ягъни 1930 елда, Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Азәрбайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли-азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора.

Бөек әдип фикеренчә, хәзерге заманда матбугатсыз халык телсез, вәхши халык кебек. Иҗтимагый-сәяси көрәштә вакытлы матбугатның ролен шәхси тәҗрибәсендә тирәнтен аңлаган Гаяз Исхакый 1928 елгы Варшау корылтаенда гәҗит-журналлар чыгару бурычын бөтен кискенлеге белән куя. Бер төркем милләттәшләренең матди һәм рухи ярдәме белән ул үзе «Милли юл» мәҗмугасын чыгаруга керешә. Аның 1 нче саны — 1928 елның 23 декабрендә, ә икенчесе 1929 елның 15 гыйнварында дөнья күрә. Журнал 1930 елга кадәр айга ике мәртәбә «Милли юл» исеме белән чыга, инде алга табан ул «Яңа милли юл» атамасын ала һәм, кагыйдә буларак, айлык мәҗмугага әверелә. 11 еллап вакыт эчендә журналның барлыгы 136 саны дөнья күрә, шуның берничәсе — куш саннар (1929: № 20—21, № 22—23; 1933: № 8—9; 1935: № 9—10; 1938: № 8—9…). Текстлар — гарәп графикасында. Тышлык битләрдә латин хәрефендәге сүзләр, атамалар һәм белешмә характерындагы немецча текстлар да күзгә ташлана. Мәҗмуганың теле татарча. Әмма Кырым татарлары, төрек һәм кайбер башка төрки телләрдә бирелгән өзекләр, текстлар да бар. Журналның форматы — 24 ә 16,5 см. Күләме — 15 көнгә бер чыкканда — 16 шар бит (куш саннары — 26 битлек), айлык саннары 1930—1932 елларда — 26, ә алга таба, кагыйдә буларак, 32 битлек. Арада 38 һәм 42 битлек саннар да очрый. Мәҗмуга юка тышлыкта чыга.

Журнал, нигездә, Берлинда (Штеглитз, Миквелштрассе, 14) нәшер кылына. Аның 1929 елгы 20—21 нче куш санында шушындый белдерү бар: «Мәҗмугамызның башкарма йортын (идарәханәсен) Берлиндан күчерергә туры килде. Әлегә төпле бер башкарма йорт табылганга кадәр «Милли юл» өчен йибәреләчәк акча, хат, мәкалә вә башкаларны түбәндәге адреска йибәреп торуларын бөтен укучыларымыздан үтенәмез» (биредә Гаяз Исхакыйның Польшадагы адресы күрсәтелә). «К. Русак» исеменең Гаяз Исхакый атамасы белән алышынуы, күрәсең, матди һәм кайбер башка факторлар белән бәйле булса кирәк. Мәҗмуганың 1929—1930 еллардагы берничә саны Варшаудагы ике адрес белән дөнья күрә. Ә инде журналның 1930 елның ноябреннән алып ахырга, ягъни 1939 елның октябренә кадәр чыккан саннары Берлинда (Шарлоттенбург, 1. Постфак № 8) нәшер ителә. Монда гарәп хәрефләре белән китаплар, гәҗит-журналлар чыгаручы «Виктория» дигән махсус нәшрият булуы мәгълүм. Гаяз Исхакыйның «Дулкын эчендә» исемле биш пәрдәлек пьесасы да шунда нәшер ителә (1938). Биредә кайбер башка төрки халыкларның да китаплары, аерым гәҗит-журналлары чыгуы билгеле. (Бу елларда Берлинда мөселман мәчете дә эшли.)

Журналның матди хәле шактый кыен була. Ул, нигездә, чит илләрдәге милләттәшләребез ярдәме хисабына яши, һәм шуңа да аны Гаяз Исхакый «Милләт баласы» дип атый.

Мәҗмугадагы материалларның авторлар даирәсе шактый киң һәм төрле. Алар,— нигездә, эмиграция нәтиҗәсендә дөньяның төрле почмакларына, аеруча Кытайга, Япуниягә, Төркиягә, Финляндиягә, Алманиягә, Ляһстанга, Румыниягә сибелгән татарлар. Авторлар арасында без Сания Гыйффәт, Закир Кадыйри, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Ләбиб Каран кебек билгеле каләм әһелләрен дә, Финляндиянең Вәли Әхмәд Хәким шикелле мәшһүр имамын да, Ерак Шәрык милли хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, «Милли Байрак» гәҗитенең мөхәррире Рокыя Мөхәммәдишне, Тампере татарларының мәдәни тормышын оештыручы Мәхрусә Вафаны һәм башкаларны очратабыз. Журнал эшен оештыруга, рәсми хакимият оешмалары белән мөнәсәбәтләрен коруга мәшһүр галим Рәшит Рәхмәти Арат та шактый ярдәм күрсәтә. Мәҗмугада «Котлы Мөхәммәд», «Бикбулат», «Лотфулла угылы», «М. Уфа» кебек исемнәр белән басылган мәкаләләр дә байтак.

Журналдагы шактый күп санлы материал Гаяз Исхакыйның үзе тарафыннан язылган. Кыскасы, «Яңа милли юл» журналын Гаяз Исхакыйның милли-азатлык өчен көрәш мөнбәре, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни эшчәнлегенең елъязмасы дип тә атарга мөмкин.

* * *

Ә соң мәҗмуганың идея-тематикасы, эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Әйткәнебезчә, 11 еллап вакыт эчендә журналның 136 саны дөнья күрә. Бу — якынча 4 мең бит дигән сүз. Шуңа күрә бу кадәр зур күләмле һәм төрле характердагы, эчтәлектәге материаллар хакында тәфсилле фикер йөртү бу очракта мөмкин дә түгел. Сүз бары тик журналның төп юнәлеше, үзәк тематикасы, төп рубрикалары, кайбер бүтән мөһимрәк яклары хакында гына барырга мөмкин.

«Милли юл»... «Яңа милли юл»... Бу атамалар үзләре үк мәҗмуганың төп юнәлешен күрсәтеп торалар. Милли тарих, халык язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге — менә журналның гомуми тематикасы. Журнал исеменең «Милли юл»дан «Яңа милли юл»га әйләнүе дә очраклы түгел. Яңа вазгыять, яңа халыкара шартлар төрки-татар язмышына яңачарак якын килүне, аның барыр юлын ачыграк, максатны конкретрак куюны таләп итә. Төп максат — милләтләрнең азатлыгы, тигезлеге өчен көрәш, һәр халыкның үзенең бәйсез дәүләтен төзү. Журналның 1933 ел 10 нчы санында Спинозаның мондый сүзләре теркәлгән: «Ирек — бер көч димәктер. Бу көч — һәр халыкның үзен үзе үстерү көче; боңа һәрбер мәхлук та (җан иясе дә.— *Х. М.*) табигате илә омтыла». Мәҗмуга битләрендә һәм төркестанлыларның, һәм украиннарның, һәм кавказлыларның, һәм күп кенә башка халыкларның азатлык, бәйсезлек өчен көрәше эзлекле рәвештә яклана; барын да хөр булганда гына, мөстәкыйль дәүләтчелеккә ирешү мөмкинлеге күрсәтелә. Мәҗмуганың тышлыгында еш кына «Ирекле ил уен таратучы журнал» дигән сүзләр очрый. Бу — гадәти лозунг кына түгел, ә текстларның эчтәлеге, рухы белән ярашкан төп идея дә.

«Яңа милли юл» журналының һәр санында диярлек тышлыкта түбәндәге сүзләр язылган: «Идел-Уралның истикъляльна хезмәт итүче, илнең һәм халыкның матди вә мәгънәви барлыгы һәм аның киләчәге тугрындагы фикерләрне эченә алган һәрбер язма өчен мәҗмуга битләре һәркемгә ачык». Журналда Идел-Урал, «Идегәй» дастанындагы кебек, татар дәүләте Идел-йорт рәвешендә күзаллана, аның бәйсезлек яулап алуы, мөстәкыйль тормыш коруы бөтен эшчәнлекнең, көрәшнең асыл максаты итеп күрсәтелә. Әмма әле чынбарлык башка: Идел-Урал, татар халкы — Мәскәү хакимияте, Сталин режимы астында. Бу хәл журналның тышлык рәсеме белән дә искәртелә: «Идел-Урал» харитасы (картасы), ә ул — зинданда, читлек эчендә. «Яңа милли юл» сүзләрендәге «л» хәрефенең озын сызыклары нәкъ әнә шундый символик мәгънә тудыруга ярдәм итәләр дә.

Журналның һәр санында диярлек агымдагы халыкара хәлләргә күзәтү бирелә һәм шул контекстта төрки-татар язмышы карала. Бу төр мәкаләләргә (алар, нигездә, баш мөхәррир тарафыннан язылган) киң колач, фикер тирәнлеге, көчле публицистик аһәң хас.

Мәскәү хакимияте, аның кул астындагы матбугат органнары дөнья җәмәгатьчелегенә илдәге объектив хәл, аеруча милләтләр язмышы хакында берьяклы хәбәр бирү белән генә чикләнә. Әмма шуңа да карамастан «Яңа милли юл», бар булган рәсми, басма (бигрәк тә төрки җөмһүриятләрдәге) мәгълүматларны җентекле тикшереп, СССРдагы әхвәл, төрки-татарларның хәле турында даими рәвештә материаллар биреп килә. Аларда Совет хакимиятенең урыслаштыру сәясәте, халыкның диненә, тарихи хәтеренә каршы көрәше, эзәрлекләү эш-гамәлләре кискен тәнкыйтьләнә. «Дин вә милләт,— диелә бер мәкаләдә,— халкымызның большевиклар дәверенә кадәр иң мөкатдәс дип белгән рухи барлыгы иде, һәм шуның берлә ул үзен 300 елдан артык саклады, киләчәккә өмидне өзмичә яши иде. Бүген дин вә милләт большевикларның иң курыккан каршылыгы булып тора» (1935.— № 2.— 2 б.). Шул ук санда без «совет статистикасының ышанычсыз» булуы (11 б.), уку йортларында «урыс тарихы»ның гына өйрәнелүе (15 б.) һәм башка шундый тәнкыйди фикерләр белән дә очрашабыз.

Журнал төрки-татар халкының күренекле уллары хакында да материаллар биреп бара. Мәсәлән, мәҗмуганың 1933 елгы дүртенче саны Исмәгыйль Гаспралының һәм Габдулла Тукайның үлемнәренә — 20, «Тәрҗеман»ның чыга башлавына 50 ел тулуга багышланган. Гаять тирән эчтәлекле, сурәтләргә һәм мәгълүматларга бай сан! Журналның 1936 елгы июль-август саннары (№ 7—8) тулысы белән Ризаэддин Фәхреддин хакында. Шулай ук «Яңа милли юл»да Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдерәшит Ибраһим, Йосыф Акчура, Фуад Туктар һәм татарның башка олуг затлары турында да мәгълүматлар шактый. Шунысы мөһим: аларның эшчәнлеге заманга, милли үсеш перспективасына нисбәтән карала. Мәсәлән, Мәрҗанинең тууы халкыбыз өчен кояш чыгу белән чагыштырыла. Аның «милли-дини ачык фикерле төшенчәләре, диелә бер мәкаләдә, бүген мең бер төрле авырлык эчендә яши торган халкымызга золымның чиген белмәгән дошманга каршылык күрсәтү өчен кирәкле булган гамәлләрнең берседер... Мәрҗани хәзрәтнең соңгысыз («үлмәс») хезмәтләрендән илһам алып, аның безгә калдырып киткән милли-дини иманындан куәт алып, бүгенге көндәге һичбер нәрсәдән өрекмичә, башка дин вә милләт кардәшләремез берлә бергә үземезнең милли вә сәяси корытылышымызны таләп итәбез» (1935.— № 12.— 3 б.).

«Яңа милли юл» халык тарихындагы, мәдәниятендәге истәлекле вакыйгаларны даими рәвештә яктыртып тора. Мәсәлән, журналның 1938 елгы 3 нче саны тулысы белән Милләт Мәҗлесенең егерме еллыгына багышлап чыгарылган. Анда 1917—1918 елгы тарихи вакыйгаларга анализ ясала, Милләт Мәҗлесенең халык язмышындагы, барыр юлындагы әһәмияте күрсәтелә. Билгеле булганча, бу юбилей уңае белән 1938 елда Варшауда Бөтендөнья төрки-татар корылтае уздырыла. Журналның бу санында юбилей хакында бай материаллар урнаштырылган. Алар арасында Гаяз Исхакыйның Варшау радиосыннан алтынчы февральдә ясаган чыгыш тексты да бар.

Мәҗмугадагы бер өлеш мәкаләләр — чит мәмләкәтләрдәге татарлар, аларның иҗтимагый вә мәдәни хәлләре хакында. Бу юнәлештә аеруча Финляндиядә һәм Ерак Шәрыкта яшәүче милләттәшләребезнең тормышы киң яктыртыла. Мәсәлән, бер хәбәрдә (1937.— № 4.— 9—11 б.) 1937 елның 22 гыйнварында Нагоя каласында яңа мәчет вә мәктәп ачылу тантанасы хакында сүз бара. Шунысы кызыклы: күп санлы милләттәшләребез һәм Япуния рәсми кешеләре катнашкан бу кичә татар телендә уздырыла. Аерым якташларыбыз япун телендә дә сөйлиләр. Бу истәлекле вакыйганы Япуния матбугаты да игътибардан читтә калдырмый.

Журналда әдәби материалларга да урын бирелгән. Анда без фольклор, классик шигърият үрнәкләре белән очрашабыз. Күпчелек әдәби текстлар Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Мансур Арсланбәк һәм кайбер башка мөһаҗир татарларга нисбәтле. Күләмле әдәби әсәрләр күзгә ташланмый. Мәҗмуга шулай ук татарларның һәм, гомумән, төрки халыкларның мәдәният тарихына мөнәсәбәтле мөһим язма истәлекләр хакында да мәгълүматлар биреп бара («Олуг Мөхәммәд ханның солтан Морадга язган мәктүбе», «Ибне Батутаның Алтын Урда хакында биргән мәгълүматы» һ. б.).

Тугандаш төркестанлылар, кырымлылар, төрекләр һәм башка халыкларның тормышын яктырту — журналның даими рубрикасы. Еш кына аларның чит мәмләкәтләрдә чыккан вакытлы матбугатына күзәтүләр бирелә. Мәсәлән, Кырым татарлары телендәге «Әмәл» журналына (ул Румыниянең Күстәнҗә каласында айга бер мәртәбә чыга), «Истикълял» гәҗитенә (Берлинда айга өч тапкыр чыга), Франциядәге айлык «Яшь Төркестан» журналына һ. б. басмаларга күзәтүләр ясый.

Билгеле булганча, 1935 елның 1 ноябреннән Мукден каласында «Милли Байрак» исемле атналык татарча гәҗит чыга башлый (гарәп графикасындагы бу басма 1945 елның урталарына кадәр нәшер кылына. Барлыгы 440 саны дөнья күрә)*. Аны оештыручы, нигезләүче дә — Гаяз Исхакый. Һәм «Милли Байрак», һәм «Яңа милли юл» үзләренең мәсләкләре, рухлары белән үзара бик якын. Шуңа күрә алар бер-берсенә еш урын бирешеп торалар. Мәсәлән, «Яңа милли юл»да (1935.— № 12.) «Милли Байрак»ның беренче санына җентекле күзәтү урнаштырылган, Гаяз Исхакый тарафыннан язылган «Максадымыз», мөхәррир Рокыя Мөхәммәдиш һәм кайбер башка авторларның мәкаләләре дә шактый тулы бирелгән. Мәҗмугада татарча чыккан бүтән гәҗит-журналларга да күзәтүләр очрый. «Яңа милли юл» (аны кыскалык өчен еш кына «Милли юл» дип тә йөртәләр), чит мәмләкәтләрдәге татар матбугатын, иҗтимагый хәрәкәтен рухи яктан җитәкләүче көч буларак, гәҗит-журналларга үзенең киңәш-тәкъдимнәрен дә белдерә, аларның уңай башлангычларын хуплый. Мәсәлән, Мукденда 1935 елның декабреннән башлап «Шәкердләр таңы» исемле «төрек-татар шәкердләренә ана телен онытдырмау вә аны тәрәккый итдерүче айлык мәҗмуга» нәшер кылына. «Яңа милли юл» бу журналны икееллыгы белән котлый, аның шәкертләрне, балаларны милли рухта тәрбияләүгә өлеш кертүен билгеләп үтә (1938.— № 2.— 27 б.).

«Яңа милли юл» чит ил галимнәренең төрки-татарга мөнәсәбәтле хезмәтләрен дә үз укучыларына тәкъдим итеп бара. Менә журналның 1937 елгы 1 нче саны. Анда галим Г. Менденың «Русия төркиләренең милли көрәшләре» исемле немец телендәге хезмәтенә кыскача күзәтү ясала һәм ахырда мондый фикер әйтелә: ул — «милли аңымызның үсүен вә милли көрәшемезнең төрле дәверләрен тасвир итеп, милли таләпләремезнең нидән гыйбарәт булуын аңлаткан гыйльми бер китап…» Бу хезмәт «алманча белгән һәр кешенең өстәлендә булырга тиеш».

Мәҗмугада татарча, төркичә яңа чыккан китаплар хакында күпләгән мәгълүматлар табарга мөмкин. Мәсәлән, Финляндиядә Сания Гыйффәтнең «Тормыш көзгесе» исемле 4 пәрдәлек драма әсәре басылды. Анда илдәге халыкның авыр язмышы күрсәтелә (1937.— № 7); Мукденда «Төрек-татар әлифбасы» дөнья күрде (1935.— № 12) һ. б.

Журналда, гәрчә күп булмаса да, аерым сурәтләр, фоторәсемнәр һәм төрле иллюстратив материаллар да бар. Мәсәлән, Нагояда төзелгән татар мәчете; Милләт Мәҗлесенең 20 еллыгыннан фоторепортаж; Варшаудагы Тукай кичәсе; Ризаэддин Фәхреддин хатларының күчермәләре һ. б. Мәҗмуга тышлыгында еш кына күренекле каләм әһелләренең рәсемнәре урын алган: Габдулла Тукай (1931.— № 4), Йосыф Акчура (1935.— № 6), Исмәгыйль Гаспралы (1931.— № 6), Кырым халык шагыйре Мөхәммәд Ниязи бәк (1931.— № 11), Муса Акъегетзадә (1931.— № 11), Габдерәшит Ибраһим (1931.— № 12), Ризаэддин Фәхреддин (1936.— № 6) һ. б. Журналның 1931 елгы 4 нче санын Сөембикә манарасы да бизәп тора.

Журналның 1931 елгы 7—9 нчы саннарының тышлыгында бик күркәм сурәтләр бар. Аларның берсе «Ляһстанда татар атлы гаскәре» (1660 ел) дип исемләнгән. Анда атка атланган бер яшь, чибәр татар гаскәрие тора. Икенчесе — «Наполеонның татар гвардиясе». Өченчесе — «Татар сугышчысы» (XIV йөз). Һәр өч сурәт тә «Ляһстан мөселманларының милли музәханәләрендән алынган».

Мәҗмуганың тышлыгы хакында сүз барганда, янә бер хосусияткә игътибар итү зарур. Аның күп саннарында яшәеш, милләт, бәйсезлек, көрәш, бердәмлек, белем турында гыйбрәтле сүзләр, афористик фикерләр теркәлгән. Мәсәлән, Милләт Мәҗлесенең 20 еллыгына багышланган махсус санның тышлыгында Г. Тукайның «Өмид» шигыреннән «Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә» дип башланган дүрт юлы язылган.

Журналның теле,— нигездә, инкыйлабка кадәрге татар язма теле. Совет чорында безнең телебезгә күпләп кергән урыс сүзләре мәҗмуга текстларында сирәк очрый. Ә инде гарәп-фарсы алынмалары, киресенчә, күп. Төрек теленең йогынтысы көчле. Көнбатыш Европа телләреннән турыдан-туры яисә төрек аркылы алынган сүзләр дә күзгә ташлана (обжиктиф — объектив, култур — культура, паник — паника, групп — группа, программ — программа, комитә — комитет һ. б.). Хәзер безнең телебездә «иске» дип читтә калдырылган сүзләрне, гыйбарәләрне кабат әйләнешкә кертү бара. Бу процесста «Яңа милли юл» һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдәге вакытлы матбугат, басма сүз теленә мөрәҗәгать итү зыян итмәс иде. Тагын шунысы бар: авторлар, аеруча Гаяз Исхакый, гәрчә алар Идел-йорттан читтә яшәсәләр дә, татар теленең шивәләреннән шактый мул файдаланалар... Үкенеч ки, СССР-Германия пакты һәм икенче бөтендөнья сугышы башлану нәтиҗәсендә, милләт өчен игелекле

эшләр алып барган «Яңа милли юл» журналы 1939 елда эшен туктатырга мәҗбүр була. Аның хезмәткәрләре төрле якларга тарала. Баш мөхәррире Төркиягә күчеп китә.

* * *

«Яңа милли юл» рәсми рәвештә «сәяси, әдәби, гыйльми, икътисади, милли мәҗмуга» дип йөртелгән. Аның эчтәлеген, идея-тематикасын кыскача гына күзәтү дә бу сүзләрнең чынбарлыкка туры килүен ачык күрсәтеп тора. Журнал ябыла. Әмма ул башкарган эшләр, ул салышкан милли-азатлык юлы өзелеп калмады. Гаяз Исхакыйның үзе, аның көрәштәшләре, варислары тарафыннан дәвам иттерелде һәм иттерелә. Алар арасында Гали Акыш, Тимербәк Дәүләтшин, Надир Дәүләт, Рифат Тәби кебек чит илләрдәге милләттәшләребезне дә, Идел-йорттагы күп санлы иҗтимагый-сәяси эшлеклеләрне һәм аерым каләм әһелләрен дә күрсәтергә мөмкин.

«Яңа милли юл» үз чорының, читтәге милләттәшләрнең мәнфәгатьләрен генә түгел, ә бөтен татар халкын, аның киләчәген күздә тотып та эшләде. Мәҗмуганың баш мөхәррире 1938 елда болай дип язган иде: «...Милли юл»ның эшләрен, үзе ышанып күтәргән милли байрагының вакытлы булу-булмавын киләчәгемез күрсәтәчәк вә киләчәк буынымыз гына аның хезмәтләренә дә, эшләренә дә бәһане бирә беләчәкдер» (1938.— № 1.— 1 б.). Хәзерге югарылыктан «Яңа милли юл» алып барган эшнең бөеклеге, тарихи әһәмияте тагын да ачыграк күренә. Империяләр җимерелә, халыкларның ирек, милли бәйсезлек өчен көрәше дәвам итә. Бу — табигый канун. Аны бернинди көч тә туктата алмый.

Гаяз Исхакый, аның фикердәшләре хыялланган, үз эшчәнлекләренең асыл максаты итеп куйган азатлык, бәйсезлек татар халкы тормышында бүген гамәли төс ала бара.

1992 елда халкыбызның бөтендөнья корылтае булды. Милли мәҗлес сайланды. Идел-Урал халыклары конфедерациясен төзү дә янәдән көн тәртибенә килеп басты.

«Яңа милли юл»ның 1932 елгы 2 нче санында титул биттә мондый юллар бар: «Бер милләтне юк иткән нәрсә — ул милләтнең үз-үзенә булган ышанычының югалуыдыр». Гаяз Исхакый һәм аның көрәштәшләре бу яктан безгә үрнәк булып торырлык. Алар, нинди генә кыен хәлләрдә калсалар да, киләчәккә өмет-ышанычларын саклаганнар, милли-азатлык көрәшен дәвам иткәннәр, милләт каршындагы үзләренең изге бурычларын булдыра алган кадәр үтәгәннәр.

«Яңа милли юл»,— бер яктан, тарихны, милли-азатлык хәрәкәтен өйрәнүдә мөһим чыганак. Икенче яктан, журналдагы күп кенә фикерләр, аның юнәлеше бүгенге иҗтимагый, сәяси һәм мәдәни хәрәкәткә, милли тәрбиягә аваздаш. Шуңа күрә аны ныграк өйрәнү, андагы материалларны укучыларга мөмкин кадәр тизрәк, тулырак җиткерү зарур. Җөмһүриятебезнең Милли китапханәсендә «Яңа милли юл» журналының һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдә басылган татарча гәҗит-журналларны, китапларны туплау, булдыру һәм алардагы материалларның библиографиясен төзү шарт.

*1993*

## «ЯҢА МИЛЛИ ЮЛ» БИТЛӘРЕННӘН ШИГЫРЬЛӘР

***Мансур Арсланбәк****

### Милли намаз**

Әй туган, син күп изелдең, инде йитте, тор, уян!
Үтте төн һәм таң да атты, кычкырып әйт син азан!

Моң белән әйт син азанны, яңрасын милли азан!
Бар төрк-татар уянсын, без укыйк милли намаз!

Тиз чыгар балкып кояш, Идел-Уралга нур явар,
Дүрт гасырлап золмәт иткән урыслар да таяр.

Ач тарихың, ас хәритәң (картаң.— *Х. М.*),
Асияне текләп (текәлеп.— *Х. М.*) кара!
Чин дивардан (Бөек Кытай стенасыннан.— *Х. М.*),
Алтай үтеп, Ак Идел буена таба!

Һәм дә Байкал, Каспий үтеп, тугры Босфорга кара!
Кама буйлап бар Казанга, бак!.. Әнә Алтын Сарай...

Бакчы анда дәрьяларга, нинди зур күлләр дә бар!..
Бәһасе юк киң болыннар, нинди бай таулар да бар...

Күрче анда нинди вак парчаланган өлкәләр,
Төрле исемнәр тагып, ул өлкәләрне йөртәләр:

Я санап чык, күпме анда төрле мәзлүм кабилә?!
Казакъ, үзбәк, башкорд, болгар, кыпчаклар улә!..

Юк алай түгел иде, тик безнең күзне бөркиләр!
Һәммәсе алар бер исемнән парчаланган «төркләр»!..

Төркия, кырымлылар, Кафказ, азәрбайҗанлылар,
Шәркый-Гарби Төркестанлы — һәммәсе дә туганнар!!

Ул Сарайда иң элек канун төзегән Хан Батый!
Шул кануннарны бүгенчә (бүгенгә кадәр.— *Х. М.*)
әҗнәбиләр (читләр.— *Х. М.*) куллана!..

Ул Сарайдан сөрде хөкем хан бабаң таҗын киеп,
«Булмасын кол башкаларга бер төрк баласы» диеп!..

Аңладың милли намазың? Бар, азат ит милләтең!
Кыйбла дип танысын җиһан бердән төрклек дәүләтен!..

*Шанхай*

***Сөем***

### Казан алыну мөнәсәбәте берлә**

Казан өстен япкан куе төтен,
Кан шәүләсе төшкән кояшка,
Бу вакыйга тарих битләрендә
Төрк-татар йөзен китерә оятка.
Кичә — ханлык, бүген — хурлык, хурлык!
Капка ачып дошман кертелгән.
Кан түгүдән башка юл калмаган,
Күздән кайгы яше сөртелгән.
Кылыч тапый уңга-сулга, артка-алга,
Бәрелешәдер, чыңлый, ялтырый...

Төртеләдер сөяк-кабыргага,
Суырыладыр кулдан, калтырый.
Кем ни эшли — беркем аңламыйдыр,
Тездән канын кем дә сизмидер,
Бу хурлыкка ничек чыдармын дип, татар
Җанын бирү юлын эзлидер.
Үтте болар бары... Әсирлекнең
Ачы тәмен төрк-татар татыды,
Йөрәккә кадап җиңелү утын,
Дошман золымлыгын таныды.
Гасырлар юдылар җиңелү хурлыгын,
Тирбәттеләр төсле йокыга,
Ләкин көрәш йөрәкләрдә яна,
Карамыйча кышкы суыкка.
Кайтарырбыз иске шәһәрләрне,
Кайтарырбыз данлы дәүләтне;
Күрсәтербез бөтен җир йөзенә,
Төрк-татар исме безгә кыйммәтле.

*Харбин, 1934 ел*

***Исхак Арслан****

**Киләчәк булачак****

Килер заман, җитәр көткән сәгать,
Түзем касәләре ташып агарлар,
Өмидләрен өзгән сынык күңелләр дә
Үлем түшәгеннән басып багарлар.

Өч йөз ел буе чиккән газап —
Бар да шул сәгатьтә тәфтиш кылыныр,
Идел-Уралның бу көннәре
Дошманнарга мәхшәр тоелыр.

Ялтырап чыгар шунда милләт кояшы да
Шаулап аккан Идел суы буеннан,
Күргән җәбер-газапларыбыз шул
дәкыйка (минут.— *Х. М.*)
Алнып ташланырлар безнең муеннан.

Сөйләп бирер безгә серле Идел суы
Өч йөз ел буе җыйган серләрен.
Дулкыннары шаулап җырлап бирер
Соңгы татар ханнарының моңлы җырларын.

Таралып күздән гаиб булыр (юкка чыгар.— *Х. М.*)
кара болыт
Шанлы биек Урал тауларының башларыннан.
Бетәр хәсрәт, жуылыр шомлы кан эзләре,
Шатлык нуры балкыр һәрбер Урал ташыннан.

Күрербез шул ташларның өстендә бер заманда
Күкрәген киереп баскан милләт анасын,
Шул анадан һәрбер ана гыйбрәт алып,
Милләтенә бүләк итәр газиз баласын.

*10.VII.1934. Таупан (Тайвань?)*

***Солтан (Әхмәт Виргаз)***

**Казан өчен**

Бу кара көн бер бетеп,
Ак, якты көн илгә туар!..
Коткарыр җир селкетеп
Казан илен «Идел-Урал»...

Сөембикә түккән кайнар яшьләр
Җирдә ята, әле кипмәгән.
Унбишенче үктәб (октябрь.— *Х. М.*) —
канлы бер көн
Күңелләрдән әле китмәгән...

Җир астында каннар юа иде
Җылый-җылый Идел елгасы...
Унбишенче үктәб — кара бер көн
Синең өчен, төрк баласы.
«Нурлы илем, Казан! Бирелдең син
Шәйх Гали хаин явыздан»...
Ачы җилләр алып китә иде
Шул сүзләрне Бикә (Сөембикә.— *Х. М.*)
авызыннан.

Казан, Болгар, Сарай шәһәрләре,
Хан мәсҗеде... Моңлы манара.
Казан иле, сиңа соң мәртәбә
Сөембикә шуннан караган.

Алтын Урда, Казан ханнарының
Мәрхәмәтле изге анасы...
Унбишенче үктәб — канлы бер көн
Синең өчен, Казан каласы!..

*Мукден*

**Мукден корылтаена***

Күңлемдә балкый шатлык нуры,
Тәбрик итәм, милли корылтай!
Бүген төрк-татар өчен ике кояш,—
Шатлык берлә күңел балыккан...

Идел-Урал — илне сагынганда,
Күкрәгемә сыймый йөрәгем.
Корылтай бүген ачылганда,
Күңелемдә яна теләгем.

Ант итәбез, Алла исмен тотып,
Ил юлында бергә барырга...
Төрк-татар исмен югалтмабыз,
Җир селкетер татар тагын да.

Әй сез, милләт хаинлары!
Юл бирегез төрк-татарга!
Ил көтә безне, ил көтә,
Ил көтә безне, сагына!..

*Мукден, 1935 ел*

***Бәкер Садыйки***

**Туган тел**

*(Бер дәфтәрдән күчерелде)*

Сине мин Кырымда, Казанда таптым,
Җөрәгем кайнаган Ташкенда таптым.
Җат илдә моңаеп, ачынып җөргәндә,
Өметем, хыялым шай (?— *Х. М.*) төшеп җөргәндә.
Муеныңа сарылдым дәрдемне әйтеп,
Бер гүзәл сүзеңнән үземә кайтып,
Җырларың булмаса, мәнәң (? — *Х. М.*) булмаса,
«Җорт» дигән сүзеңнән җөрәк тулмаса,
Ах, насил (ничек.— *Х. М.*) җөрәрмән горбәт якларда?
Таныйсыз, белешсез ят сокакларда (урамнарда.— *Х. М.*)?
Белмимән, төрекме, татармы атың...

## САНИЯ ГЫЙФФӘТ

*(1899—1957)*

### «Аһ, бу язмыш… ник шулай?»

*(Тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеге)*

Язу-сызу, иҗат эше белән азмы-күпме шөгыльләнгән һәр инсан үз язмасына исем куюның никадәр мөһим һәм җаваплы, авыр вә четерекле булуын яхшы белә. Мин дә бу мәкаләгә атаманы шактый озак эзләдем. Алар арасында үзем уйлаганнар да, шагыйрәнең әсәрләреннән алынганнар да бар иде: «Мин — Чистай кызы», «Катлаулы гомер юлы», «Хәят чоңгылларын кичә-кичә», «Әй бәхет! Син ник качасың?», «Көләм тыштан, җылыйм эчтән», «Мин көләргә авзым ачсам, аһ булыб ялкын чыга», «Кыш булыр калган җәем», «Чыгарга телим ямьле бер көнгә», «Сибелсен тоз яраң өстенә, һич беркемгә баш имә», «Күкрәгем ялкын тулы», «Аһ, бу язмыш... ник шулай?» һ. б. Болардан мин соңгысына тукталдым. Ни өчен?

Эч пошып китте кинәт!
Җан нәрсәдер сизде бугай,
Хискә ниндидер галәмдән
Бер хәбәр килде бугай.

Нәрсә бар алда? Яна эч,
Ник беләлмим, йа Ходай!
Аһ, бу язмыш, бу киләчәк,
Ник табышмак соң шулай?!

Бу юллар әле шагыйрәнең гомер язында — 17 яшендә чакта язылган. Кешегә әле бу чорда бар да алда, бар да киләчәктә күренә. Әмма сизгер йөрәкле иҗат иясенең, йомшак күңелле хатын-кызның җаны, давыл алдындагы табигать кебек, нәрсәнедер сизенә, нәрсәгәдер борчыла, һәм, ни аяныч ки, аның рухи халәте, эчке тоемнары алдатмый: тиз арада инкыйлаб, ватандашлар сугышы башлана. Шагыйрә, балалы яшь ана, камгак (перекати-поле) кебек, туган, яшәгән җиреннән, Идел-йорттан мәңгегә аерылып китәргә, гомеренең зур өлешен чит-ят мәмләкәтләрдә уздырырга мәҗбүр була. Истәлекләргә караганда, Анкарада яшәгән шагыйрә тормыш юлының ахыргы елларында йөрәк авыруы, тын кысылу белән интегә. Газапланган вакытларда ул еш кына: «Их, Чистайга, Кама буйларына кайтсам, бәлкем, сулышым ачылыр иде»,— дип әйтә торган була...

* * *

Сания Гыйффәт, аның тәрҗемәи хәле, эшчәнлеге, иҗаты хакында инде минем беренче генә язуым түгел. Хәтта бу затка багышланган махсус мәкаләләрем дә бар: Сания Гыйффәт // Сөембикә.— 1991.— № 2.— 20 б.; Янә Сания Гыйффәт хакында // Сөембикә.— 1992.— № 12.— 18—20 б.; «Туфрагын үбәр идем...» // Мирас.— 1992.— № 8.— 39—41 б.; Шәһри Казан.— 4.04.1991... Боларда шагыйрәнең әсәрләреннән һәм әдәби-тәнкыйди язмаларыннан аерым үрнәкләр дә бирелгән [«Углымның җыры», «Сагынганда», «Яшьләргә», «20 ел элек ил» (Милләт Мәҗлесенең 20 еллыгына багышланган), «Халыкның сулый торган һавасы» (Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә)] һ. б. «Мирас» журналының 2002 елгы 11 нче санында шагыйрәнең төрле елларда иҗат ителгән 22 шигыре дөнья күрде (9—14 б.). Сания Гыйффәткә мөнәсәбәтле, аның турында материаллар «Яңа милли юл», «Төрек йорды» (Хәмит Зөбәер Кошай мәкаләсе.— 1957, май.— № 268.— 853—857 б.), «Kazan» (Наилә Бинарк язмасы.— 1977.— № 20.— 24—29 б.) һәм башка журналларда да бар. Безгә Финляндиядә, Төркиядә шагыйрә белән очрашкан, аралашкан аерым затлар (Халидә апа Таһир, Әнвәр ага Җамаледдин, Әхмәд ага Тимер һ. б.) белән дә сөйләшергә, алардан Сания Гыйффәт хакында кайбер мәгълүматлар алырга туры килде (моның өчен, әлбәттә, мин аларга ихлас күңелемнән рәхмәтле).

Сания Гыйффәт кайвакыт Уган, Кадыйри атамалары белән дә мәгълүм. Соңгысы ире Закир Кадыйрига мөнәсәбәттә алынган. Ә инде «Уган» сүзе — тәхәллүс. Ул борынгы төрки телдә «кодрәт иясе», «иляһи зат...» мәгънәләрен белдерә.

Гыйффәт (саф, намуслы, пакь; абруйлы) — шулай ук тәхәллүс рәвешендәге атама. Ризаэддин Фәхреддиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» романы басылып чыккач, бу сүз XX йөз башы татар дөньясында шактый активлашып китә. Заһидә Бурнашеваның (1895—1977) үзен «Гыйффәт туташ» дип атавы, Саниянең дә бу кушаматны алуы — шуның ачык билгесе.

Сания Гыйффәтнең туу вакыты ике төрле күрсәтелә: 1899 һәм 1900 еллар. Хатирә рәвешендә язылган бер хикәясендә автор үзенең «исем көнен» октябрьнең унберенә нисбәт итә.

«Мирас» журналының 1998 ел 9 нчы санында Зөфәр Рәмиев Сания Гыйффәт Кадыйриянең, 1918 елгы җыентыгыннан алып, өч шигырен («Өмид өзелгәндә», «Хөррият таңы», «Син булмаганда») бастырып чыгарды (23—26 б.). Ул бик кыска гына кереш сүзендә авторның «хәзерге... Ютазы районындагы Кәрәкәшле авылында 1899 елда туган»лыгын да язып китә. Ә инде Хәмид Зөбәер Кошай, Наилә Бинарк, Әхмәд Тимер Сания Гыйффәтнең «Чистай кызы» булуын, анда тууын, балалык һәм яшьлек елларын шунда уздыруын искәртәләр.

Әмма булачак шагыйрә билгеле бер дәрәҗәдә Кәрәкәшле белән дә бәйле булса кирәк. Ул Чистай каласында Хәбирҗан (Сабирҗан?) исемле сәүдәгәр гаиләсендә туа. Әнисе Галия гасыр башында үлеп китә. Сания шактый укымышлы, диндар Хәдичә әбисе тәрбиясендә үсә. Казан университеты профессоры, Кәрәкәшле кызы Фәһимә Хисамова фикеренчә, Саниянең бабасы яисә агасы Мортаза, Кәрәкәшле авылына килеп, Ютазы елгасына тегермән

кордыра, 1913 елда мәктәп салдыра. Аны ачуда күренекле зыялыларның, шул исәптән Г. Сәгъдинең дә катнашуы мәгълүм. Кәрәкәшлегә, аеруча җәй айларында Сания Гыйффәтнең дә берничә мәртәбә килеп китүе билгеле.

XIX йөз ахырында — XX гасыр башларында Чистайда күп кенә татар сәүдәгәрләре яши. Алар ярдәмендә биредә милли-мәдәни һәм рухани тормыш шактый җанлана. Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Ф. Туктар һәм кайбер башка күренекле әһелләрнең Чистай мәдрәсәсендә белем алулары да юкка гына түгел.

Сания Гыйффәт бик кечкенәдән үк укырга, язарга өйрәнә. «Ысулы җәдит» мәктәбендә белем ала, хосусый рәвештә урысча да укый. Аның үз өйләрендәге бай китапханәдән күпләгән татар, төрек, урыс китапларын, журналларын укуы мәгълүм. Булачак шагыйрәнең милли, иҗтимагый һәм әдәби үсешенә туганнан туган апасы, журналист Фатыйма ханымның да тәэсире зур була.

Сания Гыйффәт атаклы «Буби» мәдрәсәсен тәмамлый, бераз вакыт мөгаллимәлек кыла, гәҗит редакцияләрендә эшләп ала. Инкыйлаб алды елларында ул кияүгә чыга. Аның ире Закир Кадыйри — күренекле тарихчы, журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Ул — чыгышы белән хәзерге Ульяновск өлкәсе Чердаклы районы Абдулла авылыннан. Әтисе — Хәлим мулла. З. Кадыйри әүвәл үз авылында укый, аннан — Бохарада һәм Төркиядә. Истанбул университетының илаһият факультетында бераз белем алгач, Хиҗазга китә. Анда ике ел буена Шәйх Исхак Һиндидән хәдис һәм тәфсир дәресләре, Мәхмүд Алидән гарәп әдәбияты сабаклары ала. Аннан Мисырдагы Әл-Әзһәр университетында укый. Мостафа Кәмал Паша чакыруы белән «Әл-Лива» гәҗитендә дә эшли.

1906 елда Рәсәйгә кайта. Петербургта Рәшит Ибраһим тарафыннан нәшер ителүче «Әт-Тилмиз» журналында хезмәттәшлек кыла. Оренбургтагы «Хөсәения» һәм Уфадагы «Галия», «Госмания» мәдрәсәләренең атаклы мөдәррисе. Уфада чыга торган «Тормыш» гәҗитен (1913—1918) җитәкли. 1917 елгы Бөтенрәсәй мөселман төрки-татар корылтайларын оештыруда актив катнаша. Милләт Мәҗлесенә, Мәгариф нәзарәтенә (аның җитәкчесе итеп) сайлана. Әмма ватандашлар сугышы елларында, большевиклар хакимияте белән каршылыкка кереп, мөһаҗәрәткә китәргә мәҗбүр була. Бераз вакыт Кытайдагы Хайлар шәһәрендә яши. 1922 елда Төркиягә күчеп килә. Әүвәл Тарсуста, аннан Анкара, Истанбул шәһәрләрендә педагог, тәрҗемәче, китапханә хезмәткәре булып эшли. 1936 елдан 40 нчы елларга кадәр Финляндиядә балалар укыта, фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Аннан соңгы гомерен Төркиядә уздыра. Кабере — Анкараның Җәбәҗи мазарлыгында.

З. Кадыйри — татар, гарәп, төрек телләрендә язылган күп санлы мәкалә-хезмәтләр авторы. Алар Мисырда, Рәсәйдә, Төркиядә, Финляндиядә һәм кайбер башка илләрдә нәшер ителгән. Казан университеты китапханәсендә галимнең «Гарәп нәхүе», «Куәт һәм рух», «Мәмләкәт идарәсе рәвешләре», «Кызлар дөньясы», «Хатын-кыз мәсьәләсе» һ. б. китаплары бар. Финляндиядә 30 нчы елларда дөнья күргән төрек-татар тарихы дәреслекләре чит илләрдәге милләттәшләребез арасында киң таралыш таба. З. Кадыйриның тарихка, этнографиягә, дин тарихына, мәгарифкә, телгә мөнәсәбәтле күп
кенә мәкаләләре «Төрек йорды» журналында басылып чыккан. З. Кадыйри гарәпчәдән Ибне Халдун, Ибнел-Әсир, Табәри, Мәсгуди, Макризи һәм башка күренекле авторларның хезмәтләрен төрекчәгә тәрҗемә итә.
А. Е. Крымскийның өч җилдлек (томлык) «Гарәп әдәбияты тарихы», Иностранцевның һуннар һәм гуннар турындагы хезмәте дә төрек укучыларына З. Кадыйри тәрҗемәсендә ирешә. Галимнең әле хәзергәчә басылмаган хезмәтләре дә бар (мәсәлән, Әфганстан тарихы, гарәп сүз сәнгате турында һ. б.). Аларның бер өлеше — Әхмәт ага Тимернең шәхси архивында.

* * *

«Аһ, бу язмыш...» Октябрь инкыйлабы болай да тәмам какша-
ган Рәсәй тормышын чыгырдан чыгарды, әйтерсең Кыямәт көне җитте. «Ул көндә,— диелә Коръәннең 101 нче сүрәсендә,— кешеләр каты куркуларыннан тузылган чикерткәләр кеби тузылып, таралып китәләр һәм бер-берсен күрмәсләр» (Коръән тәфсире.— Казан, 1994.— 674 б.). Ватандашлар сугышы Рәсәй тормышын да нәкъ шуңа охшаш халәткә китерде. Миллионлаган инсаннар кырылды яисә чит-ят төбәкләргә күчеп, качып китте. Алар арасында әле яңа гына гаилә корып, бер-бер артлы ике бала тапкан, 19 яше дә тулмаган Сания Гыйффәт тә бар. Иреннән башка ул үзе Шәркый Төркестанга — Гөлҗага барып чыга. Биредә берничә ай торгач, Пекинга юнәлә. Аның Гоби чүлләре аркылы үткән бу сәфәре ярты еллап вакытка сузыла. Кытай башкаласы да татар хатынын кочак җәеп каршыламый. Аптыраган, йөдәгән Сания Гыйффәт милләттәшләре күпләп яшәгән Хайлар шәһәренә килеп урнаша. Ире дә инде бу вакытта Маньчжуриягә килгән була. Әмма тиз арада ул диңгез юлы белән Төркиягә юнәлә. Сания Гыйффәт Хайларда балалар укыта, мөһаҗир татарлар арасында милли-мәдәни эшләр алып бара. 1924 елда ул, мең газаплар кичереп, ике баласы белән Төркиягә ире янына күчеп килә. Сания Гыйффәтнең бу еллардагы тормышы, эш-шөгыльләре хәзергә бик билгеле түгел. Әмма ул милли идеалларга, әдәбиятка тугрылыклы кала. Биредә, әлбәттә, Гаяз Исхакыйның да роле зур була. Бу ике әдип,— бердән, якташлар, икенчедән, З. Кадыйри һәм Г. Исхакый инкыйлаб елларында мөселман корылтайларын оештыруда, Милләт Мәҗлесендә бергә эшлиләр. Төркиядә дә Кадыйрилар бөек әдип белән аралашып торалар.

Мәгълүм булганча, Г. Исхакый — Финляндиядәге милләттәшләребез белән якыннан таныш зат. Октябрь инкыйлабыннан соң да ул Суомида күп мәртәбәләр була. Аның тәкъдиме белән Финляндиядәге милләттәшләребез 1936 елда үзләренә мөгаллим итеп Кадыйриларны чакыралар.

Хельсинкига күчкәч, Сания Гыйффәт яңадан ачылып, дәртләнеп эшкә керешә: үз татарларына белем-тәрбия бирә, төрле кичәләр, мәдәни чаралар оештыра, мәкаләләр, шигырьләр яза, драмалар иҗат итә. 1938 елда «Уку китабы» басылып чыга. Татар, урыс, төрек, гарәп телләрен камил белгән Сания Гыйффәт тиз арада фин телен дә үзләштерә. Үзләренең мөгаллимәләрен Финляндиядәге өлкән буын милләттәшләребез әле хәзер дә зур хөрмәт белән искә алалар, аның гаять культуралы, укымышлы, татар җанлы булуын сокланып сөйлиләр.

Дөнья сугышы, сәяси вазгыять Кадыйриларга да китереп суга. Финляндиядән әүвәл ире китә. Сания Гыйффәт исә Төркиягә 1944 елда әйләнеп кайта.

40—50 нче еллар — Төркиянең икътисади, рухи яктан авыр чоры. Бу кыенлыклар мөһаҗир татарларны да читләтеп үтми. Бу елларда, мәсәлән, Г. Исхакыйның да ачлы-туклы яшәве мәгълүм.

Сания Гыйффәтнең Азад һәм Лалә исемле ике кызы була. Олысы 40 нчы елларда мәшһүр галим, милләттәшебез Әхмәд Тимергә (1912—19.04.2003) кияүгә чыга. Гомеренең соңгы елларында Сания Гыйффәт түшенкелеккә бирелә, кешеләр белән юньләп аралашмый. Иренең һәм Г. Исхакыйның үлемен гаять авыр кичерә. 1957 елның 12 апрелендә Анкарада вафат була. Ире Закир Кадыйри белән янәшә күмелә. Финляндиядәге элеккеге шәкертләре аның кабере өстенә 1957 елда язулы таш куялар.

* * *

Сания Гыйффәт — табигый талант иясе. Ул кечкенәдән үк шигырьләр чыгару, такмак әйтү белән мавыга. Шундыйларның берсе менә болай яңгырый:

Өстеңә чүккән җәһаләт берлә мескенлекне ат,
Иң явыз дошман саналган чеп-чи ялкаулыкны ат.

Син — төрктән бер бүлек, син — һәм татардан бер халык,
Мондый мескенлек вә зилләткә (түбәнлеккә; хурлыкка.—*Х. М.*)
баш игмәс бер халык.

Әйтүләренә караганда, Сания укучы вакытында бер авылга (Бүкрәш — ?) барып чыга. Шигырь шундагы фәкыйрьлекне, наданлыкны күреп язылган. Сания Гыйффәт иҗатына, гомумән, публицистик рух, ораторлык интонациясе хас. Күрәсез: бу сыйфатлар аның тәүге шигырьләренең берсендә үк үзен сиздерә.

Хәмит Зөбәер Кошай язуынча, Сания Гыйффәтнең беренче шигыре Томскида нәшер ителгән «Сибирия» гәҗитендә 1912 елда басылып чыга. «Үлсәм әгәр» дип исемләнгән бу романтик рухлы язмада мондый юллар бар:

…Үлсәм әгәр мин бу йирнең
Якты көнен күрмәдән (? күрмичә.— *Х. М.*),
Төрле идеаллар берлән
Тулган бу күңлем сүнмичә,—
Ялтырар караңгы гүрдә
Тереләй күмелгән күңел.

Октябрь алды елларында Сания Гыйффәт шигырьләре татар вакытлы матбугатында, бигрәк тә ире һәм үзе эшләгән «Тормыш» гәҗитендә (Уфа, 1913—1918) шактый басыла. Аларның күпчелеге, бергә тупланып, 1918 елда Уфадагы «Шәрык матбугасы»нда «Сания Гыйффәт шигырьләре» исеме астында нәшер ителә (32 б.). Кечерәк форматлы бу китапта авторның 35 шигыре һәм «Кабер янында» исемле бер тәрҗемәсе урнаштырылган.

Бу мәҗмуга мөһаҗәрәттәге матбугатта, шул исәптән Хәмит Зөбәер Кошай, Наилә Бинарк мәкаләләрендә дә күзгә ташланмый. Шагыйрә үзе дә аны бик телгә алмый. Әллә болгавыр елларда бик аз данәдә басылган бу китап мөһаҗир татарларга ирешмәгәнме?

Җыентыктагы шигырьләрнең күпчелеге 1916—1917 елларда язылган. «Ил агаларына» дип исемләнгән бер парча 1918 ел-
ның мартына нисбәт ителә. Калганнары, күрәсең, элегрәк елларга карый.

Яшь кызны, яңа гына гаилә корган 17—18 яшьлек ханымны, нәрсәләр борчый соң? Аның уй-кичерешләренә, шигъри фикерләү рәвешенә нинди сыйфатлар һәм күренешләр хас?

Мәҗмугадагы парчаларның һәммәсе дә диярлек лирик характерда. Аларда лирик каһарманның рухи халәте, тегеләй яки бу мәсьәлә хакында уйланулары, эмоциональ һәм психологик мөнәсәбәте шактый тулы һәм калку гәүдәләнгән.

Шагыйрәнең атаклы төрек әдибе Габделхак Хәмиднең
(1852—1937) «Тарикъ ибне Зияд, яки Фәтхе Әндалис» («Әндалисне яулап алу».— *Х. М.*) либреттосыннан тәрҗемә ителгән «Кабер янында» тексты гаять гыйбрәтле. Анда мөселман (гарәп) сугышчысына гашыйк булган испан кызының күңел тетрәнешләре, көчле мәхәббәте Низами, Шекспирлар югарылыгында тасвирлана. Сөйгәне һәлак булгач, кыз аның кабере өстендә үз-үзенә кул сала.

«Кабер янында» тексты берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, Сания Гыйффәт тәрҗемә өчен теләсә нинди әсәрне түгел, ә госманлы сүз сәнгатенең классик ядкярен сайлап ала. Ул, ничектер, шагыйрәнең хисси фикерләү рәвешенә авазлаш. Икенчедән, шигырьдә мәхәббәтнең бөеклеге, гашыйк затның куркусызлыгы раслана. Өченчедән, Сания Гыйффәт оригиналның татарчада ритмик, интонацион һәм стилистик яңгырашын да бирә алган. Яшь шагыйрә, яшь тәрҗемәче өчен, әлбәттә, бу әсәр — зур казаныш.

Шулай да Сания Гыйффәт җыентыгында мәхәббәт тематикасы чагыштырмача аз урынны били. Шагыйрә күбрәк фәлсәфи, милли, иҗтимагый, социаль, әхлакый мәсьәләләр белән кызыксына. «Алданган» парчасы үзенең рухы белән Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» шигырен хәтерләтә. Һәр ике әсәрдә дә хатын-кыз язмышына теләктәшлек күзгә ташлана. Тукайда кызны фаҗигале хәлгә төшерүчеләргә нәфрәт тә белдерелә. «Алданган»да исә ул мотив юк, анда кызның газаплы хәлен тасвирлау үзәктә:

…Һәр сулыш ялкын, түтенсез, ут тоташкан күкрәге,
Һәр сүзе салкын, өмидсез, төпкә баткан күзләре…

Шагыйрәнең яшьлеге, әдәбиятка килү еллары — татар милли-азатлык хәрәкәтенең күтәрелгән чоры. Бу атмосферада яшәгән, татар зыялылары белән аралашкан милли җанлы Сания Гыйффәт тә күп кенә шигырьләрендә үз халкының язмышы, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлана. 1916 елда иҗат ителгән «Өмидсезләнгәндә» парчасы — шуның бер мисалы. Шагыйрә татар язмышын тарихи яссылыкта, вакыт контрастында карый. Заманында, ди автор, татарның «шан-шәрәф»ле чаклары бар иде. Ә хәзер ул — «җанлы үлек».

Әй татар! Уйлан бераз, син нинди көч тотдың элек,
Син җир өстендә һаман да, инде син — җанлы үлек.

Автор фикеренчә, татарның мондый хәлдә калуында, бер яктан, халык үзе («Син үзең балтаң белән үз тамырыңа куйдың чабыб»), икенче яктан, «кара көчләр» гаепле. Шагыйрә татарның аяныч хәлдә яшәве белән риза түгел, ул аны көрәшкә, үз хокукларын якларга чакыра. Аның «Сирател-мөстәкыймчеләргә» (Туры юлдан баручыларга) шигырендә мондый юллар бар:

…Әй кара көч! Юкка ашкынма, басуны уйлама,
Пис (пычрак.— *Х. М.*) аяклар берлә син милләт күгендә
уйнама.

Инде милләт син белә торган сабыйлыкдан чыгыб,
Ир булыб җитде тәмам, кулда кылыч, уклар тотыб.

Кил, батыр булсаң, көрәшкә, уртага чык чын булыб,
Асда ятма шан-шәрәфле бер исемгә өртенеб.

Сания Гыйффәт, Урта гасыр һәм XIX йөз әдәби традицияләрен дәвам итеп һәм үз чорының инану-ышанычларына нисбәтле рәвештә, Коръән, дин белән бәйләнешле тематиканы да яктырта. «Табигатькә карап» шигырендә, мәсәлән, күк йөзендәге кояш, болытлар, җирдәге «чәчәк-үлән»нәр, «чишмә» агышы, «сандугачлар тавышы» мактала. Чөнки аларның һәммәсе дә — «Тәңренең кодрәте», «Беренче сәхәр», «Мәүлид таңында» шигырьләрендә вакыт агышының истәлекле мизгелләре, мөселман диненең олуг бәйрәме белән соклану хисләре бәян ителә. Аллага бирелгәнлек, иманлылык хуплана. Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүе «тугрылык», «гали әхлак» төшенчәләре белән тыгыз мөнәсәбәттә карала:

…Шулвакыт тугды пәйгамбәр, сеңде җиргә бар бозык,
Ул туган көндә аякланды җиһанда тугрылык…

Ул тугды һәркемгә үрнәккә гали (олуг.— *Х. М.*) әхлак белән.
Җиргә, күккә, бар галәмгә мәрхәмәт, рәхмәт белән.

Үзенең күп кенә элгәреләре һәм замандаш әдипләре кебек, Сания Гыйффәт тә шагыйрьлек миссиясе хакында уйлана, иҗат иясен вакланмаска, кыенлыкларга түзәргә, сер бирмәскә, югарылыкка чакыра:

Син изел, салсын фәләк (язмыш.— *Х. М.*) зур-зур
богаулар муеныңа,
Юк зарар, рух тетрәсен, шундан сиңа илһам иңә.

*(«Шагыйрьгә»)*

Сания Гыйффәтнең кайбер шигырьләрендәге лирик каһарман романтик табигатьле, гыйсъян рухлы, космик фикерләүче зат рәвешендә күзаллана. Ул әле «кунарга ботак тапмаган» «адашкан кош» кебек бәргәләнә («Зар»), әле «котырыныб ташкан тирән диңгез тыныб калган кеби» була («Нигә тынмыйм?»), әле дөньяны каһәрләп («Чәчелеп кат дөнья, Утка ян дөнья»), зынҗырларны өзеп, «ямьле бер көнгә» чыгарга ашкына («Дөньяга»). Лирик герой үз укучыларын «батыр булырга», эшкә, хәрәкәткә өнди:

…Гел үләргә йөз тотыб, син дөньядан бизмә,
Сибелсен тоз яраң өстенә, һич беркемгә баш имә.

Батыр бул! Ирлекеңне җуйма, еглаб торма дөньяда,
Түз, әрнетсен, зарар юк, соңра пешкән җир тиз уңала
(төзәлә.— *Х. М.*).

*(«Васыятем»)*

1917 елгы инкыйлаб күп кенә татар әдипләре тарафыннан хуплап каршыланды. Мәсәлән, Ш. Бабич үзенең «Хөррият бүләге» шигырендә болай дип язды:

Ябылды капусы сәкарьнең,
Ачылды җәннәте Ватанның,
Чәчелде хуш һава, хөр һава…—
Бу иде көткәне татарның.

Сания Гыйффәт тә 1917 елгы үзгәрешләрне гаделлек тантанасы, «хөррият таңы» рәвешендә тасвирлый. Аның фикеренчә, «Юк залим көч җир йөзендә, Бар кеше хөр, шад, азад». Әмма тиз арада шагыйрәнең тәэсир-карашлары тамырдан үзгәрә. 1918 елның мартында Уфада иҗат иткән «Ил агаларына» шигырендә ул илдәге ачлык, хәерчелекне, халыкның «туктамый кырылуын» күреп ачына, «каны кыза». «Ил агаларына» дәшеп, ул болай ди:

Нинди җан бар сездә, әй сез, зур кавем башлыклары,

Күрмисезме, кан түгеб алган хокуклар нишләде?!

1917 елда, аз гына вакытта булса да, инсани, милли хөрлекне татыган шагыйрә җаны янә читлеккә керергә, хокуксыз яшәргә теләми һәм тиз арада Идел-йорттан, Рәсәйдән китәргә дә мәҗбүр була.

* * *

Сания Гыйффәт җыентыгында газәл, кыйтга, робагый, багышлау һәм кайбер башка шигъри жанр үрнәкләре бар. Мәсәлән, «Син булмасаң», «Мин сөям» парчаларында классик газәлнең күп таләпләре сакланган. Шагыйрәнең күпчелек шигыре гаруз, икеюллык строфалар белән язылган. Автор аеруча һәр юлы 15 әр иҗектән торучы үлчәмне яратып куллана. Арада 11 гә 11, 12 гә 12 үлчәмле вәзен төрләре дә бар. «Син булмаганда», «Дөньяга» шигырьләре һәр юлы 5 әр иҗектән торган дүртьюллык строфалар белән язылган. Мәгълүм булганча, мондый шәкелле парчалар Тукай иҗатында да бар.

Шагыйрә янәшә рифмалар (аа бб …) кулланырга ярата. Юл ахырын бер үк сүзләргә, ягъни рәдифкә төгәлләү дә аның берничә шигыренә хас. Мәсәлән, 6 строфалык «Мин сөям» шигыренең һәр юлы «саен» сүзенә төгәлләнә. Шунысы кызык: биредәге бер мисрагта рифмалашу да бертөрле.

Мин сөям ирне батырлык, көч сачеб торган саен,
Кыз-хатынны мин сөям нечкә вә саф булган саен…

[«Әй бәхет»…] парчасында шагыйрә Яков Емельянов, С. Рәмиев яратып кулланган ялгау алымына да мөрәҗәгать итә:

…Эзләнәм мин чын бәхетне, кайда, кайчан, әйтегез!
Әйтегез дә ул качып торган урынга илтегез!

Җыентыкта юлбаш анафора (ягъни мисрагларны бер үк сүз белән башлау), эчке рифма куллану очраклары да еш очрый. Кайвакыт автор, эстетик максатны күздә тотып, бер юлда бер үк сүзне дә кабатлый: «Мин сөймим шөһрәт, сөймим байлык, сөймим зур мәртәбә» («Юк хакыйкать»); «Үтәр айлар, үтәр еллар, үтәр көн» («Картлык»)…

XX йөз башы татар поэзиясендә, бигрәк тә С. Рәмиев, бераздан Һ. Такташ иҗатларында иркле шигырь белән язу да күзгә ташлана. Сания Гыйффәтнең дә җыентыктагы бер әсәре (ул Корбан бәйрәме уңае белән язылган) — шушы шәкелдә. Автор аны үзе «Мәнсур (чәчмә.— *Х. М.*) шигырь» дип исемләгән. Ул болай башлана:

Җирдә моң,
Ишетелми шатлыклы өн.
Үлгәнме ул?
Ник тын?
Кайгылы һәрьяк: якты күренми,
Караңгы төн…

Биредә җитмәгән иҗекләр пауза ярдәмендә тутырыла (компенсацияләнә).

Сания Гыйффәт шигырьләрендә заманчалык, үз дәверенең сулышын тою көчле. Яшь кенә хатын-кызның күп кенә мәсьәләләр хакында үзенчә уйлануы, кызыклы гына сурәтләр, сәнгати алымнар куллануы аның сәләтле иҗат иясе икәнен янә бер мәртәбә раслап торалар.

* * *

Сания Гыйффәтнең илдән киткәннән соңгы әдәби иҗатын мөһаҗирлек чоры эшчәнлеге дип атарга мөмкин. Ул шагыйрә гомеренең өчтән икесен алып тора. Инсан, әлбәттә, кайда гына яшәсә дә, үз табигатенең асыл сыйфатларын саклап кала. Әмма шулай да мохитнең, нәсел-нәсәбеңне формалаштырган һәм яшәткән тирәлекнең үзгәрүе психологиягә, дөньяга карашка да теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясый.

Моңа кадәр чагыштырмача җитү тормышта яшәгән, Идел-йортның иҗтимагый, мәдәни, милли даирәсендә кайнаган унтугыз яше дә тулмаган зыялы хатынның ике яшь баласы белән газаплы юл сәфәрләрен кичерүе, чит-ят төбәкләрдә көн күрергә мәҗбүр ителүе аның иҗади эшчәнлегенә дә, әлбәттә, тискәре йогынты ясый.

Ватанында вакытта ике-өч ел эчендә берничә дистә шигырь язган Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлектә иҗат иткән әсәрләре әллә ни күп түгел. Булганнарының да әле бер өлеше генә безгә мәгълүм.

Әйткәнебезчә, Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлек елларында бер иҗади күтәрелеш чоры була. Ул — 30 нчы еллар, аеруча Финляндиядә эшләү дәвере. Бу вакытта ул дәртләнә-дәртләнә мөгаллимәлек кыла, дәреслекләр төзи, шигырьләр, сәхнә әсәрләре яза, вакытлы матбугатта чыгышлар ясый. Мондый иҗади активлыкның сәбәпләре дә бар. Бу еллар — мөһаҗәраттәге татарларның милли яктан уянган, җанланган чоры. Польшада, Ерак Шәрыкта төрле корылтайлар була, төрле илләрдә һәм төбәкләрдә татарча гәҗит-журналлар чыга, китаплар басыла. «Яңа милли юл» (Берлин), «Милли Байрак» (Мукден) басмалары үзләре генә дә ни тора! Сания Гыйффәт боларда актив катнаша. (Аеруча — «Яңа милли юл» журналында. Биредә аның берничә публицистик һәм әдәби-тәнкыйди язмасы, ике дистәгә якын шигыре күзгә ташлана). Бу — бер. Икенчедән, шактый еллар буе милли мохиттән аерылып яшәгән шагыйрәгә Финляндиядә, гәрчә чикләнгән кысаларда булса да, үз халкы белән, үзенең күңеленә һәм белгечлегенә ятышлы эш белән шөгыльләнү мөмкинчелеге туа. Матди яклар да өлешчә яхшыра. Өченчедән, Сания Гыйффәт милләт зыялылары белән янә ныграк аралаша башлый. Чөнки бу елларда Финляндиягә мөһаҗәраттәге күп кенә татарлар еш кына килеп-китеп йөри. Суоминың үзендә дә Хәсән Хәмидулла,

Хәбибрахман Шакир, Хөсәен Садыйк, Гайсә Хәкимҗан һәм тагын берничә иҗат әһеле яши. Шагыйрәнең иҗади күтәрелешендә, әлбәттә, Гаяз Исхакый белән очрашу-аралашулар аеруча мөһим роль уйный.

Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлектәге иҗади эшчәнлеген бер-берсе белән үзара тыгыз, табигый бәйләнешле поэзия, драматургия, проза, әдәбият белеме, тәрҗемәчелек тармакларына аерып карарга мөмкин.

Шагыйрәнең бу елларда язган тезмә әсәрләре арасында иң күренекле урынны, әлбәттә, «Углымның җыры» шигыре алып тора. Ул мөһаҗирлектәге төрки-татарларның, аеруча яшьләрнең үзенә күрә бер гимны булган.

Шигырь лирик каһарман — «мин» исеменнән сөйләнә. Ул — төрки вәкиле «Атилла» варисы. Шагыйрь төрки кавемнәрен бер-бөтеннең (гәүдәнең) әгъзалары (Кырым — «кан тамры», Төркия — «күз бәбәге», Азәрбайҗан — «куллар») рәвешендә кузаллый. Әмма автор өчен иң беренче чиратта үзенең Идел-Уралы якын. Юкка гына ул аны төрки берлекнең «үзәге» дип атамый.

Лирик каһарманның данлы үткәне, дөньяда билгеле исеме, үзенең ата-бабадан калган тарихы, ил-йорты бар. Шуңа күрә аның кол булып яшәргә хакы юк. Ул хөрлек өчен көрәшергә, үз-үзенә хуҗа булып гомер кичерергә бурычлы.

«Углымның җыры» әсәрендәге мотивлар шагыйрәнең «Милли байрак» («Омтыл алга, татар! Бул гайрәтле! Тот уң кулга милли байракны… Мен атыңа, татар! Тот кылычыңны! Яр дошманның кара йөрәген»; «Син бит Бату ханның баласы…»), «Диябез» («Безнеке диябез, Бу ил — безнеке. Бирмәсәң — алабыз — Үзебезнеке…»), «Тәңре тавына карап» һәм кайбер башка шигырьләрендә дә гәүдәләнеш таба. Авторның рухи халәте, бөтен яшәеше ил гаме, Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнешле. «Ил дәрде» шигыренең лирик каһарманы кайгы, сагыш утында, бөтен табигать, тирә-юнь аның өчен «күңелсез», «ямьсез»:

…Кайда бассам читенсенәм, җан эчкә сыймый тарсына,
Кайда баксам буш, тонык, ул нәрсә-нидер юксына.

Дүрт ягым бөркү, караңгы, дөнья тик бер сер миңа,
Нишләсәм дә ач, туялмый, җан өлешсез талпына.

Мондый халәтнең төп сәбәбе — ил кайгысы («Бар теләкне көл итеп күңлемдә ил дәрде яна»). Ил-Ватанның ирекле, бәхетле булуын күрү — шагыйрәнең иң зур теләге:

…Ил йөзеннән ал караңгы
Пәрдәсен, золмын күтәр.
Изге көн бир, шат, бәхетле
Көн тудыр, күңлен күтәр.
Йорт-йиремнең үзирекле
Булганын күрсәт, күрим…

*(«Актык теләк»)*

Сания Гыйффәт Мостафа Кәмал хөрмәтенә язылган «Газыйга хитаб (дәшү.— *Х. М.*)» дигән шигырендә (Яңа милли юл.— 1933.— № 3.— 8 б.) күп кенә төрки-татар кавемдәшләренең «тоткын»лыкта яшәвенә газаплануын белдерә һәм укучы алдында бу халәттән ничек чыгу соравын куя: «Күз яшьләре дәртен басар өчен, Сөйлә, Газый, нинди чара бар?»

«Газыйга хитаб» парчасыннан тыш, шагыйрәнең Исмәгыйль Гаспралыга, Гаяз Исхакыйга багышлап язган әсәрләре дә бар. «Исмәгыйль бабага» дигән шигыре — татар әдәбиятында күпгасырлык тарихы булган мәдхия-мәрсия жанрларының күркәм бер үрнәге. Анда без Тукай традицияләренең дә дәвам ителешен күрәбез. Макталучы зат, аның эш-гамәлләре, сыйфатлары, яшәештәге урыны идеал планда, максималь югарылыкка куеп тасвирлана:

…Зур дию, зурлау да, мактау сүзләре бик кечкенә,
Син «бөтен»нең каршысында вак боларның барысы да.

«Тел» дә юк, «мактау» да юк сине сөяргә дөньяда,
Күз камаша бар бизәктән, өстә исмең өр-яңа…

Шагыйрәнең «…Гаяз әфәндегә багышлыйм» дигән әсәрендә (Яңа милли юл.— 1934.— № 4.— 34—35 б.) әдипнең иҗтимагый-социаль дошманнары, «кара көч»ләр фаш ителә, ирек өчен көрәшне бернинди «балта», «киртә»ләрнең дә туктатып кала алмаячагы, вулкан-лавиналарның атачагы искәртелә:

…Көн килер, дәверләр, атар ул, бөркер эчтән утларын,
Юк итәр, өртәр («бетерер».— *Х. М.*) золым, кан, вәхши көч
кайнакларын («чыганакларын».— *Х. М.*).

Мәгълүм булганча, 1917 елда Милләт Мәҗлесе төзелә, һәм ул милләтне торгызуда кыска гына вакыт эчендә күп эшләр башкара. Әмма бу милли оешма 1918 елның башларында Мәскәү-Петербург хакимияте тарафыннан тыела, аның җитәкчелеге (Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Закир Кадыйри, Габделбарый Баттал, Фуад Туктар…) илдән качып, күчеп китәргә мәҗбүр ителәләр.

1937—1938 еллар аралыгында мөһаҗәрәттәге татарлар Милләт Мәҗлесенең 20 еллыгын киң күләмдә билгеләп үтәләр. Хатирә чаралары Япуниядә, Финляндиядә, Кытайда, Эстониядә, Төркиядә һәм аеруча Польшада үткәрелә. Шушы уңай белән Сания Гыйффәт үзенең мәшһүр «20 ел элек» исемле шигырен яза. Анда ул көннәрнең куаныч-шатлыклары, өмет-теләкләре, якты буяулар, дәртле аһәң белән белдерелә («гөрләде, шау килде», «әнкәсен күргән баладай» җилкенү, «яшь арыслан төсле… күкрәде», «яңгырады күк йөзенә җырлары, тәкбирләре…»).

Шагыйрә үз иҗатының тәүге баскычларында ук яшьләргә зур өмет баглый. Ир балага багышланган «Тәбрик» шигырендә ул болай яза:

Үс матур гөл төсле, үссен бергә гаклың да синең,
«Милләт өчен үсәм» булсын җитәкләүчең синең.

Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлек елларында иҗат ителгән «Яшьләргә» дигән махсус шигыре-багышламасы да бар. Ул лирик каһарманның авыр халәтен тасвирлаудан башлана. Әмма «күкрәгән ил егете» яисә «яшен төсле алтын ил кызы» белән очрашу аны кабат тугандай итә…

Җанланам, терләм, үсәм, баштан яшим, илһам алам!
Шаңгырап-шаулап торамын, өр-яңа булган булам.

Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлек чорында иҗат ителгән шигырьләре, нигездә, иҗтимагый-социаль, сәяси, тарихи характерда. Болар арасында, утрау кебегрәк, шагыйрәнең «Ахирәт дустыма» дигән парчасы аерылыбрак тора. Эчтәлегенә карап, мин аны «Сагындым» дип атар идем. Чөнки бу сүз рәдиф рәвешендә һәр икенче юлның ахырында кабатланып килә, шигырьнең аһәңлелеген көчәйтә. Автор бу парчасын халык җырлары рухында иҗат иткән, һәм ул, ничектер, үзе дә көйгә, моңга соралып тора.

…Ак өстендә ал бөрчекле
Күлмәгеңне сагындым.
Битләреңне чокырайтып
Көлгәнеңне сагындым.
Маңгаеңның сул ягында
Миңнәреңне сагындым.
«Сандугачым, кил тагын да»
Дигәнеңне сагындым…

Кеше, кайда гына, ничек кенә яшәсә дә, туган илен, туган туфрагын оныта алмый. Сагыну хисе аның рухына, кан тамырларына сеңгән. Бу тойгы яшь арткан, инсан өлкәнәйгән саен көчәя генә бара. Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлектә язылган парчалары арасында үтә дә лирик, үтә дә ихласи аһәңле, күңел сазларын тетрәндерерлек бер шигыре бар. Ул «Сагынганда» дип атала. Дәреслекләргә кертеп өйрәнерлек бу парчада шагыйрәнең күңел дөньясы да, фаҗигаи язмышы да гәүдәләнеш тапкан!

…Ил йөзен күрсәм бераз,
Шат булыр идем, бәлки,
Мин дә, мин дә, мин дә. Аh,
Җан алыр идем, бәлки.

Сагындым дияр идем,
Туфрагын үбәр идем,
Кочаклап, коча-коча,
Күз яшем түгәр идем.

Кайгылы ил ташларын
Сыйпап җуатыр идем,
Җылы, үз кочагында
Назланып ятыр идем.

* * *

Сания Гыйффәт шигырьләренә эчке бер драматизм, уй-хисләр каршылыгы хас. Шагыйрәнең тормыш юлы да төрле борылыш-сикәлтәләргә гаять бай. Шуңа күрә мондый затның драма жанрына мөрәҗәгать итүе — мантыйкый күренеш. Аның «Тормыш көзгесе», «Хан бүләге», «Яңа көй» исемле сәхнә әсәрләрен язуы мәгълүм. Әмма, кызганыч ки, хәзергә бу ядкярләрнең берсе генә кулыбызда бар. Ул — «Тормыш көзгесе» әсәре. Бу драма гарәп хәрефләре белән 1937 елда Хельсинкида «Финляндия төркләре Берлеге» тарафыннан нәшер ителгән (64 б.).

Сания Гыйффәт пьесалары Финляндиядә, Эстониядә, Кытайда, Румыниядә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан укыла, уйнала. Димәк, алар идея-эстетик яктан тамашачыларны үзләренә тартканнар. Автор үзенең сәхнә әсәрләренә шигъри юллар дә кертеп җибәрә. Әйтүләренә караганда, аның «Яңа көй» драмасы шигырь белән язылган.

«Тормыш көзгесе» — дүрт пәрдәлек (20 күренешлек) драма. Андагы тәүге вакыйгалар Октябрь инкыйлабы дәверендә бара. Аларның урынын шартлы рәвештә Казанга нисбәт итәргә мөмкин. Анда татар мәркәзе, Сөембикә хакында да сүз бара. Хәмит Зөбәер Кошай бу әсәрдә «большевиклар золымы тасвир ителүен» искәртә. Әмма драманың эчтәлеге бу идея белән генә чикләнми. Анда мәхәббәт тә, гаилә мәсьәләләре дә, ireккә омтылыш та һ. б. да бар. Иң мөһиме — кешеләр язмышы, чор фаҗигасе.

«Тормыш көзгесе»нең тәүге күренешләрендә егет-кызларны тасвирлау өстенлек итә. Алар яшьлеккә хас булганча бәхәсләшәләр, көлешәләр, шаяралар. Җыр-музыка да бу егетләр һәм кызлар белән бергә. Хәлим иҗат иткән көйләр аларның рухына туры килә. Яшьләрне уртак куаныч, хис берләштереп тора: каракош алып ташланган, ирек килгән, Милләт Мәҗлесе эшли (ул 1917 елның 22 ноябрендә ачыла, 1918 елның 11 гыйнварында большевиклар тарафыннан куып таратыла). Егетләр һәм кызлар татарның данлы үткәнен, аянычлы соңгы хәлен искә төшерәләр, яңа тормыш өчен көрәшергә ант итәләр. Романтик рухлы бу яшьләр арасында драманың төп каһарманнары Хәлим белән Нәфисә дә бар. Егет авылдан чыккан. Үз көче белән көн күрә. Хәзер Нәфисәнең

этисе — Гали байда хезмәттә («конторщик»). Консерваториядә дә дәресләр ала. Пианинода уйный, көйләр яза, җырлый. Нәфисә белән аның арасында көчле мәхәббәт.

Алга таба вакыйгалар куера башлый. Әнисез дә калган Хәлимнең этисе дә авыр хәлдә. Нәфисәнең дә ата-аналары егетнең үтенечен кабул итми. Бераздан большевик гаскәриләр килеп, Гали байны, аның хатынын яралыйлар (бармагын кисеп, йөзекләрен алалар), акчаларын, алтын-көмешләрен үзләштерәләр. Хәлим Нәфисәне коткарып кала. Моның өчен Гали бай яшьләргә үз фатихасын бирә дә ярадан үлеп китә. Озак та тормый кызның әнисе дә вафат була.

7—8 еллап вакыт үтә. Хәлим белән Нәфисәнең Ирҗан һәм Айсылу исемле балалары бар. Фәкыйрьлек, тар, салкын бүлмә, ачлык. Нәфисә авырый. Хәлим таш эшендә. Әмма гаиләдә мәхәббәт, инсани мөнәсәбәтләр яши. Бервакыт төнлә белән боларның өенә «ике солдат» килеп керә, авыру хатынны, балаларны мылтык түтәсе белән кыйнап, Хәлимне кулга алалар. «Бай кияве» булганы өчен һәм нахак бәла ягылып, Хәлимне Соловкига сөрәләр. Бераздан Нәфисә аның үлем хәбәрен ала. Әхмәт исемле бер кешегә кияүгә чыга, һәм алар бер чит илгә качып китәләр. Биредә Әхмәт үзенең бик бай «абзасы»н таба. Бу кеше йортын, байлыгын Әхмәт белән Нәфисәгә калдыра.

Соңгы пәрдәдә вакыйгалар чит илдә бара. Ирҗан һәм Айсылуга инде 16—17 яшь. Мул тормыш. Әмма Нәфисә генә Хәлимне оныта алмый.

Әхмәтләр йорты тирәсенә еш кына кара күзлекле бер фәкыйрь килеп йөри. Сиздермичә генә балаларны күзәтә. Бервакыт Ирҗан һәм Айсылу уйнаганда, туплары бу кешегә барып төшә. Балалар аның янына килеп гафу үтенәләр. Әмма бу фәкыйрь шулчак йөрәген тотып үлә. Баксаң, бу зат Хәлим булып чыга. Ул Соловкидан качкан, үзенең киемнәрен, документын бер мәетнеке белән алыштырып, чит илгә киткән була. Очраклы рәвештә Нәфисәләр торган шәһәргә эләгә. Хәлим балаларының иминлеге өчен үзен белдертми йөри. Һәм, гомумән, аның гомер ахыры, аянычлы сукбай тормышы якыннары өчен, мөгаен, мәңгелек бер сер булып кала.

Хәлим — талантлы (ягъни җыр-моңга бай), намуслы, милли җанлы, йомшак күңелле, сентименталь табигатьле инсан. Ул олы мәхәббәткә ия. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»ендәге Зыяга да охшаш. Анда балаларын ярату, аталык хисе дә көчле. Әмма мондый затларга яшәве кыен. Иҗтимагый-сәяси хәлләр Хәлимнең язмышын тагын да авырайта. Ул үлгәч, аның нотага салынган җыры табыла.

Бу әсәрне Хәлимнең улы белән кызы пианинода уйнап җырлыйлар. Нәфисәнең күзеннән яшьләр килә. Ул болай ди: «Бу җыр бик эчемне яндырды. Һай, бичара, кем белә, бәлки, бу шигырь — аның үзенең тормыш көзгеседер... Балалар, тагын шуны бер кат уйнагыз әле». Ирҗан белән Айсылу уйнап җырлый. Шуннан соң әсәр тәмамлана, пәрдә төшә.

Бу — Хәлимнең авыр язмышын, җан газабын гәүдәләндергән символик бетем. Автор фикеренчә, бу җыр — каһарманның тормыш көзгесе. Әмма мондый фаҗигале бетемдә яшәешнең оптимистик диалектикасы да бар. Беренчедән, җыр яңгырый, димәк, тереклек бар. Бу моң исәннәр күңелен кузгаткан. Икенчедән, гәрчә үзе корбан булса да, Хәлимнең бала-чагасы, буыны кала, җыры-моңы яңгырый, димәк, яшьлек идеалларының юкка чыкмаслыгына өмет бар.

Нәфисә язмышында билгеле бер дәрәҗәдә авторның үз тормышы да гәүдәләнеш таба. Ул да, Октябрь инкыйлабын, яңа тәртипләрне кабул итә алмыйча, мөһаҗирлек юлына баса. «Тормыш көзгесе»ндә Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» пьесасына аваздаш, охшаш яклар да бар. Бу аеруча большевикларның эш-гамәлен, золымлыкларын күрсәтүдә күзгә ташлана. Биредә хәтта урыны белән артык тенденциозлык та сизелә. Мәсәлән, яңа система тарафдарлары гел тискәре сыйфатлар белән генә тасвирлана.

Әсәрдәге персонажларның сөйләме аларның холык-табигате, иҗтимагый-социаль хәле белән табигый яраша. Мәсәлән, тормышны күргән Гайнеддин агай авылдагы күңелсез, фаҗигале хәлләрне җайлап кына җиткерә белә. Хәлимне тынычландыру өчен, «Алланың хөкеменә чара юк, үлем тазамы, авырумы дип карап тормый, сәгате җитсә ала да китә»,— дип өстәп тә куя. Аның телендә төрттерү, юмор да бар. Егетнең консерваториядә укыйм диюен Гайнеддин агай «капсаң каба тор» дип ишетә, музыка коралында уйнауга «безнең авылның көтүче Нуридан гына өйрәнергә кирәк» дигән киңәш бирә. Гаскәриләр сөйләме өчен басым ясау, куркыту, мыскыллау хас.

Драмада катнашучылар телендә урынлы гына кулланылган кызыклы детальләр, гыйбарә-тәгъбирләр күзгә ташлана. «Дөнья гыйшыктан гына тормый»; «Безнең турыда (ягъни татарның үткәне хакында.— *Х. М.*) сүз ачылганда, бөтен дөнья усак яфрагы төсле... тетри башлый иде»; «Кар башына кар җитә, кыз башына кыз җитә» һ. б.

«Тормыш көзгесе» драмасы тәүге мәртәбә 1937 елның 31 гыйнварында Хельсинки сәхнәсендә уйнала. Ул зур уңыш белән бара. Анда Гаяз Исхакыйның, авторның да катнашуы мәгълүм. «Яңа милли юл» журналының 1937 елгы 3 (108) нче санында (20—21 б.) «Хельсинкида милли-әдәби кичә» исемле мәкалә басыла.

«Гыйнварның 31 ендә Хельсинки шәһәренең зур залларыннан берсендә «Финляндия төркләре Берлеге» (ягъни татар җәмгыяте.—*Х. М.*) тарафыннан милли кичә ясалды. Кичәгә Финляндиянең Тампере, Або, Вибург (Выборг.— *Х. М.*), Котка вә башка шәһәрләреннән килгән кунаклар да шактый күб иде. Кичәне берлек рәисе Ибраһим Гарифулла бәк ачкач, әдәби бүлемендә башлаб Нәҗия туташ Габделрәхим тарафыннан пианода (пианинода.— *Х. М.*) «Аксак Тимер маршы» уйналды. Соңра чук сөемле мәктәб балалары күмәк һәм берәм-берәм сәхнәгә чыгыб, «Туган тел», «Милли моң», «Ашкынам», «Сөембикә маршы», «Яшьләргә», «Күбәләк», «Аерылмаек», «Пар ат» кеби халык җырлары вә әдәби шигырьләр сөйләнеб алкышланды. Мәктәб балаларыннан Мөнир Рәхмәтулла, Сания Гали, Нияз вә Рәфгать Бәшәрләр, Гыйффәт вә Әдибә Таһирлар тарафыннан әйтелгән милли шигырьләрне халык бик яратыб тыңлады. Соңра сайгылы (хөрмәтле.— *Х. М.*) Закир Кадыйри бәк әдәбият вә театрның милли тәрбиядәге роле хакында озын вә бик кыйммәтле сүз сөйләб, беренче бүлем тәмам булды.

Икенче бүлемендә Сания Гыйффәт ханымның «Тормыш көзгесе» исемле дүрт пәрдәлек драмасы уйналды. Үз халкымыз тормышыннан алынып язылган бу драма — чын мәгънәсе берлә әдәбият сахәсендә (мәйданында.— *Х. М.*) Сания Гыйффәт ханымның шагыйрәлеге өстенә, бөек бер әдибәлеген күстәргән (күрсәткән.— *Х. М.*) бер әсәрдер. «Финляндия төркләре Берлеге» бу әсәрне басдырырга карар итү берлә, әсәрнең Финляндия төркләре каршында кыйммәте үлчәнгән булуы адына Сания Гыйффәт ханымны алкышлар туфаны эчендә сәхнәгә чыгарыб, берлек тарафыннан букет тәкъдим ителүе әсәрнең нә дәрәҗәдә тәэсир быракдыгына (ясавына.— *Х. М.*) бөек бер дәлил булса кирәк.

Кичә 250 кешенең иштираке (катнашуы.— *Х. М.*) берлә, аеруча карт әдибемез сайгылы Гаяз әфәнде Исхакыйның да кичәдә хазыйр булуы (катнашуы.— *Х. М.*) кичәнең томансыз саф һавасы артында күтәренке бер рух берлә тулы вә матур там (тулы.— *Х. М.*) бер милли кичә төсен алуы аеруча кайд итәрлекдер («игътибарны җәлеп итәрлекдер».— *Х. М.*). Уйналган драма, байтак авыр бернәрсә булса да, уйнаучыларның һәрберсе үз ролен көтелгәннән күб артык бер дәрәҗәдә осталык берлә чыгардылар. Баш рольләрне алыб баручылардан Хәлимә туташ Габделрәхим — Нәфисә ролен, Госман Гали Хәлим ролен тәҗрибәле оста артистлар дәрәҗәсендә яхшы чыгардылар. Суфлер һәм режиссер вазифасын күргән Гайсә Бәшәр — Гали ролен, Фәрихә туташ Миңлегөл ролен фәүкылгадә (гадәттән тыш.— *Х. М.*) бер мәһарәт (осталык.— *Х. М.*) берлә уйнадылар. Кадрия Хәким — Гайниҗамал ролен, Назыймә Хәким Гөлбану ролен уйнаулары һәр җәһәтдән килешле чыкды. Укыган яшьләр рольләрен Зәйтүнә Габделрәхим, Халидә, Кадрия, Зиннәт Габдулла, Әнүр Сәлах, Фуад Хәким, Хөсәен Габделрәхимләр там (тәмам.— *Х. М.*) бер милли яшьләр төсен биреб, сөйләгән сүзләре дә тирән мәгънәле, күб тәэсирле сүзләр иде. Гаскәриләр ролен Садрый Гарифулла зур кабилият (талант.— *Х. М.*) берлә, Зыя Җамлихан вә Әнүр Сәлах да үз рольләрен бик килешле чыгардылар. Сәхнә бүлеге туктаусыз алкышлар эчендә беткәнлекдән соңра, Гаяз Исхакый бәкнең йитешсезлекләремез, милли бурычларымыз хакында ачы-ачы хакыйкатьләрне ачыб биргән озын сүзе тыңланды. Гаяз әфәнденең үткен чыбыркысы һәммәбезнең аркасында уйнаса да, тугрылыкның татын, тәмен белгән халкыбыз тарафындан сүрәкле («көчле».— *Х. М.*) алкышлар берлә каршы алынды. Имам Вәлиәхмәд Хәким хәзрәтләре кичәнең соңгы сүзен яшьләргә тегәб сөйләде: «Яшьләр! Һәр эшеңездә каһарманлык күрсәтмәк бурычыгыздыр. Милләт сездән каһарманлык көтә!» — дия, алкыш эчендә бетерде.

Сәгать алтыда башланган кичә сәгать уникеләрдә тәмам булгач, яшьләр тарафындан Сания Гыйффәт ханым илә Гаяз бәк шәрәфенә чәй зыяфәте (мәҗлесе.— *Х. М.*) бирелде». «Хәбәрче».

Бу материалның авторы, ягъни «Хәбәрче»,— мәкаләдән аңлашылганча, бу кичәдә үзе дә катнашкан зат. Ул,— мөгаен, Тампереда яшәүче, Гаяз Исхакый белән аралашып торучы Халидә Вафаның әнисе Мәхрусә Вафадыр. Чөнки бу милләтпәрвәр зыялы «Яңа милли юл»да еш язышып тора. Мәгълүматны Сания Гыйффәт, Закир Кадыйри яисә Гаяз Исхакый үзләре дә әзерләп бирергә мөмкин.

Бу мәкалә, тарихи бер факт буларак, күп нәрсә хакында сөйли. Беренчедән, Суомида гомер кичерүче милләттәшләребез татар милли-мәдәни тормышында яшәгәннәр, әдәбият, сәнгать, аеруча театр белән кызыксынганнар, төрле кичәләр, очрашулар оештырганнар. Икенчедән, бу материал Г. Исхакыйның Финляндиягә килүен, биредәге татарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә торуын янә бер күрсәтеп тора. Бөек әдипне хөрмәт иткәннәр, аның сүзләренә колак салганнар. Гаяз Исхакый, гадәттәгечә, мактау-тәнкыйть сүзләрен, киңәш-теләкләрен туры, ачык итеп бәян кылган. Өченчедән, «Тормыш көзгесе» тамашачылар тарафыннан кабул ителгән, аларның күңелендә авторга теләктәшлек, хөрмәт уянган. Дүртенчедән, «Яңа милли юл»да басылган бу мәкалә Сания Гыйффәтнең Гаяз Исхакый белән мәсләктәш булуын, аларның бу елларда да аралашуларын янә бер мәртәбә раслап тора.

* * *

Кытай, Япуния, Румыния, Польша һәм кайбер башка төбәкләрдә оешыбрак яшәүче татарлар, үз балаларын милли-дини рухта тәрбияләү өчен, мәктәпләр, түгәрәкләр ачканнар, төрле дәреслек-әсбаплар чыгарганнар. Бу эш аеруча Финляндиядә әйбәт оештырылган. Биредә, мәсәлән, йөзәрләгән китапның нәшер ителүе мәгълүм. Болар арасында Сания Гыйффәт Кадыйриның «Уку китабы» мөһим урынны алып тора. Чагыштырмача зур форматлы, алтмыш битлек бу дәреслек гарәп хәрефләре белән Хельсинкиның «Финляндия төрк нәшрияты җәмгыяте» тарафыннан 1938 елда чыгарылган. Китапның язылу, басылу тарихы хакында мондый искәрмә дә бар: «Хельсинки шәһәрендә торучы изге ниятле сатучылар бездән Хәмзә әфәнде Йосыф вә сайгылы (сөекле.— *Х. М.*) ибдәше Гали бикә Ибраһим, 1935 елында 8 мартта вафат иткән угланлары мәрхүм Габделкадыйр әфәнде Йосыфның рухына багышлаб, бу китабны басдырыб, гыйлемгә, китабка сусаган балаларымызга, яшьләремезгә иң кадерле бүләкләрен соналар…» (2 б.). Дәреслек яхшы кәгазьдә, шрифтлары ачык итеп басылган. Тел-стиле үтемле. Гомумән, түбәнрәк сыйныфларга адресланган бу китап уку, файдалану өчен уңайлы. Аның тышлыгында Сөембикә манарасы төшерелгән. Бу юкка гына түгел. Чөнки китаптагы материаллар татар рухын үстерүгә, милли тәрбия бирүгә, Казанның милләтебез өчен пайтәхет, мәркәз икәнлеген раслауга юнәлтелгән. Сөембикә манарасы исә боларның һәммәсенең үзенә күрә бер символы булып тора.

Кереш сүзендә автор дәреслекнең төзелеше, төп юнәлешләре, максат-бурычлары хакында искәртеп үтә. «Китабның язылышында,— ди ул,— шул нигезләр күздә тотыла:

1) Төп тормыш вә милли тормыш белән таныштыру.

2) Балага сүз байлыгы бирү.

3) Бала белән бик киң итеб, җәелеб, тармакландырыб сөйләшергә юл ачу.

4) Гомуми аң вә белемләренең киңәюенә булышу.

5) Милли тойгы вә аң, милли тәгассыб (биредә: патриотизм.— *Х. М.*) вә төркчелек рухын ашлау һәм шул ук чакда аларны эш белән дә бәйләү күздә тотылды.

Укытучыга җиңеллек вә тел сабакларына булышчы булсын өчен, төрле сораулар, йомыш вә үрнәкләр куелды» (2 б.).

Китапның эчтәлеге, төзелеше авторның бу сүзләрен тулысы белән раслап тора. Анда, чыннан да, балаларга белем, тәрбия бирү, аларның милли рухын үстерү, эзләнү, фикерләү сәләтен камилләштерү юнәлешендә шактый эш башкарылган.

Дәреслек, нигездә, ел фасылларына туры китереп, тематик принципта төзелгән. Анда табигать һәм җәмгыятьнең, кешеләр яшәвенең төрле тармаклары буенча материаллар бирелә. Мәсәлән: авыл, кала, үсемлекләр, хайваннар; җәйге, көзге, кышкы, язгы эшләр; тарихи сәхифәләр; бәйрәмнәр һ. б. Ел фасылларына һәм куелган темаларга мөнәсәбәттә фольклор һәм язма әдәбият үрнәкләре бирелеп бара. Алар тәрбияви һәм эстетик яктан белеп, шактый зәвык белән сайланган. Китапта без Г. Тукай («Пар ат», «Исемдә калганнар», «Эш»), Г.Исхакый («Сабан сөргәндә»), Дәрдемәнд («Кыш көннәре»), З. Ярмәки («Ак каен») һәм кайбер башка әдипләрнең әсәрләре белән очрашабыз. Авторлары күрсәтелмәгән шигырьләр дә бар.

«Уку китабы», бер яктан, Сания Гыйффәтнең педагог, дәреслекләр төзүче икәнлеген күрсәтсә, икенче тарафтан, ул авторның әдәби, тәнкыйди эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнешле. Чөнки китапта аның шактый гына үз язмалары да бар. Аларның бер өлеше — белешмә, мәгълүмат бирү, икенче кыйсеме — әдәби характерда. Мәсәлән, китапта авторның «Углымның җыры» исемле мәшһүр шигыре урын алган (59—60 б.). Шулай ук без биредә Сания Гыйффәтнең кыска-кыска хикәяләре, әдәби-тарихи эчтәлектәге чәчмә әсәрләре белән дә очрашабыз. Алар, әхлакый, педагогик максатны күздә тотып, укучыларның психологиясен, кабул итү үзенчәлекләрен искә алып язылганнар. Бу чәчмә әсәрләрнең күбесе балалар тормышы, гаиләдәге һәм мәктәптәге мөнәсәбәтләр, вазгыятьләр белән бәйле. Мәсәлән, «Ябык ел» хикәясендә кояшлы көннәрне генә яратучы, болыт-яңгырларны өнәмәүче бер кечкенә кызның корылык аркасында көзен үзенә дә кыенлыклар килүе тасвирлана. Ахырда ул «болытны, яңгырны да кояшны сөйгән төсле үк сөяргә кирәк икән» дигән нәтиҗәгә килә.

«Мәктәптә» язмасында шәкертләрнең үтенече белән мөгаллим Тукайның бала чагы, халыкның бөек шагыйрьгә мәхәббәте хакында кыска һәм үтемле итеп бәян итә.

«Язгы Идел өстендә (Бер баланың истәлеге)» әсәре бөек елганың матурлыгын тасвирлау белән башлана. «Ут көймәсендә»ге (пароходта.—*Х.М.*) бер ана, аның кызы һәм улы Иделнең гүзәллегенә хозурланып баралар. Шунда кечкенә кыз: «Әни, әни, Сөембикә дә Казаннан шулай … киткәнме?» — дип сорап куя. Ана, кызына җавап рәвешендә, ханбикә хакында сөйли башлый. Аның сөйләме алга таба да кызның сорау-үтенечләре белән бүленеп бара. Мондый алым хикәяләүнең табигый агышын, үтемлелеген тәэмин итә. Кызыклы, гыйбрәтле чагыштырулар, мисаллар китерелә. Бала әнисен Сөембикә, үзен аның улы Үтәмешгәрәй белән чагыштыра. «Аһ, әнкәем,— ди ул,— әгәр мине синнән көчләп аерсалар иде, мин синнән башка тора алмас идем, үләр идем…» Боларның сүзен тыңлап торган кечкенә малай — Батыр — «Сөембикә бәете»н җырлый башлый:

Идел ага, яр кагып,
Уңга-сулга чайкалып;
Ут көймәсе китеп бара,
Сөембикәне алып…

Алга таба бу бәетнең янә өч строфасы китерелә. Күрәсез: «Язгы Идел өстендә…» язмасында татар бәйсезлегенең символы булган Сөембикә образы үткән һәм хәзерге вакыт яссылыгында, лирик-эмоциональ мөнәсәбәт планында тасвирлана. Кечкенә кыз һәм малайның уй-кичерешләре, әлбәттә, укучыларның да күңел дөньясына күчә.

Шагыйрь йөрәкле, милли җанлы Сания Гыйффәтнең «Уку китабы» иҗади башлангычны, күп кенә материалларны туплаган оригиналь дәреслек рәвешен алган. Үзенең рухы, эчтәлеге, төзелеше белән ул Г. Тукай, Г. Ибраһимовларның дәреслекләр язу өлкәсендәге традицияләрен уңышлы дәвам иттерә. «Уку китабы»ның Суомида гына түгел, мөһаҗир татарлар яшәгән кайбер башка төбәкләрдә дә (Харбин, Токио, Гөлҗа һ. б.) укылуы, дидактик әсбап рәвешендә файдаланылуы мәгълүм.

* * *

Сания Гыйффәт — шагыйрә, прозаик, педагог, драматург кына түгел, ә публицист, әдәбиятчы да. Аның, әллә ни күп булмаса да, әдәби, иҗтимагый, тарихи, мәдәни темаларны яктырткан язмалары да бар. Алар, нигездә, «Яңа милли юл» журналында һәм «Милли Байрак» гәҗитендә дөнья күргән.

«Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә» исемле мәкаләсендә (Яңа милли юл.— 1937.— № 4.— 13—16 б.) Сания Гыйффәт бөек әдипнең иҗатына кыскача күзәтү ясый. Якташының иҗади фикерләвенә хас аерым сыйфатларын, эшчәнлегенең әһәмиятен күрсәтә. «Аның әсәрләре,— ди ул,— бер генә кат укылыб ыргытылмый, ул кат-кат укыла вә ничә кат укылса да ялыкдырмый, яңалыгын җуймый, аның яраткан типлары кайчакны эч катырганчы көлдерә, кайчакны сулкыдырыб-сулкыдырыб җылата». Мәкалә авторы «Зөләйха»ны Г. Исхакыйның «шаһ әсәре» дип атый. «Аның бу китабы гына аны мәңге яшәтергә вә аның исеменә абидәләр (һәйкәлләр.— *Х. М.*) утыртырга чакырырлыкдыр.

Аның әдәби эшләренең күләмен күрсәтә алу өчен, аның халкыбызның рухына ашлаган сөйләб бетергесез тәэсирләрен аңлата белү өчен, аның әсәрләрен вә иҗтимагый тормышыбызның тарихын, вә үзгәрешләрен, халкыбызның аң вә тәрбия дәрәҗәсен бик нечкәләб үлчәргә, бик җентекләб тикшерергә тиеш. Шуннан соң гына, бәлки, аның эшләренең чын үлчәве, зурлыгы вә тәэсире аңлашыла белер. Шуның өчен монда аның тугрындагы берничә сүз аны бик сүнәк кенә («кечкенә» генә.— *Х. М.*) итеб танытачакдыр».

1936 елның 12 апрелендә халкыбызның йөзек кашы, бәһаләп бетергесез хадиме Ризаэддин Фәхреддин фаный дөньядан китеп барды. Мәскәү хакимияте, гәрчә бу олуг зат исән вакытта аңа тынгы бирмәсә дә, аның үлемен күрмәмешкә салыша. Әммә бу кайгылы хәбәр мөһаҗәрәттәге төрки-татарларны тетрәндерде. Тиз арада гәҗит-

журналларда төрле материаллар дөнья күрде. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналының 1936 елгы 7—8 нче саннары (июль-август) махсус рәвештә Ризаэддин Фәхреддингә багышланган. Анда Гаяз Исхакый, Вәлиәхмәд Хәким (Финляндия), Закир Кадыйри, Хатиб Халиди һәм башка билгеле затларның хатирә-тәэсирләре бар. Болар арасында Сания Гыйффәтнең дә лирик-публицистик планда язылган «Мин нәрсә?» исемле материалы урын алган.

Шагыйрә Ризаэддин Фәхреддин белән якыннан аралашканмы, юкмы — анысы хәзергә караңгы. Әмма ул бу бөек затның эшчәнлеген, әсәрләрен, хезмәтләрен яхшы белгән. Ире Закир Кадыйри Риза Казый белән Мисырда укыган вакытта ук хат алышып торган. Оренбургта, Уфада аларның «атна саен диярлек» очрашып, сөйләшеп торуы мәгълүм. Кыскасы, Сания Гыйффәт Ризаэддин Фәхреддиннең шәхесен, эшчәнлеген, иҗтимагый ролен яхшы белеп, тоеп яза.

Элеккеге әдәбиятның күп кенә ядкярләрендә яхшы кеше үзе үлсә дә, «игү аты» мәңгелек дигән караш үткәрелә. Сания Гыйффәт тә олуг остазның үлемен шул рухта яктырта. «Аның үлемгә мәхкүм булган вөҗүде,— ди ул,— арабыздан аерылыб, үлә торган минләргә, барлыкларга катнашканы хәлдә, исеме берлә һаман да хатерләрдә калачак вә үлмәячәк булган барлыклар җөмләсендән булыб, һәр заман арабыздадыр». Мәкалә авторы Риза Казыйның сабырлык вә тугрылыкта инсаннарга игътибарлылыкта гаҗәеп зат булуын искәртә. Аның өчен милләт, гавам мәнфәгатьләре барыннан да кыйммәт. «Мин» сүзе аның каршысында бер юк хөкемендә бик кечкенә бернәрсә генә, аның каршысында «мин» түгел, «без» генә бар, шуңар күрә хәятта аның бөтен эшләгән эшләре «без»гә генә кайта, «без» өчен генә эшләнә. Автор фикеренчә, Ризаэддин Фәхреддин «үзенең милләтен үзендәге бөтен кодрәтләрдән файдаландырды, үстерде, тәрбия итде», ягъни үз кавеме, инсаннар өчен чын мәгънәсендә остаз булды.

* * *

Сания Гыйффәтне гасыр яшьтәше дип атарга мөмкин. Ул үз дәверенең зилзиләләрен, күп кенә шатлык-газапларын үз йөрәге аша кичергән. Аның язмышы татар хатын-кызы өчен генә түгел, ә гомумән, инсан өчен дә шактый гыйбрәтле. Туган иленнән, газиз халкыннан аерылып, мөһаҗирлектә гомер кичерү — үзе генә дә зур газап, олуг фаҗига. Әмма шунысын да онытырга ярамый: әгәр дә Кадыйрилар илдә калган булсалар, аларның гомере, башка бик күп кенә татар зыялыларыныкы кебек, мөгаен, 30 нчы елларда ук киселгән булыр иде. Чөнки шул чордагы матбугатта Закир Кадыйрины «буржуа ялчысы», «милләтче», «динче», «хыянәтче» дип сүгүләр тулып ята. Ә инде андыйларның хатыннарын, бер гөнаһлары булмаса да, СССР эчке эшләр халык комиссарының 1937 елгы 15 август приказы (№ 00486) нигезендә кулга алу, җәзага тарту каралган.

XX йөзнең 10 нчы елларында әдәбиятка килгән Сания Гыйффәт үзенең шигъри, драма, проза, тәрҗемә, фәнни-публицистик әсәрләре белән татар сүз сәнгатенә билгеле бер өлеш кертә. Аның иҗатына миллилек, татар язмышы өчен яну-көю, көрәшчелек рухы хас. Шагыйрә — Исхакый мәктәбе вәкиле, аның фикердәше, каләмдәш дусты. Мөһаҗәрәттәге күренекле татар зыялысы Хәмит Зөбәер Кошай әйтүенчә, Сания Гыйффәтнең «Казан ләһҗәсе белән язылган шигырьләренең күп кенә мисраглары (юллары.— *Х. М.*) дога кеби тәкрарланып йөри». Профессор Фәһимә Хисамова да үз әнисенең Сания Гыйффәт иҗатындагы аерым юлларны (мәсәлән: «Хәсрәтеңдән җаннарым көйде, җаным, су бир!» — дисәм, Учлатыб киткән икән утлы күмерне белмәдем»; «Мин күләргә авзым ачсам, аһ булыб ялкын чыга, Күзләремдән тамчылый яшь, сүзләрем салкын чыга» һ. б.) еш кабатлавын искә ала.

Сания Гыйффәтнең милли рухлы әдәби традицияләре Гәүһәр Туганай, Ләбиб Каран, Исфәндияр Ишгай, Минһаҗ Исмәгыйли, Наилә Бинарк һәм мөһаҗирлектәге кайбер башка татар әдипләре тарафыннан дәвам иттерелде. Сания Гыйффәтнең 16—17 яшьләрдә язылган бер шигырендә «Күб заман үтмәс, тәнем гүргә керер» дигән юл бар. Әйе, романтик рухлы, ялкын йөрәкле шагыйрә инде күптән җир куенында. Әмма аның дәртле, сагышлы, сугышчан рухлы әсәрләре, «Батыр бул! Ирлекеңне җуйма, еглаб торма дөньяда», «Ташламам утлы мәхәббәтне тәмам үлгәнчегә», «Әй татар! Уйлан бераз син…», «Юк, берәүгә баш имәм!» кебек шигъри юллары ике гасыр, ике меңьеллык аралыгында яшәгән бүгенге укучы өчен дә чит түгел.

*2003*

***Сания Гыйффәт әсәрләре***

## Шигырьләр*

### Зар

Язма, каләм, уйлама, баш, сүнче, әй дәрдем минем!
Кем суза кул соң сиңа, кем соң йитәкләүчең синең?

Мин адашкан кош кеби булдым, кунарга юк ботак,
Юк күгемдә балкыган ай, калды ак таңым ерак.

Нәрсәгә манчыб сине языйм, каләм, юк бит карам!
Утлы, ялкынлы мәхәббәт яшьләре кибде тәмам.

Ак кәгазь өстен каралтыб таблатырга юк дәвам,

Чөнки күңлем вулканы сүнгән, атылмый таш вә җам.

Мин бирешмәслек идем бит, бу фәләкнең
(«язмышның».— *Х. М.*) каһренә,
Дәрига (үкенеч.— *Х. М.*)! Иң ачы агуын
тамызды бәгъремә...

**Аңладым**

Үтде гомрем җил кеби, үткән икәндер белмәдем,
Ай-кояшка алданыб, алдымда төнне күрмәдем.

Күкрәгемдә ялкыным сүнгән, «Кабынмый ник?» — дисәм,
Сүндерүче су сибеб «хәсрәт» икәндер белмәдем.

Кул сузыб, «Дустым, йөрәкдән ал, бу хәсрәтне!» — дисәм,
Ул миңа андан авыр хәсрәт бирер диб белмәдем.

«Хәсрәтеңдән җанларым көйде, җаным, су бир!» — дисәм,
Учлатыб киткән икән утлы күмерне, белмәдем.

Кайда Коръән, кайда — мөэминләрне мин күрмим дисәм,
Коръәнем янда,— алар качкан икәнне аңладым...

**[Әй бәхет!]**

Әй бәхет! Син ник качасың, ник куналмыйсың миңа?
Әллә күкдән Җәбраил фәрман китердеме сиңа?

Якты көнләр, чын мәхәббәт юлдаш улмый ник миңа?
Әллә җирдән киртәләндеме мөкатдәс юл миңа?

Эзләнәм мин чын бәхетне, кайда качкан, әйтегез!
Әйтегез дә ул качыб торган урынга илтегез!

**Кыйтга**

Михвәрендә (күчәрендә.— *Х. М.*) тиб-тигез йөреше белән
Җир әйләнә,
Ул йөри, бергә аның йөршендән ай, ел әйләнә.

Һәм шулай ук тиб-тигез, акрын йөрешләр берлән ул,
Бергә шадлыклар да кайгылар катыш гомер әйләнә.

**Тәэсир**

Рухны үткен бер кисү берлә кисәсең, моңлы саз!
Иң тирән серләрне эчдән болгатасың, ямьле саз!

Мин көләм тышдан, җылыйм эчдән сызыб, хальдән таеб,
Сыздырыб, дулкынланыб киткән чагында моңлы саз.

**[Мин була алсам...]**

Мин була алсам болыт яудырмага рәхмәт суын,
Бар мөселмандан җуар идем кирәкмәс чир, чүбен.

Килми, әлбәттә, минем көчдән бу, буш булган хыял,
Әй Ходаем, сал үзең киң рәхмәтеңне, бир дә халь.

**Нигә тынмыйм?**

Мин нигә тынмыйм соң инде, күзләрем йокламыйлар?
Уйларым таркау, алар бер ноктага туктамыйлар.

Мин ялынмыйм, бар ягымда әйләнәм, пошнам һаман,
Күзләрем ачыла, йокым килми, ләкин белмим нидән.

Әллә нинди бер куәт яшрен генә баскан мине,
Котрыныб ташкан тирән диңгез тыныб калган кеби.

Мин җәфасыз күк бу төн, тыб-тын йөрәк, ул сызламый.
Никдер эчдә бер тынычлык, җан өзелми, егламый.

Бар кеше йоклый, тынычлыкка чумыб киткән тәмам,
Мин тыныч эчдән, ләкин тышдан тыналмыйм ник һаман?

Әллә михнәт әйләнәме чын бәхетле көнгә, дим,
Әллә җан өзгеч газабка күндеме, дим, бу җаным...

## Юк хакыйкать

Мин сөймим шөһрәт, сөймим байлык, сөймим зур мәртәбә,
Чөнки дуст түгел алар миндәй сагышлы бәндәгә.

Шул сагышдан аерылам бит, булса ул дан, мәртәбә,
Булса байлык, кайда инде, ул «хакыйкать» нәрсәгә?

Юк хакыйкатькә оя, куйдым ясаб сагышымны мин,
Ул сөймәгәнгә күрә, сөймим аларны инде мин.

Сөйми ул, сөймәс дә шул, күрнеб тора: бик хаклы бит,
Бар да шул байлык вә данлыклы тарафлар яклы бит.

## Беренче сәхәр

Барча мәүҗүдат (булган.— *Х. М.*) иляһи көчкә буйсынган
бу төн,
Бу беренче төн сәхәр, серле вә изге төн бу төн.

Бер агач селкетми баш, күлләр дә тын ярылыб ята,
Күкдә йолдызлар көлеб, җиргә караб нурлар сачә.

Тәсбих әйтә барча җан, сулышын да алмый җир йөзе,
Һәр иманлы чын күңелдән сәҗдәдә — җирдә йөзе.

Барсы Тәңрегә юнәлгән, һәр гөнаһдан күз йомыб,
Йарлыкану, ак, бәхетле көн тели, күңлен тегеб.

## Тәбрик

Котлыйбыз туган көнеңне кечкенә, иркә энем,
Көнләрең булсын синең ак һәрвакытда, күз нурым.

Үс матур гөл төсле, үссен бергә гаклың да синең,
«Милләтем өчен үсәм» булсын йитәкләүчең синең.

## Шагыйрьгә

Бирмә сер, түз, аһларың йот, чыкмасын күздән яшең,
Таммасын җиргә ул энҗе тамчы берлә рәнҗешең.

Ялгызың тор, ялгыз эшлә, ялгыз уйлансын башың,
Тик каләм булсын бөтен ялгыз чагыңда сердәшең.

Игътиля итсен (күтәрелсен.— *Х. М.*), шагыйрь, күңлең, югары аш янә,
Һич килешми вак галәмнең ваклыгы зур шаинигә
(дәрәҗәгә.— *Х. М.*).

Син изел, салсын фәләк (язмыш.— *Х. М.*) зур-зур богаулар муеныңа,
Юк зарар, рух тетрәсен, шундан сиңа илһам иңә.

**Син булмасаң**

Дөнья ямьсез, көн күңелсез, төн озын, син булмасаң,
Килми шадлык, гел боеклык, мин ятим, син булмасаң.

Атмый гөлләр, сайрамый кош, акмый су, син булмасаң,
Шауламый күңлем, тына, юк дәрд, әгәр син булмасаң.

Бер томан күз теккән урным, күрми күз, син булмасаң,
Юк, керә алмам, бирсә җәннәтне Ходаем, син булмасаң.

**Охшату**

Мин җыладым, көзге яфракка караб,
Саб-сары булган алар миндәй җылаб.

Күб заман үтмәс, тәнем гүргә керер,
Нәкъ минем күк ул төшеб җирдә черер.

**Сирател-мөстәкыймчеләргә***

Бу кара көч безне җиңмәс, без тамырланган хәзер,
Ир, хатын-кыз — барысы бер, ярты бөтен булган хәзер.

Пакь, кадерле намусымыз бар, сез буяр җирдә түгел,
Төрле хурлыкка чыдаудан узган ул, мескен түгел.

Бездә ныклы бер куәт бар, без ятыб мүкләнмәгән,
Бездә изге бер иман бар, кер белән тапланмаган.

Күкрәде күк, яуды яңгыр, безнең өсдән җил исеб,
Калды милләт инде шундан соң басылмазлык үсеб.

Әй кара көч! Юкка ашкынма, басуны уйлама,
Пис (пычрак.— *Х. М.*) аяклар берлә син милләт күгендә уйнама,

Инде милләт син белә торган сабыйлыкдан чыгыб,
Ир булыб җитде тәмам, кулда кылыч, уклар тотыб.

Кил, батыр булсаң, көрәшкә, уртага чык чын булыб,
Асда ятма, шан-шәрәфле бер исемгә өртенеб.

Бер киңәш бирим сиңа, тыңла сугышка кермәдән
(кергәнче.— *Х. М.*),
Бездә бер сүз бар, диләр: «Чыгуыңны уйла — кермәдән».

*1916*

**Хөррият таңы**

Бер уяныб күр әнә син:

Нинди ямьле таң ата,
Нинди керсез, пакь сәламен
Җылмаеб җиргә ата.

Алды җир ак таң сәламен,
Шад, бәхетле җил аша.
Каршылый таңны бүген ул
Тугрылык, хаклык аша.

Ул кызармый таң кашында,
Таңга гакес (каршы.— *Х. М.*) итми гөнаһ.
Юк залим көч Җир йөзендә,
Бар кеше хөр, шад, азад.

## Бәхет баглаганда

Кайвакыт дөнья миңа никдер тора аркан караб,
Нишләсәм, ни сөйләсәм, һич булмый бер аңа яраб.

Башласам җиң сызганыб эш, алга китми төртелә,
Шадланырга уйласам, ул әйләнә гел кайгыга.

Мин көләргә авзым ачсам, аһ булыб ялкын чыга,
Күзләремдән тамчылый яшь, сүзләрем салкын чыга.

Бәйләсәм күңлем берәүгә чын вә изге дуст белеб,
Кайда дуст, һәйһат (үкенеч.— *Х. М.*)! Аның урнында
бер дошман тора.

Кулны селкеб абдырыйм да күңлемә бер зарланам:
«Ахры, бәхтем баглыдыр, эшнең шуңар киресе тора».

## Мин сөям

Мин сөям ирне, батырлык, көч сачеб торган саен,
Кыз-хатынны мин сөям, нечкә вә саф булган саен.

Мин сөям җәйне, кызудан тыннарым беткән саен,
Мин сөям кышны, буран, карлар тәмам баскан саен.

Мин сөям диңгезне, дулкынларны ул аткан саен,
Бөтерелеб өсткә чыгыб, шаулаб килеб төшкән саен.

Мин сөям дөньяны, ул баскан саен, изгән саен,
Ул изәм диб, мин җиңәм диб, халь-көчем беткән саен.

Пакь мәхәббәтне сөям мин, йөзләрем сулган саен,
Ут юлында җан кыйган пәрванә (күбәләк.— *Х. М.*) күк
булган саен.

Мин сөям, һәрнәрсәдә бер чын сыйфат күргән саен,
Бер табигый юл белән өсткә чыгыб үскән саен.

## Син булмаганда

Урманлар, кырлар,
Сахра, болынлар.
Җиргә нур сибкән
Ай вә йолдызлар.

Матур ага су,

Ямьле киң басу,
Моңлы яз башы,
Язгы су ташу.

Офыкның матур,
Кызарган чагы,
Сандугачларның
Өзеб сайравы.

Май айларының
Серле, тын киче,
Синсез боларның
Ля шәйдер (әһәмиятсездер.— *Х. М.*) барсы.

**Мәүлүд таңында**

Куркынычлы, киң, ачулы, эссе Гарәбстан чүле,
Серле бер бәйрәм таңында таңга калган бу юлы.

Таң җиле — саба, акыртын, бик акыртын бер исеб,
Гүя аңгартды (төшендерде.— *Х. М.*) җиһанга:
«Мисле юк бәйрәм бу»,— диб.

Бар иляһи тын галәм шатландылар бәйрәм итеб,
Чын бәхетле юлга әйдәүче Мөхәммәдне көтеб.

Нәрсәдер селкетде җирне, дерт итеб ул тетрәде,
Күк йөзендә изге тәкбирләр авазы яңгырады.

Шулвакыт тугды пәйгамбәр, сеңде җиргә бар бозык,
Ул туган көндән аякланды җиһанда тугрылык!

Төрле хаксызлыкка селтәгән гарәб хәнҗәрләре,
Керде кынсына кире, бетде адәм рәнҗешләре.

Һәр авырлыкка әсир, тереләй күмелгән кызлары,
Чыкды балкыб яктыга — әйләнде көнгә төнләре.

Ул туды һәркемгә үрнәккә гали (олуг.— *Х. М.*) әхлак белән,
Җиргә, күккә, бар галәмгә мәрхәмәт, рәхмәт белән.

*1917*

**Табигатькә караб**

Мәһабәт берлә зур кояш күкдә йөзеб,
Арыб, талыб иңгән чакда тау артына,
Кичке салкын салмак кына җиргә төшеб
Җәелгәндә акрын-акрын Җир йөзенә;

Урман буе шагыйранә томаланыб,
Чәчкә, үлән хуш исләрен аңгытканда,
Еракдарак тау өстендә катлауланыб,
Җәелеб торган күчмә болыт авышканда;

Шарлаб аккан чишмә таушы катнашканда,
Төрле кошлар, сандугачларның таушына,
Сахра, кырлар серле тынлыкга батканда,
Хәйран калам зур Тәңремнең кодрәтенә.

**Бәхтем таңы**

Мин күзем ачдым, карадым: таң яңа аткан иде,
Төн буе күкдә йөзеб, нур түккән ай яткан иде.

Күкдә җем-җем балкыган йолдызлар инде сүнгәләб,
Таңны белдереп, матур Чулпан торыб чыкган иде.

Күк тирәсе алланыб, күкдә болыт һич юк иде,
Бар табигать җанланыб, кош-корт торыб очкан иде.

Яңлышам: таң юк әле, чын таңга бик иртә иде,
Күк йөзе дөм күк караңгы, урталыкда төн иде.

Бар кеше гырлаб тирән төн йокысыны йоклый иде,
Тик минем күңелемдәге бәхтем таңы аткан иде.

**Хәзер**

Көч дә юк, куәт дә юк, арган вә беткән мин хәзер,
Кулга алган эш дә юк, эшсез вә көчсез мин хәзер.

Зур җаным арган, кыйналган, рух да юк, үлгән хәзер,
Күз тегелгән бер өмид юк, бер җуаныч юк хәзер.

Күзләб аткан ук хата-ялгыш барыб батканымдыр,
Йөз сары, күңлем сүрән, күңлем гөле шиңгән хәзер.

Юк яшеллек, аллы гөлләр, кыш булыб калган җәем,
Юк сафа, шадлык — җан азгы, язмый кул — арган хәзер.

**Васыятем**

(А... гә)

Адашсаң, эз югалтсаң син хәятның зур сәмасында
(күгендә.— *Х. М.*),
Эзләсәң, төшсә рухың, чыкмый катса күздә яшең дә,

Бөтен дөнья томанга чорналыб торса каршыңда,
Җылы, якты урынны табмасаң инсан арасында,

Шулай да гел үләргә йөз тотыб, син дөньядан бизмә,
Сибелсен тоз яраң өстенә, һич беркемгә баш имә.

Батыр бул! Ирлекеңне җуйма, еглаб торма дөньяда,
Түз, әрнетсен, зарар юк, соңра пешкән җир
тиз уңала (төзәлә.— *Х. М.*).

**Көз**

Килде көз. Салкын, иләмсез көн менә,
Җил дулый, шаулый, агачларны бөгә.

Ямь-яшел хәтфә паласдай җир хәзер,
Кап-кара, ямьсез төс алган кайгыда.

Күк йөзен соргылт болытлар каблаган,
Вак кына, тымзык кына яңгыр ява.

Кайда да пычрак, коры җир калмаган,

Төз басыб булмый, аяклар да тая.

Ул сулар салкын, лэтафэт (гүзэллек.— *X. М.*)
калмаган,
Бакча, урман шыр ялангач, кап-кара.

Көйлэре гел эчпошыргыч, җан өзэ,
Дөм караңгы төнлэре җилдэй уза.

### Ил агаларына

Нинди җан бар сездэ, эй сез, зур кавем башлыклары!
Нинди вөҗдан берлэ соң сез тик ятасыз эшлэми?!

Җан түзэрлекме, кара: ил ач, халык җандан яза,
Бер кабым икмэк сораб, гел шыр сөяк куллар суза.

Зур җинаять бит югалту ил йөзендэн бер ата,
Күр энэ анда... аларны: туктамый кырлыб ята.

Тэндэ төклэр өрпэлэр (кабарыр.— *X. М.*),
уйласаң ил бөлгэнен,
Кан кыза, сүткэн саен дошманлары бар үргэнен.

Нинди җан бар сездэ, эй сез, зур кавем башлыклары!
Күрмисезме кан түгеб алган хокуклар нишлэде?!

Эйдэгез алдан, эле без кальгалар кордыкмыни?!
Җан тынычлаб, тын ятырлык интикам (үч.— *X. М.*)
алдыкмыни?

*1918 ел*

## Тэрҗемэ тэҗрибэсе

### Кабер янында

*(Габделхак Хамиддэн)**

Төрек эдиплэренең иң мэшһүрлэрендэн Габделхак Хамиднең «Тарикъ ибне Зияд, яки Фэтхе Эндалис» («Эндалисне яулап алу».— *X. М.*) исемле апиртикасы (оперетта.— *X. М.*) — төрек эдэбиятында кадерле бер эсэрдер. Бу эсэрдэ гарэблэрнең Испанияне фэтих иткэндэге хальлэре һэм алар белэн испаниянлэр арасындагы мөнэсэбэт тасвир ителгэн. Шул пьесаның каһарманлары арасында испан урдусында (гаскэрендэ.— *X. М.*) мэсакыялек — гаскэр сугарыб йөрүче бер кыз бар. Ул мөҗаһид гарэблэрдэн берсенэ гашыйк була. Бу гарэб сугыш вакытында шэһид булгач, теге кыз шуның кабере башына килеб, шул шигырьлэрне сөйли вэ кабере янында үзен үлтерэ. Тэрҗемэ бабындагы тэҗрибэм итеб, шул апиртиканың бер кисэген, бу урында дэреҗ итэм (урнаштырам.— *X. М.*) (*С. Г.*).

**I**

Бер тарафда яктылык юк, тик караңгы көч (төн?— *X. М.*)
кенэ,
Аерылыб күренэ караңгыдан фэкать шул төш кенэ.

Күп йөреб арган кояш яткан тарафмы эллэ ул?
Эллэ ялгыз бер каберме ул күренгэн якты нур?

Бер матурның йоклый торган урны микэн эллэ ул?
Төш түгел, юк, бик ачык бит, күзгэ күренэ өндэ ул.

Шул хэрабэ җир бу көн бер гөлгэ чумган эверелеб,
Эллэ таң көткэн болыт җиргэ җэелгэнме төшеб?

**II**

Монда мәдфүнме (күмелгәнме.— *Х. М.*) минем җандан кадерле ак ярым?
Юкса нурлы ай тотылганмы, караңгы бар ягым?

Күр! Күрәмсең каршы якдагы сүнеб торган кара,
Әүвәле күзне камашдырган матур нур бит, кара!

Чардуган күк чорнаганлар серле кабрен чәчкәләр,
Нинди ямьле чардуган нәкъ кыз өе бу чәчкәләр.

Кыз өе булса әгәр бу чардуган, изге ярым,
Ач җылы куеныңны, мин бит интегеб килгән ярым (? ярың.— *Х. М.*).

**III**

Бер косва (аулак.— *Х. М.*) җир, урны нинди хуш, ни ямьле гөл генә,
Юк фәкать монда бәхет кочагын ачкан хур гына.

Рәхмәтен җәйгән бу җиргә Алла. Пакьлек урны бу,
Аңкыта оҗмах сараен бер гүзәл җан кабре бу.

Яки бер-бер әүлиядыр Тәңрегә ихлас белән,
Мәңгегә куйган башын җиргә ятыб сәҗдә белән.

**IV**

Мин югалырга тиешлемен бу йирдә дөньядан,
Бит кояшым инде баткан — туктаган ул балкудан.

Якты, нурлы бер кояш ул, ләкин ул сүнгән кояш,
Бер караңгылыкда мәшрикъ, нур сачә баткан тараф.

Кайгы киемем чәчкәдән үргән кара төс күрлүгә,
Якты төн, ак төн хәзер мин тик кара төн күрнүгә.

**V**

Бөрсен аткан төрле төсдәге чәчәкләр барсы да,
Тын, зәгыйфь җисмең өмид шәмгыме алдым яктыда.

Изге кабрең охшый күкдәге кояш-нур шарына,
Гүя ул җиргә төшеб чәчкән нурын Җир шарына.

Күк ярылганмы, Ходаем, нинди серле яктылык!
Нурлы гөлләр, аһ, гаҗәб, нинди хуш исле нурлылык!

**VI**

Эзләми һичкем ярын, табса әгәр кат тагын,
Булмасаң син, мин ятим, синсез миңа җәннәт тә буш!

Яткан урның тышкы якдан булса да туфрак калын,
Эч ягындан, шөбһәсез, мең мәртәбә нурлы вә хуш.

Нур эчендә чорналып яткан вакытда син шулай,
Утлы хәсрәтләр йотыб, яныб торалмыйм мин болай.

**VII**

Пакьлегеңне аңлатырга сүз кирәкме, әйтче, ә?

Күр: караңгы төнне кабрең нинди яктырткан әнә!

Күкдән иңгән пакь, мөкатдәс таш кеби ул яки дә,
Гөл, чәчәкләр диңгезендә нурлы гәүдәдер гүя.

Мин дә гәүдәмнең канын бирдем бүләк бераз гына,
Нинди төс берлә төшәр иде бизәкләр өстенә?!

**VIII**

Төрле хуш исле матур гөл чорнаганмы бар ягын?
Яки күкдән исле кар яуганмы каблаб һәр ягын?

Шул матурлык ләззәте берлә исергән бер адәм,
Чын бәхетле бер үлем, диб белмәсен үлмен нидән.

Бу ләхеддә йоклый бер җан, ул түгел салкын мәет,
Аңлый күңлем бу ташын изге терәк күк ташы диб.

**IX**

Син исән чакда минем күңлем сиңа салкын иде,
Күренсәң ямьсез, сөйкемсез, сүзләрең тәмсез иде.

Кайвакыт белдем синең кул селтәвеңне дөньядан,
Гыйшкың авына тотылдым шул сәгать мин кайтудан.

Мин синең изге никахың астына кердем хәзер,
Бар югалган нәрсә булса, мин күрәм синдә хәзер.

**X**

Нурлы кабрең баш куярга михрабым булды минем,
Бу кара толмым минем булсын камәр (билбау.— *Х. М.*)
билгә синең,

Күңлем үз күрде синең динне мөкатдәс, пакь таныб,
Ул бозык бер дин түгел, хаксыз тотылмаз һичвакыт.

Мин гыйшык әмренә буйсындым — бирелдем баш иеб,
Шөбһәсез, Зөһрә сиңа әйләр шәфәгать бервакыт.

**XI**

Әй рәхәт йоклаучы зат, килдем сиңа ярдәм сораб,
Артдагы үткән бәхетләрне кабатларга теләб.

Ач! Җылы куйныңны ач, килдем җыларга яшь түгеб,
Кайгы, хәсрәт, яшь эчендә көйләрем китде үтеб.

Чикли гомремнең ахыр сулышы, якын тарта һаман

*(Бер кечкенә хәнҗәр чыгарыб),*

Ямьле кабрең ачкычы бу хәнҗәрем, күр, күз карам!

**XII**

Бер раһиб (рухани.— *Х. М.*) бирде бу ачкычны —
бу хәнҗәрне миңа,
Ул матур кабрең сигез җәннәткә юл төсле тора.

Ач җылы куеныңны, ач да, барсы да белсен халык,
Бар икән бер башка йортда диб гаҗәбләнсен халык.

Башкалык юк, бер тигез анда адәм һәм һәр җенес,
Башкалык юк диндә дә һәрберсе бер дип җенес.

**XIII**

Аһ, әгәр мөмкин булыб кылсаң иде ихсан (ярдәм.— *Х. М.*) миңа,
Бер кәфенгә чорналыб оҗмахка китсәң — урныңа.

Бер бичара, ач, ялангач, кызганыч калдым менә,
Разыймын шул туфрагың берлә тигез булсам янә.

Ач җылы куеныңны, ач тугсын заманның соң көне!
Күкдә бер йолдызны зольмәт каблаган дисен кеше.

Зольмәт (караңгылык.— *Х. М.*) иңгән якты йолдызга күләгә җирдә ай,
Бер гүзәллеккә матәм һәм бер нәфсе вөҗдан белән.

Аздыруда күб йөреб, шәйтан да бит инде йөдәй,
Бер имансыз колнымы, акланса ул иман белән?!

Сау, таза кешеләр үлемдәй җан газабын тартмыймы?
Кабланыб калган һидаят (туры юл.— *Х. М.*) нуры да туфрак белән.

*(Хәнҗәрен бәгъренә кадаб, кабер өстенә егыла.)*

## Мөһаҗирлек чоры әсәрләре

### Тәңре тавына карап*

Күптән инде үлеп югалганнар
Атиллалар, Чыңгыз, Батулар;
Бу тауларны ашып, җир иңрәтеп,
Күкрәк киереп йөргән батырлар.

Бу тау әле һаман шул тау әле,
Какшатмаган еллар агымы,
Тик йөзендә аның күп җыерчык —
Үткән көннәрнең эз таныгы.

Ак чалмасын урап, сахра буйлап,
Күккә карап, нидер уйланып,
Төрклекнең үткән зурлыкларын
Торган төсле өнсез сөйләнеп.

Ник дәшмисең, нигә сер чишмисең,
Ник торасың болай читсенеп?
Усал колаклардан куркасыңмы,
Әллә уйлыйсыңмы чит диеп?!

Мин дә синең кебек шунда җәйләп
Йөргән бабайларның баласы.
Мин дә синең кебек дәртле йөрәк,
Моңлы йөрәк — илнең баласы.

Кемнәр тотты синең киң якадан,
Кем аерды шөһрәт-даныңнан?
Кем калдырды сине ятим итеп,
Чит кулында төрк иленнән?!

Әйт әле син миңа: күргәнсеңдер
Кем тирәңне элек биләде?

Кемнәр басып синә, кемнәр ашып,
Кемнәр килеп монда җәйләде?

Ни киңәшләр корды, ни сөйләде
Чыгтай*, синдә каган булганда?
Нинди золым, нинди гадәләтләр
Булып үтте синең тирәңдә?

Нинди матур кызлар, яшь егетләр
Синдә җырлап кымыз эчтеләр?
Ак тирмәләр тегеп, куйлар суеп,
Кемнәр синдә бәйрәм иттеләр?

Әйт әле син миңа: күргәнсеңдер,
Ялан кылыч болгап, селтәнеп,
Нинди батыр җаннар моннан үтте,
Симез юргаларын уйнатып?!

Нинди гашыйклар, әйт, серләштеләр,
Синең янда башка баш куеп?
Нинди гашыйклар, әйт, җылаштылар,
Яшел чирәмеңә яшь коеп?

Син күргәнсең: ничек ил еглады,
Нинди башлар шунда кыелды?!
Нинди байлык, нинди шан-шәүкәтләр
Кая китте, ничек тузылды?!

Үлгән илнең хиссез балаларын
Күрәсеңдер, ниләр уйлыйсың?
Нинди каргыш, нинди ләгънәт әйтеп,
Нинди хәсрәт белән карыйсың?

Кая ил торгызган арысланнар?
Югалганнар, көчле ил тузган.
Хисләр сүнгән, тонган утлы күзләр,
Хурлык, кимлекләргә буйсынган.

Беткән инде ата-баба каны,
Җир убардай гайрәт басканда.
Намус кая хәзер бу җаннарда?! —
Дип янамсың күңлең ташканда?

Әйт син аларга, әйт күргәнеңне,
Өр сурыңны — алар уянсын!..
Уянсын да, торып, хәйран булып,
Иске зурлыкларын уйласын!

### Ирек җыры

Алга, туган, алга! Җиңгәнгәчә,
Ил юлында тиңсез тартышка!
Бергә, туган, бергә! Үлгәнгәчә,
Ирек өчен изге тартышка.

Ирек сөйгән батыр бабайларның
Сөякләре әле чермәгән,
Күңелләрне яккан ирек уты
Йөрәкләрдә әле сүнмәгән!..

Ил юлында канлы тартыш өчен

Алган кылыч тагын ташланмас.
Иркен алган изге туган илнең
Коллык көне тагын башланмас!..

Алга, туган, алга! Җиңгәнгәчә,
Ил юлында тиңсез тартышка!..
Бергә, туган, бергә! Үлгәнгәчә,
Ирек өчен изге тартышка!..

**Илем****

Юк, кичә алмам мин синнән, син — минемсең мәңгегә,
Хәсрәтеңнән эчтә каннар кап-кара таш булдылар.
Бак, матурлык юк хәлеңдә: яп-ялангач, тап-такыр,
Килмешәкләр таптый-таптый бар матурлык сулдылар.
Бакчаларда юк ачылган алсу гөлләр шатланып,
Иңле-иңле (? — *Х. М.*), моңлы-моңлы гончә гөлләр шиңделәр.
Шарлап аккан чишмәләрең бирмиләр өн, кайда алар?!
Бак: алар да юк булып, туфрак шикелле кордылар.
Нинди җанбарлар беләмсең, ни тозаклар кордылар,
Безне аерып бер-береннән нинди көннәр ордылар.
Бик озак тордык җылап, сыктап, канаттан каерылып,
Син минем өчен, мин синең өчен зар булып йөз күрмәгә.
Инде кулны киң ачып, тылсым богауларын атып,
Эч үзәктән кычкырамын: кил миңа, үз бәгъреңә!
Син минемсең, тик минемсең, та-әзәлдән (яратылмыштан бирле.— *Х. М.*) син минем;
Ташларың, туфракларың, ул күп балыклы су минем.
Ул Җаек та, ул Урал да, ул Идел дә бит минем,
Ул Казан, Болгар, Кырымлар, ул матур таулар минем.
Ул Себердә тайгалар, ул киң болынлар, сахралар,
Ул нәфис җилләр белән тетрәгән таллар минем.
Ник бирим мин читкә, бирмим, бу матур җирләр минем!
Бу — бабамларның мирасы, бу — минем бит үз илем!

**Ил дәрте**

Нәрсәдер учлап кыса күкрәкне, соң мин ни телим?!
Ник күңелсез Җир йөзе, ник кайгылы мин, ник җылыйм?!
Ни җитешми, ник болай кыр-бакчалар ямьсез тора?!
Чәчәкләр, гөлләр сөйкемсез, бирми бер сөенеч миңа.
Кайда бассам читенсенәм, җан эчкә сыймый тарсына,

Кайда баксам буш, тонык, ул нәрсә-нидер юксына.
Дүрт ягым бөркү, караңгы, дөнья тик бер сер миңа,
Нишләсәм дә ач, туялмый, җан өлешсез талпына.
Ни телим, белмим-беләлмим, ни теләсәм ул — шуның,
Бар теләкне көл итеп күңлемдә  ил дәрте яна.

**Төрк егетенә**

Асау (?) каннарыңның теләкләре,
Киң Төркестан чиген ташканда,
Такырлардан сулар эчә-эчә,
Сахра кичеп таулар ашканда,
Кавышу өчен кайсы изге көнне
Билгеләдең? Ни дип ат куйдың?
Ярсу тавышың белән тау тетрәтеп,
Бүз кырларга ни дип ант бирдең?!

Актык кәрван үткән озын юлны
Сахра төнбоеклары каплады,
Ул заманнан бирле Төркестанга
Сөенеч таңы — ак таң атмады.
Ул заманнан бирле җылый, җырлый
Кәрваннарны көтеп саргайды.
Ул заманнан бирле ком чүлләре
Эзләреңне үбеп саклады.
Ул заманнан бирле сине көтә,
Хәсрәт тулы күзен ачмады.
Төркестан ул синең, синнән башка
Беркемне дә күңле үз итмәс.
Аяклаunion, тетрәр бар кисәге,
Күңле үтәр аңа, көч үтмәс.
Аның бикле күңлен синнән башка
Берәү килеп көчләп ачалмас.
Беркем рәхәтләнеп синнән башка
Адымнарын җәеп атламас.
Тау-ташлары синең исмең белән
Чокылганнар, исем алганнар,
Көчле, батыр, нәүмәш (?имин.— *Х. М.*),
тын күренешне
Синнән үтеп, синнән алганнар.
Туфраклары — чыдам маңлаеңның
Тирләреңә эчеп куырылган.
Һавасында сулышың, ташларыңда
Талмас беләгеңнән эз калган.
Чулак даласында — синең чалмың;
Синең төсең сеңгән, үз иткән.
Синнән аккан канлар агачларын,
Яшел үләннәрен өлгерткән…

Актык кәрван үткән озын юлны
Сахра төнбоеклары каплады,
Ул заманнан бирле Төркестанга
Сөенеч таңы — ак таң атмады.
Ул заманнан бирле кая калдык,
Ятлар көтә үксез йортыңны.
Чирчирегән (йончыган.— *Х. М.*) атың хәл алдисә,
Тотыр, егет, биргән антыңны.

## Ис

*(Мелодрама)**

Бер җил исте, кинәт
Бик тәмле ис
Кагылды да китте борныма.
Чү, нинди ис бу?—
Җофарлы ис.
Исертте дә үтте җилегемә…
Һем-м-м, ә-ә-ә… Һем-м-м… беләм,
Таныйм, бу ис
Эч төшемне — мине каклаган;
Каннарымны җуып,
Җанны сөеп,
Хисләремне буйлап каплаган.
Һем-м-м, ә-ә-ә… Һем-м-м ә-ә-ә… беләм,
Таныйм, бу ис —
Илкәемнең тәмле, хуш исе.

Урал тауларыннан
Кубып килгән
Туган илнең үзлек төп-төсе.
Бу истә бар тойгым,
Бөтен үзем
Туган чактук (чакта ук.— *Х. М.*) мине төсләгән!
Бу искә мин тоткын,
Аны эзлим,
Аны чакырам, аны иснәнәм…
Бу ис белән яндым,
Бу ис миңа
Юл күрсәтер кайда булсам да.
Бу ис, бер көн татсам,
Җан очыртыр,
Хәсрәтеннән көйсәм, үлсәм дә…

**Актык теләк***

Үтте гомрем бер генә көн,
Бер теләгем тулмыйча,
Сыкранып, күзне тегеп,
Ак көнгә күңлем туймыйча.

Яшь йөрәгем тетрәсә,
Сызланса да мәхрүм көйгә,
Баш бөгеп тордым чыдап,
Зарланмадым Тәңрем сиңа.

Үрсәләндем яшьнәгәндә
Күзләремдә чаткылар,
Яшьләремне төйнәдем гел
Эшләмим дип бер гөнаһ…

Уйнаган, көлгән чагында
Эч-үзәктән башкалар,
Мин дә җылмайдым йотып кан,
Димәдем уфтанып аһ…

Төрле төстә чын бәхет
Бирдең бу чаклы бәндәгә.
Барсының ялган ягын,
Тик шәүләсен бирдең миңа.

Инде актык бер теләгем
Бар, Ходаем, бирсәнә,
Инде бу янган йөрәккә
Бер кара, бер күрсәнә!

Ил йөзеннән ал караңгы
Пәрдәсен, золымын күтәр;
Изге көн бир: шат, бәхетле
Көн тудыр, күңлен күтәр.

Йорт-йиремне үзирекле
Булганын күрсәт, күрим.
Кайгысыз, моңсыз килеш
Күкрәкне киереп бер йөрим.

Мин дә тордым дөньяда ак,
Якты көн күрдем димим.
Киң колачлы рәхмәтеңнән

Бер өлеш алдым димим.

**Теләгәндә**

Нинди рәхәт миңа, иркем көчле:
Теләгәндә сөям, сүзлим мин;
Теләгәндә көләм, күңлем тыныч,
Йөрәгемдә авыру сизмим мин.

Теләгәндә табам чиксез бәхет,
Ким көчләрне кимерәм, кимсетәм.
Теләгәндә дөньям «дузәх» (тәмуг.— *Х. М.*) була,
Кара уйлар уйлыйм, гамь йотам.

Ирек-иңлекләрне яннан куам,
Бармак селкеп яныйм-куркытам.
Теләгәндә — әби, теләгәндә
Сабый булам: сикереп йөримен.

Теләгәндә үткен дошманымның
Күзен уям, бәхетен буйыймын.
Теләгәндә ташам, күккә басам,
Бер сихерле йомгак буе мин.
Теләгәндә йомшак «саба» (таң җиле.— *Х. М.*) төсле,
Теләгәндә «мәйдан ире» мин…

**Ахирәт дустыма**

Син бүген күңлемдә тудың,
Йөргәнеңне сагындым.
Тәмле сүзләр әйтеп сыйлап,
Сөйгәнеңне сагындым.

Ак өстендә ал бөрчекле
Күлмәгеңне сагындым.
Битләреңне чокырайтып
Көлгәнеңне сагындым.

Маңлаеңның сул ягында
Миңнәреңне сагындым.
Сандугачым, кил тагын да
Дигәнеңне сагындым.

Синлегеңнән бар эшеңне,
Бар төсеңне сагындым.
Һәммәсеннән бигрәк артык
Чынлыгыңны сагындым.

**Яз айлары**

Яз айлары керде,
Өстән карыйм
Кара кышның салкын җиленә.
Бирелмимен инде,
Аяк терим,
Катланмыймын аның иркенә...

Күбәләкләр оча,
Гөлләр коча,
Җирнең өстен «сөю», «ямь» коча.

Бөтен нәрсә җырлый,
Уйный, көлә,
Кояш кайный: терелек, тәм чәчә.

Нинди матур яшел
Язны сөям,
Бәхет туа яздан күңлемә.
Үз-үземне сөям.
Җирне сөям,—
Матур күренә барсы күземә.

### Яшьләргә

Кайсы көннәр тормышымның утлары өртә мине,
Бизгәге үтми дә бетми, тетрәтә-селкә мине.

Инде «көлмим» дим, «үләм» дим, нәрсә бар соң ис
китим (искитмәле.— *Х. М.*),
Нәрсә бар соң талпынырлык, нәрсәдән бер ямь көтим?

Шундый көннәр очрасам бер күкрәгән ир-җегетенә,
Я яшен төсле атылган ил кызыннан берсенә.

Көч керә аннан теләккә җаннан аккан сүз белән.
Җилпенә күңлем күренмәс бер илаһи кул белән.

Кан тамырлардан эри дә күпреп аккандай була,
Уй җылы, йомшак, мамык ястыкка яткандай була.

Җанланам, тереләм, үсәм, баштан яшим, илһам алам.
Шаңгырап, шаулап торамын, өр-яңа булган булам.

Тагыламын алдагы көчнең алга куйган агышына,
Җем-җем иткән аллы-гөлле алгы көннең сагышына.

Ух, кызык артык миңа дөнья! Йөзәм, күңлем ачык,
Уңга-сулга селти-селти очканымны ут чәчеп.

Әй, яшә яшьләр! димен, ил сезгә күңлен беркетә!
Нәкъ минемдәй авыру күңле сездән им, бәйрәм көтә.

### Кара көчкә

*(Гаяз әфәндегә багышлыйм)*

Атлама, тукта, базынма, кит кире, чик аркага,
Артта калды «шомлы көннәр», «канлы Колчак» аркада.

Сытма, кит ил күкрәгәндә, чыкма, шиң, күрсәтмә баш.
Көтмә корбан, тетрәмәс беркем бөгеп алдыңда баш.

Нинди тәнгә батмады ач, вәхши үткен тырнагың,
Нинди ак көннәргә балта, киртә салып тормадың.

Нинди җаннар тар, караңгы зинданыңда чермәде.
Нинди җаннар кан эчендә чирпелеп җан бирмәде.

Сөргенеңдә нинди җаннар саргаеп көн күрмәде,
Дар агачыңда, күрәкдә (?) күпме җан сыкранмады.

Камчы, зынҗыр, кайгы, күз яше ордың илем өстенә,

Көчле ил сыртын китәрдең, корбан иттең иркеңә.

Инде юк сыенырга почмак, төште маскаң, шымчы җау,
Аулана алмассың төреклек дөньясында бетте ау.

«Ак» күрәлмисең «кара»сын, яктылык, нур дошманы,
Үрләтмәкче булдың, ахры, «күпсенеп» бер чаткыны.

Чаткы санма яңлышырсың асты лаулы (лавиналы.—*Х. М.*) вулкан ул,
Пыскып астан тын гына «ут пошкыра торган тау» ул.

Көн килер, дәверләр, атар ул, бөркәр эчтән утларын,
Юк итәр, үтәр золым, кан, вәхши көч кайнакларын.

**20 ел элек ил**

Иске ирке, үзлеге үз куенына кайткач кире,
Йөрде «кан» тамры буенча, телгә килде ил йөзе;

Җан катылды, кузгатылды бар үлеб ятканлары,
Гөрләде, шау килде, акды боз корыб катканлары.

Җем-җем итде, нур чәчелде изге, мәгъсум йөзенә,
Әй бизәнде, аллы-гөлле төскә керде гөл генә.

Әй канатланды, сөенде, чик-чама юк иркенә,
Әнкәсен күргән баладай ач теләкләр җилкенә.

Ялтырады, яп-яңа булды тутыккан күкрәге,
Яшь арыслан төсле һәйбәт берлә җәелеб күкрәде.

Күз камашды, тел адашты ил йөзенең бәхтенә,
Иске шанлы көн урынлашды шәрәфле тәхтенә.

Яңгырады күк йөзенә җырлары, тәкбирләре,
Үз иркенең, чын бәхетнең үлчәү алмас өнләре.

**Углымның җыры**

Мин Атилланың улы,
Күкрәгем ялкын тулы,
Дөньяда исеме олы,
Үткәнем зурлык тулы.

«Идел-Урал» — үзәгем,
«Төркия» — күз бәбәгем,
«Төркестан» — киң күкрәгем,
«Бушка» сүнмәс теләгем.

«Кырым» — минем кан тамрым,
«Азәрбайҗан» — кулларым,
«Казакъ-Кыргыз» — уң ягым,
«Башкортстан» — үз ягым.
Тагын бар күп ыруым,
Тоткан илем — туфрагым,
Алар белән мин «бөтен»,
Аералмас безне беркем…

Кол булырга тумадым,

Үз илемдә туйладым,
Идел-Урал буйларын
Җырлый-җырлый буйладым.

Йортым өчен торырмын,
Иркәм өчен үләрмен,
Белегемне, уйларымны
Ил-көн өчен бирермен.

Йодрыкларым һавада,
Каннарымда «үч» ага,
Юк, берәүгә баш имәм,
Кол булалмам башкага…

Мин Атилланың улы,
Күкрәгем ялкын тулы,
Читкә бирмәм йортымны,
Тетрәтермен дөньяны...

## Драма әсәрләреннән

### Тормыш көзгесе

*(4 пәрдәдә)*

Халкының йитешсезлек эчендә күзләрендә җыйган теләкләре читлектәге кош тарлыгы белән җылынып торучы, утлы-үзәкле «Финляндия Туран Берлеге» яшьләрен вә аларны элгүче эшлекле башканнары Ибраһим Гариф бәкне самим йөзеннән бу әсәремне аларга багышлыйм.

*С. Гыйффәт,*
*3.01.1937,*
*Финляндия — Хельсинки*

#### Бастыручыдан

«Финляндия төркләре (бу очракта: татарлары.— *Х. М.*) Берлеге»нең элек теләге Финляндиядә яшәмәктә булган төркләрнең милли тойгыларын уяндырмак вә куәтләндермәк һәм дә милли культурны (культураны.— *Х. М.*) сакламак, җәймәк, аны яшьләребезгә һәм читләргә танытмактыр. Бу максат өчен Берлегебез төрле юлларда көче йиткән кадәр эш күрмәктәдер. Үткән ел эчендә эшләребездә азмы-күпме муаффәкъ булдык исә (уңышларыбыз булса.— *Х. М.*), боның (моның.— *Х. М.*) өчен сайгылы (хөрмәтле.— *Х. М.*) Сания Гыйффәт ханым илә Закир әл-Кадыйри бәккә бурычлыбыз. Без бу йирдә эшләребезнең күплеген вә мәсьүлиятле (җаваплылык.— *Х. М.*) булуын ачык сөйләп, бөтен милләттәшләребезнең мәгънәви вә матди ярдәмнәренә мохтаҗ икәнлегебезне дә әйтеп үтәбез.

Сәүгеле Сания Гыйффәт ханымның Берлегебезгә багышланган ошбу әсәре яшь көчләребез тарафыннан Хельсинкида 1937 елның 31 нче гыйнварында ясалган милли кичәдә сәхнәгә куелып, шул ук кичәдә бастырылырга карар кылынды вә хазыйр булынган (катнашкан.— *Х. М.*) берничә илдәшебезнең җумардлыкларын сузуы белән бу карар эшкә ашырылды. Әдәби кыймммәте вә халкыбыз өчен файдасы һич шөбһәсез булган бу әсәрне бастырып чыгарганда, Сания Гыйффәт ханымга вә ярдәмдә булынган илдәшләребезгә йөрәктән чыккан сайгы вә тәшәккерләребезне (рәхмәтләребезне.— *Х. М.*) сонамыз.

Әсәрнең имласында, төзү вә төзелешендәге техник кимчелекләр матбаганың кечкенәлегеннән килеп, бу хосуста укучыларның кичерүләрен үтенәбез.

*Хельсинки, Финляндия, 15 нче февраль, 1937 ел*
*Финляндия төркләре Берлеге*

УЙНАУЧЫЛАР:

Гали — бер зур бай, үзе хаҗи, 55 яшендә.
Миңлегөл — аның хатыны, 50 яшьләрдә.
Нәфисә — аларның кызы, 20 яшендә.
Хәлим — консерваториядә укучы, Галинең контор эшләрен караучы, 25 яшендә.
Хәдичә — укыган бер кыз.
Гайшә — Нәфисәнең иптәшләре.
Хәлимә —
Сәлим —

Әнвәр —
Госман — яшьләр.
Җәмил —
Гайнеддин — бер авыл карты (Хәлимнең якыннарыннан), 65 яшьләрендә.
Гайниҗәмал — асрау кыз, 20 яшьләрдә.
Иржан — Хәлим белән Нәфисәнең балалары, 3 нче пәр-
Айсылу — дәдә 6, 7 яшьләрендә; 4 нче пәрдәдә 16, 17 ләрдә.
Вәли — йорт караучы, 25 яшендә.
Гөлбану — бер хатын, 37 яшьләрендә.

Болардан башка 3 гаскәр(и), полис (полицейский.— *Х. М.*), халыктан берничә кеше.

Вакыйганың элек өч пәрдәсе Русия шәһәрләренең берендә, 4 нче пәрдәсе Русиядән тыш чиктәш бер мәмләкәт шәһәрендә үтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ярлы гына җыештырылган бүлмәнең эче күренә. Уртада бер чәй өстәле корылган. Хәлим өстәл янында әйләнгәләп, өстәл өстенә
куйган нәрсәләрне төзәткәләп йөри. Ишек шакыганы ишетелә.

Беренче күренеш: Хәлим, Гайнеддин.

Хәлим. Кер, кер. *(Ишектә авылча киенгән Гайнеддин күренә. Сәлам бирә. Хәлим, көтелмәгән бер хәл алдында калган бер кыяфәт белән килеп, Гайнеддиннең ике кулын бердән тота, аркасыннан шап-шоп сөя-сөя сөйләнеп, бүлмә уртасына китерә, сәлам биреп.)* О, Гайнеддин агай, күктән төштекме, җирдән чыктыкмы, ничек болай, ничек болай?!

Гайнеддин *(көлемсерәп)*. Кала дигән йирдә кеше табу бик кыен икән, сине эзли-эзли көчкә таптым. Уф... *(Яулыгын алып битен сөртә.)*

Хәлим *(тагын аны тотып диванга китерә)*. Кил менә шунда утыр да хәл җый. *(Гайнеддин утыра. Тирә-ягына карана.)* Иншалла, яхшы хәбәрләр белән килгәнсездер. *(Гайнеддин эндәшми тора.)* Йә, Гайнеддин агай, сөйлә, ниләр бар, сине күргәч, бөтен авыл күз алдымда җанланды. Бар нәрсәсе «мине сора, сора!» дигән төсле торалар. Кайдан башлап сорашырга белмим: урманнары, сулары, кырлары, тегермәннәре, күршеләр, туганнар, картлар, яшьләр, ирләр, хатыннар — барысы бергә күз алдымда кайнашалар. Арадан берсен генә тартып алып сорарлык түгел. *(Көлә.)* Мин авылымны, авылымның бөтен иң кечкенә нәрсәләренә барганчы ул хәтле сөям, ул хәтле сагынганмын икән, моның шулай булганлыгын әле сине күргәч кенә аңладым. Йә инде, үзең сөйлә. Әтием бик матур карт булдымы? Күрмәгәнемә өч ел булды бит. Байтак үзгәргәндер. Сеңлем Хәлимәне кияүгә китте дип язганнар иде. Ничек, уңышлы чыкдымы? *(Үзе дә Гайнеддиннең янына утыра.)*

Гайнеддин *(уйчан вә күңелсез генә)*. Уңышлы, уңышлы булды. Ире күрше авылның Озын Миңлекәйнең углы Хәйрүк бит, белә торгансыңдыр.

Хәлим. Әйе, әйе, беләм. Ник белмәскә. Әтием тереләдеме, аны авырып тора дип язганнар иде.

Гайнеддин. Әтиең инде бик картайды. Өч айдан бирле түшәккә төште шул. Хәле яхшыдан түгел инде. Әле мин дә шуның өченрәк килдем, Хәлим. Син кайтсаң, бер догасын алып калсаң, яхшы булыр иде. Инде көннәре санаулыга охшый. Сине бик чакыра. Кайтмаса, бәхиллек бирмәм, ди. Аны күрмичә үлсәм, күзем аркамда калыр, ди. Кайтсын, мине күрсен, сөягемне тотышсын, ди.

Хәлим *(кайгырып)*. Шулаймыни, Гайнеддин агай, шулай укмыни? Авыруы азып (төп нөсхәдә «озаб» дип язылган. «Озак» дип тә алырга мөмкин.— *Х. М.*) киттемени?

Гайнеддин. Шулай шул, Хәлим. Алла кушса, иртәгә өйләдән соң минем белән бергә китәрсең инде. Җиңгәң Галимә дә бер айга якын булып килә, үлде.

Хәлим *(бик әсәрләнеп)*. Җиңгиме диден?!

Гайнеддин. Җиңгәң Галимә инде.

Хәлим *(дога кыла)*. Ничек алай булды: бик таза хатын иде бит ул. *(Уйланып, аптырап.)* Әй Алла, дөрес әйтәсеңме, Гайнеддин агай, бу хәбәргә бер дә ышанасым килми.

Гайнеддин. Алланың хөкеменә чара юк, Хәлим. Үлем тазамы, авырумы дип карап тормый. Сәгате җитсә, ала да китә.

Хәлим *(әрнеп)*. Ай, мескен, ай, мескен. *(Торып, кулын маңгаена куеп, уйланып, әрле-бирле китеп килә дә тагын Гайнеддиннең янына утыра.)* Маһруй, Фәрихә, Исмәгыйль ятим калдылар диген ә, нинди авыр хәл! *(Бераз торып.)* Ничек үлде соң?

Гайнеддин. Кинәт кенә авырып, тиз генә үлеп китте. Ни булганын белеп булмады. Башым гына авырта дип ятты.

Хәлим *(тересәген ботларына терәп, ике яңагын куллары арасына алып, бераз уйга кала. Соңра башын күтәреп, тураеп)*. Алла рәхмәт итсен, әйе, болай булгач, китми булмый инде, Гайнеддин агай... Мин синнән сөенечле хәбәрләр көткәндә, син бик ямьсез хәбәрләр белән килгәнсең икән, Гайнеддин

агай. Алла хәерле итсен! Аның теләгенә каршы килеп булмый. Мин, алайса, иртәгә иртә белән байга барып, хисапларымны бетерермен дә, кичкә табан китәрбез. Бүген булмый инде. Бүген мөселман кибетләре ябык, бәйрәм итәбез. Милли бәйрәм. Бүген өйләгә хәтле бер җыелышыбыз булган иде. Сәгать 3 тә миңа иптәшләр килергә булды. Милли бәйрәмне котлашабыз. (*Сәгатен карап.*) Инде килә дә башларлар.

Гайнеддин. Ярый, ярый, бик яхшы, бик яхшы соң. Син үзең нишләп (ни эшләп.— *Х. М.*) көн итәсең? Атаң укый дип сөйләгән иде. Башка эшең дә бармы?

Хәлим. Минме, Гайнеддин агай, мин, бер яктан, эшлим, бер яктан, укыйм. Укуымны алып барыр өчен эшләргә туры килә. Гали байның контор эшләрен карыйм. Консерваториядә укыйм.

Гайнеддин *(ишетми вә аңламыйчарак)*. Капсаң каба тор дидеңме? Нәрсә ул, нинди нәрсә?

Хәлим *(көлемсерәп)*. Юк. Капсаң каба тор түгел. Консерватория дидем. Музыка мәктәбе ул.

Гайнеддин. Нәрсә укыталар анда?

Хәлим. Музыка гыйлеме, музыка.

Гайнеддин. Ә, аңладым. Барабан кагарга, быргы кычкыртырга өйрәтәләр дип өзеп, аңлатып әйтсәнә. Алай һәвәслек булгач, син аны үзебезнең авылның көтүче Нуридан гына өйрәнү кирәк иде. Яшьлекнең җүләрлек булуы шундый эшләрдә күренә инде.

Хәлим *(көлеп)*. Юк… Ул син аңлаганча түгел, Гайнеддин агай. [*Торып пиано* (пианино.— *Х. М.*) *янына барып*.] Менә моны бер иптәш биреп торды. *(Пианоны ача.)* Моңар пианин диләр.

Гайнеддин. Ә, пияный урысча исерек дигән сүз түгелме соң?

Хәлим *(шаркылдап көлеп)*. Юк, Гайнеддин агай, алай түгел. Пияный түгел. Пианин. Бу исерек түгел, исертүче. Моны тыңлаучыларның, аңлаучыларның җаннары исерә. Аңладыңмы инде? [*Көлә. Тушларга* (клавишларына, телләренә.— *Х. М.*) *баскалый*.] Менә ишетәсеңме, шулай төрле тавышлар чыгара ул. *(Ноталарны алып күрсәтеп.)* Менә болары минем сабакларым. *(Арадан берничәсен алып күрсәтә.)* Болары минем үземнең язганнарым. Менә сиңа уйнап күрсәтим. Бу үзем язган «Сөйлә миңа, әнкәем!» дигән романс.

Гайнеддин. Әнкәеңне онытмыйсың икән әле. Бик яхшы хатын иде мәрхүмә. Вәсилә җиңгине авылда да бер дә онытмыйлар. Һәй, дөнья, һәй!.. *(Хәлим пианога утырып, уйныйм дигәндә генә, ишек кагыла.)*

Хәлим *(торып)*. Рәхим итегез! *(дип кычкырып, ишеккә таба бара. Ул арада ишектән Нәфисә керә.)*

Икенче күренеш: Хәлим, Гайнеддин, Нәфисә.

Нәфисә *(каранып вә Хәлим белән күрешеп)*. О, миннән башка килүче юк, ахрысы.

Хәлим *(җылмаеп)*. Бар. Рәхим ит! Менә безнең Гайнеддин агай килде. Танышыгыз. *(Гайнеддингә карап.)* Менә бу — Нәфисә туташ — минем байның кызы була. *(Нәфисәгә карап.)* Гайнеддин агай безнең авылның картларыннан. Миңа якынлыгы да бар.

Нәфисә *(килеп күрешеп)*. Бик яхшы.

Хәлим *(күңелсезләнеп Нәфисәгә)*. Ләкин Гайнеддин агай күңелле хәбәр белән килмәгән. Иртәгә мине алып китәргә дип килгән... *(Нәфисәнең чырае үзгәрә.)* Әтием үлем түшәгендә икән, мине чакырткан.

Нәфисә *(кайгырып)*. Ник алай әйтәсең, Хәлим? Алла кушса терелер. Авырган бер кеше үлеп бетми бит!

Хәлим *(сузып)*. Анысы шулай. Ләкин әтием бик карт инде. 86 яшендә. Өмид бик аз шул!

Гайнеддин *(урыныннан торып)*. Кая, Хәлим, сез мәҗлесегезне уздыра торыгыз. Соңыннан сөйләшербез. Мин бер әйләнеп киләм әле. Без Сеннойдагы дворга («Печән базарындагы торакка» мәгънәсендә.— *Х. М.*) төштек. Гыйльман да килде. Бергә килербез.

Хәлим. Шулаймы, ярый, алайса, Гайнеддин агай, көтәрмен. *(Аның артыннан барып озата.)*

Өченче күренеш: Хәлим, Нәфисә.

Нәфисә *(Хәлимгә таба барып, моңланып)*. Хәлим, чынлап та китәргә уйладыңмы?

Хәлим *(кайгылы)*. Әйе, Нәфисә, әти бәхиллек бирмәмен дигән. Китми булмый инде. Догасын алырга кирәк.

Нәфисә. Мине ялгыз калдырыпмы, мине кызганмыйсыңмы?

Хәлим *(аптырап)*. Нәфисә, кеше икегә ярыла белсә иде, ни бәхет булыр иде. Минем дә яртым синең янында калыр иде. Мин, син әйтмәсәң дә, ул хәбәрне ишеткәннән бирле, ут белән су арасында калдым.

Нәфисә *(тагын моңланып)*. Озак торырсыңмы соң?

Хәлим. Әйтеп булмый, Нәфисә. Җиңги дә үлгән. Аның үлем хәбәре мине бигрәк тә борчыды. Әтигә бер хәл булса да, булмаса да, инде аларны карарга бер кеше кирәккә охшый. Җиңги булса, бүтән зуррак туганнарым булса иде. Алар да юк. Бигрәк тә хәзер, өч бала да калды. Авылда эш вакыты бетеп килә,

аларга ярдәм итәргә, эшләрен рәткә салырга кирәк. Мондагы эшемне дә ташлап китәргә туры килә. Әтиең дә минем урынымны саклап, миңа акча биреп тормас; кешесез дә тора алмас, Нәфисә.

Нәфисә *(пошынып)*. Хәлим, мин синнән башка бер көн тора алырмын дип уйлый алмыйм. Синсез көннәрем караңгы калачак. Мин нәрсә белән җуанырмын, кемгә сөеп карармын, кемгә эндәшермен? *(Җылый.)*

Хәлим *(җуатып)*. Нәфисә, җылама. Мине дә җылатырсың. Синең гыйшкың белән исереп, елларның, айларның, көннәрнең, сәгатьләрнең ничек үтүен тоймый да идем. Күзләреңнең яктысы рухымны яктыртты, яшәр өчен яңа көч бирде, мине бәхетле итте. Синнән башка үтәчәк көннәрем минем өчен дә бик авыр, бик ачы булачак... *(Башын чайкый.)* Ләкин... Ләкин нихәл итик. Дөнья кешеләр белән шулай уйный, аларның җәннәтен шулай җәһәннәмгә әйләндерә.

Шулай итеп, шатлыгын тартып ала, шуның өчен үтерә. Уф... *(Йөренгәли.)*

Нәфисә. Хәлим, Хәлим, мине дә үзең белән алып кит, мине дә үзеңә иптәш ит!

Хәлим *(аңар таба килеп, кулын җилкәсенә куеп)*. Нәфисә, әгәр моны эшләү сөйләү хәтле җиңел булса иде, «әйе» дияр идем. Бу турыда мине уйламый дип беләсеңме?! Мәктәпне дә бетерә алмадым, аның да бер елы бар әле. Бу хәлемдә әтиеңнең сине миңа бирәчәге акылыма да кереп чыкмый... Өмид тә итмим. Башкача ничек, Нәфисә?! *(Ике кулын тотып уйга кала.)*

Нәфисә. Син мине әтидән сорап кара. Бәлки, биреп тә куяр. Синең үзеңне дә, эшеңне дә сөя төсле. Бирми торган булса, мине качырырсың. Миңа синнән башка барыбер тормыш юк. Әтием башымны киссә дә, мин синнән башкага барачак түгелмен. *(Җылый.)*

Хәлим *(аптырап, аның җилкәсенә кулын куя, башыннан сыйпап, җуатып)*. Нәфисәм, син әле яшьсең. Дөньяны аңлап бетерә алмыйсың. Тукта, җылама, түземле бул; миңа калса, сине бу көн, бу минутта үземнеке итәр идем. Ләкин, бердән, ата-анадан узып эш итү күңелсез эш булачак. Икенчедән, минем киләчәк өчен юлым алынмаган, мәктәбемне бетереп, эш-көч иясе булмаган. Бүген сине бәхетле итәчәк хәлдә түгелмен. Син байлык эчендә дөньяның ачысын татыганың юк. Фәкыйрьлекнең җәһәннәмнән авыр, каһәрле көннәрен синең, бәлки, төшеңдә дә сизгәнең юктыр. Хәзерлексез берләшсәк, бер көн килер, бәлки, бу акылсыз эшебез өчен җылый-җылый үкенербез, ләкин эш эштән үткән булыр.

Нәфисә *(күзләрен сөртеп)*. Юк, Хәлим, юк, синең гыйшкың булганда, миңа дөньяның башка ягы тубыктан калыр...

Хәлим. Яңлыш уйлыйсың, Нәфисәм, дөнья гыйшыктан гына тормый. Мине тыңла! Дөньяда гыйшыктан да зур көч булмауга мин ышанган кеше булсам да, аның тәмле зәһәрләрен (агуларын.— *Х. М.*) эчә-эчә яшәүнең татына җитә торган бер татның булмавына да ышанганмын. Безне табигатьнең безгә биргән каршылыклы тарткычы үзенең көчле хөкеме астына алган икән, без аңар исереп тормышыбызны агу итәчәк, бу матур гыйшыкыбызны корытачак юлны тотарга ярамый. Бераз көтик: әтиең бирә торган булса да, барыбер иртәгә туй ясап бирә алмас бит. Шулай түгелме, Нәфисәм? *(Аңар иелеп карый, аның иелгән башын югары күтәрә.)*

Нәфисә. Шулаен шулай, Хәлим, ләкин минем тойгыларым акылдан көчлерәк. Ничә айлар, бәлки, бер ел, бәлки дә, артыкка сине күрүдән мәхрүм булу минем өчен бик авыр булачак. Син шулай да киткәнче әтиемнең уен бел, өйләнүебезгә каршы килмәячәген аңла. Минем дә җаным тынычланыр. Мине сиңа бирергә разый булып сүз бирсә, миңа, өмидләнеп, сине көтәргә җиңелрәк булыр иде. Бирми торган булса, тагын да бер чарасын эзләр идек.

Хәлим *(бераз уйланып)*. Ярый, Нәфисәм, алайса, син дигәнчә булсын. Иртәгә иртә белән конторга баргач, әтиең белән бу турыда сөйләшермен вә кирәк булса арадагы мөнәсәбәтебезне дә туп-туры сөйләрмен. Ярыймы? *(Кулларын тотып, аңар карый.)*

Нәфисә *(шатланып)*. Ярый, Хәлим, ярый, рәхмәт!

Хәлим. Үзеңә рәхмәт, Нәфисә. *(Нәфисә утыра. Хәлим йиргә бер тезе белән тезләнеп, аның кулын алып үбә вә тезенә башын куя. Нәфисә аның чәчен сыйпый. Хәлим башын күтәреп, Нәфисәгә карап.)* Мин синең гыйшкың белән ул хәтле бәхетлемен ки, җир-күкләргә хуҗалык бирсәләр, мин аннан аерылуны кабул итмәс идем. Минем куркуым тик тормышның авырлыклары эчендә бәхетсез булачагыңны уйлап кына, Нәфисәм. *(Торып Нәфисәнең янына утыра.)*

Нәфисә. Иртәгә мине күрмичә китмә. Әтиемнең нәрсә әйткәнен миңа әйтерсең, Хәлим.

Хәлим. Билгеле. Иртәгә киткәнче мин сезгә күрешергә килермен. Шунда... *(Ишек кагыла. Хәлим торып ишеккә бара. Ишектә Хәдичә, Сәлим, Госман күренәләр. Шаулашып керәләр.)*

Дүртенче күренеш: Нәфисә, Хәлим, Хәдичә, Сәлим, Госман.

Хәдичә. О, без соңга калганбыз. *(Нәфисәгә таба бара. Күрешәләр.)* Нәфисә килгән дә инде.

Хәлим. Әйдәгез, утырышыгыз. (*Өстәлне күрсәтеп.*) Бәйрәм өстәле әзер.

Сәлим. Кая? *(Өстәл янына барып, җылмаеп.)* Алла, безне чикләвек белән генә сыйларга уйлаганга охшыйсың. Өстәлеңдә чикләвектән башка бернәрсә дә күренми. *(Берничә чикләвек алып, ватып ашарга*

*тотына. Кабыгын утырган Госманга төбәп ата. Үзе көлә. Хәлим җылмаеп бер ишектән эчкә кереп китә.)*

Госман *(атылган кабыкны алып, карап көлеп)*. Акыллы икәнсең. Эчен үзе ашап, тышын безгә бирә.

Сәлим *(көлеп)*. Мә, тот, алайса. (*Бер чикләвек бирә.*)

Госман *(торып)*. Юк, кирәкми, аякларым исән булсын. *(Өстәл янына килеп, чикләвек алып ашый башлый. Башкалар аңа карыйлар. Кызларга.)* Кызыгасызмы? Мәгез сезгә дә. *[Икесенә дә чикләвекләр бирә* (ата.— *Х. М.*). *Кайсын тоталар, кайсын төшерәләр. Ишек шакылдый вә Гайшә белән Хәлимә, Әнвәр, Җәмил керәләр.]*

Бишенче күренеш: әүвәлгеләр, Әнвәр, Җәмил, Гайшә, Хәлимә.

Әнвәр *(карангалап)*. О, болар чәйләгәннәр инде. Авызлары да чәпчелди башлаган. *(Көлешә вә күрешәләр.)*

Сәлим. Шулай шул. Хәлимнең өстәлдәге чикләвегенең төбенә төшеп киләбез инде. *(Әүвәлгеләр тагын көлешәләр.)*

Әнвәр. Бу турылык түгел-л-л-л... *(Тиз-тиз өстәлгә барып карангалый да бер чуклы кәгазьле конфет алып, селкеп күрсәтә.)* Менә мин нәрсә таптым. Тагын да тәмлесе. *(Чатыр-чотыр сүтә башлый.)*

Хәлим *(көлеп)*. Әйдәгез, утырыгыз инде алай булгач. Аяк өсте ашап, өстәлнең ямен бетермәгез. Хәзер чәй дә китерәм. *(Тагын ишектән кереп китә. Бүлмәдәгеләр, уйнап-көлеп, өстәлгә урнашалар. Хәлим чәй тотып күренә.)*

Берничәсе. О, чәй килде, чәй. *(Хәлим өләшә, башкалар да булышалар. Чәй өләшенеп беткәч, Хәлим тагын эчкә кереп бер тәлинкә белән сохари алып чыга.)*

Хәлим. Менә сезгә катырмач.

Берничәсе. Катырмачмы? *(Көлешәләр.)*

Хәлимә. Нәрсә ул катырмач, ни дигән сүз ул?

Хәлим. Улмы? Сохари дигән сүз. Мондый милли бәйрәм котланган көндә чит телдә сөйләргә-катыштырырга ярамый.

Хәдичә. Урысның үзе дә, сүзе дә ул хәтле җанга үткән инде. Мәгънәсез булса да, күңел үз нәрсәнең булуын тели.

Берничәсе. Шулай, шулай.

Хәлим *(утырып)*. Ягез инде, ашагыз, эчегез. Бар яктан да сөйләшегез, котлашыгыз.

Госман. Элек сүз синеке. Син — өй иясе. Син сүз ач.

Хәлим. Шулаймы. (*Төзәтенгәләп.*) Ярый, алайса. *(Тамагын кыра, тора. Бераз уйлап.)* Бәйрәм ни өчен кирәк? Без монда ни өчен җыелдык?! Моны барыгыз да бик яхшы беләсез. Бәйрәм — эчтәге шатлыкны тышка чыгару, бер йорт халкының бергә, барысына да уртак булган, бер хәл өчен бертөсле тойгыларын бергә уртаклашулары. Безнең бүгенге бәйрәмебез бүгенгә чаклы булган бәйрәмнәрнең берсенә дә охшамый. Бу барысыннан да зур, барысыннан да котлырак. Моны милләт йөзе 365 елдан соң (ягъни 1917 елда.— *Х. М.*) элек мәртәбә күрә. Бүген, беләсез, урыс боендырыгының (төрек сүзе: Изүенең; игосының.— *Х. М.*) каһәрле кулыннан котылып, рәхәт тын алырга башлаган көннәрендә үзебезнең киләчәгебезне вә үзебезне идарә итү өчен, Милләт Мәҗлесебез[1] алынган көн. Менә монда без шуның бәйрәмен итәр өчен җыелдык, туганнар. Бу көнебезнең шул берничә сәгатен бергәләп, тойгыларыбызны уртаклашып үткәрик. Яшәсен халкыбыз, яшәсен иркебез!! *(Хәлим утыра.)*

Бар да. Яшәсен! *(Кул чабалар.)*

Җәмил *(барысы да тынгач, берүзе кычкыра)*. Син дә яшә, Хәлим! *(Берүзе кул чаба. Көлешәләр.)*

Әнвәр *(торып)*. Әйдәгез, җегетләр, шашыгыз, сөенечегезнең күплегеннән шашыгыз, сикерегез, биегез, кечкенә бала шатлыгы белән шатланыгыз! Моңар хәтле төшләрегездә дә күрергә теләмәгән көннәребезнең башлангычы алдында без. Яшәсен изгелек, яшәсен керсез көннәр!!

Бар да. Яшә! *(Кул чабалар. Әнвәр утыра.)*

Сәлим *(торып)*. Сөембикә, Сөембикә, күр! Яткан йиреңдән башыңны күтәр дә кара: синең елап аерылган Казаның бүген бәйрәм көннәре ясый («яши» дип басылган.— *Х. М.*). Вакыты белән өстендә кан елгалары аккан Казаныңның бүген туфракларын синең каныңнан булган балаларың күкрәкләрен киереп таптыйлар. Аны моннан соң үз гаскәрең саклар. Синең манараңда синең байрагың җилбердәр. Казанның иң урта йирендә синең бер һәйкәлең күз камаштыручы һәйбәтлек белән корылыр. Аның янында хатиблар (ораторлар.— *Х. М.*) синең авызыңнан ялкынлы-ялкынлы сүзләр сөйләрләр. Яшә Казан, яшә халкым, яшә ил, яшә ирек!!

Бар да. Яшә, яшик-к!.. *(Кул чабалар. Җылмаялар.)*

Хәдичә *(торып)*. Ирек сөенече дөньяның иң исертүче сөенече булганын бүген аңладым. Чын адәм төсенә кереп, йир өстенә басып йөрергә хаклы булуымны бүген аңладым. Көннәрем әйтерсең ялтыравык белән ямьнән тугылган (тукылган.— *Х. М.*). Илнең йөзе, моңарчы бер дә авырлык үткәр-

мәгәндәй булып, башка төс алган. Күз алдымда өмид белән матурлыкны кочаклашкан күрәм. Яшәсен ирек! *(Утыра.)*

Бар да. Яшәсен! *(Кул чабалар.)*

Гайшә *(торып)*. Бу сөенечле көнгә бер-ике генә сүз белән булса да, мин дә катнашасым килә, дустлар. Әнә кичә генә ил өстен — безне каракошның шомлы канаты өртә («каплый».— *Х. М.*) иде. Теләк бәйле, адымнарың хисаплы, көнең ямьсез, күңелең өмидсез, кайгылы иде. Кара урысның кара колы идек. Менә бүген, бүген, уф-ф... *(Бераз торып.)* Сөйли алмыйм, бугазыма сөенеч төелә. Сүздән артык тойгым эшли. Бу сөенечнең зурлыгын аңлатырга телем йитми. Бүгеннең шатлыгы шундый зур, туганнар. Мине кичерегез! *(Утыра. Кул чабалар.)*

Госман *(торып)*. Минлегебез үтерелде. Әйтеп бетергесез түбәнлекләр, бөлгенлекләр эчендә башыбыз әйләнеп, кулыбыз бәйләнгән иде. Көчләп чукындырылганбыз, русларга, рус байларына кол ителеп өләшелгән без идек. Хәлбуки вакытында боларга хөкем иткән — без; дөньяны тетрәткән, йөрәкләргә курку салган без идек. Безнең турыда сүз ачылганда, бөтен дөнья усак яфрагы төсле тер-тер тетри башлый иде. Шундый зурлыктан коллыкка төшүебезгә дә үзебез сәбәпче булган идек. Аны таркаулыгыбыз, бер-беребезне күрә алмыйча, руска сатылганлыгыбыз өчен башыбызга китергән идек. Инде бу көн тагын шул данлыклы, зур көннәребезнең эзе өстендә без. Бу көннең кадерен белик, уйлап эш күрик. Бу көнне яшәтергә, үтермәскә тырышыйк, туганнар.

Бар да. Сүз, сүз (ант.— *Х. М.*). *(Кайберсе.)* Үлгәнче. *(Кайберсе.)* Бер тамчы каныбыз калганчы *(дип кычкыралар)*. Яшә! *(Кул чабалар.)*

Сәлим *(торып)*. Сүз йитәр инде. Әйдә, Хәлим, син бераз сыздырт, яңа көйләрең булса әйттер. Җырлыйк.

Хәлим *(торып, пианога таба сөйләнә-сөйләнә бара)*. Ярый. Сезгә үземнең яңа гына язган бер ерымны (җырымны.— *Х. М.*) уйнап күрсәтим. *(Килеп утыра да, уйный вә җырлый.)*

Башкалар да *(кузгалышып, төрлесе-төрле хәлдә тыңлап торалар. Бетергәч, кул чабалар)*.

Бәйрәм сиңа бүген менә,
Ямьле көнең инде килә.
Җир-күк тула сөенеч белә,
Инде җырын яңгырат, сөйлә...

Тойсын аны күп ел элек
Шәһид булып үлгән егет;
Рухы белән күктән торып,
Катнашсын ул, бәйрәм итеп.

Җәмил. Яшә, Хәлим. *(Урыныннан торып, Хәлимнең аркасына кулы белән шап итеп бәрә дә кулын кыса. Башкалар да акрын-акрын берәм-берәм Хәлим вә пиано янына җыелалар.)*

Хәлим *(башкаларга карап)*. Инде «Әйдәгез»не уйныйм. Аны инде барыгыз да беләсез. Бергә җырлыйбыз.

Берничәсе. Ярый. Башла. *(Хәлим уйный башлый. Бергә «Әйдәгез»не җырлыйлар. Җырлап бетергәндә, пәрдә төшә.)*

ӘЙДӘГЕЗ

Әйдәгез — һәр эшнең
Башлангыч бер көче;
Хәл җыйгач, тын алгач,
Эшкә башлау сүзе.

Әйдәгез, йокладык,
Хәл җыйдык, туктадык.
Яңа бер көч белән
Дәртләнеп юл алыйк.

Әйдәгез, кузгалыйк,
Тууыбызны кулга алыйк.
Шау килеп, гөрләшеп,
Ил төзик, туй ясыйк.
Ничә йөз ел буе,
Каны көйгән көе,
Ил йөзе, карт-яше
Көтә үз иркене.

Тилмереп, әлсерәп
Тора ил кайгысы.

Ямьле күзләр белән
Күтә бар нәрсәсе.

Әйдәгез, берләшеп
Күткән илгә таба,
Иске зур барлыктан
Тоткан илгә таба.

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бик яхшы җыештырылган Гали байның кунак бүлмәсе күренә. Пәрдә ачылганда, асрау кыз бүлмәнең тузаннарын алып йөри.

Беренче күренеш: Гайниҗамал.

Гайниҗамал *(үз-үзенә сөйләнә)*. Бу байларның хәлен бер дә аңлап бетәр хәл юк. Гел юк-бар белән көннәрен үткәрәләр. Ашыйлар, эчәләр, киенәләр. *(Бераз сөйләми торгач.)* Абыстай, аягым-билем сызлый дип, көн буе караватында ята. Менә минем кебек дыңгыл-дыңгыл бертуктамый эш эшләсә иде, сызлаулары күккә очар иде, кызының да нишләп йөргәнен күрер иде. Кызының кайгысы — Хәлим. Хәлимне сөя. Хәлимне икедә бер сылтау табып югары чыга. Үзләренчә беркем дә аңламый дип беләләр инде. *(Мыскыллап.)* Сезгәме соң мин булганда сер яшерергә. Мин менә алга карыйм *(күрсәтә)*, артымдагын күрәм. *(Мактанып күкрәген кага.)* Мин шундый кеше, мин шундый үткен, мин шундый булдыклы. Мин падишаһ булса идем, дөньяны бармак очында гына уйнатыр идем. *(Бармагы белән әйләндереп күрсәтә. Күзге алдына тузан алырга килә. Анда торган йөзеккә күзе төшеп, тиз генә кулына алып бер югары, бер түбән китереп, кашын уйната. Үзе аңар сокланып-сокланып, җылмаеп карый.)* Ничек ялтырый! Абыстай йөзеген монда салып калдырган икән. Бу йөзекне аның бармагында күргән саен соклана идем. Ярлылар байларның нәрсәсен бүлешергә кирәк диләр бит инде. Берсе бай булып, икенчесе киемсез, ач булырга ярамый, диләр. Абыстайның бармаклары йөзек белән тулган. *(Бармакларын күрсәтеп.)* Ә минем бармагымда бер йөзек тә юк. *(Йөзекне бармагына киеп, кулын әйләндереп карый.)* Менә нинди килешә. Абыстайга алай килешми. *(Тагын карап.)* Минем бармакларым нинди матур. Аның бу хәтле күп йөзеге бар. Миңа бер йөзек күп булмас әле. Моны мин үземә алыйм да куйыйм. Абыстай сораса, күрмәдем диярмен. *(Йөзекнең кашын эчкә таба әйләндереп, кулын төшереп.)* Абыстай янында шулай гына торырмын. *(Ишектән тамагын кыра-кыра Гали хаҗи керә.)*

Икенче күренеш: Гали, асрау (Гайниҗамал).

*(Гайниҗамал, Галинең тавышын ишеткәч, тиз генә эш эшләгән булып йөри башлый.)*

Гали *(Гайниҗамалга)*. Бар, тизрәк абыстаңны чакыр.

Гайниҗамал. Ярый, абзый, хәзер. *(Чыга.)*

Гали *(үз-үзенә)*. Синең кебек салам сыйраклар, кыска койрыклар, кубыз уйнап кул чабып йөрүчеләрнең *(чатын-потын басып, Миңлегөл ишектән керә)* исәбе-хисабы юк. Авызларыннан ана сөтләре кипмәгән, торырга куышлары, ятарга урыннары юк. Аларга кыз бир, имеш.

Өченче күренеш: Гали, Миңлегөл.

Миңлегөл. Ни булды, кемгә ачуланасың болай?

Гали *(аны күреп)*. Кемгә булсын, безнең конторщикка —Хәлимгә. Оятсызның исемен дә телгә аласым килми. Ничә елдан бирле икмәгемне ашаганын онытткан. Килмешәк, хәерче. Инде, оялмыйча, чабатасы белән башыма менеп утырырга тели.

Миңлегөл *(ачулы тавыш белән)*. Әллә безнең Нәфисәне сорыймы? *(Утыра.)*

Гали *(ачулы-ачулы йөренгәли)*. Синең дә миең череп беткән. Баядан бирле шуны сөйлим бит. Иртә белән конторда миннән Нәфисәне сорый. Гашыйк булган, имеш, кызым белән сөешәләр, имеш. Әле ул оятсызын — Нәфисәсен дә чакырып бик нык сабак бирергә кирәк. Оялмыйча, йөз кызартып, бу яшьтән егет сөеп йөргәне өчен күрсәтермен мин аңа күрмәгәнен.

Миңлегөл. Менә килмешәк. Шул башы белән, оялмыйча, безнең бердәнбер күз карабызга үрләшә диген. Кара син аны, җир бит. Ничек итеп, күзгә карап, мин синең кызыңны сорарга килдем, диярге кирәк. *(Исе китеп башын селки.)*

Гали. Юк, күзен дә йоммый. Сөешәбез, ди, арабызда сүз бар, ди.

Миңлегөл. Акчасы булгач, кем сөймәс. Минем кызымны кем сөймәс. Сөя, имеш. Белгән кемне сөяргә. Керче Галимәнең кызын ник сөйми? Турысын әйткәндә, керче кызлары да андый дуадак казларга кызганыч.

Гали. Әйттем инде үзенә дә. Син, энекәш, дидем, үз тиңеңә күз салсаң яхшырак булыр, дидем. Минем сиңа бирә торган этем әле балаламаган, дидем. Юлыңны кара, икенче кат сине күзем күрмәсен, дидем.

Миңлегөл *(сузып)*. Би-и-к яхшы әйткәнсең, би-и-к яхшы әйткәнсең, авызыңа бал да май. Яшь кызларның иркенә йибәрсәң, аларның акылы юк. Кайда матур, анда күзләре китә. Алар дөньядан нәрсә аңлый? Каршысында мыегын борып, эскрипкәсен сызып торгач; гомер шулай гына үтә дип белә. Бу турыда Нәфисәне гаепләр хәл юк. Ата-ана кулында, дәүләт эчендә ул; ни күргән дә ни белгән.

Гали *(утырып)*. Син авызыңны ачып торасың. Кызыңны күзәтә белмисең. Күрәсеңме: ул ниләр эшләп йөри икән? Кая бара, кем белән күрешә, иптәшләре кем?! Ана булгач, барысын да белеп торырга кирәк.

Миңлегөл. Ул бит инде яшь бала түгел. Куенда-култыкта гына асрап булмый. Замана балалары хәйләсен дә төзи белә, эшен дә йөртә белә. Әнә шул Хәдичәдән шикләнәм. Ала да китә, ала да китә. Әле туган көн ясый, имеш, әле иптәшләр киче була, имеш. Шундый мәҗлесләрдә башын-күзен әйләндереп бетергәннәр инде. Зурая башлагач та, мин сиңа әйтә килдем: мәктәбеннән алыйк, дидем; әллә кая азып-тузып китәр кыз бала, дидем. Ул чакта син каршы килдең. Инде миңа бәйләнәсең, сакламадың, дисең. Менә укытып ни чыкты, бар да үзеңнән.

Гали. Син дә әллә ниләр сөйләп эчемне поштырасың. Әнә Хәлил байның да кызы укыды да, мондый нәрсә булдымы?! Уку бозмый кешене, иптәш боза; кар башына кар җитә, кыз башына кыз җитә дип, борынгылар белмичә әйтмәгәннәр аны. Менә моннан соң әйт: беркая да чыкмасын да, йөрмәсен дә. Атаң кушмый, диген. *(Утыра.)*

Миңлегөл. Аты-чабы чыкканчы, башлы-күзле иткәнебез яхшы булыр иде. Вакыты да йиткән инде. Шул Галим байны хатын аерган дип кире какты. Безнең шәригатьтә, хатынны аермаса да, дүртенчегә хәтле алырга ярый. Әле бу аерган, эчә дә, имеш, дидек. Эчсә бит, синең акчаң белән эчми, үзе таба, үзе эчә.

Гали. Узган эшкә салават инде, карчык, син алдагын кара. Салих байның малаен качырмыйк, өйләнергә тели, кыз күзли, имеш, дип ишеттем. Монда аңар тиң булырлык бездән бай кеше юк, булганнарның да Нәфисәгә җитәрлек кызлары юк. Безгә килми, кемгә барсын.

Миңлегөл. Шулай, шулай. Моны Маһруй җиңгәйнең дә колагына төшереп куярга кирәк.

Гали *(урыныннан торып)*. Ярый әле, мин чыгыйм. Бу көннәрдә тирә-яктан бик күңелсез хәбәрләр ишетелеп тора. Әллә кая бармаслар баруын да. Шулай да кулдагын култыккарак җыеп торырга кирәк. Әле бүген дә берсе сөйләде: Бөредә өч кибетне, бер йортны большевиклар кереп талаганнар, ди. Әле тәртип утырып җитмәгән чак, куркынычрак чак. Һәр көн әле кибет, әле өй басылуын сөйлиләр.

Миңлегөл *(курку белән)*. Илаһым, үзең сакла. Галимә абыстайга укырга бирергә кирәк, Аллага сыгынып торырга кирәк. Безнең халыктан да иярүчеләр бар микән әллә?

Гали. Бар икән, ди шул. Бар икән, ди. *(Ишектән Гайниҗамал керә. Галигә карап.)*

Дүртенче күренеш:Миңлегөл, Гали, Гайниҗамал.

Гайниҗамал *(кулындагы төргәкне сузып)*. Абзый, моны сары мыеклы, озын буйлы бер кеше калдырып китте.

Гали *(аңар әйләнеп)*. Китер. *(Ул арада дөбердәгән тавышлар ишетелә. Эчтәгеләр бер-берсенә карашып, эндәшмичә тыңлыйлар.)* Сөбханалла, сөбхан... бу ни хәл? *(Ишектән туп кеби атылып Вәли керә, күзләре акайган, тыны беткән, йөткерә, тавышы калтырый, сүзен әйтә алмый. Бер йирдә дә тора алмый. Качарга юл эзләргә әзләнгән кеше төсле карангалый.)*

Бишенче күренеш:әүвәлгеләр, Вәли.

Вәли. Киләләр, киләләр. *(Барысы да аптырашалар.)*

Гали. Кемнәр килә?

Вәли *(аның саен куркынып)*. Киләләр, дим, бит инде. Тегеләр килә.

Гали *(сабырсызланып, ачу белән барып, Вәлине ике җилкәсеннән тотып селкетә)*. Әйт, кемнәр килә, җүләрләндеңме? Ни бар?

Вәли *(кычкыра)*. Большевиклар килә, большевиклар.

Гали *(каушап)*. Ә, ә. Большевиклармы, дидең? Солдатлармы? Кая килә, кая?! Ә, ә. *(Әйләнгәли.)*

Вәли. Безгә, безгә. Безне таларга. [*Ул арада сүгенеп, кычкырынып, дөбердәп килгән аяк тавышлары ишетелә. Кайсы йөткерә, бүлмәдәгеләр бер минутка боз күк* (кебек.— *Х. М.*) *катып калалар. Ишектән өч гаскәр* (гаскәри.— *Х. М.*) *күренә. Ярты исерек, күзләре тонган.*]

Алтынчы күренеш:әүвәлгеләр вә өч гаскәри.

*(Вәли, гаскәриләрне күрүгә куркып, икенче ишектән качарга тели. Гаскәринең берсе аны күреп кала.)*

Икенче гаскәри *(Вәлигә карап кычкыра)*. Тор, кая качасың? Моннан кош та очалмас. *(Барып Вәлинең беләгеннән тота вә әйләндереп идән уртасына ата. Вәли шап итеп барып төшә. Аннан шуып килеп, диван янына барып чүмәли* (чүгәли.— *Х. М.*)*, тетри* (калтырый.— *Х. М.*). *Гайниҗамал да куркудан агарып, арка-арка барып стенага сыена. Миңлегөл аягүрә баскан көйгә кулларын яңагына куеп, куркынып, аптырап тора.)*

Беренче гаскәри *(Миңлегөл белән Галигә карап)*. Ә, үзләре дә монда. *(Иптәшләренә.)* Әйдә, башлагыз, ни карап торасыз? *(Икенче гаскәригә.)* Син берсен дә бүлмәдән чыгарма. *(Икенче гаскәри ишеккә тегелә. Өченче гаскәри бүлмәдә эзләнә. Үзе Галигә таба барып.)* Чыгар акчаңны. *(Гали каушап, тиз-тиз генә портмонетын чыгарып бирә. Гаскәри тартып ала да ачып карый.)* Бу үзеңә булсын. *(Күтәреп бәрә.)* Кая, чыгар тизрәк. *(Галинең киемнәрен тарткалап, кесәләрен актарырга тотына. Бер төргәк чыгарып.)* Кара син аны, карт хәйләкәр, безне син кем дип беләсең? *(Акча төргәге белән бер яңагына йибәрә.)* Мә, менә бел кем булганны. *(Тагын икенче яңагына йибәрә. Гали артка чигенә. Гаскәри тагын өстенә барып.)* Кайда бар тагын акчаң, бир, чыгар! *(Гали эндәшми.)* Ни карап торасың? Тиз бул! *(Гаскәринең берсе якынрак килеп.)* Бирмәсә, йотдыр пилюлне!

Беренче гаскәри *(гайрәтләнеп)*. Бирәсеңме, юкмы? Югыйсә (*мылтыгын төзәп*) йотдырам пилюлне үзеңә.

Гали *(тетри башлап)*. Юк, дим, башка акчам. Янымда юк. Барысы банкада.

Беренче гаскәри *(ачуланып)*. Банкадамы, ә, банкадамы? Бала алдатам дип уйлыйсыңмы? Күрсәтерем мин сиңа кем икәнемне. Чыгарасыңмы яшергән акчаңны, юкмы? *(Мылтыгын төзи. Өченче гаскәри икенче бүлмәгә чыгып китә.)*

Гали *(җылаган төсле)*. Юк, валлаһи, юк.

Беренче гаскәри. Син валлаһи белән муллаңны ышандыр. Алайса, ал, сиңа! *(Ата.)*

Гали. Алла, Алла. *(Арка-арка барып, диванга бәрелә дә егылып китә. Мылтык атылганда, Вәли диванның читенә битен ябыштырып сеңә.)*

Миңлегөл *(Галигә аткач, ачы аваз белән кычкырып йибәрә)*. Һәй, Аллакаем, безне коткар. *(Тиле кеше күк йөгергәли башлый.)* Үтерделәр, үтерделәр. *(Гали янына килеп.)* Нихәл итим-м-м... Гали, Гали-и. *(Җылый.)* Динсезләр, имансызлар. Тик торганда ник кеше үтерәсез? *(Җылый.)*

Икенче гаскәри *(аңар килеп, төртеп йибәрә)*. Акча бирсәң үлмәссең. Әйдә, китер акчаңны.

Миңлегөл *(җылап, куркып)*. Миндә акча юк.

Беренче гаскәри. Акча кайда?

Миңлегөл. Акча кибеттә, кассада.

Беренче гаскәри. Китер касса ачкычын, тиз бул. Булмаса, күрәсеңме? *(Мылтыгын күрсәтә.)* Син дә берне йотарсың. *(Миңлегөл ачкычны биргәндә, кулындагы йөзекләрне, беләзекләрне күрәләр.)* Чыгар кулыңдагы алтын-көмешләрне дә. *(Миңлегөл тиз-тиз беләзекләрен чыгарып гаскәринең сузган учына сала. Ул арада Вәли култык янындагы йирдән торып каршыдагы балконга ачылган тәрәзәдән атлап качмакчы булып бара.)*

Икенче гаскәри *(аны күреп)*. Тагын качарга телисеңме? *(Вәлигә таба бара.)* Качырырмын мин сине, буржуй ялчысы. *(Аркасыннан килеп, киеменнән өстерәп төшерә дә бер яңагына салып йибәрә.)*

Вәли. Ай, ай. *(Кычкырырга курка. Яңагын тотып, бөгелгәләп, күзен акайтып әйләнгәли.)*

Икенче гаскәри. Йитмәдеме? Мә тагын. *(Мылтык түтәсе белән ике-өч рәт бирә. Вәли лап итеп идәнгә егыла.)*

Вәли. Ай, ай. *(Яткан йиреннән бер кулын сузып.)* Абзыкаем бул. Йитәр. Тимә миңа.

Икенче гаскәри *(Вәлинең сәгать чылбырына күзе төшеп, иелеп, чылбырыннан тартып сәгатен чыгара да, тартып алып, кесәсенә сала. Соңра идәндә сызланып яткан Вәлигә бик ямьсез итеп карап)*. Әйдә, кач! Ник торасың *(дип китә. Ул яныннан китүгә, Вәли диван астына кереп ята. Ул арада икенче гаскәри, бүлмәдә йөренгәләп, тартмаларны актарып, өстәл өсләреннән рәтлерәк нәрсәләрне кесәләренә салгалый. Ярамаганнарын тотып карый да идәнгә атып бәрә. Кайсы ватыла, кайсы тәгәрәп китә. Бүлмә эчен астын-өскә китерәләр)*.

Беренче гаскәри *(Миңлегөлнең йөзекләрен алуда дәвам итеп)*. Я, тиз бул, бу йөзегеңне дә чыгар.

Миңлегөл *(чыгарырга азапланып)*. Бусы чыкмый, тыгыз.

Беренче гаскәри *(аяк тибеп кычкыра)*. Чыгар тиз генә, көтәр вакыт юк.

Миңлегөл *(тагын чыгарырга азаплана)*. Чыкмый. Бармагым бүрткән.

Беренче гаскәри. Бармагың бүрткән, ә. Бүртсә, аның да име бар. *(Биленә таккан каеш кыны эченнән бер хәнҗәр чыгарып.)* Китер ул бармакны. *(Кулын, тартып китереп, өстәл почмагына куя.)*

Миңнегөл. Ай, бармагымны нишләтәсең? *(Ул кычкырынган арада гаскәри хәнҗәр белән шап итеп өстәл почмагына куйган бармакка чаба. Йөзеген ала. Киселгән бармакны Миңлегөлгә атып.)*

Гаскәри. Ал бармагыңны, үзеңә булсын.

Миңлегөл. Ай, бармагым, ай, кулым. *(Ачы тавыш белән каннар аккан кулын тотып җыларга тотына.)*

Беренче гаскәри *(яныннан китәм дигәндә, тагын әйләнеп)*. Әле алкаларың да чыкмый торгандыр, колагың да бүрткәндер. *(Якынлашып, Миңлегөлнең колагындагы тамчылы алкаларын шарт-шорт итеп тартып ала.)*

Миңлегөл. Уф, колагым, уф-ф. *(Җылый-җылый янындагы култыкка төшә. Башын артка ташлап яртылай иссез булып кала.)*

*(Ул арада шапкасы кулында, өстендә җәйге кием, урам кыяфәте белән Нәфисә килеп керә дә аптырап карангалый вә анасына күзе төшә.)*

Җиденче күренеш: бүлмәдәгеләр, Нәфисә вә өч гаскәри.

Нәфисә. Әни җаным, әнкәем җаным, нишләттеләр сине?! *(Туп-туры анасына барып кочаклый, өзелеп җылый башлый. Өченче гаскәри кулында бер кочак нәрсә белән икенче бүлмә ишегеннән килеп керә.)*

Икенче гаскәри *(стена буенда җансыз күк торган Гайнижәмалны күреп)*. Кулыңны ник яшереп тотасың, кая, синең дә йөзегең бармы? *(Гайнижәмал дәшми.)* Күрсәт, дим, кулыңны. *(Гайнижәмалның аркасына куйган кулын алып карый.)* Ә, менә кайда хәзинә. *(Йөзекне алып, әйләндереп карый.)* Моның ише аз булыр. *(Кесәсенә сала да, башкаларга карап.)* Әйдәгез, кибеткә, кассага.

Нәфисә *(башын күтәреп анасына карап)*. Әнкәем җаным, ник дәшмисең? *(Төрткәли, җылый. Ике гаскәри алданрак чыга. Беренче гаскәри ишек төбендә Нәфисәнең тавышын ишетеп.)*

Беренче гаскәри. Җаны-әнкәсе икән буржуйканың. *(Көлә. Кире әйләнеп Нәфисәгә.)* Кил әле, матур кыз. Синең белән бераз сөйләшик. *(Бу арада Гайнижәмал тиз генә тәрәзәдәге калын пәрдәнең арасына кача. Нәфисә эндәшми. Гаскәри анасының өстеннән аны тартып ала.)* Ә, кил, әнкәеңне соңыннан карарсың.

Нәфисә *(куркып)*. Кит, хайван, нишләмәкче буласың? *(Төртә.)*

Беренче гаскәри. Я, назланма. *(Тарткалый.)*

Нәфисә. Кит, дим, хәерсез. *(Тырнарга, яңакларга тотына.)*

Гаскәри *(ачуланып, мылтыгын күрсәтеп)*. Булмаса, күрәсеңме шуны?

Нәфисә *(батырланып)*. Мин синең мылтыгыңнан куркам дип беләсеңме? *(Каршысына торып, изүен тотып.)* Әйдә, үтер. Үтер. Гыйфрит, төфү, төфү. *(Төкерә.)*

Беренче гаскәри *(кинәт Нәфисәнең ике беләгеннән тотып өстерәргә башлый)*. Син миннән котылмассың, кызый. *(Тартышалар.)*

Нәфисә. Кит, кит. *(Кулларын ычкындырырга әйтеп кычкыра.)* Килегез, кем бар, килегез... *(Гаскәри аны яндагы бүлмәгә алып кереп китә. Ул арада икенче ян ишектән Хәлим күренә. Хәлим як-ягына каранып, аптырап торганда, яндагы бүлмәдән дөбердәгән вә «килегез», «коткарыгыз» дип кычкырган тавышлар ишетелә.)*

Сигезенче күренеш: әүвәлгеләр, Хәлим.

Хәлим. Нәфисә *(дип кычкырып, аткан ук шикелле, тавыш килгән бүлмәгә кереп китә. Кисек-кисек тавышлар, дөмбердәшүләр тоела)*.

Вәли *(бүлмә эче тынга калгач, диван астыннан курка-курка гына башын чыгарып карый. Аннан соң акрын-акрын ярты гәүдәсен чыгара. Теге бүлмәдәге дөмбердәгән тавышларны ишетеп*). Безнең Нәфисә туташны талыйлар! *(Аның пышылдаганын Гайнижәмал ишетә дә пәрдә читеннән башын озатып* (сузып.— *Х. М.*) *карангалый.)*

Гайнижәмал *(Вәлигә)*. Әйдә, тиз генә качып чыгыйк. *(Каранып.)* Бүлмәдә абыстай белән абзыйдан башка кеше калмаган. *(Икесе дә акрын гына курка-курка урыннарыннан чыгалар.)*

Гайнижәмал *(колагындагы алкаларны тотып)*. Монда кереп качмаган булсам, алкаларымны да алырлар иде әле. *(Соңра кулына моңланып карый.)* Нинди килешә иде ул йөзек миңа. Мин байныкын алган идем. Алар ярлыдан тартып алдылар.

Вәли. Алар байны, ярлыны тикшерми, кемдә ни күрсә, шуны ала. Большевик диләр аларга. *(Калтырана.)* Большевик. Аларның телләре генә сөйли. Минем дә сәгатем китте. *(Сәгать урынын тота.)* Акчамны гына алмасалар ярар иде дип котым очып ятты. *(Кесәсеннән портмонетын чыгарып акчасын карый.)* Кичә байдан айлык алган идем. *(Урынына куя. Теге яктан дөп итеп бернәрсә ауганы ишетелә. Икесе дә, чәчрәп китеп, иске урыннарына качалар. Бераздан Вәли тагын диван астыннан башын чыгарып карый. Гайнижәмал да шулай ук.)*

Вәли *(яткан җиреннән Гайнижәмалга карап, йодрыгын йомарлап кизәнә)*. Большевиклар бер кулыма эләксен генә, бирермен мин аларның кирәген. Син әле мине бер куян йөрәк дип белә торгансыңдыр. *(Тагын урыннарыннан чыгалар.)*

Гайнижәмал. Әйдә, тизрәк качыйк. *(Аяк очлары белән тиз-тиз атлап барып, ишектән чыгып китәләр. Бераздан бүлмә ишегеннән, бер-берсенең җилкәсеннән тоткан көйгә, Хәлим белән Нәфисә*

*күренәләр. Икесенең дә чәчләре тузган, изүләре чишек, төсләре киткән. Аякларының хәле беткән: бер-берсенә чолгана. Туры баса алмыйлар, авып-түнеп йөриләр. Хәлим көчкә сулыш ала. Куллары-битләре канаган, сызыклар бар.)*

Тугызынчы күренеш: бүлмәдәгеләр, Хәлим, Нәфисә.

Нәфисә *(лап итеп урындыкка утырып, башын тотып)*. Уф, Хәлим. Килеп йитешмәгән булса идең, тартышырлык көчем калмаган иде. Ничек килә белдең?

Хәлим. Алла туры китерде, Нәфисә. Авылга китеп барганда, сине күреп китәр өчен дип килгән идем. Капка төбенә йиткәндә, ике солдат чыгып баралар иде. Шундук талаганнарын аңладым. Йөгерә-йөгерә кердем. Аннан соң бүлмәдән синең тавышыңны ишеттем. *(Бераз торып, Нәфисәнең башын сыйпап.)* Курыкма инде, Нәфисә, тынычлан. Үзенең дә жаны җәһәннәмгә киткәндер. Өченче каттан таш өстенә төшү бик шәп түгел. Исерек булмаса, көч тә йитәрлек түгел үзенә, аюдай таза. Алла ярдәм итте, вакытында булды. *(Ул арада Миңлегөл ыңгырашып күзен ача.)*

Миңлегөл. Аһ, уф. Мин кайда, мин нишләдем?

Нәфисә *(урыныннан торып, анасы янына бара)*. Әнкәем жаным, кичер мине. Үз кайгым белән сезне беразга онытырга туры килде. *(Кинәт атасына күзе төшә. Атасына таба барып.)* Әти, әти. *(Бераз кулы белән селкетә.)* Әткәем бәгърем, ник дәшмисең, сине нишләттеләр? *(Кулына күзе төшеп.)* Алла, Алла. Хәлим, Хәлим. Әтиемне атканнар. Аһ, бәгърем. *(Өзелеп җылый башлый.)* Нишлик, нишләтик?!

Хәлим *(якынлашып, читкә атылган кулын алып төзәтеп куя)*. Абзый, абзый. *(Нәфисәгә карап.)* Кан бик күп акканга охшый. *(Иелеп йөрәген тыңлый.)* Йөрәк эшли. Өмид бар. Мин тиз генә китеп доктор китерим. *(Китә башлый.)*

Нәфисә *(күзләрен сөртеп, Хәлимгә артыннан кычкыра)*. Хәлим, Хәлим. Кил әле. Әтием нидер әйтә.

Хәлим *(кире кайта. Галигә колагын биреп)*. Абзый, ни дисең? Ә, ә. Ярый, ярый. *(Нәфисәгә.)* Утыртырга куша. *(Икесе ике яктан ябышып рәтләп утырталар.)*

Гали *(күзен бераз ачып аларга карый, бер-ике ыңгырашканнан соң, Хәлимгә карап)*. Ишеттем, Хәлим, барын да тойдым. *(Бераз тора.)* Нәфисәмне — кызымны син коткардың. Нәфисә... сиңа... хәләл булсын! Бәхетле... булыгыз. Миңа инде доктор урынына... бер мулла китер. Мин... мин инде ү...үләм. Бә... бәхил... бу... *(Егылып китә, Нәфисә җылый башлый.)*

Нәфисә *(кочаклап кычкырып)*. Әти жаным, әткәем бәгърем, үлмә, үлмә...

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бик фәкыйрь, пычрак бер бүлмә. Җимерек бер-ике утыргыч. Иске бер өстәл. Ике йирдә караватка охшатып ясалган, иске нәрсәләр түшәлгән урын. Чиләк, чүлмәк кук вак-төяк нәрсәләр. Арттагы урында башын бәйләгән бер хатын ята. Сирәк-сирәк ыңгырашканнан авырганлыгы билгеле. Бүлмәдә ике бала күренә. Кыз бала анасының баш очындагы кечкенә урындыкка утырып, анасына башын терәгән.

Беренче күренеш: бүлмәдәгеләр, Хәлим.

Пәрдә ачылуга, ишектән Хәлим керә. Ул керүгә бер яткан хатынга, бер балаларга карый.

Балалар *(Хәлимне күреп)*. Әти, әти, кайттыңмы? (*Каршы барып кочаклыйлар. Хәлим аларның башларыннан сыйпый. Аркаларыннан сөя вә үбә.)*

Хәлим. Нишләдегез? *(Малайга карап.)* Иржан углым, син әниеңне борчымадыңмы, сүзен тыңладыңмы? *(Хатынга таба барып.)* Әниләре, син ни хәлдә соң? Бераз уңайланмадыңмы?

Нәфисә *(акрын тавыш белән)*. Юк шул, Хәлим. Никтер бер дә савыгып китә алмыйм.

Хәлим *(авыр сулый. Янында тетрәп торган Иржанга күзе төшеп)*. Нигә тетрисең, углым, өшисеңме? *(Айсылу тагын анасының урынына башын терәп тора.)*

Иржан. Әти, суык. *(Хәлимгә сырыша.)*

Хәлим *(тирә-якка карана да, бернәрсә күрмәгәч, өстендәге иске киемен, салып, Иржанга кидерә)*. Ки, углым, шуны. *(Бармагы белән утыргычны күрсәтеп.)* Әнә анда барып утыр. Бераз җылынырсың.

Иржан *(утырырга дип барганда, кире әйләнеп Хәлимгә)*. Әти, әти. Мин бернәрсә китердем.

Хәлим *(борылып)*. Нәрсә китердең, Иржан?

Иржан *(бик зур эш эшләгән кешеләрнең сөенече белән йөгереп барып, бер почмактан ике кечкенә генә утын күтәреп килеп, атасына суза да)*. Менә, әти, кара, нәрсә китердем мин. *(Хәлимгә карап җылмая.)*

Хәлим *(уйга калып)*. Боларны каян алдың, углым?

Иржан. Тыштан алдым. Безнең яндагы Иваннан алдым. Ул утын яра иде.

Хәлим. Бу утыннарны Иван бирдеме, углым, сиңа?

Ирҗан. Ул бирмәде. Мин үзем генә алдым.

Хәлим. Ник сорамадың?

Ирҗан. Сораган идем дә, бирмәде.

Хәлим. Нәрсә диде?

Ирҗан. Сезгә этиең китерсен диде. Мин этиемнең акчасы юк дидем.

Хәлим. Ул нәрсә диде?

Ирҗан. Аңарга мин гаепле түгел диде.

Хәлим. Бирмәгәч, син ничек алдың?

Ирҗан. Минме? *(Утыннардан ераграк китеп, читтән аяк очы белән акрын гына килеп күрсәтә.)* Шулай гына итеп килдем дә *(бөгелеп алып)* тиз генә өйгә кереп киттем. *(Сузып.)* Бер кеше дә күрмәде.

Хәлим. Беркем дә күрмәдеме?

Ирҗан. Юк, эти, беркем дә күрмәде. Өебез елы булсын, эти, як. Аннан соң әнием дә терелер. Ә, эти, ягасыңмы? *(Хәлимнең күзенә карап җавап көтә.)*

Хәлим. Углым, бу — кеше нәрсәсе. Кеше нәрсәсен алу гөнаһ була, ярамый. Син аларны кире Иванга бирерсең. Кеше әйберен яшереп алуга урлау диләр. Кеше булмаган йирдә дә Алла бар. Ул күреп тора. Икенче кат мондый эшне эшләсәң, мин дә, әниең дә, Алла да сине сөймәс. Безнең балабыз булмассың, ишетәсеңме, углым.

Ирҗан *(атасын кочаклап)*. Ярый, эти. *(Бераз торып.)* Беркөн безгә бер хатын килгән иде дә, ул да бит бездән сорамыйча алды.

Хәлим. Нәрсә алды, углым?

Ирҗан *(бер йир күрсәтеп)*. Менә биредә бер кап шырпы тора иде. Ишектән чыкканда, алды да кесәсенә салды. Әнием күрмәде. Мин генә күрдем.

Хәлим. Андый эшне начар кешеләр генә эшлиләр, углым. *(Айсылу, йөгереп килеп, йирдән кечкенә генә бер кара нәрсә ала да, бер почмакка сыенып, кимерергә башлый. Аны күреп калган Ирҗан Айсылу артыннан китә.)*

Ирҗан *(Айсылуга)*. Миңа да бир.

Айсылу *(ике кулын аркасына яшереп)*. Мин таптым аны. Ул минеке.

Ирҗан. Бир. *(Алырга тотына. Айсылу бирмәскә тартыша. Ала алмагач, Ирҗан Айсылуга суга. Айсылу да аңа суга. Үзе җылый башлый.)*

Хәлим *(килеп)*. Ни булды, нишлисез? Кызым, ник җылыйсың?

Айсылу. Ирҗан минем икмәгемне аласы килә. Аны мин таптым. *(Йөгереп барып күрсәтә.)* Шуннан таптым. *(Хәлим икмәк катысына карый. Ирҗан, куркып, атасына карап тора. Хәлим икесен дә кочаклый. Хәлимнең күзеннән аерылган бер тамчы яшь Айсылуның битенә тама. Айсылу, битен сөртеп, югары карый.)*

Айсылу *(Хәлимгә)*. Эти, битемә су килде. *(Битен ышкый. Хәлимгә текәлеп карап.)* Эти, син җылыйсыңмы?

Хәлим. Юк, кызым, җыламыйм.

Ирҗан *(Хәлимгә карап)*. Җылыйсың, эти, җылыйсың. Әнә күзләрең юешләнгән бит.

Айсылу. Эти, минем бу төшем авырта. *(Ашказанын күрсәтә.)*

Хәлим *(күзләрен сөртеп)*. Әйдәгез, балалар, ятыгыз. Мин әниегезне карыйм. Ятсагыз җылынырсыз да. *(Айсылуга.)* Йокласаң, кызым, ул йиреңнең авыртуы да бетәр. Иртәгә карточкага барып, сезгә икмәк китерермен. Ярармы? Әйдәгез, минем акыллы балаларым, яткырыйм сезне. *(Урыннарын төзәткәли. Икесе дә яткач, өсләрен ябып, битләреннән үбеп, яннарыннан аерыла.)*

Хәлим *(бер почмакка барып, яшерен генә, үзен тота алмыйча, битенә яулык каплап җылый)*. Нинди тәмле уйлар белән тормышка кердем, балаларымны тәрбия итү турында ниләр төшенмәдем, ниләр. Күңелем белән шулай итәчәк булдым, болай итәчәк булдым. Балаларымны кешелек дөньясына бер үрнәк булырлык итеп йитештерәчәк булдым. Менә алар. *(Җылый.)* Инде яшьтән караклыкка өйрәнәләр, бер-берсен җәберләргә өйрәнәләр. Аларның кечкенә, тапсыз миләре бу куркыныч тормыш, бу сәфаләт (хурлык; түбәнлек.— *Х. М.*) күренешләреннән илһам-азык алып агулана, керләнә. Бу хәлнең, бу әхлаксызлыкның алдына төшеп бетәргә дә мөмкин түгел. Бу большевик — коммунистлык көчләре белән туган бер хәл. Кая карама — үтереш, сугыш, кычкырыш, талаш. Бөтен мәмләкәт кан эчендә. Яшь эчендә. Кая китте өмидле, матур көннәр?.. *(Җылый.)*

Нәфисә. Хәлим, син кая соң?

Хәлим. Киләм, Нәфисә, киләм. *(Тиз генә барып янына утыра.)*

Нәфисә. Авыруым бик озаеп китте. Синең көнең бик авырга калды. Алла миңа ике якның берсен бирсә иде тиз үк.

Хәлим. Юк, Нәфисә, андый авыр сүз әйтмә. Син булганда, минем кичләрем көнгә әйләнә. Авыр таш эшләре җон теткән шикелле җиңел тоела. Тик син, син исән бул. Алла сине барыбыздан аермасын.

Нәфисә. Хәлим җаным. Кара күзләреңнең угы минем җан тамырыма хәтле эшләгән (барып җиткән.— *Х. М.*). Мин аларга карый-карый җан бирәм, җан ачысын тоймаслыгымны бик яхшы беләм. Ләкин, ләкин бу ике бала. Мин аларны ничек ялгыз, ачлыкта, суыкта, бер кешесез ташлап китә алырмын?! Минем бөтен кайгым шулар. Мин бары аларны уйлыйм, алар өчен үлмәскә-яшәргә тартышам, үлем белән тартышам, Газраил белән тартышам. *(Җылый.)*

Хәлим *(торып, өстен төзәтеп яба)*. Җылама, Нәфисәм, җылама. Алла зур. Өмид өзәргә ярамый. Өең суык, ашарыңа җылы аш юк. Ягарга булса, ашарыңа булса, син күптән терелер идең. Сезне тәрбия итә алмыйм, көчем җитми. Тормыш бәхетсез юл алды. Бу турыда күбрәк мин үземне гаепле күрәм. Сиңа бирәр хәл була калса, мин ике дөньяда да ут эчендә калачагымны бик яхшы беләм. (*Җылый.)* Кичер мине, Нәфисә, кичер! *(Башын ятакка тери.)*

Нәфисә *(аның башын сыйпап)*. Җылама, Хәлим, балалар уянмасын. Мин сиңа бер дә рәнҗемим. Болар бар да — минем үз теләвем белән эшләнгән эшләр. Турысын әйткәндә, беребез дә гаепле түгел. Бу — большевиклар хәятының китергән фәлякәтләре (кайгы-афәтләре.— *Х. М.*). Сабыр итик. Бәлки, Алла ярдәмен салыр. *(Йөткерә.)* Син дә ят, Хәлим, хәл җый.

Хәлим. Рәхмәт, Нәфисә, син һәрчакта җылы сүзләрең белән миңа җан каттың, мине яшәттең. *(Кинәт бик нык ишек кагыла, Хәлим сискәнеп тора. Нәфисә дә курка. Ишектә мырылданган тавышлар ишетелә.)* Курыкма, Нәфисә. *(Ишеккә бара.)* Кем анда?

Ишектән. Ач, ач. Хәлим Садыйков монда торамы?

Хәлим. Әйе, монда тора. Ни телисез?

Ишектән. Ач тизрәк. Ачкач күрерсең. *(Хәлим ача. Ишектән ике куркыныч сөңгеле большевик солдаты керә.)*

Берсе *(Хәлимгә)*. Син Гали байның кияве Хәлим икәнсең. Без сине эзлибез. *(Ике ягына торалар.)* Әйдә! *(Хәлим каушап кала.)*

Нәфисә *(урыныннан көчкә-көчкә генә торып)*. Нишлисез, нишләтәсез аны? Аның бер гаебе дә юк бит. *(Торып Хәлимгә асылмакчы була. Солдатның берсе аны мылтык түтәсе белән бик нык төртеп йибәрә. Нәфисә бөерен тотып, идәнгә егыла.)* Уф, Алла, үләм-м-м. *(Балалар бу тавышка сикерешеп торалар да куркышып җылый башлыйлар. Өйнең эче кыямәт хәлен ала. Балаларның берсе — анасына, берсе атасына килеп ябыша. Хәлимгә ябышкан Ирҗанны гаскәриләр төртеп йибәрәләр.)*

Ирҗан. Әтием, әтием *(дип җылап, тагын барып ябыша. Тагын төртеп егалар)*.

Хәлим *(Нәфисәнең йирдәге хәлен күреп)*. Нәфисә, Нәфисәм, ни булды *(дип барырга теләгәндә, гаскәриләр җилкәсеннән тартып кире алалар. Хәлим Нәфисәгә тилмереп карый. Гаскәригә)*? Җибәрегез мине, зинһар, бер минутка. Күрмисезме, авыру хатынны нишләттегез. Урынына күтәреп салырга ирек бирегез.

Берсе *(ачуланып)*. Әйе, сине йибәрергә, синең кәефеңә карап торырга кирәк. Үлсен, бетсен бу буржуйка.

Хәлим *(җылап)*. Әй җаннарым, миңа рәнҗемәгез. Алла ярдәмчегез булсын!

Гаскәриләрнең берсе *(мыскыллап)*. Әйдә, Алласы кил. Безнең кулыбыздан ала алсаң ал! Ничек алырсың икән, көчеңне күрсәт! *(Кычкырып көлә.)*

Икенчесе *(Хәлимгә төртеп)*. Әйдә, атла. *(Хәлим башына алып кия.)*

Хәлим *(җылаган тавыш белән)*. Исән булыгыз, җаннарым. *(Чыгалар. Бүлмәне беразга үлем тынлыгы каплый. Балалар калтырап идәндә яткан аналары янында чүмәләп утыралар. Тилмерешеп карашалар. Бераздан Нәфисә ыңгыраша-ыңгыраша торып утыра. Кинәт кычкырып җылап йибәрә дә балаларын кочаклый. Башын аларның җилкәсенә куя.)*

Нәфисә. Әй балакайларым, балакайларым, сез гөнаһсызларның хакына Тәңрем безгә ярдәм итсен; кайгыларымны кемгә бушатыйм? Уф. *(Башын күтәреп.)* Сез бигрәк яшь әле. Сез бернәрсә дә белмисез, аңламыйсыз, аңламыйсыз әле. Хәлим, Хәлим, аh, җаным, сиңаниләр күрсәтерләр икән? Әтиемне үтерделәр. Әнием кулы шешеп үлде. Әгәр сиңа да шул хәл булса, мин ничек түзәрмен, балаларым нишләрләр, без ничек дөнья күтәрбез? *(Җылый.)*

*Пәрдә.*

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урам буенда асты таш, өсте челтәрле бер койма белән әйләндерелгән зур бакча күренә. Коймадан эчкәрәк кертеп салынган бер өйнең бакчага караган тирәсендә кара-каршы ике хатын утырган. Хатыннарның берсе бәйли, берсе тегү тегә вә сөйләшәләр. Бакчада агач астына куелган бер бакча утыргычында 15 яшьләрендә бер кыз китап укып утыра. Бераздан бакчаның бер юлыннан 18 яшьләрендә бер егет килеп чыга. Аның да бер кулында китап.

Беренче күренеш: Нәфисә, Гөлбану, Ирҗан, Айсылу.

Ирҗан *(җиңел-җиңел атлап, кычкыра-кычкыра килә)*. Айсылу, Айсылу-у, һу-у-у.

Айсылу *(Ирҗанның тавышын ишетеп, башын китабыннан ала. Ул да кулын авызына куеп җавап бирә)*. Оу, һу-у-у.

Ирҗан *(Айсылу җанына килә дә, аның кулындагы китабын тартып алып, утыргычның бер читенә ыргыта. Үзенең китабын да аның өстенә ташлый)*. Әйдә, бераз туп сикертик. Укый-укый күзләрем арып бетте. *(Айсылуны кулыннан тартып торгыза да әйләндерә башлый.)*

Айсылу. Ай, тукта. Җитәр. *(Тырышып кулын ычкындыра да, кире качып, көлә-көлә йөгереп, бер юлдан өйнең аркасына таба чаба вә югала. Ирҗан да аны куып китә, «тот!» дип кычкыра.)*

Нәфисә *(балаларның бакчада йөгерешү тавышына эшеннән башын күтәреп карап тора да тагын эшләргә тотына)*. Инде, шөкер, үстеләр. Кеше булып баралар. Гимназияне бетереп киләләр. Бер китек йирләре булса — үз аталары булмавы гына. Әхмәдкә Алла ике дөньяда ни теләсә, аны бирсен. Берсен дә какмады. Аларга үз баласы төсле итеп тәрбия бирде. Хәлим генә кызганыч. Балаларын үстерә алмады. Аларның кеше булуларын күреп шатлана алмады. Япь-яшь көенчә бөтен авырлыкларны күрде; ахырында үлеп тә китте.

Гөлбану. Күңеленә авыр тоелыр дип бүгенгә хәтле Хәлим әфәнде турында берни дә сорый алмадым. Әле үзең сүз ачкач сорыйм инде. Ничек үлде соң, мескен?

Нәфисә. Аны сөйләсәң, озын инде. Әгәр мондый эшләр минем генә башыма килгән булса иде, эчемдәге ут мине күптән үтергән булыр иде. Ләкин большевикларның кылган явызлыклары, хаксыз эшләре картын-яшен, баласын-чагасын аермаганга, бөтен халыкны бертөсле итәбез дигән булып, төрлесен төрлечә җәберләгәннәре өчен, барысына да төрле-төрле бәхетсезлекләр күрсәткәннәре өчен, мин дә, башкаларның хәсрәтен, ачыларын күрә-күрә, үземнең авырлыкларымны, ачыларымны бастырырга өйрәндем, аларга күнәргә тырыштым.

Гөлбану. Русиядән ничек итеп чыга алдыгыз соң?

Нәфисә. Анысын да сөйләрмен. Бер («ул», «бу».— *Х. М.*) кичне уйласам, әле дә үземне югалта язам. Хәлимне искәртмәстән ике сөңгеле большевик солдаты килеп алып киттеләр. Шул кичтән соң Хәлимне гомергә югалттык; бер генә кат булса да күрә алмадым. (*Яулык белән күзләрен сөртә. Шул арада рәшәткә буенча кара күзлек, сакал-мыеклы, ябык, хәлсез бер кеше, урам читенә үскән бер агачның төбенә килеп, агачка ышыкланып, бакчаның эчен карый.)*

Икенче күренеш: әүвәлгеләр, Хәлим.

Хәлим *(каранып үз-үзенә)*. Балаларым күренми. Хатыным Нәфисә әнә анда террасада утыра. Мескен, минем монда булганымны белсә, нишләр иде икән; әллә мине бөтенләй онытты микән? Алар инде мине үлде дип белә торганнардыр. Алай дип белмәсә, иргә чыкмаган булыр иде. Әгәр Соловкадан[1] качмаган булса идем, юлда туңып үлгән кешегә очрап, Алла рәхмәт итсен, мәрхүмнең киемнәрен салдырып киеп, үземнекен аңар кидереп, Русиядән качып чыгып, бу мәмләкәткә, бу шәһәргә килеп, аның паспорты белән урнашып тормаган булса идем, бәлки, үлгән дә булыр идем. Андагы азапка кеше түзәрлек түгел иде. Үлгән булсам, бәлки, минем өчен мең кат яхшырак булыр иде. Үлми калуымнан инде миңа ни файда бар? Ике балам, хәләл хатыным күземнең алдында. Кулымны сузсам җитәрлек йирдә. Мин дә иректә, иркендә булганым хәлдә, алар белән күрешеп, алар арасында тора алмыйм. Аларның бу шәһәрдә булуларын башта белми идем. Моннан өч ай элек уйламаганда аларга бер китап-кәгазь кибетендә очрадым. Нот (нота.— *Х. М.*) язар өчен, кәгазь алырга кергән идем. Алар да нәрсәләр алалар иде. Хатыным «Ирҗан» дип углыма эндәште. Миңа бик таныш вә бик сөемле булган бу тавышның углымның исемен әйтүен ишеткәч, яшен суккан шикелле булды. Әйләнеп карасам *(бераз тора)* — алар иде. Кинәт башым әйләнде. Тотынып калмаган булсам, егылып киткән булыр идем. Көчемне җыеп, аларга белгертмичә, артларыннан күзәтеп бардым. Алар бу өйгә кереп югалдылар. Шул көннән бирле һәр көн монда килеп бер кат аларны күрмәсәм, тавышларын ишетмәсәм, тора алмый торган булдым. Алар мине бу хәлдә, бу кыяфәттә һич тану ихтималлары булмаганга, менә бу агач төбендә сәгатьләрчә утырам. Бу хәлгә кайчанга чаклы мин түзәрмен. Бу болай ни чаклыга барыр,— белмим. *(Агач төбенә халыкка каршы чүмәли.)*

Гөлбану. Нишләттеләр соң?

Нәфисә *(җылап)*. Элек зинданга япканнар. Аннан Соловкага озатканнар.

Гөлбану. Гаебе нәрсә иде соң?

Нәфисә. Син дә, Гөлбану, большевикларны белмәгән төсле, гаебе нәрсә иде, дип сорыйсың. Большевиклар акыл-исәп белән эш күрәләр дисеңме?! Алар кешегә гаебе өчен генә күрәм күрсәтәләрмени, гаебе: бай кешенең кияве, имеш. Атамны байлыгы өчен үтерделәр. Безнең тормышыбыз эттән дә ярлы иде: ашарыбызга юк, ягарыбызга юк. Ач-ялангач. Үзе аларда таш вата, таш эше эшли иде. Җир өйдә торабыз. Шул хәлебездә тынычлык бирмәделәр. Өебезне тузгыттылар. Эшләгән йирендә сүз арасында «Байның эше фәрман белән, юкның эше дәрман белән» дигән икән. Бер әләкче, шул сүзгә койрыклар кушып, большевикларына җитештергән: «Менә шундый пропаганда сүзләр сөйли»,— дигән. Үзе шулай яхшы атланып күзгә кермәкче булган. Сораштыралар: Хәлим бай кияве булып чыга.

Алар каршында моннан да зур гаеп булырга мөмкинме? Шулай итеп, мескенне онытмадылар: Соловкага озаттылар.

Гөлбану. Ничек булды, сез ничек белдегез?

Нәфисә. Йибәрелгәннең икенче кышны Соловкадан качкан булган. Качып барганда, бер йирдә урман арасында өшеп үлеп калган. Яз башында карлар эрегәч, авыл кешеләре, күреп, хөкүмәткә хәбәр биргәннәр. Өс-башындагы киеменнән вә кесәсендәге кайбер кәгазьләрдән Соловкадан качкан Хәлим атлы кеше булуын аңлаганнар. Үзе танырдай булмаган. Каралган. Исхак исемле үзе белән Соловкада булып кайткан сөйләде. Аннан соң артыннан йөреп, сорашып аңладым. Кулыма кәгазь дә бирделәр.

Гөлбану. Сез шуннан соң качтыгызмы, бичаралар?

Нәфисә. Әйе, ул хәбәрдән соң минем күземә дөнья күренмәс булды, җылый-җылый күзләрем бетте, хәлем-көчем бетте. Тормышыбыз төзәлмәслек авырга калды. Мин — хатын кеше — эш белмим. Кара эшкә көчем җитми. Әхмәдкә иргә чыктым. Әхмәд этиемдә кечкенәдән бирле торган кеше иде. Аның да хатыны өч ай элек үлгән иде. 5 яшьлек ир баласы калган иде. Без ике бәхетсез гаилә шулай итеп берләштек. Ул минем кайгымны уртаклашты. Мин аныкын уртаклаштым. Бергә җыладык, авырлыкларга бергә күндек.

Гөлбану. Алла ярдәм иткән инде.

Нәфисә. Әйе, әйе. Хәлимнең укымышы бар иде. Патша төшкәч, ирек көннәрендә тоткынлыктан котылабыз дип, милли көннәрдә омтылган чакларда Казанның яңадан тереләчәген, йиребезне яңадан үзебез көтәчәгебезне тәмләп сөйли иде. *(Җылый.)* Мескен. Әле дә күз алдымда өч айлык бала иде. Тезенә бастырган да: «Әйдә, Ирҗан, өйрәнә башла; бер-ике-өч, син Тимернең тимере шикелле гаскәрие булачаксың. Менә бу йирдә *(күрсәтеп)* сызылып чыккан мыекларың булыр. Күкрәгеңне киерерсең, җилкәңдә мылтык, үз йортыңа сакчы булырсың. Их, нинди кызык булыр, ә Ирҗан, дигән иде.

Гөлбану. Әй мескен. *(Бераз торып, башын күтәреп.)* Монда ничек чыгуыгызны сөйләмәдең әле, Нәфисә.

Нәфисә *(эшеннән башын алып)*. Качып. Мең бәла белән. Аларны сөйләп аңлатырдай түгел инде. Монда килгәч, абзасын эзләп таптык. Ул бик бай кеше икән. Сабын фабригы, җирләре, йортлары, әйтеп бетергесез дәүләте бар икән. Баласы булмаган. Безне күктән төшкән төсле каршы алды. Әхмәднең дә углы качкан чагыбызда юлда авырып үлеп калды. Алма кебек бала иде. Барыбызга да бик авыр булды. Шул көннән бирле бу ялганчы (?япанчы.— *Х. М.*) җәннәтендә торабыз. Үткән ел Әхмәднең абзасы үлде. Карт иде. Башка кешесе булмагач, бу дәүләт абзасының хатыны белән Әхмәдкә калды. *(Бакча юлыннан Ирҗан белән Айсылу, шаулашып үтеп, баягы җиргә киләләр. Ирҗанның кулында зур гына бер туп бар.)*

Өченче күренеш: әүвәлгеләр, Ирҗан, Айсылу.

Ирҗан *(Айсылуга урын күрсәтеп)*. Син әнә шунда утыр. *(Койма буеннан сирәк кенә бер-ике кеше узып киткәне күренә.)*

Айсылу *(арка-арка килеп)*. О, бик ерак. *(Каршы бәрешеп төшерә-тота уйный башлыйлар. Көлешәләр, сөйләшәләр. Туплары төшеп тәгәрәп китә. Аның артыннан икесе дә китеп тагын бераз югалалар.)*

Хәлим *(балаларның тавышын ишеткәч, аякка басып, акрын гына койма буена килә)*. Әнә алар чыктылар. Нинди матур булып үскәннәр. Тал чыбыктай булып җиткәннәр. Нинди тәрбияле күренәләр. Хатыным — Нәфисәм — ул тагын да матурая төшкән. Хатынлыгының гөрләп торган чагына килгән. Болар янында мин бөтен бәхетнең эченә чумачагым билгеле. Ирҗан бөтенләй үземә охшый, аңар эндәшәсем килә. Уф-ф *(йөрәген тота)*, йөрәгемнең янганын беркем дә белми дә, күрми дә. Баланы чакыру, балаңа эндәшә алудан да зур бәхет бармы? Мин моны хәзер аңладым. *(Уйланып.)* Күрә торып, болай үз-үземне бәхеттән мәхрүм итүем турымы? Ник мин үземне мәхрүм итәм, ник ирексезлим, ник болай көчлим? *(Йөрәген тотып, башын күтәреп, кызганыч карый.)*

Дүртенче күренеш: әүвәлгеләр, Ирҗан, Айсылу.

Хәлим *(бераз торып, Ирҗан белән Айсылу күренә)*. Юк, чыдар хәлем юк. Аларга үземне белгертәм. Алар арасына атылам. Юк, балаларым, юк. Мин болай сезне күреп, сезгә эндәшмичә тора алмыйм. *(Тиз-тиз атлап, бакча капкасына туры бара башлый.)*

Айсылу. Бераз утырып хәл җыйыйк. *(Кулын селкеп барып, баягы урынга утыра.)*

Ирҗан. Әй, кызлар белән уйнауның бер дә кызыгы юк. Алар бик тиз арыйлар. *(Тупны бик каты җиргә бәрә дә үзе Айсылу янына утыра. Сөйләшкән вә көлешкән кыяфәттә җиргә чыбык белән сызыклар сызып уйнап утыралар.)*

Хәлим *(кинәт туктап)*. Нишлим мин, әллә, әллә җуләрләнәмме? Ни йөз белән барып балаларга күренергә кирәк? Ничек, мин сезнең атагыз, дип уйламыйча әйтергә кирәк? Мин хәзер аларга үземне танытсам, дөньяның иң түбән бер кешесе булырмын. Алар тормышларын үзгәртәчәкләр. Мин... Аларга бер җылы урын әзерләүдән дә мәхрүммен. Яхшы аш түгел, бер икмәкне, бәлки, мең бәла белән ашата

алырмын. Бу качакчылык тормышында, чит җирдә эшләргә эш тә таба алмыйм, исәнлегем дә юк. Алар минем кулымда бөтен мәгънәсе белән бәхетсез, ач-ялангач, ярлылык эчендә торачаклар, гөл шикелле яңаклары саргаячак, кайгысыз көннәре моңланачак, башлары җилкәләренә борылып төшәчәк. Тормышлары агу йоткан төсле ачы, көннәре җәһәннәмгә әйләнәчәк, бәлки, эчләреннән миңа мең-мең ләгънәтләр укыячаклар. Аларны бәхет кочагыннан алып бәхетсезлек эченә атарга хакым бармы? Болай итсәм, мин аларны сөйгән булмыйм, тик үземне сөйгәнлегемнән — эгоистлыгымнан булган бер эш кенә булачак. *(Торып.)* Юк, юк; уф, балалар, белмисез, җаннарым, мин сезне нихәтле сөям! Күзләрегезгә бер карар өчен тилмерәм. *(Җылый.)* Сезнең кулларыгыздан тотасым килә. Сүзләрегезне ишетәсем килә, сезгә эндәшәсем килә. Бичара атагызның хәлен бер аңласагыз иде. *(Җылый.)* Юк, аңламагыз, юк, белмәгез, мин сезне сөйгәнем өчен үземне сездән сакларга, танытмаска кирәк. Минем кулымда үскән булсагыз, мондый бәхетләрне күрә алмаган булыр идегез. Сезне бу рәхәтегездән аерсам, мин сезне сөйгән аталмам. Юк, мин үземне сезгә белдермәм, сез мине үлде дип белегез. Күз яшьләремне эчемә агызырмын, чыдарга тырышырмын. *(Акрын гына кузгалып китәргә дигәндә, балаларның тавышын ишетә дә тагын туктап текәли.)*

Ирҗан *(торып, тупны алып бераз китә дә Айсылуга)*. Әйдә, тот. *(Җылмаеп атарга әзерләнә.)*

Айсылу *(торып каршысына баса)*. Я, ат. *(Тупны тота алмый. Тәгәрәгән туп артыннан барып.)* Син ата белмисең.

Ирҗан. Син үзең тота белмисең. *(Көлешәләр.)*

Нәфисә *(террас читеннән килеп кычкыра)*. Ирҗан, Айсылу, чәй эчәргә килегез.

Айсылу. Ярый, әни, хәзер киләбез. *(Сузып кычкыра. Тупны ашыгып-ашыгып атыша башлыйлар.)*

Хәлим *(акрын атлап)*. Нинди җылы, нинди рәхәт сезнең янда. Йөрәгем май күк эреп китә. Бер дә генә аерыласым килми. *(Туктый. Тагын карап бераз тора. Ул арада Ирҗанның аткан тубы Айсылуны үтеп Хәлимнең шапкасына* («баш киеме» мәгънәсендә.— *Х. М.*) *килә дә башыннан йиргә төшерә. Хәлим бердән сискәнеп китеп башын тотып әйләнә.)*

Айсылу. Ай, нишләдек, Ирҗан, мескен бер кешенең башынамы, күзенәме тиде. *(Икесе дә йөгерешеп Хәлим янына баралар.)*

Ирҗан *(Хәлимнең янына ук барып)*. Кичерегез мине, зинһар, яңлышлык белән булды, абзый.

Айсылу *(якынлашып)*. Абзый, бер йирегез авырттымы? Катымы бәрелде, әйтегез.

Ирҗан. Бер йирегез авыртамы? *(Хәлимнең маңлаена ябышкан туфракларны сөртә, төшкән эшләпәсен алып бирә.)*

Хәлим *(кинәт кычкырып җылап йибәрә. Вә Ирҗанның кулын тотып)*. Углым, рәхмәт, рәхмәт! Тубың тигән йирем бер дә авыртмады. *(Бер-ике кеше үтеп китә.)*

Ирҗан. Ничек авыртмасын, абзый, әнә кызарган; бераз җилсенеп тә киткәнгә охшый. *(Кызганып карый.)*

Хәлим. Юк, борчылма, ул йирем авыртмый. Авырта торган йирем монда, углым. *(Йөрәген тотып күрсәтә.)* Әнә әллә нишли. Уф-ф... *(Кинәт шап итеп егылып китә. Ирҗан белән Айсылу куркып, аптырап калалар. Егылган кешене вә алар янында карап торган Ирҗан белән Айсылуны күреп, узып баручылар да тукталып, кире килеп карарга башлыйлар. Тагын бер-ике кеше килә.)*

Халыктан берсе *(тирә-якка карангалый да халыкка)*. Әнә бер полис (полицейский.— *Х. М.*) китеп бара, шуны чакырыйк. *(Кулын селкеп кычкыра.)* Полис, полис! *(Бераздан тиз-тиз атлап, полис килеп чыга.)*

Полис *(ятканны карап, халыкка)*. Китегез, юл бирегез. Берегез миңа булышыгыз, әнә шул каршыдагы аптекага алып керик. *(Полис белән бер кеше берсе башыннан, берсе аягыннан кочаклап югалалар. Халык та вә Ирҗан белән Айсылу да алар артыннан китеп югалалар. Бераз тынлык.)*

Нәфисә *(террас читенә килеп каранып кычкыра)*. Балалар, кая сез? *(Гөлбануга әйләнеп.)* Болар кая китте икән, күренмиләр. Урам ягыннан бераз шау-шу тоелган төсле булды. Урамда берәр кызык карап торалармы әллә?!

Гөлбану *(башын күтәреп)*. Киләләр, киләләр. Пошынма.

Бишенче күренеш: Нәфисә, Гөлбану, Ирҗан, Айсылу.

Бераздан Ирҗан белән Айсылуның урам буйлап күңелсез генә әйләнеп кайтулары күренә. Ирҗан, бакча капкасы янынарак йиткәч,
йирдән бер төрелгән кәгазь ала да сүтеп карый.

Айсылу *(якынлашып карый)*. Язылган бер нот.

Ирҗан. Әллә теге мескен кешенеке төште микән? *(Тагын йиргә карангалый.)* Әнә бер карандаш та ята. *(Иелеп ала.)*

Айсылу *(яңа исенә килеп)*. Ә, әйе, әйе. Аныкы төшеп калды, мин күзем белән күрдем күрүен дә полисның янына барып әйтә алмадым. Бик буталчык чак иде. Аннан соң онытып йибәрдем.

Ирҗан. Алып керик. Соңыннан бирербез.

Айсылу. Кемгә?

Ирҗан. Полиска.

Айсылу. Ярый. *(Икесе дә, акрын гына бакча капкасыннан кереп, терраска, аналары янына баралар.)*

Нәфисә *(аларны күреп)*. Кая югалдыгыз, балалар? Чәйләрегез суынып бетте. Утырыгыз, эчегез! *(Ирҗан белән Айсылу күңелсез генә урнашалар. Нәфисә икесенә дә карап алып.)* Ник болай бик күңелсезләндегез, берәр хәл булдымы әллә? *(Ирҗан белән Айсылу бер-берсенә карыйлар. Икесе дә чәй өстәленә утыралар.)*

Гөлбану *(кул белән битен җилпеп)*. Фу, эссе. Тышта утырып чыдап булмый. *(Балаларга карап.)* Болар, чынлап та, бик күңелсезләр, уйга чумып утыралар.

Нәфисә. Я, ни булды? Бая урамда шау-шу ишеткән күк булдым. Берәр хәл булдымы әллә? Бу хәлегезгә эчем поша башлады.

Ирҗан. Әйе шул. Бер кеше үлде.

Нәфисә *(каушап китеп)*. Ә, кеше үлдеме, кем үлде, кем?!

Ирҗан. Әни, син кызык кеше, әйтмәсәң — эчең поша, әйтсәң — кәефең китә.

Нәфисә *(тынычлык күрсәткән булып)*. Я, юк, юк. Сөйлә: кем үлде, ничек үлде?

Ирҗан. Без туп уйный идек, минем тубым рәшәткәдән узып, үтеп торган бер кешенең башына тиде.

Нәфисә *(куркып)*. Ай, рәхмәт төшкере, әллә бәреп үтердеңме?

Ирҗан *(куркып)*. Әнкәем, нигә болай юк сүзләр сөйлисең?! Сүзнең ахырына чаклы көтеп торсана инде.

Нәфисә. Я, я.

Ирҗан. Шуннан соң бу туп артыннан барып, аның да хәлен сорадык. Юк, башым авыртмады диде. Җылап йибәрде. Минем йөрәгем авырта дип әйтеп тә бетермәде, егылып китте. Без аптырап калдык.

Ике хатын да *(бик исләре китеп, бер яктан кызганып)*. Ай, бичара, аннан соң?

Ирҗан. Аннан соң халык җыелды, полис та килде. Каршыбыздагы аптекага алып бардылар. Без дә аркасыннан (артыннан.— *Х. М.*) бардык. Анда доктор бар икән, ул карады да йөрәге тукталып үлгән диде. Аннан соң хастаханәгә алып киттеләр.

Хатыннар. Мескен-н-н.

Нәфисә. Нинди кеше икән, мөселман микән?

Айсылу. Әйе, мөселман икән, әни. Әхмәдҗан Гыйльметдинов дигән кеше. Кесәсеннән паспортын алып карадылар. Адресын белмәделәр.

Нәфисә вә Гөлбану *(дога кылып)*. Ай, бичара, ай бичара, Алла рәхмәт итсен!

Нәфисә. Алла урынын оҗмахта итсен, кемнәре калды икән бичараның?

Ирҗан. Белмим. Анда билгеле булмады. Әни, бәлки, син дә ул кешене күргәнсеңдер?

Нәфисә. Каян күрим? Күрсәм күргәнмендер. Урамда кеше күп, кайсын белеп бетерәсең, углым?

Айсылу. Юк. Бу кеше гел урамдагы шул каен төбендә утыра яки узып китә иде.

Ирҗан. Кара күзлекле, сакаллы бер кеше.

Нәфисә *(исәпләп торып)*. Ә, әйе, әйе, аны мин дә күргәләдем. Бик кызганыч бер хәле бар иде. Шул кеше икән, алайса. *(Тагын кулын күтәреп дога кыла.)* Алла рәхмәт итсен!

Айсылу. Без әйләнеп кайтканда, аның кесәсеннән төшеп калган бер язылган нот белән бер каләм таптык. Иртәгә полиска бирәбез.

Ирҗан *(Айсылуга)*. Пианода уйнап карыйкмы, матур микән? Матур булса, күчереп алып калырбыз.

Айсылу. Ярый, чынлап та. *(Тора.)* Әйдә, уйнап карыйк. *(Террас ишегеннән өйгә керәләр.)*

Нәфисә. Әйе, уйнагыз әле. Безнеңчә булса, без дә тыңлыйк. Мөселман булган, күрәсең. Нинди явыз тәкъдир сине бу якларга кугандыр? Качактыр инде.

Гөлбану. Шулай, Нәфисә. Әллә кемдә әллә ниләр бар. Беркемнең дә сарае буш түгел. *(Эчтән пиано тавышы ишетелә. Бер кат җырламыйча уйнала.)*

ХӘЛИМНЕҢ НОТАДАГЫ ҖЫРЫ

Йөрәгемдә хәсрәт авыр таштай,
Кара төндәй күңлем караңгы.
Инде һич юк миңа җылмайган көн,
Мәңгелек гүр кочды дөньямны.

Шатлыгымны тартып ятлар алды,
Бәхет гөлем шиңде, боекты.
Эчем яна ялкын, күңлем каный,
Бөтен дөнья кара төс алды.

Матурлык юк, көнем-күңлем суык,

Бәхетсезлек — җирдә өлешем.
Төзә алмаслык ачы яра белән
Ничек үтәр ялгыз тормышым?..

*(Икенче кат уйнаганда, икесенең дә җырлаганы ишетелә. Җырлап беткәч.)*

Нәфисә *(күзләрен сөртеп)*. Бу җыр бик эчемне яндырды. Һай, бичара, кем белер, бәлки, бу шигырь — аның үзенең «тормыш көзгесе»дер. *(Эчкә таба кычкыра.)* Балалар, тагын шуны бер кат уйнагыз әле! *(Ирҗан белән Айсылу җырлап уйныйлар. Җырланып беткәндә, пәрдә төшә.)*

*Пәрдә.*

## «Уку китабы»ннан үрнәкләр

### Язгы Идел өстендә

*(Бер баланың истәлеге)**

…Идел өсте нинди ямьле: шоп-шома, тып-тыныч, тик ут көймәсенең (пароходның.— *Х. М.*) көпчәк тавышлары белән, алардан чыккан күбекле сулар гына аның шомалыгын, тынычлыгын бозалар. Көпчәк астыннан күбекләнеп чыккан сулар ике яклап акрын гына артка таба җәеләләр дә су өстендә озын энҗеле юл калдыралар, аксыл-сары җирлек өстенә ак сәйләннәр белән чигелеп барган төсле тора.

Акчарлаклар, моңсу тавыш белән чыкылдашып, балык күзләп, көймә янында очалар. Әнә көннең бер очына таба авышкан кояш батарга әзерләнә. Ике яклап сузылган матур яр яшел белән сарыдан тугылган (тукылган.— *Х. М.*) төсле күренә.

Әнә безнең каршыга бер ут көймәсе килә. Ул ак буяуга буялган, кечерәк кенә, үзе бик җитез йөри. Менә безнең ут көймәсе белән алар сәламләштеләр: байраклар селкештеләр, кычкырыштылар. Аннан соң көймәләр бер-берсе турысына килеб, үтеп киткән чакларында ике ут көймәсеннән дә кайбер юлчылар вә балалар бер-берсенә яулыклар селкештеләр. Каршы килгән ут көймәсеннән кечкенә кызлар яулык селкә иде. Мин дә, яулыгымны чыгарып, аларны сәламләдем.

Ул арада мине әнием чәй эчәргә чакырды. Мин: «Керәм, әни, хәзер керәм»,— дип сөйләнә-сөйләнә, әни янына киттем. Идел суы белән чәй эчәргә мин бик яратам. Аның сарырак, төчерәк аерым бер тәме бар. Чәй эчкән арада, никтер, исемә кылт итеп Сөембикә (автор бу исемне «Сөем бикә» рәвешендә язган.— *Х. М.*) килеп төште. Әниемнән: «Әни, әни, Сөембикә дә Казаннан шулай ут көймәсендә киткәнме?» — дип сорадым. Әни: «Әйе. Ул чакта әле мондый яхшы ут көймәләре булмаган. Зур көймә төсле нәрсәләр генә булган».

— Әни, миңа Сөембикәне сөйләсәнә!

— Сөембикә безнең иң соңгы ханыбыз була. Ул бик акыллы, бик зирәк, булдыклы, уйчан, халкын, йортын (илен.— *Х. М.*) бик сөюче бер хатын булган. Ул Казанны урысларга бирмәс өчен бик тырышкан. Бөтен көче белән гаскәрләребезне урысларга каршы торып сугышырга димләгән. Ләкин усал кешеләрнең зарары тигән: Казанның урысларга китүенә сәбәпче булганнар.

Шуннан соң инде без Казансыз, хансыз калганбыз, урысларга тоткын булганбыз.

— Казан инде безнең үзебезнеке түгелмени, әнием?

— Ул һәрчакта безнеке, ләкин урыслар, төрле алдаулар белән безгә бик зур авырлыклар китереп, бик каты көчләп алып, аны үзләрендә тоталар. Бер иптәшең синең кулыңдагы матур уенчыкка яки курчагыңа кызыгып, сине көчләп, чәчләреңне йолкып, кыйнап, сугып, битләреңне тырнап, курчагыңны үзенә алса, ул курчак синеке буламы, кемнеке була? Я, әйтеп кара!

— Минеке була, әнием! Ул минем курчагымны көчләп кенә үзенеке ясаган була. Ул бик усал, начар кыз була. Ул курчак гел минеке була.

— Алай булса Казан да шул гел безнеке инде. Казанны да, башка җирләребезне дә урыслар бездән шулай безне көчләп, үтереп, талап, җылатып алганнар.

— Алай булгач алар минем курчагымны талап ала торган кыз кебек безнекен талап алып торучылар икән.

— Әйе, Сөембикә дә шулай Казанын бирергә теләмәде. Аның үзен дә, Казанын да тартып, талап алдылар. Үзен Мәскәүгә тоткын итеп елатып алып киттеләр.

— Анда киткәч нишләде, энкәем, Сөембикә?

— Үлде, кызым, елый-елый кайгысыннан үлде. Ире Сафагәрәйнең кабере Казанда калган иде. Кечкенә углы Үтәмешгәрәйне сөекле әнисеннән аерып алып чукындырдылар. Сөембикә аның өчен дә бик кайгырды.

— Аһ, энкәем, әгәр мине синнән көчләп аерсалар иде, мин синнән башка тора алмас идем, үләр идем. Кызганыч Үтәмешгәрәй, кызганыч Сөембикә,— дидем дә әниемне барып, кочаклап үптем. Әни, минем башымнан сыйпый-сыйпый: «Шулай, кызым, син менә ут көймәсендә, әниең янында шатланып,

авылга, әбиләрең янына кунакка китеп барасың. Ә Сөембикә бу юллардан, Казаннан аерылу ачысына чыдый алмыйча, үз-үзен белешмичә, елап, кайгырып барган. Менә Идел шуларны күргән.

— Әнкәем, Иделнең теле булса иде, безгә шул чактагы хәлләрне хәзер сөйләсә иде! Ниләр сөйләр иде икән?! Идел дә безнекеме, әнкәем?

— Идел дә безнеке. Ул бит — безнең изге суыбыз. Аңар Сөембикәнең яше катышкан.

Безнең әни белән сөйләшкән чакта безнең сүзгә катышмыйча чәен эчеп утырган Батыр (минем энем) акрын гына «Сөембикә бәете»н ерлый башлады...

Идел ага, яр кагып,
Унга-сулга чайкалып;
Ут көймәсе китеп бара,
Сөембикәне алып.

Сөембикә ак яулыгын
Тоткан учлап кулына,
«Хуш, Казаным, каласың»,— дип
Үкереп елый буена.

Ия башын, түгә яшен,
Казанга таба карап,
Миндән башка ничек итеп
Көн итәрсез, дип айап.

Зифа буйлы, кара кашлы,
Сөйкемле ханбикәбез.
Тоткын булып торган чакта,
Ничек итеп түзәрбез?!

«Сөембикә бәете»н ерлап бетергәч, Батыр сикереп торды да: «Тукта әле, менә мин үсим дә...» — дип күкрәген киереп йөренгәли башлады. Әнием аңар көлемсерәп карап торды да: «Син үскәч нишләмәкче буласың соң, улым? — дип сорады. Ул: «Минме, мин үскәч, Казанымны кире алам!» — дип, күкрәген кагып кычкырды.

### [Ризаэддин Фәхреддин турында]*

Мөхтәрәм Риза Хәзрәтнең үлеме хәбәрен китергән хатын алганым чакта кулымдагы гәзитәдә бу исемдә бер популяр мосахәбә («трактат», язма.— *Х. М.*) укый идем. Бу мәкалә Риза Хәзрәтнең шәхсыятенең тирәнлекләренә кайтканга күрә, бонда күчереп китүне зарарсыз булдым:

«Иске вакытларда кайбер мәктәпләрдә тулы дәрәҗә 45 иде. Боның сәбәбен миңа балалык көннәремнән күп еллар үткәннән соң гына белергә туры килде. Бу «адәм» дигән сүз булып, әбҗәд хисабы белән «45» тота икән. Бу укучы «адәм булды» дип әйтелерлек дәрәҗәдә җаваплар биргән чагында гына аңар тулы дәрәҗә бирелә икән.

Кешегә хәятында да бу тулы дәрәҗә ала белергә кирәк. Фәкать бу имтиханда сөаль сораучы, җавап бирүче дә кешенең үзе булу шарты берлә; искеләрнең моракабә (уйга чуму; онытылу; экстаз хәле; суфыйчылыктагы бер психологик халәт.— *Х. М.*) дигәннәре бу, кешенең эчендә, үз-үзе берлә сөйләшүендә иң зур хакыйкатьләрнең шәкелләре күренә вә мәгънәләре өстә чыга. Франклин һәркемгә, ятудан элек, үз-үзенә хисап бирергә киңәш бирә иде. Ярты үлем саналган йокыга китүдән элек кеше үзенең хисабын үз кулы берлә тотарга, эшләгән эшләрен үз башы берлә чагыштырырга, үлчәргә кирәк. Мин бу мосахәбәдә «нәфси моракабә»нең иң авыр мәүзугын (мәсьәләсен, темасын.— *Х. М.*) аерам. Фәкать бу авыр мәүзугъ турыдан бирелә беләчәк сорауларның беренчеседер дә, аңар 45 дәрәҗәлек җавап кайтару һәркемгә насыйп булмаучылыгын мин бик яхшы беләм. Шулай булса да аңар биреләчәк җавап турында уйланырга хәзерләнү дә үзе бер җавапдыр. Менә хәят мәктәбендә бик күпләрне сыйныфта вә шулай ук байтагын яңадан хәзерләнүгә калдыручы бу сөальне бергәләшеп сорыйк.

— Мин нәрсә?!

Бу сорауга каршы элек кешенең хәятындагы эше, дәрәҗәсе, һөнәре исенә төшәр. Хәлбуки «мин» дигән нәрсә күп вакытта бик еракта, болар соңрадан килгән, сүнәргә мәхкүм (дучар ителгән.— *Х. М.*) хәлләрендәдер. Хадисәләр мондый тотрыксыз нәрсәләрдән кешене ялангачдалыгы тәкъдирдә, ул йоны коелган мачы төсле булып калыр иде.

Икенчеләтеп, ашап-эчеп, йөрүче-хәрәкәт итүче барлыгыбыз искә килер: башым, аягым, гәүдәм, йөрәгем сүзләрендәге «м» замирлары (зат кушымчалары.— *Х. М.*) берлә минлегебезгә кайтканын белдергәнебез бу әгъзаларыбыздан ясалган бербөтенне «мин» дип белербез, хәлбуки болар да үлмәгә мәхкүмдер. Үлем килү берлә мәгънәләре тиз үк башкарыр, вазыйфаларын үти алмый торган хәлгә килер, черерләр. Вөҗүдләре шулай үлмәгә буенсынып (буй-сынын.— *Х. М.*) дөньядан аерылдыклары

хәлдә, исемләре берлә һаман да хәтерләрдә яшәүчеләрнең минлекләрен ничек итеп башка, югалган барлыклардан санарбыз?

Боны белү өчен, элек бездән нәрсә кала вә безгә бездән әүвәлгеләрдән нәрсә калган? Боны тикшерергә кирәк. Аналарыбызның вөҗүдендә бер «рәшим» («билге», сыйфат, «үзлек».— *Х. М.*) булып барлыкка килгән вакытыбыздан башлап шөгуребезнең (акыл-тоюбызның.— *Х. М.*) өлгереп җиткән чагына кадәр булган чагыбыз эчендә соңрадан искәрмәгәнебез вә безнең өчен шөгуребез алдында юк күренгән әллә ни хәтле хадисәләр бардыр ки, әгәр боларны башкаларда күрмәсәк вә башкалар боларны безгә күрсәтергә сәбәпче булмаса, берзаманнар боларның бар булуларында ышанырга мөмкин түгел. Шулай булгач безгә беленмичә, хафизәбезгә (зиһенебезгә.— *Х. М.*) бер ачык күләгә төшермичә киткән бу тәэсирләр кайда китә?

— Ата-ана вә болар мәнсүб булган (боларга мөнәсәбәте булган.— *Х. М.*) җәмгыять — бөтен бу беленер-беленмәс интыйбагларны («билгеләрне», бәйләнешләрне.— *Х. М.*) ясаучы вә эзләр калдыручы бердәнбер барлыкдыр. Без юк булган чакта ул яши иде. Без үлгәннән соң да «фәрд (шәхес; бөтен; ялгыз.— *Х. М.*) булып» ул яшәвендә дәвам итәчәктер. Шул тәкъдирдә мин «мин» булу ягыннан үземдә үлми торган нәрсә итеп, бары җәмгыятьне күрәм, димәктер. Чөнки үлми торган ул барлыкның үлә торган бу барлыктан алган кодрәтләр аның хәят азыгы була. Мин аннан җәмгыятьтән алганым нәрсәләр берлә нихәтле яшәсәм, аңар биргәнем нәрсәләр берлә дә аны ул хәтле яшәтмәкдәмен. «Фәрд юк, җәмгыять бар» сүзенең иң тугры мәгънәсе будыр.

Җәмгыять дигәнебез бу барлык шөгуре өлгерү берлә милләт сыйфатын ала. Без үзебезне бу шөгурле җәмгыятьнең бер кисәге итеп хис итүебез күләмендә «барыбыз» дибез. Миндә бар нәрсә үлеп бетәр. Фәкать миннән элек бар булган шикелле, миннән соң да бар булачак булган бу зур гозвуят (җәмгыять.— *Х. М.*) үлмәстер.

Һәртөрле истихаләләр (бер хәлдән икенче хәлгә керү.— *С. Г.*) (эверелү — метаморфозалар.— *Х. М.*) берлә үлемебездән соң да аңар биргән нәрсәләребезне үзенең барлыгында бергә соңсызларга алып барачак булган бу саклаучы, юк булудан коткаручы барлык безнең өчен бөтен нәрсәдән изге булырга кирәк.

Һәр кеше «фәрд» — бөтен кодрәтен мәнсүб булганы бу изге җамигага (тупламга, җәмгыятькә.— *Х. М.*) нихәтле җәя, тарата алса, ул хәтле адәмчелек таба, үсә, зурая, мәңгеләшә. Башлангычы миллият булмаган бөтен идеаллар үзләрен аңар кайтаручы бер юл булмаган тәкъдирдә җавапсыз калып, үлмәгә мәхкүм була. Үзләрен милләт дигәнебез бу чикле вә шөгурле төркемгә бәйләнгән итеп сизмәүчеләр бу зур хәят юлында адашалар.

Инде сезне тагын сезнең берлә калдырам: «Мин нәрсә?» соравына үзегез җавап бирә белерсез вә нәтиҗәдә алачагыгыз дәрәҗәне дә үзегез үлчәрсез».

Бу мәкаләне укыганнан соң, үрнәк булып җанлана торган типлардан берсе дә Риза Хәзрәттер. Менә үлеме берлә безне тирән кайгыда калдырган сайгылы (хөрмәтле.— *Х. М.*) Риза Хәзрәт «мин нәрсә?» сөаленә җавап биргән, яшәгән чагында төшкән вазыйфасын үтәгән, хәятта тулы дәрәҗә — 45 санымы алган бер шәхсыять иде. Аның үлмәгә мәхкүм булган вөҗүде, арабыздан аерылып, үлә торган минләргә, барлыкларга катнашканы хәлдә, исеме берлә һаман да хәтерләрдә калачак вә үлмәячәк булган барлыклар җөмләсеннән булып һәр заман арабыздадыр. Ул хәятта һичбер адымын хисапсыз атламаган вә файдасыз, һәдәфе (максаты.— *Х. М.*) булмаган бер сүзне сөйләмәгән бер кеше иде.

Үзенең милләтен үзендәге бөтен кодрәтләрдән файдаландырды, үстерде, тәрбия итте. Аның күреше тугры вә тирән, фикере бакышы хөр иде. Сабыры вә самимияте, хисаплылыгы, тугры сүзлелеге берлә аерым бер яратылышка ия иде. Кеше аның берлә очрашкан чагында һәрвакыт күрергә ашыккан (басмада — «алышкан».— *Х. М.*) белешләреннән берсе итеп кенә күреп китә алмый; аны күрү берлә башыңның эчендә синама тасмасы (кинокадр.— *Х. М.*) төсле алышынып тора торган күренешләр җанлана; бөтен ил, аның бөтен эшләре уйга килә, ул кешене уйландыра, әллә нинди изге вазыйфаны искәртә, ниндидер бер кирәк нәрсә онытылган шикелле булып җан борчыла башлый, сискәнә, эзләнә, аннан аерылганнан соң, кеше үзеннән зәмзәм суы берлә коенган шикелле бер җан рәхәтлеге, бер җиңеллек сизә иде. Кыскача гына әйткәндә, ул барлыгы берлә каршысындагының милли хисләрен кабарта, өрпәтә, дулкынландыра, аны пасларыннан («кимчелекләреннән».— *Х. М.*) арчый, аңар ышаныч вә иман тәлкыйн итә (төшендерә, сеңдерә.— *Х. М.*) иде.

Ул дини-милли мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләреннән бик өстен йөртә. «Мин» дигән нәрсәнең барлыгын да сөйләргә ояла, «мин» сүзе аның каршында бер «юк» хөкемендә бик кечкенә бер нәрсә генә, аның каршында «мин» түгел, «без» генә бар. Шуңар күрә хәятта аның бөтен эшләгән эшләре «без»гә генә кайта, «без» өчен генә эшләнә иде.

Аның нихәтле шулай булганын сезгә аның хәятында каршылашкан вакыйгалардан куркыныч, фидакярлек вә ирлек теләгән бер мисал берлә аңлатып үтим.

1931 елда аны большевиклар Мәскәүгә чакырганнар. Аңар үзләренең иң пычрак эшләреннән булган бер ялган пропаганда хитабәсе (мөрәҗәгате.— *Х. М.*) имзаларга кушканнар. «Моны имзаламасаң үтерәбез»,— дип тә куркытып куйганнар. Риза Хәзрәт алып укып караган. Ул хитабә

Совет Русиясендә диндә кысанкылык, җәбер, золым юклыгы вә моңар охшаш мең ялган сүзләреннән гыйбарәт булып, боның берлә алар гүя мөфти авызыннан, аның тарафыннан таратылган вә эшнең эч («чын».— *Х. М.*) йөзе хакында бер вәсика (документ.— *Х. М.*) күрсәтмәкче булалар. Дөньяның күзен буяп, авызын ябачаклар, үзләрен акка чыгарачаклар. Шулай итеп, нәтиҗәдә рәхәт эш күрүләре өчен ялган нәшриятка хәзерләнәләр икән.

Риза Хәзрәт, боны укып караганнан соң, һич үзен-сүзен үзгәртмичә, бик суык канлылык берлә генә: «Мине мәгъзүр күрегез (гафу итегез.— *Х. М.*), мин бу кәгазьгә имза ата алмыйм»,— дигән. «Ник? — дигәннәр.— Булмаса, үтереләчәксең!»

Риза Хәзрәт:

— Ялган булганга күрә, монда язганнарыгыз ялган. Ялган сөйләү, ялганны дөресткә чыгару безнең шәригатебездә юк. Ярамый, гөнаһ. Мин ялган сөйли алмыйм. Бу юлда үлемнән дә курыкмыйм. Үтерегез,— дигән вә имзаламаган. Менә ул шундый кеше иде. Мин бонда аның әсәрләре, эшләре, хәяты турында язмыйм. Аларны язуны аны тагын да якыннан белгәннәргә вә бергә-бер юлда эшләшкән иптәшләренә калдырам. Бигрәк тә, сакланган булса, аның үз кулы берлә язып калдырган «Хатирә дәфтәре» халкы өчен бер «тәрбияче» вә «шаһ әсәр» вә пакь рухының тәрҗеманы («чагылышы».— *Х. М.*), аны күрергә теләүчеләрнең көзгесе булачактыр.

Мин бонда тик аның шәхсыятендәге артыклар (сыйфатлар.— *Х. М.*) турында ике генә юл булса да каләм уйнатып, аңар каршы булган бурычымны үтәү берлә бергә хөрмәтемне вә күрсәтәсем, вә, әй зур, олуг, әй кадерле тәрбияче, синең халкың өстенә тетрәгән бик пакь җаныңны таныган мөбарәк кулыңны мәгънән үбәм диясем килде.

## «КАЗАН» ҺӘМ «ТАТАР» — АЕРЫЛМАС ТӨШЕНЧӘЛӘР[1]

Татар, ул кайда гына яшәмәсен, Казанны үзенең рухи башкаласы, Мәккәсе итеп хисаплый. Миллионлаган милләттәшләребезнең гомуми уй-теләкләрен белдереп, чит илләрдә ярты гомерен уздырырга мәҗбүр булган Минһаҗ ага, Казан турында уйланып, заманында болай дигән иде:

Син бит — йөрәк, син бит — якты йолдыз,
Син бит — кыйбла татар халкына.
Күптән инде сине ташласам да,
Һаман йөрәк сиңа ашкына...

Әйе, Казан — татарның кыйбласы, яшәеш символы. В. Маяковскийның мәгълүм сүзләренә охшатып, болай да әйтергә мөмкин: «Без Казан дигәндә — татарны, татар дигәндә — Казанны күзаллыйбыз». Ерак Төркиядә чыккан «Казан» журналының (яки мәҗмугасының) төп өндәмәсе-девизы да нәкъ әнә шул сүзләрнең аерылмас бердәмлегеннән гыйбарәт. Казан, «Казан төреге», «Идел-йорт», «Идел-Урал» һәм, гомумән, татар — журнал өчен еш кына синонимик төшенчәләр. Аның күз уңында — татар халкы, аның тарихы, теле, гореф-гадәте, мәдәнияте, үткәне, хәзергесе, киләчәге һәм дөнья кавемнәре арасында тоткан урыны. Журнал тышлыгындагы мәһабәт Сөембикә манарасы, боларның һәммәсен бергә туплап, үзенә күрә бер символ, татар халкының яшәеш күрсәткечен дә үти.

### I

«Казан» журналының Ватаны — Төркия. Бу мәмләкәт халкы элек-электән татар өчен үз һәм якын. Кан кардәшлеге, дин уртаклыгы, тел якынлыгы, һәр ике халыкның да гарәп-фарсы мәдәниятен кыйбла итүләре һәм башка бик күп факторлар аларны үзара тартып торган[2]. Октябрь инкыйлабына кадәр төрекләр һәм татарлар бер-берләрендәге мәдәни яңалыклар хакында шактый хәбәрдар булганнар. Төркиянең атаклы дипломаты Адилә Аида исеме күпләргә таныш. Ул 1913 елда Казанда туган, Берлин, Париж, Истанбул, Анкара калаларында укыган. Төрекчә, татарча, французча, немецча, итальянча камил белгән бу зат Төркиянең АКШ, Югославия, Голландия, Италиядәге илчесе, БМОдагы вәкиле булып эшли (Казан.— 1976.— № 18.— 12—13 б.). Адилә Аида әтисе Садри Максуди хакындагы истәлекләрендә XIX йөзнең икенче яртысында Төркиянең башка төрки халыклар белән булган багланышларының бүгенге көндәгедән көчлерәк булуын күрсәтә. «Казан китапчыларында,— ди ул,— Истанбулда басылган һәммә… гәҗит һәм… айлык, атналык журналлар була иде… «Тәрҗеман» гәҗите белән бөтен төрки дөньясына мөрәҗәгать иткән… Исмәгыйль Гаспралы бик билгеле шәхес иде» (Казан.—1977.— № 19.— 3—4 б.).

Татарларның төрле сәбәпләр аркасында элек-электән үк Төркиягә күчеп китүләре мәгълүм, һиҗрәтнең зур бер дулкыны — XIX гасыр азакларында, икенчесе —1905—1907 елгы инкыйлабтан соң.

Миңа 1990 елда Хельсинки мәчетенең имамы Әнвәр әфәнде Елдырым белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Ул — 1937 елгы. Себер татары. 1976 елдан бирле Финляндиядә эшли. Әнвәр әфәнде сөйләвенчә, аның әти-әниләре, әби-бабалары бер төркем якташлары белән 1908 елда Себернең Тура төбәгеннән Төркиягә күчеп китәләр һәм Конья шәһәреннән 130 чакрым ераклыктагы бер авылга нигез салалар. Ул авыл хәзер бик зурайган, матди һәм мәдәни яктан бик алга киткән[3]. Үз мәктәпләре, мәчетләре бар. Сөйләшү, гореф-гадәтләре барысы да үзебезчә — татарча икән. Әнвәр әфәнде минем күз алдында Хельсинкидагы фатирыннан Төркиядәге туган авылына (!) шалтыратып, сөйләшеп тә алды.

Октябрь инкыйлабына кадәр Төркиягә күчкән татарларның күпчелеге — хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгеннән, Самара, Сембер өлкәләренең шуңа чиктәш авылларыннан. Төркиядәге «Идел-Урал[4] төрекләре (татарлары.— *Х. М.*) культур вә ярдәмләшмә дәрнәге»нең (җәмгыятенең.— *Х. М.*) хәзерге рәисе Синан Утрау «Шәһри Казан» гәҗитендә басылган чыгышында болай дигән иде: «Минем әби-бабаларым узган гасыр ахырында хәзерге Татарстанның Әби (Сарабиккол) авылыннан күчеп килеп, Искешәһәрдән ерак түгел бер җирдә Коры Көек авылына нигез салганнар. Мин дә шунда туганмын. 12 яшемә чаклы шунда үстем. Әбием 107 яшендә дөнья куйды. Ул: «Мәмләкәтне кайтып күрәсем килә, бүген мәмләкәтне төшемдә күрдем»,— дип, гел Идел-Урал буйларын, туган авылын сагынып сөйли, аның табигатен, халкын, җырларын, мәзәкләрен, риваятьләрен исенә төшерә иде. Без Коры Көектә милли мохиттә тәрбияләндек, әмма башка җирдә туган балаларым инде татарча белми»[5].

Төркиянең Бурса шәһәре тирәсендә дә татар авылы булуы мәгълүм. Тумышы белән хәзерге Ютазы районы Кәрәкәшле авылыннан чыккан Финляндия татары, шагыйрә Гәүһәр апа Туганай да (ул 1911 елгы) Төркиядәге бу авылда бераз яшәп алган. Әйтүләренә караганда, Бурса тирәсендәге бу авылны нигезләүдә татар халкының атаклы улы Габдерәшит Ибраһим да (1850—1944) бик нык ярдәм итә.

Октябрь инкыйлабы болай да таралган татарны янә дөньяга сипте. 20 нче елларда Төркиягә күп кенә татар кешеләренең, аеруча зыялыларыбызның күчеп китүе мәгълүм, һиҗрәтнең соңгы дулкыны 40—50 нче елларга карый. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Алманиядәге, Ерак Шәрыктагы татарларның бер өлеше Төркиягә килеп җирләшә. Надир Дәүләт тикшерүләре күрсәтүенчә, 70 нче елларда Төркиядә 25 меңләп татарның яшәве мәгълүм[6]. Аларның күпчелеге шәһәрләрдә гомер кичерә: Анкарада — 900—1000 тирәсе, Истанбулда — 500—600, Искешәһәрдә — 300—400, Измирда — 20—30 кеше һ. б. (Казан.— 1975.— № 15.—30—31 б.) Шунысы мөһим: Төркиядәге «Казан төрекләре» белеме, мәдәнияте ягыннан шактый югары торалар, күпчелеге берничә тел белә. Алар арасында Йосыф Акчура (1876—11.03.1935), Садри Максуди Арсал (1880—20.02.1957), Габделбарый Баттал-Таймас (8.12.1883—26.04.1969), Әхмәтзәки Вәлиди Тоган (1891—26.07.1970), Абдулкадир Инан (1889—1.10.1976), Акъдәс Нигъмәт Курат (22.04.1903—8.09.1971), Рәшит Рәхмәти Арат (1900—1964), Әхмәт Тимер (1912

елда туа), Хәмит Зөбәер Кошай (1897—1984) һәм дөнья фәненә мәгълүм башка затларның булуы да күп нәрсә хакында сөйли. Безнең илебез тарихын яхшы белгән бер Төркия кешесе үзара әңгәмә вакытында болай дигән иде: «Соңгырак дәвер Русия мәдәниятен, фәнен үстерүгә яһүдләр гаять зур өлеш кертте. Сезнең казанлылар да (ягъни Идел-йорттан күчеп килүчеләр дә.— *Х. М.*) Төркия тарихында шундый рольне башкардылар».

Үзләренең рухи, аеруча мәдәни ихтыяҗларын күздә тотып, Төркиядәге татарларның төрле оешмалар төзүе, гәҗит-журналлар, китаплар чыгаруы мәгълүм. Профессор Рәшит Рәхмәти Арат «Казан төрекләрендә периодик матбугат» исемле мәкаләсеннән (Казан.—1975.— № 16.— 7—14 б.) инде Октябрь инкыйлабына кадәр үк Төркиядә казанлылар тарафыннан «Мизан» гәҗите (1908 ел. Морад бей), «Тәгърифи мөслимин» мәҗмугасы (1910 ел. Бу атналык әдәби журналны Рәшит Ибраһим һ. б. нәшер итә.), «Ислам» («Ислам дөньясы», 1914 ел. Айга ике чыга. Әдәби-дини басма. Н. Сабит) һәм башка басмаларның да нәшер ителүе билгеле. 1910 еллардан бирле чыгып килүче мәшһүр «Төрек йорды» журналын оештыручыларның да берсе татар кешесе — Йосыф Акчура. Мәҗмугада татар авторлары актив катнаша, татар теле, мәдәнияте, тарихы мул яктыртыла. Менә минем алда журналның 1341 (1923) елгы 7 нче саны. Анда без Акчура углы Йосыф, Садри Максуди, Закир Кадыйри («Идел-Урал буендагы төрек ләһҗәләре хакында бер тәхлил», ягъни тикшерү) һәм кайбер башка таныш исемнәрнең мәкаләләре белән танышабыз. Дөнья тюркологлары тарафыннан югары бәяләнүче айлык «Төрек культуры» журналының да күп саннары татар галиме Әхмәт Тимер мөхәррирлегендә чыккан.

50—60 нчы елларда Төркиядә татар милли тормышы янә активлашып китә. Төп оеткыны, әлбәттә, Гаяз Исхакый һәм аның Ляһстаннан, Алманиядән, Ерак Шәрыктан күчеп килгән көрәштәшләре сала. 1955 елда Истанбулда «Идел-Урал төрекләренең культур вә ярдәмләшмә дәрнәге (җәмгыяте.— *Х. М.*)» төзелә. Шул ук калада 1957—1964 елларда «Сөембикә культур җәмгыяте»нең эшләве мәгълүм. Аны оештыруда һәм җитәкләүдә милләтпәрвәр, табиб, шагыйрь һәм галим Әхмәт Ләбиб Каран (5.01.1887—30.07.1967) аеруча зур көч куя.

1963 елда Истанбулда «Тукай клубы» эшли башлый. Аны бераздан «Казан төрекләре культур вә ярдәмләшмә дәрнәге» дип йөртә башлыйлар. Ике елдан соң, ягъни 1965 елның 21 октябрендә, шушындый ук оешма Анкарада корыла. Аларның максаты, оештыручыларның үз сүзләре белән әйткәндә, түбәндәгедән гыйбарәт: «Казан төрекләренең культур эшчәнлеген таныту, бу юнәлештә басма эшләре белән шөгыльләнү, милли фольклорны, сәнгатьне, музыканы пропагандалау һәм мохтаҗларга матди һәм мәгънәви ярдәм күрсәтү (Казан.— 1971.— № 3— 61 б.), милли барлыкны яшәтү».

Чыннан да, бу «культур җәмгыять»ләре милли кичәләр, мәҗлесләр, түгәрәкләр һәм башка күптөрле чаралар уздыралар, милләтне, аның телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен саклауга, өйрәнүгә, аларны төрекләргә дә танытуга үзләреннән зур өлеш кертәләр. Бу эшләрне оештыруда Сәйдә Арсланбәк, Рифат Мөхтәсип, Надир Дәүләт, Наилә Бинарк, Фәрит Бичури, Рәшидә Дәвеш һәм башка күп санлы милләттәшләребез актив катнаша.

50—60 нчы еллардагы «культур оешмалары»ның мөһим бер тармагы — басма сүз. Шушы чорда татар халкының тарихына, мәдәниятенә, теленә, күренекле улларына багышланган күп санлы мәкаләләр, берничә китап дөнья күрә. Мәсәлән: *Гали Акыш*. Идел-Урал мәсьәләсе вә совет империализмы.— Анкара: «Ай-йолдыз» матбагасы, 1963.— 47 б. (төрек телендә); *Г. Баттал-Таймас*. 1) Ризаэддин Фәхреддин углы.— Истанбул, 1958.— 62 б. (төрек телендә),
2) Муса Җарулла Биги.— Истанбул, 1958.— 62 б. (төрек телендә),
3) Алимҗан Баруди.— Истанбул, 1958.— 79 б. (төрек телендә); 4) Ике Максуди.— Истанбул, 1959 (төрек телендә.); Милли мөҗәһит вә милли әдип Аяз Исхакый.— Истанбул: Османбәй матбагасы, 1955.— 47 б. (төрек телендә); *Исфәндияр Ишгай*. Җәһәннәмнән котылганнар.— Анкара: Ени Дежен матбагасы, 1956.— 65 б. (латин язуында, татар телендә шигырьләр җыентыгы) һ. б. «Сөембикә культур җәмгыяте» җитәкчесе Ә. Ләбиб Каран үзе татар телендә берничә китап чыгара: Шиһабетдин Мәрҗани. Тормышы һәм әсәрләре.— «Таң» матбагасы, 1960.— 79 б.; Татарларның «төпчыгышы» (этногенезы.— *Х. М.*).— Истанбул: Әхмәт Сәйт матбагасы, 1962.— 96 б.; Яшь вакытым җырлары.— Истанбул, 1959.— 96 б.; Төшенчәмнең җырлары.— Истанбул: Әхмәт Сәйт матбагасы, 1959.— 96 б. һ. б. Шунысы гыйбрәтле: һәм И. Ишгай, һәм Ә. Ләбиб Каран шигырьләре көчле милли рух белән сугарылган. Менә И. Ишгайның «Яшүсмер» шигыреннән бер строфа:

Кайда гына булма, аерылма син
Үз динеңдән, милли юлыңдан.
Милли байрагыңны югары тот,
Һич төшермә аны кулыңдан.

*(Казан.— 1975.— № 15.— 52—53 б.)*

Әхмәт Ләбиб Каран (ул Сарман төбәгендәге яисә Башкортстандагы Каран авылларының берсе белән бәйләнешле булса кирәк)[7] гаҗәеп бай биографияле зат: туган авылы, Петербург гаскәри уку йорты курсанты, Балкан сугышы, Истанбул университетының медицина факультеты студенты, гаскәри табиб, Алмания, Төркия һ. б. Ул Гаяз Исхакый белән берлектә «Яңа милли юл»да да эшли. Аның туенда Йосыф Акчура белән Гаяз Исхакый шаһит буларак катнашалар. Ләбиб Каран аеруча Сөембикәне иляһилаштыра, аның хакында китап та яза. Үзе исән вакытта ук үзенең кабер ташына Сөембикә манарасын ясатып куя. Менә аның Гаяз Исхакыйның 50 еллыгына багышлап 1949 елның 20 апрелендә язган бер шигыре:

Гаяз Исхакый — татарның бер олуг инсаныдыр,
Татар әдәбиятының таҗлы бер хаканыдыр;

Аның ак башы — платиндан үрелгән таҗыдыр,
Аны күреп кулын үпкәнләр гүя кем хаҗидыр.

50 гә кадәр әсәр язды милләтнең файдасына,
Бу бер җиңел эшмедер? — Кулга каләм ал да сына!

Бу әсәрләр ярдәм итте аның зураймасына,
Сәяси тормышы сәбәп булды хурланмасына.

Ул беренче гәҗит, журнал чыгарып та тартышты,
Илне изгән дошман белән аяусызга атышты.

Татар тормышын күтәрү өчен ул күп көрәште,
Татарларның ирке өчен урыс белән торышты.

Укучы гафу итсен, бераз төп темамнан читкәрәк кереп киттем. Төркиядәге «культур җәмгыять»ләре аеруча Тукай иҗатын өйрәнүне, пропагандалауны күз уңында тоталар. 1965 елда Анкарада «Тукай бәйрәме» исемле бер брошюра дөнья күрә. Төзүчеләре: Гали Акыш, Сәйдә Арсланбәк, Наилә Бинарк. Анда Наилә Бинаркның «Тукайның вафаты» исемле пьесасы да бар. 1965—1968 елларда «Тукай бюллетене» исемле кечкенә генә мәҗмуга чыгып килә. Аның 24 саны бар. Биредә Тукайның шигырьләре, аның хакындагы материаллар, шагыйрьгә мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләр дә урын алган. «Тукай бюллетене»ндә Төркиядәге татарларның мәдәни тормышы турында да кайбер мәгълүматлар бар. Әмма читтәге милләттәшләребезнең рухи ихтыяҗларын мондый кечек бюллетень, анда-санда чыккан китаплар гына канәгатьләндерә алмый. Махсус журнал чыгару көн тәртибенә бөтен зарурияты белән куела. Шулай итеп, 1970 елда «Казан» мәҗмугасының беренче саны дөнья күрә.

## II

«Казан» — латин хәрефләре белән төрек телендә чыккан журнал. Әмма анда аерым материаллар, бигрәк тә әдәби әсәрләр, фольклор үрнәкләре әүвәл татарча, аннан төрекчәгә тәрҗемә итеп биреләләр. Мәҗмуга үзенең форматы, күләме белән «Мәгариф» журналына якын: юка тышлыкта, форматы 17 ә 24 см тирәсе, битләр саны — 64. Журналның 1972 елгы 7—8 нче саннары бер төпләмдә чыккан (120 бит).

Мәҗмуга өч айга бер мәртәбә нәшер кылына. Саннары һәр ел өчен аерым-аерым түгел, ә үтәли. Журнал 1979 елда, күрәсең, чыкмыйча торган. Безнең мәгълүматлар буенча, соңгы саны (23) 1980 елда дөнья күрә. Димәк, унъеллык мәҗмуга саннарының гомуми күләме — 1426 бит. Бу — шактый зур сан! Журналның идарәсе, хезмәткәрләре, нигездә, Истанбулда эшли, ә «Казан» үзе Анкараның «Ай-йолдыз» матбагасында нәшер ителә.

Мәҗмуганың җаваплы «сахибе» (хуҗасы) әүвәл Рифат Мөхтәсип, ә бераздан доктор Мәхмүт Аликәй була. «Язу эшләре мөдире» вазифасын башта Надир Дәүләт, ә ахырга таба Рәшит Агый башкара. Журналның сәркатибе, нигездә, Сәйдә Арсланбәк була. Ә инде «Казан»ның редколлегия составы ун ел дәвамында үзгәрешсез диярлек кала: Әхмәт Тимер, Рифат Мөхтәсип, Мәхмүт Таһир, Надир Дәүләт. Бары тик ахырга таба гына боларга Әмрулла Агыйв һәм Наилә Бинарк өстәлә. Шунысын да әйтик: журналны чыгаручы бу фидакяр затлар — Казан, Сөембикә, Тукай «культур җәмгыять»ләренең актив әгъзалары, татар халкының Төркиядәге милләтпәрвәрләре.

Октябрьдән соң чит мәмләкәтләрдә чыккан татарча гәҗит-журналлар, китаплар — Гаяз Исхакый сүзләре белән әйткәндә, «милләтнең үз балалары». Чөнки алар бары тик халкыбызның үз тырышлыгы, матди вә мәгънәви ярдәме белән генә оештырыла, дөнья күрә алган. Рәсми хакимият оешмалары аларга бер тиен дә акча бирмәгән. Куаныч ки, мондый хәлдә милләтебезнең аерым байлары чын егетләрчә эш иткән. Хөсәеневләр һәм Рәмиевләрнең изге традицияләрен дәвам итүче мондый затлар арасында мәшһүр Әхмәт Вәли Мәңгәр дә бар (8.12.1891—10.11.1978). Ул Кызылъяр (Петропавловск) каласында хәлле кеше гаиләсендә унөченче бала булып дөньяга килә. Әтисе — Казан артындагы Мәңгәр авылыннан, әнисе — Сабабаштан. Әхмәт татар мәдрәсәсендә, урыс гимназиясендә укый. Яшьтән үк сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый. Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә була. Ерак Шәрыкта зур ширкәт тота («Мәңгәрләр ширкәте»). 1925 елда Бөре кызы Гайшә белән гаилә кора, бераздан Алманиядә эшли. 1938 елдан — Истанбулда. Ул — Төркия, Алмания, Япуния һәм кайбер башка илләрдәге зур гына фабрика-заводларның, ширкәтләрнең тәҗрибәле эшмәкәре, хуҗасы. Казан урамнарында хәзер йөри торган «Мерседес-Бенц» автобуслары күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итәдер. Ә бит бу мәһабәт машиналарны эшли торган Алмания-Төркия уртак фирмасының башында заманында Әхмәт Вәли Мәңгәр була. Берничә чит тел белгән бу зат татар теленә, сәнгатенә гашыйк булып яши. Гомеренең ахыргы көннәрендә дә матур итеп саф татарча сөйләшүе белән кешеләрне таң калдыра. Ул Кызылъярда яшәгән вакытта ук яшьләр кичәләрен оештырып йөри, спектакль, концертларда катнаша. Бу традицияне чит мәмләкәтләрдә яшәгәндә дә дәвам итә. Үз хисабына студентлар укыта, китаплар, дәреслекләр чыгара. 1935—1945 елларда Мукденда чыккан «Милли Байрак» гәҗитенең төп химаячесе (спонсоры) була. Төркиядәге татар «культур җәмгыять»ләренә ул бик нык ярдәм күрсәтә. «Казан» журналы да аның инициативасы һәм матди ярдәме белән корыла, яши. Мәҗмуганың ябылуы да, нигездә, бу олуг шәхеснең вафаты белән бәйле.

Дөньяны күп гизгән Әхмәт Вәли Мәңгәр күп кенә татар зыялылары белән таныш булган, аралашкан. Алар арасында Габдулла Карый, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина, Һади Атласи, Габдерәшит Казый, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Фатих Әмирхан, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый һәм башка мәшһүр кешеләр бар (1972.— № 6.— 2 б.). Ул төрле кичәләрдә, конференцияләрдә татар тарихы, мәдәнияте, халкыбызның күренекле уллары хакында чыгышлар ясый, истәлекләр сөйли, милли тәрбия эшендә актив катнаша.

Әхмәт Вәли Мәңгәр — «Казан» журналының матди химаячесе генә түгел, ә төп авторларыннан берсе дә. Аның мәкаләләре факт-күзәтүләргә байлыгы, милләт тарихына итагатьле мөнәсәбәте белән сыйфатланалар. Аның

«Имтиязлы (дәрәҗәле, өстенлекле, эшмәкәр.— *Х. М.*) бохарлылар» дигән язмасы (1971.— № 4.— 2—6 б.) — шундыйлардан. Биредә сүз, нигездә, XIX йөз—XX гасыр башы татар сәүдәгәрләренең, җөмләдән Вәисевләрнең, Төркестан белән мө-
нәсәбәтләре, андагы эшчәнлекләре хакында бара. Ташкентта 1828 елда ук Вәисевләр зур сәүдә йорты ачалар. Татар сәүдәгәрләренең кибетләре, фабрикалары XIX йөзнең икенче яртысында бөтен Төркестанга мәшһүр була. Мәкалә авторы 1911 елда, Ташкентка килгәч, үз милләттәшләренең «һотель»ләренә (кунакханәләренә), кибетләренә «хәйран калуын» әйтә. Вәисевләр Төркестанда «мәдәни-иҗтимагый өлкәдә дә күп эшләр» башкаралар. «Ысулы җәдит» мәктәпләре ачалар. 1917 елда аларның «Олуг Төркестан» исемле көндәлек гәҗит чыгара башлаулары да мәгълүм. Аның
баш мөхәррире итеп «Вакыт» гәҗитеннән Кәбир Бәкер чакы-
рыла (6 б.).

Әхмәт Вәли Мәңгәрнең икенче бер мәкаләсе Буби мәдрәсәсенең тарихын, мәшһүр педагог Габдулла Буби эшчәнлеген яктыртуга багышланган. Мәгариф, мәдәният мәсьәләләрен автор иҗтимагый-сәяси тормыш белән тыгыз мөнәсәбәттә карый.

1921—1922 еллардагы ачлык — татар тарихындагы иң фаҗигале сәхифәләрнең берсе. Заманында ул Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан һәм кайбер башка каләм әһелләренең игътибарын үзенә тарткан иде. Әмма бу башлангыч безнең матур һәм гыйльми әдәбиятта, ничектер, сүнеп калды һәм, мөгаен, шуңа күрәдер бу кот-очкыч афәт хакында укучыларыбызның күзаллавы әле хәзер дә бик тонык. Ачлыктан интегүчеләргә америкалылар гына түгел, Ерак Шәрыкта, җөмләдән Харбинда яшәүче милләттәшләребез дә ярдәм иткән икән[9]. Әхмәт Вәли Мәңгәр (Казан.— 1976.— № 17.— 18—21 б.) язуынча, Харбиннан Татарстанга
100 мең пот ашлык җибәрәләр (барып җитте микән?). Озата барган кешене Совет хакимияте органнары «15 елга хибескә ябалар» («Менә сиңа рәхмәт».). Әхмәт Вәли Мәңгәрнең татар мәдәниятенең аерым вәкилләре хакындагы фикерләре, Мәкәрҗә ярминкәсе хатирәләре һәм башка күп язмалары да кызыклы гына.

## III

«Казан»ның төп спонсоры Әхмәт Вәли Мәңгәр кебек, журнал-
ның үз хезмәткәрләре һәм редколлегия әгъзалары да мәҗмуга битләрендә төрле темаларга еш чыгыш ясыйлар. Мәхмүт Таһир (1922—26.12.1991, Анкара) Харбин каласында туган, Төркиягә күчеп килгәнче, Ерак Шәрыкта[10] яшәгән, укыган. Шуңа күрә аның мәкаләләренең күпчелеге Кытайда, Кореяда, Япуниядә яшәгән милләттәш-ләребезнең тарихын, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен яктыртуга багышланган. Белгечлеге белән инженер кешенең тарихыбызга, мәдәниятебезгә мөнәсәбәтле гаять күп санлы факт-мәгълүматларны туплап, укучыларга җиткереп баруы — сирәк очрый торган күренеш. «Казан театры хакында» исемле мәкаләсендә (1975.— № 14.— 25—30 б.) ул, мәсәлән, СССРдан читтә язылган татарча драма әсәрләренең тулы бер исемлеген бирә, анда Гаяз Исхакый (1878—1954), Сания Гыйффәт (1899—12.04.1957), Хөсәен Габдүш (5.01.1901—14.04.1944) кебек билгеле исемнәр белән бергә, безгә бөтенләй яисә тиешенчә таныш булмаган авторларның да әсәрләре бар: *Әсәт Әхтәм*. Язмыш. 3 пәрдәдә; *Исхак Арслан*. 1) Илгә кайткач. 1 пәрдәлек пьеса; 2) Газизәкәй балдыз. 3 пәрдәлек оперетта; *Мозаффар Кайа*. Сөембикә. 3 пәрдәлек трагедия; *Шаһвәли Келәүле (Илдәр)*. Асламчылар. 1 пәрдәдә һ. б. Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Мәхмүт ага Таһирның «Гарәп хәрефләре белән басылган татар нәшриятының библиографиясе» исемле зур күләмле кулъязма хезмәте (Анкара, 1976. Без аның Хельсинки университеты китапханәсендәге күчермәсе белән таныштык.) үзенең басылуын күптәннән көтеп ята. Анда чит илләрдә саклanучы татарча китаплар, гәҗит-журналлар хакында тиешле библиографик белешмәләр бирелә.

Профессор Әхмәт Тимер[11] мәкаләләренең күпчелеге төрки-татар теленең, әдәбиятының тарихын яктыртуга багышланган. Менә аның «Тукай дәвере Казан шагыйрьләре» исемле язмасы (1971.— № 63.—13—17 б.). Биредә Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Зариф Бәшири, Н. Думави, М. Укмасый, Зыя Ярмәки, Әхнәф Таңгатар иҗатларына хас төп сыйфатлар күрсәтелә. Риза Казыйга кушылып, ул Тукайны Мәгарри белән чагыштыра. Дәрдемәндне автор «куәтле шагыйрь, фикер иясе» дип атый. Бу әдип аерым шәхесне түгел, милләт, Ватан, кешелек хакында җырлады. Нәҗип Думавины Әхмәт Тимер Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиевтән соң «иң куәтле шагыйрьләребездәндер» ди. Ул фикер ягыннан Дәрдемәндкә, өслүп җәһәтеннән Тукайга якын. Әхнәф Таңгатар исә романтик вә өметсезлек юлында лирик шигырьләр яза. Ул «бөек бер кабилияткә ия», әмма халык тарафыннан бу шагыйрь танылмаган. «Казан вә Шимали төрек (төрки.— *Х. М.*) әдәбиятының иске кайнаклары (чыганаклары.— *Х. М.*)» исемле мәкаләсендә Әхмәт Тимер XIX йөзгә кадәрге (1971.— № 4.— 10—15 б.) төрки-татар әдәбиятына күзәтү ясый, ул чордагы төп истәлекләр, авторлар хакында кыскача мәгълүматлар бирә. Бу язма бай библиографик материаллар белән тәэмин ителгән.

Наилә Бинарк күбрәк татарның мәшһүр кешеләре турында
яза. «Гомәр Йосыф Акчура» исемле мәкаләсендә (1972.— № 10.— 32—40 б.) ул бай факт-мәгълүматлар ярдәмендә бу олуг затның тәрҗемәи хәлен һәм иҗтимагый эшчәнлеген шактый тулы яктыртуга ирешә. Шушындый ук сыйфат аның Сөембикә (1974.— № 11.— 27—32 б.), Муса Акъегетзадә (1975.— № 15.— 54—55 б.), Абдулкадыйр Инан (1971.— № 4.— 20—25 б.), Сания Гыйффәт (1977.— № 20.— 24—29 б.), Муса Ярулла Биги (6.01.1875.—25.10.1949; 1975.— № 16.— 27—29 б.) һәм башка мәкаләләре өчен дә хас.

Наилә Бинаркның бер язмасы Кемал Локман (1899—1976) дигән кеше турында (1976.— № 8.— 51—56 б.). Баксаң, бу зат та татар икән. Әтисе Шәрәфетдин — Оренбург имамы. Локман Россиядә, Истанбулда белем ала, Француз һәм Гренобль политехник институтларында, Страсбургта укый, француз, инглиз, гарәп, төрек һәм кайбер башка телләрне камил белә. Румыниядә эшли. 1929 елдан — Төркиядә. 1957 елда «Төркия җөмһүриятенең нефть

компаниясе» рәисе була. 1963 елдан Төркиянең энергетика һәм табигый байлыклар министры. Күп кенә җәмгыятьләр әгъзасы, фәнни китаплар авторы.

Наилә Бинарк — дистәдән артык сәхнә әсәрләре язган автор да: «Тукайның хәяты», «Насреддин Хуҗа», «Ышанмау бәласе», «Сатучылар», «Су анасы» һ. б. Иҗат эше белән шөгыльләнү аның фольклор, сәнгать турындагы мәкаләләрендә дә сизелеп тора. Әгәр дә Мәхмүт Таһир Ерак Шәрык татарларының тормышын яктыртса, Наилә Бинарк Финляндиядәге милләттәшләребез хакында кызыклы гына материаллар биреп бара. Бу аңлашыла да. Чөнки ул 70 нче елларда Хельсинкида балалар укыту белән шөгыльләнгән, берничә уку-укыту ярдәмлеге (Мәкальләр.— 1971) төзегән, күптөрле кичәләр оештырган. Наилә Бинаркның Финляндиядәге элеккеге укучылары аны хәзер дә хөрмәт белән искә алалар.

1992 елның ямьле июнь айларында Казанда Халыкара тюркологик конференция һәм Бөтендөнья татар конгрессы узды. Аларда дөньяның төрле почмакларыннан, тугандаш җөмһүриятләрдән мөхтәрәм кунаклар, олуг галимнәр катнашты, күп санлы доклад-чыгышлар тыңланды. Конференция һәм конгресс мөнбәреннән яңгыраган нотыкларның иң төпле һәм иң көчлеләреннән берсе Истанбул университеты профессоры Надир Дәүләт чыгышы булды дисәм, шәт, ялгышмамдыр. Берничә чит телне белгән урта яшьләрдәге бу зыялы милләттәшебез үзенең һәм татарча матур сөйләме, һәм тирән фикерләре белән залны җәлеп итте, һәм ахырда аңа озаклап кул чаптылар. Шунда мин Надир Дәүләтнең «Казан» журналындагы гыйльми-теоретик һәм гамәли яктан гаять кызыклы һәм тирән эчтәлеккә ия булган мәкаләләрен искә төшереп утырдым. Димәк, галимнең бүгенге үсеше, уңышлары һич тә очраклы күренеш түгел, ә 70 нче еллардан, «Казан» журналыннан ук килә торган эзләнү һәм уйлануларының зарури нәтиҗәсе.

Надир Дәүләт, Гаяз Исхакый традицияләрен дәвам итеп, үз мәкаләләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләләрен куя, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында бербөтен процесс рәвешендә уйлана, тарих, тел, әдәбият, сәнгать, фәлсәфә, сәясәт кебек күренешләрне ул шул бербөтен милләтнең аерым атрибутлары рәвешендә тикшерә. Шуңа күрә аның мәкаләләре өчен масштаблылык, комплекслылык хас.

«Казан төрекләре вә Габдулла Тукай» исемле язмасында (1971.— № 3.— 6—12 б.) Надир Дәүләт бөек шагыйрь иҗатын милләт язмышы белән тыгыз мөнәсәбәттә карый. «Тукай,— ди ул,—татарларның милли рухы, «милләтнең баш таҗы». Сөембикә манарасы казанлыларның бәйсезлек символы булса, Тукай татар халкының «бер әдәби символыдыр». Шунысы мөһим: Надир Дәүләт Тукай иҗатына чит ил галимнәренең дә нинди мөнәсәбәттә торуларын ачыкларга омтыла. Баксаң, Тукай үлгәч, төрекнең мәшһүр галиме Фуад Күприлезадә «Төрек йорды» журналында (1913.— 497—515 б.) махсус мәкалә язып бастырган икән. Анда ул Тукайны Ислам дөньясының зур шагыйре дип атый. «Казан»ның тәүге саны Надир Дәүләт мәкаләсе белән ачылу да күп нәрсә хакында сөйли. Анда татар тарихына кыскача экскурс ясала, халкыбызның саны, СССРның төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдәге таралышы бәян ителә. Алга таба чит мәмләкәтләрдә чыккан гәҗит-журналлар, мәдәни җәмгыятьләр хакында мәгълүматлар бирелә. Шулай итеп, татар турында гомуми күзаллау тудырыла һәм шул нигездә журнал алдында торган максат-бурычлар атала.

Мәҗмугада, аның редколлегия әгъзаларыннан һәм үз хезмәткәрләреннән тыш, Сәгадәт Чагатай, Хәмит Зөбәер Кошай һәм башка авторлар катнаша. Профессор Сәгадәт Чагатайның берничә материалы әтисе хакында: «Атам Гаяз Исхакыйның соңгы көннәре» (1974.— № 12.— 18—23 б.), «Гаяз Исхакый хакында хатирәләр» (1974.— № 12.— 24—29 б.) «Казан» журналының 1972 ел 9 нчы саны Каюм Насыйриның үлеменә 70 ел тулуга багышланган. Мәҗмуга Сәгадәт Чагатайның «Габделкаюм Насыйри вә әсәрләре» исемле күләмле мәкаләсе белән ачыла (3—17 б.). Анда бөек мәгърифәтченең тормышына һәм иҗатына шактый тулы күзәтү ясала, ахырда китапларының исемлеге тәкъдим ителә.

Мәгълүм булганча, 1974 елда Лондонда милләттәшебез профессор Т. Дәүләтшинның «Советский Татарстан: теория и практика ленинской национальной политики» дип исемләнгән монографиясе дөнья күрә. Бу китап кайбер Казан галимнәре тарафыннан «советка каршы» хезмәт дип тискәре бәяләнде. Сәгадәт Чагатай исә, беренчеләрдән булып, Т. Дәүләтшин монографиясенә төпле, уңай рецензия язды һәм авторның бу китабын югары бәяләде (1976.— № 18.— 8—11 б.)[12]. Тарих галимнең хаклыгын күрсәтте: Т. Дәүләтшин язганнар хәзер киң татар җәмәгатьчелегенең зиһен хәзинәсенә әйләнә бара.

Чит илләрдә яшәүче күп кенә татарлар Европаның һәм Азиянең мәшһүр уку йортларында белем алалар. Мәсәлән, 20—30 нчы елларда дистәдән артык татар егетләре һәм кызларының Берлин университетының медицина факультетында укуы мәгълүм: Рабига Ибраһим, Абидулла Бадай, Абдулла Байчура, Абдулла Сөнәй, Ибраһим Вәли, Хәерниса Исмаил, Зөһрә Кошай (1931 елда фаҗигале төстә үлә), Шәмсия Әшрәф, Сәхипҗамал Солтан һ. б. Боларның күпчелеге Ерак Шәрыктан, нигездә, Харбиннан 1922 елда Алманиягә килгән була. Шушы ук чорда Рәшит Рәхмәти дә Берлин университетының Шәрык шөгъбәсендә укый. Татар яшьләре һәм кызлары, медицина факультетын уңышлы тәгәлләп, Ерак Шәрыкта, Алманиядә, Төркиядә, АКШта уңышлы эшлиләр, араларыннан мәшһүр докторлар, профессорлар чыга. Сәгадәт Чагатай үзенең ике мәкаләсен шуларга — үзенең яшьлек дусларына багышлый: «Доктор Сәхипҗамал Солтан» (10.03.1901—27.05.1975)[13], «Профессор, медицина докторы Ибраһим Вәли Одар»[14] (18.05.1899 — 25.06.1975) —1975.— № 16.— 42—48, 49—50 б.

Журналда Хәмит Зөбәер Кошайның Йосыф Акчура һәм Садри Максуди хакында кызыклы гына мәкаләләре бар (1976.— № 18.— 2—7 б.; 1977.— № 19.— 15—22 б.).

Мәҗмугадагы кайбер материалларның, аеруча хәбәр-белешмәләрнең, авторлары күрсәтелмәгән. Бер өлеш мәкаләләрнең теге яки бу хезмәттән файдаланып язуы искәртелә. Мәсәлән, шагыйрь Исфәндияр Ишгайның (Чынбайның) «Сәйф Сараиның яңа табылган әсәрләре» мәкаләсе (1978.— № 22.— 6—10 б.), нигездә, «Казан утлары»ндагы безнең публикациягә (1972.— № 6.— 129—139 б.) таянып язылган (анда сүз, нигездә, «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны хакында бара). Исфәндияр Ишгай (1908—1992) — Себер, Урал төбәкләре белән бәйләнешле шәхес[15]. Мәкаләдә ул үзенең Оренбургта тел вә әдәбият факультетында укуын, Чиләбе якларында булуын телгә

ала. Бу мәгълүматларны күренекле әдәбиятчы Шакир ага Абилов та раслый. Баксаң, алар Оренбургта студент булып, шигырьләр язып, бергәләп әдәби кичәләр оештырып йөргәннәр икән.

**IV**

«Казан» журналы өчен вакыт вә урын киңлеге, тематик төрлелек хас. Анда без үткән һәм бүген, тел вә мәдәният, сәясәт вә икътисад, Россия һәм Төркия, һуннар һәм европалылар һәм башка бик күп мәсьәләләр белән очрашабыз. Әмма аларның һәммәсенең үзәгендә — халкыбыз язмышы, аның эчке һәм тышкы бәйләнешләре. Бердәм татар проблемасы журналдагы төрлелеккә эчке бөтенлек бирә. Һәм бу үз чиратында мәҗмуга саннарының барлык тупламын бөтен бер система, ә аерым номерларны шуның чагыштырмача мөстәкыйль өлешләре итеп карарга мөмкинлек тудыра.

Журналда халкыбызның этник, иҗтимагый, сәяси, мәдәни тарихы төп урынны алып тора. Ул гомуми күзәтү планында да, аерым дәверләргә нисбәтән дә (гомумтөрки, Хәзәр, Болгар патшалыклары, Алтын Урда дәвере, Казан, Хаҗитархан, Кырым, Нугай, Себер ханлыклары чоры, колониаль изелү дәвере, Совет хакимияте еллары һ. б.), этник һәм социаль яктан төркемләп тә (болгарлар, мишәрләр, типтәрләр, «бохарлылар», гаскәриләр, шәкертләр һ. б.), аерым проблемалар (урыслаштыру, татар-урыс мөнәсәбәтләре, җәдитчелек, милли азатлык хәрәкәте һ. б.) аркылы да яктыртыла. Чит мәмләкәтләрдәге (Кытай, Япуния, Финляндия, Алмания һ. б.) татарларның тормышын чагылдыру да шактый урынны алып тора. Ул, нигездә, төбәкләп башкарыла.

Журналның зур һәм даими бер рубрикасын мөхтәрәм милләттәшләребез, күренекле татар әдипләре һәм галимнәре хакындагы мәкаләләр, очерклар, белешмәләр тәшкил итә. Алар еш кына туу, үлү, түгәрәк даталар тулу, юбилейлар уңае белән биреп барыла. Мәсәлән: Ризаэддин бине Фәхреддин (1859—1936. Үлеменә — 35 ел. 1972.— № 4.— 39—43 б.), Һади Атласи (1875—1940[16]. Тууына — 100 ел. 1975.— № 16.— 1—6 б.), Гани бай (1839—1902. Вафатына — 70 ел. 1972.— № 7.— 8—63 б.) һ. б. Журналда бу төр шәхесләрнең саны дүрт дистәдән артып китә. Алар арасында һәм илдәге, һәм чит мәмләкәтләрдәге татар вәкилләре бар. Аерым күренекле шәхесләргә журнал махсус саннарын да багышлаган. Аларда бу затларның тәрҗемәи хәлләре, эшчәнлекләре бәян ителә. Хезмәтләреннән, иҗатларыннан үрнәкләр дә бар. Хатирәләр дә очрый. Мәҗмуганың 6 нчы (1972) һәм 23 нче (1980) саннары, мәсәлән, Әхмәт Вәли Мәңгәргә багышланган. Садри Максудига журнал берничә мәртәбә урын биргән. Ә инде 19 нчы (1977) саны махсус аңа багышлап чыгарылган.

Шунысы мөһим: аерым шәхесләр турындагы материаллар биографик, библиографик мәгълүматларга шактый бай. Бу хәл журналның белешмә (справочник) буларак та әһәмиятен арттыра. Күрсәтмәлелек ягыннан да «Казан» игътибарга лаек. Анда әдип-галимнәрнең, мөхтәрәм затларның сурәтләре, төрле фото-иллюстратив материаллар бик күп. Аларның шактый өлеше безнең укучыларга бөтенләй диярлек таныш түгел.

«Казан» — иҗтимагый, тарихи, сәяси, мәдәни журнал гына түгел, ә әдәби мәҗмуга да. Аның һәр санында илдә һәм читтә яшәгән татар әдипләре хакында материаллар, аларның иҗатларыннан үрнәкләр биреп барыла. Мәсәлән, 4 нче (1972) санда үлеменә 50 ел тулу уңае белән Дәрдемәнд хакында Надир Дәүләт тарафыннан язылган матур гына мәкалә бар (32—38 б.). Анда бу шагыйрьнең «өслүб вә вәзен техникасының остазы», «татар классикларының иң көчлесе» булуы хакында әйтелә. «Кораб», «Шагыйрьгә» һәм кайбер башка шигырьләре укучыларга татар һәм төрек телләрендә тәкъдим ителә.

М. Гафури («Хан мәчете», «Ачлык пәйгамбәре»), С. Рәмиев («Таң вакыты»), Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш хакында да шул рәвештә бирелгән материаллар бар. Гаяз Исхакыйга, нигездә, журналның ике саны багышланган: 12 нче сан (1974) үлеменә — 20 ел, 22 нче сан (1978) — тууына 100 ел тулу уңае белән. Аларда әдипнең тормышына һәм иҗтимагый, әдәби эшчәнлегенә кагылышлы мәкаләләр, истәлекләр бар. «Тәүбә кылган хатын» хикәясе дә (№ 12.— 29—44 б.) тәкъдим ителгән.

Журналда әдипләрдән иң зур урын, әлбәттә, Г. Тукайга бирелгән, һәр санда диярлек, бигрәк тә шагыйрьнең туу-үлү айларында Тукайның шигырьләре («Туган тел», «Шүрәле», «Таз», «Теләнче», «Нәсыйхәт», «Су анасы» һ. б.) басыла, аның хакында язылган төрле материаллар урнаштырыла. Мәсәлән, мәҗмуганың 20 нче санында (1977) Наилә Бинаркның Тукай шигырьләренә нигезләнеп төзелгән «Мәдрәсәдә улан бер малай» (төрекчә) исемле сценарие (42—56 б.) бар. Ул рәсемнәр, (ноталы) музыка белән тәэмин ителгән. Журналда Минһаҗның, Шаһвәли Илдәрнең («Ил йолдызы», «Тукай эзеннән»), Солтанның (Әхмәт Виргазның «Шагыйрьгә») һәм кайбер башка каләм әһелләренең Тукайга багышланган, аны сөеп, хөрмәтләп язган шигырьләре бар. Менә шулардан аерым юллар:

...Син бит Данте, син бит Гете,
Син бит Байрон татар халкына... *(Минһаҗ)*
...Әнә офык аша балкып тора
Якты йолдыз — илнең бизәге.
Карап аңа күңел моңга тула,
Җыламыйча йөрәк түзәме?

«Ил йолдызы» диеп без таныйбыз
Сине, бөек шагыйрь, бу көндә,
Сызган юлларыңдай һәм карыйбыз,
Син торасың илнең күгендә». *(Шаһвәли Илдәр)*

...Канлы көнләр үтәр... еллар китәр,
Илнең бәхте бер көн ачылыр.
Бер кайгыда синең, бер шатлыкта,

Илкәй сине мәңге сагыныр. *(Солтан)*

Журналда мөһаҗәрәттәге башка әдипләр белән дә еш очрашасың. Шундыйлардан Хөсәен Габдүш (1901—1944) һәм Сания Гыйффәт (1899—1957) хакында инде без матбугатта язып та чыккан идек (Соц. Татарстан.— 1990.— 15 октябрь; Сөембикә.— 1991.— № 2; 1992.— № 11; Мирас.— 1992.— № 8, 9). Боларның беренчесе, илдән киткәч, Ерак Шәрыкта, нигездә, Харбинда яши. Хөсәен Габдүш — артист, режиссер, мөгаллим, журналист, әдип. Аның журналдагы хикәяләрендә («Пәрәмәч машинасы», «Уртак вөҗдан», «Нидән мин кечкенә Апуш түгел», «Үзебез өчен», «Тормыш ыгы-зыгысында» һ. б.) авторның көчле табигый таланты, туган халкына ихлас мәхәббәте сизелеп тора. Сания Гыйффәт исә әүвәл Идел-йортта, аннан Кытайда, Финляндиядә, Төркиядә яши. Аның шигырьләре көчле пафос, милли рух белән сугарылган. Журналда илдәге Совет чоры әдипләренең аерым әсәрләренә дә урын бирелә. Алар, нигездә, «Балалар почмагы»нда урнаштырылганнар. Бу төр әсәрләр арасында С. Хәкимнең «Әбиләрнең иске сандыгыннан», «Казан арты» (№ 9), Г. Афзалның «Китаплар язмышы» (# 16), Зәки Нуриның «Ял көне», Ш. Галиевнең «Хәзинә», Зәкия Туфайлованың «Әни сүзе» (№ 14), Мәхмүт Газизовның «Бармаклар» (№ 13) шигырьләре, Вахит Монасыйповның «Салават күпере» (№ 13), «Төп-төгәл сәгать» (№ 14) хикәяләре бар. Алар, күп кенә башка әдәби текстлар кебек, татарча һәм төрекчә бирелгәннәр.

«Казан» хезмәткәрләренең илдәге соңгы дәвер әдәбияты, сәнгате, фәне белән танышып барулары башка материалларда да күренә. Журналның 19 нчы (1977) санында А. Халиковның Казан тарихы хакындагы мәкаләсе, «Казан утлары»ннан (1976.— № 8) алып, төрек телендә бирелгән. Динә Вәлиеваның «Казан утлары»нда басылган мәкаләсе дә (1977.— № 1) мәҗмугада, төрекчәгә күчерелеп, урын тапкан (1978.— № 21.— 45—51 б.).

Журналның 6 нчы (1972) санында Көньяк Америка кешесе М. Д. Каратеевның (вафаты — 1978 елда) «Татарлар хакында кайбер фикерләр» исемле кызыклы бер мәкаләсе бар. Ул Америкада чыгучы «Новое русское слово»дан (1971.— 25 июль) алып урнаштырылган. Мәкаләдә күп кенә күренекле урыс кешеләренең татар нәселеннән булуы хакында языла. Болар арасында Менделеев, Мечников, Тимирязев, Кантимер, Карамзин, Тургенев, Языков, Денис Давыдов, Загоскин, Огарев, Куприн, Арцыбашев, Замятин, Булгаков, Анна Павлова, Уланова, Каратыгин, Ермолова, Скрябин, Танеев, Шишкин (рәссам), Апраксиннар, Япанчин (адмирал), Мордвинов (адмирал), Борис вә Федор Годунов һәм башка мәшһүр фамилияләр телгә алына[17] (48 б.).

«Казан» журналы илдә һәм чит мәмләкәтләрдә чыккан аерым китапларга да рецензияләр урнаштырып бара. Мәсәлән, «Очерки по истории Поволжья и Приуралья» китабына (1969) Куратның бик төпле рецензиясе бар (1972.— № 6.— 59—60 б.). Анда А. Халиков, М. Госманов хезмәтләре дә телгә алына. Шунысын да әйтик: бу — Куратның соңгы, тәмамланмаган мәкаләсе.

Заманында М. Госмановның «Тарихтагы тирән эзләрдән» исемле мәкаләсе (Казан утлары.— 1970.— № 5) татар җәмәгатьчелегендә кызыксыну тудырган иде. Моңа чит илләрдәге милләттәшләребез дә игътибар иткәннәр. Әхмәт Вәли Мәңгәр шушы мәкалә уңае белән «Казан утлары»на ачык хат белән мөрәҗәгать иткән. Аның тексты «Казан»ның 14 нче (1975) санында басылган (60—63 б.). Хат авторы М. Госманов мәкаләсен яратып укуын әйтә һәм шуңа үзе дә кызыклы мәгълүматлар бирә.

Фольклор — халыкны милли-әхлакый рухта тәрбияләүнең мөһим чарасы. Шуны күздә тотып, мәҗмуга даими рәвештә халык авыз иҗатыннан үрнәкләр биреп бара. Мәсәлән, журналның 1 нче санында ук «Халык әдәбияты» исеме астында «Ямьле Агыйдел буйлары» җыры, «Зирәк карт» әкияте, «Алып батыр», Болгар, Казан турында легендалар урнаштырылган. Шушы ук санда тиешле аңлатмалар белән «Сак-Сок» бәетенең тексты да бирелгән. Журналның аеруча 7—8 нче (1972) куш саны фольклор материалларына бай. Анда «Тәфтиләү», «Бишек җыры», «Умырзая» җырлары ноталары белән урнаштырылган (56—59 б.).

Ашкын таулар аша, ташкын сулар аша,
Лачынлардай кайтырбыз туган илләргә,—

һәр строфадан соң шушы кушымта кабатланып килүче «Япанчылар» җыры да журналда урын алган. Мәҗмуга сәхифәләрендә башка әкиятләр, мәзәкләр, бәетләр, җырлар да бар.

Мәкальләр махсус рәвештә дә, эпиграф итеп тә биреләләр. Мәсәлән, шул ук 7—8 нче куш санда мондый текст бар:

Кеше күрке — йөз,
Йөзнең күрке — күз.
Уйның күрке — тел,
Телнең күрке — сүз. (99 б.)

Бу юллар генетик яктан Йосыф Баласагунлының мәшһүр «Котадгу белек» (1069) поэмасына барып тоташа: Үкеш күрке — тел ул, бу тел күрке — сүз, Кеше күрке — йөз ул, бу йөз күрке — күз (Ташкент басмасы, 1971, 100 б.). Журналдагы фольклор әсәрләрнең кайберләре безгә таныш түгел. Билгеле булганнарында да аерым үзгәлекләр очрый. Менә 1785 елда туган «Салават бәете» (1972.— № 9.— 28—29 б.). Анда «Татар халык иҗаты: «Бәетләр» китабында (Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.— 35—36 б., 296 б.) булмаган «Салаваткайның билендә Алтын гына кылыч ялтырый. Салават торып сүз әйткәндә, Гәүр урыс калтырый» строфасы бөтенләй юк. Ике текст арасында хосусый характердагы башка аермалар да күзгә ташлана. Журналда татар театры, музыка, рәсем, бию сәнгате хакында да материаллар бар. С. Сәйдәшев, Г. Кариев, Ф. Яруллин һәм кайбер башка сәнгать ияләренең рәсемнәре дә урын алган.

Татар халык «емәкләре» (пәрәмәч, чәкчәк, пылау, тутырган та-
вык һ. б.), милли киемнәре — мәҗмуганың яраткан рубрикасы (аны, нигездә, Наилә Бинарк алып бара). Бу төр материаллар өчен конкретлылык, күрсәтмәлелек хас.

«Казан» төрки дөньясының һәм тугандаш халыкларның бик мөһим истәлекле вакыйгаларын, милли һәм дини бәйрәмнәрен дә читтә калдырмый. Мәҗмуганың 6 нчы санында Мәхмүд Кашгарый китабының төзелүенә 900 ел тулуга карата да материаллар бар
(25—26 б.). Атаклы галим Фәрәбинең тууына 1100 ел тулу уңае белән журнал үз укучыларына Садри Максудиның «Фәрәбинең хокук фәлсәфәсе» исемле мәкаләсен тәкъдим иткән (1973.— № 10.— 11—16 б.).

АКШта яшәүче милләттәшебез Шәмсия Апакай инде 60—70 нче еллардан бирле Идел-йортка килеп йөри, музейларга, китапханә-
ләргә кыйммәтле материаллар бүләк итә. Бу сәфәрләре хакында ул «Казан» журналында мәкаләләр дә бастырган икән (1976.— № 17.— 41—43 б.; 1978.— № 21.— 52—54 б.). Шәмсия Апакай үз язмаларында Казанга, Тукайга, Идел-йортка, аның кешеләренә җылы мөнәсәбәтен белдерә.

Мәҗмуганың хроника өлеше татар дөньясындагы вакыйгаларны, чит мәмләкәтләрдәге татар тормышының һәм мәдәниятенең төп вакыйгаларын, милләттәшләребезнең үзара багланышларын, бер илдән икенче илгә күчүләрне, килеп-китүләрне билгеле бер дәрәҗәдә чагылдыра. Бу фактик материаллар — тикшеренүчеләр өчен мөһим чыганак. Менә берничә хәбәр: милли шагыйрәбез Сания Гыйффәт вә тарихчыбыз Закир Кадыйри Уганның кызлары Лалә Уган 1977 елның 4 маенда вафат булды (1977.— № 20.— 61 б.); Истанбулда
Сабан туе, Тукай кичәсе булды (1974.— № 12.— 61 б.); 1971 елның 19 августында «Казан» журналы авторларының берсе Наилә Бинарк, укыту өчен, Финляндиягә китте (1971.— № 5.— 60 б.); 1970 елның 20 декабрендә Анкарадагы Казан культура җәмгыятенең 9 кешелек (составы күрсәтелә.— *Х. М.*) яңа идарәсе сайланды… (1971.— № 4.— 62—63 б.) Журналның ахыргы санында Финляндиядә Фатыйма Җамаледдинның вафат булуы (1883—1.07.1978) хәбәр ителә. Мәгълүм булганча, бу зат һәм аның ире Суоми татарларының матди һәм мәдәни тормышын үстерүгә үзләреннән зур өлеш керткәннәр. Бу гаилә, Ризаэддин Фәхреддин, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Абдулла Баттал һәм башка күренекле кешеләр белән бәйләнештә торып, аларга тиешле ярдәм дә күрсәткән. Шунысын да искәртик: Фатыйма әби — Халидә апаның (кызганыч ки, ул 1992 елның җәендә озакка сузылган каты авырудан соң вафат булды) әнисе. Профессор Гомәр ага — аның кияве, ә инде татар дөньясына таныш исем — Окан Таһир — Фатыйма әбинең оныгы.

* * *

«Казан» мәҗмугасы Төркиянең үзендә генә түгел, төрки-татарлар яши торган башка мәмләкәтләрдә дә таралыш тапкан. Финляндия татарларының күпчелегендә миңа бу журналны үземә дә күрергә туры килде. Соңгы вакытта Алманиягә, АКШка, Кытайга баручы кайбер кешеләр «Казан» журналының аерым саннарын хәтта илгә дә алып кайталар. 80 нче елның урталарына кадәр бу мәҗмугага СССРда юллар ябык иде диярлек. Килгән кадәресе дә, нигездә, Мәскәү вә Ленинградның махсус фондларында бикләнеп кала иде. 70 нче елларда Ленинградтагы махсус китапханәләрнең берсендә «Казан» журналын бик авырлык белән яздырып алуымны хәтерлим. Анда да берничә санын гына. Тулы комплекты белән исә Хельсинки университеты китапханәсендә генә таныштым.

«Казан» журналы, бик озын гомерле булмаса да, чит мәмләкәтләрдәге татарларны милли рухта тәрбияләүгә, телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклауга, буыннар бәйләнешен тәэмин итүгә, милләтне туплауга үзеннән зур өлеш кертте. Ул халкыбыз хакындагы белем-мәгълүматларны бергә туплап, гомумиләштереп, милләтебезне башка халыкларга танытуда, аның игү атын, абруен саклауда һәм күтәрүдә дә билгеле бер роль уйнады. Идеологик догмалар белән бәйләнмәгән «Казан» татар әдәбиятын һәм сәнгатен пропагандалауның да бер мөнбәре булды. Анда совет басмаларында тыелган аерым әсәрләр дә урын тапты. Журнал илдәге һәм чит мәмләкәтләрдәге күптөрле һәм берничә телдәге басма, кулъязма, архив материаллары белән эш иткән. Турыдан-туры тормыштан алынган беренчел мәгълүматлар да шактый.

Миңа 1928—1939 елларда Берлинда Гаяз Исхакый редакциясендә чыккан «Яңа милли юл» журналы белән махсус танышырга туры килгән иде18. Шуңа күрә мөһаҗәрәттә нәшер кылынган бу ике мәҗмуганы чагыштыру мөмкинчелеге дә бар.

«Казан» иҗтимагый, сәяси, мәдәни характерда булуы, татар язмышын үзәккә куюы, төп юнәлеше, идея-тематикасы, даими рубрикалары белән «Яңа милли юл»га якын тора, аның тәҗрибәсен файдалана, күп кенә традицияләрен дәвам итә. Әмма Берлинда чыккан журналда сәяси пафос көчле, Совет хакимиятен кискен тәнкыйтьләү бар. «Казан»да исә тарих, фән, әдәбият, сәнгать, мәгариф, тәрбия мәсьәләләре өстенлек итә. Хәзер безнең алда, соң булса да, илебездәге татар укучысын «Казан» журналы белән якынайту, очраштыру бурычы тора. Моны гамәлгә ашыру халкыбызның зиһенен баетуга, милли үзаңын күтәрүгә ярдәм итәр иде.

Казанга Халыкара тюркологик конференциягә һәм Бөтендөнья татар конгрессына (1992) Төркиядән килгән әдип Гөнүл ханым Пултар (ул — Адилә Аиданың кызы, Садри Максудиның оныгы) бер изге эш башкарды: ул җөмһүриятебезнең Милли китапханәсенә «Казан» журналының күп кенә саннарын бүләк итте. Әйткәнемчә, мәҗмуганың аерым саннары илдәге кайбер кешеләрдә дә очрый. Димәк, журнал белән танышу, аны күбәйтү мөмкинлеге бар. Һич кичекмичә, мәҗмуганың библиографиясен төзү шарт. Журналдагы аерым материалларны, бигрәк тә күренекле шәхесләр хакындагы язмаларны, мөһаҗәрәттә язылган әдәби әсәрләрне вакытлы матбугат битләрендә, аерым җыентыклар рәвешендә бирү зарур. Галимнәребезнең дә «Казан» мәҗмугасына ешрак мөрәҗәгать итүләре, андагы факт-мәгълүматларны кыюрак гыйльми әйләнешкә кертүләре сорала.

ИСКӘРМӘЛӘР

1 Бу мәкаләнең беренче варианты «Кызыл таң» гәҗитендә 1992 елның 10, 12, 15—17, 19 сентябрь саннарында (177, 179—184 б.) һәм «Казан» журналының 1 нче (1993 ел) санында дөнья күргән иде.

2 Бу хакта карагыз: *Хатыйп Миңнегулов*. Татар-төрек әдәби багланышлары // Татарстан.— 1993.— # 9.— 50—56 б.; *Тәүфикъ Әйди*. Хәзинәләр уртак (төрек-татар багланышлары) // Казан утлары.— 1993.— # 11.— 156—170 б.; 1993.— # 12.— 160—167 б.

3 Бу авыл хакында Р. Гыйльфанов болай яза: «Это самая большая татарская деревня в Турции, в ней живут около 1100 человек, приблизительно 250 хозяйств... Богределек был основан в 1908 году сибирскими татарами — выходцами из деревень Каракуль, Еланлы, Янаул близ Омска» (Татарская эмиграция) // Татарские края = Татар иле.— Май.— 1993 г.).

4 Электән яшәп килгән бу оешма 80 нче елларда эшен туктатып тора, 1992 елда кабат эшли башлый.

5 Киләчәккә нигез // Шәһри Казан.— 11 декабрь.— 1992 ел.

6 Бу санга Кырым татарлары керми. Америка галиме Алан Фишер раславынча, Кырым Россия тарафыннан яулап алынганда, ягъни XVIII гасырның 80 нче елларында анда 100 меңләп кенә татарның яшәве билгеле. 1928—1929 елларда, буржуаз милләтчелектә гаепләнеп, 35—40 мең Кырым татары янә иленнән сөрелә (Казан.— 1980.— № 23.— 56—58 б.). Александр Беннигсен хисаплавынча, Октябрь инкыйлабына кадәр вакыт эчендә Төркиягә барлыгы ярты миллионнан артык Кырым татары качып, күчеп китә (Исмаил бей Гаспринский... В кн.: Россия и Восток.—Казань: Татар. кн. изд-во, 1993.— С. 82—83).

1944—1945 еллардагы геноцид чорында 110 мең Кырым татары һәлак була (*Тамурбек Давлетшин*. Советский Татарстан...— Лондон.— 1974.— С. 320). Рәсми булмаган мәгълүматларга караганда, Төркиядә яшәүче Кырым татарларының саны берничә миллионга җитә.

7 Аны кайберәүләр «Казан тирәсенә» дә нисбәт итәләр. «Каран авылы» шигырендә мондый юллар бар:

Шуңа күрә авылым Каран кыйммәтледер алтындан,
Шунда кайтып үлсәм иде дип кичерәм акылымдан.

8 Тәүфикъ Әйдигә юллаган хаты аркылы (Илдән еракта // Татарстан хәбәрләре.— 3 сентябрь.— 1991 ел) без Әмрулла Агыйның гаять гыйбрәтле язмышка ия булганлыгын күрәбез. Ул 1912 елда Пенза төбәгендәге Нагур авылында туа. 1917—1922 елларда Благовещенск каласында, аннан Харбинда һәм Кытайның башка шәһәрләрендә яши. Ерак Шәрыкта татар мәдәни, мәгариф эшләрен оештыручыларның берсе була. 1945—1965 елларда совет зинданнарында, сөргендә газап чигә. «Илдәшебез Әхмәт Вәли Мәңгәрнең, аның дусларының тырышлыгы вә Төркия хөкүмәте ярдәме белән генә, 1965 елда Төркиягә килеп, гаиләм белән кавыштым,— ди ул.— Егерме ел атасыз үскән улларым без күрешкәндә тәмам җитлеккән ир-егетләргә әйләнгәннәр иде инде!» Әмрулла Агый, Төркиядә бераз яшәгәч, АКШка күчеп китә.

9 Финляндиядәге кардәшләребез дә, Садри Максуди, Лотфый Исхакый инициативасы белән, Идел буендагы ачыгучыларга ярдәм оештыралар (Казан.— 1977.— № 7.— 27 б.).

10 Карагыз: *Әбрар Кәримуллин*. Элемтә // Ватаным Татарстан.— 4 сентябрь.—1992 ел.

11 Төркиядә, Германиядә укыган, хезмәтләре белән дөнья тюркологларына яхшы таныш булган Әхмәт Тимер — Бөгелмә имамы Ярулла хәзрәтнең улы. Аның этисен, нахак бәла ягып, атаклы тарихчы һәм педагог, баҗасы Һади Атласи белән берлектә 1938 елда атып үтерәләр (*М. Мостафин*. Оныклар кайтты // Ватаным Татарстан.— 18 июнь.— 1993 ел).

12 Журналның 17 нче санында «Советский Татарстан...» китабы «милләткә бөек хезмәт» дип бәяләнгән иде (1976.— № 17.— 52 б.).

13 Сәхипҗамал Солтан да, аның ире Абидулла Бадай да — чыгышлары белән Пенза ягыннан; һәр икесенең дә эти-әниләре, болар балачакта ук, Харбинга, Хайларга күчеп килгән булалар.

14 Ибраһим Вәли — тумышы белән Троицкидан. Сәүдәгәр гаиләсеннән. Мәдрәсәдә, аннан Чиләбе гимназиясендә белем ала. Томск университетының медицина факультетында укый башлый. Аннан — Иркутск. Харбинда бераз яшәгәч, Берлинда укый. Алмания клиникаларында эшли. 1937 елдан — Төркиядә, 1953 елдан — Анкара университетының медицина факультеты деканы. Күп санлы китаплар, дәреслекләр авторы.

15 *Хатыйп Миңнегол* (Миңнегулов). Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты // Казан утлары.— 1993.— № 7.— 159 б.

16 Һади Атласи 1938 елда үтерелә.

17 Безнең матбугатта (Ватаным Татарстан.— 14 май.— 1993 ел) Александр Филипповның «Татарлар намуслы, тугрылыклы...» исемле гаять кызыклы бер язмасы дөнья күрде. Мәкаләдә М. Каратеевның Россиядән мөһаҗәрәткә төшүе, гомеренең ахырын Уругвайда уздыруы, күп санлы әдәби әсәрләр, очерклар, тарихи хезмәтләр язуы аңлашыла. Мәсәлән, биш тарихи романны берләштергән «Русь и Орда» эпопеясы, «Арабески истории» исемле монографиясе һ. б.

М. Каратеев — татарларны нахак бәладән аралаучы, тарихи гаделлек тарафдары. «Безнең елъязмачыларыбыз,— ди ул,— татарлар һәм аларның кылган гамәлләрен тасвирлаганда, бары тик бертөрле төс кенә — кара буяу һәм аның да артык куертылганын гына кулланганнар. Алга таба, шуннан файдаланып, урыс әдәбияты, бигрәк тә беллетристика, татарларга карата бу төсне берничек тә үзгәртмичә кулланды...» «...Кеше һәм дәүләт башлыклары буларак татарларның ифрат күп уңай сыйфатларга ия булганлыкларын да танырга кирәк. Барыннан да элек, алар иң югары дәрәҗәдә намуслы, бурычка тугрылыклы һәм тәртипле булулары белән аерылып торалар, бу нисбәттә аларның урыс халкына булган йогынтысы бары тик яхшы гына була ала».

18 *Хатыйп Миңнегулов*. Азатлык көрәшенең мөнбәре // Казан утлары.— 1993.— № 3.— 122—135 б.

*1993*

## ШАҺВӘЛИ КЕЛӘҮЛЕ (ИЛДӘР)

*(1900—1970)*

### «Иркәләп сөйгән Ватан»

Бу зат Уфадан көньяк-көнбатыштарак урнашкан Габдессәлам исемле татар авылында туа. Яшьли үк әти-әнисез кала. Петропавловскида (Кызылъярда) мәдрәсәдә укый. Бераз вакыт урыс мәктәбендә дә белем ала. 1914—1918 елларда Дим буендагы Дәүләкәндә сатучы (приказчик) булып эшли. Келәүле (Клявлино) якларына да барып чыга. Милли-мәдәни чаралар оештыруда башлап йөри. 1918 елда хәрби хезмәткә алына. Аклар ягына эләгә. Сугышта чигенә-чигенә Хабаровскига килеп җитә. Каты яралана. Кореяда дәвалана. Шанхайга килә. Биредәге «Төрк-татар милли-дини оешмасы»нда секретарь вазифаларын да башкара. Бер еллап «Милли Байрак» гәҗитендә эшләп ала. 1949 елда Истанбулга күчеп килә. Кыен шартларда яшәвенә дә карамастан, Төркиядә дә, Кытайдагы кебек, милли кичәләр оештыруда актив катнаша. Гаяз Исхакый белән аралашулар Шаһвәли Риян улы Келәүлегә көчле йогынты ясый. Гомеренең соңгы елларын картлар йортында уздыра, шунда ук вафат та була.

Шаһвәли Келәүле яшьтән үк әдәбиятны, музыканы ярата. Әдәби иҗат белән Шанхайда яшәү елларында ныклап шөгыльләнә башлый: шигырьләр, поэмалар («Ачы язмыш») яза. Сәхнә әсәрләре дә бар. Аның «Асламчылар» исемле бер пәрдәлек комедиясе (1937) Кытайда һәм Төркиядә дә сәхнәләштерелә. Аерым шигырьләргә көйләр дә яза. Мәсәлән, аның «Байкал күле» исемле җыры Ерак Шәрыктагы татарлар арасында бик яратып җырлана.

Шаһвәли Келәүленең аерым язмалары «Милли Байрак» гәҗитендә, «Яңа милли юл», «Kazan» журналларында һәм мөһаҗирлектәге кайбер башка басмаларда нәшер ителгән. Әдипнең тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнүгә, әсәрләрен бастыруга Төркиядә яшәүче милләттәшебез Надир Дәүләт билгеле бер өлеш кертә. [Карагыз: Шаһвәли Илдәр // Kazan.— 1970.— № 1.— 19—25 б.; 1974.— № 13.— 2—3 б.; Шагыйрь Шаһвәли Келәүле иҗаты // Казан утлары.— 2000.— № 2.— 147—153 б.].

* * *

Мөһаҗирлек чоры татар сүз сәнгатенә хас күп кенә сыйфатлар Шаһвәли Келәүле әсәрләрендә аеруча калку гәүдәләнеш тапкан. Ватанны, туган җирне сагыну — шагыйрь иҗатындагы төп мотивларның берсе.

Әй Ватан, туган Ватан,
Иркәләп сөйгән Ватан.

Бу юлларда «Ватан» сүзенең кабатлануы үзе генә авторның күңел халәтен, сагыну-өзгәләнүләрен ачык күрсәтеп тора. Шагыйрьнең үзенә тәхәллүс-кушамат итеп «Илдәр» атамасын алуы да юкка гына түгел.

Шаһвәли Келәүле иҗатында «Ватан», «ил» төшенчәләре туган халкы, татар язмышы белән табигый бәйләнештә бирелә. «Яңа милли юл» журналында басылган (1936.— № 5.—15 б.) «Тугры юл» шигырендә автор татарның данлы үткәненә аның хәзерге аяныч хәлен каршы куя, үз укучысын ирек, Ватаны Идел-Урал өчен көрәшкә чакыра. «Безнең ил,— ди ул,— Идел-Урал. Анда төрк-татар туган». Шагыйрь иҗатында «ил», «Ватан», «халык» төшенчәләре кайвакыт Казан белән дә тәңгәлләштерелә.

Мәгълүм ки, Тукай — мөһаҗирлектәге әдипләр өчен милли символ, татар яшәешенең бөек бер заты. Шаһвәли Келәүле өчен дә бу шулай. Бер шигырен ул күңелдән Ватанга, Казанга сәфәр кылу рәвешендә язган һәм аны «Тукай эзеннән» дип исемләгән. Әмма автор «ямьле Казан»нарны, «пар ат»ларны тапмый. Анда — һаман да «зольмәт».

Шаһвәли Келәүле Тукайны «ил йолдызы», «бөек шагыйрь» дип атый. «Тукайсыз,— ди ул,— һич ямь табалмыйм».

Шаһвәли Келәүле төрки бердәмлек хакында да уйлана. «Гүзәл Истанбул» шигырендә ул, мәсәлән, бу шәһәргә мәдхия укый. Әмма шагыйрь өчен бу кала — төрекләрнең генә түгел, ә гомумән төркиләрнең дә «башкаласы», «милли кыйбласы, җаны, йөрәге».

Гомумтөрекләрнең мәркәзе Истанбул,
Син яшә һәм бар ол (бар бул.— *Х. М.*), һәр заман гүзәл бул.

Гомеренең ахыргы елларында (1968 елда) иҗат ителгән «Аерылмак юк, берлек бар» шигырендә дә автор төрки бердәмлек, бу очракта татар-башкорт берлеге мәсьәләсен күтәрә. Шаһвәли Келәүле фикеренчә, бу ике кавем элек-электән бердәм булып яшәгән. Аларны аеру, дошманлаштыру — «җирәнгеч» гамәл.

Ялварып мин сезгә әйтәм. Берләшик без һәммәбез,
Бар кабилә бергә булсын, булмасын һич сез вә без.
Һәм Иделнең, һәм Уралның буйларында барчабыз,
«Ашказар»ны бергә җырлап, бергә эчәрбез кымыз.

Шигырь авторы хәтта татар белән башкортны берләштергән исем дә тәкъдим итә: ул — «Татбашия»:

«Тат» ди бездән, «Баши» сездән, я хәрефен беркетеп,
«Татбашия» дип куйсак без һәр ике якка итеп.

Шаһвәли Келәүле — яшәешнең ачысын-төчесен күргән, сугышларның, мөһаҗирлекнең авыр газабын кичергән зат. Ул «аклар»га, «кызыллар»га бүленеп сугышуның мәгънәсезлеген яшьли үк аңлый. Чөнки бу тәр орышлар илнең талануына, берничәшәр йөз мең кешенең кырылуына китерә.

Надир Дәүләт фикеренчә, Шаһвәли Келәүленең 66 шигыре булган. Кызганыч ки, безгә аларның бары бер дистәләбе генә мәгълүм. Алар, нигездә, «Kazan» журналында татар һәм төрек телләрендә нәшер ителгән.

*2006*

**[Кара бәхет милләтемә кадалган]***

...Каһәр суксын фикер биргән галимне,
Сугышырга котырткан бар залимне.
Шулар изде минем яшьлек чагымны,
Алар ала язды минем җанымны.
Сугышка сөрелде ифрат күп инсан,
Бере — кызыл, бере ак төскә кергән.
Кирәкмәгән гамәлгә әһли шайтан
Өчен бирде ничә йөз мең кеше җан.
Идел-Урал бу ихтилял чагында,
Янып көйде әҗәлнең кочагында.
Газиз туган илнең һәрбер ягында
Таланды, туналды халкыбыз тагын да...
...Куылды бар халык безнең сугышка,
Яше, карты канлы, явыз буышка.
Куылды һәр ике якка булышка,
Алар өчен, имеш, әйдә сугышка.
Кара бәхет милләтемә кадалган,
Йөз елларга ирексезлектә калган.
Сарык кебек сөрелде, чөнки мәхкүм,
Илем әсир, халкым кол, барысы мәзлүм.
Ике аеры әмәл һәм канлы гая
Өчен халкым шәһит булды, бичара.
Белә алмый турылык кем ягында,
Без кан костык кызыл һәм ак сафында.

**Ил йолдызы***

Янә офык аша балкып тора
Якты йолдыз — илнең бизәге.
Карап аңа күңел моңга тула,
Җыламыйча йөрәк түзәме?!
«Ил йолдызы» диеп, без таныйбыз
Сине, бөек шагыйрь, бу көндә.
Сузган юлларыңнан һәм карыйбыз,
Син торасың илнең күгендә.
Син идең бит, шагыйрь, дәрдең белән
Халык уртасында гизүче.
Ярлы, ятим, сынык күңлең белән
Ил моңнарын сызып бирүче.
Хәтереңдәме? Илнең чүп-чарларын
Син тазартып, безне пакьләдең,
Ерак торып калган ил данларын
Җир казгычың белән җанладың.
Бар иде бит заман, безнең илдә
Җитешмәгән илләр дөньясы,
Имеш: «Дию-пәри фәлән
Ыжгырадыр, абау, ун башы».
Балкып чыктың, шагыйрь, шул арада
Якты йолдыз кеби нурланып.
Бөтен дию-пәри шау-шу кача
Үлеп бетте шунда хурланып.
Авыр йөкне син таратып киттең,
Бөек шагыйрь, илнең баласы.
Шиңгән чәчәкләргә сулар сиптең
Күренми һәм суның анасы.

Ил йолдызы сүнмәс, якты янар,
Ил догасы белән бизәлер.
Шигыреңнән халык азык табар,
Яктылыкта мәңге тирбәлер.
Баш иябез шагыйрь рухына,
Ялварабыз бөек Тәңрегә.
Кертсен изгелекләрнең гөруһына (төркеменә.— *Х. М.*),
Оҗмах итсен урның мәңгегә.

**Тукай эзеннән***

Кич белән беркөн Ватанга
Мин дә киттем уйланып:
Ник Тукай ямьле Казанга
Юлда барган моңланып.
Мин шулай уйда юнәлсәм,
Туп-туры илгә карап,
Һич Тукайсыз ямь табалмыйм,
Сүзләрен алам талап.
Әй бөек халык шагыйре,
Кайда ул ямьле Казан?
Кайда ул мәсчетләрендә
Ишетелә моңлы азан?
Кайда пар ат? Кайда калфак?
Кайда алтын балдагың?
Барысы бетте, милли шагыйрь,—
Җанланырмы бер тагын?
Бетмәде зольмәт һаман да,
Китмәде тир җәбһәдә (биттә.— *Х. М.*).
Ул синең сөйгән Казанда
Милли һәр эш шөбһәдә.
Тик синең белән пар ат та
Иркәли ил, ямь бирә.
Шул матур моңлы азанда
Ил якын, якын килә.
Әй Ватан, туган Ватан,
Иркәләп сөйгән Ватан.
Максаты мәрхүм шагыйрьнең
Җанланыр синдә кайчан?

**Корбан бәйрәмендә****

Гайд Корбан көне килгән,
Өйгә бәйрәм төсе кергән.
Ерак булсак та без илдән,
Алабыз каршы, күңелдән.
Тора өстәлдә чәкчәге —
Бөтен ашларың (ашларның.— *Х. М.*) иң шәбе,
Үзе милли, үзе тәмле,
Карап торсаң да ул ямьле.
Бәлешләр төрле җимештән,
Кызарып һәр йире пешкән.
Кабарган камыры җитешкән,
Матурлыгы да килешкән.
Бүген безгә кунак килер,
Озын гына сәлам бирер,
Мөбарәк көнне котлап, ул
Бу ашларга шәрәф бирер.
Яса чәеңне син, хатын,

Җимер чәкчәкнең өс катын,
Алыр ашларның ул тадын (тәмен.— *Х. М.*),
Сыйлап калыйк кунак затын.

**Байкал буенда***

Егерменче ел башында
Киттек тезелеп гаскәр сафында,
Гаскәр сафында.
Төрек-татар халкының без
Мәхкүм яшьләр аклар ягында,
Байкал буенда, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Байкал өсте бозлы ялан,
Күренми һич аргы яр чите,
Аргы яр чите.
Тик күренгән кебек шунда
Ерак күксел биек тау бите.
Байкал буенда, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Байкал аша атлый гаскәр,
Чыктык бер-бер артлы тезелеп.
Артлы тезелеп.
Шаулый, үкерә Байкал асты,
Ярылып китә бозлар өзелеп.
Байкал өстендә, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Салкын искән җил куәте
Чеметә битне ачы сыздырып,
Ачы сыздырып.
Ирексез без гаскәрләрне
Язмыш йөртә Байкал гиздереп.
Байкал буенда, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Җәелеп яткан боз сахрасы
Иске данлыкларны уйлата,
Данлыкларны уйлата.
Ничек әүвәлге бабайлар
Дәүләт корган Байкал буйлата.
Байкал буенда, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Элек заман изге Байкал
Күле булган ханлар кулында,
Ханлар кулында.
Югалган шул зур байлыкны
Күреп уздык Байкал буенда.
Байкал буенда, Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

*Шанхай, 1930*

**ХӨСӘЕН ГАБДҮШ**

*(1901—1944)*

## «Сәлам әйтче туган илләргә»

Чит илләргә киткән татарларның берничә дистә меңе Ерак Шәрык мәмләкәтләрендә, төгәлрәк әйткәндә, хәзерге Кытай, Корея, Япуния җирләрендә кала. Харбин, Хайлар, Токио — мөһаҗир милләттәшләребез тупланган төп үзәкләр.

Милли җанлы, укымышлы татарлар Ерак Шәрыкта мәктәпләр ачалар, мәчетләр төзиләр, күп санлы гәҗит-журналлар, китап-
лар нәшер итәләр. [Бу хакта карагыз: *Х. Миңнегулов*. Чит илләрдә татар әдәбияты һәм матбугаты // Казан утлары.— 1993.— # 7.—
154—163 б.; *Х. Миңнегулов*. Милләт бетмәсә, аның теле вә әдәбияты яшәр // Шәһри Казан.— 13.06.1992].

Аларның максаты — милли җанны, туган телне саклап калу, яшь буынны татарчылык рухында тәрбияләү. Шунысы мөһим: чит илләрдәге татар матбугаты һәм әдәбияты, иң беренче чиратта Г. Исхакый язмалары, Совет чорында Идел-йортта тәмам зәгыйфьләнгән милләтпәрвәрлек идеяләрен үзәккә куйды, үстерде һәм Тукай дәверендәге милли рухны хәзерге буынга җиткерүдә җитди роль уйнады.

Хөсәен Габдүш Ерак Шәрыктагы татар мәдәни тормышының үзәгендә кайнаучы, аны оештыручы, нурландыручы фидакяр затларның берсе була. Ул — әдип, шагыйрь, журналист, артист, режиссер, мөгаллим, тәрҗемәче. Бу талантлы инсанның эшчәнлегенә аны якыннан белгән Гаяз Исхакый, Рәшит Рәхмәти Арат, Мәдинә Сәлиәхмәд, Солтан, Мәхмүт Таһир һәм башка билгеле затлар югары бәя бирәләр. Хөсәен Габдүшкә багышланган истәлекләр шактый. Аларның күпчелеге 1970—1980 елларда Төркиядә нәшер ителгән «Казан» журналында дөнья күрә.

Безгә инде Хөсәен Габдүшнең тормышы, эшчәнлеге хакында язарга туры килгән иде (Социалистик Татарстан.— 15.11.1990; Мирас.— 1992.— # 9.). Шуңа күрә биредә әдипнең тәрҗемәи хәлендәге төп этапларны атап китү генә урынлы булыр.

Хөсәен Рәхимҗан углының балалык һәм үсмер еллары Троицк каласы белән бәйле. Мәгълүм булганча, бу — элеккеге татар мәдәни үзәкләреннән берсе. М. Акмулла, М. Гафури, Г. Сәгъди, Ш. Бабич, С. Әдһәмова, А. Расих һәм кайбер башка татар әдипләренең тормышы һәм эшчәнлеге Троицк белән бәйләнгән. Хөсәен Габдүш шушы калада 1901 елның 5 гыйнварында мөгаллим гаиләсендә дөньяга килә. Яшьли үк ятим кала. Бабасы Мөхәммәдвәли Ибраһим тәрбиясендә үсә. Әүвәл Троицкидагы татар мәктәбендә, аннан әдәбиятыбызга Н. Арслан, М. Хөсәен һәм башка билгеле затларны биргән Петропавловскидагы (Кызылъярдагы) реаль училищеда укый. Әмма ул бу уку йортын тәмамларга өлгерми: инкыйлабтан соң, кардәшләре белән берлектә, Маньчжуриягә күчеп китә. 1919 елда инде аның Харбинда яши башлавы мәгълүм. Ул Токиода, Кытайның кайбер шәһәрләрендә дә була.

Хөсәен Габдүш чирек гасыр буена мөһаҗирлек газапларын чигә, горбәтлекнең ачысын-төчесен татый. Аның җитәр-җитмәс тормышта ачлы-туклы яшәве әсәрләрендә дә билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Әмма ул күңел көрлеген, милләткә, әдәбиятка, Тукайга фидаиләрчә бирелгәнлеген гомере буе саклап кала. Хөсәен Габдүш төрле гәҗит-журнал редакцияләрендә, мәктәпләрдә, үзешчән түгәрәкләрдә, мәдәният учакларында «бәйгеләрдә чапкан ат сыман» эшли. Әҗәл дә аңа шушындый вакытта килә: 1944 елның 14 апрелендә Тукай бәйрәменә сәхнәдә репетиция ясаганда йөрәге тибүдән туктый. Бу милләтпәрвәрнең гәүдәсе Харбин татар зиратына җирләнә. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Маньчжуриядәге татарлар дөньяның төрле кыйтгаларына янә таралып китәргә мәҗбүр булалар. Хуҗалары киткәч, Харбиндагы татар зираты, Хөсәен Габдүш кабере дә, мөгаен, ятим булып, онытылып калгандыр.

Хөсәен Габдүш әдәби иҗат белән Ватанда вакытта ук шөгыльләнә башлый. Мөһаҗәрәттә ул бу эшен тагын да активлаштыра. Аның язган материаллары аеруча «Ерак Шәрык» журналында күпләп басыла. «Дүрт хикәя» исемле җыентыгына 1930 елда язган кереш сүзендә автор менә нәрсәләр ди:

«1920 елның гыйнварында Харбинда чыга башлап, 30 нчы санына чаклы гомер иткән «Ерак Шәрык» журналының әдәби парчалар өчен артдырылган барлык битләре шагыйрь Казанлы* һәм бу китабдагы дүрт хикәя иясенең шигырь вә хикәя язудагы сынауларына багышланып килделәр.

Алар икесе дә үз күңелләрендәге әле илдә чакда ук чаткыланган әдәбиятка мәхәббәт утының, Тукай сүзләре белән файдаланып әйткәндә, кабыныр-кабынмас сүнмәве өчен, үзләрен мәзкүр (телгә алынган.— *Х. М.*) журналга зур бурычлы дип беләләр.

Таркаулыкдан җыйнаклыкка таба эшләнгән ошбу зәгыйфь бер тәҗрибәмнең беренче битендә Кытай капкалары төбендә беренче кат чыккан татар журналын вә аны алып барудагы авырлыкның арыслан өлешен үз өстләрендә күтәргән мәрхүм Гыйниятулла Әхмәди һәм Казанлы исемләрен яхшылык белән хәтергә алып узмыйча булдыра алмадым».

Хөсәен Габдүшнең шигырьләре, хикәяләре, мәкаләләре, тәрҗемәләре, «Ерак Шәрык» мәҗмугасыннан тыш, «Чаткы», «Милли Байрак», «Яңа милли юл», «Белдереш», «Kazan» һәм башка гәҗит-журналларда дөнья күрә. Әмма әле, кызганычка каршы, аларның барысы да барланмаган, өйрәнелмәгән. Әдип әсәрләрен туплап, махсус җыентык рәвешендә нәшер итү — көн тәртибендә торган мөһим мәсьәлә.

Соңгы елларда безнең тарафтан Хөсәен Габдүшнең аерым хикәяләре укучыларга җиткерелде: «Үзебез өчен» (Социалистик Татарстан.— 15.11.1990); «Алданумы?» (Мирас.— 1992.— # 9.—32—46 б.); «Уртак вөҗдан» (Мирас.— 1996.— # 5—6.— 39—41 б.).

1931 елда Токиодагы «Матбагаи Исламия»дә Хөсәен Габдүшнең гарәп хәрефләре белән «Дүрт хикәя» исемле китабы (барлыгы — 83 бит) дөнья күрә. Биредә авторның 20 нче елларда иҗат ителгән «Яр читендә», «Алданумы?», «Орлыклар» һәм «Мылтыклы хикәя» исемле дүрт әсәре урнаштырылган. Тәүге өлештә язучының кереш сүзе бар. Токио басмасы — хәзергә Хөсәен Габдүшнең китап рәвешендә чыккан бердәнбер җыентыгы.

Хөсәен Габдүш хикәяләрендә вакыйгалар, нигездә, Идел-йорттан читтә — Ерак Шәрыкта бара. Аларда мөһаҗир татарларның яшәеше, уй-кичерешләре, рухи халәте шактый тулы гәүдәләнеш таба. Урыны белән Кытай, Япуниянең тормыш-көнкүреше, табигате белән бәйләнешле детальләр һәм күренешләр дә очрый. Вакыйга-хәлләрнең күпчелеге Октябрьдән соңгы елларда бара. Хикәяләүче образ белән автор шактый якын, хәтта еш кына алар үзара керешеп, тәңгәлләшеп тә китәләр. Персонажлар, — нигездә, мөһаҗир татарлар. Башка милләт вәкилләре — икенче планда. Фикерләү, кагыйдә буларак, табигый, образлы. Аерым чатаклыкларны исәпкә алмаганда, тел-стиле дә шактый шома, үтемле. Хикәяләү, тасвирлау еш кына диалогик һәм монологик сөйләм белән үрелеп бара. Автор каһарманнарның рухи халәтен, күңел дөньясын ачуга җитди игътибар бирә. Шуны күздә тотып, ул кайвакыт шартлы алымнарга, гайре табигый образларга да мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, «Орлыклар» хикәясендә Мохтаров күңелендә шайтан балалары белән курчак фәрештәләр «ызгыша». «Уртак вөҗдан» әсәренең персонажы Хәсән көзгедә «моннан алтмыш ел элек дөньядан кичкән Бәхтияр бабасы»ның сурәтен күрә, аның вәгазьләрен тыңлап тора. Гомумән, Хөсәен Габдүш үткән белән хәзергене очраштырырга, тарихи хәтернең милләт өчен мөһим сәхифәләрен кинокадрлар рәвешендә күз алдыннан уздырырга ярата. Менә «Алданумы?» хикәясенең төп каһарманы Мәрҗани, Тукай, Кариев, Вахитов һәм башка тарихи затларны барлап утыра. Ярым төш, ярым өн халәтендәге егетнең күңелендә каршылыклы уйлар өермәсе. Өзек-өзек, бәйләнешсез, кыскы-кыска җөмләләр!.. «Бу ни бу? Өнме-төшме? У-у! Әнә ут! Тагы ут. Әнә эшчеләр. Хатын-кыз! Солдатлар. Шәкертләр... Татар солдатлары... Аклар, кызыллар...»

Күрәсез: мондый стиль геройның психологик халәтенә туры килеп тора. Һәм, гомумән, автор атау җөмләләрне, чагыштырмача кыска фразаларны кулланырга ярата. Бу ягы белән ул К. Нәҗми, Г. Кутуйларның шушы еллардагы язу стилен искә төшерә.

Хөсәен Габдүш әсәрләрендәге автор образы, хикәяләүче, төп каһарманнар — әдәбияттан, сәнгатьтән шактый хәбәрдар затлар. Алар, Г. Ибраһимовның романтик геройлары кебек, җыр-музыкага битараф карый алмыйлар. «Алданумы?» хикәясендәге Нияз җырчыны үз-үзен онытыр дәрәҗәгә җитеп тыңлый. «Әйтерсең, тәннән аерылып, Ниязның җаны гына калды». «Үзебез өчен» хикәясендәге Габдулла әсәрнең азагында сагынуына, йөрәгенең януына түзә алмыйча җырлап җибәрә:

Карлыгач, кая барасың,
Бармыйсыңмы безнең илләргә?
Барсаң да гына безнең илләргәләй...
Сәлам әйтче туган илләргә...
Сәлам әй...т
Нечкә билләргә.

Хөсәен Габдүш хикәяләренең интонацион яңгырашы да төрле. Аларда җитдилек аһәңе һәм юмор да, куаныч һәм моңсулык та бар. Әмма шулай да сагыш интонациясе, җирсү (ностальгия), туган җирне, Идел-йортны сагыну аһәңе өстенлек итә. Бу моң каһарманнарның рухына, текстның тукымасына сеңгән. Бу аңлашыла да. Чөнки һәм автор, һәм аның геройлары — чит-ят җирләрдә, туган иленнән, газиз халкыннан еракта гомер кичерергә мәҗбүр ителгән затлар. Сагыну, сагыш хисе аларның даими юлдашына әверелгән. Идел, Казан, Сөембикә, Тукай, татар сүзе, татар моңы мөһаҗирләрнең күңелен юата, яшәешләренә мәгънә, өмет бирә.

Хөсәен Габдүш хикәяләрендә милли рух, татарга, Идел-йортка мәхәббәт, хөрмәт хисе гаять көчле. Әмма авторның милләтпәрвәрлеге инсанлык, әхлаклылык белән тыгыз бәйләнештә. Ул үз халкының кимчелекле якларын, артталыгын да күрә, япуннарның тәрбияле, тәрәккыятле булуына соклануын да белдерә. «Мылтыклы хикәя»дә яшь кыз Мәрьям «сары мыеклы бер татарга» кияүгә чыга. Ә инде бу кешенең Русиядә хатыны, балалары була. Әсәрдә бу затка тискәре мөнәсәбәт ачык сизелеп тора.

Г. Исхакыйның 1916 елда иҗат ителгән «Ул әле өйләнмәгән иде» исемле повесте бар. Бу психологик әсәрдә татар егете Шәмсетдиннең урыс хатыны Анна Васильевна белән катлаулы мөнәсәбәтләре гәүдәләндерелә. Төп персонаж, катнаш никахның аянычлы нәтиҗәләрен аңласа да, күнегелгән гадәт, инерция буенча урыс хатыны белән яшәвен дәвам иттерә. Бу мотив Хөсәен Габдүш хикәяләрендә дә гәүдәләнеш тапкан. «Орлыклар» әсәрендәге Мохтаров та марҗасыннан аерыла алмый. Аның да рухына акылы түгел, хис-тойгы хуҗа. «Алданумы?» хикәясендәге Ниязның да күңеле урыс кызы Людмилага төшә. Әмма әкренләп татар кызлары Гөлйөзем, Мәрфуга, Зөләйха, Фатыймаларның Лидия, Людмила, Наташалардан һич ким булмавына төшенә бара. Людмилалар белән мавыгуның яшьлек шаукымына гына бирелү икәнлеге әсәр контекстыннан ачык аңлашыла.

Х. Габдүш гадәти нәрсәләр, һәркемгә таныш вакыйга-хәлләр турында укучыны кызыксындырырлык итеп яза белә. «Өйләнмәклек ыгы-зыгысында» исемле юмористик хикәядә, мәсәлән, гомумән кешеләргә хас булган эш-гамәлләр, сыйфатлар үтемле рәвештә бәян ителә. Әсәр героеның «Фәлән әфәнде» дип аталуы да юкка гына түгел. Ул, күпләр кебек, хатын-кыз белән таныша, ярата, гаилә кора, балалар үстерә, тормышын алып бара, олыгая. Аның татар икәнлеге, милләт рухы белән бәйләнеше сүз-сурәтләрдә дә, холык-фигылендә дә ярылып ята. Автор, ничектер, хәят-тереклекнең ямен, тәмен белеп яза.

Хөсәен Габдүш хикәяләрендә гыйбрәтле язмышлар, драматик вазгыятьләр шактый. Бу яктан аеруча «Яр читендә» әсәре игътибарга лаек. Укуга, белемгә омтылыш татар егете Габделбарыйны ерак Америкага китереп ташлый. Әмма көне-төне эшләүне, укуны аның организмы күтәрә алмый, егет теге дөньяга вакытсыз китеп бара. Камиләдә дә белем алу, милләткә лаеклы кеше булу дәрте гаять көчле. Бу фидакяр кыз бераздан әнисез дә, абыйсыз да япа-ялгыз торып кала. Идел-йорттагы ачлыкның аянычлы күренешләрен тасвирлавы белән дә бу хикәя Г. Ибраһимовның, Ф. Әмирханның шул темага язылган әсәрләренә билгеле бер дәрәҗәдә аваздаш.

Хөсәен Габдүшнең «Үзебез өчен» әсәренең төп сюжет сызыгын Октябрь инкыйлабы чорында Сөембикә манарасыннан Рәсәй империясенең гербын — «орел»ны алу вакыйгалары тәшкил итә. Хикәя аркылы без шул көннәрнең катлаулы тарихи вазгыятен шактый дәрәҗәдә күз алдына китерәбез.

Татар әдәбияты Ватанда, Идел-йортта гына түгел, чит илләрдә дә билгеле бер дәрәҗәдә үзенең яшәвен, үсүен дәвам иткән. Башында Гаяз Исхакый торган мөһаҗир әдипләрнең тәүге сафында Хөсәен Габдүш тә үзенә лаеклы урын алып тора. Аның каләмдәш дусты Солтанның (Әхмәд Виргаз) «Хөсәен Габдүшкә» исемле мәрсиясе (1944) болай яңгырый:

Син безгә милләт өчен кирәк идең,
Синең кебек милләт сөюче сирәк иде.
Күңелеңдә янып торган милләт уты
Безнең өчен һәрвакытта үрнәк иде.

Каләм белән бизәкләдең телебезне,
Ил белән багладың син күңлебезне.
Чит илләрдә, ерак илдә яшәсәң дә,
Милли эшкә чакыра идең бит син безне.

Күңел әрни: сине бүген югалттык без —
Милли тәсбих төймәсеннән өзелдең син.
Милли иман көчле иде күкрәгеңдә.
Милли эшче, милли көрәшче син идең — син.

...Милли юлда калдырган синең эшләр
Безнең өчен һәрвакытта үрнәк булыр.
Шома телдә синең язган хикәяләр
Милләт белән бергә яшәр, илһам бирер.

Хөсәен Габдүш белән еш аралашкан, анда укыган Рокыя Дәүләткилде бу зат хакында болай яза: «Харбиннан Хөсәен Габдүш күп кенә хикәяләрен «Милли Байрак»ка юллый иде. Сәяси мәсьәләләргә кагылмый иде.

Хөсәен Габдүш бик сәләтле журналист һәм әдип иде. Аның язмалары урыс эмигрант басмаларында да чыга иде.

«Милли Байрак»ка даими эшкә килергә бик тырышып димләп карасак та — килмәде. ...Ул артист һәм бай тавышлы җырчы иде.Үз истигъдадына (сәләтенә; талантына.— *Х. М.*) киң өлкә булмау аркасында бу зат мөһаҗәрәттә әрәм булды. Аның ата-анасы булмаган, бер бай тәрбиясендә булып, мөһаҗирлек бәхетсезлегенә эләккән»*.

Укучыларга без Хөсәен Габдүшнең берничә хикәясен тәкъдим итәбез. Аларның «Алданумы?» «Яр читендә», «Орлыклар», «Мылтыклы хикәя» дип исемләнгәннәре 1931 елда Токиода дөнья күргән «Дүрт хикәя» атлы җыентыгыннан алынды. Калганнары — башка чыганаклардан. Гарәп графикасындагы текстларны хәзерге язуга күчергәндә, төп чыганакларның язылыш үзенчәлекләрен, редакцион үзгәрешләр кертмичә, мөмкин кадәр тулырак сакларга тырыштык.

*1998*

## Алданумы?

*Бу хикәя иптәшем шагыйрь*
*Казанлыга багышлана.*

Беркөнне «Италия»дә ак кыз күренмәде.

Нияз кергәндә, ул анда юк иде. Каһвәне (кофены.— *Х. М.*) икенче бер туташ китерде. Болай, кая да булса берәр җиргә вакытлы гына чыгып киткәндер, дип уйлады Нияз. Ул, ишек ачылган саен, Людмила түгелме дип, аны көтү белән интегә башлады.

Людмила килмәде.

Егетне хәсрәт чолгады. Ул газаплана иде. Шундый авыр иде аңа бүген, ул шундый борчылды... Минә ничек була икән аның юклыгы, аны күрми торуы, ансыз булу!

Төн каплады Ниязның күзләрен — аларга нур бирүче Людмила «Италия»дә юк иде.

Аның йөрәк төбендә бернәрсә бик озак сызлады. Җылак иде ул нәрсә, ятим иде.

Ул өстәл янында бик озак утырды. Ул көтә иде әле Людмиланы. Аңа хәзер, Людмила булмагач, бөтен дөнья да аның кебек үк кайгылыдыр, күңелсездер төсле тоелды.

«Италия»дә кич булды.

Килмәде, килми иде Людмила — Нияз яраткан ак кыз!

Нияз аны шагыйрьләрчә яратып китте. Оҗмах булды кечкенә генә каһвәханә «Италия». Ә Людмила — Нияз яраткан ак кыз — оҗмах кошы.

Егет һәр көнне сәгать унике тулгач та анда, «Италия»дә була. Буш өстәл янына барып утыра да, Людмиланы чакырып, төрекчә әзерләнгән каһвә сорый. Кыз китә. Кечкенә генә чынаяк тотып, тагын Нияз янына килә. Нияз тилмереп кенә карагач, кыз да аңа җылмаеп куя, бик матур итеп аз гына көлә дә икенче өстәлләр янына таба тагы китә.

Нияз нәфис һәм бик юка читле чынаяклар ярата. Ул шундый, үзе яраткан чынаяк белән бирелгән каһвәне, сәгатьләр уздырып, Людмиладан күзләрен алмыйча, акрын гына, тәмләп кенә эчә.

Барыбер, Людмила аңа карыймы, юкмы яисә икенче өстәл янындагы кунакларның йомышларын үтәп, аңа аркасы белән торамы — Нияз аның һәрбер адымын карый, һәрбер итенешен үбә (кыланышын хуплый.— *Х. М.*), көлмәк сызыкларын, чәч бөртекләрен иркәли; күңеленнән аның бүген үз янында булуына, аның дөньяда яшәвенә сөенә. Аз гына пудра сөртелгән түгәрәк ак йөзенең үзенә таба борылып, күзләренең нур чәчүләрен, җылмаюларын көтә.

Бәхетле «Италия»дәге Нияз. Нинди рәхәт аңа анда! Матур, бик, бик сөйкемле андагы Людмила, ак йөзле кыз...

Гыйнвар узды, аның артыннан — февраль. Йомшак март иде инде. Нияз беркөнне Людмиладан чәй сорады. Туташ кулына стакан тотып килә иде. Ниязга күрше өстәл янында утыручы берәү терсәге белән ялгыш стаканны бәреп җибәрде дә, кайнар чәй кызның уң кулына түгелде.

— Ой! — дип җибәрде ул. Йөзе борчылып китте. Күзләре рәнҗеделәр.

— Ah! — диде егет. Урыныннан торды. Ни эшләргә, ни әйтергә белмәде. Әйтерсең кайнар чәй Людмиланың кулына түгел, егетнең йөрәгенә түгелгән иде.

Җитмәсә, аны кызганучы да юк бит! Каһвәханә хуҗасы да, утырганы утырган, ичмасам, йөзен дә чытмады!

Людмила икенче стаканны тотып, тагын Нияз янына килде.

— Авыртамы кулыгыз? Миңа сезгә караганда авыррак булды. Үз кулыма түгелсә, болай ук булмас иде.

— Рәхмәт сезгә. Юк, берни түгел. Бетәр.

— Туегызга кадәр бетәр! — диде теге терсәге белән кагылган кеше.

Егет шул вакытта берничә мәртәбә Людмиланың кулын тотып куйды. Кеше мондый вакытта песи баласын да кызгана бит.

«Италия»дә утлар сүнгән, кизү (каравылчы.— *Х. М.*) булып бер генә лампа калган иде. Людмила да килеп чыкты. Аның өстендә күк язгы пальто, башында юка гына җиңел шарф иде. Урамдагы фонарь яктысында Нияз аның йөзен бик ачык күрде: кечкенә авызлы, күзләре караңгыда кара иделәр.

Туташ чыккач та уңга борылды. Аның кызу адымнарына караганда, ул эштән бушавына шатланган, тизрәк өенә кайтырга ашыга иде.

Нияз да, аны куып җитәр өчен, тизрәк атлый башлады. Куып җитеп, бер чат барды. Бер-ике кат аңа эндәшмәкче булган иде дә булдыра алмады. Ахырында әйтте: «Людмила!»

Авыр да, рәхәт тә иде шул исемне әйтүе! Шуны әйткәч, егетнең күкрәге йомшарып китте.

«Матур нәрсә кыен була»,— дигән юнан хакиме. Шулай икән шул: кич буе «Италия» читлегенә ябылган кызны көтеп, инде ул чыккач та, аның артыннан менә дәшәм, менә дәшәм ди-ди, ике чат җир барган Ниязга җиңел идемени шул матур исемне кычкыру?

Юк, бик тиз генә әйтә алмады ул аны. Хәтта бер минут булды, ул бу исемне әйтүне иртәгә, тагын да бер азаплы төн, йокысыз сәгатьләр уздырып, әйтергә калдырырга булып борылырга да уйлады.

Кыз: «Йә!» — диде.

— Сезне озатырга мөмкинме? Сез өегезгә кайтасызмы?

— Әйе, өйгә.

— Урамда бераз йөрергә теләмисез?

— Юк, бик ардым. Мин йөрмим дә...

— Алай булгач, рөхсәт итегез, мин сезнең белән өегезгә чаклы барыйм.

— Рәхим итегез.

Алар бергәләшеп киттеләр. Бер чаттан борылып аз гына бардылар да, Людмила тәбәнәк кенә бер йорт каршысына килеп җиткәч туктады.

— Рәхмәт сезгә, мин шунда торам.

Ниязның ышанасы килмәде: мөмкинме соң! Кайчаннан бирле ул аның белән күрешергә теләде. Аның белән бергә баруны, очрашу минутын, аның көлүен күз алдына китереп, аңа әйтәчәк матур сүзләрне уйлап, ничә көннәр уздырды — инде хәзер, төш өнгә әверелгәч, ул «хуш» ди!

Имеш, аның фатиры шунда! Соң нигә хәзер үк кереп китәргә? Апрель киче нинди йомшак, һава нинди җылы, тегендә урам очындагы озакламый яфрак ярырга бөреләнгән бакча эчендә нинди аулак,

шундый бер шигъри тынлык... Ичмасам, бер генә минут шунда барып сөйләшсеннәр инде! Яшь егет йөрәгендә шул матур кыз өчен туган хисләрнең берсен генә булса да аңа, кара күзле, зифа буйлы Людмилага әйтеп бирсен!

Аптырагач, ни дияргә белмичә һәм үзенең дөньяда бердәнбер теләге булса, ул да кыз белән ничек тә булса озаграк тору икәнлекне, бәхетне аның матур күзләренә карауда дип белүен аңлата алмыйча:

— Хуш булыгыз,— диде. Людмиланың бала кулы шикелле, кечкенә генә йомшак кулын кысты.

Туктамыйча, бик озак яңгыр яуды. Күктән төшкән тамчылар шундый күп иделәр, исәпсез бер урам бөтенләй инешкә әверелде. Өй түбәләре, морҗалар, урамдагы кешеләр, ат, арба, автомобильләр әйтерсең бер дә кипмәслек булып юешләнгәннәр иде.

Кичкә таба, караңгы төшә башлагач, түбә тимерләре тагын да катырак зарлана башладылар. Әллә кайдан бик зур ачу белән кап-кара болыт килеп чыкты да туп-туры шәһәр өстенә карады. Аның төсенә, ямьсез тавышына караганда, таш яисә тимер явуы көтелә иде. Ләкин ул, киресенчә, ачу итү урынына зур-зур яшьләр белән җылый башлады.

Фонарьлар — урам күзләренең утларына чаклы әйтерсең юеш иделәр. Гүя ут яктыртмый, яңгыр суы үзе шулай, ут кебек, җир өстендәге күлчекләр, су җыентыклары өстенә яктылык ташлый иде.

Нияз, өч катлы биек бер йорт капкасы астына килеп, судан качты. Юеш «Италия» тәрәзәләре аңа күренеп тора иделәр, димәк, Людмила анда әле.

Әнә ул... Зонтиклы берәү килә. Ул, ул! Ничәнче тапкыр инде, каһвәханә ишек башындагы лампа сүнгәч тә, тормышның һәрбер тармагында әкият күрергә яратучы егет шатланып китә. Бүген дә шулай.

— Людмила! — диде Нияз. Үзенең күңелен шигырьләгән кыз исемен бу юлы да тиз генә әйтә алмады. Акрын гына әйтелде. Юнан фәйләсуфы әйтмешли, дөрес шул, читен була икән матурлык.

Егет озатып куярга рөхсәт сорады. Бала күк булган иде ул. Ул көн буе, Людмилага әйтергә дип, матур сүзләр хәзерләде. Аны күргән минутларында алган кыйммәтле хисләренә охшаган, аның күзләре, чәч бөртекләре төсле ямьле сүзләр, исемнәр эзләп, шуларның һәрберсен аңа сөйләмәкче булды. Күңелендә шул сүзләрне энҗеләр кебек тезеп, бөтен көнен бер әкият ясап үткәрде.

— Людмила, сез миңа ошыйсыз! Шул сүзне әйтү өчен, ничә көннәр кирәк булды. Шуны сезгә белдерү өчен, ничә көннәр «Италия»гә йөрдем. Мин күптән шулай... сезнең өчен генә йөрдем.

— Шулаймы? Әйдәгез, тизрәк... Тагын ява башлады. Миңа бүген өйгә тизрәк кайтырга кирәк.

Людмила ашыкты. Яңгыр туктамады.

— Соң кайчан, кайда иркенләп сөйләшә алырбыз?

— Хуш, сау булыгыз! Мин үзем әйтермен, бу атнада кайда булса барырбыз.

Нияз, шәһәр китапханәсенә барып, Шекспирның бүген сәхнәгә куелачак «Мәхәббәт фаҗигасе»н алып кайтты. Аны бер утыруда укып та чыкты.

Бу юлы опера өчен шәһәрнең зур театры «Олимпик» сайланган иде. Бу Нияз тора торган җирдән ерак түгел, шуңа күрә ярлы егеткә трамвай өчен арттырырга кирәкми. Алдан ук алып куелган бу билет аңа арзан төшмәде: ике көнлек кайнар шулпа, бер кичлек «министрларча шницель» шунда кереп китте.

Театрның ишекләре зур китап төбе шикелле авыр иделәр: Нияз шуны ачып керүенә каршында: «Бүген кайбер сәбәпләргә бинаән (сәбәпле.— *Х. М.*) уйналуы игълан ителгән «Ромео һәм Джульетта» урынына «Севилья чәчтарашы» уйналачак» дигән сүзләрне күрде.

Ни эшләргә: керергәме, юкмы? Керергә булды — кайвакытта шундый көтелмәгән әйбер кызыклырак та булып чыга.

Чишенде. Залдагы көзге алдына барып, чәчләрен тарады. Муен бавын (галстугын.— *Х. М.*) төзәтеп, кесәсеннән билетын алды. Аңа опера увертюрасыннан ук ошый башлады. Фигаро ариясен бик яратты.

Чарлакта (сәхнәдә.— *Х. М.*) кыз ролендә уйнаучы, исеме дөньяга танылган атаклы артистка җырчы күренде.

Икенче пәрдәне тыңлау — артистканың тавыш серләрен ишетү — Ниязга бүгенгәчә тиңе булмаган шатлыклар бирде.

Белми, оныткан ул менә шушы минутта, икенче пәрдәдә дә җырлаган артистканы тыңлаган минуттагы кебек үзенең бәхетле булуын. Туганнан бирле беренче кат ул музыка-җырдан шундый ләззәт алды.

Җырчы үзенең ефәк тавышын шундый уйната, шундый шаярта иде, Нияз, аны тыңлаганда, бөтен барлыгы белән матурлык кына тулган бер«бөтен»гә әверелде. Әйтерсең, тәннән аерылып, Ниязның җаны гына калды.

Кайда яткан ул? Кайда яшәгән?

Җырчы һаман җырлый, тамагы белән тавыш чәчәкләре үстерә... Аларга шигъри сулыш өреп җан бирә иде. Егет, ул җырлаган саен, тыштан хәрәкәтсез кала бара, бөтен ноталар — җырчы күкрәгеннән сибелгән энҗеләр — Ниязның күкрәгенә җыела иделәр.

Бармы аның кайчан да булса, бүгенгедәй, җырчыдан күзен алмыйча, опера тыңлаганы? Юк, беренче кат ул бүген генә музыка шигыренең очына менде. Аның дөньядагы көчләрдән көчле серләрен аңлады. Үзенчә аңлады. Ул үзен таныды... Тормышның тирән бер мәгънәсен, үзәген ачкандай булды.

Бигрәк тә оста җырчы, сөю уты өстендә очучы күбәләк төсле, бер кыз булып итенгәндә, үзенең тавышы белән Ниязга бетмәс-төкәнмәс бер шатлык китерде.

Шундый оста уйнады ул бу рольдә, залны алкыш диңгезе тутырды. Җырчы тагын кабатлады.

Урамда җил, ап-ак кар комыннан дулкыннар ясап, һаман котыра. Аның үз музыкасы, үз тавышы, үз җыры иде — кыш операсы.

Нияз, «Олимпик»тан чыккач, якасын күтәреп, күкрәген каплады: җил бу кич артистка биргән бүләкләрне аның күкрәгеннән очырмасын. Бүреген басыбрак киде: гүя башында туган дөнья, серле тавыш өреп яраткан җиһан, шулай итмәсә, җил белән җимереләчәк, юкка чыгачак иде.

Бүлмәсенә кайтып чишенгәч тә, кечкенә генә ялкынлы шәм яктысында ул тиз генә яза башлады: «...сайрый!»

Татар теле, әле дә ярый синең шундый матур бер сүзең бар — сайрый. Юк исә мин нинди сүз белән, нинди каләм белән аңлатыр идем бу кич ишеткән тавышны. Кеше җырлый — кош кына сайрый.

Бүген мин ишеткән артистка коштан да остарак җырламады, юк! Сайрады!

Нинди тавыш, нинди уен! Никадәр зур осталык! Юк, адәм баласы шулай сайрый белгәч, мөмкин икән әле дөньяда торырга.

Бу кич — минем тормышымда бердәнбер якты кич. Бүген сафлык, йомшарган күңел: йөрәгемдә нечкә, ефәк шикелле, йомшак тойгылар.

Бу шатлыкны миңа беренче мәхәббәт тә бирмәде. Беренче сөюем, беренче кат сөю биеклекләренә ашкынуым да йөрәгемә андый бер хис танытмады.

Тик бүген, бу кич аңладым мин: без аңлаган мәхәббәттән дә көчлерәк бер мәхәббәт барын, без аңламаган дөнья барын, бөек уйлар, күп-күп яшерен серләр, тойгылар, утлар, өметләр барын...

Ярабби, калсын хәзерге минутта йөрәгемне эреткән тойгылар! Иртәгә, иртә белән үк «чын» тормыш кешесе булып уянгач та, алар инде юкка чыкмасыннар, югалмасыннар!

Әйтәләр: Тукай үз гомерендә бер мәртәбә дә опера күрмәгән. Беләм, аңлыйм хәзер, шагыйрь өчен бу — нинди зур югалту. Әгәр ул, ятим яшәгән татар шагыйре, бүген мин ишеткән тавышны, җырны тыңласа иде, шундый шатлыклы, шундый өметләр җыйган бер әсәр калыр иде аннан — бәһасез!

Бүген мин шатлык сизәм. Тормышның шигырен төшенеп, бөтенләй башка дөнья аңлыйм, энҗеләр сибелгән юл күрәм!

Шәһәрнең бөтен эшчеләре йоклаган ярлы бер читендә ялгыз егетнең төн уртасында шулай, шәм яктысында утырып, кәгазь өстенә хис коюы матурлыкка булган гыйшыкның чиге, бу матурлыкка багышланган бер гыйбадәт иде.

Шуннан соң ул «Фауст»ны, «Кармен»ны, «Риголетто», «Травиата» шикелле операларны барып тыңлады. Аларның кайберендәге музыканың тагын да тирәнрәк, тагын да югарырак икәнлеген аңлый башлады.

Яз якынлашты.

Күк битендә икенче, йомшарган, җылы карашлы кояш иде инде. Нияз озакламый шәһәрдән Европага китәчәк артистканың соңгы кичәсенә барырга әзерләнде.

Бөек артистка французча бер пәрдәлек оперетта сайлаган. Исеме — «Сюзаннаның сере».

Ниязның урыны бу юлы «Апуллу» театрында, әлбәттә, артта иде; ул да әле бер көнлек эш торды.

Өстәвенә шуны да әйтеп узарга кирәк: аның кыш урталарында бертөрле, ярыйсы гына булып күренгән киеме матур яз көннәрен ертылган, тузган көенчә каршы алды.

Гомумән, бу егет бик ярлы тора иде. Аның бөтен килере хосусый дәресләр бирүдән җыела иде. Ул гомеренең чәчәк шикелле ике елын — егерме бер, егерме икенче яшьләрен — тар, кечкенә һәм бик караңгы бер бүлмәдә үткәрде.

Кемдер бер француз язучысының бүлмәсен күргәч әйткән бит:

— Дөньяга иң шат караучы шагыйрьне дә үзен үзе үтерү турында гына уйлатырлык иде бу бүлмә.

Бервакыт Ниязга иттифакый (очраклы.— *Х. М.*) гына килеп кергән кунак та (инде бу сукбай көнендә яшәүче кеше һәрбер җиһазга ияләшкән булырга тиеш иде), бүлмәгә килеп кергәч, исе китеп, артка чигенде.

Менә шуңа, ярлыга күрә, Нияз «Сюзаннаның сере»н белергә бер иптәше биреп торган яңа киемнән, өстенә ул биргән күлмәкне киеп, муенына аның ефәк муенбавын бәйләп килде.

Әле пәрдә күтәрелер алдыннан гына ул: «Нигә минем бүген кәефем яхшы?» — дип үзенә үзе сөаль бирде. Беленде: сәбәбе яңа киемнән булу икән; шул аны җиңеләйткән, Гаеткә киенгән бала шикелле ясаган.

Биюче кызлар төшерелгән зур рәсемле пәрдә ачылды. Нияз сәхнәдә бик матур бүлмә, тәрәзә алдылары (төпләре.— *Х. М.*) тулган гөлләр, чәчәкләр, йомшак урындыклар, ефәк тышлы мендәрләр күрде.

Башта баритон чыгып җырлады. Аннан соң җиңел уйлы, шат француз хатыны ролендә уйнаучы артистка килеп чыкты. Нияз тагын бу хатынның тавыш сихеренә бирелде. Аның йөрәге тагын бу тавыштан шигырь имде.

Егет, инде театрга еш кына йөреп, җырчы хатынның тавыш серенә бик якын төшенде. Бу тавыш кайгыны бик аз сөйли, ул күбесенчә шатлык күгендә оча, тормыш бакчасының күңелле, дәртле, бик җиңел моңлы һәм матур мәгънәле яфракларына гына кагыла иде.

Аны тыңлаганда, Ниязның күз алдына күбрәк аяз, ачык зәңгәр күкле җәйге көн килә. Матур гына түгәрәк күл өстенә шул көннең кояшы үзенең хыялый бер рәсемен ясаган; камышлар читендә күңелгә тынычлык бирә торган күләгәләр ята; күлнең арты — очсыз-кырыйсыз киң дала; уртада — эссе көннәрдә аяк табаннарына рәхәтлек бирә торган салкын каз үләне белән бизәлгән озын юл; аның очы әллә кая, еракка ук, тирәнлеккә китеп югалган; бар җирдә җан, бар җирдә гүзәл бер тормыш сулышы; күңел, тилгән кош шикелле булып, салмак кына шул дөньяның өстеннән йөзеп, үзенә кирәкне сайлый, матурлык таба... күңел, тургай булып, болытларга менеп төшә, балык булып, зәңгәр су өстен чәп итеп үбә, камыш күләгәләрен, судагы кояш тәңкәләрен, ашлыкларны, урман араларын ефәк музыка җепләреннән тукылган шигъри пәрәвез каплый... Ямь, яшьлек, мәңге бетмәстәй тәмле уй!

Людмила килгән!

Әнә ул хәзер генә алдагы урындыкларның берсеннән кузгалып китте. Үзе генә. Гаҗәп: белмәгән кеше яңлышыр да — алар, артистка белән Людмила, бер-берсенә ике каш шикелле охшаганнар.

Егет аның янына барды.

— Сездә минем бер үтенечем бар, мөмкинме?

— Рәхим итәсез!

— Әйдәгез, йөрик бераз залда.

Концерт инде беткән, карау залында бу вакытның соңгы биюе — фокстрот башланган иде.

— Минем үтенечем шул: сез миңа рәсемегезне бирә алмассызмы?

— Нигә ул сезгә? Ни өчен кирәк?

— Людмила, сез беләсез инде, онытмаган булсагыз, хәтерегездәдер.

— Ярый, мин сезгә вәгъдә бирәм.

Әле бераз йөрергә дә мөмкин иде, буш урындыкларның берсен алып сөйләшеп тә утырырга. Тик Нияз ни өчендер тиз генә:

— Рәхмәт! Гафу итегез, мәшәкатьләдем сезне,— диде дә Людмиладан аерылды.

Моның өчен эчтән бер тавыш аны үчекли башлады: «Их, син егет! Башка берәү булса, әллә кайчан инде бу кызны, уен беткәч тә, ресторанга, кабинетка алып китәр иде. Ә син йөрисең үзеңнең фәлсәфәң белән, шигырең, хисләрең белән. Кем дип уйладың ул «Италия»дәге хезмәтче хатынны! Андыйлар шәһәрдә йөзәрләп...»

Җәй узды.

Яшьлек көннәре дә үтә баралар, мәңгегә кайтмаска...

Көз керде…

Җилле яңгыр иде. Таланган агачлар...

Пычрак өстенә, канатсыз кош шикелле булып, сап-сары яфрак ятты.

Ачулы иде бу вакыт. Ул нигәдер үсемлекләрдән, шаулаган агачлардан, гөнаһсыз чәчәкләрдән үч алды. Аларны изде, үтерде, җан кыйды.

Ниязның кулында Парижның «Иллюстрацион» журналы иде. Ул аны укымый, болай бер битен генә ачкан да, шуннан күзләрен алмыйча, бик озак карап торды. Анда ни бар? Артык бернәрсә дә юк. Фәкать бер рәсем, хатын рәсеме генә. Аның күзләре егеткә матур мәгънәләр, шигырьләр сөйлиләр. Алар, ияләренең (?) җырлары шикелле, тормышның җиңел бизәкле, шат вә кайгысыз серләрен әйтеп бирәләр. Артистканың үз тавышы кебек сайрыйлар.

Шул рәсемгә караганда, аның күз алдында сөю тойгылары шикелле нәзек, ефәксез кыллар, шәүләләр үтә; болар — алга таба өмидләр, бәхеткә таба юллар, имеш...

Шул ук вакытта әнә диварда икенче бер рәсем. Анысы да — хатын-кыз рәсеме.

Нияз журналны бик кадерләп кенә бер читкә куйды да соңгы рәсемгә күзләрен төшерде. Аның белән сөйли башлады:

— Әйе, Людмила, мин менә шунда торам. Берүзем, япа-ялгыз шунда торам. Миңа бик күңелсез була. Минем, көзге көндә урманда адашкан кеше кебек, дөньяда миннән дә бәхетсез кеше юк, дип уйлаган бик-бик авыр минутларым була. Әйдә, икәү бергә торыйк. Син дә минем белән менә шушы бүлмәдә тор. Мин сине яратырмын...

Егет караватына килеп ятты да уйларында дәвам итте:

— Чынлап та, мин аңа өйләнсәм! Ул минем хатыным булса... Мөмкинме соң?! Ул бит рус кызы... Менә шуларны уйлыйсы булмаса иде. Аның руслыгы, минем татарлыгым хакында бернәрсә дә уйланмыйча, шулай үзеннән-үзе килеп чыксын иде. Болай, бергә кушылдык та, бәхетле булдык та киттек...

Бу ике сурәт — берсе, дөньяга мәшһүр җырчы, җанлы бер илһам буларак, егетнең күңелен моннан, Маньчжуриянең мәркәзеннән, Парижга, мәдәни Европага; икенчесе, бер хатын гәүдәләнгән җир бәхете буларак, аның йөрәген үзенә тартып, аны моңлы бер карарсызлык вә азапның шагыйре иттеләр. Бу соңгысы да шул шигъриятнең кызганыч бер тоткыны булып бара иде.

Беркөнне Ниязга мөгаллим Рамазанов очрады: «Әйдә,— диде ул.— Мин сине эзләп йөрим. Бүген Әсма туташларда яшьләр мәҗлесе. Менә записка. Киттек!»

Мәҗлестә аларның икесен дә бик шатланып каршы алдылар. Нияз, эшләпәсен алдынгы бүлмәдә калдырып, зур кунак бүлмәсенә кергәч, танышлары белән күрешеп, утыру өчен озын өстәл янындагы урындыкларның берсен алды.

Мәҗлес иясе — Әсма туташ — күрше бүлмәдәге кунакларны чакырып чыгарды да игълан итте:

— Бер туташ янына бер кавалер утыра. Рәхим итегез өстәл янына!

Ниязны Сәлимә исемле бер туташ белән бергә утырттылар. Бу — юаш кына бер туташ, күп сөйләшергә яратмый торган бер кыз иде. Ул:

— Кәефләрегез яхшымы? — диде.

— Хәер-фатихагызда,— диде Нияз. Иренеп кенә шаярып куйды. Туташ та, әлбәттә, бу сүзгә каршы әйтелә торган җөмләне әйтмичә калмады:

— И, минем фатихам белән бик ерак китәрсез инде.

Өстәл өсте ямьсез түгел иде, чит-читендә кайнар чәйле стаканнар тезелгәннәр, ике башта вазаларда алмалар, җимешләр, чикләвекләр. Уртада инде, үзенә муафыйк урында — җиләк бәлеше.

Кунаклар бик кыстатмый иделәр. Чәй эчү, чикләвек чиртү бик тизлек белән гамәлгә куелды. Бер гимназист алма әрчергә тотынды.

Өстәлнең Ниязга каршы почмагында Рамазанов янында утыручы кара кыз: «Нияз әфәнде! — диде.— Ни эшләп утырасыз, туташыгызга алма әрчеп бирегез».

Нияз аны тыңлаган булды. Бер алма алып, аны бик оста гына итеп әрчеде дә аны янындагы күрше туташына тәкъдим итте:

— Рәхим итегез. Ухажер буларак җитешмәгән җирләрем булса гафу итегез!

Мәҗлес күңелле генә иде: ашыйлар, эчәләр, сөйлиләр... Ләкин Нияз гына бу ашаучылар, көлүчеләр төркемендә үгилек хис итте.

Аның эче поша иде. Аның күз алдында һаман Людмила иде; мәҗлестәге туташларның берсе дә аңа охшамаган, гүя алар Людмила кебек сөйли дә, итенә дә белмиләр иде.

Бу нинди бизү, нигә аңа кунак кызларының берсе дә ошамый?!

Чәй эчелә барды. Яшьләр арасында алма, мандарин кабыклары белән бер-берсенә ыргытышып уйнау китте.

Бер туташ янындагы егеттән зарланды:

— Ухаживать та итә белмисез, ичмасам!

Егет кызарып китте:

— Рәхим итәсез, рәхим итәсез! — ди башлады.— Ни кирәк сезгә, Фатыйма туташ? Алмамы? Чикләвекме? Конфетмы? Тагы берәр стакан чәйме?

Туташ:

— Җә! — дип сузып куйды, иреннәрен күрсәтте.— Кеше чәй эчеп беткәч сыйламыйлар аны. Соңгарак калдыгыз!

Чәйдән соң яшьләр икенче бүлмәгә чыктылар. Рамазанов кулына мандолин(а) алды. «Зиләйлүк»не уйнады. Бер туташның җырлавын үтенә башладылар. Бик кыстатып кына җырлаган булса да, аның тавышы Ниязда бер кызгану хисе генә уятты.

Бүлмәнең почмагында бер гимназистка һәм татар мәктәбендә генә укып чыккан бер кыз утыра иделәр. Соңгысы иптәшенең беләген чеметкән булса кирәк, гимназистка «чыр-р!» итеп кычкырып җибәрде: урыныннан кузгалып икенче бүлмәгә чыгып китте.

Чирек сәгатьтән соң кунаклар «Римский папа» уенын башлаганнар иде инде, Нияз белән Рамазанов Әсма туташка рәхмәт укып кайтып киттеләр.

Нияз бүген Рамазановта кунмакчы булды. Урамга чыккач, соңгысы: «Әйдә, берәр җиргә барып утырыйк»,— диде. Нияз, билгеле, моңа каршы килмәде:

— Әйдә, барабыз. Хәзер сезгә барсак та йоклап булмас. Өстәвенә чәйдән соң ашыйсы да килә.

Икесе дә «Себер» ресторанына барып керделәр. Ресторан күренеше тагын Ниязның күз алдына «Италия»не, андагы Людмиланы китереп куйды.

Рамазановның тәкъдиме буенча, аш алдыннан гына дип «берәр» әйтелгән иде дә, утыра-утыра ул «икешәр», «өчәр»гә җитте.

Бик начар бер скрипкачы белән гармунчы нindiдер рус көе уйныйлар иде.

Ниязның «башына китте», кычкырып сөйләргә тотынды. Аш килгәнче, ул татар кызы турында сүз башлаган иде, Нияз тагы шуңа күчеп, сүзен куәтләргә теләгәндәй, кулын өстәлгә бер куеп, бер алып сөйли иде.

— Берсен дә яратмыйм... Татар кызы янына бардыммы, сөйләшәсем килми. Сөйләшсәм дә, коры гына булырга тырышам. Барысы да җансыз, телсез күренәләр. Никтер, рус кызы җанлырак та, кызыклырак та...

Рамазанов аңа каршы сөйләп карады:

— Гаеп үзебездә. Үзебез читтә торабыз...

Алар «Себер»дән ресторан ябыла башлагач кына чыгып киттеләр.

Мәҗлестән соң ике атна узгандыр, Ниязның кесәсендә бер тиен бакыр калмады. Юк, әҗәл даруына да юк!

Эш тә табылмый. Бурычка сорауны уйлама да инде: ышанмыйлар! Бүлмәсенең ае тулды да, чыгып китте.

Әгәр инде, Хода кушып, бәхетенә каршы гына берәр танышы очрамаса, бүген урамда куначак.

Хәер, зарар юк, август рәхимле генә күренә; төннәр дә суык түгел. Егет кешегә нәрсә: өйдә йоклады ни, урамда ни!

Өченче көнне дә бер генә кадак икмәк белән уздырды. Кичә дә ике помидор да тоз белән ярты кадак арыш ипие, ә бүген инде валчык та юк. Ни эшләргә?

Ачлык егетнең күңелен тутырды. Бөтен күңеле шигырьгә әйләнде. Дөрес, аның йөрәгендә кемнәргәдер билгесез бер үч, дошманлык кайный иде, күңелендә исә матур бер дөнья.

Уйлар бер-бер артлы агылып кына торалар. «Менә хәзер шуларны төшереп алсаң,— дип уйлады Нияз,— язып түгел, аппарат белән генә. Менә кайчан хакыйкать дөньяга килә икән. Ачның күңелендәге фикер һичбер «кушымтасыз» саф һәм чишмә суы кебек якты. Һәм бөтен бөек мәгънәләр оясы да — әнә шул ачлыкка, юклыкка интегүче кешенең күңеле».

Ашыйсы килә!

Нәрсә белән булса да туенырга кирәк. Бәлки, кытай кибетендә, кичкә чаклы дип сорасаң, бер кадак икмәк биреп торырлар? Бәхетсезлеккә каршы, булмады: кибетче чирек кадакны да ышанмый. Егет (ул бердәнбер чемоданын фатир хуҗасында калдырып торган иде) үзе торган йортка барды да әйберләре арасында китап тапты. Китап! Бу бит ике көнлек тормыш дигән сүз! Моңа ике көн сатып алырга мөмкин. Чынлап та, көннәр акчага сатып алынган шикелле бит. Бүген ачтан үләргә торган чакта, акчаланып китсәң, гүя шуңа әз-әзләп кенә булса да гомер сатып алырга була.

Нияз китапны алды да ашыга-ашыга базарга йөгерде — иске китаплар алучыга.

— Күпме?

— Бер тәңкә!

— Егерме тиен. Алсаң аласың...

— Кушыгыз инде тагын биш тиен — ашарга җитсен.

— Их,— диде китапчы рус эмигранты. Биш тиен бакыр белән егерме тиенлек кәгазь ташлап: — Их, безнең тормыш! — дип куйды. Кызганды, ахры.

Егетнең күңелендә нидер ачылып китте. Кальбенең (йөрәгенең.— *Х. М.*) ябык көенчә торган бер тәрәзәсеме, ишегеме, әллә инде капкасымы шунда... Бик киң ачылды.

Бер минут булды, ят бер тойгы тоелды: үзе һәм бөтен дөнья кинәт йөреп киткән кебек булды. Бөтен җир «барган» шикелле булды. Гүя әллә нинди тавышсыз кылларда «марш» көе уйналды да, шул көйгә бөтен урамнар, йортлар, арбалар, кешеләр, балалар ниндидер бер куәт алдында уза башладылар...

Тизрәк, тизрәк ашарга!

Егет «Италия»гә таба юнәлде.

— Нияз, Нияз, кая барасың? Шулчаклы ашыгып? Танымыйсың да.

Егет борылып караган иде, башына шәл ябынган бер татар хатынын күрде.

— Исәнмесез!.. Камилә абыстай икән.

— Кая киттең?

— Ашарга барам, Камилә җиңги... Ашарга.

— Урындамы? Нигә бер дә күренмисең? Безгә дә барып чыгарлар.

Хатынның күзләрендә ниндидер, көчсез генә булса да чакыру уты яна иде.

Егет үз-үзенә: «Нигә соң әле мин бу көнгәчә сине эзләп бармадым?» — диде. Ул, юри шаяртып кына:

— Әйдә, киттек. Хәзер ярыймы? — дигән иде, хатын шуны гына көткән шикелле:

— Әйдә, әйдә,— диде.

— Чәй эчертәсеңме соң?

— Анысын инде баргач күрербез.

Бу кер юучы тол хатын Ниязның күптәнге белеше иде. Элегрәк Ниязның керләрен дә юа иде. Берничә айлар була инде, Нияз аны күрми йөрде; бервакыт, исенә төшкәндә, әллә киттеме икән, дип уйлап куйган иде. Бүген очрашырга язган икән.

Алар бара-бара шәһәрнең халык кайнаган урамнарыннан шактый ерак киттеләр. Уң якта бер зур йорт калдырып, тар гына бер урамга борылгач, «җиңги», капкасы җимерек бер агач өй алдына туктап, арткарак калган кунагын көтеп алды.

— Әйдә, тизрәк атла аягыңны! Менә без шунда торабыз инде.

Нияз аның артыннан өй ишеген ачып кына кергән иде, аптырап китте: гармун тавышы, көлешкән, сөйләшкән тавышлар, кемнеңдер җырлавы, барысы бергә кушылып, аны каршылаган кебек булды.

Алдынгы бүлмәдә бер кеше дә юк, ишетелгән тавышлар каршыдагы бүлмәнең ачык ишекләреннән чыга иде.

— Сөбханалла! — диде Нияз.— Әллә сездә туймы?

Абыстай, шәлен сала-сала:

— Бездә һәр көн туй. Әйдә, уз, бу минем бүлмәм булыр,— диде.

Ачык ишек янындагы икенче, йозаклы бүлмә ишеген ачып, кунакны эчкә алып керде.

Ниязны матур һәм җыйнак кына бер бүлмә каршылады. Диварлар эремчек кебек ап-ак; агач карават, бер өстәл, артык матур әйберләр дә күренми, ләкин ничаклы илдәге бүлмәләргә, Русиядәге йортларга охшаган. Ап-ак мич, чуар карават чаршавы, кечкенә генә яшел сандык, корама торган, киҗеле ашъяулык, сөлге, кечкенә генә сары самовар... Соң бит болар барысы да илдәге шикелле. Мондагы тормышчыларның күбесендә мондый стиль юк. Әйтерсең Нияз Русиягә, өенә кайтты...

Егет, үзендә бер куану сизеп:

— Сездә бөтенләй «Рәчәйдәге» шикелле! — дип куйды.

Бу вакытта хатын башындагы шәлен ак яулыкка алыштырды. Аның яхшы юылып, яхшы үтүкләнгән күлмәге эченә тулы гәүдәсе яшеренгән, йөзе дә шулай ук тулы булып, бераз гына озынаеп киткән иде.

— Элек чәй эчәсеңме, Нияз, әллә бераз итем бар, шуны ашап, аннан соң чәй эчәрсеңме?

— Җиңги, инде мин синең ихтыярыңда. Теләсәң ни эшләтәсең! Икесен дә китер. Чәен дә, ашын да.

Ул арада булмады, бүлмәгә кып-кызыл, сипкелле йөзле таза гына бер егет килеп керде — изүе чишек Сәйфулла.

— И, үзебезнең кеше икән лә! Мин тагы, кунак бар дигәч... Кайдан килеп чыктың син, Нияз туган? Әйдә, туган, безнең янга! Монда берүзең ни эшләп утырасың? Камилә җиңгәй, кунагыңны безгә дә биреп торырсыз бит?

— Тукта, Сәйфулла, хәзер мин аңа аш бирмәкче идем. Бераз ашасын инде. Исерек Сәйфулла аңа ирек бирмәде. Ниязның кулыннан тотты:

— Әйдә, безнең янда ашарсың!

— Ну, ярар инде, алайса.

Кунакны өстәлнең нәкъ башына, буш калган урынга утырттылар. Мәҗлестәгеләр, берсеннән башка, барысы да Ниязга таныш егетләр иде: ач яңаклы, кара гына йөзле Биктимер, көләч чырайлы Муллаҗан — Колчакта хезмәт иткән солдатлар һәм бер ят сары мыеклы гармунчы.

Өстәлдәге тәртипсезлек белән Нияз бер караудa ук танышып алды: берсе бушаган, икенчесе башланып куелган аракы шешәләре, икмәк сыныклары, тозлы балык, кәбестә, кыяр, хәзер урыныннан китәргә торучы йоклаган самовар, чәнечкеләр, пычаклар...

— Ягез әле! — диде Сәйфулла, һәркемнең алдына аракы салып чыкты.— Берәрне пилмән алдыннан: хәзер пилмән килә. Нияз, син әле мактап йөрисең икән.

Кунаклар, инде эчкән кешеләр төсле булып өлгерсәләр дә, яңа килүчедән уңайсызланып булса кирәк, эндәшми тордылар.

— Ягез! — диде, извозчик көтә иде.

Иң элек Муллаҗан дигәне рюмкасын кулына алды:

— Булган-булган икән... исемегезне онытам, кунак, әйдәгез! — диде.

— Юк, юк,— дип карады Нияз.— Миннән булмый!

— Юк инде, туган! Алай барып чыкмый ул. Күп түгел — бераз гына.

Кыстау озакка сузылмады, барысы да берьюлы эчеп җибәрделәр.

Ниязның янында утыручы егет күршесенең стопкасына карап куйды: «Булмый-булмый, дигән иде дә, яхшы ук кына уртлаган!»

Сәйфулла, соңга калмаска тырышып:

— Менә, менә! — диде, Ниязның алдына тозлы кыяр сонды.

— Я, нигә уйнамыйсыз? — диде Нияз.— Әллә мин сезгә мишәйт итәмме?

— Син инде,— диде Муллаҗан.— Безнең янда утырсаң, туры гына утыр. Мишәйт булса, без сине чакырып та кертмәс идек.

Хуҗа икенчегә кыстый башлады:

— Ягез әле, кунаклар, тагын берәрне. Пилмән хәзер өлгерә. Маруся, ты там, поскорей, пожалуйста! Насчет пилмән то...

— Хәзер, не торопи! — диде күрше бүлмәдән маржа тавышы (Сәйфулла бер ел инде рус хатыны белән тора иде).

Бу юлы стопкалар җиңелрәк күтәрелделәр. Пилмән дә килеп җитте. Тәмәке төтене шулай күтәрелгән идеме, шулпадан күтәрелгән бу шулай ясадымы, Нияз өстәл өстен, кунакларның йөзләрен, ишек төбендә аларның «кызыгын» карап торучы Камилә җиңгине — барысын да матур томан, юка пәрәвезгә чорналган төсле күрә башлады.

Аракы аңа кыюлык бирде! Камилә аның күз алдында бик матур бер хатын иде. Ул аңа карап елмая, эченнән аңа рәхмәт укыйсы, торып битеннән үбәсе килә.

Күршесенә карады:

— Шулай диген, Биктимер! Я, ни хәлләр соң, эшләр кай тирәдә?

— Безнең эш билгеле инде...— диде дә егетебез кулына гармун алды: — Тукта, бераз тартып җибәрик әле.

Нияз шатлыгыннан ни эшләргә белмәде:

— Менә бу эшең ярый! — Уенчы, Ниязның яратуын бел-
гән кебек, иң элек «Баламишкин»ны әйттерде. Нинди матур такмак! Күңелнең буш җирләренә тыгызланып-тыгызланып тула.

Тимер икенче көйгә күчмәкче булган иде дә, Нияз аннан үтенде:

— Зинһар, туктатма әле. Уйна шул көйне!

Бая җырлаучы Муллаҗан булган икән, һаман ишек төбендә басып торучы Камилә абыстай:

— Я, ни карап утырасың, Муллаҗан, җырлап та җибәр инде! — диде.

Муллаҗан кинәт кенә нечкә тавыш белән борын аркылы җырлый да башлады:

Уфа таулары биек, йөри арыслан, киек,
Су сипмәгән гөлләр кебек йөрибез җанып, көеп.
Су сипмәгән гөлләр кебек...

— Их! — дип җибәрде Нияз. Гармун биргән хисләрнең барын да берьюлы сөйләп бирмәкче булды. Белсәләр иде, аның күңеле нинди бай хәзер! «Баламишкин», «Ижбулдин», «Салкын чишмә», «Бибкәй Әсма» — татарның шул көйләрендә Нияз аерым бер моң, татар күңеленә якын бәйләнүче аерым бер аһәң таба иде.

Менә кайда бәхетле минутлар: операң да кирәкми, дәүләт театрларыңның җырчылары да — берсе дә, берсе дә...

Моңлы күкрәк шикелле гөлдерәп торучы гармун гына уйналсын да, төне буе аның эченнән бертуктамый көйләр генә агып торсын. Рәхмәт Камилә җиңгәсенә: кайдан туры килде, Ниязны бу дөньяга алып килә белде!

— Рәхмәт,— диде егет.— Үтердең гармуның белән!

Уенчы егетнең аркасын какты:

— Уйна тагын! «Салкын чишмә»не!.. Озын көйләрне беләсеңме? «Кара урман»ны? Уйна, берсен дә калдырмыйча уйна...

Җырчы да туктамады:

Ак Иделнең аръягында акбүз атлар су тапмый.
Су тапмагач, үлән капмый, ялгыз башлар ямь тапмый.

Юкка гына Нияз бүген иртәдән бирле икмәк эзләгән: музыка кирәк булган аңа, музыка! Көйләр генә кирәк булган. Моң гына!

Рәхмәт, тагы рәхмәт Камилә абыстайга! Ул кайда әле үзе? Күренми...

Нияз, аны күрергә теләп, икенче бүлмәгә чыкты. Абыстай анда Сәйфулланың хатыны белән бергә тарелкалар юа иде.

— Рәхмәт, җиңги... р-рәхмәт! Күптән гармун ишеткәнем юк иде.

— Килсәң, ишеткән булыр идең. Килмисең бит.

— Белмәдем... валлаһи, белмәдем. Килми йөрүемә дә үкенәм.

Хатын, эшен бетергәч, сызганган тулы беләкләрен сөртте дә:

— Чәй эчәсең киләме? — диде.

— Эчәм, эчәм... Мин бит әле синең бүлмәңә фатыйха да бирергә өлгермәдем.

Камилә плитә өстендә кайнап утыручы чәйнекне алып, аны үз бүлмәсенә алып керде. Нияз да, аның артыннан керергә ашыгып, үзеннән соң ишекне япты.

— Чү, Нияз! Нигә ябасың, япма ишекне!

— Төтен керә, җиңгәем!..

Ул, юри генә шаярган булып, хатынның җиңенә сыя алмыйча тулып торган беләгенә төртте.

— Сәгать ничә? — дигән булды. Тәрәзә төбендәге кечкенә сәгать янына барып:

— О-о! — диде.— Сәгать унынчы — миңа китәргә дә вакыт... Хәер, китәргә урын да юк инде. Барыбер монда да кунып булмас.

— Ник булмасын, менә караватта йокларсың.

— Ә син үзең кайда?

Нияз алдындагы чәен бер генә уртлады да, белештермәгән кебек кенә, хатын янына килеп утырды.

— Ух, син шаян хатын! — диде. Аның кулыннан тотты.

Нәкъ шул вакытта бүлмәгә Сәйфулла килеп керде.

— Син ник ташладың безне? Әйдә, тагы берәрне төшерәбезме?.. Пилмән өстенә.

Ярты сәгатьтән соң инде мәҗлеснең кызыгы да китә башлады. Гармунчы уйнаудан туктады, җырчы исә йөзтүбән капланып йокыга китте.

Нияз, Камилә абыстайның кушуы буенча, аның караватына кереп ятты. Ләкин аның күзләренә йокы керми иде.

Урынның йомшаклыгы, чаршау эченең аулак булуы аның күңеленә төрле уйлар салды. Әгәр ул өйләнгән булса, кечкенә генә менә шуның кебек бер аулак бүлмәсе булса...

Кинәт ишек ачылды да, бүлмәгә Камилә абыстай керде. Ул, Ниязның тора башлавын күргәч:

— Ят, ят! — диде.— Мин шәм сүндерергә генә кердем. Хәзер чыгам.

— Җиңги!..

Кунак тагын ятты. Бәйрәм бүген: карын да туйды. Җан азыгы да нинди мул булды.

Тик аның менә күкрәгенең сул ягында бер төше елый иде. Нидер сорый иде бу төш: нидер җитми, анда нәрсәнедер юксыну бар иде. Күрше бүлмәләрдән тынлык ишетелә башлады.

...Кич керсен. Төн түгел, караңгылык сөременә әкрен-әкрен генә буялып, кайдандыр төшә торган кебек, җәелә торган кич. Караңгы төн — йокы түгел, яп-якты уйларга да һәм эшләмәскә дә ирек бирми торган көн — көндез дә түгел, шуларның икесенең арасы — кич керсен. Җәйгесе дә һәм яз башындагысы да түгел, әнә шул, күренми, кызгылт-сары кипкән, корыган яфраклар белән бакча юлларын, урамнарны тутыручы Мань(ч)журиянең матур, яңгырсыз көзге киче. Нияз шул вакытта көннең гасабиятен, аның мәшәкатен, көндезге борчылуны онытучан.

Бүген ул көне буе диярлек бернәрсә тоймыйча йоклаган. Камилә абыстай китереп биргән чәйне эчкәндә, сәгать дүрт иде инде. Кичәге кунаклар бары да таралганнар. Сәйфулла белән хатыны эшкә киткәннәр.

Камилә абыстай да: «Бер җиргә керләр илтәсем бар»,— дип чыгып китте. Шулай итеп, әле ут алынмаган бүлмәнең шигъри караңгылыгында, тынлык эчендә егет берүзе генә калды. Тәрәзә янына килеп, көзге көннең сүнүен карый башлады.

Менә шул чакта аның күңеле дустына, сердәшенә һәм башка берәүгә дә аңланмый торган телендә сөйли башлады.

Бер Ниязда гынамы! Һәрбер күңелнең шундый башкаларга ят, чит булучы бер теле бар. Ниязга инде ул ниләр генә сөйләмәде. Аннан ниләр генә сорамады да, җавапсыз кала торган нинди генә сөальләр бирмәде.

Ләкин менә хәзерге кебек ул бервакытта да бернәрсә дә сораганы юк иде. Әле кичәле-бүген генә... дөресрәге, үткән кич гармун уйный башлаганнан алып.

Көн узган иде. Эшсез булуын, икмәк, акча юклыкны белдереп торучы көндез түгел, кич инде хәзер.

Егетнең колак төбендә тагын кичәге гармун — җыр тавышы ишетелгәндәй булды. Ә күкрәгендә, аның сул ягында нәрсәдер һаман елый да елый.

Башланды! Сагыну, өзелеп-өзелеп, илне сагыну!

Болай ялгыз калып, уйга тирәнрәк керү, чыннан да, кызыклы икән: үзеңнең кемлегеңне беләсең.

Менә тагы сүз: соң инде шундый зур егет, үзен үзе белмәсен, имеш! Белмәгән шул! Күп кеше бит үзен үзе таныырга вакыт та аямыйча дөнья куеп йөри. «Мин кем? — диде Нияз.— Бер яшь егет. Мине аңлы бер татар егете, зыялы, диләр. Мин — милләт, халыкка хезмәт итәргә ашкынучы. Мин шигырьләр язам... Ә үзем «милләт» кызларын яратмыйм. Шигырьләремнең күбесе Людмилалар, Лидияләр, Анналарга багышланган...»

Хәтеренә яшьләр мәҗлесеннән соң Рамазановка сөйләгән сүзләре килде. Мин аңа татар кызларын хурладым. Аларны җансызлар, телсезләр, дидем. Уяна башлаган икенче Нияз бәйләнер өчен шуны гына көткән шикелле:

— Ә җансызлармы, телсезләрме? — диде.— Укы кичәге гәзитәңне!

Егет кесәсеннән начар кәгазьгә басылган татарча бер гәзит чыгарды (бу аңа Русиядән хәзер инде партиядә эшләүче аның бер иптәше җибәргән «Кызыл сүз» гәзите иде).

Үзе хәрендәш (карандаш.— *Х. М.*) белән сызып куелган бер җирен тагын укып чыкты: «Калтай авылында Бәрхенәдел исемле кыз, Мөхиб исемле егетне сөеп, сөйгәнен күрә алмыйча кайгырып, җырлый-җырлый үлде. Эре тоз авылында бер кыз сөю кайгысыннан гакылдан язды. Яңапай авылында Зөләйха исемле кызның да хәле кызганыч — сөйгәненнән аерып, сөймәгән егеткә бирәләр...»

Телсезләрме болар? Җансызлармы? Лидияләр, Людмилалар, Наташалар болардан артыкмы? Икегә бүленгән Ниязның элеккесе, үзен үзе һөҗүмнән сакларга теләп:

— Юк, юк... Гөлйөземнәр, Бәрхенәделләр, Зөлхәбирәләр — алар җанлылар. Алар берәүдән дә ким түгел, алар минем өчен барыннан артык... Беркөн, «җансызлар» дип, менә кала кызларын, туташларны әйткән идем. Мин шуларны Санияләр, Гайшәләр, Әминәләр кебек «мәдәниләшкән» туташларны әйттем. Авыл кызларына минем карашым башкача...

Егет, караватка утырып, аркасын стенага терәде. Аның күз алдына Мәфтухалар, Гөлйөземнәр, Зөләйхалар, Фатыймалар, Гайникамаллар, Әсмалар, Сәхибҗамаллар, Фәхернисалар, Ганиләр, Вәлиләр, Гайнетдиннәр, Сәйфетдиннәр, Әхмәтләр, Нурилар, Садрилар, Кәримнәр белән кайнап торучы җыеннар, туйлар, Сабантуйлары, өмәләр, бәйрәмнәр, аларның җырлый-җырлый печән чабулары, урак урулары, уеннары, җырлары килеп тезелде.

Шулай бөтен иле, меңнәрчә чакрым еракта калган сөекле иленең тормышы, кино манзаралары (күренешләре.— *Х. М.*) кебек, егетнең күз алдыннан уза башладылар. Тезелә баралар — уза баралар... Ниһаять (бүлмәдә һәм урамда караңгы иде инде), ниндидер капкалар ачылган төсле булып китте дә, соңгы күренеш, серле бер рәсем кебек, егетне үзенә тартты. Әйтерсең Нияз утырган урынны Сәйфулланың атлары алып киттеләр — ул кузгалгандай булды. Извозчик аңа аркасы белән тәрәзә төбенә килеп утырды да кулындагы чыбыркысы белән атларын кыйный башлады. Бераздан ул артына әйләнеп карады да:

— Тор! — диде.

Ниязның янында тагын берәү бар кебек булды. Ул, егетнең кулыннан тотып, алга, зур бер манарага күрсәтте. Күрсәтүче бөек Кушлавыч ятиме шагыйрь Габдулла Мөхәммәтгариф углы Тукай, имеш.

Манараның башында зыр-зыр тегермән канатлары әйләнәләр... Түгел, тегермән канатлары түгел, каракош канатлары. Ул манараның башыннан очып китәргәме, әллә куна алмыйчамы шулай талпына иде.

Юк, юк, кош та түгел, бик ямьсез бер баш икән. Хаин Шаһгали (XVI йөздә яшәгән Касыйм һәм Казан ханы.— *Х. М.*) башы. Канат төсле булып күренгән нәрсәләр — аның ямьсез колаклары.

Әнә Иван! Иван Грозный. Ул сатылган татар ханына нидер әйтте — Шаһгали кулында ут күренде. Манараның бер киртләче өстенә бик гүзәл бер хатын килеп басты. Күренешне куе төтен каплады. Төтен таралгач, базар күренде. Бер кибет алдында, аякларын бөкләп, ниндидер кеше утырган. Ул бик каты кычкырып бер көлде. Бармагы белән нәрсәгәдер төртеп күрсәтте. Аның кулында китап, имеш. Китап «Сөбател-гаҗизин»*, имеш. Бу кеше тагын бер мәртәбә бик кычкырып көлгән иде, сакалы төшеп китте, ә... бу... теге, кем... ул түгел, артист Габдулла Кариев икән!

Ут күренде. Тагы төтен. Төтенме, томанмы? Юк, төтен, тәмәке төтене эчендә карта уйныйлар. Язучылар, шагыйрьләр... Арада акыллы карашлы Фатих Әмирхан да. Тукта... берсе теге, кызын картага оттырган Мостафа мулла түгелме?**

Бу — Тукайның номеры, имеш. Әнә үзе дә. Йөткерә...

Әнә бер йорт. Капка төбендә Шиһаб хәзрәт басып тора. Каюм Насыйри да шунда, имеш... Бу ни бу? Өнме-төшме?

У-у! Әнә ут! Тагын ут. Әнә эшчеләр. Хатын-кыз! Солдатлар. Шәкертләр. Төркем-төркем муллалар. Тагын солдатлар. Әнә Вахитов... Татар солдатлары... Аклар, кызыллар. Тагы төтен. Тагы ут. Тагы манара. Тагы колаклар. Ай-йолдыз. Урак-чүкеч. Ут урамнарда. Ут тәрәзәләрдә. Ялкын кешеләр өстендә. Яшелле-кызыллы. Ак-кызыл. Кызыл-ак. Тагы ут. Ут түгел, кан! Йортлар, заводлар, фабрикалар... Тагы манара. Әнә (төтен таралды) бөтен шәһәр, бөтен бәхетсез кала.

Авыр бер хәстәлек саташуы белән күренгән төсле генә күз алдына килеп баскан манара — китапларда язылып, телләрдә сөйләнеп торучы Эйфель манарасы түгел, моңлы Сөембикә манарасы; бөтен шәһәр күренеше дә җиһанның пайтәхете Париж яисә Лондон, Нью-Йорк та түгел, күренгән бөтен манзара — Казан, Ниязга әдәбият аркылы гына таныш булган, татарның башкаласы Казан иде...

...Күрше бүлмәдән карлыккан тавыш ишетелде:

— Нияз, баш төзәтмәйсеңме?

*Харбин, 1923—1924*

### Үзебез өчен*

Мин Иделне белмим. Күрмәдем аның ничек агуын. Шунлыктан, бәлки, минем күңелем дә сынык...

Беләм: Идел буенда бер манара бар. Аны да — рәсемнәрдә күреп кенә, укып, ишетеп кенә. Исегезгә төшереп торасы да юк — олуг, бәхетсез ил хатыны Сөембикә манарасы.

Шагыйрьләр көйгә салган, янына карчыклар барып җылый торган, иске, тузып беткән булса да, күңелебездән китмәгән, тарихыбызның үксез сыңары, күз нурыбыз изге манара.

Мин әле, көннең матурлыгы белән файдаланып, су буена ял итәргә чыкканда да, кадерле рәсемне куен кесәмә салып чыкканмын. Гәҗит белән бергә. Бик ераклашканбыз шул табигатьтән. Кая ул безгә

каланың тузанынnан бик тиз генә арынырга да, аның гәҗитен, журналын, ак якасын, муен бавын (галстугын.— *Х. М.*) ташларга! Хәер, бу тагын икенче мәсьәлә — «гакыллылар фәлсәфәсе». Бу юлы әле гәҗитне өйдә калдырмавымның файдасы да тиде.

Габдулла да көнне минем белән бергә үткәрергә булды. Герман сугышын аркасында күтәреп йөртеп, иленнән аерылган, хәзер Сунгара (Маньчжуриядәге елга атамасы.— *Х. М.*) суында кимә белән кеше йөретә торган күптәнге танышым. Ул да, бүген бераз ял итим, диде.

Яр читендә аулак бер урын сайлап тукталдык. Яшел чирәм өстенә чыгып, чәй дә кайнатып эчмәгәч, ял итүнең нинди кызыгы бар!

Габдулла яр читенә казык кагып, «атын» (ягъни көймәсен.— *Х. М.*) шуңа бәйләп куйды да калай чәйнеген батырып су ала башлады. Аз гына җил бар, су өсте вак кына шадраланып тора. Бәлки, Идел дә шулай гынадыр. Шундый ук агым, шундый ук суы. Тик... тик шул аның тарихы бөтенләй башка. Ул безнеке. Үз суыбыз. Елга читенә килеп басып, кулымны куен кесәмә тыккан идем, кыяфәтем үземә дә көленеч (көлкеле.— *Х. М.*) тоелды: Наполеонмыни? Бик кирәккән иде синең эре итенешләрең! Әнә Габдулла синең кебек яр башыннан бер суның дулкыннарын тыңларга ашкынмады. Турыдан-туры эшкә тотынды. Капчыгыннан балтасын чыгарды. Чыбык-чабык җыеп, «тук-тук» кисә дә башлады. Тукта, таныш тавыш. Ә, «Шүрәле»дән икән. Менә шундый Габдулла кебек берәү булгандыр инде ул:

Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга ялгызы бер ат җигеп.

Дөрес, Габдулла инде яшь җегет түгел. Әмма, шөбһәсез, булгандыр ич аның да яшьрәк чагы. Охшатуымны аның үзенә дә әйтәм. Көлемсерәп куйды, эштә иде әле: чәй кайнатасы бар. Юкса ул үзе болай сүзчән кеше. Укымышы да юк түгел. Дөньядан хәбәрдар. Күп җир күргән. Казанын да, Иделен дә, Ак Иделен дә, Карасын да. Илнең җәгърафиясен адымлап йөренгән.

Учак гөрләп яна да башлады. Кинәт миңа да «җегетлек» кереп китте дә, өстемнән казакиемны салып ташладым. Икебез дә чәйнек янына утырдык. Куен кесәмдәге гәҗит үлән өстенә килеп төшкән, җил аны калтырата, ара-тирә рәсемле ягын да ачкалап куя иде.

Габдулланың моңа күзе төште дә:

— Бу нинди карточка? — диде. Гәҗитне кулына алды.

— Сөембикә манарасы,— дидем.

— Ә, үзебезнең Хан мәчете икән,— дип, дикъкатьләбрәк карый башлады кимәче.

— Син аны күргәнең булдымы, Габдулла абзый?

Габдулла, гәҗитне бер читкә куеп, учак астына бер өрде дә, хәйләле бер елмаю белән күзләрен кыса төшеп:

— Юк, булмады,— диде.

— Казанда булгансың ич. Ничек соң күрмәдең?

— Булмыймы соң,— дип төзәтеп бирде Габдулла.

— Башыннан орелны (биредә Русия гербы күздә тотыла.— *Х. М.*) өстерәп төшерсен дә Габдулла Хан мәчетендә булмасын.

— Ничек? — дип гаҗәпсендем мин. Бу минем өчен аның авызыннан өр-яңа бер хәбәр иде әле.

— Я, шул унҗиденче елны, революция вакытында. Ул чакны мин анда идем. Кая чәең, хәзер кайный... бу чәйне, төтен тәме килә торган чәйне эчүем иде әле.

Берәр чынаяк эчкәч, кимәче, минем үтенүемне көтмичә, үзе үк сөйли башлады.

— Ул, ни, Корбан бәйрәменең өченче көнендә булды бит. Мин (ул.— *Х. М.*) чак фронттан Казанга килеп төшкән генә идем. Сентябрьнең уртасында Хан мәчетеннән орел алына дип халыкка хәбәр таратканнар иде инде. Орел бит ул кечкенә түгел, зур иде. Шуңа күрә аны алыр өчен Гаеткә чаклы ук бөтен кирәк-яракны әзерләп куйдылар. «Кая әле гәҗит?»,— дип, Габдулла җил белән тал төбенәрәк киткән гәҗитне үрелеп алды да, манара рәсемен бармагы белән төртеп:

— Менә шуннан, иң югары тәрәзәдән чыгарып, бер балкон ясадылар. Сәгать 12 дә алына дип язсалар да, тиз генә тотына алмадылар. Ә халык инде әллә кайчан җыелып беткән иде.

— Кеше күп булгандыр? — дип сорап куйдым, сүзенә бераз көч бирим дип.

— Чутсыз,— диде Габдулла.— Тукта әле, мин бер тәмәке кабызыйм. Аннан соң сөйләрмен.

Учак сүнә башлаган иде инде. Ул «уфф» дип бер өргән иде, күзенә көл сибелде. Бераз йомылып торган сул күзен ачып, арзанлы сигаретын утлы күмердән кабызып алды да, бераз кырынрак ятып, аякларын сузып җибәрде.

— Тучно ничек әйтәсең инде. Күп иде. Алай да 15—20 меңләп булгандыр, артык булмаса. Ул чагында бит үзебезнең мөселман роталары, мөселман полклары. Үзебезнең солдатлар крепость эчендә, уртадан юл калдырып, син гаскәрдә булмадың, белмисең, цепь, әйтик, чылбыр ясадылар. Ә цепьның арты шыгрым тулы халык, кыз-хатынга урын отдельно булды. Алар шунда гына басып карап тордылар. Губернатор сараена — мәчетнең янында гына — халыкны җибәрмәделәр. Чөнки беләсең, Ходай сакласын, андый вакытта югарыдан кеше башына кирпеч-фәлән төшеп имгәнүе, үлүе бар.

Шунлыктан анда Хәрби Шура кешеләре дә, манарага менә торган кешеләр генә басып тордылар. Ике военный оркестр уйнап торды. Ул чагында бит хөррият көе, ничек әле?..

— Марсельезамы?

— Әйе, шуны уйнадылар. Менә бер вакытны халык кычкырып тәкбир әйтә башлады. Өч мәртәбә тәкбир әйтелде. Дога кылдык. Шуннан соң инде иң беренче, манарага менәргә сайланган кеше, Габдулла Исмәгыйлев дигән егет иде. Ике рәкәгать намаз укыды да кош сурәтен алырга югарыга менеп тә китте. Орел ул үзе бер тимер өстенә утыртып куелган. Шуны тимере белән кисеп алырга булганнар. Менгән кеше инде, әлеге шул Габдулла дигән егет, пычкы белән кисә дә башлады. Җиңел эш түгел, әлбәттә, бер ярты сәгать чамасы кисеп арыгач, аның урынына икенче берәү менеп китте. Исемен дә белә идем. Матрос. Ә, Минһаҗетдинов! Минһаҗетдинов бераз кисеп төшкәч, Гарифулла дигән егет менде. Алардан соң инде ике кеше берьюлы менеп киттеләр. Берсен артист диделәр. Фамилиясен дә беләм. Тукта, Салт... Салтыковский. Ул да һәм аның белән бергә Габдрахманов дигән егет. Әйбәт малай иде. Безнең якныкы. Берсе шул менеп тә җитте. Кошның канатларына ябышып күтәрелде дә муенына да менеп атланды. Атланды да — кош бит, ул ике башлы — шул башлардагы таҗларны берәм-берәм алып, иптәшенә бирә дә барды. Ә иптәше — күрсәң менә, Латиф әфәнде, исең китәр иде — кош астындагы шарга гына басып тора иде.

— Ничек егылмаган?..— дип авызымны гына ачкан идем, хикәяче:

— Тукта, сабыр ит, бу гынамы әле?..— диде.— Баскан җиреннән ул астарак торган өченче бер кешегә сүтеп алынган нәрсәләрне бирә барды. Бервакыт Габдрахманов чак кына үлмичә калды. Ниндидер бер винтны чыгарып маташканда, винт сынып китте. Әгәр шул чакта Габдрахманов кулындагы тимер кисәген түбән ташламаса, үзе дә һәлак була иде. Хода саклады.

— Ничек хәтерлисең барын да, Габдулла абзый?

— Хәтерләмәскә. Шунда, яннарында бит мин дә. Барысы да дус егетләр. Аннан соң инде...

Кимәче икенче тәмәкесен кабызды.

— Кичкә калмыйбызмы? Караңгылана.

— Я, бетер, бетер инде сөйләп,— дидем.

— Шул Хода саклады Габдрахмановны... Кошның таҗын кигезгән бер тимер колгасы бар иде. Шуны чыгармыйча кошны алып булмый. Ни эшләргә? Ә таҗны чыгару өчен, колганы бераз кисеп алырга кирәк. Бер пулеметчик бар иде. Хәбибулла исемле, Ибраһимов. Шундый оста итеп эшләде бу эшне. Шаккатарсың.— Хикәяче урыныннан кузгалды: — Менә бермәлне, мин сиңа әйтим, Хәбибуллабыз манара очында атлый башлады. Зыр-зыр әйләнеп йөри. Ат кәмитендә дә болай булмас. Исе китмәгән кеше калмады.— Габдулла, тавышын бераз җитдиләштерә төшеп: — Ә кошның үзен алырга инде Вәлиуллин, әй, ялгыш әйттем, Исмәгыйлев дигәнем, икесе менделәр. Их, малай, күрсәң иде аларның эшләгәннәрен. Адәм әйтеп, адәм ышанмас. Хан мәчете бит ул, Харбин мәчете түгел. 35 сажин аның биеклеге. Шундый югарыда аягың чак кына сыеп торырлык бер төшкә басып эшләп карале син. Халыкның исе-акылы китте.

— Шуннан соң...

— Аннан соң шул кош сурәтен, чыгыр белән бауга бәйләп, аска төшерделәр. Тагын музыка уйнап җибәрде. Бөтен һава яңгырады...

— Ә урыслар,— дидем мин.— Урыслар соң каршы килмәделәрме?

Габдулла, күзләрен зуррак ачып, тавышын күтәрә төшеп:

— Кем, урыслармы? Каршы килмиләрме соң? Алдырмаска бик тырыштылар. Әле шул орелны алган вакытта да, урыс комиссары, хөкүмәттән рөхсәтсез нигә болай эшлисез дип, кәгазь төшергән булган. Аннан соң ниндидер профессорлары гәҗиткә дә язып чыгарган: Хан мәчете ул татарларныкы түгел. Татарлар орелны алып, патша заманының төсен бетерделәр, дип. Ну, безнекеләр аңа карамадылар. Урысның ни эше бар анда! Без бит аны үзебез өчен эшләдек. Тик шунысы гына, малай, үкенечкә калды. Башына ай куя алмый калдык. Бәхете юк икән бичара Хан мәчетенең. Тагы урыс кулына төште... Әйдә, киттекме?

— Киттек,— дидем.

Караңгы иде. Су өстендә тынлык. Кимәдә икебез дә дәшмәдек. Габдулла түзмәде, су уртасына җиткәч җырлап җибәрде:

Карлыгач, кая барасың,
Бармыйсыңмы безнең илләргә?
Барсаң да гына безнең илләргәләй...
Сәлам әйтче туган илләргә...
Сәлам әй...т
Нечкә билләргә.
*Харбин, 1939*

## Орлыклар

Мохтаров, мич авызына иелеп, тәмәке кабызды. Анда, мич эчендә, утлы күмер шакмаклары ялтырап ята иделәр. Нечкә билле кисәү, черт итеп, икегә аерылды. Очкыннар, матур йолдызлар китекләре шикелле, читкә атылдылар.

Авызыннан чыккан төтен күбекләрендә үзенең уйларын күрү Мохтаров яраткан эшләрнең берсе иде. Бу юлы исә ул тәрәзә пыяласына, дөресрәге, тәрәзә пәрдәсенә, андагы караңгылык сөремене буяла башлаган җыерчыкларга карады. Алар аңа шуны әйттеләр: «Ни эшләп торасың инде? Тизрәк! Шундый минутда, бернәрсә дә булмаган шикелле, тынычлап тәмәке кабызырга ярыймы соң? Тиз бул — минут кача!»

Ләкин «минут качмады»: Мохтаров тәмәкесен почмакка таба ташлады да, утызга якынлаган һәм күбдән кырылмаган йөзенә ачу шәүләсе алып, күрше бүлмәгә ишек ачды. Анда, караңгыда, тәрәзә янында Мохтаровка аркасы белән бер хатын басып тора иде.

Җылый иде.

Мохтаров аның аяк төбендә яткан, чите кыршылган чумадан (чемодан.— *Х. М.*) һәм гәҗит кәгазенә чорнаган төенчекләргә карады һәм тиз генә әйтергә дә өлгерде:

— Я, ни эшләп торасыз инде? Мин извозчикны күбдән чакырдым. Әллә югыйсә мине шаярып сөйли дип уйлыйсызмы? Күз яшьләре мине җиңә алмаслар. Минем беренче әйтүем — соңгы мәртәбә әйтүем.

Хатынның чукрак шикелле тик торуы Мохтаровның изасын (ачуын.— *Х. М.*) китерде. Шуңар күрә ул (моны үзе дә көтмәгән иде һәм моның өчен үзе дә соңыннан оялып йөрде) кайчандыр, күп еллар элек үлгән анасы әйтмешли, исерек урыс шикелле, уртасыннан югары бер нота белән, нечкәреп киткән калын тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Ишетәсезме?!

Бу — аның хатын йөрәге аркылы үткәзергә теләгән угы иде. Ләкин ул төз барып тимәгән төсле булды. Гүя Мохтаров аның ана телендә түгел, үз ана телендә, татарча сөйли, шуңа күрә дә, имеш, аның бер сүзе дә аңланмый иде.

Алар ике ел бергә тордылар. Яратышдылар. Бер генә көнләре булсын,— тормыш керенә буялмады; болытсыз булды; күк йөзе һәрвакыт аяз иде. Тик менә бүген көтмәгәндә ир зур ачу белән кайтып керде дә хатынны куалый башлады.

Исерек түгел иде.

Ләкин бөтенләй башка бер кеше иде. Хатын ике ел эчендә беренче мәртәбә аны шундый усал итдереп күрде. Ул сәбәпләрен сорагач, Мохтаров йөрәк чирле кеше шикелле җавап бирде:

— Туйдым! — Менә сәбәп. Аерылышу өчен, сине кем белән булса да бергә тоту шикелле, зур сәбәпләр кирәкми торгандыр бит... Без бит никах белән бәйләнмәгән. Тотдык та тора башладык. Ике ел узгач, мин тотам да әйтәм: «Артык бергә торырга теләмим! Ялгыз, хөр, иркен калырга телим. Менә хәзер иске күлмәгеңне киеп, кер юууыңны, бүлмәдәге тәртипсезлекне, йөзеңне, күзләреңне — берсен дә күрәсем килми. Кит!»

Хатын аның тавышын сүз әйтелешедәй аңлады: бу, чынлап та, икеellык матур бер тормышның көтелмәгән ахыры, ахшамы иде. Ләкин сәбәп бик ят иде: кер юууын, бүлмәдәге тәртипсезлекне күрәсе килми, имеш! Шуңа күрә үзе яраткан һәм аның үзен яратучы икеellык ибдәшен куаларга уйлаган!

Төбендә исә сәбәпләр бераз тирәнрәк, картрак иделәр. Мохтаров күңелендә алар бүген генә тумадылар. Ул уйлаганча, аның тормышы (ике ел ничек кенә матур узмасын) буаланган, агуыннан туктаган тормыш; һәм бу буада хатын иде. Гүя шул хатын Мохтаров алдындагы бөтен офыкларны томалап, юл каплап тора иде.

Айнырга теләмәгән исерек шикелле, ул тагын әйтергә ашыкды:

— Бер минут торма! Ялынма да, бернәрсә дә сорама да миндән! Арабызда бөтен нәрсә бетде — аңладыңызмы?

Икеellык «син»не «сез» әйтәсенә алыштыру Мохтаровка ләззәт бирде. Әйтерсең ул, кесәләренә тутырып, таш кисәкләре алып кергән дә шулар белән хатынның җанын кыйный иде.

Хатын артык түзүдән файда юклыгын аңлады. Ялыну, гафу үтенү (ни өчен?), сөю сүзләрен тәкрарлауны кирәксенмәде. Җыена башлады. Бу — Мохтаровның ачуына тагын бер зәһәр тамчы өстәде: «Нигә тиз китә? Нигә ялынмый?»

Бу минутда күңеле буранлы кышкы төн белән бер иде: караңгы иде анда. Гүя кечкенә-кечкенә генә шайтан балалары һәм курчак фәрештәләр шул төн эчендә йызгыша иделәр.

Шайтан балаларының берсе авызын ачды: «Китә. Уйла тагын да бер ачырак сүз. Ишекдән чыккан вакытда гына шуның белән хатынның күңеленә кадарсың!»

«Курчак фәрештә» рәнҗүен белдерде: «Ни өчен? Ике ел буе сиңа яхшы тормыш ясап торуы өченме? Рәхмәтеңме?»

Мохтаров соңгы тавышны тыңларга теләмәде: күңеле йомшарып китеп, аерылу нигезенә куелган барлык планнарының җимерелүеннән курыкды. «Айный» башлаганчы, бөтен гайрәтен җыеп кычкырды гына түгел, ир ясалма итенешләр (кыланышлар.— *Х. М.*) белән акырып җибәрде:

— Югал хәзер, тизрәк югал!

Хатын абдыраунык чигенә җитде:

— Соң, җаным, ни өчен бу? Ичмасам, шуны гына белеп китим!

Бу минутда ишек шакылдатдылар.

— Әнә извозчик та килде. Тизрәк китеңез,— диде Мохтаров.

Извозчик урынына ишекдән бер ир белән хатын килеп керделәр.

— Гафу итәсез, сездәме бүлмә бирелә?

— Әйе, рәхим итәсез,— диде Мохтаров. Ул килүчеләрне өченче бүлмәгә уздырды.

Алар үзара татарча сөйләшә иделәр. Хатын, ибдәше бүлмәнең түренә таба узгач, Мохтаровка карады да, ире янына барып:

— Әхмәд, кара әле, мин бу әфәндене таныйм бугай,— диде һәм, шуны әйтеп бетерер-бетермәс, фатир хуҗасына сөаль бирде: — Гафу итегез, әллә сез... Сез... Рәфыйкамы?

...Гимназиядә укучылар кичәсе. Җиденче гыйнвар. Музыка. Мазурка. Укучы туташ һәм егетләр белән төрле сыйныф бүлмәләре. Озын коридор почмагында киоск. Мохтаров өчен ул киоск түгел — бәхет оясы: анда битләре алмаланган Рәфыйка утыра. Ялгызы гына — берәү дә юк. Мохтаров аның янына бара. Эчкә керә.

— Мин сине сөям!

Рәфыйка: «Мин дә!» Бик тәмле үбү...

Моңа инде ун ел узган булуга карамыйча, Мохтаров ул Русиядә булып узган кичәне секунд эчендә күз алдына китерде. Берсен дә онытмаган. Тик менә Рәфыйка гына «7 нче гыйнвар» Рәфыйкасы түгел: картая башлаган, тупас кына бер хатын булып бара...

— Танышыгыз, минем ирем,— диде хәзерге Рәфыйка. Сораша башлады: — Сез ничек бирәдә? Күбдәнме? Күрешмәгәнебезгә ничә ел бит инде... Өйләндегезме?

Мохтаров җавап кына биреп торды. Үзе һич сөаль дә бирмәде һәм сорашырга да теләмәде. Бу очрашу, ничаклы көтелмәгән булса да, аның күңеленә тирән ятарлык бернәрсә дә китермәде.

Рәфыйка һаман сөйли иде:

— Без Харбинда узышлый гына туктадык. Бирәдә бер-ике ай тормакчы булабыз. Бүлмәгез бераз кечерәк икән. Рәхим итегез безгә, чәй эчәргә. Без «Азия»гә (миһманханә исеме.— *Х. М.*) төшдек. Сөйләшеп утырырбыз, үткәнне сөйләрбез.

— Инде китдек, кичкә калабыз,— диде аның ире.

Мохтаров, аларны озатып, яңадан өйгә кергәндә, чынлап та, караңгы иде инде. Тәрәзәләрдән көзге юеш кич карап тора иде.

Мохтаровның хатыны, ире килүчеләргә бүлмә күрсәткән чакда, үз бүлмәсендә ут алган, аны үзенең йөзен һәм идәндә яткан әйберләрне ачык күрсәтерлек итеп яктырткан иде.

Ир, хатынга карамас өчен, бая тәмәке тарткан бүлмәгә узды. Тагын тарта башлады. Аның авызыннан бер-бер артлы чыгып качкан төтен күбекләре, түшәмгә ябышып, болыт ясадылар.

Икееллык тормышны сонгый (ясалма.— *Х. М.*) рәвешдә бер минутда өзәр өчен, ят бер юл сайлаган ир уйламаска, зиһенен бернәрсә белән дә бәйләмәскә тырыша иде. «Әгәр хатын чыгып киткәнче, менә шул бүлмәдә торса, аңа карамаса, уза инде, бетә. Тик карамаска гына кирәк».

Ул бүлмә буйлап йөрергә тотынды. Шул минутта извозчик тәрәзә чиертде. Мохтаров аның бүлмәгә керүен, хатынның кушуы буенча әйберләрне алып чыгып китүен, ныклап ябарга өлгермәгән ишек яныннан читкәрәк китеп тыңлап торды. Аның уена килде: «Әллә мин дә, чыгып, әйберләрне күтәрешимме?» Бу «курчак шайтан»ның ачуын кабартды: «Шул гына калган! Шап итеп ишекне яб да тик кенә тор инде!»

Тукта, ул бит әле хатынына дип әзерләгән акчаны бирергә оныткан!

Мохтаров кесәсенә кулын тыгып, ишекне генә ачкан иде, күзләре ал күлмәк өстенә сибелгән орлыкларны күрделәр: «талак» ителгән (ягъни аерылган.— *Х. М.*) хатын урамга керле күлмәгендә чыгып китәргә теләмичә булса кирәк, өстендәге күлмәген икенчегә, чәчәк орлыклары шикелле вак кына бизәкле ал күлмәккә алышдырган иде. Мохтаровның иң яраткан күлмәге!

Беренче кат күрүендә аның хатыны шул күлмәгендән иде бит. Дөрес, хәзер искергән иде инде ул. Шулай булса да Мохтаров хатынын шул күлмәкдән күрүне бик ярата иде. Аңа бу күлмәгенең бизәкләре — орлыклар ошый иделәр.

Хатын аңа күтәрелеп карамады, кулына шәлен алды. Ябынды. Тик, кәгазьгә чорналган бер төенчекне алып, ишекдән чыга башлаганда гына, әле һаман бер урында басып торучы Мохтаровка таба әйләнеп, татарча белә торган бердәнбер сүзен әйтде:

— Сау бул!

— А, минем түгәрәк бәхетем! — дип җавап кайтарды Мохтаров. Яңа гына куалаган тормышын, күлмәк өстенә чәчелгән орлыкларны — барысын бергә җыеп, кочагына алды. Үбде аларны. Тик элек күкрәкдәгеләрен, күлмәк җиңләрендәгеләрне. Андан соң — тагы калган икән әле керпекләр эченә күмелгән ике зәңгәр орлык, бәхет орлыклары — аларны үбде.

Төгәл ун ел әүвәл, киоскдагы үбү нинди тәмле булса, бу үбүләр — явызланган, адашкан күңелнең үкенүләре иде, гүя шулай ук ләззәтле һәм татлы иделәр.

Извозчик чумаданны кире алып керде.

*1924*

**Мылтыклы хикәя**

Ибдәшем йоклаган, мин чумаданым өстенә «таянып» кына торганмын; шулай итеп, вакыйга бик ачык: без, «Балыклар» ыстансасына (станциясенә.— *Х. М.*) төшеп калырга тиешле егетләр, «Балыклар»дан да, «кармаклар»дан да, «саблар»дан да узып киткәнбез.

Кытай-Көнчыгыш тимер юлында «Балыклар» исемле ыстанса юк һәм булмагандыр да. Укучыны Маньчжурия хәритәсендән (картасыннан.— *Х. М.*) юк нәрсәне эзләтеп мәшәкатьләмәс өчен, рәхим итегез, ашыгыч рәвешдә тагын бер җөмлә: без билетларны, ишетүебезгә күрә, янында кечкенә генә балыклы күлләре булган бер ыстансага чаклы гына алган идек.

Сәфәребездән максат да икебезнең дә бала вакытыбыздан бирле яратып килгән балык тоту гына булып, аның сәясәтдән бөтенләй ерак торганлыгын белдерү өчен, яныбызда озын-озын кармак сапларының да булуы искә төшерелсә, җитәр дип уйлыйм.

Поездда безнең мәҗбүри уянуыбыздан соң күп вакыт узмыйча, туктагач та кондуктор безне төрткәли-төрткәли икенче ыстансага төшергән чакда, яңа гына хәтергә алынган кармак сабларының берсе, хәерсез бер фал уларак, ишеккә кысылып икегә сынды.

Төн. Күкдән бертуктамый су агып тора; әйтерсең яңгыр яумый — өстебезгә диңгез коела иде.

— Уңган кеше булса, моңа чаклы инде балыкларын да тотып, шулпасын да эчеп өлгергән булыр иде. Бигрәк ерак киткәнбез. Син дә шул...

— Ибдәш, ни булса да булды, кемнең гаебе күбрәк булу турында кычкырып тормыйк, бер тәүлексез кире китәргә поезд юк, ни эшлибез, кайда кунабыз? — дидем.

Бәхетсезлекне уртаклашырга теләмичә торучы «балыкчым»:

— Кадалып кит! — диде.

Ярый әле, шул чакда яныбызга кулына фанар (фонарь.— *Х. М.*) тоткан бер «нәрсә» килеп җитде. Ул:

— Сезгә кунарга урын кирәкме? Әйдәгез,— дип, безне алып китмәсә, бәлки, минем башыма ачулы ибдәшемнең каргышы да төшәр, икебез дә бу юеш, сулы төн эчендә «кадалган» да булыр идек.

«Фанар»ны алдан җибәреп, үзебез бер-бер артлы аның артыннан китдек.

— Бу җирләргә дөнья яратылгандан бирле татар аягы басмагандыр.

«Юлдаш» авызымны каблады:

— Ә Чыңгыз? Субутай батырлар (Чыңгыз ханның гаскәр башлыгы.— *Х. М.*)? Алар басу гына түгел, табтаганлар да.

«Мин сиңа, менә үзебезнең шикелле, хәзерге татарларны әйтәм, ә син миңа мангуллар хакында сөйлисең»,— дип җавап бирмәкче идем дә эндәшмәдем: чит илләрдә бергәрәк булган яхшы. Бигрәк дә, ибдәшем кебек, илһамны татар тарихыннан алсак, бу берлекнең кирәклеге үзендән-үзе килеп чыга бит.

«Фанар», бер йортның алдына туктап, тәрәзәсен какды.

Иң элек этләр, андан соң, өй ишеген ачып, бер кеше килеп чыкды. «Кәрван башыбыз» аның белән сөйләшкәч, безне эчкә алып керделәр.

Керүебез дә булды, каршыбыздагы икенче ябык ишекне ачып, яб-яшь алма шикелле бер кыз атылып чыкды.

— Әткәй, кем бар? Нигә этләр өрә?

Ул тагы нидер әйтмәкче иде дә бетерә алмады. Чөнки аның каршында басып торучы без, «җебегән» юлчылар, икебез дә аның сөаленә каршы җанлы җаваплар идек инде.

Ул иң элек туп-туры миңа карады. Мин бу карашны ибдәшемнең яшел күзләренә күчердем. Соңгысы аны миңа кире кайтарды: «Әти! — Татар кызы?»

Мин, безне алып керүчегә карап:

— Сез дә татар... мөселманнар, ахрысы? — дип, авызымны ачкан идем, аталы-кызлы икесе дә кинәт яктырып китделәр. Юеш булсак да, «Берни түгел!» — дип, икенче бүлмәгә алып керделәр. Анда шыгрым тулы рус кызлары, егетләре бииләр, җырлыйлар, әйтерсең ыстансада торучыларның барысы да, яңгырдан качып, шунда җыелганлар иде. Арада безнең кебек «юеш» егетләр дә бар иде. Кунаклар белән танышдырып чыккач, безне дә бераз «кибдереп» алдылар.

Туташ безне анасына тәкъдим итде. Бу — тышкы кыяфәте белән руслашкан, йөзе белән «марҗа»га охшаган татар хатыны безнең белән күбдәнге танышлары шикелле сөйли башлады:

— Мәрьямнең бүген туган көне. Көне буе шау киләмез. Биредә бездән башка татар семьялары юк. Руслары белән генә аралашырга туры килә. Без инде 15 ел биредә торабыз.

Без, намаздагы кебек, икебез дә берьюлы аякка басып, Мәрьям туташны дөньяга килүе белән тәбрик итдек.

Нәфис гәүдәле, ачык чырайлы, дөньяның шау-шулы урынлардан читдә үскән бу кыр чәчәгенең безгә каршы «рәхмәт» диюе; итенешләренең табигый җанлылыгы, тәрбиялелеге; ибдәшем белән икебезгә бирелгән кечкенә бүлмә эчендә уздырылган төндән соң да, иртәгесендә һаман әле кибмәгән, юеш, яңгырлы көннең узуын да сизмәслек дәрәҗәдә берәеп (онытылып.— *Х. М.*) аның белән бергә, кала тормышына караганда, ыстансада торуның күңелсезлеге хакында сөйләнгән сүзләр; очарга теләгән күк, зуррак бер шәһәргә барасы килүен әйтеп, калада торучыларның бәхетен көнләве; телендә рус сүзләренең күп булуы өчен гафу үтенүе һәм без китәсебез килмичә генә поездга утырган чакда, аның көтелмәгән бер «номер» эшләве — ата-анасы каршында безгә яулык болгап калуы — болар барысы да безнең күңелләребезгә матур бер күләгә булып яткан иде.

Атасы:

— Икенче килгәндә, мылтыклар алып килегез, үрдәкләр атып китәрсез,— дип калды.

Ике ел узган. Ике ел буенча яуган карлар эреп, тагы язлар булып, тагын җәй килгән иде.

Ибдәшем өйләнергә җыена башлады. Бу зур адымны ничек атлау турында сөйли-сөйли бик озак һәм бик күп итеп тәмәке тарткандан соң, һаман да әле бер карарга килә алмадык: аның яраткан кызы юк. Шулай булгач, кемгә барып: «Хатыным бул!» — дип әйтергә? Мин өстәлдәге тәмәке төпчекләрендән ясалган пирамидага актык тәмәкене ташладым да әйтеп дә бирдем:

— Әйдә, китдек!

Поездда ибдәшем җәяү төшеп йөгерерлек булып сабырсызлана иде:

— Валлаһи, әгәр без күргәндәге шикелле булса, бетде — өйләнәм!

Килеп җитдек.

Ибдәшем аркасына мылтык аскан иде. Буш кул белән барып, өйләнергә килдем, дип әйтергә ярамый бит!

Әйтерсең бу ыстанса һаман әле шул: без мондан ике ел элек калдырып киткән төндәге кебек үк яңгыр ява, шул ук фанар тоткан кеше каршыбызга килеп, аның белән бергә таныш булган өйгә барып кергәндә, икенче бүлмәдән шулай ук уен-көлке, җырлаган тавышлар ишетелеп тора иде.

Этләре дә өрде, тик алдыбызга алма шикелле кыз гына атылып чыкмады. Безне анасы каршы алды.

— Бигрәк мактап йөрисез. Сез һәрвакыт мәҗлескә туры киләсез. Әллә белеп йөрисез инде... Рәхим итегез! — диде ул.

Безне кунак бүлмәсенә алып керде дә туп-туры өстәл башында утырган ниндидер күк күзлекле, сары мыеклы бер татар белән ак күлмәкле Мәрьям янына китерде.

— Танышыгыз, безнең кияү. Жалко, никахка өлгерә алмадыгыз.

Мин:

— Мөб... мөбарәк булсын,— дидем.

Ибдәшем:

— Шу... шулаймы? Бик яхшы,— дип, ни әйткәнен үзе дә белмичә, кияү белән кәләшнең кулларын кысып чыкды.

Мәрьям без күргәндән әллә ничә кат тагы да матуррак күренде. Гүя җир җиләге тулган, чын мәгънәсе белән пешкән иде инде. Мин аның күзләрендәге, «Нигә инде соңга калып килдегез?» дигән шикелле, безгә каршы бер шелтә укыдым. Әйтерсең каршыбыздагы бер кино манзарасы имеш дә, без, шуны америкалыларча «бәхетле ахыр»га җиткерү өчен, мылтык тотып, кызны коткарырга килгәнбез.

Юк, алай түгел шул — әнә хакыйкать бөтенләй башкача!

Өй хуҗалары, бик гафу үтенеп, безгә йоклар өчен ишегалдында печәнлекдә урын күрсәтделәр. Чөнки мондан ике ел элек без кунган бүлмә хәзер кияү бүлмәсе булган иде.

— Әйе, беренче килүебездә туган көне иде. Бүген аның безнең өчен үлгән көне.

Ибдәшем:

— Атам! — диде. Мылтыкны кулына алды.

— Кемне?

— Теге сары шайтанны! Аны мин бик яхшы беләм. Япуниядә бергә сату итдек... Русиядә аның хатыны, балалары бар.

Мин дә соңгы сүземне әйтдем:

— Нигә аны атасың? Үзеңне ат инде хәзер.

*1925*

**Милли төс***

Маньчжур иленең кояшлы зәңгәр көннәрен кем генә мактамас икән! Каләм дә, гадәте буенча, көз башының яхшылыгына багышлап, бер-ике генә булса да мәдхия юлы сызып китәргә кытыклап тора. Әле бер милләттәш белән милли, иҗтимагый мәсьәләләр вә дөньяның барышы хакында сөйләшеп утырдык та (ай, бик эре сөйләштек!), сүз шул ук көзге көннең тән вә җаннарыбызга ясаган елымса тәэсиреннән башланып китеп, милләттәш миңа бер сөаль бирде:

— Сезнең якта менә көз көненең шушы вакытына ничек диләр?

Ялганлап торасым килми, бу имтиханны тота алмадым. «Белмим» дияргә мәҗбүр булдым:

— Русча «бабье лето» диләр…

— Русчасы миңа кирәгемә дә юк,— диде ул.— Безнеңчә ничек була? Белмисез шул. «Әбиләр чуагы» диләр бездә! Милли дә милли дисез, үзегез чынлап татарча белмисез дә, телебез ярлы дип зарланырга тотынасыз. Сизеп үк торам: мин «әбиләр чуагы» дигәч үк, синең күз алдында «бабье лето» булып торучы матур көн бөтенләй башка бер милли төс алып китте. Менә шулай һәрбер милли төсен качырган, качыра башлаган вә милли булмаган әйбер вә хәлләрне миллиләштерә белергә кирәк аны. Алыйк никах мәрасимләребезне (йолаларыбызны.— *Х. М.*) генә. Әйтеп тә торасы юк, кияү белән кәләш бездә баштанаяк йаурупача киемнән булалар. Мулланың чалмасына күз ташламасаң, егет — урыс малае, кәләш марҗа кызы төсле. Татар туе дип тә белмәссең инде. Шунда туташның башына йодрык чаклы гына калфак, егетнең маңлаена төшереп кенә бер кара кәләпүш кидереп җибәрдеңме, күренеш бөтенләй үзгәрә дә китә. Карап торырга да күңелле һәм милли дә. Дөрест, яшьләрнең икесе дә баштанаяк бөтенләй милли киемнәрдән булсалар, тагы да күркәмрәк булыр иде дә. Заманның агышы белән санашмыйча булмый шул. Без бит инде хәзер «Гәзизә балдыз»ларны да, «Тәфтиләү»ләрне дә электәге кебек чаршау аркылы түгел, радио аркылы тыңлыйбыз. Гармунны да авылдагы кебек җиде төн уртасында мунчаларга барып өйрәнмибез. Көйләребезне көпә-көндез пианоларда (пианиноларда.— *Х. М.*) әйттерәбез. Шулай, дуст, миллиләштерә торган нәрсәләребез, бел, күп. Тагы бер мисал китерим әле. Алыйк ыстакан чәйне генә. Сыек ясалды, ди; сиңа сөйләп тә торасы юк, ул инде безгә ярамый. Без, хәзер чыраебызны сытып: «Мәскәү күренә бу чәйдән!» — дибез. Инде шул тәме дә, яме дә булмаган сыек чәй үтәли Мәскәүне күрмик дисәк, ни эшләргә кирәк була? Чәйне миллиләштерергә, ягъни аңа үзебезнең милли төсебезне бирергә кирәк була. Бу исә бер дә читен булмаган бер эш: тотасы да пишәдә (утта.— *Х. М.*) пешкән көе чәйнек борыныннан ыстаканга бер дә саранланмыйча агызасы. Шулай итеп, чәй дә үзебезнең төрк-татар төсен алыр, Мәскәү дә бөтенләй күренмәс булыр. Вакыт юк, тагы да бераз сөйләшәсе иде дә, күрешербез әле,— диде милләттәш.— Син менә, дускай, яхшымы, яманмы, бер каләм эшчесе, шул турыда берәр нәрсә язып җибәр әле. Хуш,— дип китә дә башлады.

Артыннан кычкырып калдым:

— Нәрсә, чәй турындамы?! Юк инде, анысы булмас, абзый. Аш-су хакында язу бетте! Болай да мине кайберәүләр, үзе ач йөрегәнгә күрә, бәлеш белән пәрәмәч хакында яза дип шелтәлиләр.

*Харбин, 1941*

### Уртак вөҗдан*

Хәсән «Мең ел мәсҗете»ндә** укылган Гает намазыннан соң, челтәрле капка төбендә бераз басып, илле яшьтән узган мәхәллә әгъзалары белән ике куллап, соңгарак калып дөньяга килгәннәргә бер генә кулын сузып тәбрикләште дә бер-бер артлы чыгып килүче ике кордаш(ын) каршы алды. Өч буйдак чат башында тукталып, ашыгыч рәвештә күчмә бер корылтай*** ясап алдылар.

— Я, җәмәгать,— диде берсе,— кая барабыз? Визитны берәр кызлы гаиләдән башлап җибәрәсе иде...

— Кызлы гаиләдән! Әйтерең бармы авызың кыйшайтып,—дип үчекләп куйды аны.

Намазга чаклы ук кайдадыр шома гына кырынып алырга зирәклеге җиткән икенче берсе: «Кыз-кыз» ди-ди, Чурин**** артына да китәрсең, ахры. Инде кызлы йортка барудан синең үзеңә ни файда да, кешегә ни файда? Йөрисең шунда эч пошырып...

Яр булыр өчен яралмаган,
Җан көйдерер өчен яралган.

— Туганнар! — диде башта ниндидер уе барлыгы күзләренә чыккан Хәсән.— Сез теләсәгез ни эшләгез, мин өйгә кайтып килием әле. Кайда булса очрашырбыз...

Бәйрәм көн вакыт кадерле, озак сатулашып тормады-
лар — таралыштылар. Хәсән өенә кайтып китте. Бер бүлмәле фатирда торадыр иде. Капка төбендә «Бәйрәм белән!» диеп үзен каршы алган хезмәтче русның кулына сыңар сумны төртте дә, бик җитез ачкычны борып, ишекне ачты. Бик җитезләп ярым кышкы пальтосын, баштагы очлы бүркен салып ташлады да кием-салым шкафының көзгесе алдына килеп басты. Көрән киемдән килешле генә гәүдәле, урта буйлы, тулы гына йөзле бер төрк-татар әфәндесе.

— Шулай итеп,— диде ул, көзгедәге күренешенә сокланып.— Син хәзер генә дини булган бурычыңны үтәп, Гает намазын укып кайттың. Инде калды ярым милли, ярым иҗтимагый бер вазифаң — ул да булса һәрбер өйдә берәр чынаяк чәй эчеп, милләтебезнең тере бер өлеше булган мәхәлләбезне әйләнеп чыгу.

Шулай дип сөйләнә генә башлаган иде, көзге бераз томанланып киткәндәй булды да, Хәсәннең, анда күренгән сыны кечерәеп, гәүдәсе киңәеп, бите җыерчыкланып китеп, кыска гына мыегы агара башлап, ияк вә яңакларын чал үсемлек каплады. Көтелмәгән күренеш Хәсәннең йөрәгенә курку салды. «Берәүнең каргышы төштеме әллә, беркемне да рәнҗеткәнем юк кебек» дигән уйларга китте ул. Тик өстәлдәге кечкенә көзгедә үзенең чын йөзен күргәч кенә, бераз тынычлана төште. Ләкин зур көзгедәге кеше чәч-сакалы ап-ак бер карт булып өлгергән иде инде. Очкычтан ташланган кебек югарыдан аның башына Әхмәд бай белән Каюм Насыйри бүрке шикелле бер әйбер килеп төште. Сакал-мыегы кыскара төшеп, башына чалма кигезсәк, ишан хәзрәткә охшар кебек бер төс ала башлаган иде. Сурәт телгә килде:

— Мин синең вөҗданың!

Ләкин шайтан уены һаман дәвам итә иде әле. Рәсем тагын берничә төрле үзгәрешләр кичереп, башыннан бүрек юкка чыгып, чәч-сакалы озынаеп, Лев Толстой чыраен ала башлаган иде. Хәсән:

— Кит, югал! — дип,— вөҗданым булсаң, зинһар, карт урыс төсле булып килмә, мөлаемрак бер рәвеш ала күр.

Көзгедә күренмичә эшен дәвам итүче ниндидер серле рәссам сурәткә бер матур кыз кыяфәте эшләргә тотынган иде, Хәсән моңарга каршы килде:

— Кирәкми! Хатын-кызга ышанмыйм, алдыйлар.

Ул хәлсезләнеп, көзгегә каршы дивар буйлап куелган өстәл янына килеп утырды. Көзгедәге сихерле төрләнеш, баш әйләндергеч алмашу кызулана гына бара иде.

— Соң син минем вөҗданым булгач, нигә әллә нинди пәри алмаштырган кебек кыяфәтләргә керәсең. Син минем үзем төсле үк булырга тиеш,— дип зарланды Хәсән. Күренми торган рәссам бертөрле карт башларын ясап тору эшендән туйдымы, яки яратыш-истигъмаль ахырында инде канәгатьләндерергә муафыйк булдымы, көзгедәге кыек-мыек селкенешләр тукталып, тылсымлы сурәт бер калыпка коелып, ак кәләпүшле, ап-ак сакаллы, изүе баулы, ак күлмәкле сөйкемле генә бер авыл карты төсендә төгәлләнде.

— Мин синең моннан алтмыш ел элек дөньядан кичкән Бәхтияр бабай сурәтенә кергән вөҗданың, бер син генә түгел, бөтен нәселемезгә уртак булган вөҗдан мин.

Уртак вөҗдан «эһем» дип бик аһәңле итеп бер тамак кырып алды да:

— Газиз углым,— диде,— яшең кырыктан ашты. Сиңа инде хәзер шул буа белән бәйрәм котлап йөрү килешми. Аңладыңмы, килешми! Ул табадагы капса телеңне йотарлык кайнар сумсалар, ул кетердәп пешкән кош телләре, билбау-билбау катламалар, саз җиләге, алма вә белмим тагын нинди төрле җимеш эчле бәлешләр, бал-май эчендә генә пешкән татлы чәкчәкләр, катлы-катлы торт сыман пешерелгән шоколад-кәнфитләр,— озын сүзнең кыскасы, кыз-хатынның бик күп кан бозып, бик күп көч куеп, атна-ун, хәтта берәр ай элек кайгыга салып, зур мәшәкатьләр чигеп өлгерткән бәйрәм ашларын өйдән өйгә кереп ашап йөрү түгел, авыз итәргә дә синең хакың юк! Ишетсен колагың, берсе дә, берсе генә дә алар синең өчен түгел! Алар өйләнгәнләр өчен! Бик яхшы белергә тиешсең ки, бәйрәм ашы кара-каршы була. Ә синең каршыга ниең бар?! Тәмле-тәмле нигъмәтләрне рияздан гына, күңел өчен генә мактый-мактый ашап, рәхмәт дисең дә, шуның белән эшең дә бетә. Бәйрәмнәрнең хатынлы, бала-чагалы кешегә күпмегә барып төшүе хәбәреңә (хәтереңә.— *Х. М.*) кереп чыкмый. Син бу Гаеттә утыз тиенгә барып мунча кердең, сиксән тиенле оеклар, җитмеш биш тиенгә барып әнә шул муеныңа таккан чувар (чуар.— *Х. М.*) чүпрәкне сатып алдың. Садаканы бирсәң бирәсең, бирмәсәң юк. Әлхасыйль (җыйнап әйткәндә, кыскасы.— *Х. М.*), өйләнгәнләр хисабына бәйрәм итәсең. Буйдакларга салым салырга иде дә бит, әлеге шул мөселманчылык, кызганыч күренәсез. Өстәвенә чат башындагы «Кытай кибете»нә дә бирәчәгең бар...

Уртак вөҗдан вәкарь белән бик шәплэп тагы бер кат тамак кырды:

— Әнә берүзең генә ашап бетерәсең. Америкада көненә икешәр алма ашыйлар дип кайдандыр ишетеп тә, моны эшләгәнсең. Үзеңә файдасы булганга күрә генә, һәй, бәрәкәтсез!

Бу сүзләрдән соң Хәсәннең тәне эсселе-суыклы булып китеп, терсәге белән өстәлдәге мәйвә (җиләк-җимеш.— *Х. М.*) савытына кагылды. Кызыл алмалардан берничәсе, бәрәңге тәгәрәгән кебек дөбердәп идәнгә төшеп, кайсы ятак, кайсы шкаф астларына таба юнәлеш алдылар. Хәсән качкын мәйвәләрне тотам дип урыныннан кузгалып иелгән иде, маңлаен көзгегә китереп бәрде. «Алла, башым!»— дип күтәрелеп караганда, көзгедән Бәхтияр бабасы киткән иде инде. Хәсәннең башында милли саз төркеме (ягъни оркестр.— *Х. М.*) уйнала, колакларында «Һаваларда йолдыз», «Бибисара» кебек җырлар белән радио чыгышлары үткәрелә башлады. Азакта бу концертның тукталуы тагы да күңелсезрәк нәтиҗә бирде. Хәсәннең миендә, ике тәрәзә арасына кереп безелдәгән яшел чебен кебек, бер такмаза әйләнә башлап, бертуктамый кабатланып торыр булды:

Сәт, сәт, сәтәмә,
Пәт, пәт, пәтәнә.
Саесканның койрыгы
Санап баксаң уналты. Сәт, сәт...

Сәгать бу вакытта унберенче иде инде. Хәсән фатирын ташлап качты. Күптән түгел генә чакдаш (чордаш?— *Х. М.*) француз философының «Бәхетсезлектә калганда, агач яфракларының шаулавы адәмнәрнең җылы сүзләренә кара-ганда күңелгә күбрәк тынычлык бирә» дигән сүзләрен укыган иде. Шул исенә килеп төште дә як-ягына каранды. Ләкин агач ботаклары, Шүрәле бармаклары кебек, шыр ялангач иделәр.

Димәк, яз башына чаклы икенче бер философка ияреп торырга калды. Адәм баласы — көтү хайваны. Ул кешесез яши алмый. «Хатын алмыйча да булмас. Тукай өйләнмичә дә зур шагыйрь булды. Адольф Гитлер хатынсыз булып та Аурупада зилзилә ясады»,— дип, ялгыз торырга ярамыймы дигән бер фикер узды Хәсәннең башыннан.

Буйдакларны гаепләп йөрүдән тыю мәсьәләсен я мәркәз, я Гаяз Исхакый, яки Муса Җаруллаһ* кылсын, без кечкенә кеше, диде ул эчендән, үзенә якын торучы бер таныш гаиләнең ишеге төбенә килде.

— Мең елдан артык ислам дине тотып килүче халкыбызның күркәм холыклары вә мөкатдәс ганганәне («гадәт-йолаларны, традицияне».— *Х. М.*) саклау, җимерелмәс миллият әсаслары илдә узган Милләт Мәҗлесе (нигезләре.— *Х. М.*) мөһаҗәрәттәге ике корылтаебыз (алар 30 нчы елларда була.— *Х. М.*) наменә Аллага тапшырдым, исерек түгелмен, гакылдамын, ашасам ашармын бер чикләвек дип, бер дога сыман нәрсә укып, ишарәт бармагы белән кыңгырау төймәсен баскан иде, әкиятләрдәге кебек секунд эчендә ишек ачылып китеп, бусагада буйчан гына, ачык йөзле, шад, җылмайган бер туташ күренде.

— Мөбарәк булсын!

### Тормыш ыгы-зыгысында**

Тормыш кайбер бәндәләрне кардәш-ыруг, дуст-иш, күрше-күлән, кода-кодагый белән шулай әйләндереп алгандыр ки, бу әйләнмәлек эчендә башларың гына түгел, ата-анаңның мулла абзыйдан куштырган исем шәрифең дә әйләнеп китә. Болай кемгә дә булса тиеп әйтүдән түгел, тик үрнәк өчен генә, Фәлән әфәндене алыек. Фәлән әфәнде, әйтик, буйдак. Бер дә өйләнмәгән. Бик яшь тә түгел, русчалап әйткәндә, «кыргак» инде. Көнләрдән бер көнне ул бер милли туташка күзе төшеп, артыннан йөри башлый. Туташ гүзәл генә, уңган гына, чибәр генә. Укымышы да юк түгел, һөнәре дә бар... Биегәндә дә бик әдәп белән генә бии. Фәлән әфәнде аның белән милли кичәдә тагы да якынрак танышып китә. Туташка ике лотари (лотерея.— *Х. М.*) билеты дә алып бирә, программ һәм чәчәк тә. Буфетка кереп берәр суык шукалат (шоколад.— *Х. М.*), канфит та ашап чыгалар. Фәлән әфәнде, үзе бик өшегән аяклардан булмаса, туташны фокстротка (биюгә.— *Х. М.*) чакыра. Култыгыннан тотып барырга кыюлыгы җитмәсә дә, аны өенә озатып куя.

Бер-ике көннән Фәлән әфәнде туташны теллерәсем (синема) (кинофильм.— *Х. М.*) карарга да чакыра. Ярым караңгы залда үзенең теле ачылып китә, «Маем, мин сезне сөям»,— ди. Бераз гына кесә байлыгы өстенә, Фәлән әфәнде хыялга да баерак булса, «маем» урынына «җаным», «ике күзем» диеп тә куйгалый. Сайрар кош исемләре дә эшкә китә: карлыгачым, былбылым, сандугачым, күгәрченем, тургаем, Мысыр күгәрченем... Инде башына тай типкән кеше булса да, сөйгәнен йорт кошлары исемләре белән мактамас. Ул инде шулай килә: сөйгәне бик яхшы гына итеп «Дүдәк» яки «Хәйренниса-Фәхренниса» көйләрен җырлый белмәсә дә, барыбер ул «сандугачым, былбылым» була. Керпе дә, борынгылар әйткәндәй, баласын йомшагым дип, аю да үз баласын аппагым дип сөя.

Ничек кенә тату тормасыннар, ир белән хатын арасында да бер-беренә «казым» яки «үрдәгем», яисә «тавыгым», яки «әтәч һәм кучатым» дип тә дәшкәнне ишетмәссез. Этле-мәчеле торучыларны алмыйбыз да инде. Алар арасында кызулык белән ишәк, сыер, бозау вә башка әллә нинди хайван исемләре дә акча шикелле йөри торганлардыр... Кайбер вакыт тәмле җиләк-җимеш исемләре дә гаилә тормышында бик яраклы булалар: йөзем, җимешем, хөрмә җимешем, алмам...

Гафу итегез, Фәлән әфәнде хакында сөйли идек бит. Я, әйе, Фәлән әфәнде, әйтик, шулай итеп, башлы-күзле булды. Кәләшенең исеме дә һаман әле җанкаем да майкошым гына. Бала була. Бичара җан иясе ике арадагы мәхәббәт җомгагы белән гөнаһсыз гына шаяра башлый. Фәлән әфәнде хәзер майкош урынына «әнисе» ди вә үзенә дә каршыга «әтисе» дигәнне ишетә башлый. Сабыйга да аларның мулла кушкан исемләренең кирәге юк: берсе — әннә, икенчесе — әттә.

Бикәч Фәлән әфәндегә үзе белән бергә үз өеннән кием-салым һәм бер тегү машинасы белән әллә ничаклы дәрәҗәле исемләр дә алып килә: кияү, җизни, кода, баҗа... Үзе дә боларга каршы гомерлек дәрәҗәле исемләр ала: килен, җиңги, кодача...

Фәлән әфәнденең әйләнә-тирәсендә дә шулай ук мулла кушкан исемләре белән аталмый торган затлар — әби, бабай, каенага, балдыз, кода, кодагый, каене...

Дөрес, Фәлән әфәндегә үзенең каенесенә «акыллы баш», «җебегән авыз» дип тә дәшкәләргә тормыш әйләнмәлеге ихтыяр бирә бирүен дә, әмма вакытлы гына. «Җонлы колак» буйга җизнәсенең борыныннан да югарырак озынаеп китеп, «Ай лаф-ю» сабагына төшеп, йодрыкларын «Со Luisныкы (бокстан дөнья чемпионы.— *Х. Г.*) кебек ясыйм» дип бокска да өйрәнә башлагач, аны инде чын исеме белән дә атамый булмый. Атамасаң — ататтырыр!

Фәлән әфәндене, әйтик, милли оешмадан милли кичәгә янә сорап баралар (киләләр.— *Х. М.*). Өйдә хатын гына. Ул килүчеләргә, бик йомшак кына итеп: «Белмим, үзе өйдә юк,— ди.— Миннән бер бәлеш языгыз. Акчаны инде үзе кайткач сорарсыз».

Хатын кул куеп ала торган хатларны да кире кайтара: «Үзе юк»,— ди. Чөнки Фәлән әфәнденең, әйтик, әллә нинди кызгылт, күгелҗем кәгазьләргә кул куеп, авызы пешкәнен хатын ишеткәләп тора.

Кыскасы, монда да Фәлән әфәнденең мулла кушкан исеме әйтелми, «Үзе» генә яки «Безнеке» генә: «Безнеке бик нервный. Безнеке кибеттән кайтуына аш аз гына өлгереп йитмәсә дә дөнья куптара...»

Фәлән әфәнденең исеме белән исемләнгән бик күп танышлары бар. Аларга да ул мулла кушкан исемләре белән дәшми, «адаш» кына ди. Мәсәлән:

— Адаш, ишеттеңме әле яңа хәбәр? Харбиннан мәркәз файдасына бер тиен милли салым җибәрә башлаганнар.

— Кит аннан, адаш, булмас, ышанмыйм, ничә тиен?

Фәлән әфәнденең, әйтик, фатиры белән янәшә торучы да — үзебезнең мөселман, Идел буе Шимал татар-төрке. Фәлән әфәндегә аның да мулла кушкан исеме кирәкми. Алар бер-берләренә «күрше» дип кенә дәшәләр.

— Күрше, Гайд мөбарәк булсын! Күрше, тәмәкең юкмы? Күрше, шырпың бармы? Күрше, миңа бер-ике тәңкә акча биреп тормассыңмы? Күрше, зонтигыңны биреп торчы! Күрше, миңа шәрк (җыр-бию.— *Х. М.*) кичәсенә барырга чалбарыңны биреп торчы. Бары бер син фокстротта биимсең.

Фәлән әфәнде белән бер яктан, хәтта, бәхетенә каршы, бер авылдан булган дуслары бар, аларның да метрикадагы исемләре кирәкми «якташ» кына, «авылдаш» кына:

— Якташ, ни көн әле бүген безнең, шимбә бугай?

— Юк, якташ, бүген вторник, кажется...

Гәрчә милләтчелеге милли ашлар ашаудан гына гыйбарәт булса да, Фәлән әфәнде,— әйтик, үзе бик милли кеше. Сезгә «кардәшем, милләттәшем» дип кенә хитаб итә (дәшә.— *Х. М.*). Язганда да шулай. Мәсәлән, ачык мәктүб (хат.— *Х. М.*) белән ул дуст-ишләрен бәйрәм белән тәбрикли: «Кыйммәтле кан вә тел кардәшем! Гайд мөбарәк бәйрәме вә Гайд зөһни шәриф вә сәгыйд (изге вә бәхетле.— *Х. М.*) көне белән котлап, тәбрик итеп вә... кулларыңны кысып, маңгайларыңнан үбеп, башымны иеп, йөрәгемә сул яктан кулымны куеп, әссәламегаләйкүм, җәбһәдәш (якташ, фикердәш.— *Х. М.*)!

Киләчәк бәйрәмләрдә янә туган-үскән илебездә ихлас калебтән (йөрәктән.— *Х. М.*) очрашса иде дийү, милләттәшең, илдәшең һәм дә качакташың».

Яки, мәсәлән, әйтик, котлаш (котлау.— *Х. М.*) рәсемле «ачыклама» (открытка.— *Х. М.*) түгел, болай сәлам мәктүбе генә язып җибәрә. Монда да аның үзенең дә, мәктүб адреслаган затларның да мулла кушкан атлары кирәкми.

«Һуаллаһ — ул бари (яратучы.— *Х. М.*), әткәй, әнкәй, ерак җирнең хәле. Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү улып торгучы газиз әткәмез белән әнкәмезгә безки углыгыздан күптин-күп... сәлам. Сөекле җизнәбез белән апамызга күптин-күп сәлам. Сәлам бәгъдендә (соңында.— *Х. М.*) сүзебез шулдыр: бу якларда кыш салкын килде. Хикмәт бу сәнә (ел.— *Х. М.*) куян ите бик очыз (очсыз.— *Х. М.*). Бер дә ашаганым юк иде, бу сәнә авыз иттем. Үзендән ат ите вә фазан (кыр тавыгы.— *Х. М.*) кош ите тәме дә килеп куя. Сезләрне бик сагынып вә бик саргаеп, бер күрергә зар вә интизар булып бер җыр да язамын. Язуым начар чыкса да, төзәтеп укырсыз. Сүз күп иде, мохтәсар (кыска.— *Х. М.*) кылдык һәм дә җырның җыртыгы юк:

Харбински калабыз, химически карабыз,
Балагызны сагынсагыз, көнчыгышка карагыз.

Догаларыгызны үтенеп, газиз углыгыз. Киленегез дә сәлам укыды».

Шулай итеп, Фәлән әфәнденең чын исемен аның паспортын карамыйча белә дә алмассың. Ә паспортта, билгеле инде, рус чиновнигы синең мулла кушкан исемеңне әйләндергәләп яза. «Әхмәт булсаң — Бахмет», «Шаһмәрдән булсаң — Шинмархен», «Мөхәммәдҗан булсаң — Мухидзан» булып китүең дә бик җиңел. Паспорт язучы кечкенә генә түрә болай торсын, урысның зур язучыларыннан Чехов та үзенең «Сахалин утравы» дигән китабында татарча исемнәрне, бигрәк тә хатын-кызларны язу

бик читен дип зарлана. Чехов — әле шуның өстенә төрле яңа фамилияләр уйлап чыгарырга да оста булган кеше...

Еллар уза, Фәлән әфәндебезнең икенче, өченче, дүртенче балалары да булып, Фәлән әфәнде һәм хатыны инде «әтиләре» белән «әниләре» булып китәләр. «Угылым» да «кызым», барысы да үсәләр дә, өйләнәләр, кияүгә чыгалар. Фәлән әфәнде инде бабай була. Тормышның һәнүз (һәрчак, һаман.— *Х. М.*) ыгы-зыгы килеп торган көне. Өйләндергәч, исемләр өстәлеп, артып кына торалар. Карт әни, карт әти, әни карчык, дәү әти, дәү әни, зур абый, кечкенә абый, тәтәй дә түтәй, апа да түтиш, абыз да абыстай, алма апай да матур апа, мулла җизни, шәкерт абый, иркәм дә, сабый да, кара кашым да, нечкә билем, тулган аем, тудыка, туганым, тумачы...

Шулар өстенә инде ата-бабаңнан мирас булып килә торган кушаматың да булса, бу гомерлек исемне инде нинди генә химик ысул белән тазартсаң да югалта алмассың.

Каюм бабай Насыйри үзенең «Ләһҗәи татари» китабында бик дөрест әйтә: «Татар теленең хикмәтләре бик күп, әфәндем».

## «АЗАТ ВАТАН» ЖУРНАЛЫ

### I

«Азат Ватан» — бу сүзләр аерым-аерым да, гыйбарә рәвешендә дә җаны, инсани рухы, милли барлыгы булган һәр кешегә якын һәм үз. Коллыкта, бәйлелектә, ватансызлыкта яшәү — һәркем өчен гайре табигый хәл. Ирекле тормыш, үз тереклегеңне үзеңчә кору — сулаган һава, эчкән су, ашаган ризык кебек зарури нәрсәләр.

Бу изге, мөкатдәс сүзләр белән аталган журналның исеме аның җисеменә, мәсләгенә ни дәрәҗәдә туры килә соң? Мәҗмуганың төзелеше нинди, эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Бу төр сорауларга инде гыйльми-публицистик әдәбиятта өлешчә, теге яки бу күләмдә җаваплар да бар. Мәсәлән, тарихчы Искәндәр Гыйләҗев «Казань» журналында басылган «Неоконченный урок...» исемле публицистик рухлы мәкаләсендә (1994.— № 5—6.— 107—111 б.) мөһаҗирләр язмышы, аларның көндәлек басмалары, җөмләдән «Азат Ватан» хакында да аерым мәгълүматлар бирә. Ул бу журналның 1952—1953 елларда АКШ ярдәме белән Мюнхенда нәшер ителүе, барлыгы 13 мәртәбә чыгуы (шуның 4 нче һәм соңгы саннары — яңалиф, калганнары гарәп хәрефләре белән басылуы), соңгы ун номерының урысчага да тәрҗемә ителеп, аерым төпләм рәвешендә дөнья күрүе хакында искәртә. Мәкалә авторы мәҗмуга эшчәнлеген шактый тәнкыйди рухта карый, иҗтимагый-сәяси һәм тарихи эчтәлектәге аерым материалларга күзәтүләр ясый. Ул әдәби текстларны гомумән читтә калдыруын, аларның сәнгати яктан шикле булуын әйтеп үтә.

Тәлгат Насыйров үзенең «Татар мөһаҗирләре матбугаты» исемле язмасында (Казан утлары.— 2001.— № 7), чит илләрдә чыккан башка татарча гәҗит-журналлар белән беррәттән, «Азат Ватан» мәҗмугасына да туктала (161 б.). Аның фикеренчә, XX гасырның төрле елларында Алман илендә татарча 17 гәҗит-журнал нәшер ителә. Шуларның икесен — «Идел-Урал» һәм «Азат Ватан»ны Т. Дәүләтшин нигезли. Т. Насыйров «Азат Ватан»ның латин хәрефләре белән генә басылуын искәртә. Чынлыкта исә журнал урысча да, гарәп хәрефләре белән татарча да нәшер ителә. Мәҗмуга хакында гомуми мәгълүматлар безнең мәкалә-хезмәтләрдә һәм «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә дә (Казан, 1999.— 16 б.— Урыс телендә) бар.

«Азат Ватан» дөньяның төрле төбәкләрендә сибелеп яшәгән милләттәшләребез арасында шактый киң тарала. Әмма Советлар Берлегенә ул ирешми диярлек. Чөнки махсус оешмалар, гәрчә журнал белән үзләре теге яки бу дәрәҗәдә танышып барсалар да, аның халыкта таралуын катгый тыялар. Шуңа күрә «Азат Ватан» белән без шәхсән чагыштырмача соңрак, бары 90 нчы елларда Хельсинкидагы милләттәшләребезнең китапханәләрендә генә таныша алдык. Анда да барлык саннары белән түгел. Кайберләренең я татарча, я урысча номерлары гына бар. Шуңа күрә журнал турында фикерләүдә һаман да әле тулылык җитми.

### II

«Азат Ватан» — юка тышлы, чагыштырмача зур форматлы (21 ә 29 см. 1 нче саны бераз кечерәк: 19 ә 26 см) журнал. Күләме төрлечә: урысчалары, нигездә, 32—34, ә татарчалары уртача 32—39 битле. Мәҗмуганың урысча саннары — татарчадан тәрҗемә. Әмма бу ике телдәге текстлар тәмам тәңгәл килә дигән сүз түгел. Мәсәлән, татарча 7 нче сандагы «Корбан бәйрәме» (18 б.), «Колхоз турында нәрсә сөйлиләр» (29 б.), «Халыкара хәлләр» (30—31 б.), «Белдерүләр» (32 б.) һәм кайбер башка язмалар урыс телендәге 7 нче санда күзгә ташланмый. Үз чиратында урысча номерда да татар телендә булмаган материаллар бар («Западная Сибирь во время коллективизации».— С. 9—10; «Каюм Насрый».— С. 11—12). Бу төр аермалыклар аеруча әдәби текстларга карый. Мәсәлән, татарча шигырьләр урысчада бөтенләй бирелми диярлек. Әмма, ничек кенә булмасын, «Азат Ватан» — бер журнал. Чөнки аның һәм татарча, һәм урысча нөсхәләре төзелеш һәм эчтәлек ягыннан, идея-мәсләки җәһәттән бер-берсенә бик якын, нигездә, үзара туры киләләр.

Алдарак әйтелгәнчә, мәҗмуганың татар телендәге күпчелек саннары — гарәп язуында.* Әмма аерым нөсхәләрнең ахырында гарәп графикасындагы материалларның кайберләре яңалиф белән дә бирелгән. Мәсәлән, 7 нче санның 33—39 нчы битләрен латин язуындагы текстлар тәшкил итә.

Мөгаен, әүвәл журнал хезмәткәрләре карамагында гарәпчә басма хәрефләр булмаган. Чөнки мәҗмуганың тәүге саннарында гарәп графикасындагы текстлар башта кулдан язылып, аннан соң күбәйтелгәннәр. Бу хәл журналның техник яктан сыйфатын киметкән. Әмма бераздан гарәп язуындагы татарча текстлар басма ысул белән бирелә башлый.

Күпчелек саннарда журналның кем тарафыннан, кайда чыгарылуы, адресы немец һәм инглиз телләрендә дә күрсәтелә. «Эчтәлек», гадәттә, урысча һәм татарчадан тыш, инглизчә дә бирелә.

Журналда иллюстратив материаллар, рәсем-фотолар бик аз. Мәсәлән, 8 нче санның тышлыгында Сөембикә манарасы, эчендә Гаяз Исхакый рәсеме генә бар.

«Азат Ватан» Алманиядәге «Татар-башкорт милли тәшкилияте» тарафыннан чыгарыла. Мәгълүм ки, бу тәшкилият (оешма, комитет) 1947 елда төзелә. Аның тәүге җитәкчесе — профессор, тарихчы, хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, идеолог Тамурбәк (Тамырбәк, Тимербәк) Дәүләтшин (1904—1983). 1938—1941 елларда бу зат Бөтенсоюз юридик институтының профессоры, Татарстан Югары Советы Президиумы каршындагы хокук бүлеге җитәкчесе булып эшли. 1942 елда әсирлеккә эләгә. Сугыштан соң Көнбатыш Аурупада гыйльми-сәяси, иҗтимагый хезмәт белән шөгыльләнә. Аның 1974 елда Лондонда басылган «Советский Татарстан: Теория и практика национальной политики» китабы (392 б.) заманында СССРда һәм чит илләрдә көчле резонанс алган иде. Т. Дәүләтшин 17 меңнән артык сүзне үз эченә алган «Татарча-немецча сүзлек» (Алмания: Висбаден, 1989.— 365 б.) соавторы буларак та мәгълүм (*Х. Миннегулов, М. Хайруллин*. Звезда Тамурбека Давлетшина // Вечерняя Казань.— 14.11.1990). Бу зат «Татар-башкорт милли тәшкилияте» белән 1952 елның 23 мартына кадәр җитәкчелек итә.

Аннан соң үз теләге белән бу вазифасын калдыра. Тәшкилият рәисе итеп Г. Фәйзуллин, баш секретарь итеп Ибраһим Бадай сайлана. Оешма җитәкчесе бер үк вакытта «Азат Ватан»ның мөхәррире дә була.

Г. Фәйзуллин тормышы хакында кулыбызда хәзергә мәгълүматлар юк. «Адвокат Хурамша» исемле язмасында (7—8 нче саннар) ул үзе хакында кайбер белешмәләр бирә. Истәлекләрдән бирелгән тасвирланган вакыйга-хәлләрнең 30 нчы елларда Казанда баруы, авторның фәкыйрь студент икәнлеге, әти-әниләренең, репрессияләнеп, сөргенгә җибәрелүләре аңлашыла. Г. Фәйзуллин, гаделлек өчен көрәшеп, ахыр чиктә НКВД тырнакларына эләккән атаклы адвокатка теләктәшлек белән карый.

Журналдагы материалларның шактые баш мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган. Алар Г. Фәйзуллинның белемле, киң карашлы, сәясәттә хәбәрдар булуын күрсәтеп торалар. Каләме дә шома гына. Журналның 8 нче санында, мәсәлән, аның «Разия» исемле бер язмасы бар. Хикәянең сюжеты түбәндәгедән гыйбарәт: Семипалат каласы. Кечкенә генә бер бүлмәле фатирда әтисе белән Разия исемле кыз яши. Әнисе күптәннән вафат. Әтисе — элеккеге ак офицер. Казаннан килгән бу кеше биредә монтер булып эшли. Кызын бик ярата. Аны укытып кеше итү — атаның төп максаты. Әмма беркөнне Разияның әтисен кулга алалар. VII сыйныфта укучы кыз мәктәптән чыгарыла, ачлыкта, фәкыйрьлектә кала. Күрше хатыннарының ярдәме белән ул, әтисенә тапшыру өчен, бераз ризык туплап, төрмәгә бара. Әмма Разияны әтисе белән күрештермиләр. Шуңа да карамастан кыз күп мәртәбәләр зиндан капкасына килә, декабрь суыкларында катып, дерелдәп тора, күзеннән яшьләр ага. Һәм, ниһаять, әтисенең атып үтерелгәнен ишетә. Җил. Кар. Буран тынгач, узып баручылар төрмә тирәсендә катып үлгән Разияның гәүдәсен табып алалар. Кулында төенчек. Аның эчендә әтисенә дигән кара ипи кисәге һәм берничә бәрәңге. Тетрәндерерлек язмыш. Чорның күпләгән кешеләре кичергән гыйбрәтле вакыйга.

* * *

Мәгълүм ки, икенче бөтендөнья сугышыннан соң Советлар Берлеге һәм Көнбатыш, иң беренче чиратта АКШ белән каршылыклар тагын да көчәя. Капма-каршы ике лагерь арасында көрәш төрле формаларда бара. Бу аеруча идеология өлкәсендә көчле була. Һәр як төрле мөмкинлекләрдән һәм чаралардан иркен файдалана. Бу көрәштә милли фактор гаять мөһим роль уйный. Чөнки һәр халык мөстәкыйльлеккә, үз язмышына үзе хуҗа булып яшәргә омтыла. Бу табигый омтылыш, ягъни милли-азатлык хәрәкәте XX гасыр урталарында дөньякүләм, җиһани төс ала, колониаль богаулар өзелеп, күп кенә кавемнәр бәйсезлек юлына аяк баса. Бу объектив, глобаль процесс һәм Советлар Берлеге, һәм Көнбатыш тарафыннан үз мәнфәгатьләрендә актив файдаланыла. «Татар-башкорт милли тәшкилияте» дә — шул чор объектив вазгыятенең бер күренеше. Аның оешуына, яшәвенә Көнбатышның билгеле бер күләмдә ярдәме булгандыр. Әмма шулай да бу тәшкилиятнең үзәгендә — иң беренче чиратта татар-башкортның үз мәнфәгатьләре, үзенең милли-инсани идеаллары. Чөнки Советлар Берлегендә татар-башкорт мәсьәләсе хәл ителмәгән, милли хокукларны чикләү, кысу дәвам итә. Нәкъ менә шул шартлар да инде мөһаҗирлектәге күп санлы татар-башкортларны кузгалырга, хәрәкәт итәргә, үзләренең көндәлек һәм перспектив таләпләрен куярга мәҗбүр итә.

«Азат Ватан» — «Татар-башкорт милли тәшкилияте» органы. Шуңа күрә аларның максат-бурычлары, теләк-омтылышлары уртак. 1 нче санның икенче битендә үк без мондый юллар белән очрашабыз:

«Азат Ватан» түбәндәге максатлар өчен көрәшә:

1. СССР халыкларының большевизмга каршы бердәм көрәшләре өчен;
2. Берләшкән көч белән большевизмны юк итү өчен;
3. Барлык халыкларның тигез хокуклары һәм мөстәкыйльлекләре өчен;
4. Татар-башкорт халкының үз язмышын үзе хәл итәргә хаклылыгы өчен;
5. Хакыйкатьтә (чынлыкта.— *Х. М.*) халыкның сәяси вә икътисади хакимияте өчен;
6. Халыклар арасында милли, дини, җенси яктан каршылыкларны булдырмау өчен һәм һәртөрле империализмга каршы.

Бу программа журналның һәр ике телдәге барлык саннарында диярлек күрсәтеп барыла. «Азат Ватан»ның аерым сәхифәләрендә тәшкилият куйган максат-бурычлар тагын да конкретлаштырыла, шәрехләнә. Мәсәлән, «Безнең бурычлар» исемле мәкаләдә (№ 1.— 6—7 б.— Авторы күрсәтелмәгән) мондый максатлар да искәртелә: «Чит ил халыклары арасында Советлар илендә яшәүче халыкларның фаҗигале тормышлары хакында аңлату эшләре алып бару һәм... татар-башкорт качкыннарына ярдәм итү... Большевизм хакимияте җимерелгәннән соң, татар-башкорт халкының дәүләт төзелеше, шулай ук аның башка халыклар белән сәяси мөнәсәбәте».

Тәшкилият программасында һәм журналда антибольшевизм (антикоммунизм), антисоветизм ярылып ята, империячелеккә тискәре мөнәсәбәт белдерелә, хакимият белән халыкны тәңгәлләштермәү күзгә ташлана. Мәсәлән, «Бердәмлектә көч» исемле мәкаләдә (№ 1.— 3—5 б.) большевизмга каршы көрәш халыкларның уртак бурычы итеп карала...

## III

«Азат Ватан» — үзенең эчтәлеге, төп юнәлеше белән күптар-
маклы (профильле) мәҗмуга. Анда иҗтимагый-сәяси, тарихи, мәдәни, дини һәм әдәби материаллар урын алган. Көндәлек вакыйга-хәлләр хакында да мәгълүматлар бар. Мәсәлән, журналның бер санында мондый хәбәр бирелгән: «Ярулла Ямали тарафыннан төзелгән ноталы, татар халык җырлары җыентыгы басылып чыкты. Бәһасе — 4 америка доллары». Сорату өчен адресы да күрсәтелгән (№ 7.— 32 б.). (Бу китап безнең хәзерге сәнгать әһелләренә билгеле микән?) 10 нчы санда Казанда елга порты төзелү турында хәбәр ителә (31 б.).

Журналда дөньядагы һәм Советлар Берлегендәге мөһим сәяси вакыйгалар, чорның үзәк проблемалары хакында аерым язмалар бар. Казанлының «Сталинча тынычлык» мәкаләсендә (№ 1.—

8—11 б.) «юлбашчы»ның сүздә тынычлыкны яклавы, чынлыкта исә Советлар Берлеген ашкынып кораллландыруы искәртелә. Г. Фәйзуллинның «Халыкларга каршы яңа һөҗүм хәзерләнә» материалында (№ 7.— 3—7 б.) партиянең XIX съезды алдыннан Советлар Берлегенең эчке һәм тышкы сәяси хәле җентекле анализлана, халыкларның фәкыйрьлеге, хокуксызлыгы ассызыклана. Т. Дәүләтшин мәкаләсендә (№ 10.— 5—7 б.), К. Маркс, Ф. Энгельс, В. Ленин, И. Сталин хезмәтләренә таянып, коммунистларның сугышка мөнәсәбәте теоретик аспектта яктыртыла, аларның сугышны куелган максатка ирешүдә зарури чара итеп караулары дәлилләнә. «Сателлитларның сәхнә артындагы эшләре» язмасында (№ 7.—12—15 б.) Румыния, Чехословакия, Польша, Болгария һәм Венгрия мәмләкәтләрендә сәяси вазгыятьнең тотрыксызлыгы, Кремль диктаты, репрессияләр, эзәрлекләүләр турында сөйләнә. Язма авторы А. Хәким фикеренчә, сателлит илләрдә (ягъни формаль яктан бәйсез, әмма бер куәтле дәүләткә буйсынучы мәмләкәтләрдә.—*Х. М.*) «Кремль юлыннан тайпылучылар рәхимсез җәзалана», хакимият террор, корал көче белән тотыла.

Әмма бу төр, ягъни гомум (глобаль) характердагы материаллар журнал битләрендә чагыштырмача аз. Мәҗмуганың үзәген, әлбәттә, халкыбыз яшәеше белән турыдан-туры яисә өлешчә бәйләнешле язмалар алып тора. Авторлар төп игътибарларын татар-башкортның үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә юнәлтәләр. Бу ягы белән журнал 1928—1939 елларда Берлинда Г. Исхакый тарафыннан нәшер ителгән «Яңа милли юл» мәҗмугасына аваздаш.

М. Кәриминең «Большевикларның татар-башкорт хәрби көчләрен җимерүе» исемле мәкаләсендә (№ 1.— 21—24 б.) милли факторның, сәяси максатларны күздә тотып, ничек файдаланылуы яктыртыла. Үзләренә кирәк булганда, большевиклар милли бригадалар, полк һәм дивизияләр төзергә булышалар. Ихтыяҗ беткәч, аларны тараталар. 1923 елда Казанда татар-башкорт хәрби мәктәбе ачыла. Анда татарча әсбаплар языла, укыту татарча алып барыла. «Кызыларм еец» исемле гәҗит басылуы да мәгълүм. Ел саен 180 гә якын офицер әзерләп чыгарыла. Әмма бу уку йорты милләтчелеккә каршы көрәш байрагы астында 1937 елда таратыла.

Журналның 10 нчы санында (урысча басма, 19—20 б.) М. Кәриминең «Татаро-башкиры, награжденные на Корейской войне» исемле язмасы бар. Биредә безнең күбебез өчен мәгълүм булмаган бер вакыйга турында сөйләнә. Узган гасыр урталарында Корея фронтында БМО байрагы астында махсус ирекле «төрек» бригадасы сугыша. Аның батырлыгы, фидакярлеге хакында дөнья матбугатында күп материаллар басыла. Баксаң, бу «төрек» бригадасының төп өлешен Төркиядә, Япониядә яшәгән татарлар тәшкил иткән икән. Арада шәфкать туташлары, тәрҗемәчеләр дә була. Төрек хөкүмәте Корея фронтында аеруча батырлык күрсәткән күп санлы татарларны орден һәм медальләр белән дә бүләкли. Алар арасында Зәйтүнә Шакир, Хуҗа Әхмәд Ваһап, Фәйзерахман Гыйззәтулла, Халидә Ваһап, Нурия Сәйдәш һәм башка исемнәр телгә алына.

Халкыбызның үткән юлы, азатлык өчен көрәш — «Азат Ватан»ның даими һәм төп рубрикаларыннан берсе. Бу төр материалларда гыйбрәтле факт-мәгълүматлар, мөһим фикер-күзәтүләр бар. М. Кәриминең бер мәкаләсендә (№ 8.— 7—11 б.) татар-башкорт халкының колониаль сәясәткә каршы соңгы 400 еллык көрәш сәхифәләре яктыртыла. Автор Булат-Батыр, Карасакал, Батырша, Салават Юлай, Бәхтияр Канкай күтәрелешләре хакында фикер йөртә, ватандашлар (гражданнар) сугышы елларындагы, Совет чорындагы хакимият һәм халык арасындагы кискен бәрелешләрне дә читләтеп үтми. М. Кәрими фикеренчә, 1919—1920 елларда большевиклар Нижегород төрмәсендәге 20 мең татар-башкортны атып үтерә. Күмәкләштерү вакытында күп меңләгән кешеләр кырыла, төрмәләргә утыртыла, яшәгән җирләреннән сөрелә. Казанда оешкан Татар дивизиясе совет-фин сугышының иң авыр җиренә ташлана һәм шунда аның күп өлеше һәлак тә була.

Ш. Нигъмәтинең «Диния нәзарәте (төзелүенә — 164 ел...)» исемле язмасында (№ 7.— 15—17 б.) татар-башкорт тарихы ислам диненә мөнәсәбәттә карала. Автор фикеренчә, XVI йөздән башлап татарга каршы кыру, юк итү сәясәте уздырыла. «Татар-башкорт халкына рухи көч бирүче ислам дине икәнлеген аңлаган басып алучылар беренче нәүбәттә аларның дин башлыкларын — руханиларны һәм укымышлыларны кырдылар, мәчет һәм мәктәпләрне яндырдылар». Төрле юллар белән чукындыру, урыслаштыру сәясәте алып барыла. «1720 елның сентябрендә чукынган татарларны өч елга салымнан азат итү турында Мәскәү указ» чыгара. «Бүгенге Ленинград шәһәре,— ди Ш. Нигъмәти,— меңләгән лашманчы татарларның сөякләре өстенә корылган». Халык «туктаусыз үзенең дини һәм милли ирке өчен көрәшеп килде». Мәкалә авторы 1788 елның 22 сентябрендә Оренбург шәһәрендә Диния нәзарәтенең төзелүен патша хакимияте тарафыннан ясалган мәҗбүри адым, исламга билгеле бер ташлама итеп карый. Бу оешма патшага бәйле. Мөфтине сайлау юк. Ул билгеләнә һәм үзен куючыларның мәнфәгатен кайгырта. Әмма «ничек кенә булса да, безнең өчен Диния нәзарәте төзелүнең әһәмияте бик зур булган. Халыкка мәсҗедләр ачарга мөмкинлек туды һәм аның аркасында татар-башкорт халкы әхлагын, гореф-гадәтен саклады, үзенең мәдәниятен үстерде. Дини мәктәпләрдә күп санлы руханилар, мөгалимнәр хәзерләнде. Алар арасыннан зур галимнәр һәм язучылар чыкты». Мәкаләнең ахыргы өлеше Совет чорындагы дини вазгыятькә багышланган. Исламга каршы коточкыч көрәш, мәчетләрнең ябылуы, күпләгән руханиларның юк ителүе, сөрелүе шартларында мөфти Ризаэддин Хәзрәтнең «үз вазифасын намус белән үтәве» искәртелә. Берничә ел буе тукталып торган Уфа Диния нәзарәте 1944 елда кабат эшли башлый. Мөфти Рәсүлевкә Кремль тарафыннан «мәчетләрдә намаз уку алдыннан һәр көн саен фронт хәбәрләрен укып чыгарга һәм халыкларның атасы — дин дусты Сталинның сәламәтлегенә дога кылырга әмер бирелә». Язма «ислам дине, татар-башкорт халкы яши һәм яшәячәк» юллары белән төгәлләнә.

8 нче сандагы Рәшид мәкаләсендә ислам диненең Идел-йортта VIII гасырларда ук тарала башлавы әйтелә. Болгар, Алтын Урда һәм Казан мәмләкәтләрендә дин, вөҗдан иреге саклана. Алга таба мәкаләнең эчтәлеге М. Кәрими язмасындагы фикер-күзәтүләргә шактый аваздаш.

Мәгълүм ки, «Азат Ватан» 1952 елда чыга башлый. Бу — татар тарихында мөһим дата: Казанның урыслар тарафыннан яулап алынуына, халкыбызның дәүләтчелектән мәхрүм ителүенә 400 ел тулу вакыты. Шуңа мөнәсәбәтле материаллар мәҗмугада шактый гына. Аның 8 нче — октябрь саны махсус рәвештә Матәм көненә

багышланган. Ул редакцион мәкалә белән ачыла. Анда мөһаҗирлектәге йөз меңләгән татар-башкортларның бу көнне билгеләп китүе ассызыклана, халыкның күпгасырлык фаҗигале язмышы, ireккә омтылышы искәртелә. Милли Матәм көне — башка халыкларга дошманлык күрсәтү көне түгел, ә үзара аңлашу, гаделсезлекләрне бетерү, тигезлек өчен көрәш көне. Алга таба Гаяз Исхакыйның «Казань — символ тюркского единения» исемле мәкаләсе килә
(2—3 б.). Язмада Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре, Идел-йортның урыслар тарафыннан рәхимсез рәвештә басып алынуы, Казанның фаҗигале язмышы яктыртыла. Г. Исхакый карашынча, Казан күп гасырлар буе Мәскәүнең агрессив сәясәтенә киртә булып торды. Аның җиңелүе башка халыкларның иң беренче чиратта төркиләрнең колониаль изелүгә төшүенә юл ачты. Идел-Урал инде менә 400 ел буена үз бәйсезлеге өчен көрәш алып бара, бу изге юлда гаять күп корбаннар бирде. Ахыр чиктә Идел-Урал барыбер бәйсезлеккә ирешәчәк. Бу үз чиратында Кавказ, Кырым, Төркестан халыкларына да азатлык китерәчәк.

Мәгълүм булганча, Г. Исхакый Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре, Казанның алынуы, Матәм көне турында электән үк язып килде. Бу хакта аның «Идел-Урал» китабында да фикер-күзәтүләре шактый. «Яңа милли юл» журналының 1935 ел, 11 нче санында басылган «Казан китүгә 383 ел үтде» мәкаләсе дә (ул безнең кереш сүз белән «Шәһри Казан» гәҗитендә дә басылды.— 14.11.2000) шул мәсьәләләргә багышланган. «Азат Ватан» журналындагы язма да — нәкъ әнә шул сериядән. Мәҗмуганың 8 нче санындагы «Доктор Алпаут», М. Кәрими, «Доктор Ләбиб» мәкаләләрендә дә Казан алыну тематикасы үзәктә тора. Мәсәлән, Ләбиб Каран Сөембикә ханбикә һәм аның Мәскәүгә озатылу күренешләрен шактый үтемле итеп тасвирлый.

Казан алыну фаҗигасе инде элек-электән үк мөһаҗир татарлар тарафыннан билгеләп үтелә. Мәсәлән, XX гасырның 20—30 нчы елларында Варшау, Таллин, Тампере, Токио, Харбин һәм кайбер башка төбәкләрдә матәм чараларының уздырылуы мәгълүм. Бу традиция гасыр урталарында да дәвам иттерелә. Шунысы мөһим: Матәм көненә мөһаҗирлектәге кайбер башка милли оешмалар да (Грузия, Төньяк Кавказ, Белоруссия, Төркестан...) теләктәшлекләрен белдерәләр. Мәсәлән, Грузия Милли Берлеге вәкиле Миндия Лашаури мөрәҗәгатендә мондый юллар бар: «Моим коллегам из редакции «Азат Ватан» желаю, чтобы в скором времени выпускать «Азат Ватан» в городе Казани — в столице татаро-башкирского свободного государства. Склоняю свою голову перед памятью татаро-башкир, погибших за свою национальную свободу 400 лет тому назад на улицах столицы Казанского ханства» (№ 8.— С. 28).

Татар-башкорт — тугандаш кавем. Алар илдә генә түгел, мөһаҗәрәттә дә үзара аралашып, бергә яшәгәннәр, бер халык буларак чыгыш ясаганнар. «Азат Ватан»да без чынбарлыктагы әнә шундый чагылышны күрәбез. Әмма журналда башкорт тарихы хакында махсус материаллар да бар. Шундыйларның берсе — М. Сәфәрнең «Башкорт турында кыска тарихи аңлатма» мәкаләсе (№ 7.— 19—21 б.). Биредә әүвәл бу кавемнең этник чыгышына экскурс ясала. Мәкалә авторы фикеренчә, башкортлар төрки һәм угро-фин кабиләләре кушылудан барлыкка килгән. Алар Хәзәр, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында ук татарлар белән бергә яшәгәннәр. Телләре дә бер-берсеннән бик аерылмый. Бу ике кавем үз ирекләре өчен бергәләп көрәшә. Мәсәлән, мирза Япанчы гаскәренең шактый өлешен башкортлар тәшкил иткән. Карасакал, Батырша, Пугач хәрәкәтләрендә, «сәнәкчеләр сугышы»нда да алар бергә. Мәкалә шушындый юллар белән тәгалләнә: «Югарыда язылган барлык фактлар татар-башкортларның бер җенестән, бер каннан, бер диндә, бер культурада, бер Ватанда яшәгән бер халык булганлыгын ачык итеп күрсәтәләр. Большевиклар, көч белән бер тәнне вакытлыча бүлсәләр дә, татар-башкортларның Кремль коллыгына каршы туктаусыз көрәшүләре гаҗизлеккә төшкән халкыбызга бер көн мөстәкыйльлек тудырып, киләчәктә тарихи берлекләрен яңадан кайтарырга һәм ирекле тормыш төзергә мөмкинчелек бирәчәк».

«Азат Ватан» мөһаҗирлектәге татар-башкорт язмышын да күз уңында тота. Зөләйха Йолдыз мәкаләсендә (№ 1.— 29—30 б.) бу мәсьәлә тарихи аспектта карала. «Мөһаҗирлек,— ди язма авторы,—моннан дүрт йөз ел элек безнең Ватаныбызны рус патшалары басып алганнан соң ук башланды. Патша хөкүмәте тарафыннан төзелгән түзә алмаслык авыр колониаль тәртип меңләгән татар-башкортларны, бай Ватаннарын ташлап, чит җирләргә вә илләргә качарга мәҗбүр итте. Хәзерге көндә татар-башкортларны дөньяның бөтен почмакларында очратырга мөмкин». Аларның «саны ярты миллионнан артык». Совет чорында эчке мөһаҗирлек тә көчәйде. Мәкаләдә читтәге татар-башкортларның нинди генә кыенлыклар булса да югалып калмавы, тырышуы, «үзләрен кабул иткән җәмгыятькә файдалы әгъза булып әверелүләре» искәртелә. Алар үзләренең ана телләрен, гореф-гадәтләрен саклыйлар, үз хисапларына гәҗит-журналлар, китаплар чыгаралар. Бу өлкәдә Зөләйха Йолдыз аеруча Г. Исхакый эшчәнлеген югары бәяли. Ул аны «Татар халкының бөек язучысы һәм сәясәтчесе» дип атый. Мәкалә авторы үз язмасын мондый сүзләр белән төгәлли: «Татар-башкорт мөһаҗирләренең күпчелек өлеше, большевизм җимерелгәч, илгә кайту өмиде белән яшиләр. Без моңа ышанабыз. Ләкин, илгә кайту өчен, большевизмны юк итәргә, аны юк итү өчен, аңа каршы көрәшергә кирәк».

Хокуксызлык, тоткынлык, җәбер-золым инде менә ничә гасырлар буе безнең халыкның юлдашы булып килә. Шуңа күрә алар, аеруча төрмә тормышы — язма әдәбиятның һәм фольклорның да дәвамлы бер тематикасы. Утыз Имәнинең «Горбәтнамә»се, Акмулланың төрмә циклы, Әхмәтҗан Тубыли шигырьләре, Г. Исхакыйның «Зин-дан»ы, И. Салахов һәм А. Гыйләҗев прозасы һ. б.— әнә шундыйлардан.

**IV**

Мәгълүм ки, совет төрмәләрендә һәм сөргеннәрендә газап чиккән миллионлаган кешеләрнең тормышын тасвирлау шәхес культы елларында тыелган тема булып килде. Әмма чит илләрдә бу хакта төрле язмалар туып торды. «Азат Ватан»да да андый материаллар күп. Шунысы үзенчәлекле: мөһаҗир татарларның зур өлеше — Сталин зинданнарының «тәмен», илдәге эзәрлекләүләрнең ачысын-төчесен күргән затлар. Шуңа күрә бу төр авторларның язмаларына биографизм, кырыс чынбарлыкка тугрылык хас. Аларда, уйланмадан бигрәк, документальлек, реаль вакыйгалар һәм фактлар белән эш итү өстенлек итә. Ачы, гыйбрәтле язмышлар күңелне

тетрәндерә. «Азат Ватан»да төрмә, тоткынлык белән бәйләнешле материаллар шактый. Шундыйларның берсе «Сөякләр өстендә корылган шәһәр» дип атала (№ 7.— 23—26 б.). Исеме үк шомлы, куркыныч. Очеркны укыгач, Магнитканың, чыннан да, сөякләр өстендә корылуына, биредә татар-башкортның чебен урынына кырылуына ина-насың. Бу материал Кремльнең шул чактагы сәясәтенә, кылган эш-гамәлләренә халыкара трибуналга бирерлек гаепләү акты булып яңгырый. Мәкалә авторы Фәрит Баяр үз башыннан кичкән, үзе күргән, ишеткән нәрсәләр хакында яза. 1930 елда үзен, әти-әнисен нахак бәла ягып кулга алалар, бөтен нәрсәләре конфискацияләнә. Әүвәл авылдан Идел буендагы шәһәргә китерәләр. 700 ләп тоткын чиркәү бинасында газап чигә. Ачлык, эсселек. Өч айдан соң баржа белән Сембергә озаталар. Аннан 3 меңләп кешене, вагоннарга төяп, Магнит (Магнитогорск) төзелешенә китерәләр. Биредә 100 меңнән артык ярым ач, ярым ялангач тоткын тәүлегенә 12—14 әр сәгать авыр физик хезмәт башкара. «Безне,— ди автор,— тимерчыбыклар белән урап алынган тораксыз һәм ятаксыз ялангa урнаштырдылар... Яңгырлар ява башлагач, без яшәгән җир бөтенләй сазлыкка әйләнде». Көз җиткәч, бараклар төзи башлыйлар. Авыр хезмәттән, йогышлы чирдән, ачлыктан кешеләр бертуктаусыз кырылып тора. 30—40 ар кешене берьюлы күмәләр. Урал елгасы буенда бер җирдә генә дә өч елга 28 мең кеше җирләнә. Качучыларны, гадәттә, атып үтерәләр. 1933 елда, ди Фәрит Баяр, ачлыктан әти һәм 9 туганым үлде. Һәм шул елны ул үзенең качып китүен әйтә. Язма шушындый юллар белән төгәлләнә: «Магнитогорскида булган лагерьдагы әсирләрнең күпчелеге татар-башкортлар иде. Хәзерге көндә большевиклар бу заводта бөтен дөньяны алу теләге белән көн вә төн сугыш коралы эшлиләр».

А. Кубати хикәятендә ерак төньяк концлагеренда кешеләрнең кырылуы, мәетләрнең күмелмичә аунап ятуы, ата-анасыз калган балаларның, хуҗасыз калган терлек кебек, аянычлы язмышы җанлы стиль, образлы тел белән тасвирлана. Бу язманы укыгач, җирдәге бу төр гаделсезлекләр өчен үзеңне дә җаваплы сизәсең, вәхшәт-золым ияләренә карата күңелдә нәфрәт туа. Авторның бу аянычлы вакыйга-хәлләрне үз башыннан кичерүе тексттан ачык беленеп тора. Хикәяләү, сөйләм дә беренче заттан — автор исеменнән алып барыла.

**V**

«Азат Ватан» битләрендә мәдәниятккә, мәгарифкә кагылышлы материаллар да күзгә еш ташлана. «Яңа милли юл», «Казан» (Төркия) журналларындагы кебек, бу мәҗмуга да татарның күренекле сәнгать әһелләре, билгеле галимнәре хакында материаллар биреп бара. Мәсәлән, «Азат Ватан»ның 1 нче санында ук К. Казанлының «Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин» дип исемләнгән күләмле язмасы бар (12—16 б.). Анда бу мәшһүр затның кыскача тәрҗемәи хәле һәм эшчәнлеге бәян ителә.

Мәгълүм ки, Сталин хакимияте Р. Фәхреддингә тискәре мөнәсәбәттә торды. Хәтта аның үлеме хакында матбугатта материаллар бастыру да тыелды. Мөһаҗир татарлар исә бу бөек затка ихтирам хисләрен һич тә югалтмадылар. «Яңа милли юл» журналындагы күпләгән язмалар — шуның ачык мисалы. «Азат Ватан» да шул изге традицияне дәвам итә. К. Казанлы Р. Фәхреддиннең шәхесен һәм эшчәнлеген югары бәяли. Ул аны «Идел-Урал төрк-татарларының уяну дәверендәге иң бөек дин белгече, милли тарихыбызны һәм матбугатыбызны үстерүдә гаять зур хезмәт күрсәткән, бөтен ислам дөньясына танылган галим» дип атый. Мәкаләдә төп игътибар Р. Фәхреддиннең мөфтилек эшчәнлегенә юнәлтелә. Автор аны милли һәм дини берлекне саклаучы юлбашчы, көрәшче рәвешендә тасвирлый. Р. Фәхреддиннең мөфтилек еллары — Советлар Берлегендә дингә, руханиларга каршы көрәшнең кискен чоры. К. Казанлы язуынча, «1929 елдан 1933 елга чаклы НКВД тарафыннан йөз меңләгән дин башлыклары кулга алынды, сөргенгә озатылды, хөкемсез-нисез үтерелде. Ун меңләгән мәсҗедләр ябылды. 1933 елга чаклы большевиклар тарафыннан Идел-Уралда гына җиде меңгә якын, Төркестан, Кырым һәм Кавказда егерме биш меңгә якын мәсҗед көчләп ябылды, җимерелде һәм икмәк амбарларына, динсезләр клубына әйләндерелде. Фәкать Казан шәһәрендә генә 22 мәсҗед яптырылды. Ләкин Риза Хәзрәт бу кабахәтлекләр алдында каушап калмады. Ул һаман да большевикларның бу вәхшилекләрен туктатуны таләп итеп, Кремльгә протестлар ясап торды».

Мәкаләдә шундый бер вакыйга да сөйләнелә: Г. Исхакый 1930 елда «Идел-Урал истикъляллы (бәйсезлеге.— *Х. М.*) өчен көрәш комитеты» исеменнән бөтен гарәп һәм Аурупа илләренә «Ислам дөньясына» исемле мөрәҗәгать тарата. Анда Совет хөкүмәтенең мөселманнарга каршы кылган гамәлләре фаш ителә, ислам дөньясы ярдәмгә чакырыла. Бу өндәмә көчле халыкара яңгыраш ала. «1931 елда Кремль «СССРда ислам диненә бертөрле дә кысу юк» дигән ялган кәгазьгә кул куйдыртып, бөтен дөньяга тарату максаты белән Риза Хәзрәтне Мәскәүгә чакырта. Мөфти Риза Хәзрәт исә: «Мондый ялган сөйләү безнең динебездә юк»,— дип җавап бирә.

Мәкаләдә шулай ук Р. Фәхреддиннең гыйльми, журналистик эшчәнлеге дә яктыртыла. «Асарь» — мәрхүмнең «иң зур кыйммәтле тарихи хезмәте», ә «Шура» «ул чорда иң күп таралган вә сөеп укылган мәҗмугаларның берсе» дип бәяләнә.

Алмания, немец халкы элек-электән фәнгә күренекле шәрыкшенас галимнәрне (ориенталистларны) биреп торды. Шундыйларның берсе — XX йөзнең беренче яртысында һәм урталарында яшәгән Бертольд Шпулер. Ул аеруча Алтын Урда турындагы тикшеренүләре белән мәшһүр. К. Казанлы мәкаләсендә Б. Шпулерның Р. Фәхреддин вафаты уңае белән әйтелгән түбәндәге фикере китерелә: «Мөфти Риза Фәхреддиннең үлеме Русия мөселманнары өчен бик авыр югалту булды. Алар аның белән моңа чаклы сирәк булган мәгънәви бер рәһбәрне (җитәкчене.— *Х. М.*) генә түгел, төрк-татар халкына бик зур сәяси-дини, фәнни хезмәт күрсәткән бер галимне югалттылар. Совет хөкүмәтенең Русия төркләренең соңгы берләшү багы (бакчасы.— *Х. М.*) булган мөфтинең вафатын халыкка белдермәүне тиеш табуында аның төрк милләтчелек мәсьәләсенә урын бирмәскә тырышуы күренәдер. Моның белән Совет хөкүмәте мөфтинең вафатыннан соңра аңа ничаклы зур сәяси вә мәгънәви әһәмият бирүен күрсәтте һәм Совет илендәге төрк-татарлар өчен аның вафатының нинди зур югалту булганын ачык белдерде».

Ш. Зәйтүнә исемле авторның мәкаләсендә (№ 7.—17—18 б.) бөек мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралының тормышы һәм эшчәнлеге бәян ителә. Бу зат бөтен төрки дөньяда «шөһрәт казана». Чөнки ул халыкларны берләштерүгә, мәгариф вә мәдәниятләрен үстерүгә гаять зур өлеш кертә. И. Гаспралы нигезләгән «Тәрҗеман» гәҗите «төрк халыкларының җәмгыяти һәм сәяси тормышларында зур роль уйнады».

А. Мансур (Мансур Арсланбәк.— *Х. М.*) язмасында (№ 7.—22 б.) Муса Акъегетзадә хакында гомуми белешмә бирелә. Мәкалә авторы әдипнең төп әсәре турында болай ди: «Хисамеддин мулла»да шул заман җәмгыять тормышының җитешсез яклары, тәрәккый итүе өчен тәрбия, укыту мәсьәләләренә реформа ясау, хатын-кызларга хокук бирү кирәк икәнлеге күрсәтелә. Шуның белән Муса Акъегетзадә шул ук заманда яшәгән татар реформаторлары Шиһабеддин Мәрҗани һәм Каюм Насыйриларның фикерләрен әдәбият юлы аша яклап чыкты».

Гаяз Исхакый — илдә вакытта гына түгел, мөһаҗирлектә дә татар халкын рухи яктан тәрбияләүче һәм туплаучы, аның ирке, тәрәккыяте өчен фидакярләрчә көрәшүче бөек зат, остаз. Әгәр дә татар XXI гасырга кадәр үзенең милли җанын, газиз телен, иман-ышанычын, көрәшче рухын теге яки бу күләмдә саклап калган икән, без монда шактый дәрәҗәдә үзебезнең Тукайларга, Исхакыйларга бурычлы. «Азат Ватан» халкыбызның ирке, бәхете өчен көрәштә «Яңа милли юл», «Милли Байрак»лар туплаган тәҗрибә-казанышларга нигезләнә, алардагы традицияләрне дәвам иттерә. Бу Исхакыйга мөнәсәбәттә дә ачык күренә. Аның исеме, эшчәнлеге һәрчак зур хөрмәт, абруйлы фактор рәвешендә телгә алына. Журнал хезмәткәрләренең, авторларының шактые — Исхакыйның шәкертләре, аның идеяләрендә тәрбияләнгән затлар. Бөек әдип, бәлкем, «Азат Ватан»га киңәш-теләкләрен биреп торгандыр. Үзе дә анда чыгышлар ясый. Журналда Исхакый хакында махсус язмалар да бар. Мәсәлән: А. Газизинең «Аяз Исхаки Иделли» мәкаләсендә (№ 8.— С. 3—4) Г. Исхакыйның кыскача тәрҗемәи хәле, әдәби, иҗтимагый-сәяси, журналистик эшчәнлеге яктыртыла. Язма авторы, бөек әдипне халыкның ирке, бәхете өчен фидакярләрчә көрәшкән Карасакал, Булат-Батыр, Салават кебек уллары белән янәшә куеп, болай ди: «Одним из таких народных вождей татаро-башкир является Аяз Исхаки Иделли. Воплощая в себе лучшие черты своего народа: любовь к свободе, правде, скромность, трудолюбие,— Аяз Исхаки был подлинным и широко популярным вождем татаро-башкир... На его примере и трудах должно учиться молодое поколение татаро-башкир в борьбе за завоевание свободы».

Журналда әдәбият һәм театр тарихы хакында җыйнама, күзәтү характерындагы материаллар да бар. Мәсәлән, 8—10 нчы саннарда «Арча малае» мәкаләсендә татар әдәбияты тарихы яктыртыла. Әүвәл тарихи-әдәби күзәтү бирелә. Алга таба Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, Ш. Бабич, Һ. Такташ, К. Тинчурин, Х. Туфан, Г. Кутуй һ. б. ның эшчәнлекләре, иҗатлары тикшерелә. К. Насыйриның төрле тармакларда хезмәт итүе, реформаторлыгы ассызыклана. «Һ. Такташ — Тукайдан кала, икенче татар шагыйре. Ул көчле талантка ия. «Киләчәккә хатлар» — аның иҗат таҗы. Биредә Советка каршы тенденцияләр дә бар. Такташ үзенең иҗади мөмкинлекләрен чикләргә мәҗбүр булды»,— диелә язмада.

Мәкаләдә зур урын Тукайга бирелә. Германиядә Гете, Россиядә Пушкин, Англиядә Байрон нинди урынны алып торса, Тукай да татар әдәбиятында шундый ук урынны били, ди автор.

Шунысы мөһим: «Азат Ватан»да Тукай,— гомумән, Исхакый кебек үк, абруйлы зат. Аерым саннарда аның шигъри юллары да күзгә ташлана. Мәсәлән, журналның 1 нче санында (28 б.) Тукайның «Зур теләгем» шигыреннән «Әй газиз Тәңрем, җиһанга чәч бөек Коръән нурыны...» дип башланган дүртьюллыгы бар. Шушында ук С. Сүнчәләйнең «Йа Ходая, рәхмәтеңдән безне мәхрүм кылма син! Күңлебезнең ак күгәрчендәй теләген тыңла син» дигән икеюллыгы да китерелгән.

Мәҗмуганың 8 нче санында Е. Камали мәкаләсендә (21—23 б.) татар театр тарихына күзәтү ясала. Татар зыялылары милли театр ачу уе белән күптәннән янып йөриләр. Язма авторы татарча тәүге спектакльләрнең 80 нче елларда ук куелуын искә төшерә. Мәсәлән, 1887 елда Г. Ильясиның «Бәхетсез кыз»ы сәхнәләштерелә. 1889 елда Касыйм шәһәрендә халык театры ачыла. 1905 елгы инкыйлабтан соң профессиональ театрлар эшли башлый. Язмада Г. Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» эшчәнлеге шактый җентекле яктыртыла. Г. Исхакый, Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш һәм кайбер башка драматурглар, аларның әсәрләре телгә алына. Мәкаләдә аерым композиторлар, җырчылар хакында да фикер-күзәтүләр бар.

И. Бадай мәкаләсендә (№ 10.— С. 25—26) сүз халкыбызның мәгарифе һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән татар бае Әхмәт Хөсәеннең (1831—1906) химаячелек эшчәнлеге, ул ачкан уку йортлары хакында бара. Бу игелекле башлангычны алга таба Яушев, Хәлфин һәм башкаларның дәвам итүе әйтелә. Мәкалә авторы татарларда белем-мәгърифәтнең киң таралуын турыдан-туры химаячелек белән дә аңлата. Язмада мәшһүр профессор Герман Вамбериның 1885 елда Лейпцигта немец телендә басылган «Төрки халыклары» исемле хезмәтеннән мондый өземтә дә китерелә (431 б.): «Число татар, не умеющих писать и читать, совершенно незначительно, чего нельзя утверждать даже о самой Франции и Англии нашего времени...» Мәгълүм ки, бу юлларның авторы — төрки-татар телен, тарихын яхшы белгән, Идел-йортны, Төркестанны гизгән зат.

**VI**

«Азат Ватан»да, гәрчә артык күп булмаса да, шигъри әсәрләр дә күзгә ташлана. Журнал Тукай мәктәбе вәкиле С. Сүнчәләй иҗатына бик теләп мөрәҗәгать итә. Хәтта аның аерым юлларын эпиграф итеп тә ала. Мәсәлән, мәҗмуганың 1 нче һәм кайбер башка саннары С. Сүнчәләйнең журнал мәсләгенә аваздаш булган мондый парчасы белән ачыла:

Күктәге нурлы кояш бер, ихтимал, сүнсә сүнәр,
Яктысы калмас, бетәр; әмма ләкин сүнмәс татар.
Күкне капларлар караңгы зур болытлар, төн булыр,
Әмма капланмас, каралмас, төнгә әйләнмәс татар!

«Азат Ватан» битләрендә Шиһап Нигъмәтинең мәкаләләре генә түгел, шигырьләре дә еш очрый. Аның тезмә әсәрләренең төп эчтәлеген милли рух, Ватанны сагыну, азатлык, бәхет өчен көрәш идеясе тәшкил итә. Мәсәлән, аның «Бул каһарман!» шигыре
(№ 1.— 7 б.) мондый юллар белән башлана:

Авыр елга туры килдем, диеп,
Тормышыңнан, җегет, зарланма!
Мин ирексез милләт улы, диеп,
Түбәнсенмә, юкка хурланма!

Алга таба автор үз укучысын «куркак» булмаска, «каһарман» булырга, «көрәш диңгезендә» йөзәргә, «коллык богауларын өзәргә» чакыра.

«Туган илемә!» шигырендә (№ 1.— 20 б.) Ш. Нигъмәти туган илен «алтыным», «күз нурым», үзе өчен «иң кыйммәтле» нәрсә дип атый. Әсәрнең ахыры түбәндәгечә:

Син каксаң да мине, каргасаң да,
Авырсынмам синең сүзеңне.
Көрәшермен, илем, көрәшермен,
Азат итәр өчен үзеңне.

«Байкал» исемле парчасында (№ 7.— 26 б.) шагыйрь бу күлне төрки бабаларының тарихы, теле белән бәйли. («Байлыклары өчен бу зур суга «Бай күл» диеп исем биргәннәр».)

Ш. Нигъмәти — мөһаҗир татарлар арасында билгеле шәхес. Аның немец концлагерьларында әсир булуы, анда М. Җәлил белән аралашуы, «Идел-Урал» гәҗитен чыгаруда катнашуы, сугыш елларында ук әдәби иҗат белән шөгыльләнүе, «Азатлык» радиосы белән хезмәттәшлек итүе, 90 нчы еллар ахырында вафат булуы мәгълүм. Бу затның 1953 елда Мюнхенда латин хәрефләре белән «Шигырьләр» җыентыгы басыла (48 б.). «Азат Ватан»дагы шигырьләре, нигездә, бу китабында да урын алган. Әмма аерым үзгәрешләр дә бар. Мәсәлән, югарыда телгә алынган «Бул каһарман!» шигыре җыентыкта «Зарланма» исеме белән бирелгән. Күләме дә бер строфага артык.

Бу уңай белән «Азат Ватан»ның авторлары хакында гомумән берничә сүз әйтү дә урынлы булыр. Аларның күпчелеге — мөһаҗир татар-башкортлар. Шуларның бер өлеше — иске мөһаҗирләр, ягъни Октябрь инкыйлабыннан соң яисә 30 нчы елларда чит илләргә күчеп, качып киткән кешеләр (Г. Исхакый, А. Каран һ. б.). Мәсәлән, Әхмәд Ләбиб Каран (ул чыгышы белән Идел-йорттагы Каран авылларының берсеннән) Петербург гаскәри уку йортында белем ала, аннан Истанбул университетында табиблык белгечлеген үзләштерә. 30 нчы елларда «Яңа милли юл»да эшләп ала. Аннан Төркиядә яши. Ул биредә Ш. Мәрҗани, татарларның килеп чыгышы, Сөембикә хакында берничә хезмәт бастыра, шигырьләр дә яза.

Авторларның икенче өлеше һәм күпчелеге — икенче бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләккән һәм ахырда Алманиядә торып калган затлар (Т. Дәүләтшин, Ш. Нигъмәти, Г. Фәйзуллин...). Каләм ияләренең кайберләре Төркиядә, Финляндиядә, Япуниядә, Америкада... гомер кичерә.

Журнал авторлары үз исемнәре белән дә, кушамат-тәхәллүсләр белән дә чыгыш ясый. «К. Казанлы», «Арча малае», «Ишекче»... һәм кайбер башка шундый атамалар өстәмә ачыклауларны көтә.

Журнал авторлары арасында татар-башкорт милләтеннән тыш әһелләр дә бар. Андыйларның материаллары, кагыйдә буларак, башка басмалардан күчереп, тәрҗемә кылынып нәшер ителәләр. Мәсәлән, Алманиянең билгеле язучысы Теодор Пливьеның «Москва» исемле китабы чыга. Журналның 10 нчы санында Т. Дәүләтшин тәрҗемәсендә шушы басмадан бер өзек бирелә. Анда 1941 елның көзендә Мәскәүдән йөзләгән әдипнең (нигездә, СССР Язучылар оешмасы җитәкчелегенең) Казанга күченеп килүе (эвакуацияләнүе), Татарстан башкаласындагы хәл-әхвәлләр шактый җанлы итеп тасвирлана.

Мәҗмуганың шул ук 10 нчы санында «Россия халыкларын азат итүнең Америка Комитеты» рәисе, вице-адмирал Лесли К. Стивенсның (аңа кадәр бу вазифаны адмирал Алан Г. Кэрк башкара. Журналда аның да язмасы бар.) «Народ и доктрина» дигән мәкаләсе инглизчәдән тәрҗемә итеп бирелгән. Ике система арасындагы идеологик көрәшне тасвирлаган бу язма антикоммунизм рухында. Мәкалә авторы фикеренчә, Совет хакимияте үз халкын «тимер пәрдә» эчендә тота. Урыслар объектив, тулы информациядән мәхрүм. Шуңа күрә аларның Америка турында күзаллаулары чынбарлыктан ерак тора.

1951 елда Гамбургта Әхмәт Амбаның немец телендә китабы басыла (Achmed Amba. Ein Mensch sieht Stalin). Анда Сталинның эш-гамәлләрен аклау, шәхесен идеаллаштыру өстенлек итә, Америка тәнкыйтьләнә. Китапның кушымтасында авторның Измирда туган төрек булуы, кыскача тәрҗемәи хәле, Сталин белән ике ел буена аралашуы искәртелә. Журналның 8 нче санындагы А. Муса, В. Мостафа язмаларында (29—31 б.) бу китап кискен тәнкыйтькә очрый. Аларда авторның һич тә төрек булмавы, Ленинградта татарның мәшһүр дин галиме гаиләсендә туып-үсүе, атасы белән дөньяның күп илләрендә гизүе, немецларда әсирлектә булуы, татарча камил белүе искәртелә. Сугыштан соң ул Мюнхен, Миттенвальд һ. б. шәһәрләрдә яши. «Татар-башкорт Милли тәшкилияте» бу китапка һәм аның авторына, тискәре мөнәсәбәтен белдереп, махсус мөрәҗәгать тә кабул итә.

«Азат Ватан»ның һәр санында диярлек ахырда төрле хәбәрләр, укучылардан хатлар бирелеп бара. Аларда дөньяның төрле почмакларында (Америка, Төркия, Япуния, Алмания һәм башка төбәкләрдә) яшәүче милләттәшләребез журналны яратып укулары, аның файдалы булуы хакында язалар, үзләренең тәбрикләрен, кайбер теләк-тәкъдимнәрен дә белдерәләр.

Инде мәҗмуганың теле хакында берничә сүз. 20—30 нчы елларда мөһаҗәрәттә чыккан татарча гәҗит-журналлар тел җәһәтеннән XX йөз башы традицияләрен турыдан-туры дәвам иттерәләр. Гарәп-фарсы алынмалары, формалары аларда чагыштырмача күп. «Яңа милли юл», «Яңа япун мөхбире» һәм кайбер башка

басмаларда төрек теленең дә тәэсире ярыйсы гына сизелә. «Азат Ватан»ның тел-стиле исә татар сөйләмә теленә якын. Илдәге шул чор татар матбугаты теленнән җитди аерылмый. Бу аңлашыла да. Чөнки аның төп авторлары һәм укучылары — Совет чорында тәрбияләнгән, илдәге татарча әдәбиятны һәм гәҗит-журналларны укыган кешеләр. Аларның шактый өлеше урысның сөйләмә һәм язма теленнән дә хәбәрдар. Шуңа күрә «Азат Ватан»дагы материалларның бер өлеше авторлар тарафыннан ике телдә дә язылган булса кирәк.

Гомумән, мәҗмуганың тел-стиле аңлаешлы, үтемле. Шуның белән бергә, журналда фикер кабатланулары, чагыштырмача билгеле әйберләр хакында киңәеп язулар, стиль кытыршылыклары, шигъри текстларда урыны белән ритмик төгәлсезлекләр күзгә ташлана. Кайчак фактик, техник хаталар да очрый. Мәсәлән, «Арча малае»ның татар әдәбияты турындагы мәкаләсендә «Каюм Насыйри Казан университетында укыган» диелә. Тукайның яшәү һәм уку урыны итеп «Уральск» урынына «Троицк» күрсәтелгән (№ 8.— С. 18—19). Е. Камали язмасында Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы
1888 елда уйналган дип әйтелә (№ 8.— С. 21). Чынлыкта исә бу әсәр 1898 елда гына языла. 8 нче санда Г. Исхакый 1888 елда туган дип искәртелә (С. 3). Урысча текстларда аерым исем-атамаларның бирелүе дә бәхәсле яисә хаталы: Ф. Тукта (№ 8.— С. 4) — Ф. Туктаров; Гадильша, Кутуй (№ 10.— С. 23) — Гадильша Кутуй... һ. б. Бу төр кимчелекләрнең бер өлеше, әлбәттә, техник сәбәпләр аркасында җибәрелгән. Әмма журналдагы аерым җитешсезлекләрнең билгеле бер объектив сәбәпләре дә бар. Мәгълүм ки, «Азат Ватан» Идел-йорттан, татар җирлегеннән читтә — ерак Алманиядә, башка мәдәни туфракта чыгарыла. Тиешле әдәбият, текстлар да кул астында я бөтенләй юк, яисә җитәрлек түгел. Ил хәбәрләрен алу да — үзе зур проблема. Профессиональ әдипләргә һәм журналистларга да зур кытлык. Ватандагы киң катлам укучы белән дә элемтә юк диярлек. Бу факторларның журналга, аның сыйфатына теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясавы — табигый хәл.

* * *

«Азат Ватан» журналы — гәрчә бик кыска гомерле булса да, бигрәк тә мөһаҗирләребез, халкыбыз яшәешенең, башка халыклар белән мөнәсәбәтләренең бер сәхифәсе. Анда тарихи, сәяси, иҗтимагый, мәдәни мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан. Күп кенә шәхесләрнең, шул исәптән Г. Исхакый, Т. Дәүләтшин кебек билгеле затларның, эшчәнлеге мәҗмуга белән бәйләнешле. Журналда хәзерге көн укучыларының ихтыяҗларына аваздаш яклар да бар. Көнбатыш мәркәзләренең берсендә чыккан «Азат Ватан» мәҗмугасының, андагы аерым материалларның бүгенге гыйльми, иҗтимагый һәм мәдәни әйләнешкә кертелүе — зарури һәм табигый күренеш.
*2002*

## «Азат Ватан» журналы битләреннән

***Ш. Зәйтүнә***

### Исмәгыйль Гаспралы

*(1853—1914)**

Төрк (төрки.— *Х. М.*) халкының күренекле, милли һәм сәяси эшлеклеләренең, үзләренең гомерләрен төрк халыкларының берләшкән көчен тудырырга тырышучыларның Исмәгыйльләре безгә мәгълүм. Бу эшлеклеләр арасында иң күренекле йолдызлардан бере дә Исмәгыйль ага Гаспралы иде.

Исмәгыйль ага 1853 елда Кырымда Бакчасарай шәһәрендә туган. Ул яшь вакытында ук үз халкына өзлексез хезмәт итүне бурыч итеп куя. Шуның өчен дә коллыкта яшәгән төрк халыкларының Төркестан, Кавказ, Идел-Урал һәм шулай ук бөтен төрк-мөселман дөньясында шөһрәт казанган кешеләрнең берсе булды.

Исмәгыйль аганың хезмәте күптөрле һәм уңышлы булды. Төрк халыклары, колониаль тормыш шартларына карамастан, үзләренең бай милли мәдәниятен саклап кына калу түгел, аның мөһим реформалар нәтиҗәсендә яңа сәнгать һәм әдәбиятын тудыра алдылар.

Исмәгыйль ага һәрвакыт башка халыклар белән җитди рухи бәйләнеш аркасында, милли мәдәниятнең тәрәккыяте җанланды. Ул, зур авырлыкларны үтеп, күп кенә мөһим реформалар кертә. Мәсәлән, 1877 елда үзенең шөһрәтле мәктәп реформасын эшкә үткәрә алды. Үзе башлангыч мәктәпләр өчен яңа уку программалары төзеп, кадимичелекнең бетүенә сәбәпче булды.

1883 елда Исмәгыйль ага, үзенең күптәнге теләген эшкә ашырып, «Тәрҗеман» гәзитәсе чыгара башлый. Бу гәзитә беренче булып, төрк халыкларының җәмгыять һәм сәяси тормышларында зур роль уйнады. Бу гәзитә аркылы Исмәгыйль ага мәктәп тәрбиясен бик эшлекле яңартучы пропагандасын алып барды. Аның мөһим эше дә төрк әдәбиятының, сәнгатенең һәм матур әдәбиятының үсешендә һәм аның тәрәккыятендәдер.

Исмәгыйль ага төрк халыкларының милли азатлык көрәше юлында күп көч түкте. Ул, коллыктагы төрк мөселман халыкларының берлеген тудыру өчен, гомер буе өзлексез җанын, көчен салып эшләүчеләрнең берсе иде. «Тәрҗеман» гәзитәсе битләрендә, кабилиясенә, җиренә карамастан, төрк берлеген булдырырга чакырды. Төрк халыкларының берлеге фикере Кырымда, Кавказда, Идел-Уралда,

Төркестанда бик тиз җәелде һәм нык урнашты. Исмәгыйль ага үзенең эшен телдә, эштә һәм фикердә берлек дигән шигардә алып барды.

Исмәгыйль ага 61 (дөресе — 63.— *Х. М.*) яшендә 1914 елның 1 нче сентябрендә вафат булды. Төрк дөньясының мәдәниятен күтәрү, бөтен төрк халыкларын берләштерү өчен көрәшкән бөек төркне халык онытмаган һәм онытмас.

***К. Казанлы***

## Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин*

СССР кул астында яшәүче мөселманнарның соңгы ирекле мөфтие Риза Фәхреддиннең вафат булуына 14 нче апрельдә 16 ел тула. Риза Фәхреддин Хәзрәт Идел-Урал төрк-татарларының уяну дәверендәге иң бөек дин белгече, милли тарихыбызны һәм матбугатыбызны үстерүдә гаять зур хезмәт күрсәткән, бөек ислам дөньясына танылган галим иде.

Риза Хәзрәт 1859 елның 12 нче гыйнварында хәзерге Татарстан җөмһүрияте Бөгелмә (бүгенге Әлмәт.— *Х. М.*) районында дөньяга килә. 1889 елларда имам булып хезмәт иткәннән соң, Уфа шәһәрендәге Диния нәзариятенә әгъза (казый) итеп билгеләнә. Шушы еллардан башлап дини, тарихи вә тәрбияви әсәрләрен яза башлый. 1906 елда, үзенең фәнни, әдәби хезмәтен тагы да киңәйтү максаты белән, казыйлык хезмәтен ташлап, Оренбургка күчә һәм 1907 елда «Шура» мәҗмугасын чыгара башлый.

1917 елның май аенда бөтен Русия мөселманнарының корылтае Риза Фәхреддин Хәзрәтне Идел-Урал татарлары вә казакъ-кыргызларның мөфтие итеп сайларга теләсә дә, мәрхүм, үзенең фәнни хезмәтләрен дәвам итү максаты белән, мөфти булып сайланырга теләми. Бу корылтай тарафыннан сайланган беренче ирекле мөфти Галимҗан Баруди вафат булганнан соң, СССРдагы мөселманнарның дини оешмаларының вәкилләре тарафыннан 1922 елда мөфти итеп сайлана һәм 1936 елның апреленә чаклы шул хезмәтне дәвам итә.

Мәрхүмнең мөфтилек иткән дәвере илебездә большевиклар хакимлек иткән иң авыр чорга, Совет хөкүмәтенең ислам диненә каршы вәхшиләрчә һөҗүм ясаган вакытларына тугры килде.

Риза Хәзрәт, большевиклар революциясенең беренче 10 елында Совет хөкүмәтенең дингә каршы алып барган көчле пропагандасына карамастан, СССРда яшәүче төрк-татарларның күпчелеген Уфа Диния нәзарияте тирәсенә берләштереп, үзенең мөфтилеген киңәйтергә ирешә. СССРдагы төрк-татарларның мәгънәви яктан Уфа Диния нәзариятенә, ягъни мөфти Риза Фәхреддин җитәкчелегенә берләшүләре большевикларны, әлбәттә, тынычсызлыкка төшерде. Падишаһ хөкүмәтенеке кебек, ул Совет хөкүмәтенең дә төп теләге СССРдагы төрк-татарларны, бигрәк тә Идел-Урал төрк-татарларын, большевиклардан аеру, аларның мәдәни, дини яктан гына булса да берләшүләренә юл куймаска тырышу булганлыктан, большевиклар да мөселманнарның бу мәгънәви-дини берләшүләренә каршы һөҗүм башладылар. Совет хөкүмәте, башта Уфа Диния нәзариятенең көчен бетерү, аны кечерәйтү максаты берлән, СССРдагы төрк-татарларны үзара дошманлаштырырга, шулай итеп казакъ-кыргызларны вә башкаларны Идел-Урал татарларыннан аерырга тырышты. Ләкин Риза Хәзрәтнең мәгънәви куәте, халкыбызның аның ягында булуы большевикларның ислам динен эчтән какшату планнарын җимерде.

1928 елларда Кремль, ислам диненә каршы һөҗүмен тагы да көчәйтеп, дин башлыкларына, мәсҗедләргә күтәрә алмаслык салымнар сала башлады. Бу юл белән дә ислам диненең дәрәҗәсен төшерә вә халыкны үз ягына карата алмагач, бик күп сандагы имамнарны дин хезмәтеннән ваз кичәргә мәҗбүр иткән кәгазьләргә куркытып кул куйдыртып, гәзитәләрдә игълан итә башлады. Авылларда халыкны куркытып, мәсҗедләрне ябарга дигән карарлар чыгартып, мәсхәрә итәргә тотынды. 1930 елларда инде Совет хөкүмәтенең ислам диненә каршы башлаган һөҗүме үзенең иң югары ноктасына җитте. 1929 елдан 1933 елга чаклы НКВД тарафыннан йөз меңләгән дин башлыклары кулга алынды, сөргенгә озатылды, хөкемсез-нисез үтерелде. Ун меңләгән мәсҗедләр ябылды. 1933 елга чаклы большевиклар тарафыннан Идел-Уралда гына җиде меңгә якын, Төркестан, Кырым һәм Кавказда егерме биш меңгә якын мәсҗед көчләп ябылды, җимерелде һәм икмәк амбарларына, динсезләр клубына әйләндерелде. Фәкать Казан шәһәрендә генә 22 мәсҗед яптырылды. Ләкин Риза Хәзрәт бу кабахәтлекләр алдында каушап калмады. Ул һаман да большевикларның бу вәхшилекләрен туктатуны таләп итеп, Кремльгә протестлар ясап торды.

Большевикларның ислам диненә карата эшләгән бу җинаятьләренә каршы 1930 елда Гаяз Исхакый әфәнде җитәкчелегендә Аурупадагы «Идел-Урал истикъляллы (азатлыгы.— *Х. М.*) өчен көрәш комитеты» бөтен гарәп вә Аурупа илләренә «Ислам дөньясына» дигән мөрәҗәгать таратты. Бу мөрәҗәгать, Совет хөкүмәтенең ислам диненә каршы булган җинаятьләрен фаш итеп, ислам дөньясын ярдәмгә чакырды. Чыннан да, ислам дөньясы хәрәкәткә килде һәм большевикларның дингә карата тоткан

сәясәтләренә каршы көчле протестлар башланды. Бу хәл исә Кремльне бик уңайсыз хәлгә калдырды вә үз-үзен аклау өчен юллар эзләргә мәҗбүр итте. 1931 елда Кремль, «СССРда ислам диненә иреклек, ислам диненә бер төрле дә кысу юк» дигән ялган кәгазьгә кул куйдыртып, бөтен дөньяга тарату максаты белән, Риза Хәзрәтне Мәскәүгә чакырта. Мөфти Риза Хәзрәт исә, мондый ялган кәгазьгә кул куюдан баш тартып, «ялган сөйләү безнең динемездә юк» дип җавап бирә һәм Кремльнең динебезгә азатлык бирүен таләп итә. Шулай итеп, ул, куркыныч шартларда да милләт тарафыннан йөкләнгән вазифаны дәвам итеп, большевикларны кайбер ташламалар ясарга да мәҗбүр итте.

Риза Хәзрәт үзенең сәяси карашлары белән төрк-татар халкына милли-мәдәни мөхтәрият алып бирү белән генә канәгатьләнеп калудан ерак торды. 1917—1918 елларда татар халкының Милләт мәҗлесләрендә, корылтайларында катнашып, туфраклы мөхтәрият фикерен яклады һәм «бер каршы булса да, мөселманнар яшәгән җирнең мөстәкыйльлеге өчен тырышырга кирәк» дигән юлны тотты.

Риза Фәхреддин Хәзрәт, Уфага күчү белән, татар халкының милли тарихын яза башлады. Аеруча Казан урыслар тарафыннан басып алынганнан соңгы тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр хакында бик күп материаллар туплап, «Асарь» исеме астында бастырып тарата. «Асарь» мәрхүмнең иң зур кыйммәтле тарихи хезмәте булып, 1922 елга чаклы (ул аның.— *Х. М.*) 12 кисәген бастырып тарата. Аның фәнни, тәрбияви темага язылган һәм басылган әсәрләренең саны 25 кә якын булып, басылмый калганнарының да саны 10 га җитә.

1905 елдан урыс-япун сугышында Русиянең җиңелүе һәм ул еллардагы революцион хәрәкәтләр нәтиҗәсендә татар халкы чикләнгән хәлдә генә булса да матбугат иреге яулап алды. Шушы мөмкинчелектән файдаланып, Риза Хәзрәт 1907 елда «Шура» мәҗмугасын чыгара башлый. Бу мәҗмуга мәрхүмнең бөек хезмәтләреннән берсе булып, ул чорда иң күп таралган вә сөеп укылган мәҗмугаларның берсе булды. «Шура» 1917 елда большевиклар тарафыннан ябыла.

Бөек мөфти хәзрәтләре вафат булганнан соң, аның үлеме хакында совет гәзитәләрендә бер төрле хәбәр булмады. Шуңа карамастан аның үлеме турындагы хәбәр яшен кебек бөтен илгә вә дөньяга таралды. Аның вафатыннан соң Алманиянең танылган ориенталисты профессор Б. Шпулер* түбәндәге сүзләрне язды: «Мөфти Риза Фәхреддиннең үлеме Русия мөселманнары өчен бик авыр югалту булды. Алар аның белән моңа чаклы сирәк булган мәгънәви бер рәһбәрне (җитәкчене.— *Х. М.*) генә түгел, төрк-татар халкына бик зур сәяси-дини, фәнни хезмәт күрсәткән бер галимне югалттылар. Совет хөкүмәтенең Русия төркләренең соңгы берләшү багы (бакчасы.— *Х. М.*) булган мөфтинең вафатын халыкка белдермәүне тиеш табуында аның төрк милләтчелек мәсьәләсенә урын бирмәскә тырышуы күренәдер. Моның белән Совет хөкүмәте мөфтинең вафатыннан соңрак аңа ни чаклы зур сәяси вә мәгънәви әһәмият бирүен күрсәтте һәм Совет илендәге төрк-татар өчен аның вафатының нинди зур югалту булганын ачык белдерде».

Риза Фәхреддин Хәзрәтнең хезмәтләренә йомгак ясап, тик түбәндәгеләрне генә әйтергә мөмкин: Риза Хәзрәт халкыбызның мәдәниятен үстерүдә, милли үзлегебезне саклап калуда гаять зур хезмәт күрсәткән бөекләребезнең берсе иде. Барыннан да элек, мәрхүмнең бөек хезмәте илдә, халык белән бергә большевизмның динебезгә, милли мәдәниятебезгә ясаган һөҗүмләренә каршы көрәшен, үзенең соңгы көннәренә чаклы милләт тарафыннан тапшырылган бөек хезмәтен дәвам итүендә.

***А. Мансур****

**Муса Акъегетзадә**

*(1865—1923)***

Муса Акъегетзадә 1865 елны Пенза губернасында дәүләт хезмәткәре (чиновник) гаиләсендә туды. Башта хөкүмәтнең мәгъмүре (хезмәткәре.— *Х. М.*) булган атасы, баласын да дәүләт хезмәткәре итү максаты белән булса кирәк, аны Пензадагы рус гимназиясенә бирә.

Муса гимназиядә укыган вакытында әдәбият белән бик кызыксына. Башка милләтләрнең әдәбиятын өйрәнә һәм үз милләтендә халык әдәбиятының юклыгын күреп, яшь милләтче Мусаның йөрәге әрни. Ул моңа сәбәпләрдән берсе кадимчелек — искечелек икәнен аңлый. Муса ул вакытта үсеп килә торган яңа төрек әдәбиятын аеруча әһәмият биреп өйрәнә. Шулай ук башка милләтләрнең әдәбияты белән танышкач, аңарда милләтнең тәрәккыяте өчен хезмәт итүче татар милли әдәбиятын булдыру фикере туа.

Зур уңышлык белән гимназияне бетереп чыкканнан соң, ул 21 яшендә, Казанда үзенең «Хисамеддин мулла» исемле хикәясен бастырып чыгара. Бу татар әдәбиятында халык тормышыннан алынып, беренче мәртәбә татар язучысы тарафыннан язылган беренче әсәр булды һәм аның бөтен әһәмияте дә шунда.

«Хисамеддин мулла»да шул заман җәмгыять тормышының җитешсез яклары, тәрәккый итүе өчен тәрбия, укыту мәсьәләләренә реформа ясау, хатын-кызларга хокук бирү кирәк икәнлеге күрсәтелә.

Шуның белән Муса Акъегетзадә шул ук заманда яшәгән татар реформаторлары Шиһабеддин Мәрҗани һәм Каюм Насыйриларның фикерләрен әдәбият юлы аша яклап чыкты.

«Хисамеддин мулла» ул вакытта Исмәгыйль Гаспралы тарафыннан чыгарыла торган «Тәрҗеман» гәзитәсе телендә язылган. Билгеле булганча, Гаспралы телдә, эштә, фикердә берлек дигән шигаре (лозунгы.— *Х. М.*) белән чыгарган бу гәзитәсендә барлык төркләр өчен аңлаешлы бер уртак тел булдыру теләге белән, османлы (госманлы.— *Х. М.*) төрекләре шивәсе тәэсирендә яза иде. Шул замандагы османлы төрек теле үзе дә аслы гарәп һәм фарсы телләре белән катнаш, эшләнеп җитмәгән бер тел сәбәпле, гади укучыларга «Хисамеддин мулла»ны аңлавы авыр иде. Бу әсәр аның беренче һәм соңгысы булды.

Муса Акъегетзадә үзенең әсәре чыккач бер елдан соң Төркиягә китә һәм калган гомерен анда үткәрә. Яңа татар әдәбиятына нигез салучы Муса Акъегетзадә 1923 елның август аенда Төркиядә вафат булды.

***Ш. Нигъмәти****

## Туган илемә!**

Әй илем син, алтыным син,
Сине өзелеп яратам.
Синең суың эчеп, синдә үстем,
Синдә тудым бәхетсез анадан.
Син дә ярат мине, туган илем,
Мин бит синең үз улың,
Минем өчен иң кыйммәтле
Син генә бит минем күз нурым.
Син каксаң да мине, каргасаң да,
Авырсынмам синең сүзеңне.
Көрәшермен, илем, көрәшермен,
Азат итәр өчен үзеңне.

## МИНҺАҖ ИСМӘГЫЙЛИ

*(1910—1995)*

### «Их, шатланам... татар булуыма!»

*(Тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеге)*

**I**

Минһаҗ ага исеме Идел-йорттагы татар дөньясына 80 нче еллар ахырында башланган милли хәрәкәт дулкыны белән килеп керде. Татарча гәҗит-журналлар аның хакында бер-берсе белән узыша-узыша күп санлы материаллар бастырдылар. Болар арасында аеруча Тәүфикъ Әйдинең, Александр Филипповның һәм Фирдәвес Зарифның язмалары игътибарга лаек (Йөртә безне язмышлар. Фәнни-популяр очерклар...— Казан, 1992.— 181—191 б.; Аҗаган.— 1992.— # 2.— 41—46 б.; Мирас.— 1994.— # 11—12.— 180—184 б.; 1995.— # 1—2.— 199—202 б.). Аларда Минһаҗ аганың тәрҗемәи хәле, мөһаҗәрәттәге тормышы, күренекле кешеләр хакындагы истәлекләре шактый тулы һәм үтемле итеп бирелгән.

Мин 1990 елда Финляндиядә гыйльми командировкада булган идем. Шунда чит илләрдәге татарлар, алар чыгарган гәҗит-журналлар, китаплар белән кызыксына башладым. Төрле басма чыганаклардан, Хельсинки һәм Тампере калаларындагы милләттәшләребез авызыннан миңа Минһаҗ ага исемен еш очратырга һәм ишетергә туры килде. Баксаң, ул үзе дә берничә мәртәбә Финляндиядә булган, биредәге Хәбибрахман Шакир, Хәсән Хәмидулла һ. б. татар зыялылары белән аралашкан, хатлар алышып торган икән. Аның бу илгә мөнәсәбәтле шигырьләре дә бар. «Маршал Маннерхайм» (Маннергейм) әсәрендә, мәсәлән, Финляндиянең бәйсез-
лек алуы, халкының «тыныч», «рәхәт» яшәве тасвирлана. Мөстәкыйльлек өчен көрәшнең башында торган бу затка дәшеп, автор болай ди:

Рәхмәт сиңа, маршал Маннерхайм,
Каһарман син, бөек, арыслан...

«Сау бул, Финляндия» шигырендә Минһаҗ ага биредәге татарларның милли рухны саклауларына, матур яшәүләренә куануын белдерә.

1991 елның 21—22 февралендә Батыр районында Чувашстандагы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының республика семинары булды. Шунда вакытта мине Шыгырдан мәктәбе укытучысы, университетта бер чорда укыган Кәлиф әфәнде Вәлитов үзләренә алып кайтты. Сүз иярә сүз чыгып, Минһаҗ аганың да туган авылында булуы ачыкланды. Шунда без Кәлиф әфәнде белән «Немец бабай» — «Минач абзый» (биредә аны еш кына шулай да атап йөртәләр икән) янына юнәлдек. Кич буе төрле темаларга сүз куерды. Бу очрашуда 80 яшьлек карт минем күңелгә гаҗәеп хәтерле, күп мәгълүматлы кеше, аяклы тарих рәвешендә кереп калган. Икенче мәртәбә мин Минһаҗ аганы 1992 елның сентябрендә янә Шыгырданда күрдем. Казанда да без аның белән соңгы ике-өч елда берничә тапкыр очраштык. Бездә аның миңа атап язган дистәдән артык хаты бар. Мәгълүм булганча, Минһаҗ ага шәхси архивының зур өлешен моннан берничә ел элек Казан университетының гыйльми китапханәсенә бүләк иткән. Кайбер материалларын ул, «гыйльми эшегездә файдаланырсыз» дип, миңа да бирде. Алар арасында Минһаҗ аганың шигырьләре, Гаяз Исхакый һәм кайбер күренекле кешеләр хакындагы истәлекләре, аңа адресланган берничә хат та бар. Бу материаллар үзләре үк «Немец бабай»ның мөһаҗир татарлар арасында билгеле кеше булуын, аның күп кенә күренекле шәхесләр белән мөнәсәбәттә торуын күрсәтәләр.

Менә Гаяз Исхакыйның кызы — профессор Сәгадәт Чагатайның 1988 елның 13 октябрендә язган хаты: «Хөрмәтле Минһаҗ бәк! Сезнең яз айларында язган хатларыгызны вә «Казан утлары»ның 5—6 нчы саннарын алдым. Күп рәхмәт. Әти өчен (әти хакында.— *Х. М.*) җибәргән билгиләр (мәгълүматлар) өчен дә күп рәхмәт...» Алга таба хат авторы үзенең шәхси хәле, гыйльми һәм милли яңалыклар хакында ихласи рәвештә бәян итә. Япуниядә гомер кичерүче мәшһүр милләттәшебез Тәминдар әфәнде дә үз хатында (4.10.1989) Минһаҗ агага рәхмәт һәм хөрмәт хисләрен белдерә.

«Кадерле Минһаҗ дускай!.. Еллар буе барлы-юклы акчаң белән дәрги (журнал.— *Х. М.*) чыгарып килгән, аны төрле якка сибелгән якташларга бушлай тараткан, хәтта алар белән дәвамлы язышып, элемтә тоткан син булмасаң, ил хәбәрләрен без кайдан алыр идек? Бәхетебезгә, шөкер, син бар! Алла сине бездән, милләтебездән аермасын! Саулык һәм озын гомер бирсен! Амин! Шәхес культының сафсатасын тыңлап үскән күндәм бәндәләре илдә милли әдибебез, мәрхүм Г. Исхакый турында бәхәс-тартышлар алып барганда, Тәңре синең күңелеңә салган, күрәсең, аларга да чынбарлыкны язып кына калмый, таныклык та иткәнсең. Өстәвенә бу мәсьәлә хакында Мәхмүт Таһир (Ерак Шәрыкта һәм Төркиядә яшәгән милләттәшебез. 1918 елда туган.— *Х. М.*) белән Гали Акышны да уятып, үзеңә ияртә алгансың. Милли юлдагы бу игелегең, бу хезмәтең милләт каршында хөрмәт белән тәкъдир ителергә (бәяләнергә.— *Х. М.*) тиеш...» — Бу юллар шагыйрь Исфәндияр Ишгай (Әсфәндияр Чынбай.— 1908.— 16.06.1992) хатыннан. Минһаҗ ага белән бу затның язмышлары шактый уртак: әүвәл илдә яшәү, уку, эшләү, аннан фронт, әсирлек, концлагерь газаплары.

Түмән төбәгендә туып, кырык елдан артык гомерен Төркиядә уздырган Исфәндияр Ишгайның дусты Минһаҗга багышланган шигыре дә бар. «Чын дус» дип исемләнгән бу әсәр 1964 елның апрелендә язылган:

Синдә күреп батыр милләтчене,
Эштә тугрылыклы илдәшне,
Сөенәм мин, Минһаҗ, чит илдә дә
Тапканыма дусны, тиңдәшне.

Беләсеңдер сугыш барган чакта,
Берлинда без башлап таныштык.
Кайгыларны бүлешеп, күңелләргә
Өмет утын бергә кабыздык.

...Хәтерлимсең кулны артка куеп,
Ульм (Германиядәге Ной-Ульм шәһәре.— *X. М.*)
болынында йөргәнне,
Кайгы-хәсрәт йотып, лагерьларда
Качып-посып гомер сөргәнне?..

...Юлымда күп булды танышларым;
Кайберләре җырак бара алмый
Туктадылар, аннан хат та язмый,
Ышанычлы дус та саналмый.

Ә син үзгәртмәдең дуслыгыңны,
Дөнья эшенә күмелеп калмадың.
Кичектерми хәл сорашып тордың,
Хатларыма хатлар ялгадың.

Мондый дусны ничек онытырга?
Искә төшереп, кайчак уемда
Җөрим гүя синең белән бергә
Сөйләшкәләп Дунай буенда.

Үлгәнче без, уйлыйм, дус калырбыз,
Исән булсак, хатлар язышырбыз,
Бер-беребездән фикер алышырбыз,
Җыракларга китсәк, табышырбыз.

Шушы шигърем сиңа — ядкяр итеп,
Дуслык саклап килгәнең өчен,
Хаклык даулап көрәшкәнең өчен,
Яшәтергә милләтем көчен.

Синдә күреп батыр милләтчене,
Эштә тугрылыклы илдәшне.
Сөенәм мин, Минһаҗ, чит илдә дә
Тапканыма дусны, диндәшне.

Үз чиратында Минһаҗ аганың да дусты Ишгайга багышлап язган шигырь юллары бар. Алардан бу ике шәхеснең үзара фикердәш булулары, бер-беренә ихтирам хисләре бөркелеп тора. Минһаҗ ага әңгәмәләр вакытында Ишгайны һәрчак хөрмәт белән искә ала иде. Дустының үлемен ул бик авыр кичерде. Хәтта елаганын да хәтерлим.

Минһаҗ агага килгән хатлар арасында тарихи, сәяси, мәдәни яктан гаять мөһим мәгълүматлар да бар. Шундыйларның берсе — Рокыя Дәүләткилденең 1988 елның 19 августында Казаннан язган хаты. Бу хөрмәтле ханым (Төркиядәге атаклы милләттәшебез, 1944 елда туган Надир Дәүләтнең әнисе) 1935—1945 елларда Кытайның Мукден шәһәрендә ире Ибраһим әфәнде белән «Милли Байрак» гәҗите чыгара. Аннан соң улыннан, иреннән аерылулар, совет төрмәләрендә 10 ел утыру, төрле кагылу-сугылулар... Кыскасы, романнарга, драма һәм фильмнарга нигез булырлык фаҗигале язмыш, гыйбрәтле хәл-әхвәлләр. Мондый шартларда да ихтыяр көчен саклап исән калган, яшәү дәртен сүндермәгән татар хатын-кызы, Ана алдында бөтен җәмгыять баш иярлек.

Минһаҗ ага Ләбиб Каран, Мәхмүт Таһир, Гали Акыш, Надир Дәүләт, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Гайнуллин, Ибраһим Нуруллин, Хәниф Мортазин һәм башка бик күп кенә билгеле шәхесләр белән хатлар язышып тора, милли-мәдәни тормыш белән шактый хәбәрдар була. Гомумән, Минһаҗ ага әдәбият, тарих, яшәеш, дөнья белән кызыксынуын гомеренең ахырына кадәр саклап калды. 1994 елның декабрь азакларында язган бер хатында ул Чечняга каршы сугыш башлауны кискен гаепли һәм үз сүзен «Яшәсен каһарман чечен халкы!» дип тәгәлли.

**II**

Минһаҗ Ямалетдин углы Исмәгыйли (әнисе — Миңлеҗәмал) 1910 елның 21 августында хәзерге Чувашстанның Батыр районы Шыгырдан авылында дөньяга килә. Шыгырдан, мөгаен, элек тә, хәзер дә татар авылларының иң зурларыннан берсе хисапланадыр. Әйтүләренә караганда, Октябрь инкыйлабына кадәр анда 12 мәчет була. Хәзер исә 5 мәчет, 2 мәктәп бар. Күп еллар узгач, Ямалетдин углы туган авылы хакында менә ничек язачак:

Шыгырданым, һәрвакытта син уемда,

Җөреп торам өмә, мәҗлес, туйларында.
Җыракларда яшәсәм дә авылымнан,—
Син генә бит һаман минем уйларымда...

Исмәгыйльләр (Измайловлар) — авылның зур нәселе, Ибраһим — Ямалетдин аганың әтисе. Шуларга мөнәсәбәттә Минһаҗ ага үзен Измайлов, Ямалетдинов, Ибраһимов фамилияләре белән дә йөрткән. Шигырьләрен исә ул укучыларга еш кына «Минһаҗ», «Минһаҗ Исмәгыйли» һәм кайбер башка исемнәр белән тәкъдим итә.

Яшьли үк ятим калып, укымышлы гына абыйсы кулында тәрбияләнгән Минһаҗ Ямалетдин углы авыл мәктәбендә, Касыйм педагогия училищесында, Казан университетының география факультетында укый. Аннан Үзбәкстандагы Маргилан, Ташлак калаларында укытучы, мәктәп директоры булып эшли. 1941 елда сугыш башланып, бер-ике ай да үтми, Минһаҗ Ямалетдин углын фронтка җибәрәләр. Ул анда капитан дәрәҗәсенә ирешә, өлкән политрук та булып эшли, батырлыклары өчен төрле бүләкләргә лаек була. Ике ел сугышканнан соң, 1943 елның августында Курск-Орел дугасындагы каты бәрелешләрдә яраланып, әсирлеккә эләгә. Аннан Алманиядәге концлагерь, зиндан тормышы, хастаханәләр. Бик күпләгән әсирләр белән берлектә, Минһаҗ Исмәгыйли дә, Ватанына кайтмыйча, чит илдә калырга мәҗбүр була. Аның Алманиядә төп яшәү урыны — Мюнхен һәм Штутгарт калаларыннан ерак булмаган Ной-Ульм шәһәре. Кечерәк кенә бу борынгы һәм тарихи кала Минһаҗ Исмәгыйлинең шигырьләрендә дә искә алына.

Бу шәһәрдә туган Эйнштейн,
Бу җирләрне Кеплер таптаган.
Яшьлегендә шушы урамнарда
Бөек шагыйрь Шиллер атлаган.

Даһи Гете монда булган диләр,
Һенриһ Һейне булган бу җирдә.
Чит илләрдән килгән бөекләр дә
Булгалаган икән бу илдә...

Минһаҗ Исмәгыйли заводта, «Азатлык» радиосында һәм башка урыннарда эшли, мөһаҗәрәттәге татар, урыс, украин гәҗит-журналларына язышa, «Безнең фикер», «Таң йолдызы», «Азат Ватан» кебек вакытлы басмаларны чыгаруда турыдан-туры катнаша. Алманиядә аның төрле милли-мәдәни чараларны оештыруда активлык күрсәтүе, күренекле кешеләр белән аралашуы да мәгълүм.

Кызыксынучан табигатьле, кешеләр белән тиз аралашучан Минһаҗ Исмәгыйли сәяхәт кылырга ярата. Аның дөньядагы күп кенә мәмләкәтләрдә булуы билгеле. Ул немец телен үз ана теле кебек үзләштерә. «Немец бабай»ның урыс, төрек, үзбәк, чуваш, француз, инглиз, итальян телләрендә дә аңлашуы мәгълүм.

Минһаҗ Исмәгыйли 30 нчы елларда гаилә кора. Ике балалары була. Әмма ире сугышка киткәч, Фатыйма ханым юк кына гаеп белән төрмәгә эләгә. Балалары ачлыктан үлә. Дистә еллап зинданда утырып кайткач, Фатыйма ханымның гомере фаҗигале төстә өзелә. Бу аянычлы хәлләр Минһаҗ Исмәгыйлигә бераздан гына мәгълүм була. «Фатыймага хат» шигырендә аның сагыну хисләре, хатынына олы мәхәббәте, аянычлы язмыш гәүдәләнеш тапкан:

Оныта алмам зәңгәр күзләреңне,
Күрә алмам нурлы җөзеңне.
Кара көннәр килде яшен яшьнәп,
Таба алмыйм баскан эзеңне.

Тапсам әгәр баскан эзләреңне,
Тирән дәрьялардан үтәрмен.
Кара көннәр үтәр, мин һаман да
Кавышуны, бәгърем, көтәрмен...

Ничек кенә булмасын, тереклек кешене тора-бара үзенең табигый кануннары белән яшәргә мәҗбүр итә. Минһаҗ Исмәгыйли Амалия исемле бер хатын белән тормыш корып җибәрә һәм аның белән 40 еллап гомер кичерә. Балалары булмый. «Немец бабай» үзенең алман хатынын хөрмәт, ихтирам белән искә ала, аның Коръән укуын, ислам йолаларын үтәвен еш сөйли иде. Амалия ханым 1990 елның 13 апрелендә озак авырып ятканнан соң вафат була. Минһаҗ ага янә ялгыз кала. Туган җирен һич күңеленнән чыгармаган Ямалетдин углы дүрт дистә елдан соң Ватанын кабат күрү бәхетенә ирешә. Советлар илендә үзгәртеп корулар башлангач, ике арадагы кайту-китүләр ешая. Туган-тумачалар, Казан зыялылары да Ной-Ульмны үз итәләр. Минһаҗ ага өчен яңа тормыш башлана. Хатыны Амалия ханым үлгәннән соң, ул, даими яшәр өчен, Шыгырданга кайта. Сирәк булса да, Алманиягә, Мәскәүгә, Казанга да барып килә.

Туган авылына кабат әйләнеп кайтканнан соң, Минһаҗ ага үз хисабына мәчет салдыруга керешә. Хатларында да, очрашканда да бу хакта ул гел сөйләп тора иде. Мәчет төзетүне Минһаҗ ага, ничектер, авылдашлары алдында үзенең әхлакый бурычы итеп санады, һәм, гомумән, ул Шыгырданы белән горурланып, аның үсүенә, матур яшәвенә сабыйларча куанып йөрде.

Бу дөньяның адәм баласы аңлап җиткермәслек «тәкый гаҗәп...» эшләре дә чыгып тора. Мәчет ачу хәстәре белән мавыгып йөргән Минһаҗ ага өстенә көтелмәгән кайгы-бәлаләр килеп төшә... 85 яшен тутырып килүче карт урын өстенә ава. Җәйнең ямьле айларында туып, катлаулы һәм озын гомер юлы үткән, төрле газаплар белән

теткәләнгән йөрәк табигатьнең шундый ук матур фасылында тибүдән дә туктый. Мин Минһаҗ аганың: «Туган туфрагымда үлсәм иде»,— дип әйткән сүзләрен хәтерлим. Тәңре аның үтенечен канәгатьләндерде.

Татар җәмәгатьчелеге Минһаҗ ага үлеменә үзенең кайгылы мөнәсәбәтен белдерде. «Заман» гәҗитенең 1995 ел 8 сентябрь санында басылган некрологта без мондый юлларны укыйбыз:

«Заман — Татарстан» гәҗите редакциясе, Кол Гали исемендәге Халыкара премия комитеты, «Мирас» журналы редакциясе, Татарстан Аксакаллар Шурасы, «Мирас» фонды Советы, «Сабыйга» журналы редакциясе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, «Мирас» китап нәшрияты, Бөтендөнья татар журналистлары ассоциациясе үзәк Советы, «Мирас» академиясен оештыру комитеты, Татарстан Язучылар берлеге, «Болгар» фонды, «Ярдәмче» фонды Шурасы, «Роман-газета» журналы редакциясе, «Иттифак» фиркасе, «Суверенитет» комитеты, Бөтентатар иҗтимагый үзәге Президиумы, Татар халкының Милли Мәҗлесе Президиумы, «Аҗаган» журналы редакциясе, Чувашстан мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан Диния нәзарәте, «Аргамак» журналы редакциясе, «Алтын Урда» газетасы редакциясе, Бөтендөнья татар лигасы Президиумы, Татар милли университеты, «Өмет» гәҗите редакциясе, «Бәйсез Ватан» журналы редакциясе, Татарстан бәйсезлек фиркасе татар милли азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, Гаяз Исхакый көрәштәше, антифашист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Минһаҗ Ямалетдин улы Исмәгыйлинең 86 нчы яшендә кинәт вафат булуы сәбәпле, туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар».

Авылдашлары, татар җәмәгатьчелеге Минһаҗ аганы соңгы юлга олылап, хөрмәтләп озатты. Ул үлеп бераз торгач та, Шыгырданда күп кенә кунаклар, шул исәптән Чувашстан президенты катнашында мәчет ачылу тантанасы булды. Ерактан ук балкып торган бу изге йортны халык хәзер «Минач мәчете»* дип йөртә. Димәк, Минһаҗ аганың исеме, якты хатирәсе авылдашлары күңелендә дә яши, онытылмый.

## III

Минһаҗ Исмәгыйли кылган эш-гамәлләре, төзегән мәчете белән генә түгел, аерым шигырьләре, әдипләр һәм күренекле шәхесләр хакындагы истәлекләре белән дә җәмәгатьчелеккә таныш. Аның сүз сәнгате белән кызыксынуы яшьтән үк башланып, бөтен гомере буена дәвам итә. Бу хакта филология фәннәре докторы Фәрид Кошай болай яза: «Ул яшьлегендә үк... төрле хикәяләр, шигырьләр укуны бик яраткан. Бу өлкәдә шагыйрь үзе (минә) нәрсә сөйли: «Мин яшьлегемдә әдәбият белән бик кызыксына идем. Кай вакытларда укый-укый, кулыма китап тотып йоклап китә торган идем. Минем бу яшьлегемдә каныма сеңеп калган хосусиятем әле бүген дә дәвам итә»,— ди.

Бу бик дөрес. Шагыйрь Минһаҗ әфәндене кайда гына күрмә, аның кулында һәр заман китап булыр. Әгәр дә инде аның өенә керсәң, берничә китап шкафы фәннең төрле өлкәләрен яктырткан китаплар белән тулы икәнлеген күрәсең. Ул кайбер кешеләр кебек тик татар әдәбияты белән генә кызыксынмый. Аның китапханәсендә Җир шарының төрле континентларында яшәүче шагыйрь-язучыларның әсәрләре күп. Ул бай, укып туймастай матур, тирән эчтәлекле Шәрык әдәбияты белән бергә, немец, инглиз, итальян, испан һәм башка бик күптөрле Европа илләренең әдәбияты белән дә бик кызыксына. Бигрәк тә ул бай Иран әдәбиятын сөя... Ул фәннең башка өлкәләре белән дә бик яхшы таныш. Шул сәбәпле аны күп кешеләр «аяклы энциклопедист» дип йөриләр. Ул хакыйкатьтә шулай да».

Минһаҗ Исмәгыйли Казанда уку елларында төрле әдәби кичәләргә йөри, Муса Җәлил, Төхфәт Ченәкәй, Сирин һәм кайбер башка әдипләр белән дә очраша. Урта Азиядә эшләгәндә, Зыя Ярмәки белән аралашулар да аның күңелендә эзсез калмый. Әсирлектә Минһаҗ Исмәгыйлинең Муса Җәлил, Абдулла Алиш һәм кайбер башка әдипләр белән очрашуы да мәгълүм. Аның милли азатлык, журналистлык һәм әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнеп китүенә Гаяз Исхакый белән аралашулары да көчле йогынты ясый. Бу хакта инде матбугатта язылды. Минһаҗ Исмәгыйли, гомумән, мөһаҗәрәттәге татар иҗади көчләре белән тыгыз мөнәсәбәттә тора.

Минһаҗ Исмәгыйли табигате белән эмоциональ, тәэсирләнүчән кеше иде. Казанда аның әүвәл университетка түгел, театр техникумына керергә йөрүе дә юкка гына булмагандыр. Минһаҗ аганың, Ватанында һәм чит илләрдә яшәгәндә, төрле тамаша-спектакльләрдә катнашуы, мәҗлес-кичәләрдә матур итеп җырлавы да мәгълүм. Димәк, аның күңелендә билгеле бер сәнгати сәләт булуы бәхәссез.

Алдан ук шунысын искәртик: Минһаҗ Исмәгыйли профессиональ шагыйрь түгел, ул махсус филологик белем дә алмаган. Аның өчен шигъри иҗат — өстәмә бер шөгыль, мавыгу. Бу затның шигырьләрендә аерым тел-стиль чатаклыклары, кабатланулар, ритмик төгәлсезлекләр, прозаик юллар очравы, иң беренче чиратта, нәкъ әнә шул сәбәпләр белән дә аңлатыла. Әмма без бер хакыйкатьне истә тотарга тиешбез: реаль тормышта катлаулы язмышка ия булган Минһаҗ Исмәгыйли дигән кеше яшәгән, ул әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән; аның, тарихи-мәдәни факт буларак, шигырьләре бар. Шуңа күрә алар хакында фикер йөртү, ул язмаларның кайберләрен укучыларга тәкъдим итү — табигый һәм зарури күренеш.

* * *

Мин бервакыт Минһаҗ агадан: «Кайчан шигырьләр яза башладыгыз?» — дип сораган идем. «Яшьли үк аз-маз сызгаладым. Әмма әсирлек, сагыну мине шагыйрь итте»,— дип җавап бирде ул. Бу уңай белән бер типологик күренеш хакында әйтеп китәргә кирәк: немец зинданнарында газап чигүче бик күп кенә татар әсирләре шигырь язганнар, күңел җирсүләрен сүз сәнгате ярдәмендә басарга тырышканнар. М. Җәлил, А. Алиш, Х. Мөҗәй, Г. Кормаш һ. б.— моның ачык дәлиле.

Минһаж Исмәгыйли мөһаҗәрәттә узган бөтен гомере буена әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Әмма аның әсәрләре юньләп тупланмаган, хәзергәчә төрле җирләрдә һәм кулларда тарау ятуын дәвам итә. Минһаж Исмәгыйлинең тәүге шигырьләр җыентыгы 1953 елда Алманиядә дөнья күрә. Әмма ул китап хәзер безнең кулыбызда юк. Минһаж аганың аерым шигырьләре 40—70 нче елларда чит илләрдәге төрле гәҗит-журналларда, шул исәптән «Kazan» мәҗмугасында да еш басылып тора. «Аҗаган» журналында (1992.— # 2) аның 40 нчы еллар ахырында язылган дүрт шигыре («Сара», «Казан», «Ватанны сагыну», «Солтан Галиев») укучыларга тәкъдим ителде. «Казан», «Ватанны сагыну» шигырьләре «Мирас» битләрендә дә (1995.— # 5—6) дөнья күрде.

Алдарак әйтелгәнчә, үзенең бер өлеш шәхси архивын Минһаж ага миңа биргән иде. Анда, аерым хатлар һәм әдәби текстлар белән беррәттән, 186 битлек, гарәп хәрефләре белән басылган китап та бар (*Минһаҗ*. Шигырьләр җыентыгы.— Иран-Тәһран, 1968). Бу мәҗмугада авторның төрле елларда иҗат ителгән 90 шигыре урнаштырылган (2 меңнән артык шигырь юлы). Китапның 1—8 битләрендә «филология фәннәре докторы Фәрид Кошай» тарафыннан язылган кереш мәкалә бар. Анда авторның тәрҗемәи хәле, шигырьләренең аерым үзенчәлекләре хакында кайбер мәгълүматлар бирелә, «Шагыйрьнең психикасына килгәндә,— ди кереш сүз авторы,— ул — бик йомшак, нечкә күңелле кеше. Фәкыйрь, ятим, зәгыйфьләрне күрсә, яшь бала кебек кызганып, күзләреннән мөлдер-мөлдер кайнар яшьләр тама башлый. Ул, кызганып, кесәсеннән барлы-юклы акчасын чыгарып бирә...» «Шигырьләре, җанлы кеше кебек, укучыны үзенә тартып торалар. Менә инде шуның өчен шагыйрь Минһаж әфәнденең шигырьләрен бер укысаң, тагы икенче мәртәбә укыйсы килеп тора». Китапның ахырында аерым сүзләргә һәм гыйбарәләргә аңлатмалар бирелгән.

Минһаж Исмәгыйли шигырьләренә нинди сыйфатлар хас соң? Ул нәрсәләр турында һәм ничек яза? Иң беренче чиратта, аның иҗаты өчен лириклык, эмоциональлек хас. Вакыйгалардан бигрәк, уй-кичереш, рухи халәт үзәктә тора. Автор шәхесе белән лирик каһарман, еш кына үзара кушылып, бер табигый берлек тудыралар. Шуның нәтиҗәсендә шигырьләр, ничектер, әдипнең шәхси язмыш елъязмасы, поэтик биографиясе рәвешендә дә кабул ителәләр. «Җырларымнан белерсең...» дигән мәшһүр гыйбарәдәге кебек, Минһаж Исмәгыйли шигырьләрен уку аша без авторның бала чагын һәм яшьлеген дә, зиндандагы һәм мөһаҗәрәттәге тормышын да, иҗтимагый һәм шәхси мәнфәгатьләрен дә, психологиясен һәм идеалларын да шактый тулы күзаллыйбыз.

Шагыйрь нәрсә турында гына язмасын, һәрчак татар углы булып
кала:

«Татар» дисәм, миңа күп көч керә,
Күз алдыма килә Батыйлар.
Җир тетрәтеп йөргән Атиллалар,
Нигә, дустым, кабат кайтмыйлар?!

Бу дүртьюллыкның 1968 елгы җыентыкка эпиграф итеп алынуы да юкка гына түгел:

Их, шатланам татар булуыма,
Кычкырып җырлыйм татар җырларын,—

ди автор «Урыска тәрилкә тотучы татар шагыйрьләренә» әсәрендә. Бу юллар — декларатив белдерү түгел, ә Минһаж Исмәгыйли шигъриятенең җаны, рухы.

Алга таба автор татар иленең «Иваннар» тарафыннан яулап алынуы, милләтебезнең коллыкка төшүе, хәзерге хокуксыз хәле хакында яза.

Минһаж Исмәгыйли акча, байлык өчен милләтен сатучыларны, «милли хаиннәр»не кискен тәнкыйтьли:

Кирәкмәсә вөҗдан, оялмасаң,
Рәхәт яшәргә дип уйласаң,
Акча кирәк булса — сат милләтең,
Акчага син әгәр туймасаң...

Гакыллы син, үзең алданмыйсың,
Беләсең син ничек торырга.
Иваннарга сатып Хәйрулланы,
Матур итеп тормыш корырга...

*(«Милли хаиннәргә»)*

Советлар илендә «имансызлык»ның, урыслаштыруның, «Иван көенә җырлау»ның көчәя баруы да шагыйрь игътибарыннан читтә калмаган:

Беткән икән сездә милли хисләр,
Сүнгән икән милләт хисләре.
Кайсы белән генә сөйләшсәм дә,
Аңкып тора урыс исләре...

(«*Милли имансызларга»)*

Катнаш никахлар бездә озак еллар буе макталды, андый гаиләләр халыклар дуслыгының өлгесе рәвешендә тәкъдим ителде. Хәтта Казанның миллионынчы кешесе итеп тә урыс-татар гаиләсенең баласы билгеләнде. Әмма катнаш никахларның татар милләтенә нинди афәт китерүе соңгы елларда гына җәмәгатьчелек тарафыннан күтәрелде. Минһаж Исмәгыйли исә бу мәсьәлә хакында инде моннан кырык еллар элек үк шигырьләр язган:

Әйтче, кызый, нигә кызганмыйча,
Милләтеңне читкә ташладың?
Читләр белән китеп, милләт сатып,
Кара тормыш итә... башладың...

*(«Читләр белән уйнаучы кызларга»)*

Мәшһүр «Идегәй» дастанында ук көнчелек, талаш аркасында бөек Алтын Урда дәүләтенең таралуы эчке әрнү белән тасвирлана. Әмма, кызганыч ки, татар һаман да тарихтан сабак алмый. Бердәмлек җитмәү, үзара ызгыш-талаш Минһаҗ Исмәгыйлине дә бик борчый. Киң катлам укучыларына дәшеп, ул болай ди:

Әй милләтем, нигә соң син
Берлекне һич сөймисең?
Кызганмыйсың халкыңны,
Кайгырмыйсың, көймисең?

Берлек булмау аркасында,
Көл булды ич татарың.
Ызгышып, сугышып тагы
Күпме еллар ятарсың?!

Әхмәд сөйми Биктимерне,
Биктимер — Галиләрне.
Үткән шомлы тарихка
Тагы бер карыйк әле.

*(«Милли берлек»)*

Минһаҗ Исмәгыйли халыкны уяту, аның үзаңын үстерү максатында, милләтебезнең күренекле шәхесләре хакында да шигырьләр яза («Безнең дә бөекләребез булган», «Идел-Урал азат булыр», «Такташ», «Солтангалиев» һ. б.).

Гаяз ага, син бит безгә кояш идең,
Синең юлың ак юл, бәхет юлы иде.
Шуңа күрә син курыкмадың дошманнардан,
Чөнки син бит батыр татар улы идең!..

Шагыйрь «Солтангалиев» әсәрен 1946 елда, бу тарихи затны Советлар илендә «дошман» дип бәяләгән чорда иҗат иткән. Әмма шуңа да карамастан ул Мирсәет Солтангалиевне «даһи» дип атый, аның милли бәйсезлек өчен көрәштә мөһим тарихи роль уйнавын шактый тулы гәүдәләндерә.

Минһаҗ Исмәгыйлинең аерым шигырьләре башка халыкларның мәшһүр затларына да багышланган («Президент Линкольнга», «Ататөрек», «Маршал Маннерхайм» һ. б.). Әмма бу төр тарихи шәхесләрне дә ул милли-азатлык, бәйсезлек, гаделлек өчен көрәш ноктасыннан торып яктырта:

Тарих битләрендә әз очратам
Синең кебек даһи кешеләрне.
Милләтеңне уттан чыгару өчен
Эшләдең син бөек эшләрне,—

ди ул, мәсәлән, Ататөрек хакында.

Мөһаҗир язмышы — Минһаҗ Исмәгыйли шигырьләренең төп темаларыннан берсе. «Мөһаҗир» әсәрендә аның мондый юллары бар:

Явыз фрич мине мәҗбүр итте
Ватанымны ташлап китәргә,
Адашкан каз кебек, берьялгызым
Алманиядә гомер итәргә...

Ватанны, туган җирне сагыну — мөһаҗирлеккә төшкән һәр кеше өчен табигый сыйфат. Эмоциональ, милли рухлы Минһаҗ Исмәгыйлидә исә җирсү аеруча көчле. Туган авылын, үзе туып-үскән Юхма буйларын, яшьлеге үткән Казанны, кендек каны тамган Идел-йортны сагыну аның бөтен иҗатына диярлек хас. Бу төр уй-кичерешләрен ул кайта-кайта, гаҗәеп күптөрле вариацияләрдә белдерә:

Төннәремдә һаман йокламыйча,
Күңелем белән очам еракка.
Их, син, туган илем, Юхма суы,
Калдыгыз шул инде еракта...

*(«Илне сагыну»)*

Син бит — йөрәк, син бит — якты йолдыз,
Син бит — кыйбла татар халкына.
Күптән инде сине ташласам да,
Һаман йөрәк сиңа ашкына...

*(«Казан»)*

Сагынуына дәва таба алмыйча, лирик герой искән җилләргә, очар кошларга, сайрар сандугачларга мөрәҗәгать итә:

Әй җилкәем, беләм, син барасың
Минһаҗ туып-үскән илләргә.
Сәлам сөйлә мине өзелеп көткән
Урманнарга, болын, күлләргә...

*(«Җилгә»)*

Ул «Рейн суын» кичкәндә дә, «Бельгиянең күмер шахтасында» да, Альп тау итәгендә дә туган җирен, аның кешеләрен уйлый:

...Бельгиянең күмер шахтасында,
Миссисипи елга буенда,
Сезне сагынып, иркәм, үтә гомерем,
Сез булырсыз минем уемда...

*(«Татар кызына*»)

Аның сөйгән ярлары да («Озын кара чәчле, кара кашлы, нечкә билләре дә») — җирсез-зәминсез затлар түгел, ә Идел-йорт, милләт кызлары. Туган якның хәтта этләре дә аңа «сөеп» кенә өрә.

...Далаларга чыксам, сандугачлар
Сайрый-сайрый каршы ала иде.
Урманнардан җырлап үткән чакта,
Кошлар сайрап озатып кала иде.

Этләрең дә сөеп, якын күреп,
Өрә-өрә каршы ала иде.
Ата казларың да йөгреп килеп,
Тешли-тешли озатып кала иде...

*(«Авылны сагыну»)*

Татарның күпгасырлык тарихы, мәдәнияте мөселман көнчыгышы белән тыгыз бәйләнешле. Шәрык дөньясы белән багланыш татарның рухи үсешен, милли яшәешен тәэмин иткән. Минһаҗ Исмәгыйли дә бу тарихи хакыйкатьне яхшы аңлый. Истәлекләрдән аның гарәп-фарсы һәм төрки классикасын ныклап укуы, аны хөрмәт итүе мәгълүм. Бу мәсьәләгә шагыйрь үз әсәрләрендә дә урын бирә. «Җәләледдин Румый кабере янында» шигырендә ул татар зыялыларының остазы булган, бөек фарсы әдибен (XIII йөз) гаять зурлый, аның күпкырлы талантын, тарихи ролен югары бәяли.

...Күк йөзендә зур йолдызлар күп булса да,
Һәр көн алар яңарып, туып торса да...
Синең кебек якты түгел ул йолдызлар,
Зәңгәр күкне яктыртучылар булса да.

Минһаҗ Исмәгыйли, нигездә, икенче һәм дүртенче юллары үз-ара рифмалашучы дүртьюллык строфалар белән яза. Аларның күпчелегендә иҗекләр саны 10–9–10–9, ә ритмик буыннар 4+2+4, 4+2+3... рәвешендә. Арада һәр юлы 12 шәр иҗектән торган (4+4+4) шигырьләр дә бар. Бу төр үлчәмнәр һәм рифмалашу, гомумән, татар сүз сәнгатенә хас. Күпчелек шигырьләре 6—7 строфалы.

Минһаҗ Исмәгыйли эндәш, мөрәҗәгать формасын аеруча яратып куллана:

...Син бит, Казан, мине кеше иттең,
Юл күрсәттең алга атларга...

*(«Казан»)*

...Һичвакытта, Сара, онытмамын
Синең нурлы, көләч йөзеңне...

*(«Сара»)*

Шагыйрь кайвакыт башкаларга гына түгел, ә үз-үзенә дә мөрәҗәгать итә һәм, газәл жанрындагы кебек, үз исемен дә шигырьләренә кертеп җибәрә:

Кайгырма син, Минһаҗ, түкмә яшең,
Читтә үтә диеп көннәрем.
Бөек пигамбәр дә синең кебек
Үткәргән бит шулай төннәрен...

*(«Читтә йөрү»)*

Кабатлау, ягъни янәшә шигырь юлларын бер үк сүзләр (ягъни юлбаш анафоралар) белән башлау төрки-татар сүз сәнгатендә, Бакырганый, Өмми Кәмал, Кандалый иҗатлары аша элек-электән килә. Бу сәнгати алымны Минһаҗ Исмәгыйли дә хуш күрә.

...Яз, бәгърем, зинһар, сәлам хаты,
Яз, бәгърем, зинһар, ташлама...

*(«Хат көтәм»)*

...Син генә бит минем якын дустым,
Син генә бит мине аңлыйсың;
Син генә бит, мине якын күреп,
Сахра-болыннарда сайрыйсың...

Юлбаш анафора, кабатлау алымнарын автор кайвакыт риторик сорау белән бергә дә бирә:

Нигә соң мин болай чит илләрдә?
Нигә соң мин хәсрәт эчендә?..

*(«Нигә мин чит илдә?»)*

Минһаҗ Исмәгыйли иҗатында кешенең уй-кичерешләрен, эш-гамәлләрен табигать белән бәйләнештә бирү дә еш очрый. Пейзаж инсан яшәешенең зарури бер өлеше, компоненты рәвешендә тасвирлана.

...Син, кояш, нинди генә җылмайсаң да,
Шәфкатьле җил, чәчләремне тарасаң да,
Матур-матур күбәләкләр очкан чакта,—
Һич оныта алмыйм син, алтыным, туган илне...

*(«Туган ил»)*

Минһаҗ Исмәгыйли татар сүз сәнгатендәге, сөйләм телендәге күптөрле сурәтләрне, тасвир чараларын шактый мул куллана («кара каш», «нечкә бил», «алтын кебек», «зәңгәр күзләр», «Куян кебек качып-посып йөрү» һ. б.). Шигырьләрдә «урыс» этнонимы еш кына «Иван» исеме белән атала. Автор үзе яраткан, хөрмәт иткән кешеләрне, әйберләрне кайчак «кояш», «якты йолдыз» белән тиңли: «Син бит безгә якты йолдыз идең» (Солтангалиев).

Минһаҗ ага Гаяз Исхакыйның сөйләм көчен белдерү өчен аны «аккан сулар, сайрар кошлар туктап тыңлый иде» дигән сурәтне кулланырга ярата иде. Бу детальләр аның шигырьләрендә дә очрый:

...Матурлыгын ишетеп, шигырьләрен
Агымсулар туктап тыңлаган...

*(«Безнең дә бит бөекләр булган»)*

Шагыйрь иҗатында кулланылган «кара тәкъдир», «боеккан кош», «адашкан каз» кебек сурәтләр мөһаҗир тормышын, автор язмышын тагын да калкурак күрсәтергә ярдәм итәләр.

Яшәгән урыннарына, кылган сәфәрләренә, укыган китапларына мөнәсәбәттә Минһаҗ Исмәгыйли үз иҗатында күптөрле географик һәм тарихи атамалар, кеше исемнәре куллана. Алар, кагыйдә буларак, шигырьләрнең эчтәлеге белән табигый ялганып, төп тема белән керешеп китәләр.

Безнең әдәбиятта аерым инсаннарга багышлап әсәрләр язу, мәдхияләр иҗат итү күптәннән килә. Бу традициягә тугры калып, Минһаҗ Исмәгыйли төрле багышламалар иҗат итә. Аларда, бер яктан, төп адресатлар мактала, икенче яктан, авторның хатирәләре, тегеяки бу мәсьәлә буенча уй-кичерешләре бәян ителә («Ататөрек», «Максуд дустыма», «Инженер Барый дустыма» һ. б.).

«Ак каен» — Зыя Ярмәки иҗатының йөзек кашы. Бу әдипкә багышламасында Минһаҗ Исмәгыйли нәкъ әнә шул ак каен детале аркылы дустын зурлый, Зыя Ярмәки белән үткән яшьлек көннәрен искә төшерә.

Гармун (тальян гармун) — татар рухи дөньясының бер символы. Мөгаен, шуңа күрәдер бу деталь Минһаҗ Исмәгыйли иҗатында да очрый. Хәтта шагыйрьнең «Гармун» дип исемләнгән махсус шигыре дә бар. «Барый дусты»ның «Альп буйларында» сузып-сузып уйнаган гармун моңы лирик геройның күңелен кузгата, аны Ватанга, татар тарихына алып китә, яшәргә «көч бирә».

Һади Такташ — татар шигърриятенең алтын баганасы, татар сүз сәнгатенең кабатланмас остасы. Ул чордашларына, үзеннән соңгы укучыларга һәм әдипләргә гаять зур йогынты ясады һәм ясый. Минһаҗ Исмәгыйли — шуның бер ачык дәлиле. Ул Такташны яшьтән үк яратып укуын, аның иҗатына мөкиббән китүен яшермичә сөйли иде. Әдипнең «Мокамай» авторына багышлап язылган махсус шигыре дә бар. Анда ул бөек шагыйрьгә хөрмәт хисләрен белдерә һәм әсәрен мондый юллар белән тәмамлый:

Шигырьләрең, Такташ, җөрәкләрдә
Сакланачак, һич тә югалмас.

Минһаҗ Исмәгыйлинең Такташка охшатып, аңа ияреп язылган шигъри юллары да бар:

...Бер җирдә юк андый зур урманнар,
Бездәгедәй шаулап торганнар...

*(«Себер»)*

Каласың бит, матур туган авыл,
Каласыз бит, яшел урманнар.
Зәңгәр күзле шаян шагыйрьләрен
Онытмаслар әле туганнар...

*(«Саубуллашу»)*

«Такташ» шигырендә ул «Мокамай»ның аерым сурәтләрен дә файдалана. Аның юмористик, сатирик шигырьләрендә дә бөек шагыйрь тәэсирен сизү һич кыенлык сорамый.

* * *

Минһаҗ Исмәгыйли сүз сәнгатендә Такташ та, Җәлил дә, Туфан да, яисә Гаташ та түгел. Аның әдәбиятта тыйнак кына үзенең урыны, үзенә хас сүзе, моңы бар. Бу әдипнең иҗатын гаять зур поэзия бакчасындагы меңләгән чәчәк-үсемлекләрнең берсе итеп кабул итәргә кирәк.

Минһаҗ ага — шәхес буларак та, гыйбрәтле язмышка ия зат. Ул — ярты гасыр буена диярлек мөһаҗирлек шулпасын эчкән кеше.

Аның чит илләрдәге татарларны туплауда, татар мәдәниятен, милли-азатлык идеясен таратуда да роле зур. Минһаҗ Исмәгыйли мөһаҗәрәттәге милләттәшләребезнең тормышы, аеруча Гаяз Исхакый эшчәнлеге белән татар җәмәгатьчелеген таныштыруда да сизелерлек эш башкарды. Гаяз Исхакыйның кабат Ватанга, халыкка кайтуы шактый авыр булды. Бу игелекле эштә Минһаҗ аганың да билгеле бер өлеше бар.

Күп җәфалар, кыенлыклар күргән йөрәгенә дәшеп, автор болай дигән иде:

...Беләм, җөрәк, шулай тибә-тибә,
Бер көн җиткәч типми башларсың...

Әйе, җир йөзендә яшәп алган миллиардлаган инсаннар
кебек, Минһаҗ аганың да йөрәге тибүдән туктады. Әмма үз хал-
кын яратып, татар булуына горурланып яшәгән бу зат безнең күңелләребездә калачак: аның, ягъни шыгырданлының шигъри эстафетасы якташы Рөстәм Сүлти һәм кайбер башка яшьләр тарафыннан дәвам ителә.

*1996*

## Германиядә очраштык*

Язучы һәм шагыйрьләрдән дусларым байтак кына булса да, татар халкының чит илдә яшәүче бөек әдибе Гаяз Исхакыйны ишеткәнем һәм күргәнем юк иде. Туган илемдә яшәгән вакытта дусларым Муса Җәлил, Төхфәт Ченәкәй, Сирин һәм мәшһүр «Ак каен»ны язган Зыя Ярмәки һәм башкалардан да аның турында берни ишетмәдем. Алар, аны белсәләр дә, сөйләргә курыкканнардыр, бәлки. Миңа ул вакытта Гаяз Исхакыйның халкыбызга нинди эшләр күрсәтүе билгеле түгел иде. Аның белән Обер-Байрен җирендәге Миттенвальд төрек лагеренда гына танышырга туры килде. Монысы әле аның әсәрләре буенча читтә танышу булды.

«Төрек лагере» дигәнмен икән, аз булса да аның турында да язып китим. Мин аны Люксембург кебек кечкенә генә бер дәүләткә охшатам. Ул тагын җанлы этнография музеена да тартым. Анда төрки халыклар белән бергә күп раса һәм милләт кешеләре яши иде. Барысы 6—7 мең кеше булыр. Бу лагерьда беренче бөтендөнья сугышыннан ук калган әсирләр дә байтак иде. Болардан тыш, тагын 1917 елда Россиядә Совет власте урнашканнан соң, чит илгә качып китүчеләр дә бар. Биредә Гитлер дәверендә тау дивизиясенең казармалары булган. Ул Миттенвальд шәһәренең иң матур җирендә урнашкан. Аннан Карвендаль тавы күренеп тора. Шәһәр Германиянең музыка мәркәзе булып санала. Монда скрипка эшләү индустриясе урнашкан.

Лагерьда зур матур клуб бар иде. Без менә шул клубта кинолар карый, концерт һәм лекцияләр тыңлый идек. Мондагы тупланышларда милли һәм дини кичәләр дә үткәрә идек. Кырым татарлары, карачайлар, азәрбайҗаннар кебек үк, безнең Идел буе татарлары да еш кына әдәби кичәләргә җыела иде. Бу яктан Миттенвальд лагере минем өчен зур мәктәп булды. Гаяз аганың үлемсез әсәрләре белән нәкъ менә шушында якыннан таныштым. Ул минем күземне ачты. Лагерь клубында Гаяз Исхакыйның ялкынлы драма әсәрләрен сәхнәгә куялар иде. Татар әдипләре һәм галимнәре Кол Гали, Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Һади Такташ һәм башкаларны искә алып, әсәрләрен сәхнәдән яңгыраталар иде. Башкорт әдибе Галимҗан Таган, профессор Галимҗан Идриси лекцияләр укыдылар. Бу лагерьда барлык төрки халыкларның бөек әдипләренең әсәрләре белән танышып, укып, тикшереп чыгарга туры килде. Утызынчы елларда ук Казан дәүләт университетыннан географ булып чыккан булсам, 40—50 нче елларда Миттенвальд лагеренда төрки халыклары әдәбияты «университетын» үтәргә туры килде.

1952 елда минем тормышымда инкыйлаби үзгәреш булды. Көннәрдән бер көнне, өйдә нәрсәдер эшләп утырганда, ишек кыңгыравы шалтырады. Ишекне ачсам, анда миңа таныш түгел ике ир кеше басып тора. Икесе дә өлкәннәр. Берсе — 70—75 яшьләрдәгесе — озын буйлы, үткен нурлы күзле, бик сөйкемле карт. Икенчесе — 55—60 яшьләрдәгесе — уртача буйлы, киң күкрәкле, чәчләренә чал

төшкән килеш-килбәте Чыңгыз ханга охшаган. Зур чиндагы офицер булганлыгы күренеп тора. Сүзне ул башлады:

— Минһаҗ әфәнде, без сезне күрергә килгән идек,—
диде ул.

Исемемне атап әйткәч, мин аларны өйгә узарга чакырдым:

— Әйдәгез, хуш киләсез, рәхим итегез,— дип, өйгә алып кердем.

Өйгә узгач та, сүзне Чыңгыз ханга охшаган кеше дәвам итте:

— Минһаҗ әфәнде, таныш булыгыз, бу кеше безнең милли җитәкчебез Гаяз Исхакый була,— дип таныштырды.

Аның исемен ишеткәч катып калдым, телем бәйләнде. Мондый зур шәхес алдында сүзне кайдан башларга аптырап тордым. Шундый олы әдип ничек әле Минһаҗ кебек эшче янына килеп чыгасы итте икән, дип аптырашта калдым. Без шулай танышып, сөйләшеп утырганда, тормыш иптәшем Амалия чәй дә өлгертте. Өстәл янында дуслашып киттек. Чыңгыз ханга охшаган кеше Салихов икән. Гаяз ага, миңа карап:

— Минһаҗ әфәнде, ишетүемә караганда, сезнең Ной-Ульм шәһәрендә байтак кына татарлар яши икән, шулар белән күрешеп-сөйләшәсем килә,— диде.

Мин халык җыярга чыгып киттем. Бик тиз арада кешеләрне «Ной-Ульмер Хоф» ресторанына чакырып та китердем. Аның зур залы халык белән шыгрым тулды. Идел-Урал татарларын гына җыярга уйлаган булсак та, көтмәгәндә үзбәк, казах, азәрбайҗан, шимали Кавказ халыклары, Кырым татарлары, хәтта калмык һәм монголлар да килгән иде. Кешеләр җыелып беткәч, сүзне генерал Салихов башлап җибәрде. Ул, кыска гына нотык сөйләгәннән соң, сүзне әдип Гаяз Исхакыйга бирде.

Гаяз ага Исхакый сәхнәгә менүгә, залда утырган халык аны ярты сәгатькә якын кул чабып алкышлады. Әдип, як-ягына каранып, ашыкмыйча, әкрен генә, матур итеп сөйли башлады. Үзе карт булуына карамастан, тавышы көчле икән. Кулында кәгазь-фәлән юк. Тавышында ниндидер моң бар. Авызыннан сүзләр чишмә кебек агып кына тора. Сүзен җепкә төймә тезгән кебек тезеп бара. Фикерләре тальян гармуныннан чыккан кебек яңгырап торалар. Көчле оратор икәнлегенә шунда инандым. Аны тикмәгә генә Цицерон яки гарәп әдәбиятындагы Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве хәзрәти Алига тиңләмиләр икән. Гаяз Исхакый сүзләрнең, җөмләләрнең тәэсирле чыгышына көч-куәт бирүче төрле халык мәкальләрен дә бик урынлы куллана. Ул кыска гына вакыт эчендә бөтен залны үзенә җәлеп итте. Күп вакыт узганнан соң да, аның сөйләгәннәре колак төбендә яңгырап тора кебек. Ул, сүзен дәвам иттереп, болай диде:

— Халкыбыз дүрт гасыр милләте, теле, дине, гореф-гадәтләре чит булган ятлар чабатасы астында тапталып, изелеп килә. Читләр кулында калганчыга кадәр Ватаныбыз чәчәк атып торган ил иде. Баскынчылар, Казанны яулап алу белән, илебезне таладылар. Ничә меңләгән гаепсез кешеләрне — картларны, хатын-кыз һәм бала-чагаларны юк иттеләр. Халкыбызны берниндн хокуксыз колга әйләндерделәр. Казан өчен булган сугышларда бик күп кешеләребез корбан булды. Баскынчылар Казанга 150—160 мең кешелек яхшы коралланган гаскәр белән килделәр. Аларга каршы 50—60 мең кешелек Казан гаскәре каһарманнарча сугышты. Безгә аларның искиткеч зур батырлыклар күрсәтүләре мәгълүм. Дин башлыгы Кол Шәриф үзе генә түгел, ә шәкертләре белән бергә сугыш кырында корбан булды. Казанның атлы гаскәр башлыгы Япанчы дошман гаскәренең котын алды. Казанлылар, физик яктан җиңелсәләр дә, рухи яктан бирешмәделәр. Аларның йөрәгендә милли азатлык уты беркайчан да сүнмәде.

Татарстан халкы 1990 елның 30 августында үз мөстәкыйльлеген игълан иткәч, минем күңлемдә Гаяз Исхакыйның алдан күрүчәнлек белән сөйләгән сүзләре тагын да яңарды. Ул үзенең нотыгын зур ышаныч белән болай дип дәвам иттергән иде:

— Милли азатлык уты безнең йөрәкләребездә әле бүген дә дөрләп янып тора. Ул безне соңгы көрәшкә чакыра. Явыз Иван,— диде ул,— Казанны алгач, кешелек тарихында беркайчан да күрелмәгән җинаятьләр эшләде. Әле б. э. к. римлылар Карфагенны ничек туздырган булса, Иван да Казанны яндырды, көлгә әйләндерде. Меңнәрчә зыялыларыбызның башын кистерде, галимнәрне әсир итеп Мәскәүгә алып китте. Казан тирәсендәге татарларны 40 чакрымга куды, татар авылларына урысларны китереп утыртты, изге Казан җирендә чиркәү һәм монастырьлар салдырды... Азатлык кояшы әле бөтенләй үк батып бетмәгән. Ул калкыячак. Сөекле Ватаныбыз беркөн азат булачак. Мин моңа ышанам,— диде ул, аннары,— бөтен гомерем буе барлык көч-куәтемне халкым өчен кызганмадым. Патша төрмәләрендә генә дә 18 тапкыр утырдым. Патша жандармнары, артымнан калмыйча, һәр адымымны күзәттеләр. Хәзер безнең иң төп вазифабыз,—
дип төгәлләде ул сүзен,— дүрт гасыр элек баткан арбаны тартып чыгарудан гыйбарәт! Алла безнең белән. Яшәсен халык берлеге!

Ватаннан еракта, Германия җирендә, Ной-Ульм шәһәренең бер ресторанЫ залында бөек татар әдибе Гаяз Исхакыйның әнә шундый ялкынлы чыгышын тыңларга туры килде. Ул
бу елны, инде өлкән яшьтә булуына карамастан, барлык илләрдәге татарлар белән очрашып чыккан

булырга тиеш.
Бу Явыз Иванның Казанны басып алуына 400 ел тулган көннәр иде.
*1991*

## Шигырьләр

### Казан

Син бит якты йолдыз,
Син бит кыйбла,
Син бит мәркәз татар халкына.
Күптән инде сине ташласам да,
Һаман йөрәк сиңа талпына.

Күрер идем матур Кабан күлен,
Яшьлегемдә җөргән җиремне.
Сөяр идем тагын, кысып-кысып,
Кара кашлы нечкә билемне.

Таптар идем Казан урамнарын,
Барыр идем Арча кырына.
Гөлчәчәкләр бүләк итәр идем
Сыркыдылы Хәйрул улына
(ягъни Такташка.— *Х. М.*).

Менә шунда диләр аның йорты,
Шул зиратка аны күмгәннәр.
Әнә күрәсезме: такыр сукмак —
Димәк, күпләр монда килгәннәр.

Фатих Әмирхан да биредә бит,
Камалларны монда күмгәннәр.
Урамнарда җылы аяк эзе
Мәрҗаниләр монда йөргәннәр.

...Казан, Казан —
Син бит безгә кыйбла,
Син бит мәркәз татар халкына.
Күптән инде сине ташласам да,
Һаман йөрәк сиңа талпына.

### Илне сагыну

Безнең илдә инде язлар җитеп,
Кошлар инде сайрый торгандыр!
Болыннар да бары төрле төстә
Матур чәчкә белән тулгандыр!

Кош-кортлар да инде үзләренә
Матур итеп оя коргандыр.
Юхма су буйлары, урманнар да
Мине эзләп кенә торгандыр.

Сагынам сине, туган авылкаем,
Сагынам сине иртә-кичләрен.
Сине сагынып читтә картаям мин,
Үтә сагыш белән көннәрем.

Әй авылкаем, синең урамыңнан
Җырлап үтәр идем тагын да.
Юхма су буйлары, таныш җирләр
Каршы алсыннар иде тагын да.

И Ходаем, тагын насыйп итче
Туган илкәемне күрергә.
Юхма су буйлары, урманнарда
Матур итеп җырлап җөрергә.

**Фатыймага хат**

Онытa алмам зәңгәр күзләреңне,
Күрә алмам нурлы җөзеңне.
Кара көннәр килде яшен яшьнәп,
Таба алмыйм баскан эзеңне.

Тапсам әгәр баскан эзләреңне,
Тирән дәрьялардан үтәрмен.
Кара көннәр үтәр, мин һаман да
Кавышуны, бәгърем, көтәрмен.

Инде чыкмас, бәгърем, безнең кояш,
Мәңгелеккә, бәлки, баткандыр?
Әнкәй безне бер караңгы төндә
Газап чигәр өчен тапкандыр.

Менеп карыйм Альп тау башына,
Күрмәм микән диеп җөзеңне.
Әгәр булса идең минем янда,
Сөеп туймас идем үзеңне.

Белмим, хәзер инде ишетә алмам:
«Кайда булдың, Минһаҗ? — диюең,—
Озак тордың бүген, күгәрчен»,— дип,
Гүзәл итеп синең көлүең.

Матур иде синең кара кашың,
Нурлы иде синең җөзләрең.
Минһаҗ бәгърем, диеп караганда,
Нурлар чәчә иде зәңгәр күзләрең.

Без икебез киттек ике юлдан,
Минем юлда булды киртәләр.
Каты җилләр чыгып, ду китереп,
Күп кешеләрне шулай иттеләр.

Менә көчле шундый салкын җилләр
Көймәләрне ватып ташлыйлар.
Диңгез дулкыннары шулай итеп
Күп кешенең башын ашыйлар.

**Җилгә**

Әй җилкәем, беләм, син барасың
Минһаҗ туып-үскән илләргә.
Сәлам сөйлә мине өзелеп көткән
Урманнарга, болын, күлләргә.

Тиздән кайтыр, дип әйт, сезнең Минһаж,
Сагынып кайтыр туган иленә.
Яшьлегендә уйнап-көлеп үскән
Алтыннан да кыйммәт җиренә.

Көрәш кырларында алгы сафта,
Зәңгәр байрак аның кулында.
Җиң сызганып һаман эшләп килә
Илне азат итү юлында.
Дошманнарны җиңгәч, илне азат иткәч
Сагынып кайтыр сезнең кырларга.
Хөр, мөстәкыйль илнең урманнарын,
Болыннарын мактап җырларга.

Ул җырларга туган халкы өчен,
Ул җырлауны сөя, ярата.
Илен, халкын мактап җырлаганда,
Кайгы-хәсрәтләрен тарата.

Кайтуымны сөйлә син, җилкәем,
Кайтуымны сөйлә илемә!
Кайтуымны сөйлә син халкыма,
Мине үстергән изге җиремә!

**Туган ил**

Җылмаеп кояш миңа караганда,
Шәфкатьле җил чәчләремне тараганда,
Бакчаларда сандугачлар сайраганда,—
Шул чакларда искә төшә туган илем.

Син, кояш, ничек кенә җылмайсаң да,
Шәфкатьле җил, чәчләремне тарасаң да,
Матур-матур күбәләкләр очкан чакта,—
Һич оныта алмыйм син, алтыным, туган илне.

Искә төшә туган илнең урманнары,
Җәелеп яткан яшел хәтфә болыннары,
Күз алдымда балык тоткан су буйлары,—
Шуңа күрә оныта алмыйм, туган илем.

Искә алам күл буенда җөргәннәрне,
Каз бәбкәсен саклап кайтып килгәннәрне.
Әнкәемнең каршы чыгып алулары,—
Әле дә булса күз алдымда, туган илем.

Үткәннәрне бертуктамый уйлаганда,
Хәсрәт-хыял дәрьяларын буйлаганда.
Яшь башымны кара уйлар каплаганда,—
Шул вакытта күз алдымда туган илем.
Искә төшә илдә калган туганнарым,
Зәңгәр күзле Фатыймам һәм балаларым.
Күзләремне кайнар яшьләр каплаганда,—
Шул чакларда бигрәк авыр, туган илем.

Кара тәкъдир ут эченә ташласа да,
Тормышымда кара көннәр башланса да,
Фронтларда көрәшкәндә Ватан өчен,—
Син булырсың, туган илем, күз алдымда!

**Безнең дә бит бөекләр булган**

Безнең дә бит булган Иманиләр,
Гомәр Хәйям кебек җырлаган.
Матурлыгын ишетеп, шигырьләрен
Агымсулар туктап тыңлаган.

Шаулап яңгырап торган Идел буе —
Думавилар җырлап җөргәндә.
Кош-кортлар да бары баш игәннәр,
Мөхәммәдьярлар җырлап килгәндә.

Их, нигә миңа шул нәселдән булып
Җырламаска, уйный, көлмәскә!
Мин татар бит, диеп горурланып,
Күкрәк киереп нигә җөрмәскә!

**Татар гаскәре**

Булган, диләр, татар гаскәренең
Җир тетрәткән батыр чаклары.
Бернидән курыкмый Дөлдөл кебек,
Утка керә торган атлары.

Шул атларга менеп Урта Азиядән
Җыракларга кадәр килгәннәр.
Күп җирләргә алар хуҗа булып,
Һичберкемнән курыкмый җөргәннәр.

Кешеләр генә түгел, хайваннар да
Тез чүккәннәр татар алдында.
Калтырап торган бөтен дөнья халкы
Татарларны күргән чагында.

Арысландай алар көчле булган,
Дошманнарны бик тиз җиңгәннәр.
Күп җирләрне таптап, яшен кебек,
Ромаларга кадәр җиткәннәр.

Кайда хәзер Чыңгыз, Батый, Субәдәй?
Җир тетрәткән үткен атлары.
Тар-мар итеп дошман гаскәрләрен,
Шатланышып кайткан чаклары?

Кайда киткән алар — арысланнар,
Нигә тагы кайтып килмиләр?
Нигә тагы алар дер селкетеп,
Евразияне таптап җөрмиләр?

Әйдә атлыйк, дустым, алга таба
Чыңгыз, Батый җөргән юллардан.
Дошман калтырап торсын безне күреп
Тимер-корыч кебек куллардан.

**Дустым шагыйрь Исфәндияргә**

Җырла, дустым Ишгай, матур итеп,
Җырла кычкырып татар җырларын.
Мактап Сарай, Кашлык шәһәрләрен,
Ак Идел һәм Җаек буйларын.

Ишетсеннәр урман, киң яланнар,
Ишетсеннәр җырак далалар.
Тыңласыннар матур тавышыңны
Илебездәге авыл-калалар.

Яңгырап торсын Себер далалары,
Дулкынлансын Байкал күлләре.
Ишетсеннәр дәртле җырларыңны
Казакъстан сахра-чүлләре.

Син җырлыйсың хөр, иркенлек чорын,
Син әйдисең алга атларга,
Чакырасың мескен татарларны
Коллык богауларын ташларга.

Шулай кирәк, дустым Исфәндияр,
Курыкмый җырла ирек җырларын.
Мактап илнең батыр җегетләрен,
Эш сөючән матур кызларын.

### Сандугач

Сандугачлар сайрый киң яланда,
Һаваларның матур чагында.
Сайра тагы, сөйгән сандугачым,
Мин тыңлармын сине тагын да.

Син генә бит минем якын дустым,
Син генә бит мине аңлыйсың.
Син генә бит мине якын күреп
Сахра-болыннарда сайрыйсың.

Сайра тагы, сөйгән сандугачым,
Чын күңелдән сөеп тыңлармын.
Сине сөеп, якын дустым итеп,
Сиңа каршы мин дә җырлармын.

Синең тавыш миңа дәртләр бирә,
Көчәйтә тагын йөрәк тибешен.
Ватанымны уйлап алга атлыйм,
Алып синнән илһам җимешен.

### Ак каен

Биек тауның яшел итәгендә
Җәелеп үсә матур ак каен.
Ак каенга барып серем сөйлим,
Ватанымны искә алган саен.

Бездә дә бар иде ак каеннар,
Бездә дә бар иде матурлар.
Бездә дә бар иде сезнең кебек,
Күкрәк киереп торган батырлар.

Әле дә булса минем күз алдымда
Ватандагы яшел ак каен.
Ак каенга барып серем сөйлим,
Илкәемне искә алган саен.

**Кайтырмын мин**

Шыгырданым, һәрвакытта син уемда,
Җөреп торам өмә, мәҗлес, туйларында.
Җыракларда яшәсәм дә авылымнан,—
Син генә бит һаман минем уйларымда.

Юхма, Була буйларында җөреп торам,
Илгә кайтам дип шатланам, хыялланам.
Әгәр кайтсам Юхма, Кизләү буйларына,—
Ирешер идем хыялланган уйларыма.

Һәрвакытта сез торасыз күз алдымда,
Каршы алырга сез чыгасыз юлларыма.
Кулга тотып матур-матур чәчәкләрне
Киләсез сез Юхма суы буйларына.

Сәлах абзый, кайгырма син, кайтырмын мин,
Сезнең кырда чәчәк булып атырмын мин.
Юлларымны бүлеп торган киртәләрне
Курыкмыйча җимерермен, ватырмын мин.

Явыз Гитлер аерса да туган илдән,
Мине үстергән җәннәт кебек матур җирдән.
Сагынып кайтам туганнарым күрер өчен,
Күз күрмәслек аралардан, җырак илдән.

**Идел-Урал азат булыр**

*(Гаяз агага)*

Гаяз ага, син бит безгә кояш идең,
Синең юлың ак юл, бәхет юлы иде.
Шуңа күрә курыкмадың дошманнардан,
Чөнки син бит батыр татар улы идең!

Күкрәк киереп син атладың алга таба,
Татарларың хәзер курыкмый алга бара.
Бер көн килер, Идел-Урал азат булыр,
Шуны көтә, шуны көтә халкың алда.

**Батый хан**

Кай җирләрдә генә ята икән
Җир тетрәткән Батый гәүдәсе?
Идел-Урал, Амур буйларында
Әле дә йөри аның шәүләсе.

Кайда гына соң син, нигә бер дә
Ярдәм кулын безгә сузмыйсың?!
Җир тетрәтеп узган дошман җирен
Нигә тагы таптап узмыйсың?

Байкал күлләрен дә күп әйләндем,
Амур буйларында тапмадым.
Зәңгәр күктән синең йолдызыңны
Күпме эзләсәм дә — тапмадым.

Зәңгәр күккә алсу нурын чәчеп,

Җиһан гизгән йолдыз батканмы?
Сугыш кырларыннан арып кайтып
Ял итәргә әллә ятканмы?!

*Малайзия Федерациясе,*
*Куала-Лумпур. 1961*

**Сара**

Нигә соң мин тальян гармунымны
Тартып-тартып бер дә уйнамыйм?
Шаулап аккан Майн елгасының
Зәңгәр суын чумып буйламыйм?

Көчем җитми инде Майннарны,
Рейннарны йөзеп буйларга.
Искә алып үткән көннәремне,
Чумып китәм тирән уйларга.

Алар калды инде еракларда,
Текә таулар каплый араны.
Онытa алмыйм һич тә яшьлегемне,
Кара кашлы сөйгән Сарамны.

Турларыннан үткән чакларымда,
Гаҗәпләнеп карап кала иде.
Су буенда көянтәсен аскан —
Шул ук минем сөйгән Сара иде.

Һичвакытта, Сара, онытмамын
Синең нурлы, көләч йөзеңне.
Еракларга китеп, кайта алмадым...
Кичер, Сара, кичер син мине.

*Япуния, Токио. 1965*

**Көтмә мине**

Хатлар көтмә миннән, бәгырькәем,
Өзелеп-өзелеп ерак илләрдән.
Далаларга чыксаң ишетерсең
Минем хәлне искән җилләрдән.

Алар барын сиңа сөйләп бирер,
Дикъкать белән сөеп тыңларсың;
Мине искә алып сагынганда,
Сөйгән җырларымны җырларсың.

Елама син, иркәм, түкмә яшең,
Үткән көннәр кабат кайтмаслар.
Инде хәзер бәхет бакчасында
Яшьлек чәчәкләре атмаслар!

*Канада, Оттава. 1967*

**Мөһаҗир**

Тау башына менеп карасам да
Күрә алмыйм туган җиремне.
Империалист фриц аркасында
Ташлап киттем Туган илемне.

Дучар итте сугыш әсирлеккә,
Газапларны хәтсез татырга.
Көтә, дигәч, Сталин лагере,
Юллар ябык иде кайтырга.
Мин ялгыз шул монда, минем сүзне
Якын итеп беркем тыңламый.
Ватандагы кебек сузып-сузып,
Татар көен беркем җырламый.

Әхмәдулла, Әхмәт, Биктимерләр
Урамнарда монда йөрмиләр.
Тынычланыр идем, төштә күрсәм,
Төшемә дә инде кермиләр.

Матур Кабан күле, Карәхмәтләр
Еракларда инде калдылар.
Урал тавын, Идел яр буйларын
(күңелләрдә.—Х. М.)
Дунай су буйлары алдылар.

Нинди генә кошлар сайраса да,
Яратмыйм мин Дунай буйларын.
Сөям сине, Ватан, чын йөрәктән,
Синдә генә бөтен уйларым.

Чөнки синдә тудым, синдә үстем,
Синдә алга таба атладым.
Күп илләрне күрдем, күпне гиздем,
Синнән матур илне тапмадым.

*Бразилия, Рио-де-Жанейро.  1961*

### Саубуллашу

Каласың бит, матур туган авыл,
Каласыз бит, яшел урманнар.
Зәңгәр күзле шаян шагыйрьләрен
Онытмаслар әле туганнар.

Китәм сезне ташлап еракларга,
Күз күрмәслек ерак илләргә.
Хатларга сыймаса сагынуларым,
Тапшырырмын җылы җилләргә.

Татар җырын көйләп моңаермын,
Якын итмәм чит-ят телләрне.
Алтын-көмеш, җәүһәр-якутларга
Алмаштырмам Туган илләрне.

*Чувашстан, Шыгырдан авылы.  1991*

### Ахирәтне онытма

Яратмыйм мин алтыннарны, көмешләрне,
Акча! диеп йөгереп йөргән иблисләрне.
Синең җыйган алтын-көмеш акчаларың,
Үзең үлгәч, явыз кеше алыр барын.

Бу дөньяга адәм килгән кунак булып,
Бөтен җыйган байлыкларын китәр куеп.
Мәңге яшим, бай булам дип, комсыз затлар
Йөри җирдә кеше талап, кеше суеп.

Мин хуҗамын бу дөньяда диеп йөрмә,
Акча диеп җәһәннәмгә барып кермә.
Мал җыям дип, бертуктаусыз чаба-чаба,
Вакыт җитми үз-үзеңне син үтермә.

Чыңгыз ханнар, Наполеоннар да үлгәннәр,
Вакыт җиткәч, гүр кочагына кергәннәр.
Куркынычлы ачы әҗәл киләчәген
Алар көткән, үләчәкләрен белгәннәр.

Бар инсаннар үлем өчен бит туганнар,
Планетада каһарманнар күп булганнар.
Тик алар да, гомер бетеп, әҗәл җитеп,
Матур җирне ташлаганнар, югалганнар.

Күп адәмнәр уйламыйлар ахирәтне,
Мәхшәр көне тиз-тиз басып киләчәкне.
Мәхкәмәдә ул көн сиңа өлеш итеп
Нинди бәя, нинди бүләк бирәчәкне.

*Согуд Гарәбстаны, Җиддә,*
*анабыз Хаува кабере өстендә. 1970*

**Дөньяны яратучы көч**

Карасам мин әгәр күк йөзенә,
Барлыйм иксез-чиксез галәмне.
Нинди генә сихри көчләр белән
Чолгамаган Тәңре адәмне.

Кояш, Ай да һаман хәрәкәттә,
Йолдызлар да йөзеп йөриләр.
Миллион еллар балкып торсалар да,
Ару-талу алар белмиләр.

Җәннәт иттең, Тәңре, планетаны,
Диңгез-океаннарны китердең.
Сахра-болыннарны бизәкләдең,
Матдәләрне юктан бар иттең.

Калкып чыкты Урал, Гималайлар,
Могҗизалар өстәп дөньяга.
Әмер бирде Тәңре бар галәмгә
Тау-ташлар да кирәк булганга.

Хәрәкәткә килде барлык хәят,
Җиһаннардан яуды бәрәкәт.
Тәңре көче-изгелеге белән
Җир өстендә туды чын җәннәт.

Архназуйда килде түбән хәят,
Мезазуйда килде зурлары.
Кайназуйда инде аяк басты,
Баш күтәрде адәм уллары.

Планетаның барча хайваннары
Тез чүктеләр адәм алдында.

Ә ул җир йөзеннән атлап китте
Якты, матур хәят таңында.

Тәңре бирде аңа бар байлыкны.
«Белеп яшә»,— диеп дөньяда.
Тормыш юлың синең җиңел түгел,
Горур атла шулай булса да.

Сиңа җитәр биргән ризыкларым.
Гакыл белән генә файдалан.
Ялкауланма бер дә, эшләп аша...
Һәм онытма мине — искә ал!

Онытма син минем кошларымны,
Хайваннарга тимә, торсыннар.
Аларның да урыны җир өстендә —
Үзләренчә тормыш корсыннар.

Сиңа дошман — явыз Иблис мәлгунь,
Атлама син аның юлыннан.
Әгәр тыңласаң син ул мәлгуньне,
Югалырсың һәлак кулыннан.

Алданма син аның сүзләренә,
Татлы сөйләп сине аздырыр.
Харап булырсың син ул мәлгуньнән,
Адаштырыр, юлдан яздырыр.

Шул имансыз сезгә ялган сөйләп
Кудыртты бит сезне җәннәттән.
Яхшы саклан Иблис коткысыннан,
Ул яши тик бары гайбәттән.

Ул үтерде мескен Һабилне дә,
Зур таш биреп Кабил кулына.
Күп адәмнәр гөнаһлы һәлак була
Шул Иблиснең пычрак юлында.

*Япуния, Токио. 1960*

### Изгелек телим

Утырам өстәл янында,
Кулыма каләм тотып.
Яхшы илһам килмәгәнгә
Борчылып, чырай сытып.

Хат язсам да, язмасам да,
Ни файдасы бар сиңа...
Сиңа бернәрсә теләмим,
Телим тик саулык кына.

Башка байлык көтмә миннән,
Көтмә алтын-көмешләр.
Мин саулыклар гына телим,
Миннән сиңа җимешләр!

*Алмания, Мен-һем,*
*Байба лагере. 1947*

### Сез карт дисез мине

Сез карт дисез мине, ялгыш бит ул,
Чын картлык бит әле җитмәгән.

Көрәш алып барам яшәү өчен,
Яшәү дәрте әле бетмәгән.

Мин ашкынам һаман алга таба —
Баш имичә алга атларга.
Атлантикны кисеп, Американың
Калифорниясен таптарга!

Татарларны һичкем җиңалмаган,
Җиңелерлек түгел ул халык.
Һәр акыллы кеше моны аңлый,
Бу — хакыйкать, бу бит — чынбарлык!

**Яшьлек тиз үтте**

Гыйшык уты инде күптән сүнде,
Яшь вакытлар үтеп киттеләр.
Көмеш ап-ак чәчне, ак мыекны
«Ал, бабай»,— дип бүләк иттеләр.

Әүвәлгедәй түгел көч-куәт тә,
Кул-аяклар бии, калтырый.
Ничек кенә өзелеп сагынсам да,
Яшьлек көннәр кайтмас, ахры.

Яшен кебек алар бик тиз үтте,
Сизми калдым чәчкә койганын.
Алтын чәчкә яшьлек бигрәк кыска,
Кыска гомерле аның булганын.

Ник соң яшьлек кыска гомерле ул,
Мәңгелеккә Тәңре бирмәгән?!
Нигә соң ул һаман чәчәк атып,
Нур чәчәргә безгә килмәгән?!

Яхшы булыр иде бертуктамый
Безнең белән бергә яшәсә,
Гали Дөлделеннән көчле итеп,
Бәхет кырларында кешнәсә.

Караңгыда безгә юл күрсәтеп,
Безнең белән бергә атласа.
Безгә ак нур сипкән таң йолдызы
Мәңге сүнми, мәңге батмаса.

**Юхма буе**

Чәчкә кебек матур яшь чакларым
Шаулап үтте Юхма буенда.
Шул күңелле чаклар, Юхма суы
Әле дә тора минем уемда.

Нинди күңелле иде ул вакытлар,
Кайгы-хәсрәтләрне белмәдем.
Бүгенгедәй башым аска иеп,
Хәсрәтләнеп, көеп җөрмәдем.

Кайда гына бармыйм, туган илем
Якын күреп каршы ала иде.
Җыракларга киткән чакларымда
Дус-ишләрем озатып кала иде.

Һич онытa алмыйм инде Юхма буен,
Оныта алмыйм үткән көннәрне;
Күз алдыма китереп Юхма буен,
Үткәрәм мин шулай төннәрне.

**Җөрәк**

Кем уйлаган явыз тәкъдир мине
Җыракларга алып китәр дип,
Ялкынланып янган бунтарь җөрәк
Әкрен-әкрен сүнеп бетәр дип.

Күп җәфалар күрдең чит илләрдә,
Бик күп авырлыклар күтәрдең.
Куян кебек качып-посып җөрдең,
Авыр минутларны үткәрдең.

Беләм, җөрәк, шулай тибә-тибә,
Бер көн җиткәч типми башларсың.
Туйдым инде синнән, булды диеп,
Мәңгелеккә мине ташларсың.

**Нигә мин чит илдә?**

Нигә соң мин болай чит илләрдә?
Нигә соң мин хәсрәт эчендә?
Күзем йомсам, һаман күз алдымда
Туган илне күрәм төшемдә.

Илгә кайткан булам, дуслар белән
Сахра-болыннарны әйләнәм;
Баскан эзләремдә гөлләр үсә,
Җәннәт була бөтен әйләнәм.

Күбәләкләр оча, кошлар сайрый,
Матур урман, елга буенда.
Кулым артка куеп, җөреп торам
Яшел чирәм Идел буенда.

**Явыз тәкъдир**

Әй син, явыз тәкъдир, кара тәкъдир,
Нигә мине читкә ташладың?
Тычкан белән мәче уйнагандай,
Мыскыл итеп көлә башладың...

Тычкан баласы дип, әллә мине
Шуңар күрә көлеп уйныйсың?
Мескен Минһаҗ белән уйный-уйный,
Ничек инде бер дә туймыйсың?

Биеклеккә кайчак күтәрәсең,
Югарыдан атып ташлыйсың.
Һич тынычлык бирми газаплыйсың,
Тагын инде уйный башлыйсың.

Әллә яшьлегемдә үзем белми
Зур гөнаһлар эшләп җөрдемме?
Шул гөнаһлар өчен Тәңре каргап,

Җырак Алманиягә килдемме?..

Юк-юк, беркемгә мин зарар китермәдем,
Беркемне мин мыскыл итмәдем.
Начар кешеләр белән бергә атлап,
Начар юлдан да бит китмәдем.

Шулай булгач, тәкъдир, нигә мине
Җәһәннәмгә болай ташладың?
Тычкан белән мәче уйнагандай,
Көлә-көлә уйный башладың...

Тукта инде хәзер, күп уйнадың,
Бир тынычлык рәхәт торырга.
Башка кешеләр кебек мин дә хаклы
Матур итеп тормыш корырга.

*Алмания, Яңа Ульм шәһәре.*
*1960*

**Үгет**

Их, син, ахмак Минһаҗ, тиле Минһаҗ,
Хакыйкать дип чабып җөрисең.
Хакыйкатьнең безнең планетада
Булмаганын әллә белмисең...

Мөһаҗир булып ул, бәлки, күптән
Сатурнга күчеп киткәндер.
Ә кем белә, бәлки, ялган сугып,
Су төбенә батып киткәндер.

Хакыйкать маскасын кигән кешеләр
Тик алдарга гына җөриләр.
Аңсыз кешеләр аңар ышаналар,
Ялганлыгын аның белмиләр.

**Дустым шагыйрь Зыя Ярмәкигә**

Зыя дустым, еш-еш сине искә алам,
Әүлиялар тау буена көн дә барам.
Күрсәм әгәр син җырлаган ак каенны,
Исем китә, гүзәллеккә хәйран калам.

Картаймаган, ул һаман да шаулап тора,
Аның яны яшьләр белән тулы була.
Шул вакытта күз алдыма киләсең син,
Яшь чакларым үтте диеп күңлем тула.

Ак каеның һаман сине көтеп тора,
Сандугачлар, былбыллар да анда куна.
Искә алып син дустымны юксынганда,
Ак каенны барып күрсәм күңлем була.

Аны күрсәм, сине күргән кебек булам,
Бергә үткәргән яшь чакларны искә алам.
Үткән яшьлек күз алдына килеп баса,
Яшь әле мин, тагы анамнан кабат туам.

Күз алдыма килә Кукан[1] урамнары,

Маргиланның[2] чылтырап аккан су буйлары.
Күңел ачып, икәү бергә йөргән чаклар,
Ташлактагы[3] булып торган кыз туйлары.

Без бит икәү тыныч, дус яшәдек,
Ызгышуны, талашуны һич белмәдек.
Уйлап торсам, «валлаһи» дип исем китә,
Кай җирләргә барып икәү без кермәдек.

Алар үткән, хәзер инде кире килмәс,
Ул җирләрне инде Зыя таптап йөрмәс.
«Ак каен»ың мәңгелеккә килгән бит ул,
Шаулап торыр, нур чәчәр ул, мәңге үлмәс...

**Такташ**

Сау чагыңда сине күрә алмадым,
Сөйли алмадым сиңа сүземне.
Шигырьләреңне укып хәзер менә
Күргән төсле булам үзеңне.

Яу кырына мин киттем Тамбов аша,
Хәсрәтемне җилгә тараттым.
Син мактаган Тамбов урманнарын
Өзелеп сөйдем, бигрәк яраттым.
Бу җирләрдә уйнап син үскәнсең,
Монда үткән яшьлек елларың.
Усак яфраклары шаулаулары
Яңгыратканнар дәртле җырларың.

Мокамай — чын дустың, икегез дә
Бергә чабаталар үргәнсез.
Зурлар кебек кулны артка куеп,
Шул болынны иңләп җөргәнсез.

Шушы кырда ата казлар кыйнап,
Бәбкәләрен сөеп баккансыз.
Күрше карчыгының ак әтәчен
Пешерергә учак яккансыз.

Болар бары калган сөйләр өчен,
Күңелләрдән беркем куа алмас.
Шигырьләрең, Такташ, җөрәкләрдә
Сакланачак, һич тә югалмас.

**Җәләледдин Румый[1] кабере янында**

Шигъриятнең нурлар сипкән фонтанына,
Минһаҗ килде бит күрергә дип яныңа.
Нурлы Казан шәһәреннән сиңа, Румый,
Сәлам китерде сөйгән илең Коньяңа.

Җырак юлны якын итеп сиңа килдем,
Фирдәүси, Сәгъдиләрне[2] дә мин бит күрдем.
Нур чәчүче бөек шагыйрь, җырчыларны
Зиярәт итәм[3] дип, бик күп җирләрдә җөрдем.

Менә хәзер басып торам мин алдыңда,
Коньяның гүзәл серле ал таңында.

Карап җөрим син җөргән күп урыннарны,
Бөек йолдыз, син торасың күз алдымда.

Бу җирләрне син бит сөеп атлап җөргән,
Шигъриятнең сараена барып кергән.
Җәүһәр, якут кирпечләрдән салган сарай,
Мәңге яшәр, җимерелмәсен дә син белгән.

«Мәснәви»[1] — ул бит матур бөек сарай,
Диваннарың — нур чәчүче йолдыз һәм ай.
Синең белән мактанабыз бөек ата,
Шәрык иле синдәй йолдызларга бик бай.

Фәлсәфәдә Сократ, Платоннарны[2] уздың,
Поэзиянең тирән диңгезендә йөздең.
Син бит бөркет, син бит лачын поэзиядә,
Җырлый-җырлый, бөтен планетаны гиздең.

Диалектикага да син бит нигез салдың[3],
Фәлсәфәдә бик күпләрдән алда бардың.
Күп ел әүвәл яшәсәң дә Гегельләрдән,
Кояш нурын син алардан күбрәк алдың.

Җәләй ага[4], бертуктамый сине укыйм,
Шигырьләрең шундый матур — һич тә туймыйм.
Өйрәнәм мин синнән бик күп нәрсәләрне,
Китабыңны янда йөртәм, читкә куймыйм.

Шигырьләрең магнит кебек үзенә тарта,
Алар минем кулларымда чәчәк ата.
Күтәрелә күңелләрем аны укып,
Алар мине алга өнди, мине уята.

Күк йөзендә зур йолдызлар күп булса да,
Һәр көн алар яңарып, туып торса да.
Синең кебек якты түгел ул йолдызлар,
Зәңгәр күкне яктыртучылар булса да.

*Тәһран. 1968*

**Кордова хәлифәлегендә**

Кем уйлаган Минһаҗ Пиренэйгә килеп,
Мадрид урамнарын таптар дип.
Дон Кихотлар җөргән сукмаклардан
Гибралтарга кадәр атлар дип.

Хәят бит ул шулай, инсан белми
Кай җирләрне таптап җөрүен,
Кордовага килеп корбан булган
Мескен мәсҗедләрне күрүен.

Менә күз алдымда матур мәсҗед,
Кемнәр генә монда җөрмәгән!
Кемнәр генә, моны күрү өчен,
Җыраклардан кадәр килмәгән?!

Сез мескенне күреп күңлем тулды,
Яшь баладай кычкырып җыладым.
Зинһар, Раббым, шушы әсирләрне
Азат итче диеп теләдем.

*Испания. 1968*

**Иран халкына сәлам**

Сәлам язам сезгә, Иран халкы,
Сәлам язам җырак Уралдан.
Сагынып сөйлим, һаман мактыйм сезне
Милләтегез уңган, булганнан.

Сездә туган даһи Фирдәүси,
Сездә туган Гомәр Хәйямнар.
Рудәкиләр, Сәгъди, Дакикилар —
Сезнең иранлардан туганнар.

Заманында сезнең Иран халкы
Бөек титаннарны биргән ул.
Даһи Хафиз, тагы бик күп кешеләр
Сезнең иранлардан килгән ул.

Габу Гали Сина — фән патшасы,
Якты йолдыз Иран илендә.
Фән дөньясы аны һич онытмый,
Исеме җөри халык телендә.

Галимнәрне сөям шуңа күрә,
Сезнең исем белән мактанам.
Искә алсам әгәр сез йолдызны,
Яшь баладай үзем шатланам.

Фирдәүси исә миңа патша була,
Сәгъди сибә миңа ак нурын.
Укыганда сезнең шагыйрьләрне,
Яктыра бара алдагы юлым.

**Җырлыйм әле**

Нигә соң мин чәчкә яшьлегемне
Сандугачтай сайрап үткәрмим?
Боеккан кош кебек боегып торган
Яшь күңелне җырлап күтәрмим?

Җырлыйм әле сөйгән җырларымны,
Эфирларга очып китсеннәр.
Җилләр белән очып, җырактагы
Сөйгән кызларыма җитсеннәр.

Ишетсәләр моңсу авазымны,
Минһаҗ җырлый диеп тыңларлар.
Искә алып үткән яшьлек көнен,
Мине сагынып каршы җырларлар.

Искә алырлар минем гармун белән
Урам буйлап җырлап килгәнне.
Сузып-сузып матур озын көйгә
Дуслар белән җырлап җөргәнне.

Их, искә төшә авыл урамнары,
Искә төшә елга буйлары.

Нинди матур иде яз башында
Була торган Сабантуйлары!

Сузып-сузып җырлыйм озын көйне,
Искә алып Идел буйларын.
Язып тормыйм барсын ачык итеп,
Китәр җыракка дип уйларым.

Мин җырларга туган халкым өчен,
Бабайларның дәртле җырларын.
Горурланып, мактап Ватанымның
Урманнарын, болын-кырларын.

### Илебезнең киләчәге

Кара көннәр үтеп, татар халкы
Рәхәт яшәр әле тагы да.
Җырак түгел, дуслар, без яшибез
Милли азатлыкның таңында.

Тиздән инде милли кояш чыгар,
Матурланыр Урал буйлары.
Йоклый алмыйм, дуслар, изә мине
Милли азатлыкның булмавы.

Күз алдыма килә Чыңгыз ханнар,
Күз алдыма килә Батыйлар.
Идел буйларында тиздән инде
Бәхет чәчәкләре атарлар.

Дошман баскан пычрак кара эзләрне
Җыракларга себереп түгәрбез.
Кайгы-хәсрәт, кара минутларны
Тиздән инде таптап күмәрбез.

Илебезгә якты нурын чәчәр
Зөһрә йолдыз — Казан каласы.
Хуҗа булыр тагы үз иленә
Изелеп килгән татар баласы.

**ХӘСӘН ХӘМИДУЛЛА**

*(1900—1988)*

**«Бигрәк тә татар җанлы кеше иде...»**

*(Хәсән Хәмидулла һәм аның тарих китабы)*

Миңа Кытай, Япуния, Финляндия, Германия, Төркия һәм кайбер башка чит мәмләкәтләрдә татарча чыккан кайбер гәҗит-журналлар, китаплар белән танышырга туры килде. Аларга хас сыйфатларның иң мөһимнәре — татар халкын, аның телен, моңын ярату, туган җирне сагыну, татарны алдынгы, ирекле һәм мул тормышлы итеп күрергә омтылу.

Хәсән ага Хәмидулла да — гомере буе туган җирен сагынып, туган халкы өчен җан атып яшәгән шәхесләрнең берсе. «Бигрәк тә игелекле, татар җанлы кеше иде...» — дип искә ала аны Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез. «Вөҗдан» исемле шигырендә әдип болай ди:

«Мөнафикъ (икейөзле.— *Х. М.*) син — яшерсәң милләтең,
дин вә аслыңны,
Татарлык, мөселманлыкны, һәм дә ятларга нәселеңне.
Оялсаң үз телең берлән сөйләргә ятлар алдында,
Төшәрсең аска, кимсенсәң гадәт-гөрфаннарыңнан (биредә:
«йолаларыңнан» мәгънәсендә.— *Х. М.*),
Димәк, иман зәгыйфь синдә, каның керле, тынычсыз җан,
Ничек гадел эш кылырсың, борчыганда бозык вөҗдан?!

Хәсән Низамеддин угылы Хәмидулла хәзерге Нижгар өлкәсе Кызыл Октябрь районы Актук авылында (ул Сергачтан 20 чакрымнар ераклыкта урнашкан) дөньяга килә. Биредәге Гарифулла мулла мәктәбендә белем ала. Язмыш 15 яшьлек Хәсәнне 1915 елда Финляндиягә илтеп ташлый.

Мәгълүм булганча, рус-швед сугышы нәтиҗәсендә 1809 елда Финляндия Россия империясе составына кертелә. Шуннан соң анда татар гаскәриләре һәм алыпсатарлары күренә башлый. XX гасыр башларында инде Финляндиядәге татарларның саны ярты меңнән артып китә. Алар Тирйоки, Виипури (Выборг), Хельсинки, Тампере һәм башка калаларда яшиләр.

1917 елда Финляндия бәйсезлек алуга ирешә. Төрле кыенлыклар, гаделсез сугышлар булуга карамастан, 4 миллионга якын гына халкы булган бу мәмләкәт хәзер дөньяның иң алдынгы илләреннән берсе исәпләнә. Җан башына табыш алу ягыннан ул дөньяда алдынгы урыннарда тора. Еш кына аны «Төньяк Япуния» дип тә йөртәләр.

Инкыйлабтан соңгы берничә елда кайбер татарларның Финляндиягә күчеп, нигездә, качып килүе мәгълүм. 20—50 нче елларда инде ике арадагы багланышлар бөтенләй диярлек бетә. Әмма Суоми илендә яшәгән меңләп татар югалып калмый: үзләренең гореф-гадәтләрен, телләрен саклыйлар, фин, швед, немец, инглиз, төрек һәм кайбер башка телләрне өйрәнәләр, укыйлар, эшлиләр, гәҗит-журналлар, китаплар бастыралар. Биредәге татарларның күпчелеге сәүдә эше белән шөгыльләнә. Хәзер дә Хельсинки, Тампере, Турку кебек калалардагы зур гына мех, келәм, тукыма кибетләре алар кулында. Араларында дистәләгән телне белгән эшмәкәрләр, гыйлем ияләре дә бар.

Хәсән аганың бабасы Хәмидулла (1836—1894) сәүдә эшләре белән XIX гасырның 60 нчы елларында ук Финляндиягә барып чыга. Нигездә, Виипури каласында яши. Әмма Актук белән дә араны өзми, чөнки биредә аның кайбер балалары яши. Хәсәннең әтисе Низамеддин ага (1862—1940), инкыйлаб алды елларында булса кирәк, Финляндиягә тәмам күчеп килә. Хәсән ага Хәмидулла озак еллар буе Хельсинкидан 860 чакрым төньякта урнашкан Кими каласында яши, сәүдә эше белән шөгыльләнә. Әүвәл йорттан йортка, бер төбәктән икенче төбәккә йөреп сату итсә, бераздан үзенең махсус кибетен ача. 1926—1927 елларда Төркиядә дә яшәп ала. Берлинда нәшер ителүче «Милли юл» журналының 1929 елгы берничә санында (9, 10...) аның «Совет Россиясендә кунакта» исемле сәяхәтнамәсе басылган. Бу язмадан Хәсән ага Хәмидулланың 20 нче еллар азагында Ленинградка сәүдә эшләре белән барып чыгуы аңлашыла.

1950 елның гыйнвар аенда Хәсән ага үзенең гаиләсе белән Кимидан Хельсинкига күчеп килә. 1988 елның 6 ноябрендә шунда ук вафат та була. Бер улы — Гомәр әфәнде (1928 елгы) кибеттә, икенчесе — Хөсәен әфәнде (1955 елгы) Хельсинкидагы «Ислам җәмгыяте»ндә эшли. Кызлары да Суоми башкаласында гомер кичерәләр. Хатыны — Өммегөлсем (чыгышы белән Пенза ягындагы «Лановка» татары) 1986 елда вафат була.

Хәсән ага Хәмидулла (ул еш кына үзен Кулик кушаматы белән дә йөртә), туган теленнән тыш, финча, шведча, гарәпчә, урысча, төрекчә яхшы белә. (Мөгаен, ул инженер белгечлеге дә алгандыр. Аны кайвакыт «мөһәндис» дип тә йөртәләр.) Ике мәртәбә хаҗга бара, төрле илләргә сәяхәтләр кыла. Ул туры сүзле, җор телле, ачык табигатьле кеше була. Бик күптөрле һөнәр белә. Аның агачтан, металлдан төрле әйберләр ясавы мәгълүм. Шәмаилләр дә, рәсемнәр дә ясый. Кыскасы, Каюм Насыйри тибындагы кеше була.

Хәсән ага Хәмидулла гомере буе әдәбиятка, фәнгә, сәнгатькә җаны-тәне белән бирелеп яши. Аның язып бастырган китаплары гына да иллегә якын [«Илһам йимешләре», «Ватансызлык», «Йөрәк ялкынлары», «Моңлы таңлар», «Хәерниса» (4 пәрдәле драма), «Өзелгән өмид», «Борынгы картлар сүзе», «Телләр тарихы», «Ник алай?», «Йолдызларга сәяхәт» һ. б.]. Болар арасында поэмалар, драма әсәрләре, романнар, фольклор җыентыклары, гыйльми, публицистик, автобиографик язмалар, лирик шигырьләр һ. б. бар.

Шунысы гыйбрәтле: Хәсән ага Хәмидулла китап язу белән генә чикләнми, ул аларны үзе үк редакцияли, үзе үк бастыра да (әүвәл гарәп хәрефләрендә, соңга таба латин белән аралаштырып). Бернинди гонорар да, ярдәм дә

алмый. Миңа, кызганычка каршы, Хәсән аганың үзен күрергә насыйп булмады. Әмма мин аның үзе төзегән йортында булдым. Диңгез култыгы янында диярлек урнашкан бу зур гына ике катлы йорт миңа матбага музееи хәтерләтте. Анда китап басу станоклары, язу машинкалары, төрле хәрефләр, гаҗәеп күп санлы китаплар, сызымнар, рәсемнәр... Боларның бит һәммәсен Хәсән ага үзе булдырган! Язган, баскан китапларын ул үзе төпләп, еш кына милләттәшләре арасында бушка үзе үк өләшеп тә йөргән. Бу — чын мәгънәсендә фидакярлек, милләтпәрвәрлек!

Хәсән ага Хәмидулла 1943 елда, Скандинавия дөньясында беренчеләрдән булып, гарәпчә Коръәнне бастыра (20 мең данә) һәм аны мөселман әсирләре арасында бушка тарата да. «Яңа иман шарты һәм белемлекләр» исемле китабының да алты меңе төрки-татар әсирләренә «һәдия кылына».

Хәсән ага Хәмидулла — Суомида беренче татар гәҗитен чыгаручы да. 1925 елның 16 гыйнварында ул Кими каласында «Мәгърифәт» исемле гәҗит бастыруга керешә. «Сәяси, милли вә әдәби» характердагы бу атналык гәҗит, 12 саны чыккач, шул ук елның 17 апрелендә ябыла. Сәбәбе: абунәчеләрнең (подписчикларның) азлыгы һәм татар телен белүче «синзурның» булмавы.

Хәсән ага Хәмидулла 1943 елда «Шималь очкынлары» исемле журнал чыгара башлый. Бу басма 1977 елга кадәр төрле вакыт аралыгын саклап чыгып килә һәм милләтне әхлакый, милли, дини һәм эстетик яктан тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Финляндиядә яшәүче татарларның асыл Ватаны — Нижгар төбәге. Күпчелеге — Актук авылыннан. Кайберләре шуның янәшәсендәге Куйсуы, Чүмбәләй, Уразавылдан. Сергач якларында туганнар инде хәзер өлкән буын арасында да бик аз (Гомәр ага Таһир, Хәйдәр ага һ. б.). Әмма шуңа да карамастан Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез асыл Ватаннары белән нык кызыксыналар, аның тарихыннан да шактый хәбәрдарлар. Тарихи хәтернең саклануын, буыннан буынга күчүен тәэмин итүдә дә Хәсән ага Хәмидулланың хезмәте ифрат зур. Аның әсәрләрендә туган ягы, аның табигате, кешеләре, гореф-гадәтләре шактый тулы гәүдәләнеш таба. Әмма ул болар белән генә чикләнми, «Яңапар (Актук авылының элеккеге исеме.— *Х. М.*) тарихы» исемле махсус хезмәт тә яза. Аның аерым өлешләре «Шималь очкынлары» журналында нәшер ителә. 1954 елда ул Хельсинкида гарәп хәрефләре белән аерым китап рәвешендә дөнья күрә.

«Яңапар тарихы» — уртача форматлы, 82 битлек китап. Анда фоторәсемнәр (Хәсән аганың үзенеке, әти-әнисенеке, мөгаллимә Рәйханә Җәмаледдин, Зиннәтулла Әхсән Бүре, Садрый Хәмид һәм башкаларның сурәтләре), Актук авылының сызымы, аерым күренешләре, кайбер документларның күчермәләре, авылга нигез салган Актук бабай нәселенең шәҗәрәсе, шигъри үрнәкләр һ. б. бар. Китап авторның туган ягы хакындагы шигыре белән ачылып китә.

...Онытмыйм ул дәверләрне, илемне һәм инешләрне,
Җанымны да бирер идем, күрәлсәм ул күршеләрне...

Китапның ахырында автор үзе чыгарган китапларның исемлеген дә урнаштырган.

«Яңапар тарихы» — үзенең төзелеше һәм эчтәлеге белән тарихи-этнографик характердагы хезмәт. Анда авылның табигате, тарихы, яшәү рәвеше, көнкүреше, тарихи ядкярләре, «мәктәп вә укыту эшләре», «каләм ияләре», идарәчелек, аерым күренекле кешеләрнең язмышы һәм кайбер башка мәсьәләләр махсус рәвештә бәйнә-бәйнә карала. Хронологик яктан хезмәт 1667—1919 елларны үз эченә ала.

Автор нинди чыганаклардан, материаллардан файдаланган соң? Китапның тәүге өлешендә мондый юллар бар: «Финляндиядә вакыты илә иң картларымыздан саналган мәрхүм Хисамеддин Хәмидулланың үз дәфтәрендән файдаланып, аның хатыны Хәдичәдән һәм Хисамеддиннең карт борадәре Низамеддин Хәмидулла вә аның хатыны Мәдинәләрдән истифадә иделде (файдаланылды.— *Х. М.*)».

Хисамеддин (ул 1864 елда туган) — Хәсәннең әтисе Низамеддиннең бертуганы. Боларның икесе дә,— шактый гына укымышлы булып, Финляндиягә XIX гасырда ук барып чыккан кешеләр. Хисамеддин Хәмидулланың «Яңапар тарихы»на кагылышлы язмасы («дәфтәре») булган. Димәк, китап авторы аны үз хезмәте өчен нигез итеп алган. Моннан тыш, ул күп кенә кешеләрдән, аеруча өлкәннәрдән, мәгълүматлар туплавын искәртә. Шулай ук Хәсән ага төрле язма документларны, үзенең шәхси күзаллауларын да китапта файдалана. Дусты, якташы Садрый Хәмид тә аңа булышлык күрсәтә: рәсемнәр ясаша, сызымнар сыза. Кыскасы, автор бу китабы өстендә шактый озак һәм җентекле эшли. Бу «мөкатдәс эшнең» ничек барышы хакында ул болай яза: «Тизлекдә чыгару нияте белән башланган бу әсәремнең эченә керә барган саен, бик күп читенлекләр һәм бер-берләрен мәху итә (бетерә.— *Х. М.*) торган төрле-төрле мәсьәләләр чыга торып, шуларны тикшерүләр һәм, шуларның хакыйкатенә төшәр өчен, янә картларымызга мөрәҗәгать ителүләр, шуның өстенә әле дә Финляндиядәге балакайларымызга да ата-аналарының сөекле туган илләре булган Яңапардан бераз мәгълүмат кеби нәрсәләр бирүгә тырышулар да минем кул-аягымны, эшемне һәм гакылымны бәйләп алдылар...

Шулвакыт мин үземнең башланган бу эшемнең, чыннан да, шулкадәр мөкатдәс вә шулкадәр бөек бер эш икәнчелеген аңлап алып хәйрәт итдем (таң калдым.— *Х. М.*). Бу бөек 300 еллык мөһим бер вазыйфаны үтәүдә Алланың миңа ышануыннан һәм Алланың, чыннан да, миңа гына насыйп итүендән шашып калып, шадлыгымдан йөрәк майларым да эрегән һәм күз яшьләремнең дә бөртек-бөртек тамчылары шушы тарих сәхифәләренә тамган заманлары булды» (79 б.).

Хәсән ага Хәмидулла Актук һәм аның тирәсендәге кайбер авылларның тарихын 1667 елдан башлап китә, Яңапарга нигез салган Актук бабайның Төмән ягыннан килү ихтималлыгын да искәртә. Әмма бу һич кенә дә Нижгар татарларының бередә төп халык булуын, аларның бу якларда бик күптәннән яшәвен шик астына алырга тиеш түгел. Мәшһүр В. Н. Татищев фикеренчә, Түбән Новгород XII йөздә болгар-татар шәһәре Ибраһим каласы урынында төзелә. Бу факт үзе генә дә Нижгар татарларының озын тарихлы булуын күрсәтеп тора. Ә инде

гасырлар дәвамында аерым үзгәрешләрнең, төрле күчешләрнең, керешүләрнең булып торуы — тарихи яктан табигый күренеш.

«Яңапар тарихы»нда кызыклы, мөһим мәгълүматлар бар. 1920 елда Актук авылында 580 йорт, 3000 ләп кеше була. Аларның 500 сыер, 1500 сарык, 500 ат асравы мәгълүм (48 б.). Совет чорында бу авыл шулкадәр «үсә» ки, анда хәзер 100 дән артыграк кына өй бар. Инкыйлабка кадәр Актукта 4 мәктәп булуы билгеле. Хәзер исә тулы булмаган бер урта мәктәп, анысында да 20 ләп кенә бала укый.

Актук авылы элек-электән үзенең җил тегерменнәре («милчәләре») белән мәшһүр була. Алар бередә XIX гасыр башында ук корыла башлый. Инкыйлаб алды елларында аларның саны 15 кә җитә. Араларында 38 әр ат куәтле тегерменнәр дә була. Шушы ук елларда 4 «крупчатка» да корыла. Хәзер исә бу якларда җил тегерменнәре барлыгын юньләп белмиләр дә. Актук халкы, иген игү һәм хайван асрау белән беррәттән, башка һөнәрләр белән дә шөгыльләнә. Биредә тимерчеләрнең, көмешче, башмакчы, умартачы, тегүче һәм башка һөнәр ияләренең булуы мәгълүм. Мәсәлән, Фәтхулла исемле кеше 50 баш умарта тоткан. XIX гасырда сәүдә эше белән төрле төбәкләргә йөрү көчәя. Актуктан ерак булмаган Мәдәнә тавында атаклы ярминкә булган. Әмма ул 1840 елда ябыла. Шунысы мөһим: хәзер Мәдәнә авылында атаклы мәчет-мәдрәсә комплексы төзелде. Үзенең мәһабәт рәвеше белән Сәмәрканд, Истанбул корылмаларын хәтерләткән бу бина якын киләчәктә мөселман дөньясының төньяк үзәге булырга мөмкин. Бәлкем, Мәдәнә ярминкәсе дә ачылып, элеккеге традицияләр яңарыр.

Китапның мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр, укымышлылар хакындагы бүлекчәләре аеруча кызыклы. Актукта укый-яза белү шактый әйбәт торган. Биредә «укый белмәгән хатын-кызлар бик сирәк иде» ди автор. Авылның Мулай угылы Ризван исемле кешесе китаплар язып бастыра торган була. Ул 1847 елда Петербургта «Рисаләи Газизә» китабының да беренче басмасын нәшер итә. Биредә Габделкоддус Якъкуб угылы диган билгеле педагог, журналист та эшләп китә.

Китапның янә бер мөһим ягы шунда: автор, Актук төбәгенә мөнәсәбәттә, Финляндия татарларының тарихын, мәдәниятен дә билгеле бер дәрәҗәдә яктырта. Бу бигрәк тә «Яңапардан чыккан каләм ияләре» бүлекчәсендә ачык күренә.

30—40 нчы елларда Финляндия татарлары арасында төрекчелек юнәлеше көчәеп китә. Төрек теле, латинча язу, төрек мәдәнияте кыйбла итеп алына. Хәсән ага Хәмидулла бу хакта да мәгълүмат бирә һәм бу юнәлешнең бер вәкиле булган Зиннәтулла Әхсән Бүре турында да яза. Бу кеше 1886 елның 20 мартында Актукта туа, белем ала. Аннан Суомига күчеп китә. 1916—1920 елларда Тирйокида муллалык вазифасын да башкара. Аннан Тампереда яши. 1945 елның 9 ноябрендә вафат була. Сәүдә эшләреннән тыш, Зиннәтулла Әхсән Бүре берничә китап та бастыра. 1934 еллар тирәсендә ул латин хәрефләре белән «Туран» исемле гәҗит чыгара башлый. Әмма бу басма өч саны чыгу белән туктый. Зиннәтулла Әхсән Бүренең олуг бер хезмәте — фин теленә Коръәнне тәрҗемә итеп 60 мең данә белән бастыру.

Яңапарга мөнәсәбәтле икенче бер каләм әһеле — Бәдреддин угылы Садреддин, ягъни Садрый Хәмид (11.10.1905—14.12.1987). Ул — күп санлы шигъри әсәрләр авторы. «Үз тормышын яхшы гына сәүдәгәрлеге аркасында алга алып барган бу Яңапар шагыйренең,— ди Хәсән ага Хәмидулла,— башка бөек тойгылары булган рәссамчылык, филадисычылык (филателия.— *Х. М.*) вә музачылык (музыкачылык.— *Х. М.*) дәрдләре дә бик көчле булганга, Яңапарның йөзенә бу мөхтәрәм зат аркылы кызыллык килмәве мөхәкъкак (дөрес.— *Х. М.*) вә шөбһәсездер» (67 б.). Хезмәттә «торагаш»лар (таш сыннар), аларның тарихи әһәмиятләре, экология, табигый афәтләр хакында да фикерләр бар. Мәсәлән, 1837 елда Актук авылы бөтенләй диярлек янып бетә. 1877 елда «Яңапар кырын һәм бөтен күрше авыл кырларын бик көчле боз суга» (46 б.).

Бу китап — Сергач диалектын һәм аңа мөнәсәбәтле Финляндия татарларының телен, кеше исемнәрен, кушаматларын һәм топонимнарын өйрәнүдә дә мөһим чыганак (милчә — тегермән, иш(ет)меш — имеш-мимеш, киндераш — киндер, яз ката — яз буенча, мурта — умарта, ягага — читкә, алаша — ат, чырылдак — гөрләвек һ. б.).

«Яңапар тарихы» — Актук халкы яисә Финляндия татарлары өчен генә түгел, ә гомумән татар тарихы өчен дә игътибарга лаек хезмәт. Анда кызыклы факт-мәгълүматлар, легенда-риваятьләр, гыйбрәтле фикерләр шактый. Бу китап халкыбызның тарихи хәтерен яңартуда, аның үзаңын үстерүдә, туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә, үзенә охшаш хезмәтләр тудыруда мөһим фактор, чыганак була ала. Кызганыч ки, бу хезмәт фән ияләренә генә түгел, әдипнең якташларына да билгесез булса кирәк. Миңа 1992 елның февраль аенда Нижгар ягында булырга һәм Сергач төбәгенең, шул исәптән Актук авылының берничә кешесе белән очрашып сөйләшергә туры килде. Алар бу китап хакында хәбәрдар түгеллекләрен әйттеләр.

Хезмәтнең «Гыйлавә» (өстәмә.— *Х. М.*) өлешендә мондый юллар бар: «Яңапарның кочагында—гүрдә яткан анам, туганнарым, кардәш вә әби-бабаларымның хөрмәтенә, шулай ук шул мөкатдәс авылның икмәге, суы берлән ризыкланган вә аның җылы тәрбиясе белән буйга йитеп кеше булган минем үземнең дә Яңапарга булган бөек бурычларымызны үтәү өмидендә дөньяга туган бу әсәрем бөтен кимчелекләре берлән Яңапарга миндән һәдиядер (бүләктер.— *Х. М.*)».

Тыныч йокла, хөрмәтле Хәсән ага, изге сүзләрең, һәдияң, бераз соңгарак калып булса да, Ватаныңа, якташларыңа, бүгенге һәм киләчәк буыннарга ирешә һәм ирешер!

* * *

Мин «Яңапар тарихы»н тулысынча хәзерге графикага күчереп чыктым. Иллюстратив материалларның кыскача эчтәлеге аңлатылды. Укучыларга авыр аңлаешлы сүзләргә аңлатмалар җәяләр эчендә күрсәтелде. Аерым искәрмәләрне ахырда бирүне кулай дип таптык.

Авторның язу рәвеше, стиле, орфографиясе, нигездә, үзгәрешсез калдырылды. Әйткәнебезчә, автор үз әсәрләрен үзе бастырып тараткан. Бернинди редактор да, корректор да аларны күздән кичермәгән. Китаптагы аерым стиль кытыршылыклары, механик хаталар шуның белән аңлатыла. Авторның озак еллар татарның төп мәдәни төбәгеннән читтә яшәвен дә онытырга ярамый. Китапның битләр саны җәяләр эчендә күрсәтелде.

Хезмәтне хәзерге графикада аерым китап рәвешендә чыгарырга иде дә бит. Әмма, кызганычка каршы, хәзергә андый мөмкинлекләр күренми.

*1992*

***Хәсән Хәмидулла әсәрләре***

## Яңапар тарихы*

Көләм, сагынам да яшь чакны, тула кәйфем-сафалар да,
Шуның берлән куанам, күп вакыт күрсәм казалар да.

Сабый чак ул—минем бәхтем, исәплим дә,— көләм, еглыйм,
Бөтен нигезем корылгандыр — фәкать шундан диеп уйлыйм.

Онытмыйм ул дәверләрне, илемне һәм инешләрне,
Җанымны да бирер идем, күрәлсәм ул күршеләрне.

Исемдә уйнаганнар һәм көрәшкәннәр, талашканнар,
Җыйнаулашып кыр, инешләргә буа буып маташканнар.

Гулап торган күгәрченнәр, каралган карга, чәүкәләр,
Чикерткәләре, карлугачлары — бар да исемдәләр...

Исемдә әниемнең шад йөзе берлән мине җуатканы,
Сыйпап йомшак кулы берлән минем өчен җан атканы.

Исемдә кыр-болыннар һәм тирән елга, биек таулар.
Кызау, капкан белән кайчак күгәрченнәр идем аулар.

Китә идем чиләк белән җыярга йир җиләкләрне,
Ура идем билем агыртса да кыстырып беләкләрне.

Урак берлән кисә идем йә тырнакны, йә учларны,
Ташыйм көлтә өчәрләп, күрсәтим дип миндә көч барны...[1]

*Финляндиядә вакыты илә иң картларымыздан саналган мәрхүм Хисамеддин Хәмидулланың үз дәфтәрендән файдаланып, аның хатыны Хәдичәдән[2] һәм Хисамеддиннең карт борадәре[3] Низамеддин Хәмидулла вә аның хатыны Мәдинәләрдән истифадә иделде (файдаланылды.— Х. М.).*

### 1

Русиянең Нижний вилаятендә — Мәскәү белән Казан тимер юлы арасындагы Сергач эстанчасындан (станциясеннән.— *Х. М.*) егерме чакрым көньякка таба эчкә кереп корылган Яңапар (Актук) авылы Сергач өязенә һәм саналып, Нижний вилаятенең дә һәм Сергач өязенең дә Сембер вилаятенә каршы булган ходудындадыр (чигендә.— *Х. М.*) һәм соңгы авылыдыр.

Бу тигезлеге һәм берничә биек таглары белән мәшһүр булган Яңапар авылы төньяк ягындан Уразавыл, көнбатыш ягындан Кызылъяр, Өчкүл, көнчыгыш ягындан Кадемавыл һәм Сембер вилаятенең ходуды булган[4] Эрбитшә вә аны уза төшеп көньяк Чүмбәли, Мәдәнә, Суксу авыллары белән уртага алынып, аның бигрәк тә күрше авыллары белән күбрәк бәйләнеше булган һәм кыз алып, кыз бирешү кеби кода-кодагыйлыклар да көчлерәк рәвешендә дәвам итеп, шул авылларга бик күп нәсел дә тараткан.

Бу тораташы (сыны, изге ташы.— *Х. М.*) белән, мәшһүр әүлия кабере Текмәли бабай һәм Әйтүли (?— *Х. М.*) милчәләре (тегермәннәре.— *Х. М.*) вә галим-муллалары белән бөтен тирә-якларга мәшһүр булган Яңапар авылы, үз гомерендә башындан бик күп вакыйгалар һәм һәлакәтләр кичереп килсә дә, халыкның тырышлыгы белән, ягага (читкә.— *Х. М.*) киткән сәүдәгәрләрнең дә бәхетлерәк булганлыклары белән һаман өсткә чыгып, һаман да һаман үсеп, тазарып, күрше авыллардан артка калырлык түгел, бәлки дә алардан өстенрәк булырга көч (4) куйган вә шуңар шактый гына муафыйк да булган.

Яңапарның иске урыны булган Пар буендан, ягъни су янындан коры һәм тирән ярлы сусыз бер йиргә күчеп утыруы, бер яктан караганда, әлбәттә, кырларының зурлыгы һәм яраклыгы роль уйнаган булса да, дөрестән уйлаганда — Актук бабай авылын күчерү белән ул вакытта бер дә яңлышмаган. Чөнки ул вакыт Яңапарның урынында шактый гына тирән ике күл булу өстенә, әлеге сусыз тирән елгалары да шаулап агып торган дәвердә булганлар.

Тора-бара бу күлләр, ягъни Мортаза буасы, Хуҗа күле диеп йөретелгән әлеге күл урыннары кибә барып, елгалары да корып бетә барганлар. Хәзер исә яз башларында гына ул элеккеге хәлен алып, җәйләр(ен) чырылдак (гөрләвек.— *Х. М.*) кебек кенә агуларында дәвам итмәкдәдерләр. Яңапарның башка авыллар белән мактанырлык бер нәрсәсе булса, ул да — кырының якынлыгыдыр5.

[Китапның 5 нче битендә Яңапарның әтрафындан «хыялый хәритә», ягъни карта бирелгән. Анда Суксу, Мәдәнә, Яндавитше, Өчкүл, Уразавыл һәм тирә-юньдәге кайбер башка татар авыллары теркәлгән. Үзәктә — Яңапар һәм аның географик атамалары: Ишмәт тавы, Керәшеннәр кабере, Торataш, «Эстип» һ. б.— *Х. М.*]

(6) Аның кырының бер очы Кадәм авылыннан тотынып, Мәдәнәгә кадәрле озайган (сузылган.— *Х. М.*) булганга, кырын ераксынып тәхминән (чама белән, якынча.— *Х. М.*) 1080 елларда (хәзерге ел исәбе белән 1669/1670 елларга туры килә) Актук бабай иске урыны булган Пар буендагы Актук авылын әлеге урынга күчереп матди вә икътисади җәһәтләрен генә түгел, җитезлек һәм җиңеллек якларын да рәткә куйган. Тора-бара бу авылга һәм Актук авылы да, һәм Яңа кушымта исеме белән Яңапар авылы да диеп исем биргәннәр.

Яңапарның әлеге урыны, мәгаттәәссеф (үкенечкә каршы, кызганыч ки.— *Х. М.*), бик күп еллардан соң күлләре вә акар елгалары кибеп, сусыз коры йир булып калса да, йире кара туфрак һәм тауларының да урмансыз ялангач булуы сәбәпле, иген чәчәр өчен һаман да уңайлы һәм бәрәкәтледер.

Яңапарны көнчыгыш ягындан чорнап алган Мар, Суык кизләү, Тугай, Ишмәт, Эрбитшә, Бүктау, Урта каен, Чагыл (?), Иске тау төркемләре үз нәүбәтендә авылга һич ышана алмаслык ямь керткәннәре кебек, кыйбла һәм көнбатыш тарафларының да тигезлеге хәйран калырлык гүзәл бер манзарадыр (күренештер). Аның тау битләре, тигез чирәмле елга буйлары агызда эрерлек татлы җиләк вә гүзәл чәчәкләр йитештергәне кебек, тауларыннан чыккан тозлы вә шифалы сулары да һәм салкын кизләүләре дә — хайваннар өчен дә һәм авыл халкы өчен дә акчага сатып ала алмаслык бөек бер хәзинәдер (7).

Заманында мәһабәт сурәтендә зәңгәр төсе белән ялтырап торган Мортаза буасында әле дә алтмыш еллар гына мондан элек атлар юындырып, йебләр буяп, каз-үрдәкләрнең хахылдаган тавышларындан төнләр буе туеп бетү өстенә, әле дә күпме шунда батып үлүчеләр (иң соңгы ике малай батды) булып торгаласа да, хәзер ул 1900 еллардан бирле бөтенләй кибеп, урынында Ваһаб мулланың өе, мәктәбе һәм Беренче дөнья сугышыннан соң салынган кызлар һөнәр мәктәбе каһарманлык сөрә. Шулай ук Йосыф Җәмалиның (Гыймад Җәмал) йортының да күбрәк өлеше шул элеккеге күл өстендәдер.

Күлдән агып торган суның ерындылары бүген дә әле Җәмал йорты белән кызлар мәктәбе арасында бар булып, бара-бара Юныс күпере тугрысында куркынычлы биек, тирән яр хәленә керәдер. Бу тугрыда салынган Юныс күперенең (чын исеме Кәйбулла күпере) бу кадәр биек һәм тирән ярга салынуы күпердән үткән кешеләрнең калебләрен (күңелләрен, йөрәкләрен.— *Х. М.*) җәлеп итү генә түгел, шашарлык бер манзарадыр.

Яңа урам яхуд «Югары оч» диеп аталган һәм, чыннан да, XVIII гасырдан башлап кына төзелә башлаган бу урамның урта бер йирендәрәк булган Мортаза буасыннан югары очка таба менеп Кара Газиз белән башмакчы Җамак һәм (8) Бадаслар йортындагы Хуҗа күле дә заманында мәһабәт сөргәне кебек, мондан әле дә 80 еллар гына элекдә Газиз белән Җамак арасында салынган тар басма үтәли йөрергә мәҗбүр булынган. Хәзер исә анда күлдән калган эзләр вә әсәрләр көндән-көнгә югала барадыр.

Бу күлнең булган урыны күл өчен бик уңгайлы йирдә булганга, бик иске заманларда монда шактый гына зур күл булырга да юлы бар. Чөнки күлнең кыйбла тарафы югары очында шактый гына кашлы (камышлы? — *Х. М.*) булу өстенә, түбән ягында берсәк (бераз.— *Х. М.*), өстдәрәк булып, күлнең көнчыгыш ягы Кулик (Колын? — *Х. М.*) Гыйлавы йорты үтәли ындырларга кадәрле дә озаерга мөмкин. Әгәр дә бик иске заманда Яңапарның Чүмбәлигә таба Чокын очындагы хәзерге печәнлек йире булган Сары саз күле авылның иң зур күлләрендән саналган булса, Хуҗа күле дә,— шөбһәсез, икенчеседер.

Яңапарда тагын кечкенә генә, вак-вак кына күлләр булуы картлар агызыннан ишетелгәләсә дә, авылның төньягында каберләр каршында өстке Уразавыл юлы белән асткы Уразавыл юлы арасындагы Сәүбән күленең бар булуы мөхәкъкакдыр (хактыр, дөрестер.— *Х. М.*) һәм булмыштыр. Бу күлнең кибүе дә XIX гасыр эчләрендә генә булып, мондан 75 еллар элек кенә ул күлдә халыкның пәзиләр (киндер.— *Х. М.*) батыруларын картлар бик яхшы беләләр (9).

XX гасырның башларында бу урында Сәүбәннең богыллары (көлтә кибәннәре.— *Х. М.*) иде. Мондан шул аңлашыла ки, бу күлнең исеме соңгы заманларда гына Сәүбәннең үз исеме бирелгән исем булып, элеккеге чын исеме мәгълүм түгел.

Шулай да Хуҗа күле дә әлеге заманның Хуҗа йортында булу сәбәпле, аның исеме берлән бирелгән ялган исем булып, Мортаза күленең дә хакыйкый, чын вә тарихи исеме мәгълүм түгелдер.

Яңапарның урта бер йирендә Урталык урамы исеме белән йөретелгән урамының Кызыл мәсҗед турылары һәм бигрәк тә урамның ары ягындагы Мөхаджан бабай йортлары (бу тирәләргә Кучан авылы диләр) калын каен урманнары белән тулы булып, аның арткы ягы Исмәгыйль мулла мәсҗеде тирәләренә кадәр куаклык, чыбыклык һәм баткаклык булып, әүвәлдә мондан 75 еллар гына элек әлеге ялангач, урмансыз һәм коры хәленә килмешдер.

Яңапарның кырлары, бая әйткәнчә, кара туфрак булганы кебек, авылның үзе дә кара туфрак өстендә. Анда-монда гына бик сирәк очрый торган кызыл балчыклы ярлар һәм иген йирләре булгаласа да, коеларында су бетмәслекдер. Бу күп урынларда казылган йиргә су чыкганы өчен коесыз йортлар бик ярлы йортларында гына булып, нинди коры (10) һәм ягмурсыз елларда да суга мохтаҗлык һич юктыр.

Яңапарның өстендә дә, астында да ташның һичбер әсәре юк. Казыган йирдән таш чыгу — Яңапарның тарихында ул булмаган вә гакылга сыймаган нәрсә. Үзенә күрә зур авыл һәм киң кырлар сахибе (хуҗасы.— *Х. М.*) була торыб да, мунча ташына да ят авыллардан яхуд ерактан тугай елгаларындан берәр ташлап җыеп йөрүләр ташка шулкадәр ярлылык икәнчелегенә ишарәтдер. Шулай ук йирендә ком да юк. Шуның өчен Яңапарның юллары ягмурлар артыннан урам аша чыга алмаслык пылчырак һәм арбаның көпчәкләре гөбшәләренә кадәр батарлык герәзле (пычрак, саз.— *Х. М.*) булып, ягмурсыз коры вакытларда бәгъзән (кайчак.— *Х. М.*) күзге кебек ялтыравыклы, бәгъзән гордалы (кантарлы.— *Х. М.*), йөрер өчен газап вә мәшәкатьледер.

Кыш көнләрендә дә кар йөрер өчен авыл бик уңгайлы йирдә булганга, кар астына калуы, кар тауларының өелүе, ыжгырып-сызгырып килгән ачы буранларның өрүе — һәммәсе гади бер эш булып, кышның кышлык манзарасы да мөкәммәлдер һәм ачы бер хакыйкатьдер.

Баштарак әйткән көенчә, Яңапарның елгаларында, чырылдак (гөрләвек.— *Х. М.*) кебек булса да, сулар агып торуы — бу да, әлбәттә, бөек ганимәтдер. Шул елгаларга буалар буып (12), шул буаларда җәй көнләрендә юынулар, керләр юулар, хәтта атлар йөздерүләр тансык вә хозурлы бер эш булганга, авыл халкының аз-маз йөзә белүләре дә — шул буалардан алынган өлешнең берседер.

Бигрәк тә түбән очның, ягъни Чокын очының елгасы еракдан — эстипләрдән, Буриле елгалардан кадәрле килгәнгә, аның чырылдак кебек акар суы җәйнең эссе вакытларында да бөтенләй үк кипмәү сәбәпле, буалары да зурлак (зуррак.— *Х. М.*), тирәнрәк һәм дәвамлырак булып, түбән оч ул якдан бәхетлерәкдер. Югары очның елгасы фәкать бик якындан «Кучкарник» исемле бер уйдан (уйсу җирдән.— *Х. М.*) гына агып торганга, коры елларда зәгыйфьдер, буалары да дәвамсыздыр.

Яңапарның кырларына чәчкән игенләр: арыш, солы, бодай, тары, карабодай, эре борчак, вак борчак һәм шуның өстенә әле дә күбрәге үз йортларына чәчелгән аз-маз киндераш, бәрәңге кебиләрдән гыйбарәт булып, бөтен махсулат (уңыш, керем.— *Х. М.*), авыл зураеп, халык артып китү сәбәпле, елы-елы белән үзләренә генә йитәрлек кадәр генә булса да, арада зур гына иген байлары да һәм иген белән сату итүчеләр дә юк түгелдер.

Яңапарның кырлары — хосусый беркемнеке дә булмыйча, бөтен авылга бергәлекдер. Бу кырлар 10 елга бер мәртәбә генә шобага белән бүленеп, ул да җан башына бүленмичә, ирләр вә ир балаларга гына душлап бүленә һәм кыз балаларга өлеш чыкмый иде. (Большевикларның башланган елларында кырларны җан башына бүлә башладылар.)

Кыр, гадәттә, өчкә бүленеп, бер өлеше арыш, бер өлеше каташлык (сабан ашлыгы.— *Х. М.*), бер өлеше парна (пар басуы.— *Х. М.*) иде. Арыш өлешенә бөтен авыл халкы үзләренә тигән өлешләренә арыш чәчеп, каташлык өлешенә дә шулай ук бөтен авыл халкы яз башларында солы, борай, карабодай вә башкалар кеби тиз өлгерә торган игенләрен чәчеп, өченче (14) өлеше — парна кыры чәчелмичә буш калынып, бу кыр көтүләр өчен генә тотыла иде.

[13 нче биттә «Кырларның ел саен үзгәреше» исеме астында план бирелгән. Анда өч ел дәвамында кырда аерым-аерым нинди ашлыклар (арыш, каташлык, парна) чәчүе күрсәтелгән.— *Х. М.*]

Бу, гадәттә, шулай була иде:

1) Каташлык кыры. Көзен игенләрне җыеп бетергәч, көтүләр йибәрелә дә, бу кыр киләсе елга парна кыры булып кала.

2) Парна кыры, яз ката (язын, яз буенча.— *Х. М.*) берни дә чәчелмичә буш калынып, хайваннар өчен тотыла. Ягъни көтүләрдән тапталып, көзен, кышка каршы, арыш чәчелеп, озимь (уҗым.— *Х. М.*) кыры була.

3) Арыш кырындан көзен игенләрне җыеп бетергәч, янә анда көтүләр йибәрелә дә, киләсе яз башында анда каташлык чәчелә.

Шул кырларның өстенә әле дә Яңапарның печәнлек йирләре дә аерым-аерым кырларда бүленеп, иң зуррагы — болын, Алдагы саз, Урта саз, Арттагы саз, Сары саз кебиләрдер. Болар да бөтен авылга бергәлек булу сәбәпле, чабу заманында гына душ башына бүленеп, бергәләшеп чабыла торган һәм авылның печәнгә булган ихтыяҗы елына карап үти киленә иде.

Яңапарның авылында һәм кырында да, искедә булгалаган булса да, урман һич юктыр. Авыл йортларында, бигрәк тә югары очда, яңа урам буенда утыртылган алмагач (15), сиринә (сирень.—

*Х. М.*) вә бөйрәк (зирек.— *Х. М.*) кеби урманлар 1919 елларга кадәрле акрынлык белән генә булса да, алга китә алган булсалар да, югары очда Кулик Нәкыяларының елгага таба бакча очларындагы дүрт борадәрнең (туганның.— *Х. М.*) — Низамеддин, Хисамеддин, Хәйреддин һәм Кәлимулланың (Хәмидулла угыллары) бергәлек булган ике йорт буйлыгындагы бер төркем биек урманлары карга вә чәүкәләре белән дә, эрелекләре белән дә Яңапарның иң мәшһүредер һәм тәхминән (якынча.— *Х. М.*) 100 еллык бер әсәредер. Бу урманлар — Хәмидулланың атасы Мөхәммәд Габдерәхим заманында үзләре утырткан урманлардыр.

Шулай ук шул урманларга ялганып киткән Низамеддиннең йорты янындагы күрше Сабирның бакча очындагы кое һәм йорты буеның күләмендәге бер төркем талчыбыклары да авылның бик мәшһүре булганы кебек, ике йортның арасында, ягъни ике урманлык арасына казылган Сабирның коесы да (кизләве) — бөтен тирә-күршеләргә чәй өчен татлылыгы белән мәшһүрдер һәм иң күп истигъмаль иделгән (файдаланылган.— *Х. М.*) коеларның берседер.

Менә шул урманга ярлылык җәһәтендән Яңапар авыл халкының утынга булган ихтыяҗы фәкать базарлардан яки еракдагы рус авылларындан гына сатып алган утынлар белән генә үтәленеп килгәнгә, мичләргә салам ягу мәҗбүрияте иң беренче (16) шартдыр һәм дә бик мәгъкульдер.

Ярлырак кешеләрнең кырлардан эжнивә (урган артыннан калган черегән салам төпләре) җыюлары да ягуга шактый гына җиңеллек биреп, соңгырак елларда инде бу гадәт баерак йортларга да күчеп киткән иде.

Яңапар халкының дөнья тереклекендә иң мөһим бер ихтыяҗлары булса, ул да җил милчәләре (тегермән) иде. Җил һәфтәгә (атнага.— *Х. М.*) кадәрле генә туктап тордымы, авыл халкы хәзер ачка үләргә тора... Хайваннарның да ачы авазлары ишетелә башлый иде. Менә авылның шушы иң мөһим булган ихтыяҗларын үтәр өчен, сәүдәгәрлеккә бераз мәйле (теләге, сәләте.— *Х. М.*) бар булган һәм аз гына һөнәрдән хәбәрләре булган берничә кешеләр милчәләр корырга күңел баглап, бер заманда аларның саннары 15 кә йитде.

Җилсез көннәрдә дә, бик аз көч белән (бер кешенең көче белән) булса да әйләнүендән бер дә туктамаган, авылның иң уңышлы һәм иң гадел милчәләрендән саналган Куликныкыларның (бу тарихны язучы аталарының) 38 ат куәтле милчәсе авыл халкын һәм ач көйләрендә дә химая итеп (саклап; булышып.— *Х. М.*) ачлыкларындан коткарып торганы кебек, уңганлыгы һәм гаделлеге белән мәшһүр булган икенче Садыйк (Бүре) милчәсе дә халыкның бик күп ихтыяҗын үтәп килде. (17) Шулай ук башка милчәләр дә үз нәүбәтендә халыкка хезмәт итеп тордылар.

Җил милчәләренең беренче мәртәбә дөньяга чыга башлавына тәхминән 145 еллар гына мондан элек диеп хисап иделеп, чыгар-чыкмас ук беренче уларак Әхмәр бабайның (моны язучының бабасының бабасы) авылга җил милчәсе коруы бөтен авыл халкын шаккатырмыш вә догалар белән алкышланмышдыр. Башдарак милчә ул заманның фасуны буенча дүрт читле булса да, Хәмидулла заманында алты читлегә күчерелмеш, аның угыллары Низамеддин, Хисамеддин, Кәлимуллалар заманында инде ул бөтен тирә-як авылларның иң мәшһүре һәм бүрәнәдән такта ярырлык бер такта заводы хәленә кадәр керерлек хәлгә ирешкән иде. Бу Кулик нәселенең бабалардан бирле һөнәрче нәсел булулары сәясендә булырга кирәк. 1909 елларда ук Хисамеддиннең үз кулы белән электрик машинасы эшләп, милчәгә ут йибәрүе бөтен халыкны хәйранга калдыру гына түгел, гомере электрикның (электрның.— *Х. М.*) исемен дә ишетмәгән муллалар тарафыннан азан белән котланылды. Ләкин бик үк уңышлы булып чыкмаганлыкдан тукталып калды. Шулай ук милчәнең көчен һаман да артдыру фикерләре белән мәшгуль булган Низамеддин белән Кәлимулланың да икесенең аеры-аеры гакылга сыймаслык таза тешле (насатлы) барабан(18)лар кәшеф итүләре (уйлап табулары.— *Х. М.*) урынсыз калмаганлыкдан, милчәнең дә 38 ат көченә кадәр үрләве шуларның үстергән йимешедер.

Югарыда әйтелгәнчә, Яңапарда заманы белән, ягъни иң күбрәк вакыты XX гасыр башларында саннары унбишкә кадәрле үрләгән җил милчәләре булганы кебек, авыл халкы өчен янә бик кирәкле нәрсә булган крупчаткалары да (дранка) дүрт данә бар иде. Менә бу ике ат белән әйләндерелгән крупчаткалар, ярма яру вазыйфаларын гына үтәп килсә дә, бик җилсез заманнарда халыкның шул ярма ашына гына бәрелүләре дә авыл халкын аларның ачлыкларындан бик күп химая итүгә катнашулары мөхәкъкакдыр (хактыр, шөбһәсездер.— *Х. М.*) һәм алдаусыздыр.

**Крупчаткалар шул кешеләрдә иде:**

1) Әмишнеке, 2) Ходайбирденеке, 3) Канукныкы, 4) Нуркайныкы. Милчәсе янгач эшләткән.

**Җил милчәләренең ияләре:**

1) Госман (Остый) милчәсе. 2) Балтый милчәсе. 3) Мылчык. 4) Халислам. 5) Нарим бай имамы. 6) Сафиян бабай. 7) Пасла Исхакы. 8) Канук (19). 9) Кулик Рәхим милчәсе. 10) Садыйк (Бүре) милчәсе. 11) Садыйк икенче. 12) Бали. 13) Мәтүс (?) Нуркай милчәсе. 14) Нарим бай Әмиш милчәсе. 15) Хәмидулла Мөхәммәд Габдерәхим (Кулик) милчәсе. Бу милчәне милчә мастерларының иң осталарындан саналган Красный авылының (Красная горка, ягъни Сафаҗай.— *Х. М.*) Садыйк эшләмеш.

Авылда шушы милчәләр эшләп яткан вакытларында 1912 елда шулар өстенә ут милчәсе корылып, боларның берәм-берәм бетә баруларына юл ачылды. Кайсы янып, урынына инде яңадан эшләнмәде.

Кайсы сатылды. Сафиян бабай милчәсен Кызылъярга сатканы кебек, Мәтүс Нуркае да, милчәсе янгач, крупчатка гына эшләтде. Башка милчәләр дә эшсез калып, кайсы сүтелде, кайсы череп тузып бетде. Ут милчәсе белән көрәшергә большевикларга кадәрле фәкать авылның ике генә мәшһүр милчәсе калып, алар да бересе Бүре милчәсе белән Кулик милчәсе иде. Ләкин Кулик милчәсенең дә, гомере большевиклар заманында тәмам булып, аның да оста идарә итә алмаучылар кулына күчүе сәбәпле, янып көле күккә очды. Бүре милчәсенең соңгы хәле мәгълүм түгел.

Югарыда әйтелгәнчә, авылга ут милчәсе салдыру белән, шактый гына иске вә тарихи әсәрләрне җимерүгә юл ачылса да, (21) әлбәттә, ут милчәсенең авыл халкына бик күп җиңеллекләр китерүе дә шөбһәсездер. Бердән, бу милчә җилгә булган таянычдан авыл халкын коткарып, икенчедән, кибтерелмәгән ашлыкны да тарта белүгә ул оста булып чыкды. Ләкин гомере үтде аның да. Бабайлар чуманы, мәгаттәәссеф (үкенечкә каршы, кызганыч ки.— *Х. М.*), бу ут милчәсенә дә килеп йитде. Әүвәлдә большевиклар заманында Уразавылга күчереп, анда эшли башламышлар. Хәзерге хәле аның да мәгълүм түгел. Бу ут милчәсе ширкәт нигезе белән төзелеп, ширкәт ияләре алты кеше шулардыр: Гыймад Җәмал, Лотфулла Җәмал, Гомәр Салый, Хәсән Канук, Мостафа Исмәгыйль, Кәмал Байбулат. Милчә ике ташлы булып, йөреше нафта (нефть.— *Х. М.*) белән һәм үзенә йитәрлек кенә электрикләнмеш дә иде.

(20 нче биттә крупчатканың бинасы һәм эчке төзелеше төшерелгән.— *Х. М.*)

## 2. АКТУК ИЛЕНЕҢ ИСКЕРӘК ХӘЛЕ

Актук иленең кайсы елларда төзелә башлавыннан тулы мәгълүмат алу мөмкин булмаганлыкдан, бу көрәшдә (эштә.— *Х. М.*) без дә бабаларымыз кеби тәхмин (чама.— *Х. М.*) үлчәвен кулланудан ерак китә (22) алмыйбыз.

Актук, Ураз, Антар, Кызем, Кадем исемләрендәге биш борадәр бишесе дә бергә бу тарафларга күчеп килеп, бишесе дә бер-берсенә күрше уларак биш йиргә урынлашмышлар. Алар шунда үз утырган йирләренә үз исемләрен дә биреп, хәзердә дә бу биш күрше авылның исемләре берсәк бозылган көенчә дә — Актук иле (Яңапар), Уразавыл, Атаравыл, Кыземавыл, Кадемавыл диеб йөретеләдер.

Боларның кайдан килеп чыгулары, кем рөхсәте белән бу йирләрне ишгаль итүләре (биләүләре.— *Х. М.*) мәгълүм булмаганы кебек, боларның бишесе дә биш туган булмыйча, Актук, Ураз, Антар гына өч туган икәнчелегенә һәм Кадем белән Кызем фәкать аларга кардәшләр генә булган икәнлегенә ышанулар да шулкадәре ук көчледер.

Бу өч туганның кайсысы олыграк икәнчелеге дә мәгълүм түгелдер. Менә бу биш кардәш, бер иттифак белән бу әтрафларның агымсуларын, күлләрен мәгъкуль күреп, шунда төзелә башлаганлар да шунда утырып калганлар...

Тора-бара авыллары зурая барганы кебек, Актук авылының да халкы күбәеп, хәтта кырлары йитешми башлаган дәрәҗәгә ирешкән. [Ул вакытда һәркемнең хосусый үз йирләре булып, (23) йиргә булган бу хуҗалыкларны 1855 елның падишаһ фәрманы белән бетерелгән һәм ун ел саен душ башына бүлү белән әмер бирелгән.]

Актук бабай, бу эшнең, ягъни халыкның күбәюенең очы яхшы булмаячагын сизеп алып, кулдагы мөлкәтне ныграк һәм чынрак итдереп идарә вә тәртипкә кую нияте белән кырның уртасына күчәргә карар иткәндә, әлеге яңа йиргә, Яңапар урынына яңадан төзелә башлаган... Менә болар бар да Яңапарның тарихы хакында сөйләнелгән һәм картлар агызындан сөйләнә килгән хассыз (нигезсез.— *Х. М.*) вә дәлилсез һәм бәлки дә хакыйкатьдән байтак ерак тора торган материалларның берседер. Актук һәм күрше авылларындан хакыйкатән дә (чыннан да.— *Х. М.*) тулырак итдереп бирә торган мәгълүматлы дәлил вә документларның бар булуы беркемгә дә мәгълүм булмаганга күрә, бөтен ни бар булган мәгълүматлар — фәкать кайдандыр табылган иске бер могаһәдәнамә (килешү, договор, вәгъдәләшү.— *Х. М.*) кәгазенә баглы булып калган.

Менә бу иске вә тарихи могаһәдәнамә кәгазе бабайлардан кулдан кулга күчеп, моның эчендәге мәфһүмен (эчтәлеген, мәгънәсен.— *Х. М.*) төрлесе төрлечә яңлыш итдереп аңлаганлар да, Актук елын хәтта 900 яшьлеккә санап чыгарганнар. Бүген дә халкымызның игътикадлары (ышанулары.— *Х. М.*) шушыдыр. Бигрәк дә табылган бу иске (24) могаһәдәнамәне дөрест итдереп укучылар да бәлки дә искерәк заманларда аз булганлыкдан, аның эчендәге мәфһүме(н) я арттырылган да, я киметелеп дә киленгән...

Шуның өстенә әле дә картларның хикаярәк итдереп кызык-кызык иске хәлләр хакында сөйләгән сүзләре Яңапарның иске тарихының эченә кереп китеп, боларда бөтен иш(ет)меш вә картлар агызындан сөйләнгән сүзләрнең дөреслеген исбат итәргә бөек дәлил булганлар һәм тарихның чынын вә хакыйкатен шундан эзләтергә сәбәп булганлар... Мәсәлән, хикәяләрнең берничәсе шундан гыйбарәт: Актук бабай белән Ураз туганлары, Антарны эшкә кушып:

— Антар! Бар, куйларны кайтар! —диеп аны сылтау белән куйлар артыннан йибәрәләр дә шулвакыт кырларның шәбрәкләрен һәм зурракларын сайлап үзләре өчен ишгаль итеп (биләп.— *Х. М.*) куялар... Антар кайткач сизенсә дә, эш инде узган була...

Актук авылында бик ачлык елы булып, ун кадак икмәккә олы юлның авылга таба ягындан ике йир буе йир (тәхминән 50 дисәтинә) Кыземавылга саталар. (Бу йир большевикларга тикле Кыземавыл кулында иде.)

Тора-бара бу биек (олы.— *Х. М.*) хаталыгын Актук авылы сизә дә, эш инде (25) узган була...

Ләкин ничек итдереп үчне алырга? Алар шул үч алуны уйлап торганда, ничектер, хикмәти Хода, аларга илһам килә... гакыл керә. Алар катык эшләү һөнәрен өйрәнеп алып, шул һөнәрне үзләрендән ягага чыгармаска ант итешеп, Кыземавыл һәм Кадемавыл халкын катык ашарга өйрәтәләр. Алар катык-ны шулкадәр ярата башлыйлар ки, Актук авылындан аның ничек эшләнүен өйрәтергә сорыйлар. Ләкин Актук авылы әйтми. Ахырда Кадем авылы, кырык чүлмәк катыкка һәм катык эшләүне өйрәтү шарты белән, Актук авылына зур болынны сата.

Ләкин шунысы тәәссефдер (үкенечдер.— *Х. М.*) ки, Кыземавылдан үч алынмый кала. Алар катык эшләүне Кадемавылдан өйрәнмешләрдер...

Биш мең мишәр халкы Мәскәү падишаһына буйсынмыйча качып йөри-йөри таралып бетә башлыйлар. Безнең Актук бабаларымыз да шулар арасында бу йирләрдә качып утыра башлаганнар. Ахырда падишаһка буйсынып, гафулык алганлар да шушы утырган йирләре өчен падишаһка налог (салым) түли башлаганнар...

Менә бу кеби төрле-төрле хикаяләр агыздан агызга сөйләнеп килеп, тарихка әверелеп калганлары кебек, кулда чын (26) итдереп мәгълүмат бирерлек документлар булмагач, бу имеш (-мимеш.— *Х. М.*) сүзләре дә бик мәгъкуль һәм мәгалмәмнүният (шатланып.— *Х. М.*) кабул иделүгә юл тапкайлар... Башдарак, әлбәттә, болар да хакыйкатькә бик якын булсалар да, тора-бара бәлки аларда табылган иске могаһәдәнамәнең мәфһүме үзгәргәне кебек үзгәреп, я артдырылып, я киметелеп килгәнләр.

**Могаһәдәнамә асыл көенчә шундан гыйбарәт:**

1078 елда (милади белән 1667/68 еллар) гакрәб (чаян.— *Х. М.*) йолдызының (Зодиак тамгасы белән 22 октябрьдән 22 ноябрьгәчә була торган вакыт.— *Х. М.*) 13 нче көне. Без Актук иленең Дилбак Тугай углы, Сунак Тугай углы, Ураз Тугай углы. Тугай углы Ураз үлде. Аңардан өч угыл калды. Бере — Яникә (?Иәнкә.— *Х. М.*), икенче — Кабил, өченче — Гомәрүк. Болар — Ураз угланлары, андин соң Дилбак берләң Сунак энемез Ураздин калган өч углының арасыннан берсене сайлап, Яникә адлысын киңәш итеп, бер йирдә ултырып, Мәскәү шәһәренә рәхимле падишаһ хәзрәтләренә (50) читвәр йир сорарга йибәрдек. Шул ук Актук иленең Адрый Алмакай углы илә икесене бергә кушып, үземезнең малымыз берлән вә һәм атымыз берлән тунымыз берлән йибәрдек.

Адрый иләң Яникә Мәскәү шәһәренә бардылар вә падишаһ (27) хәзрәтләренә керделәр. Падишаһ хәзрәтләре сораган 50 читвәр бунлара бирде. Андин Яникә белән Адрый килделәр. Андин соң без Дилбак илә Сунак Тугай угланлары, энемез Яникә, Кабил, Гомәрүк (Гомрүк) Ураз угланларына бер йиргә килеп киңәш итдек вә һәм ул йиргә шул ук Актук иленең яхшы кешеләрен дәшеп килтердек. Ул Нурани Тауры углы, вә янә Симай Актук углы, янә Сәфәр мулла Алмакай углы, вә янә Актук абзый Келәш углы.

Без Дилбак иләң Сунак Тугай угланлары вә һәм Яникә, Кабил, Гомәрүк өчәве Ураз угланлары ошбу юкарыда ултырган яхшы кешеләр алдында 150 читвәр йирне өч өлешкә бүлдек. Илле читвәр Дилбакга, илле читвәр Сунакга Тугай угланларына. Янә илле читвәр Ураз угланларына. Аның өчен без Дилбак берлән Сунак үз малымыз берлән энемез Яникәгә илле читвәрне бирдек. Алар кабул күреп алдылар. Яникә, Кабил, Гомәрүк — Ураз угланлары, без Дилбак илә Сунак — Тугай угланлары, вә янә шул ук юкарыда язылган яхшы кешеләр алынында (алдында.— *Х. М.*) Сәфәр мулланың кулындагы Коръәнне мәсҗедкә алып бардык вә, һәрберемез үз кулымызга алып, Коръән үбтек. Алланың олуг адлары илә ант итдек. Без Ураз угланлары: Яникә, Кабил, Гомәрүк (28) үземез кабул кыйлып алган илле читвәр йирне биләрмез диеп, атамыз берлән тугма агаларымызга сүземез юк диеп; бу көндән соңра анлар үзләре хәзер булып бу эшкә Актук Келәш углы юкарыда язылган Ураз угланлары Яникә, Кабил, Гомәрүк, анларның үтенече буенча кулым куйдым.

Бу хатны яздым шул ук Актук иленең юкарыда язылган Ураз угланларының үтенүе буенча, шул ук илнең Нурый Меллакай углы мулла углы кулым куйдым.

Бу тарихи могаһәдәнамә кәгазе кулдан кулга сакланып килеп 1850 еллар тирәсендә Биккол углы Таҗеддиннең (моны язучының әбисенең атасы) кулына төшә. Аның бик шәкерд Хәсән адлы углы моны үлгинчә саклап, ул үлгәч, бик күп еллардан соң, ничекдер, Нижнийда торучы Яңапарның кулак Гылау-Габделгазизнең (Туктар Йосыфның нәүгы — нәселе.— *Х. М.*) кулына тап була. Тәсадефән (очраклы рә-вештә.— *Х. М.*) тугры килеп Финляндиядән 1910 елларда Нижний үтәли авылга — Яңапарга төшеп барышлый Зәйнелбәшир Гыйлаеддин (Кулик) Кулак главада кунак булып, аның кулына бу нәрсәнең эләккәнен сизә дә аңардан ала. Кардәшләре Зәйнелбәширдән Низамеддин, Хисамеддин Хәмидуллалар

күчереп алалар. Зәйнелбәшир авылга төшеп (29) вафат булгач, бу язу аның әһелендә (хатынында.— *X. М.*) калды.

### 3. АКТУК ИЛЕНЕҢ ХАКЫЙКАТЬКӘ ЯКЫН БУЛГАН КЫСКАЧА ТАРИХЫ ВӘ БАШЫНДАН ҮТКӘРГӘН ВАКЫЙГАЛАРЫ

Актук иленең тарихы хакындагы чуалчык хәбәрләр белән укучыларны таныштыру тиеш күрелгәнлекдән, иң беренчегә шуларны язу мәҗбүриятен кабул иделгән иде. Ләкин болар кемне канәгать итдерде соң? Бу шуның белән инде тәмам булдымы? Әлбәттә, юк! — диеп әйтеп була.

Ишмеш сүзләр һәм картлар агызыннан сөйләнеп килгән хикаяләр аркылы гына алынган мәгълүматлар белән, әлбәттә, Актук иле хакындагы тугрыга якын булган хакыйкатьләрне бирә белү мөшкел бер эш икәнлеген әлегә кадәр сөйләп, аңлатып килдек. Нәтиҗә дә һаман бер: имеш-мимеш булып чыкды. Менә шул имеш сүзләр бездә кызык өчен генә һаман да һаман тыңланылганда, шуның артында һәм алынында уйланып бер дә багылмаган. Багылуга инде, әлбәттә, әһәмият тә бирелмәгән (30). Ләкин шушы имеш сүз вә хикаяләрне һәм югарыда язып күстәргән могаһәдәнамәне хакыйкате безгә мәгълүм булган берничә хәбәрләр белән чагыштырып карасак, ис-гакыл киткеч бер хакыйкать мәйданга килеп чыга ки: Актук иленең бик чын вә хакыйкатькә якын булган тарихы кул сузып йитәрлек якын бер йирдә генә икән!

Иң элек шуны әйтеп узарга тиешдер ки: бөтен хаталыкның башы булган Актук иленең яше 900 түгел. Шулай ук бөтен тирә-як күрше авыллары да андый карт түгелдер...

900 яшь ул бик озын гомер. Бөтен агырлык вә төрле вакыйгаларны кичереп үткәргән тукыз йөз яшьлек бер авыл нинди генә җаһилият заманына тап булмас, ул инде үзен үзе иске икәнчелеген күрсәтерлек бер хәлгә килә ала. Бу әсәрләр һәм Актук илендә дә һәм бөтен күрше авылларда да — берендә дә юктыр.

Аларның бик яшь икәнлекләрен каберстаннары да ап-ачык күрсәткәне шикелле, күл вә ага торган елгаларының да этрафларына иген чәчелә башлау сәбәпле генә кибеп, гил (туфрак.— *X. М.)* белән тулып бетә баруларының XVIII—XIX гасыр-
ларда гына башланганы һәркемгә мәгълүмдер һәм бу да шуларга бөек бер дәлилдер (31). Шулай ук бөтен бу хаталыкка сәбәпче булган могаһәдәнамәнең язылган елы да ул 1078 миладо түгел, һиҗри елыдыр. Менә бу миладига әйләндереп тәхминән (якынча.— *X. М.*) 1667 гә әйләнгән ел хисабы, катгыян (һичшиксез.— *X. М.*), дөресткә бик якын булып, бу тарихны да безнең өчен мөһим булган еллардан гына алып китәчәкмез.

* * *

Актук бабайларның ничек бу тарафларга күчеп килүләре вә кемләр булганлары хакында бәхәс итүләрне без, матбага кимчелекләре һәм хәрефләр йитешмәүлеге сәбәпле, мәгаттәәсеф (үкенеч ки.— *X. М.*), бу әсәрнең соңынарак калдырып торып, аларның нинди елдан башлап төзелә башлауларындан гына алып китәргә мәҗбүр буламыз.

Актук бабайның атасының исеме Келәш булып, Келәшнең һәрхәлдә икенче углы Тугай исемендә булган. Кадем, Кызем, Антар — болар Келәшнең балаларымы, яхуд туганының угылларымы — анысы мәгълүм түгел. Антарны картлар, шөбһәсез, Актукның борадәре, диеп йөрткәнгә, без дә инде аның Келәш угылы булганлыгына каршы килә алмыйбыз.

Актукның борадәре Тугай вафат булгач, аның калган өч ир баласын — Дилбак, Сунак, Уразны Актук үз янына (32) алып, Антар, Кызем, Кадемлар белән бәрабәр 1650 еллар тирәсендә бу якга килеп төзелә башлыйлар.

Антар, Кызем, Кадемлар үз исемләре белән үз өлешләренә тигән йирләргә төзелә башлаганлары кебек, Актук та борадәре мәрхүм Тугайның олуг углы Уразга үз өлешен биреп аерганда, Тугайның кечек угыллары Дилбак белән Сунак Актукның абзыйларының идарәсе астында калганлар.

Ул вакытда бу күчеп килгән кардәшләрнең кырлары әлеге Коям зурлыгындагы кебек булмыйча, бәлки дә үзләренә генә йитәрлек тар булганлыкдан, тора-бара якларына яңа күчеп килгән күршеләре дә арта барып, аларның кырлары да арта вә киңәя барганлар. Бу киңәюләр Уразавыл, Кадемавыл, Антар авылларында да шул көйгә көчәеп китү сәбәпле, этрафлардагы буш булган хуҗасыз йирләрне, бер дә кирәге булмаса да, киләчәкне күздә тотып ишгаль итеп (биләп.— *X. М.*) кую уздырыш хәлен алган. Ләкин бу киңәюләргә, әлбәттә, падишаһның рөхсәте кирәк булганга, Мәскәүгә барып, падишаһдан рөхсәт алулар ешаеп киткән.

Падишаһның да, әлбәттә, йир сорап барганларга: «Ишгаль иткән йирләреңезне, мотлакан (һичшиксез.— *X. М.*), биләргә тиешлесез»,— диеп агыр шартлар куюы, әгәр шулай булмаса, йирләрнең дә кире алыну куркынычы (33) барлыгы шушы шартлар эченә кергәнгә, киңәюләргә бу бераз манигъ

(киртә.— *Х. М.*) була торып, буш һәм ишгаль ителмәгән йирләрнең дә булып торуы 1667 елга кадәрле дәвам иткән.

Менә бу ишгаль иткән вә киңәя барган йирләрне биләү (игү) мәҗбүрияте һәм аның агыр шартлары Актук бабайның күңеленә курку төшереп, ул, шул шартларны йиренә йиткерер өчен, ансыз да ераклыгындан эче пошып торган Актук авылы кырының уртасына күчерергә тиеш тапкан һәм мәҗмугы (барлыгы.— *Х. М.*) 20 ызбалар тирәсендә генә булган Актук авылының кешеләре дә, бу яхшы фикерне бердән кабул итеп, 1667 елда әлеге урынга күчеп утырганнар һәм нык итдереп эшкә ябышканлар.

Менә шушы күчкән елны ук кыр мәсьәләләрен бик яхшы итдереп авыл халкы бер фикер белән рәтләп, бөтен кырны
7—8 шобагага бүлгәннән соң, әлегә кадәрле әле дә ишгаль ителмичә калган 150 читвәр йирне дә Тугайның Актук ягында калган балалары Дилбак белән Сунак борадәрләре Уразның Яникә исемле углын русча белүче Сәфәр мулланың борадәре Адрый Алмакай белән икесен Мәскәүгә падишаһка йибәреп, шул буш йирне үзләренә сораганлар.

Падишаһ биләү шарты белән бу йирне биргәндән соң, һиҗри ел 1078, гакрәб йолдызының 13 нче көнендә, ягъни (34) 1667 ноябрь 2 сендә язылган могаһәдәнамә кәгазе буенча бу йирнең 100 читвәре Дилбак белән Сунакга Яңапарда, 50 читвәре Уразавылга Уразның өч углына — Яникә, Кабил, Гомәрук-кә калган. (Могаһәдәнамәдә 50 читвәр генә булса да, әлбәттә, 50 шәр читвәр диеб аңларга тиеш.)

Бу йирне ишгаль итеп куюлары, бу китапның башындарак әйтмешли, халкы артып китеп, кырлары йитешмәүдән түгел, максадлары киләчәкне күздә тотып ишгаль итеп кую гына иде. Ачлык елны ун кадак икмәккә Кыземавылга илле дисәтинә йир сатулары вә Кадемавылның да кырык чүлмәк катыкка шулкадәр зур болын бирүләре бу фикернең дөрестлеген бик ачык исбат итә һәм кырларының артып та калганлыгын аңлаталар.

Актук авылының иске урынында утыруы тәхминән
17—20 еллар гына кыска булганга, күчкән вакытларында каберләре дә ун-унбиштән артык булмаганы кебек, өйләре дә егермедән артык булмаган. Картлар сүзенә караганда, өйләре егермеләп булса да, кырлары 8 генә хуҗалыкда булган. **Алар шулардыр:** 1) Актук Келәш углы, 2) Симай Актук углы, 3) Нурай Тауры углы (Текмәли бабай), 4) Сәфәр мулла Алмакай углы (муллалары) (35), 5) Адрый Алмакай углы, 6) Дилбак Тугай утлы, 7) Сунак Тугай углы. 8) Нурый Меллакай углы.

Исеме Актук (Ак түк) һәм Яңапар диеп йөретелгән бу авыл хәзерге урынга күчүе берлән нык итдереп утырып калган. Күчкән йирләрендән мәмнүн (разый.— *Х. М.*) калып, хәрәкәткә башлаганнар. Иске күчкән авылларын да кырга әйләндереп чәчеп йибәргәннәр...

Күчкән йирләренең эзләре Уразавыл зыяратлары янында иске зыяратлары, бакча эзләре, буразна һәм ләкалары (чәчми калдырган буразналары.— *Х. М.*), киндераш урынлары большевикларга кадәрле әле дә бар булса да, бүгенгесе мәгълүм түгелдер.

Печән вакытларында печән болынын бүлгәндә, киндераш урыны диеп аталган йирне аермыйча бүләләр иде. Мондан йитмеш биш ел элек кенә киндераш бакчаларында бик биек киндерашлар үсә торган булып, бу тирәләрдә йөрүчеләрне куркыта торган булган. Кызыл кирпечләр, казан, табак, пычак кеби нәрсәләрнең бу йирләрдән табылып торуы большевикларга кадәрле дәвам итде. Яңапар бу урынга күчеп, бая әйткәнчә, 20 ызбалык, 8 шобагалык бер авыл булып башланган. Бик динле һәм фал ачуда, һәм йолдызлар (нөҗүм гыйлеме) белән багучылык (36) итүдә дә (гакрәб йолдызы — «скорпиони» да фал ачуның бер кыйсемедер) шактый алга киткән бу халык үзләренә гыйбадәт кыйлырлык кечкенә бер өй тотып, шунда гыйбадәт кыла торган булганнар. Халык бик күбәеп китү аркасында гына 1820 елларда Галим мулла йортына салам башлы мәсҗед корырга муафыйк булып, ул да манарасыз булган.

Яңапарның бу урынга күчеп утыруыннан 4 ел соң, ягъни 1671 елда иң беренче уларак вафат иткән адәмләре Нурай бабай булып, аның үлүе авылны бик зур кайгуга төшергән. Яңа зыяратларга, ягъни хәзерге зыяратларга иң беренче күмелгән мәет 71 яшендәге бер мөхтәрәм Нурай бабайдыр, ягъни Текмәли бабай. Аның артындан озакламыйча 90—95 яшьләрендә мөхтәрәм бабамыз Актук вафат иткән. Изге һәм бөек әүлия диеп танылган Нурай бабайның бөтен тирә-якларга мәшһүр булган кабере бүген дә бар булса да, Актук бабайның каберенең кайдалыгы мәгълүм түгелдер. Аның каберенең каберстанның авылга таба ягындагы елга янында булуын картлар бик куәтлиләр. Чөнки бу зыяратларның башлангычы да шундан булып, соңга елларда яр җимерелеп, шундан кеше сөякләре дә чыкгалады.

Каберстанның башлангычы елга яныннан башлап булса да, беренчегә үлгән Нурай бабайның тау башына күмелүе аның бик зур (37) хөрмәт иясе булганлыгын аңлаталар.

Нурай бабайның каберендән ерак да түгел каберстанның урта бер йирендәрәк гаять гүзәл һәм биек вә калын бер каен урманы гаять еракга күренеп узган-барган халыкны гаҗәпкә калдыра иде. Бу урманны Актук бабайның кабередер диеп бик күбе шөбһәләнеп килсәләр дә, 90 яшендәге Әмин Ихсаны исемле карт бу урманның 1800 елларда Ямилхан исемле бабайның бердәнбер генә углы вафат итдекдән соңра баласының кабер өстенә утыртылганын сөйли икән.

Әлеге каберстанның әйләнәсе хайваннар керә алмаслык тирән вә киң канаулар белән чормап алынган булса да, 1910—1913 еллар тирәсендә Гыймад Җәмал, Әхмәджан Җәмалларның тәшәббесе (тырышлыгы, башлап йөрүе.— *Х. М.*) илә Финляндия мөселманнарындан акча тупланып, әйләнәсенә забор (койма) тоттырылды.

Нурай бабайның чын исеме Нурмөхәммәд булса да, терек вакытында ук аны Нурай бабай диеп йөреткәнләр. Ул үлгәч дә бик күп еллар, хәтта 1870 елларга кадәрле аның каберен Нурай бабай кабере диеп йөретеп килгәннәр. Әлеге заманда «Текмәли бабай кабере» диеп йөретеләдер.

Текмәли дигән сүздән «тегү» мәгънәсе аңлашылса да, бу сүзнең асылда кайдан чыкганлыгы мәгълүм түгел. Ләкин (38) шунысы гына мәгълүмдер ки, Нурай бабайның каберенә иске заман гадәте буенча имән агачларын яргалап, кабер әйләнәсенә йиргә утыртып югары башларын бер сөям кадәрле ярып, ярган төшкә кабернең дүрт ягына да имән тактасы кигезеп чардуан ясалган булган. Болай итдереп эшләнгән чардуанга «текмә» диеп әйтелгәнгә, «Текмәли бабай кабере» дигән сүзнең дә шундан калуы шөбһәсездер.

Бу көйгә салынган имән чардуаннары каберләр өстендә соңгы елларда да берничәләп булдыгындан, имән чардуаннарының шулкадәр чыдамлыгы һәм башка шул каберләрнең дә Нурай бабай гасырында вафат итдекләре, шулай була калса Актук бабай кабереннең дә бәлки шулар арасында булуы, яхуд Нурай бабайның беренче чардуаны җимерелеп, соңгырак бер гасырда, ягъни бу адәмләр вафат иткән гасырда, ул заманга муафыйк булган текмә чардуаны ясалуы аңлашыладыр.

Соңгы елларда, ягъни 1910 елда, Әхмәд бабай углы Гайнеддин, иске текмәне эчкә калдырып, әлеге заманга муафыйк итдереп, Нурай бабайның каберенә чардуан ясаткан иде. Хәзерге хәле безгә мәгълүм түгелдер.

Нурай бабайның туган елы 1600 ләрдә булып, 71 яшендә вафат иткән. Әлегә кадәрле аның калган нәсел-нәсәбендән һичкемсәнең бере булмаса да, Эрбитшә тавына менгәндә, 105 яшендәге (39) Тау Ихсаны исемле бабаны (Финляндиядән Садыйк Хәкимҗанның кардәше) һәм урталыкдагы Мөхаджан, ягъни Мөхәммәджан бабаны (язучының кунак әбисенең атасы) аның нәселендән диеп сөйлиләр иде,

Нурай бабайның изге бер әүлия һәм бөек бер кәрамәт иясе булган икәнчелегендә һичкемсәнең шик вә шөбһәсе булмаганы кебек, аның каберенә йөри торган чирәм юлының аны зыярәт итүчеләр тарафындан тапталып, ашалып бетүе дә — шуңар бөек бер дәлилдер.

Аның рухына нәзер корбаннары чалулар, юлга, ягъни сәфәргә чыкганда, сәдакалар күтәрүләр, бөтен тирә-як күрше авыллары тарафыннан да, әлбәттә, әле дә бу көндә дәвам иткәне кебек, кабереннең өстенә кырык көн йөрүләр, чардуандан агач кисәкләре юынып алып, шул агач парчаларын зәхмәт башына тотулар һәм, хикмәти Хода, шундан шифалар табулар — һәммәсе әле дә шулай ук дәвам иткәне кебек, бу гадәтләр, әлбәттә, бик озак заманнарга чикле (чаклы.— *Х. М.*) дәвам да итәчәкдер.

Элеккерәк елларда күрше урыс авыллары да аны изге кеше диеп танып, кайгылы вакытларында аңардан дога өмид итеп сәдакалар бирә торган булганнар.

Бу мөхтәрәм бабайның Яңапар каберлекләрендә булуы — Яңапар өчен бөек бер шәрәф (дәрәҗә.— *Х. М.*) һәм мәңгелек дога чишмәседер (40).

**4**

Яңапар авылы корылып, кечкенә генә бер хәлендә яшәгәнләре бер заманда гыйбадәт өчен кечкенә генә бер өй тотканнар вә, халкы күбәеп китү аркасында, 1820 елларда Галим мулла йортына, салам башлы гына булса да, манарасыз бер мәсҗед салырга муафыйк булганнар диеп, югарыда язып үткән идек. Тора-бара халык янә күбәеп, бераз баеп китү сәбәпле, авыл уртасына хәзерге урта мәсҗеде урынына гаять гүзәл, чынаяк пичле, манаралы бер мәсҗед салдырганнар. Ләкин, мәгаттәәссеф (үкенечкә каршы.— *Х. М.*), мәсҗедләре бик озак гомерле булмыйча, 1837 елда авылда бик зур янгын чыгып, бөтен авыл янып, мәсҗедләре дә янган. Яңапарда фәкать Талус бабай ызбасы гына калып, аның йорты Туктар углы Йосыф бабайның аланында (алдында? — *Х. М.*) булган.

Авылның януы урак өстендә булып, халык бары да кырда ура торган булганнар. Көн уртасында авыл өстендә ут күтәрелгәнен күреп, аһ-ваһ итеп, кырдагы халык авылга кайтсалар да, салам башлы өйле авылны барча ут каплаганлыкдан, бер чүп итә (бернәрсә дә эшли.— *Х. М.*) алмыйча, өйдә калган аз-маз хайван терлекләрен коткарудан гына башка берни дә итә алмаганнар (41). Кичкә каршы хайван көтүләренең авылга кайтулары, хайваннарның акырып-багырышулары кырдан арып кайткан халыкның өйсез, ятаксыз, ач, ялангач һәм яшь балаларның илереп-илереп җылаулары, Кыямәт купкан шикелле, фаҗигале бер хәл алган...

Янгыннан соң халыкга бик агырлык килеп, берничә ел эчендә яңадан корылып йиткәнләр дә, йиде ел чәчү вәгъдәсе белән мукшыларга «эстип» дигән кырны кисеп биреп, шул акчага бөтен авыл бергә тырышып янә мәсҗед эшли башлаганнар.

Иске заманнарда «эстип» кыры бөтенләй кара урманлык булса да, мукшыларга бирелгән вакытда талчыбыклы, ертмаган чирәмлек булган. Мукшылар шуны йиде ел эчендә тәмамилән чәчәрлек итдергән яхшы кыр ясап кайтарып биргәннәр.

Яңапар халкы, бердән, бик яхшы «эстип» кырлы булган, бердән, шул кергән акчага шул ук урта мәсҗеде урынына ике катлы, төрек планы белән бик зур мәсҗед салдырган.

Бу мәсҗедләре күп еллардан соң искереп, шул ук мәсҗедне, боздырып һәм кечерәйтеп, хәзерге хәленә китергәннәр. Бу әлегә кадәрле сәламәт торып, бу көнге хәле безгә мәгълүм түгелдер.

Бу мәсҗеднең беренче имамы Алтынбай мулла булып, ул (42) вафат иткәч, углы Садыйкны муллалыкка куелган. Ләкин ул озын гомерле булмау сәбәпле, озакламыйча вафат иткәндән соң, ул нәселдән имамлык киселеп, Хисам мулланы муллалыкга куймышлар. Ул вафат иткәч, янә нәсел киселү сәбәпле, Низамеддин муллалыкга кереп, ул вафат иткәч, углы Шәрифҗан мулла булган. Ул вафат иткәч, углы Лотфулла мулла булып калды. Әлеге вазгыятьдән (хәленнән.— *Х. М.*) хәбәремез юкдыр.

Яңапар авылы бөек вә фаҗигале янгыныдан соң корылып йитсә дә, авылда һәм атаклы зур иген байлары байтак кына булган булса да, күп елларга кадәрле авыл янә салам башлы ызбалардан гына гыйбарәт булып торган. Фәкать соңгы елларда гына Уразавылның Әмирхан исемле бер останы китереп, иң беренчегә (беренче булып.— *Х. М.*) Гыйбадхан бабай агач түбәле өй эшләткән.

Авыл зурайган саен, Урта мәсҗедләре генә авыл халкына йитешми башлагач, 1851 елда Хәлиулла мулла яңа урамга мәсҗед салдырса да, канун буенча мәхәлләсе җомга укырга йитешмәгәнлекдән, җомгага Урта мәсҗедкә йөрергә мәҗбүр булынып, мәхәлләсе ике йөз душка ирешкәч кенә, үз мәсҗедләрендә җомга укый башлаганлар.

Бу мәсҗеднең беренче имамы Хәлиулла мулла вафат иткәч, углы Хәйреддинне муллалыкга куелган. Аның артындан углы Габделваһаб мулла булды. Хәзерге хәле безгә мәгълүм түгелдер (43).

Мәйданга чыгып тартышу вә бик күп эшләргә көндәш чыгу кеби эшләр ул заманда да бар булганы өчен, 1874 елда түбән оч мәхәлләсенең Габделгазиз мулла углы Гыйззәтулла ахун хәзрәт вафат булгач, урынына гаять күркәм холыклы углы Сибгатулланы муллалыкга куелып, түбән оч мәсҗеден салдырырга ул муафыйк була.

Сибгатулла хәзрәтнең мәхәлләсе йитәрлек кадәр зур булганлыкдан, башдан ук аңар җомга намазы укытырга рөхсәт ителгән. Ләкин Сибгатулла хәзрәт кыска гомерле булып вафат иткәч, мәхәлләсенең бәгъзе бер атаклырак һәм үзсүзлерәк адәмнәре Гыйззәтулла хәзрәтнең яшь хатыныннан туган 16—17 яшьлек Исмәгыйльне муллалыкга куярга бик каты тырышканнары кебек, Гыйззәтулла хәзрәтнең кечек агасы Төхфәтулла мөәззиннең углы Гарифулла да, үз тарафына бер мәхәллә җыеп, муллалыкга керергә бик каты көч куя. Исмәгыйль тарафдарлары бер мәсҗедкә ике мәхәллә, бер имам тели; Гарифулла тарафдарлары бер мәсҗедкә ике мәхәллә, ике имам тели. Исмәгыйль мәхәлләсе, карарларында нык торып, Гарифулланы муллалыкга куярга ирек бирмиләр. Икенче тарафдан Гарифулла ягында Исмәгыйльне муллалыкга куярга ирек бирмәгәч, вакытлыча гына мулла кирәк булдыгыйндан Гарифулланың атасы Төхфәтулла мөәззинне мулла урынында тотсалар да, ахырда Исмәгыйль тарафдарлары (44) хәйлә корып: «Фәлән кешенең баласына исем кушарга бармады, канунга хилафлык кылды...»,— диеп шаһитлар куеп, Собраниега (мөфтият, Дини идарә күздә тотыла.— *Х. М.*) өстендән кәгазь йибәргәнләр. Собрание исә Төхфәтулланың зарарына хөкем кылып, аның указын алып имамлыкдан төшергән дә мәсҗедкә вакытлы итдереп Урта мәсҗеде мулласы Шәрифҗанны муллалыкга билгеләп куйган. Дүрт-биш еллар кадәре Шәрифҗан хәзрәт бу ике орышучы мәхәлләгә имам булып торгач, Исмәгыйль солдатка эләккән.

Исмәгыйль тарафдарлары, бу эшкә бик кайгырып, Кызылъярның Шәрәфеддин головага (волость башлыгы) Борын Исмәгыйльнең солдатдан калуына чара табуын үтенгәнләр. Ләкин Шәрәфеддин голова, Гарифулла тарафдарлары булдыгы өчен Исмәгыйльне солдаттан калдыруның шарты Гарифулланы муллалыкга сайлау дигәч, бонлар бу шартка разый булып кайтып киткәннәр. Вәгъдә буенча Исмәгыйль солдаттан калган. Ләкин аның тарафдарлары биргән вәгъдәләрен бозып, сүзләрендән кире киткәнләр дә Гарифулланы янә муллалыкга кабул итмәгәнләр.

Бу низаг вә орышлар шулай дәвам итеп торганда, ягъни 1890 елда Яңапарга мәшһүр Норлат ишаны Фәхреддин килгән. Уразавылның бай сәүдәгәрләре Фәтхулла (45) исемле адәм, бөек бер мәҗлес ясап, мәҗлесдә Яңапарның Исмәгыйль белән Гарифулла мәхәлләсенең аралары бозыклыгыйндан Фәхреддин ишанга шикаять (жалоба.— *Х. М.*) кылына. Ул мәҗлесдә Исмәгыйль белән Гарифулла, аларның тарафдарлары да була. Ишан, мәҗлесдә гаять әсәрле (тәэсирле.— *Х. М.*) вәгазь сөйләп, халыкны йомшартып, Исмәгыйль белән Гарифулланы бөтен халык арасында имам хатыйб вә мөдәррис, Исмәгыйльне шул ук мәсҗедкә имам мөгаллим итеп сайлый. Шуның белән низаглары да бетә. Икесе дә бер мәсҗедкә калалар.

Гарифулла мулла 1915 елның көз айларында картаеп вафат итеп, Исмәгыйль мулла да, 1922—1930 еллар тирәсендә картаеп, большевиклар заманында Нижнийда төрмәдә вафат итде. Бу ике мәхәллә вә ике имам булып бергәләшкән түбән оч мәсҗеденең рәсми мөәззине уларак сайланган Гарифулланың борадәре Ягъкуб Төхфәтулла да азанчылык вазыйфасын картаеп үлгәнчегә кадәрле шактый гына гыйлеме барга күрә бик яхшы үтәп килгәне кебек, аның олуг углы Габделкоддус да бик галим, ачык фикерле вә бик милләтпәрвәр (милләтне сөюче.— *Х. М.*) булдыгы өчен, авылның надан дошманлары арасына сыя алмадыкдан, ул Кырымга китеп, андагы биек (югары.— *Х. М.*) мәктәптә мөгаллим булып

яшәде һәм 1929 еллар тирәсендә анда вафат итте дә (46). Аның анда кылган бөек хезмәтләрен Ялта, Севастополь, Симферополь кеби Кырым халкы һич оныта алмадыклары кеби, аның өчәр меңләп халкы каршына басып, һиҗанлы (дәртле, илһамлы.— *Х. М.*) нотык сөйләүләре дә мәшһүрлеге белән һәркемгә мәгълүмдер һәм танулы бөек кешеләремез Муса Бигиев вә Лотфый Исхакыйлар каршында иseme гаять атаклыдыр.

Бая сөйләгәнчә, 1837 елда авылга бик зур янгын казасы ирешеп, ансыз да ярлы авыл халкын гакылдан шашарлык дәрәҗәгә ирешдергәне кебек, андый зур янгын бер шуның белән генә калмыйча, бик күп мәртәбәләр шул янгынлар белән авыл йөдәп беткән вә бетеп килгән.

Ягмурсыз бик коры еллар да ачлык вә кытлык еллары булалар, ягмур теләп аглашып (елашып.— *Х. М.*), кайгыдан башларын астка салып, бөтен авыл бергәләшеп милчәләр артына теләккә чыгулар вә Аллага зарый кыйлулар — һәммәсе бөек бер фаҗига каршында инсанның хәлендән бернәрсә дә килмәгәнне аңлатканы кебек, 1877 елда Яңапар кырын һәм бөтен күрше авыл кырларын бик көчле боз сугуын да телгә алмыйча үтеп китә алмыйбыз.

Боз ягмуры шулкадәр көчле булган ки, олуг юлдан көтүләр кыр инешенә агып төшкәнләр. Артдагы сазга (47) сыгырлар агып, саз сыгырлар белән тулган. Кат(ы) ашлык кырын кем дә әл дә урып өлгермәү сәбәпле, бөтен кыр һәлак булган. Ул заманның 80 яшендәге картлары да мондый дәһшәтле боз яуганны хәтерли алмагайлары кебек, бозлар шулкадәр калын булуы сәбәпле, азбарларда берәр атналап эремичә торганлар.

## 5. ЯҢАПАР АВЫЛЫНЫҢ МӘДӘНИ ВӘ ИҖТИМАГЫЯТЬКӘ БАГЛЫ БУЛГАН ИСКЕРӘК ДӘВЕРЛӘРЕ ВӘ СОҢГЫ БАРЫШЛАРЫ

Әсәремезнең башындарак авыл халкының көнкүрешләре фәкать зирагатьчелек, ягъни игенчелек белән генә үтәлеп килгәнлеген вә шуңар лаек булган милчә һәм крупчаткаларының да бар булып торганлыгын язган идек.

Яңапарның иң элекке кечкенә дәверендә кырның бу кадәр зур булуы сәбәпле, авыл халкы шактый гына яхшы көн кичергән булсалар да, тора-бара авыл күпме зурайды, шулкадәр кырлары да тарая барып, бик күбесенең ягага китеп, тулмаганларын андагы казанулар белән тутыру мәҗбүриятен арт-дыра торды. Кышларын шәһәрдә эшләп, җәйләрен өйгә кыр эшләренә (48) кайтулар башдарак модага гына киткән кебек тоелса да, соңгырак елларда инде авыл янә зураеп китеп, бик күбенең тормышларын тәэмин итә алмаслык дәрәҗәгә ирешдерде дә байтак гаиләләрнең шәһәрләргә күчүләренә дә юл ачды.

Элекдә Яңапар авылы 20 ызба белән башланган булса, 1920 елларда инде тәхминән (якынча.— *Х. М.*) 580 ызбалык һәм тәхминән 3000 нөфүслек (кешелек.— *Х. М.*) зур бер авыл булды. Халкы арта барган саен, әлбәттә, хайван-терлекләр дә шулкадәр үк артып китеп, авылдан һәр иртән бик зур биш көтү чыга башлады. Тәхминән һәр көтүдә йөз сыгыр, өч йөз куй хисабы белән саналгач, бөтен авылда 500 сыгыр, 1500 куй булуы мөхәкъкак (дөрес.— *Х. М.*) булганы кебек, шуның өстенә әл дә биш йөзләп хисап ителгән алашаларның да бар булуы элекдә зур күренгән кырның хәзер инде, әлбәттә, бөтен йирен тартып-сузып, хәтта күлләрен, елгаларын киптереп бетерергә мәҗбүр булынды. Менә бу йиргә тыгызлык һәм шуның өстенә әле дә ир балаларга гына6 өлеш (49) биреп «душ» итеп бүлү тәртибе күбрәк кызлы гаиләләрне бик агыр бер хәлгә төшергәнгә күрә, алар фиркасендән дә (төркеменнән дә.— *Х. М.*) күбрәге шәһәрче булып бетәргә мәҗбүр булындылар. Менә шушы йиргә тыгызлыкларның көндән-көн арта барганы бер заманда 1912 елда хөкүмәт тарафыннан авылга бер урыс бояры килеп Чүмбәлинең керәшеннәр кырын сатачагын сөйләгән. Бу кыр искедә Чүмбәли кыры булган булса да, Чүмбәлидә керәшенләр була башлагач, авыллары аларны авылдан куган булганлар. Аларның кырларын хөкүмәт Чүмбәлидән алып, илле ел кадәр үзе биләп торгач, кире Чүмбәлигә сатарга маташса да, Чүмбәли акча түләргә разый булмагач, бояр йөрәкләнеп, бу кырның Яңапарга фәкать 3 кенә чакрым ераклыгында булуыңдан форсат табып, Яңапарга тәкъдим кылган.

Бу кырны, ягъни керәшенләр кыры дигән кырны алган кешеләр үзләре дә анда күчәргә тиешлеләр дигән кеби ялганмы, дөрестме бер хәбәр таралгач, Яңапар авылы аларга курыкганлыгы сәбәпле, бояр бу кырны теләүчеләргә кисәкләп, ягъни полсталап саткан. Бу кырның зурлыгы 28 участка, һәр участкасында 30—35 чыбык һәм участкасының буе 240, киңлеге 100 сажин булган. Алучылар шулар иде: Хисамеддин Хәмидулла (50), Җәмаледдин Йосыф, Кәмал Байбулат, Исмәгыйль Аюхан, Гыйлаэддин Мөхәммәд Габдерәхим (Кулик), Акимад, Сәгыйд Билали, Гомәр Гыйлаэддин, Зариф Сабир, Исмәгыйль мулла Гыйззәтулла, Минһаҗ һәм угыллары, Гайсә Садыйк, Хәлил Садыйк, Хәйреддин Фәтхулла, Рәхмәтулла Динмөхәммәд.

Бу кыр алучыларга бәрәкәтле вә бик табышлы йир булып чыкганга күрә, аның файдасы һәм бөтен авылга тиеп, вазгыятене шактый гына яхшыртып йибәрде. Бер якдан, авыл иген белән түләсә, икенче якдан, авылның ачылып китүенә бу бик күп ярдәм итде. Ләкин бу кырны большевиклар чыгу белән үк, Чүмбәли халкы йир ияләрендән кире тартып алды.

Яңапарның Эрбитшәгә бара торган юлында тау борынында Куйсуы юлының чатында керәшенләр кабере дигән бер йир булып һәм анда берле, икеле каберләр булуын аңлаталар. Бу каберләрне Чүмбәли керәшенләренең кабередер диеп уйлау хатадыр.

**Яңапарның атаклы иген байлары:**

Яңапарның мәшһүр иген байларындан беренче Пасла бабай булган. Аның алты углы һәм бер кызы булып, бик куәтле иген бае булган. Бер елда бердән утыз богылын (көлтә кибәнен.— *Х. М.*) бер дошманы (52) яндырса да, икенче елны янә утыз богыл салган.

(Китапның 51 нче битендә — Садрый Хәмид тарафыннан ясалган «хыялый рәсем». Ул Яңапарның гомуми күренешен чагылдыра. Рәсем астында мондый юллар бар: «Яңапарның Эрбитшә тавы башыннан күренеше. 1921 елда. Өч мәсҗеде һәм дүрт милчә күренеп тора...» — *Х. М.*)

Икенче иген бае Салават бабай булган. Өченче бай — Мәтүснекеләр (?). Дүртенче — Гүбәш бабай. Бишенче — Габдехан бабай. Алтынчы — Йосыф бабай. Йиденче — Канук бабай. Сикезенче — Җәли бабай (Балук). Тукызынчы — Айнуш бабай. Унынчы — иген белән сәүдә итүче Аюхан бабай. Унберенче — Ташбулат бабай. Уникенче — Габдеррәвык бабай [Монысы язучының кунак бабасы.] Унөченче — Сафиян бабай. Ундүртенче — Патус бабай. Унбишенче — Йосыф бабай Аблас углы. Уналтынчы — Камус бабай. Унйиденче — Салый бабай. Унсикезенче — Әмин бабай. Унтукызынчы — Кулик глава вә Хәмидулласы. Әхмәр бабай — боларның бабалары —мәшһүр иген бае булып, иген һәм куйлар белән сату иткән вә, авылга иң беренче мәртәбә милчә коручылардан булып, ярты гомере милчәдә үткән.

Егерменче — Батырбай бабай — кызыл мал берлән сәүдә итүче булган. Егерме беренче — Керпе Гайсасы. Авылда зур кибет тоткан, кызыл мал белән сату иткән.

**Авылның һөнәр ияләре:**

Авылда Кулик нәселе мәшһүр һөнәрчеләр диеп саналган кеби, көмешчеләрдән, шөбһәсез, Тагун Хәлиленең углы Гомәр (53) иде. Агач осталарыннан Арыслы (?) Сибаты вә балалары, пич салучылардан Шири Хәйреддине Масул вә угыллары, тимерчеләрдән, ягъни кузничлардан, Тагун Хәлиле вә ике урыс кузничы һәм тегүчеләр, башмакчылар, чабата тугучылар, аш-су кибетчеләре кеби эшкә сәләтле кешеләр үзләренә йитәрлек кадәр булып торганы шикелле, ягага киткән сәүдәгәрләрнең мәшһүрләре бар иде.

Әсәремезнең 7 нче битендә Мортаза буасы исемле күл хакында язып узган идек. Менә шул күл шактый гына зур һәм тирән булганга күрә, шунда каз-кошлар асралып, күл әйләнәсендә йебләр буяучылык белән кәсеп итүчеләр дә булган. Ул вакытларда, ягъни XIX гасырның ахырларында да, әле дә буяучылык бик алга китеп, буялган йебләрдән төрле-төрле киемнәр текдерү аркасында, кибет малларына, ягъни ситса вә фәләнләргә, халыкның ихтыяҗлары булмаган. Хәтта шул маллар белән алыш-биреш дә кыйлганлар. Ул вакытларда әрмәнләр, кызыл йебләр белән сату итеп, Мәдәнә тавына ярминкәләр коралар икән. Шунда халык бик күп җыя торган булган. Ләкин Мәдәнәдә ул вакытда салаванлык, ягъни аракы кибете булганлыкдан, ярминкәгә җыелган халыкның бозылып китүендән куркып, Мәдәнәнең Габделвахид мулла аракы кибетен 1840 елда яптырып, ярминкәне дә бетергән (54).

*Муртачылар* (умартачылар.— *Х. М.*): Яңапарның мәшһүр муртачылары Фәтхулла байда илле мурта булган. Мөхәммәд Әминдә һәм Туктар углы Йосыф бабайда да байтак кына булып, Арслан Сибатында вә Хөҗҗәтулла Салават утарларында да (моны язучының әнисенең кыз туганы Мәрхәбәләрдә) берничәләп бар булган.

*Абдалчылар:* Яңапарның һәм бөтен тирә-як авылларының мәшһүр оста абдалчыларындан, ягъни бала сөннәтләүчеләрендән Абдрук (?Абдыравык.— *Х. М.*) баба, ягъни Габдерәхим бабай булган. (Моны(сы) язучының кунак бабасы.) Ул вафат булгач, аның углы Исмәгыйль янә атасы кебек үк бик зур шөһрәт казанды, болардан башка Гали Ходайбирде һәм Мәки Билалы да шул вазыйфаны үтәп килделәр.

*Хаҗилар:* Яңапарда 6 хаҗи булып, аларның исемләре шунлардыр: 1) Исмәгыйль Хаҗи үзе өчен һәм Пичәнең (?) Мөлүк (?) вә Суксуның Мөхеддин өчен бары 3 мәртәбә хаҗга барган, 2) Мөхәммәд Әмин, 3) Бавас, 4) Сәмәрхан, 5) Сәйфулла углы Нуреддин, 6) Гали углы Нуреддин (55).

**Мәктәп вә укыту эшләре.**

Яңапарның иң мәшһүр мәктәпләрендән саналган мәктәп Гарифулла мулла мәктәбе булса, икенчесе дә, шөбһәсез, Ваһаб мулла мәктәбе иде. Исмәгыйль мулла мәктәбе белән Шәрифҗан мулла углы Лотфулла мулланың да мәктәпләре заманларына муафыйк укытулардан бик үк артка калышмаганлыкларындан, Яңапар халкының агару вә укымышлык җәһәтләре башка күрше авыллардан һаман да һаман өстдә булып торды. Бу дүрт мәктәпләр шулай бер-берләре белән үзара уздырыш кыяфәтендә укытып яткан заманнарында да, хосусый хатын укытучылары тарафындан өйләрдә кызларга сабак бирүләр искедән бирле дәвам итеп килә торганы сәбәпле, авылда укый белмәгән хатын-кызлары бик сирәк иде. Егетләргә язу язмасын дип искедә кызларны фәкать укырга гына өйрәтеп, язуны һич өйрәтелмәгәнлекдән, яза белүче хатын-кызларның саны юк хөкемендә бик аз булып торды.

Мәрхүм имам Лотфый Исхакый хәзрәтләренең кузгап (кузгатып.— *Х. М.*) йибәрүе вә тырышуы аркылы Гыймад Җәмал, Мостафа Исмәгыйль, Фәттах Гарифулла, Кәмал Байбулатларның тәшәббесләре (инициативалары.— *Х. М.*) нәтиҗәсендә Финляндия мөселманнарындан һәм авыл халкындан акча җыелып, Таулы Хәсәнинең йортын сатып алынгандан соң, 1909 елда (57) шул йортка Лотфулла мулла мәхәлләсе исеменә кызлар мәктәбе салды. Бу мәктәпне салдыруда багыш-көреш итүчеләрдән Йосыф Җәмалы, Аюхан Исмәгыйле, Юныс Закиры һәм Сәгыйд Билаллары булдылар.

Шул мәктәп тәмам булганнан соң, 1910 елда беренче уларак мөгаллимәлеккә Бубиның Рәйхана туташ Батыршина килде, (Шушы биттә Рәйхана Җәмаледдинның фоторәсеме дә бирелгән. Калфаклы яшь кенә кыз.— *Х. М.*) Ике ел мөгаллимәлек вазыйфасын бик уңышлы итдереп үтәгәндән соң, ул Җәмал углы Хәсәнгә иргә чыкса да, шушы аз дәвердә дә үз урынына яраклы бик шәп мөгаллимәләр йитешдереп калдыруы аркасында, мәктәп бик дәвамлы булды, һәм бөтен авылның хатын-кызларының бик тиз агарып вә ачылып китүләренә һәм бик җиңеллек белән матур төстә яза да укый белүләренә уйланмаган кадәр аның, ягъни Рәйхана Җәмалның файдасы тиде.

1917 еллар тирәсендә шул ук кызлар мәктәбе якынында кызларга муафыйк һөнәр мәктәбе салынган булса да, аның башлангычы һаман соңга кала барганлыгы өчен, соңгы вазгыятьләрдән хәбәремез (58) юкдыр.

Бөтен тирә-як авылларга мәшһүрлеге белән исеме таралган Гарифулла мулла мәктәбенең мөгаллимнәре шулар иде: искерәк дәвердә Гарифулла мулла үзе һәм углы Мортаза. Яңа мәктәп салдыргандан соң, олуг углы Мостафа, 1909 елларда Казандан укып кайтып, яңа ысулы җәдид белән бик нык итдереп мөгаллимлек вазыйфасын үтәргә тотынды. Ысулы җәдидне Яңапарга китерүчеләрдән иң беренче ул булды. (Моны язучы да аның бөек шәкердләрендәндер.)

Исмәгыйль мулла мәктәбендә Хәлил исемле кеше мөгаллим булып торганы кебек, Ваһаб мулла мәктәбендә дә күбрәк вакыт Ваһаб мулланың үзендән гайре ягадан алынган мөгаллимләр белән эш күрелде. Лотфулла мулла үз мәктәбендә мөгаллимлекне үзе үтәп килде.

**Авылны идарә итү эшләре.**

Яңапар халкы искедән бирле бик күп бәла вә казаларга очрый килеп, һәр эшләрендә Аллага гына тапшырылуга өйрәнеп беткәнлекләренә күрә, алар бик күп агырлыкларга баш бөгүдән башкага гафиллар иде. Авыл каракларына, ут төртеп яндыручы усалларга ялынып, ялварып, алардан куркып торалар. Тәэссефле (үкенечле.— *Х. М.*) гади бер эш булып беткәне кебек, авыл (59) куштанларының да тезгенне үз теләгенләренчә тотулары халык өчен биек (зур.— *Х. М.*) бер бәла вә богау булып торды. Бу кеби хәлләр тирә-күрше авылларында да, әлбәттә, булып торганы өчен, бу Алладан йибәрелгән гомуми бәла хакында бу әсәремездә язып торуның хаҗәтен күрмимез.

* * *

Яңапар 1866 елларда әле дә Яндавишчә волос(т)е булган. 1865 елларда Уразавыл волос(т)ена күчкән. 1873 елларда авылда Аюхан Госманы голова булган. Аның артындан Аюхан Бигелде (Гайса Садыйкның бабасы) головалык хезмәтен иткән. Андан соң головалык Кызылъярга күчкән. Кызылъярдан соң головалык янә Яңапарга күчеп килеп, Салый утлы Гыйлаэддин (Таз Гомәрнең атасы) һәм аның артындан аның атасы Салый голова булган.

Мондан соң головалык янә Кызылъярга күчеп, Шәрәфеддин голова булган. Аның артындан головалык Уразавылга күчеп, Уразавылның Ризван Шәрифе һәм аның артындан Сәлахеддин Нуреддин Мәгъдиев углы булган.

*Авылныц старосталары:* Мәтүс Нуркае, Тамка (артлы-алынлы), Тала (Хәлиулла Җалук), Җалук Бәдри, Таз Исмәгыйль, Сәлимҗан Бәдри вә башкалар (60).

*Авыл куштаннары:* Аюхан бабай, Әхсән Габдерүш, Ходайбирде Араслы, Тала, Туктар Йосыфы, Йосыф Җәмалы, Сәгыйд Билалы, Дәүләтшаһ Макҗаны, Тимук Җәләе, Аюхан Исмәгыйле һәм Вафасы, Бали Сәүбәны, Сабир Зарифы, Нуркай Хәйреддине, Габделмән Хәйреддине, Җидекан Ногманы (вакыты белән голова да булган). Имамеддин Нарим байның өендә искедән калма (калган.— *Х. М.*) җыен урыны булып, гомерлек янгын сараенда уртаклыкда кызыл мәсҗед площадындадыр. Шуны да әйтеп узарга онытылган ки, Яңапарның башлангычы шул тирәләрдән булган!

*Авыл караклары:* Яңапарның XIX гасырның соңгы вә XX гасырның мәшһүр каракларындан — Арслан Сибатиның борадәре һәм Шири углы Әюбнукы, Чокын Сабиры вә Сәүбән Батырбае кеби берничә каракларны мәҗмугы 10 гаилә хатын вә бала-чагалары илә 26 җан, Шәрәф голованың тырышуы аркасында, авылдан Себергә югалтканнар (озатканнар.— *Х. М.*). Болардан башка да авыл кечкенә каракларбан һәм үчләнеп яндыручылардан өзелмәде.

*Тораташ.*

Яңапарның көнчыгыш ягындагы биек тау итәгендә (61) тарихы һичкемгә мәгълүм булмаган Тораташ исеме берлән йөретелгән бер таш һәйкәл бар. Бу һәйкәл ташы кеше кыяфәтенә охшаган

булып, элекдә басып тора торган хәлендә булган булса да, соңгы заманларда сузылып йиргә яткан вә кул-аяклары сынык хәлендә иде. Аның хакында халык телендә: «Анасы баласын Торараташ бул!» — диеп каргап өйдән куылуы, куылгач да бала бу йиргә йитеп ташка әверелүе кеби кызганычлы хикаяләр сөйләндекдән, аны багарга баручылар тарафындан кызганыч таш өстенә сәдакалар куеп китү гадәте бар булу сәбәпле, шул акчаларны эзләүчеләр ташны екмышлар һәм зыянламышлар.

Бу Тораташ елгага якын булу сәбәпле, аның ел саен бер атлам сикереп елгага таба якыная баруы вә елгага төшкәч ахырзаман булуы хакында халык агызында сөйләнелеп килгәнгә, ахырзаман кубудан куркып, 1912 елда Кәстәк Исмәгыйленең углы Габдулла тарафындан Тораташның әйләнәсенә чардуан тотылды.

Большевиклар заманында бу Тораташның астын казып, астан ат зурлыгында зур таш һәм таш астындан күмер чыкмыш. Ләкин ул елны ягмур һич ямагач, сәбәбе шундадыр диеп куркынып, кире күммешләр вә иске хәлендә калдырмышлар (62).

Бу кеби Тораташ Яңапардан 8 чакрым ераклыгындагы Пашат авылының якынында һәм бар булып, ул исә төзселәнгән (төссезләнгән? — *Х. М.*) сыйфатдадыр.

Тарихы мәгълүм булмаган бу тораташлар хакында без, әлбәттә, каргалып ташка әйләнгән балалардыр диеп ышана алмыймыз. Бик иске заманлардагы сугышларда шунда үлеп калган бөек каһарманнар өстенә куелган һәйкәлләрнең булуы гакылга муафыйк кебек, искедән дә бәлки тау араларында качып торучы дәрдле бер «беглай» (качкын.— *Х. М.*) яхуд дәрдле бер көтүче тарафындан кызыксынып вакыт үткәрер өчен эшләнгән кеше сурәтләренең булуы да бик мөмкин.

Бу тораташларның Яңапар һәм Пашатда булулары искедән калма бөек бик кыйммәтле әсәрләр булдыгы өчен, аларны нык итдереп саклау бу ике авылның әдәби вә вөҗдани бурычларыдыр.

**Яңапардан чыктан каләм әһелләре:**

XVIII (—XIX.— Х. М.) гасырларда Яңапарның Мулай (?Мәүләй.— *Х. М.*) углы Ризван[7], бик галим булуы сәбәпле, бик күп китаплар язып, язган китапларын Казанда басдыра торган була. Китапларының сыртына шулай языла икән: «Нижний губернасы, Сергач өязенең Актук карьясе Ризван Мулай углы хөраҗате илә...» (63). Аның басдырган китаплары бик соңгы вакытларга кадәрле дә, әле дә кулда йөретелгән булганлыкдан, аларның бик уңышлы һәм файдалы әсәрләр булган булулары шөбһәсездер.

Бу тарихны язучының 4 нче бабасы Мулай һәм аның Ризван исемле углы да бар булганлыгы сәбәпле, бу китапларны язган кешенең дә шул Ризван булуы шөбһәсездер. Мулай бабай үзе Мар күперендән югары менеп күпер салдырган булган. Бу — Мулай күпере исемле күпернең калдыклары әле дә бардыр.

Шулай ук моны язучының кунак бабакасы Габдеррәхим дә үзенең йорты тугрысына Ишмәт тагына зур кое казыган булган. Бу әлегә кадәрле дә Габдеррәвык кизләве исеме белән йөретелгән тозлы һәм гаять шифалы кизләү авылның бүген дә иң мәшһүр вә мөһимләрендәндер.

* * *

Әсәремезнең 45 нче битендә зикер ителгән (әйтелгән.— *Х. М.*) Ягъкуб мөәззиннең олуг углы мәрхүм Габделкоддус әфәнде, Кырым газеталарында (64) шиддәтле (көчле.— *Х. М.*) милли мәкаләләр язып торуы өстенә, 1925 елда Хәсән Хәмидулла тарафыннан Финляндиядә чыгарыла башлаган һәфтәлек (атналык.— *Х. М.*) «Мәгърифәт» газетасына да милли мәкаләләр язып торды. (64 нче биттә «Коддус Ягъкубның рәсеме» бирелгән.— *Х. М.*) Финляндия мөселманнары Коддус әфәндене үзләренә муллалыкга чакыру нияте белән маташсалар да, араларында ике партиягә аерылулары сәбәпле, аңар ул хезмәт насыйп булмады.

* * *

Яңапарда туган вә үскән булып да, соң гомерләрендә татарлыгындан бөтенләй ваз кичеп, үзен фәкать төрек вә төркияле генә диеп таныган Төркия тәбәгале (тарафдары, гражданины.— *Х. М.*) *Зиннәтулла Гыймадеддин углы Бүре* дә Финляндиядә тәхминән (чама белән.— *Х. М.*) 1934 еллардан башлап каләм әһеле булырга тәшәббес итде (кереште.— *Х. М.*). Аның 10 лап чыкган рисаләләре латин хоруфаты (хәрефләре.— *Х. М.*) илә төрекчә вә финчәдән генә гыйбарәт булып, рисаләләренең максады фәкать үзенең (64) Финляндия Җәмәгате исламиясенең мөтәвәллияте (идарәсе.— *Х. М.*) вә әгъзалары берлән тартышканлыгын аңлату һәм үзе рәсмиләшдергән «Фин-төрек халык мәктәбе химая җәмгыяте» исемендәге вөҗүдкә (дөньяга.— *Х. М.*) чыга алмый торган мәктәбен гамәлгә ашдыруга тырышу иде.

Менә шушы юлда узышкан вә алышкан хатларыны нәшер итела барудан мөрәккәб булган (тупланган.— *Х. М.*) бу рисаләләре өстенә ул 1934 еллар тирәсендә Төркиядән хосусый мөгаллиме азәрбайҗанлы Мөхәммәд Садыйкның ярдәме белән Тампере шәһәрендә «Туран» («Turan») исемле латин хоруфатында (хәрефләрендә.— *Х. М.*) газета чыгарырга муафыйк булса да, айга берне генә чыгару нияте белән башланган һәм хакы бер генә марка торган бу газета, халыкның теләмәүлеге сәбәпле, өч номра (номер.— *Х. М.*) белән тәмам булды. Ул Хәсән Хәмидуллага

ачынып язган бер мәктүбендә: «Син, Хәсән әфәнде, Финляндиядә газета чыгаручылардан тарихда иң беренче булсаң да, мин дә, шөбһәсез, икенчемен»,— диеп, шул шадлыгына да канәгать иткәнлеген белдерде. Шундан соң ул, үзенең бөек бер теләген вөҗүдкә чыгарыр өчен, финчә Коръән тәрҗемәсен чыгару хезмәтенә ябышды. Бу хезмәт аның өчен бик агырга килеп, үзенең ни бар сәламәтлеген шунда югалтса да, эшендә күп еллар нык итдереп дәвам иткәндән соң мороды хасыйл булып, гүзәл вә мөкәммәл рәвешдә финчә Коръән дөньяга тугды (66). Гаять бай һәм үткен сәүдәгәрлеге һәм шулкадәре үк тугрылыкны өсткә чыгаруда фәүкылгадә (гадәттән тыш.— *Х. М.*) үзсүзлелеге аркасында байлар тарафыннан эшләнгән ләгънәтле бойкотлар эчендә газап чиккән вә 1916—1920 елларда Тирйокиның (Финляндиянең көнчыгышындагы шәһәр исеме. Анда татарлар күпләп яши. Фин-совет сугышыннан соң биредәге татарлар Финляндиянең башка шәһәрләренә күчеп китә.— *Х. М.*) указлы мулласы да булып торган бу заты шәрифнең (асыл затның.— *Х. М.*) вакытсыз 59 яшендә үлүе Финдәге колониямез өчен зарар булды.

[Китапның 66 нчы битендә «Зиннәтулла Әхсән Бүренең язу ысулыннан вә җөмләләрне төзү тәртибендә бер нәмүнә» бирелгән. Бу хат 1943 елның 13 нче декабрендә Тампере каласында латин хәрефләре белән язылган. Төрек теле йогынтысындагы бу хаттан аерым юллар (алар өлешчә татарчалашдырып бирелә). «Мөхтәрәм мөһәндис (инженер.— *Х. М.*) бәй Хәсән. Кыйммәтле ачык мәктүбегезне укып хәйрәт иттем (таң калдым.— *Х. М.*)... Коръән Кәримне 60 мең нөсхә бастыргансыз икән, гаять бөек һиммәт, моны васыф итмәк делләр йитешмеш (моны сыйфатларга көч җитми.— *Х. М.*). Дөньяның иң бөек миссионер җәмгыяте дә урысча дини китаплар(ны) бары 100 мең нөсхә басдыра белде. Аны да Инглиз вә Америка парәсе (акчасы.— *Х. М.*) белән. Сез исә ялгыз башыгыз белән дөнья миллионерларын уздырдыгыз. Афәрин һиммәтегезгә, исемләрегез дөнья, туранча, ислам дөньясы телендә бакый калачакдыр...»]

(67) Яңапарда туган вә үскән һәм аның бөек тәрбиясе риясәтендә (биредә: «тәэсирендә» мәгънәсендә.— *Х. М.*) кешелек дөньясында матбугатка чыкган Бәдреддин углы Садреддин, «Садрый Хәмид» исеме белән Финляндиядә шигырьләр язып, матур шигырьләре берлән милләтемезнең барлыгын арттырды.

Үз тормышын яхшы гына сәүдәгәрлеге аркасында алга алып барган бу Яңапар шагыйренең башка бөек тойгылары булган рәссамчылык, филадисычылык (филателия белән шөгыльләнү.— *Х. М.*) вә музачылык (музыкачылык.— *Х. М.*) дәрдләре дә бик көчле булганга, Яңапарның йөзенә бу мөхтәрәм зат аркылы кызыллык килмәве мөхәкъкак (дөрес.—*Х. М.*) вә шөбһәсездер.

Әлегә кадәр чыгарган шигъри әсәрләре: «Дәфтәре номра — I», «Татар теле», «Закир», «Хаким», «Үткән елдагы хәбәрләр», «Без», «Яз хәбәрләре», «Мачы белән тычканлар», «Фәкыйрьлек», «Үткән елның хәбәрләре», «Дәҗҗәләр», «Ярлылык», «Яз башы», «Калдык», «30 ел Финляндиядә», «Олимпиат» вә башкалар (68).

«Садрый Хәмиднең шигырьләрендән бер нәмүнә (үрнәк) («Дәфтәре номра — V» тән):

Гөнаһлар күп, кайсы бездә тәмам тездән,
Вакыт йитеп үлеп китсәк әгәр тиздән,

Җанлар чыкгач сузлып ятыр гәүдә-сөяк.
Кабер казып куярлар соң йиргә сөяп.

Сөйләргә без берни юкдыр анда барып,
Фәрештәләр керер хәзер йирне ярып.

Ни әйтербез төрле сөаль сорасалар,
Йөрәкләнеп камчы белән сыласалар.

Бу әсәрне язучының үз әсәрендә үз кулы белән үзе хакында мәгълүмат бирү әдәб ягындан да, матбугатка ригая итү (хөрмәтләү, олылау.— *Х. М.*) ягындан да бәлки бик үк килешеп бетмәсә дә, мәсьәлә Яңапарның каләм әһелләре хакында булганга күрә, ул бабны (бүлекне.— *Х. М.*) ансыз тулы итдереп чыгарып булмау куркынычы барлыгындан, моны язучының исемен дә шунда кертми хәл булмады. Шуның өчен хөрмәтле укучыларымның гафуларын үтенәм!

Яңапарның Гарифулла мулла мәктәбенең иң биек (зур.— *Х. М.*) шәкердләрендән *Хәсән Низамеддин углы Хәмидулла* (Кулик) 1915 елда 15 яшендә Финляндиягә килеп, шул килү белән анда (69) бөтенләй калгандан соң, эчке тойгыларына чыдаша алмый 1925 ел гыйнвар 16 да Кими шәһәрендә һәфтәлек (атналык.— *Х. М.*) «Мәгърифәт» исемле сәяси, милли вә әдәби газета чыгарырга тотынды. Ләкин абунәчелеккә (подпискага.—*Х. М.*) язылучыларның саны аз булу сәбәпле дә һәм татар телендә синзур (цензор.— *Х. М.*) табыла алмаганлыкдан, фин хөкүмәтенең газетаны туктатып торырга йибәргән әмере сәбәпле дә, 3 ай дәвам итдекдән соң, шул ук елның апрель 17 сендә 12 номра белән моны, ягъни фин вә

Скандинавия дәүләтләрендә татар телендә тарихда иң беренче мәртәбә чыга башлаган газетаны туктатырга мәҗбүр булынды.

1943 елда Скандинавия дәүләтләрендә тарихда янә беренчеуларак 20 мең данә гарәбчә Коръәнләр басдырып, Икенче дөнья сугышында әсирлеккә төшкән мөселман әсирләренә бушка тараткандан соң, үзенең «Яңа Иман шарты һәм белемләр» исемле әсәрләрен дә меңләрчә әсирләргә вә бөтен дөньяга таратды.

Шулай ук 1943 елда янә бу мәмләкәтләрдә тарихда беренче булган «Шималь очкынлары» исемле мәҗмугасын да (70) («журналын» мәгънәсендә.— *Х. М.*) хосусый һәм үзе баш мөхәррире уларак чыгара башлады. Үзенең кечкенә матбугасы һәм кул көче берлән баса вә бөтен дөньяга «ихтыяр түләү» шарты белән тарата барган үз шигырь вә әсәрләренең саны вә хисабы да бу әсәрнең тышындагы игъландан мәгълүмдер. (Бу исемлек китапның ахырында бирелгән.)

ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘН БЕР НӘМҮНӘ

[«Моңлы таңлар»дан «Яралы нәфәс» (җан, рух.— *Х. М.*)].

Нахаклардан газап чиксәң, эчелсә канларың бушка,
Бөтен ялган вә гайбәт-ифтиралар (гайбләр.— *Х. М.*)
борчыса юкга,
Бетәр тәм дөньядан, киселер өмидләр һәм иминлекләр,
Качар дуст, шадланыр дошман, бетәр абруй вә минлекләр.
Җәһәннәмгә дүнәр тормыш, яшәрсең (?) утлы күлмәкдә,
Бөтен әтрафларың тулган — хәүф вә куркыныч беттә...
Чыдар берсәккә (беразга.— *Х. М.*) инсан, бу золым, агыр
сулышларга.
Бетәр ләкин чыдамлык, бу тотынса инде эшләргә,
Саярыр шунда иманлар, ышаныч бетәр Аллага,
Сүнәр соңгы өмидләр дә, имеш, Алла сынап бага!
Җуатмас һич күңелләрне, сабыр җәмил (гүзәл.— *Х. М.*)
дигән сүзләр,
Качу, ятсыну, ялгызлыкны гына инде ул эзләр...

[Китапның 71 нче битендә Коръәннең титул бите бирелгән. Анда болай язылган: Каләме шәриф. Кәнди мосарыфлары (үз чыгымнары.— *Х. М.*) илә фотограф ысулы белән Казан басмасындан күчертеп эш итүчеләр: Хәсән Низамеддин Хәмидулла (Нижний вилаяте Сергач өязе Актук авылы) вә хатыны Өммегөлсем Гыйззәтулла Шәйхмамет (Пенза вилаяте Краснослобот өязе Лановка авылы). Басылган урыны: Финляндиядә милади 1943 елда.]

(Китапның 71 нче битендә «Басылып таратылган гарәпчә Коръәнләрдән берничә нәмүнә» бирелгән.— *Х. М.*).

(72) ***Наширләрендән бер теләк:***

Мөселман сәүдәгәрләренең Финляндиягә килә башлауларына бу сәнә 75 ел тулу мөнәсәбәте илә вә килүчеләрдән дә иң беренче уларак Нижний вилаятендән Сергач өязе, Актук карьяле мәрхүм Хәмидулла Габдеррәхим (Кулик) углы безнең бабамыз булдыгындан аның хөрмәтенә вә аның безгә бәхетле юл күстәреп (күрсәтеп.— *Х. М.*) калдыруына догалар әйтеп, ошбу Коръән Кәримне Казан басмасындан фотограф ысулы белән янда йөретерлек кечкенәрәк шәкелдә (формада.— *Х. М.*) күчерелеп һәм меңнәрчә данә басдырып, хәзерге дәвам итә торган бөек сугышларда Финляндия вә Алман (Германия.— *Х. М.*) кулларына әсир булып төшкән мөселман кардәшләремезгә һәдия уларак өләшүне үземезгә бурычлы итеп күрдек. Вә һәм шуның чарасына башладык.

Сугышларның дәһшәте сурәтдә дәвам итүе вә миллионнарча әсирләрнең дә меңләрчә баракларда төрле-төрле җенесләр белән катнашдырылып мәмләкәтләрнең һәрбер почмакларына таратылулары сәбәпле, эстәдекемез максадка ирешә алмавымыз табигыйдер. Вә мәгаттәәссеф (үкенеч ки.— *Х. М.*), ирешә алмаячакмыз да. Ләкин шулай булса да, чарасына керешелеп, мөмкин кадәр күбрәк итдереп таратырга иҗтиһад идәчәкмез вә шул изге юлда башкаларның да безгә ярдәм итүләрен түбәнчелек илә үтенелеп, түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итүләрен сабырсызлык илән көтеп каламыз: Хәсән Хәмидулла, шәһре «Кими», Финляндия. [Китапның 73 нче битендә «Низамеддин Хәмидулланың Яңапардагы йорты» (хыялый рәсем) бирелгән. Койма белән әйләндереп алынган зур ихата. Ике катлы йорт. Кое. Агачлар. Сарайлар, мунча һ. б.— *Х. М.*] (74)

**6. АКТУК БАБАЙНЫҢ КАЙДАН КИЛҮЕ**

Әсәремнең 31 нче сәхифәсендә Актукның кайдан килеп чыкганлыгы хакында бәхәс итүне соңгарак калдыру белән вәгъдә иделгән булса да, бу мәсьәлә хакында сәясәтнең бик күп эченә кереп китү хәүфе

булганлыкдан, ул хакдагы бәхәсләрне, мәгаттәассеф (үкенеч ки.— *Х. М.*), бик күп кыскартып, фәкать мәфһүменгә (эчтәлеген, асылын гына.— *Х. М.*) аңлатып узарга тиеш күрелде.

Мәскәү падишаһы 4 нче Иванның әмеренә буйсынудан качып юлбасарлык итеп, талап йөрүче 5000 качак үзләренең олуг башлыклары булган Дон казагы атаман Ермак Тимофеевичның идарәсе астында Строгоновларның ярдәме белән Себергә таба татарларны талау нияте белән хәрәкәт иткәндән соң, 1580 елның август 1 ендә Себердәге татар шәһәре Төмәнгә йитеп, аны сугышып татарлардан алгач, ул йирне алар бик мәгъкуль күреп, шунда ук алар кышларга да калганлар.

Менә шул кышлау нәтиҗәсендә Ермак Төмән татарларының бик күбен үзенә көчләп буйсындыргач, алар һәм забыт ителә (буйсындырыла.— *Х. М.*) барган башка татарлар берлә Ермак өчен Күчем ханның (75) ханлыгын җимерүгә зур ярдәм иткәнләр.

Күчем ханга хыянәт иткән вә аның ханлыгының җимерелүенә бик күп сәбәп булган һәм Күчемнең актыккыгы сулышларында Күчем ханга каршы гайрәт белән сугышкан татарларга Мәскәү падишаһы Феодор рәхмәт укып Себердәге урыс гаскәре башлыгы Феодор Елетскийга (Елецкига.— *Х. М.*) 1595 елның август 16 сында түбәндәге шадланып язган ярлыкны йибәргән: «...Сезгә безнең шушы ярлыкымыз барып йиткәч дә, сез Борис Дамажировка ушандак хезмәт күрсәткән кешеләргә, Тобольск, Төмән, Тара шәһәрләрендән сугышка баручы бояр балаларына, атаман һәм Литва казакларга, сугышка иштирак иткәнләрнең (катнашканнарның.— *Х. М.*) барчасына безнең рәхмәтемезне ирешдерәсен(ң). Без анларга шушы хезмәтләре өчен олуг вазыйфалар ихсан (ярдәм.— *Х. М.*) итеп, мондан соң да анларга үземезнең ингамларымызны (игелегебезне, бүләгебезне.— *Х. М.*) йибәрермез. Анлар киләчәк заманларда да безгә шулай хезмәт итеп, яңа шәһәрдә олуг саглык илә терек итсеннәр. Күчем хан һәм нугайларның хәрәкәтләрен безгә белгертә торсынлар...» — диелгән.

Падишаһ Феодор, чындан да, бу сүзендә торып, аларга үзенә ярдәмдә булынмаган татарларның йирләрен алып бүләк итеп бүлгәндән соң, йирләре алынган вә яхуд йирләре кечерәеп калган татарларның бәгъзеләрен мәҗбүри вә бәгъзеләрен (76) үз ихтыяҗлары белән Русия эченә күчергән вә анда аларга күп йир бирүләр белән вәгъдәләр дә иделгән һәм шуның белән кызыкдырылган да.

Йирсез калган вә яхуд йирe таланып фәкыйрьлекнең соң дәрәҗәсенә ирешкән түмәнле Актук бабай да, вәгъдә иделгән күп йирләргә кызыгып, Төмәнгә йирләшеп калган җиһангиз качаклардан бу йирләр хакында алынган мәгълүматларга таянып, үз ихтыяры берлән кардәшләрен янына алган да Төмәндән бу урынга күчеп килгән һәм шунда утырып да калган. Аның артындан башка Төмән татарлары да күчә башлаганлар...

Татар ханлыклары төрле йирдә җимерелә барганы саен... татарларның көчләрен мәңгелеккә киметү сәясәте белән йирләрендән вә ватанларындан урыс мохите эченә мөкяфәтләр (бүләкләр.— *Х. М.*) вә йир байлыклары берлән кызыкдырылып һәм мәҗбүр дә иделеп адаштырыла барган вә шунда урынлашып кала барган тирә-якдагы татар авыллары кебек үк, Яңапар да шушы сәясәтнең бер корбаныдыр (тәмам).

***Дикъкать:***

Яңапарның 300 еллык бәйрәмен ике мәртәбә эшләп була: һиҗри ел 1378 дә—милади ел 1967 дә.

(77 нче биттә «Якындагы мөселман авылларының Яңапардан ераклыгы чамалау үлчәү белән» күрсәтелгән. Түгәрәкнең уртасында—Яңапар. Радиуслар рәвешендә якын-тирәдәге татар авылларының исемләре, ераклыгы аталган. Мәсәлән, Суксу — 7, Мәдәнә — 10, Чүмбәли — 7, Эрбитшә — 12 һ. б.— *Х. М.*) (78)

**ГЫЙЛАВӘ** (өстәмә.— *Х. М.*)

Яңапарның тарихы, шөбһәсез, бар булырга кирәк, тарихсыз авыл төбсез, нигезсез авыл дигән бер фикер миндә бик күп еллардан бирле миемә кереп утырганга, шуның тарихын вөҗүдкә чыгару хакында мәгълүматлар җыюлар вә хәзерләнүләр дә бик күп еллардан бирле дәвам итеп килде.

Тарих язар өчен кирәкле булган материалларның меңләрчә чакрым ераклыгында булулары мине бәгъзән бик өмидсез хәлгә дә төшереп, шулай да мондан 39 ел элек үз күзем берлән күргән вә белгәнләрем бүгенгесе көндә дә картина кебек әле дә күз алдымда торганга вә шуның өстенә әле дә картлардан сорашып алган мәгълүматларның да көчле рәвешдә кучага (бер җиргә.— *Х. М.*) җыелып шешләр тула барганга, минем ул өзелгән өмидләрем шундан куәтләнеп китеп, хыялый рәвешдән ерак китә алмаслык булса да, шушы тарихны язуга тәшәббес итдем (керештем.— *Х. М.*).

Башдарак бу тарихны «Шималь очкынлары» мәҗмугамның 4 нче санындан башлап китеп, аның белән генә дәвам итдерү фикерендә булган булсам да, бәгъзе бер туган илләрен сөючеләр тарафындан килгән риҗалар (үтенечләр.— *Х. М.*) аркылы да вә һәм (79) үзем дә инде шул ук фикергә килгәнемә күрә, башлаган бу мөкатдәс эшемне инде мин аеруча бер әсәр итдереп тизлекдә чыгару кирәклеген тиеш таптым һәм шуның мәҗбүриятендә дә калдым.

Көнләр үтеп китде. Тизлекдә чыгару нияте белән башланган бу әсәремнең эченә керә барганым саен, бик күп читенлекләр һәм бер-берләрен мәхү итә (бетерә.— *Х. М.*) торган төрле-төрле мәсьәләләр чыга торып, шуларны тикшерүләр һәм, шуларның хакыйкатенә төшәр өчен, янә картларымызга мөрә-

җәгать ителүләр, шуның өстенә әле дә Финляндиядәге балакайларымызга да ата-аналарының сөекле туган илләре булган Яңапардан бераз мәгълүмат кеби нәрсәләр бирүгә тырышулар да минем кул-аягымны, эшемне һәм гакылымны бәйләп алдылар...

Шулвакыт мин үземнең башланган бу эшемнең, чындан да, шулкадәр мөкатдәс вә шулкадәр бөек бер эш икәнчелеген аңлап алып хәйрәт итдем (таң калдым.— *Х. М.*). Бу бөек 300 еллык мөһим бер вазыйфаны үтәүдә Алланың миңа ышануындан һәм Алланың, чындан да, миңа гына насыйп итүендән шашып калып, шадлыгымдан йөрәк майларым да эрегән һәм күз яшьләремнең дә бөртек-бөртек тамчылары шушы тарих сәхифәләренә тамган заманлары булды.

Бигрәк дә көндән-көнгә арта барган туган илемнең сагышы да (80) шул бөртек-бөртек тамчыларга катнашып китеп, бу мөкатдәс тарихны тиз генә, әлдә (кулда.— *Х. М.*) хәл бар вакытда, шөбһәсез... вөҗүдкә чыгаруның кирәклеген бер-бер артлы колагыма тугый (тукый.— *Х. М.*) һәм җәсарәтемне дә (кыюлыгымны, батырлыгымны да.— *Х. М.*), һәм беткән көчләремне дә ул артдыра вә яңа җан бирә торды. Яңапарда туган вә үскән һәм Яңапарда укып кеше дә булган минем кеби берничә күңелле (кебек; ирекле; рухи халәтле.— *Х. М.*) Яңапар шагыйре вә мөәллифенең Яңапар өчен утка керергә тиешлеген дәлаләт (дәлил.— *Х. М.*) кыла... вә мөхәкъкак (чыннан да.— *Х. М.*) бу мәсьүлият (җаваплылык.— *Х. М.*) минем өстемдә икәнчелеген белдереп, гүяки бармагын да селкеп аңлата да торды.

Менә бу кеби читенлек вә эчке мөгаззәб (газаплар.— *Х. М.*) һәм эчке шадлыклар эчендә мәйданга килгән вә 300 елдан соң гына дөньяга туган тарихлы вә мәгълүматлы зәгыйфь бу әсәрем минем үз каршымда һәм минем үз гомеремдә эшләнгән Коръәнләр вә «Иман шартлары» басдыру шадлыкларымдан соң иң мөкатдәс, иң бөек хезмәтләремдән өченчеседер диеп күрелсә дә, хөрмәтле укучыларымның нәзарында (карашында.— *Х. М.*) бәлки бу андый мөкатдәс дә түгел вә көнче дошманларым каршында бу бәлки дә бер чүп-чар гынадыр да.

Яңапарның кочагында — гүрдә яткан шәфкатьле анам, туганнарым, кардәш вә әби-бабаларымның хөрмәтенә, шулай ук шул мөкатдәс авылның икмәке, суы берлән ризыкланган (81) вә аның җылы тәрбиясе белән буйга йитеп кеше булган минем үземнең дә Яңапарга булган бөек бурычларымызны үтәү өмидендә дөньяга туган бу әсәрем бөтен кимчелекләре берлән Яңапарга миндән һәдиядер (бүләктер.— *Х. М.*). Әсәремдә кулланылган исемләрнең бик күбенең халык телендә йөретелгән бозык вә кушымта исемләр көенчә генә калдыруым, бердән, тугры исемләрен инде белмәвем булса, икенчедән, бозык исемләрнең инде бик танулы булып киткәнлекләрендәндер. Бу белеб һәм мәҗбүрият йөзендән эшләнгән хата вә кимчелекләремдән шәхесләренә тигәнләрдән гафулык теләвем өстенә, киләчәкдә Яңапарның тарихын язуда дәвам итүче затлардан да минем бу әсәремдән табылган хата вә кимчелекләремне бик үк күрмәүләрен һәм йөзгә бәрмәүләрен риҗа итәм (үтенәм.— *Х. М.*).

*Яңапардан хәйр-дога өмид итү канымның шартыдыр.*
*Финляндия, Хельсинки, 25 август, 1954*

[Китапның ахырына ике кушымта теркәлгән. *Беренчесе —«Яңапар авылының хыялый харитасы»* (картасы.— *Х. М.*). Анда авылның урнашу тәртибе, урамнары (Озын урам, Яңа урам...), мәчет, мәктәп, тимерчелек, каберлек, крупчатка, милчәләр, керү-чыгу юллары (Өчкүл юлы, Мәдәнә юлы) һ. б. шартлы билгеләр белән күрсәтелгән. Карта 1949 елда Садрый Хәмид тарафыннан эшләнгән.

*Икенче кушымта* — Актук картның нәсел шәҗәрәсе (Актукның бер тармагындан Кулик нәселендән кечкенә генә бер өлеше. Эшләүчеләре: Хәсән Хәмидулла һәм Садрый Хәмид). Зур агач, аның ботак-яфраклары рәвешендә эшләнгән бу схеманың беренче буыны итеп Актук күрсәтелгән. Аннан түбәндәге рәвештә: Симай — Йомай (Йомакол) — Мулай (Муллакай) — Әхмәр — Габдерәхим Мөхәммәд Кулик...— Хәмидулла (1836 да туган, вафаты — 1894...) — Низамеддин (туган 1862, вафаты — 1940...) — Хәсән (туган 1900, 25/II; хатыны Өммегөлсем, Пинзәдән) — Гомәр (туган 15/XII, 1928, хатыны Гыйффәт Таһир кызы, Финляндия) һ. б. [Күпчелегенең туган, үлгән еллары күрсәтелгән.] [Китапның ахыргы тышлыгының эчендә авторның «Әлегә кадәрле чыккан әсәрләр исемлеге» бирелгән.— *Х. М.*] Алар түбәндәгеләр:

— Коръән Кәрим... Бөтен мосарыфлары илән басып таратучы... Хәсән Хәмидулла. Төзүчесе: Хәсән Хәмидулла (20 мең данә әсирләргә һәдия ителде).

— Яңа Иман шарты һәм белемлекләр (6 мең данә әсирләргә һәдия ителде)...

— Илһам йимешләре...

— Милчәче белән пәри карчыгы.

— Ватансызлык...

— Күңел шәүләсе.

— Йөрәк ялкынлары.

— Пикай (хикәя).

— Моңлы таңлар...

— Сүнүгә таба.

— Хәйрелниса... 4 пәрдәлек драма.
— Йолдызларга сәяхәт (хикәя).
— Тәкъдир каршында...
— Мөһаҗир бәхете.
— Исем көнләре календаре (мәгълүмат).
— Борынгы картлар сүзе (мәкальләр).
— Тәүбә догасы (гарәпчә-татарча).
— Яңапар тарихы...
— Шималь очкынлары мәҗмугасы. Номра 1—2—3—4.

[Китапның ахыргы тышлыгында автор, әсәр исеме, 1667—1919 еллар, чыгу урыны, вакыты (1954) латин һәм гарәп хәрефләре белән язылган. Финчә дә сүзләр бар. Китап «Актук авылына да һәдиядер» диелгән.]

ИСКӘРМӘЛӘР

1 Автор бу шигырен китапка кереш рәвешендә биргән.

2 Китапның 3 нче битендә бу ике затның рәсеме дә бирелгән. Хәдичә Галим кызы — чыгышы белән Уразавылдан.

3 Карт борадәре — өлкән ир туганы.

4 Хәзерге Нижгар өлкәсендәге татар авылларының бер өлеше (Мәдәнә, Чүмбәли, Сафаҗай һ. б.) элек Сембер губернасына кергәннәр.

5 Китапның 4 нче битендә бер әби белән бабайның фоторәсемнәре бирелгән. Аның астына «Мәрхүм Низамеддин Хәмидулла һәм хатыны Мәдинә Мәүлихан кызы» дип язылган.

6 Өч кырның өчесенә дә бер душ башына төрле 7 йирдән 2 шәр сажин киңлегендә 60 ар сажин буйлыгында, мәҗмугы (барысы.— *Х. М.)* 14 сажин, ягъни бер душның бөтен чәчү йире өч кырда фәкать 5292 квадрат метр (?) гына. Аның да 1764 квадрат метрысы парна кыры булып чәчелмичә буш кала. *(Х. Х.)*

7 «Рисаләи Газизә» әсәренең тәүге (1847 елгы) , ягъни Санкт-Петербург басмасы да шушы зат катнашында дөнья күрә. Анда шушындый юллар бар: «Нижний губернасының Сергач өязенең Яндавишчә волостеның Яңапар авылының Ризван Маллай (Мулай.— *Х. М.*) хөраҗате (чыгышы.— *Х. М.*) илән» нәшер ителде.

## Хәсән Хәмидулланың шигъри иҗаты

Хәсән Хәмидулланың иҗат мирасында шигърият мөһим урынны били. Әдипнең тезмә әсәрләре, нигездә, төрле күләмдәге басмаларында нәшер ителгән. Болар арасында аеруча «Илһам йимешләре. Шигырьләр» җыентыгы (Хельсинки, 1970. — 308 б. Беренче җөзэ, ягъни том) игътибарга лаек. Андагы әсәрләр гарәп һәм латин хәрефләрендә нәшер ителгән. Шулай ук «Вәзыйгать эчендә» («түбәнлектә», «бозыклык эчендә».— *Х. М.*) китабында да (Хельсинки, 1973) кызыклы гына шигырьләр бар.

Туган җирдән аерылу, сагыну, җирсү кешенең күңелен нечкәртә, җыр-моңга, шигъри сүзгә тартылуын көчәйтә диләр. Мөгаен, шулайдыр. Шигырь чыгару, такмак әйтү белән кечкенәдән үк аз-маз гына шөгыльләнгән Хәсән Хәмидулла да Финляндиягә күчү белән әдәби иҗатка ныклап керешеп китә. «Шигырьләремнең күпчелеге,— ди ул,— 1915—1917 елларда язылган». Әмма тормыш мәшәкатьләре, чит-ят җирдә тереклек күңелең теләгәнчә иҗат итәргә тиешле мөмкинлекләр дә бирми. Еллар узгач, яше 70 ләргә җиткәч, Хәсән Хәмидулла бу хакта үзе дә үкенечен белдерә. «Яшәгән һәм яшәп килгән мохитем,— дип яза ул бер истәлегендә,— минем башыма килеп, агылып тора торган «илһам»ларыма бик каты киртә булып торганы өчен, әллә кайларга өскә һәм күкләргә менеп булмады... Бик зур эшләргә хәзер булган көчем вә кодрәтем йөрәгемә тулып аша китә торган заманда тыштагы манигъләр (киртәләр.— *Х. М.*) рухны, тәмне, теләкне сүндерергә сәбәп булучылар — шул тартышуларыма киртә булдылар. Бигрәк тә рухның сүнүенә латин гаугасы һәм шуңарга мәхәббәт баглаучылар яшьләремез һәм берничә картракларымыз булганы өчен, гарәп хәрефенә бик каты дошманлык арттырды да, гарәп хәрефе белән язылганларны читкә быргытылды (ыргытылды, ташланды.— *Х. М.*)».

Шагыйрь күңеленниләр борчый, ул нәрсәләр хакында һәм ни рәвешле яза соң? Әйткәнебезчә, Хәсән Хәмидулланың шигъри мирасы шактый бай, күпкырлы һәм күләмле. Анда лирик парчалар да, багышлау-котлаулар да, мәдхия-мәрсияләр дә, лиро-эпик әсәрләр — поэмалар да, марш-җырлар да, мөнәҗәт-мәсәлләр һ. б. да бар.

Мәгълүм булганча, Октябрь инкыйлабыннан соң, Совет чорында татар шигъриятендә һәм форма, һәм идея-тематик яктан җитди үзгәрешләр кичерде. Күп гасырлар буе халкыбызның рухи терәге булган ислам дине, аның белән бәйләнешле әхлакый, инсани кыйммәтләр читкә кагылды, үз милләтеңне ярату кебек табигый хис тискәре бәяләнде; борын-борыннан халкыбызга хезмәт иткән гаруз шигырь системасы, күп кенә әдәби шәкел-формалар, сүз-сурәтләр заманга яраксыз дип табылды. Хәсән Хәмидулла исә, Советлар Берлегеннән читтә яшәү аркасында, бу төр тыю-киртәләрдән азат. Һәм шуңа да аның иҗатында озын-озак тарихлы әдәбиятыбызның, аеруча XX йөз башы татар сүз сәнгатенең, традицияләре мул һәм уңышлы дәвам иттерелә. Аның күпчелек шигырьләре гаруз, һәр юлы 15 әр иҗектән торган икеюллык строфалар белән язылган. «Кыйссаи Йосыф», бәет-мөнәҗәт шәкелләрендә иҗат ителгән әсәрләр дә күзгә ташлана. Мәсәлән, «Нәфес корбанлары» исемле шигырь — әнә шундыйлардан. Автор үзе үк бу парчасының «Йосыф китабы көенә» язылуын искәртә. Ул шундый юллар белән башлана:

Мең тукыз йөз утыз тукыз елның ахыры,
Башлады туп тавышлары белән яңгыры.

Анда (аңа.— *Х. М.*) кадәр бик үк кирәк булмаса да,
Инде кирәк булды һәрбер кемгә Тәңре...

Шунысы мөһим: бу шигырендә автор ялган патриотизмга, каршы көчләрне гаепләүгә бирелми. Совет-фин сугышының да, урыс-алман орышының да инсаннарга афәт китерүен, «мәхшәр кеби» вазгыять тудыруын искәртә. «Фин татары» да бу коточкыч фаҗиганең бөтен газапларын кичерә:

Бу эшләрне дә күрде фин татар халкы:
Сугышты, үлде, янды һәм яраланды...

Шагыйрь өчен тыныч, имин тереклек барыннан да кыйммәт. Сугыш беткәч, ди автор, халык «тотынды сәүдәгә һәм иске тормышка».

Урта гасыр һәм XIX йөз шагыйрьләре кебек, Хәсән Хәмидулла да Аллага бөтен күңеленнән ышана, аңа гаделлекнең, инсаниятнең төп чыганагы итеп карый; кыен вакытларда Тәңрегә ялвара, аннан рәхим-шәфкать, ярдәм сорый. («...Арта һәвәсем Аллага, кызганып халкым өчен күңелем Ходайга ялвара»; «Әй Ходай, кил син үзең коткар мине...»)

Кыен, мәшәкатьле, хәтта вакыты белән фаҗигале булса да, татар зыялылары элек-электән хаҗга барган, кайберләре үзләренең тәэсир-кичерешләрен, күргән-ишеткәннәрен кәгазь битләренә дә төшергән. Мөхәммәд Әмин, Шиһабеддин Мәрҗани, Гали Чокрый язмалары, хаҗнамәләре — әнә шундыйлардан. Хәсән Хәмидулла да бу традициягә тугрылыклы кала. Аның «Хаҗ хатирәләре» исемле сәяхәтнамәсе (Хельсинки, 1968.— 100 б. Гарәп язуында) факт-мәгълүматларга байлыгы, үтемлелеге белән игътибарга лаек. Чәчмә формадан тыш, Хәсән Хәмидулла үз тәэсирләрен шигъри шәкелдә дә яза. Аның бу төр парчаларының бер өлеше «Илаһи шигырьләр: 1970 елның хаҗ сәфәрендәге хәстәлек истәлекләре» исеме белән бер цикл-шәлкемгә дә тупланганнар. Анда шагыйрьнең Мәдинәдә язылган «Үлем түшәгендә», «Өмидсезлек каршында» дигән шигырьләреннән тыш, «Әл-Каһирәдә», «Шамда», «Багдадта», «Бәйрутда» һ. б. парчалары да бар. Хәсән Хәмидулла икенче хаҗ сәфәре вакытында бик каты авырый. Мөгаен, шуңадыр аның бу чакта язылган шигырьләрендә өметсезлек, газап мотивлары да үзен шактый сиздерә. Шуның белән аларда Мисыр, Багдад, Димәшкъ, Бәйрут кебек ил-калаларның бай тарихлы булуы, бүгенге хәлләре дә рәсемләнә:

Мин хәзер Ләбнан йирендә, яткан урным Бәйрут ул,
Монда майлар, ак әпәйләр... әфлисуннар бар да мул...

* * *

...Бу — Мисырдыр иске милләт, бу — фиргавенләр иле,
Бу заманында бөек культурга малик ил иде...

Милли тематика — XX йөз башы татар шигъриятенең җаны, арка сөяге. Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич җырлаган татар язмышы Хәсән Хәмидулла иҗатының да төп асылын билгели. Бу ягы белән ул Сания Гыйффәт, Ләбиб Каран, Минһаҗ Исмәгыйли һәм кайбер башка мөһаҗир әдипләрнең иҗатлары белән турыдан-туры керешеп китә. Шагыйрьнең «Куанычым» шигырендә мондый юллар бар: «Сөям мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым»; «Татар булгач татармын мин, шуңардан бәхтиярмын да (бәхетлемен.— *Х. М.*), Көләрмен һәм татар бәхтенә, хәсрәткә җылармын да...» Үз халкының бәхетенә сөенү, хәсрәтенә көенү, чыннан да, Хәсән Хәмидулланың бөтен иҗатына хас. Мәсәлән, «Милләт маршы»нда бу мотив төрле вариацияләрдә бирелә. Милләтнең «шатлануы», «дәртләнүе», «кайгыруы», «еглавы», «яшәве» — барысы да шагыйрьнең үз халәте кебек кабул ителә. Бу марш «Син яшәсәң — мин дә яшим, син бит минем милләтем» дигән мәгънәле юллар белән төгәлләнә.

Хәсән Хәмидулла, милләт язмышы хакында уйлаганда, еш кына капма-каршы кую, ягъни антитеза алымы белән эш итә. Элек татарның данлы, шанлы, мөстәкыйль чаклары булган. Ә хәзер — шуның киресе. Шагыйрь үз халкын гафләт-ваемсызлык йокысыннан уянырга, үткәненнән гыйбрәт, сабак алып, тулы канлы тормыш белән яшәргә чакыра: «Уйла, эшкә башла, бәгърем, Котыл әрнүле вөҗдандан».

Хәсән Хәмидулла иҗатында милли тематика туган җир, туган ил төшенчәләре белән табигый бәйләнешле. Чит мәмләкәттәге тормыш никадәр генә әйбәт булса да, ул ил синеке түгел. Бу хакыйкатьне шагыйрь тирәнтен аңлый. «Адашкан халык» шигырендә автор «ябанчы (чит.— *Х. М.*) йирдә без ирексез» дип, хаклы рәвештә үзе дә искәртә. «Иркәләнү» исемле парчасында әдип үз халкының данлы үткәне, бөек затлары хакында яза. Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдемәндләр белән беррәттән, ул Г. Исхакый, Галимҗан Идриси, Муса Биги, Г. Баттал, З. Вәлиди кебек билгеле мөһаҗир шәхесләрне дә телгә ала. Әсәр «Тик бәхетсезләр алар, илсез бәхет юк бернидә» дигән бик мәгънәле мисраг — шигъри юл белән төгәлләнә.

Хәсән Хәмидулла өчен туган ил, Ватан, иң беренче чиратта, аның туган авылы «Актук иле» — Яңапар аркылы күзаллана. Мәгълүм булганча, Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев кебек олуг җырчыларны биргән бу төбәк — Финляндиядә гомер кичергән һәм кичерүче күпчелек милләттәшләребезнең дә асыл Ватаны. Шуңа күрә әдип әсәрләрендә Хәсән Хәмидулланың үз шәхси кичерешләре генә түгел, билгеле бер дәрәҗәдә башка бик күп мөһаҗирләрнең дә рухи халәте гәүдәләнеш таба.

Бер парчасында шагыйрь «Актук иле»нең, андагы елга-тауларның барчасы «истә булуын, андыйларның «Финдә» һич юклыгын искәртә. «Туган ил тәэсирендән» шигыре авторның сагыну, җирсү хисләрен, кече Ватаны өчен әрнү-борчуларын шактый тулы чагылдыра. Кол Гали, Кандалый кебек ул да «искән җил»ләрнең ике арада илче, хәбәрче булуын тели:

...Ни бәхет, җил кайтса илгә, сөйләсә миндән сәлам,
Әйтсә анда — мин аларны нинди күб сагынып калам.

Хәсән Хәмидулланың башка шигъри әсәрләрендә дә «Актук иле», аның кешеләре, истәлекле урыннары, гореф-гадәтләре телгә алына. Бу яктан шагыйрьнең «Пикай», «Милчәче (тегерменче.— *Х. М.*) белән пәри карчыгы» исемле поэмалары кызыклы. Аларның һәр икесендә дә автобиографик хәл-вакыйгалар, хәтерне яңартып, балачакны искә төшерүләр гәүдәләнеш тапкан. Автор, Тукайның «Шүрәле»се, «Су анасы»ндагы кебек, хикәяләүне тасвирлау, лирик чигенешләр белән үреп бара, әсәрдә җитди аһәң юмор белән кушылып та китә.

Милчә (мельница) — Сергач һәм шуңа мөнәсәбәттә Финляндия татарлары телендә «тегермән» дигән сүз. Актук һәм ул төбәктәге кайбер башка авылларда Октябрьгә кадәр җил тегермәннәре, крупчаткалар тоту киң таралган була. Бу хакта Хәсән Хәмидулланың «Яңапар тарихы» исемле китабында да шактый мәгълүматлар бар.

«Милчәче белән пәри карчыгы» поэмасының (ул 89 икеюллыктан тора) үзэгендә — Мүктәр исемле тегерменче карт. Аның, ди автор, «гомере үтде милчәдә». Ул, «тол» килеш, шунда яши. Үзе диндар, ничек кенә булса да, тәһарәт, намазын калдырмый. Халык аннан канәгать. Әмма бервакыт җил туктый, тегермән өч көн буена эшләми. Кешеләр кайгыра. Нишләргә? Аптыраган Мүктәр карт төнлә йокыга тала. Уянып китсә күрә: бер бик ямьсез карчык он или:

Йоклады бер көн тоташ ул, күзне ачды — төн иде,
Бакса, ул ни күз белән күрсен — әби бер он или!

Күзләре шакмак кебек: күкле-кызыл ут ялтырый,
Чулкасы юклыкка күренә — кап-кара йон балтыры.

Чәчләре тузган, сүрелгән, каплаган киң иңсәсен,
Мөгезе бар бер маңлаенда, шунда ул үргән чәчен.

Куллары зурлак (зуррак.— *Х. М.*) көрәкдән, бармагы зур,
нечкәләр,
Агзы ырбайган, котың, шиксез, чыгар көлсә әгәр...

Тегерменче пәри карчыгын кыйный башлый. Тегесе ярдәмгә башка пәриләрне чакыра.

Күп тә үтми тулды милчәгә пәриләр агрышып,
Сизмәгәндә сызды карт тиз бер сызык, артдан чыгып.

Карт һәр эш-гамәлен бисмилла әйтеп кенә башкаргач, пәриләр сызыкны («мәрә»не) уза алмый, киресенчә, үзләре «тоткын»га әверелә. Карчык, хәлнең асылын аңлап, Тукай әсәрендәге Шүрәле кебек ялвара башлый:

Әйтә карчык: «Сукма, абзый, бит тәнем булды күмер,
Урламам мәңге синең нәрсәңне дә һичбер гомер.

Башка җенләрдән дә урлатмам, диярмен «дустым ул
Һәр пәриләрдән дә тидертмәм теләк булса кабул...»

Карт пәри карчыгына һәм аның иптәшләренә тегермән ташын әйләндерергә боера. Тегеләр эшкә керешә.

Шул күгә (көйгә.— *Х. М.*) он тартды милчә көнне-төнне алты көн,
Тулды капчыклар тәмам, онга авыл батды бөтен.

Бу бабайның хөрмәте артды, хәзер бар да якын,
Булды мәмнүн (канәгать, риза.— *Х. М.*) барсы да һәм бирделәр
бер тол хатын.

Хәсән Хәмидулланың туган як хатирәләре белән бәйләнешле бу әсәре (автор аны «хикәя» дип атаган) мифологик риваятькә нигезләнгән. Әмма ул бер үк вакытта реаль чынбарлык күренешләре һәм детальләре белән дә үрелеп бара.

Шагыйрьнең «Пикай» поэмасы (ул 136 икеюллык строфадан гыйбарәт) беренче юлларыннан ук Актук авылы, аннан чыккан аерым затларны (Низами, Гыймад абзый, Гомәр Гали, Хисам мелла углы Габдрахман һ. б.) телгә алу белән башланып китә:

Бар иде Актук илендә тол хатын исме Пикай,
Белмим инде нәрсәдәндер, һәммәсе бит ди шулай.

Тугры исмен кем дә белми һәм Куликның Хисамы,
Ул хот (хоть.— *Х. М.*) инде белмәсен дә, белми мәрхүм Низами...

«Йиргә кергән кечкенә өй»дә торучы Пикай — усал, явыз хатын: «Кылган ул төрле усал эш»; «Күпме ул кешеләрне бәргән метла һәм көрәк берлә. Күпме хайванларны чәнечкән... сәнәк белән»; янгыннар чыгара, «карта уйный, каба» һ.б. Кыскасы, автор Пикайны бөтен начарлыкның, бозыклыкның гомумиләштерелгән образы рәвешендә тәкъдим итә. Әмма алга таба персонаж бераз онытылып тора. Автор үзенең балачак хатирәләренә бирелә башлый:

...Әтием иде шәһәрче, безне бакды шундый шәп,

Шундый шәп бакганга инде ул ята оҗмахта, шәт.

Өч кыз артыннан туган мин ялгызак бер ир бала,
Барсына тансык идем, әнкәм дә мине бик бага.

Шулай ук автор башка балалар белән үзенең төрле уеннар уйнавын, ураза тотуын, өлкәннәрнең кырда эшләвен искә төшерә, йомшак күңелле, диндар табигатьле әбисен яд итә, Г. Исхакыйның Сөннәтче бабае кебек, «абдалчы» Габдерәхим, аның улы «Исмәгыйльләр»не дә телгә ала. «Милчәче белән пәри карчыгы» поэмасындагы шикелле, биредә дә тегермән тартулар ассызыклана:

Бакчалар да бар да шунда — милчәләр, крупчаткалар...
Ул крупчатка белән тик ярма гына яралар.

Автор бервакыт, төгәлрәге «кадер кичендә», йокларга ятуын, бераздан мәче кычкыруына уянып китүен яза:

Аз гына йомдым күзем, баксам, мачым борчыла:
Кычкыра, тырный, мияулый, анда-монда омтыла.

Эт-мәчеләрнең афәт килүен алдан ук сизүе күпләргә мәгълүм. Бу очракта да ул шулай булып чыга: баксаң, янгын чыккан икән, «Ихсан Әмиш крупчаткасы»на ут капкан. Авылның барлык халкы куба; ыгы-зыгы, кычкыру, елау:

Мәрхәмәт юк утта бер дә, ул яна, шарт-шорт итә,
Шартлаган саен агачның тәсбихе, гомре бетә.

Кешеләрне «калдыра өйсез», «ач һәм ялангач». Шунда «ярма бирмәгәне» өчен «крупчаткага» Пикай ут төрткән икән дигән хәбәр тарала. Барча халык аңа каһәр укый:

Һәммәсе әйтә: явыз ул, бәдбәхет, йөзе кара,
Шундый изге кичәдә аның вөҗданы ничек бара?

Янгын көчәйгәннән-көчәя бара, җил дә авыл ягына борыла. Нишләргә? Шунда халык тезелеп, җилгә каршы бик каты кычкырып азан әйтә башлый. Гаҗәеп хәл туа: җил борыла, йомшара һәм бераздан янгын да бетә.

Бетде утлар... сүнде шунда, һәммәбез калдык тынып,
Шадлыгымдан мин дә китдем, бик тирән уйга чумып.

Шушы юллар белән поэма төгәлләнә. Нәкъ «Милчәче белән пәри карчыгы» әсәрендәге кебек, биредә дә диннең кодрәти көче, иманлылык, инсани эш-гамәлләр мактала, бозыклык, явызлык фаш ителә, кире кагыла.

Күргәнебезчә, Хәсән Хәмидулла, гәрчә үз халкын бик яратса да, милләтне тәмам идеаллаштыру юлы белән китми, андагы кимчелекләрне, имансызлык күренешләрен кискен тәнкыйтьли.
Аны аеруча халкыбызда бердәмлек җитмәү, милли мирасны төрле якка тарткалаулар борчый. Мәгълүм булганча, узган гасырның
30—60 нчы елларында Финляндия татарлары арасында ике агым барлыкка килә: берәүләр төреклекне, аның телен, гореф-гадәтләрен яклый; икенчеләре исә — татарлыкны саклап калу ягында. Бу ике юнәлеш арасындагы каршылык шактый җитди төс ала. Хәсән Хәмидулла, Гыймад Җәмаледдин, Хөсәен Садыйк, Гайсә Хәкимҗан, Гомәр Таһир, Гәүһәр Туганай һәм кайбер бүтән зыялыларыбыз татарлыкны саклап калу буенча күп эш башкаралар, ахыр чиктә татарлык җиңеп чыга. Хәсән Хәмидулланың аерым «милли шигырьләре» шушы көрәш, бәхәс уңае белән дә язылган.

Шагыйрьнең әсәрләрендә Финляндиядәге милләттәшләребез, аларның рухи халәте белән бәйләнештә бу илнең табигате, мәдәнияте дә билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Мәдинә каласында авырып ятканда, автор яшәгән ягын романтик идеаллаштыру, көчле сагыну белән искә ала һәм, Ходайга мөрәҗәгать итеп, мондый юлларны яза:

Эстәлием гаршеңне, көрсеңне, мине кайтар үгә (өйгә.— *Х. М.*),
Анда бит кардәш, якынлар, анда бит рухлар үбә.

Анда салкын, анда кар бар, анда ашлар тәмлеләр,
Анда йөзләр һәм сыйфатлар бар да бит бик ямьлеләр.

Мәгълүм ки, Финляндия — фән-техника, сәнәгый (промышленность), тормыш-көнкүреш ягыннан гына түгел, ә мәдәни яктан да дөньяда алга киткән мәмләкәтләрнең берсе. Анда күпләгән театрлар, музейлар эшли, гаҗәеп күп гәҗит-журналлар, китаплар басыла. Фин әдәбияты да бик бай. Биредә яшәүче милләттәшләребез, әлбәттә, бу илнең рухи казанышлары, фәне, әдәбияты белән танышып баралар, үзләренең зиһеннәрен баеталар, интеллектуаль дәрәҗәләрен күтәрәләр. Кызганыч, бу мәсьәлә, ягъни фин һәм татар багланышлары, аеруча әдәби мөнәсәбәтләр өйрәнелмәгән диярлек. Аны ачыклауда Хәсән Хәмидулла эшчәнлеге — менә дигән материал. Анда әдәби тәрҗемәләр дә бар. Шундыйларның берсе «Табигать серләре» дип исемләнгән. Авторы күрсәтелмәгән бу парча, күрәсең, татар шагыйренең рухи халәтенә аваздаш булган. Анда күпгасырлык татар шигъриятенә дә хас булган яшәеш һәм үлем, җирнең «асты вә өсте» проблемасы яктылык, кояш, ай образлары аркылы гәүдәләнеш тапкан:

Яраткан булса иде Тәңре дөньяны караңгы төн,
Кояшсыз булса һәм айсыз, күренмәс булса якты көн;

Булыр иде әҗәл ансат, үлемдән кем дә курыкмаста!

Барыбер соң түгелме — өстә йирнең я аста?!

Кызыгырлар иде әл дә күрергә тиз оҗмахларны,
Шулай ук анда да сөйләнсә бик якты оҗмах барны...

«Финдән» файдаланып язылган «Саргайган йөзләр» шигыренең композициясе «космик караш»ка корылган. Айдагы кешеләр өчен, ди автор, «йир» һич тә «ямьле» шар түгел, ул чокыр-чакырлы, таулы, адәмнәр кызыгырлык түгел. Айга «сипкән» нуры да аның үзенеке түгел, ә «кояшның шәүләсе». «Йир» канга баткан:

...Күренә Айга зур булып йир һәм кызыл, һәм бик сары,
Чөнки баткан канга ул йир, саргаеп беткән бары.

Хәсән Хәмидулла — күпкырлы, эшчән, алтын куллы шәхес. Ул башкаларга ышанып, аркаланып йөрмәгән, һәрнәрсәне үзе башкарырга, үз тормышын үзе көйләргә омтылган. Бу сыйфатлар аның шигъриятендә дә чагылыш таба: «Һөнәр, сәнәгать миңа чүп! Чөнки йөз төрле һөнәр — миндә», «Үз көчем илән... ризкымны мин таптым», «Анда барсам — эш көтә, монда килсәм — эш көтә, Инде шул күп эш белән минем бөтен гомрем үтә», «Эшли алам һәммәсен мин, эшләсәм кулдан килә...» Шунысы мөһим: актив табигатьле лирик каһарман эштән рухи канәгатьләнү таба («...Эшкә башласам, миңа гайрәт кирә... яшьлек килә», «Эшләдем күп, эшләгән көнләр иде иң тәмлесе, Бакчадагы гөлләремнең иң матуры, ямьлесе»), хезмәттә милләтнең бәхетле, хөр яшәешен күрә. Аның төп кайгысы — үз эшеңне үзең эшләп бетерү, башкаларга калдырмау:

...Ташламасын инде Аллам, эшне миндән алмасын,
Мин аларны бетерим эшләп, башкаларга калмасын.

Шагыйрь фикеренчә, бары «иҗтиһад» иткән, тырышкан инсан гына чын мәгънәсендә «кеше»: «Әй туганым, алга атла! Иҗтиһад ит эш өчен, Бик йирәнгеч бер фигыль, ятма ашап кеше көчен. Эшлә җаным һич иренмә, син тырышсаң — чын кеше».

Әйткәнебезчә, Хәсән Хәмидулла гомере буе шигырьләр язган. Аларда авторның рухи халәте, шатлык-кайгылары, күңел биографиясе шактый дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Әгәр дә без шагыйрь әсәрләрен бер система, бөтен итеп карасак, аларда билгеле бер үзенчәлекләр дә күрербез. Яшь чактагы шигырьләрендә күңел күтәренкелеге, оптимизм бөркелеп тора. Еллар уза барган саен уйлану, җитдиләнү көчәя. Яшьлек һәм картлыкны бер-берсенә каршы кую, үкенеч, сызлану, сагыш аһәңнәре, үлем, теге дөнья турында уйлану мотивлары ешрак очрый. Бу хәл шагыйрь әсәрләренең исемнәрендә дә күренеп тора: «Соңгы теләк», «Сынган күңел», «Үтде миннән», «Үлем түшәгендә», «Санаулы көнләр» һ.б. Автор кайвакыт үз-үзе белән әңгәмә кора, кылган гамәлләрен, тормышка ашмаган хыял-өметләрен башыннан кичерә. Хәсән Хәмидулла, күп кенә башка шагыйрьләрдән үзгә буларак, мәхәббәт, хатын-кыз турында аз яза. Шулай да аның иҗатында бу тематикага мөнәсәбәтле кызыклы гына парчалар очрап куя. Мәсәлән, «Хатын-кызлар» шигырендә автор бу затлар алдында «һәр ир»нең үзгәрүен искәртә:

Бу дөньяда табигый бер гадәт бардыр ки, һәр ирләр
Хатын-кыз күрсә, күңле йомшара һәм тетриләр... анлар.

Тәбәссем берлә (елмаеп.— *Х. М.*) бер иргә әмер итсә хатын-кызлар,
Кылыр, ни генә җинаять эш, ки хәтта сәҗдә кылырлар.

«Фәкыйрьлек һәм хатын» парчасында шагыйрь «инсафлы», «гакыллы», ачык йөзле, «ир шатлыгына шатланып, ир кайгысына көйгән» хатынның гаилә өчен җәннәттәй тормыш тудыруы рәсемләнә.

Финляндиядә гомер кичерүче милләттәшләребезнең, гәрчә алар аз санлы (меңгә якын) гына булсалар да, үзләренең эчке мәдәни-әдәби тормышы, мохите була. Хәсән Хәмидулла Садрый Хәмид, Гайсә Хәкимҗан, Гәүһәр Туганай һәм биредәге кайбер башка каләм тибрәтүчеләр белән аралашып тора, аерым әсәрләрен алар белән әңгәмә-бәхәс, фикер алышу рәвешендә дә яза. «Пикай» тәнкыйтьчеләренә» парчасы — әнә шундыйларның берсе. Күрәсең, шагыйрьнең «Пикай» поэмасы аерым кешеләр тарафыннан тәнкыйтькә очрагандыр. Автор аларга шагыйрьлеккә хас гомуми сыйфатны телгә алу белән җавап бирә:

Шагыйрь язар, сорамас ул язачак нәрсәсен кемдән,
Аңарда бит алар чөнки фәкать илһам белән килгән.

Белер күбрәк үзе мәфһүмләренең* барганын кайда,
Әләкләү һәм дә тиргәүләр дә итмәс һич аңар файда.

Язар, чөнки килә аның хәлендән андый шәп эшкә,
Шуңардан бит санар да ул нахаллардан үзен өсткә.

«Хәзерге вазгыятемез» шигыре дә бәхәс-полемик рухта язылган. Анда автор үзенә ташланган гайбәт-тәнкыйть сүзләрен телгә ала да аларга дәлилле һәм төпле җавабын ирештерә. Шигырь шушындый юллар белән төгәлләнә:

...Чаба кол халкымыз безнең, сүләсә әллә кем булсын,
Гадәт шул инде бездә, хот (хоть.— *Х. М.*) сүләгән
сүз нәҗес булсын.

Мөһаҗәрәттәге татар әдәбиятына Тукай иҗаты гаять көчле йогынты ясый. Бу — Хәсән Хәмидулла иҗатында да ачык күренә. Ул да, нәкъ бөек шагыйрь кебек, милләт тематикасын, татарны хөр, белемле, әхлаклы, бәхетле итү проблемасын үзәккә куя, Корьәнне [«Таң вакыты» (Коръәннән тәрҗемә)], элеккеге рухи-әхлакый

кыйммәтләрне иҗатында мул файдалана... Тукай кулланган күпчелек шигъри үлчәмнәр, жанрлар, поэтик формалар Хәсән Хәмидулланың әдәби мирасында да бар. Мәсәлән, ул үзенең «Сакчы белән бала» шигырен Тукайның «Бала белән күбәләк» калыбында, үлчәмендә, рухында яза:

— Әйт әле, бала,
Кайда йөрдең бая?
Белмисеңме йөргәч,—
Бит сабагың кала...

Хәтта Хәсән Хәмидулланың аерым парчалары бөек әдип әсәрләренең атамалары кебек исемләнгән дә («Тәрәддед вә шөбһә», «Булмаса», «Мөнафикъка» һ. б.). Шагыйрь урыны белән Тукай әсәрләренә сылтамалар да ясый:

...Гадәт бездә җыйналу бер кибеткә я трактирга,
«Печән базары» дип йөртә Тукай шуларны шигырендә...
Менә шунда бөтен кешеләр сүгелә һәм хөкем кылына,
Бу булса искедә анда, Казанда,— кылына һәм монда.

Хәсән Хәмидулла халык иҗаты әсәрләрен бик ярата («Үтде яшь чак җыр белән бик күп вакытда җырладым», «Сыкрадым күп, егладым көйләп ачы ул моңларын...»), аларны туплап бастыра да. Мәсәлән, 1975 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары һәм моңнары» китабында «Хан кызы», «Көзге төн», «Сак-Сок», «Сылу кыз», «Зәңгәр күлмәк», «Сагыну» («Зиләйлүк» көенә), «Салкын чишмә», «Газизәкәй», «Сөембикә манарасы» һ.б. җыр-бәетләр, мөнәҗәтләр урнаштырылган. Шактый гына дүртьюллык җырлар да бар. Хәсән Хәмидулла үз иҗатында фольклор казанышларыннан мул файдаланган, берничә шигырен, нәкъ Тукай кебек, аерым көйләргә туры китереп яза: «Күңелгә» («Ак каен» көенә), «Уян, бәгърем» («Уян, татар» көенә), «Сандугачка» [«Каригласки» — «Карие глазки» көенә], «Төшде яфрак» («Әй мөкатдәс» көенә) һ. б.

Бөек шагыйрьнең Ш. Мәрҗани, Х. Ямашев һәм башка күренекле затларга атап язылган мәрсияләре бар. Бу традицияне Хәсән Хәмидулла да дәвам иттерә. Бер матәм шигырен (1967) ул Финляндиядәге милләттәшләребезнең бик тә мөхтәрәм кешесе, күп кенә татар зыялыларының дусты һәм ярдәмчесе, «Ислам җәмгыяте»нең хәзерге рәисе Окан Таһирның бабасы Гыймад Җәмаледдингә багышлый. Автор аның игелекле гамәлләрен, олуг шәхесен зурлый; Алладан аңа рәхим-шәфкать сорый, мәрхүмнең онытылмаячагын искәртә:

...Без әле истә тотармыз, һәммәбез сагыныр сине,
Йөз түгел, меңләрчә кылган яхшылык берлән сине.

Тукайның «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» дигән мәрсиясе күпләргә мәгълүм. Анда күренекле әдип Заһир Бигиевнең рухы яд ителә. Шунысы мөһим: Хәсән Хәмидулла шуның энесенә багышлап матәм шигыре яза. Автор Муса Биги (Җарулла. — 1875—1949) белән якыннан таныш була. Чөнки бу зат 1932—1935 елларда Финляндиядә балалар укыта, милләттәшләребезне белемле, динле, әхлаклы итүгә үзеннән зур өлеш кертә, биредәге зыялылар белән озак еллар буе хәбәрләшеп, билгеле бер дәрәҗәдә аралашып та тора. Хәсән Хәмидулла да Муса Бигине бик хөрмәт итә, аның хезмәтләре белән даими танышып бара. Шуңа күрә бөек галимнең үлеме шагыйрьгә чын мәгънәсендә заман ахырындагы гайре табигый хәл кебек күренә. Олы кайгы хәбәре укучыга табигать фонында, шартлы, мифологик сурәтләр (Дәҗҗал, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ) ярдәмендә җиткерелә. Көз. Көчле җил. Караңгылык. Яңгыр. Бүреләр улавы...— болар бар да табигатьнең гаять борчылуын, афәт килүен искәртә. Автор мәрхүмнең янар йолдыз кебек булуын, «әһле исламга», «дөньяга», инсаннарга «нур» биреп торуын романтик югарылыкка куеп тасвирлый: «Мусаның вафаты»на бөтен табигать, «йир» кайгыра:

Тетрәде йир, үлде Муса, булды хәсрәтдән азат,
Кайгы төшде дөньяга — Муса Җарулла дип вафат.

Мәрсиянең соңгы юллары да Тукай шигыренә аваздаш рухта төгәлләнә, хәтта аерым гыйбарәләр кабатлана да:

...Белмәдек кадрен аның без, белмәде һәм милләте,
Белмәсәк тә калды дөньяда аның зур хезмәте.

Хәсән Хәмидулланың «Соңгы ядкярем (әтиемнең кабер ташына)» шигырендә дә Тукай мәрсиясеннән файдаланып, ягъни «интертекстуаль алым» кулланып язылган юллар бар: «Шад бул, әти, мәркадеңдә (кабереңдә.— *Х. М.*), без онытмыйбыз сине». Тукайда: «Шадыман ул мәркадеңдә! — Без онытмыйбыз сине...»

Хәсән Хәмидулла шигырьләре тел-стиль ягыннан да Октябрьгә кадәрге традицияләрне дәвам иттерә. Гарәп-фарсы алынмалары да күзгә ташлана. Сирәк кенә булса да, госманлы теле элементлары да очрый. Әмма, гомумән, әдип әсәрләренең теле аңлаешлы, чын татарча. Мәгълүм ки, Хәсән Хәмидулла һәм Финляндиядәге милләт-тәшләребез чыгышлары белән, нигездә, Сергач төбәгеннән, мишәр төркеменнән. Әмма автор үзен һәм телен һәрчак диярлек татар дип атый. Шулай да аның шигырьләрендә мишәр шивәсенә хас булган аерым сүзләр, формалар бар, урыс алынмалары да очрый: төн ката («...йоклыйм төн ката», ягъни төн буена), тирес (кире, каршы), куча (өем), мәч (мяч), богыл (кибән), ызба («Күпме яндырган богыллар һәм келәт, һәм ызбалар») һ. б.

Хәсән Хәмидулланың аерым шигырьләрендә, бигрәк тә поэмаларында, әкият, элеккеге хикәятләр стиленә хас юллар һәм гыйбарәләр дә күзгә ташлана: «Бар иде иске заманда яр янында бер авыл», «Белмәсәләр белмәсенләр, бик кирәкле эш түгел» һ.б. Автор шигъри стильнең кабатлау, көчәйтү, мөрәҗәгать, риторик сорау, анафора, рәдиф һәм башка төрле чараларыннан иркен файдалана. Мәсәлән, биш строфалык бер шигыренең тугыз юлын ул «нәрсә файда» сүзләре белән башлый:

Нәрсә файда ул агачтан, тәмле җимеш бирмәсә,
Нәрсә файда ул чәчәктән, хуш исләре килмәсә.

Парчаның соңгы икеюллыгы түбәндәгечә төгәлләнә:

Нәрсә файда ул шәкерттән, уйласа бары үзен,
Сөймәсә үз милләтен, кызганса әйтер сүзен.

«Су буенда» җырында автор эчке рифма, синтаксик янәшәлек, кабатлау алымнарын уңышлы гына файдалана:

Кулларым да артда, күзләрем дә астда,
Акрын басып китдем су буйлап.
Канларым да кипте, йөрәгем дә типте,
Милләтемнең сагышын уйлап.

Кулларыммы әллә, юлларыммы әллә,
Нигә мине болай борчыйлар?
Әллә минем бик күп үтәлмичә калган
Милләтемә бик күп бурычым бар...

Кыскасы, әдип иҗатына һәм идея-тематик, һәм сәнгати яктан төрле үзенчәлекләр хас. Без исә аларның тик кайберләренә генә тукталдык. Шунысын да искәртик: Хәсән Хәмидулла күп язган, үз әсәрләрен үзе үк бастырып тараткан да. Киңәш-табыш итәргә, тәҗрибәле мөхәррир, рецензентларга күрсәтергә дә мөмкинлек булмаган. Шуңа күрә аның әсәрләрендә аерым кимчелекләрнең булуы — табигый да. Урыны белән ритмик төгәлсезлекләр, рифма-кафия кытыршылыклары, тиешсез кулланылган сүз-гыйбарәләр күзгә ташлана. Кайбер шигырь юлларына һәм парчаларга сәнгатьлелек җитми. Тезмәгә салынган гадәти сөйләм үрнәкләре дә бар.

Әмма бер хакыйкатьне онытмыйк: Хәсән Хәмидулла дигән милләттәшебез, чит мәмләкәттә яшәсә дә, үз халкы өчен гаять зур хезмәт куйган, күп санлы әсәрләр язган. Аларда кызыклы гына фикерләр, хис-кичерешләр, вакыйга-хәлләр гәүдәләнеш тапкан. Шуңа күрә бу шәхеснең иҗатын өйрәнү, бүгенге һәм алдагы буыннарга җиткерү — безнең бурычыбыз. «Телгә бай һәм сүзгә бай татар иле — бу үз илем», «Сөям мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым» юлларын язган әдип игътибардан читтә калырга тиеш түгел.

*2006*

## Хәсән Хәмидулла шигырьләре

### Вакыт йитде*

Җырлыймын шадлык көен, хәсрәт көен мин ташладым,
Милләтем чөн чөнки хезмәткә бу көн мин башладым.

Янса да бәгъpäм исәпләп милләтем фөрьядларын
(аһ-зарларын.— *Х. М.*),
Ташласам үлгинчә мин инде аның ул якларын.

Шауласын сәүдә илән, байлык илән дөнья бары,
Милләтем саг булдисә — байлык минем — я ни тагын?!

Үз көчем илән әгәр ризкымны мин таптым икән,
Байлыгы мәҗбүр түгел, үрләләсәм милләт тавын.

*Кими, 1925*

### Сүнмәдем

Яшь минем күңлем, фәкать өмидләрем сүнгән кебек,
Сүнмәсә дә, бәлки, мин инде аңар күнгән кебек.

Эшли алам һәммәсен, мин эшләсәм кулдан килә,
Ул югалган көчләрем — күрми калам юлдан килә.

Ни гаҗәп бу: мин үземне карт димен, картка саныйм,
Эшкә башласам, миңа гайрәт керә... яшьлек килә.

Җырладым хәсрәт көен күп, булды һәм шадлыкларым,
Әрнүле үтсә дә гомрем, булды һәм саулыкларым.

Эшләдем күп, эшләгән көнләр иде иң тәмлесе,

Бакчадагы гөлләремнең иң матуры, ямьлесе.

Булмаса да абруем һәм булмаса да хөрмәтем,
Күкрәгем тулы иде... анда төялгән милләтем.

Эстәгән йирләрне гизгәч, атды чәчәк-гөлләрем,
Тик тәәссеф (үкенеч.— *Х. М.*) күрмәдем һич татлы
туган илләрем.

**Соңгы теләк**

Күңлем төшә минем, уйласам бер:
Нигә минем чәчем ак, димен,
Нигә барсы миңа дуст түгелләр,
Нигә миңа алар ят, димен.

Тугры иде җилкәм һәм аяклар,
Көчле иде кулым, тәнләрем.
Ник соң әле бер дә сизмимен, дим,
Дөньяның бит ямен, тәмләрен.

Гайрәтем сүнгән тора ник,
Ник теләкләр, димен, беттеләр.
Бетте көлке һәм һөҗүләр
(«төрттерүләр».— *Х. М.*)
Корыды бар да, сүнде, киптеләр.

Аллага бар минем соң теләгем:
Ит, Ходаем, димен, син сабыр,
Бетмәде бит әл дә, бик эшем күп,
Көтмәсен лә иде тар кабер.

Эшләмимен инде үз эшемне,
Эшлимен бит ул халкым өчен.
Шул сүгән халкым бетерде
Имди минем бар көчем.

Аллаһым! дим, бирмәдең ирек,
Бер дә бит бу бәндәгә.
Шул сәбәптән калды эшләрем күп,
Алдым-артым тулган әле дә.

**Сынган күңел**

Бәлки, әле мин тынам, бәлки дә, инде мәңгегә,
Һич исем китми хәзер шөһрәткә, тәмгә, ямьлегә.

Файдаландым дөньядан мин Алла биргән көч белән,
Гомрем әз, эшләп калыйм дип дәрд белән һәм үч белән.

Калмады үз тиңләрем, мин ялгыз тартдым йөген,
Ни гаҗәп бар булмаса да башда бер кара төгем.

Кайгырам тик булмагач мин: ни булыр дип халкыма,
Чөнки эшләр шәп түгелдән керми никтер гаклыма.

**Үтде миннән**

Яшь вакытта күкрәгемнән чәчрәгән утлар кая?

Инде бозсыз йирдә дә минем аякларым тая.

Күп хәрефләрне тезеп, бик күп арыган күзләрем
Күрми язарга әле булса да бик күп сүзләрем.

Дөньям үткән дип әрәмгә, уйлыймын, катып калам,
Инде күзләр күрмәсә дә, яшь чыга — агзып алам.

Үтде гомрем, шәп диялмим, юлда булды киртәләр,
Кичләре шәп булса да, җәнҗаллы булды иртәләр.

**Фин җәе**

Китде җәй, тулды матурлыкка шимальнең төнләре,
Яктылык басты әле, бетде караңгы көнләре.

Кайтды кошлар көньягындан, тулды дөнья кош белән,
Саф һава монда әле, иснәргә мөмкин хуш белән.

Китде ул кыш, ул суыклар, китде озын төнләре,
Ул ябык йөзләр белән бүздәй суынган көнләре.

Әй рәхәт бу җәй көне, барсы киенгән нечкәдән,
Әтрафың (тирә-юнең.— *Х. М.*) тулган яшеллек берлә
төрле чәчкәдән.

Шунда уйлый һәммәсе дә: мин әле тәгътил (ял.— *Х. М.)*
алам,
Тәгътиле беткәч дә, күңле әйтә: мин монда калам.

Калмый ул, андай бәхетләр булса булыр миңгә бер,
Монда да бит — финдә дә тормыш итә бик күп җәбер.

**Телим әл дә**

Анда барсам — эш көтә, монда килсәм — эш көтә,
Инде шул күп эш белән минем бөтен гомрем үтә.

Яшь вакытта калган эшләр йөкләнелгән муйныма,
Булдылар анларда җәнҗал, тулды бар да куйныма.

Картаеп беткәч, дидем мин, бер күрермен якты көн,
Кайда ул?! Артты гына эш, бетми эшләп көнне-төн.

Ташламасын инде Аллам, эшне миндән алмасын,
Аларны бетерим эшләп, башкаларга калмасын.

**Илгә**

Әткәм-әнкәм һәм бабамлар сөйләгән шул тел белән,
Чөнки анлар бик сүгән бергә яшәргә ил белән.

Ул мөкатдәс ил минем һәм ул иде татар иле,
Күпме күрсә дә агырлык, чатнамады һич биле.

Шат яшәгәнләр, бу телдән бит алар ямь-тәм табып,
Бу мөбарәк тел эчендән төрле үрнәкләр алып.

Телгә бай һәм сүзгә бай татар иле — бу үз илем,

Чөнки анда күп белем һәм дөньясы тулган гыйлем.

Мин әле (әһле) «бабай» үзем дә — сезгә калсын җәүһәрем,
Сезгә саклап, башкаларга мин бирергә жәлләдем.

**Милләтсезләр**

Анда барса — мин татар, ди, монда килсә — ул төрек,
Файдасы булмады — торсак та нәсыйхәтләр биреп.

Булмагач милләт үзеңнең, ул адашкан куй кебек,
Кайда барса үртәлер, чөнки башында шул куык.

Инде онтылган бабайлар, ханлары, шәүкәтләре,
Ул батырлар, ул биек таулар кебек дәүләтләре.

Кайдалар ул саф хатынлар, кайда керсез кызлары
Һәм такыр башлар, мыеклар, динләре — боерыклары?

Биколли (тәмам.— *Х. М.*) беткән гакыллар, күп күреп беткән башы,
Шәп ашап, киенеп оныткан,— инде кипкәндер яше.

**Дөнья тынычсызлыгы**

Ятып ятмас, үлеп үлмәс
Хәлебез мәңгегә мәллә,
Әзерлән дә көт зарыгып,
Ходайдан юк әмер әл дә.

Бу авыру өстә һәркемнең,
Чыдармы инде күп айлар?!
Ни хикмәт ауса, җимерелсә
Гакыл, инсаф вә вөҗданнар?!

Тынычсыз көндәлек тормыш,
Рәхәт юк һич күңелләргә,
Куандырмый да, көлдерми
Көләрдәй кай фикерләр дә.

Бу хәлләр инде тиз бетмәс,
Сөйсәләр бар да тик үзен,
Ачулы һәм дә үзсүзле
Олуглар бирмәсә сүзен.

**Нәрсә файда?**

Нәрсә файда ул агачтан, тәмле җимеш бирмәсә,
Нәрсә файда ул чәчәктән, хуш исләре килмәсә?

Нәрсә файда бай булып та, күрсәң мәңге хәстәлек,
Нәрсә файда сөешүдән, тик булса бер һәфтәлек (атна.— *Х. М.*)?

Нәрсә файда ул хатыннан, өйгә күңелен салмаса,
Нәрсә файда андый ирдән, эчсә, карта уйнаса?

Нәрсә файда дус булудан милләтен саткан белән,
Нәрсә файда сөйләшүдән нык кына капкан белән?

Нәрсә файда ул шәкерттән, уйласа бары үзен,

Сөймәсә үз милләтен, кызганса әйтер сүзен?

**Мәзһәб**

Беләм мин, дус, синең күңелең боеккан төрле хәлләргә,
Изгәннәр безне күп еллар залимнәр төрле мәлләрдә.

Егылган алар алдында иманнар һәм дә вөҗданнар,
Бөгелгән күпме бил вә баш, агылган азмы соң каннар?

Вакыт җитте, уян син дә, киереп күкрәк сулыш ал да,
Күтәр йодрыгың селкеп бер, бар бит синең көчең әле дә.

Хөррә (азат, бәйсез.— *Х. М.*) ит үзеңне үзең
бу разыйлыктан, бу хурлыктан,
Йә, син әйт, бер фикер ит тә, ни тәм бар соң бу коллыктан?!

**Фәкыйрьлек һәм хатын**

Ир боекмас фәкыйрьлектән өе булса җылы, якты,
Хатыны булса инсафлы, гакыллы һәм дә өй яклы.

Көлеп алса ирен каршы, аның муенына ул ауса,
Бу тормыштан разый булып, ачык йөз белән елмайса.

Өмет бирсә вә юатса, тәмиз (чиста, пакь.— *Х. М.*)
өйдә ашын бирсә,
Ир шатлыгына шатланып, ире кайгысына көйсә.

Бу тормыш инде җәннәттер, бәхетле вә сәгадәтле,
Ир боекмас андый чакта, куәтле ул вә дәүләтле.

Фәрештә тик андый хатын, оҗмахта булыр урыны,
Көләч йөз, тәмле сүз илә чәчәр анда да ул нурны.

**Уян, бәгърем**

*(«Уян, татар» көенә)*

Тор син, бәгърем, күзеңне ач,
Уян бу гафләтлекләрдән
(ваемсызлыклардан.— *Х. М.*).
Киер канатың, селкен дә,
Уян бу мескенлекләрдән.

Уйла син ул бабаңларны,
Көчле, милекле шаһ-ханнарны.
Кайда киткән ник ул заман,
Башла сагнырга анларны.

Эзлә син, ач тарихыңны,
Тапсаң син анлар кайдалар.—
Ерткан дошман, яккан барсын,
Юктыр үз телеңдә анлар.

Дәртең кайда?! Дәрманың да
Бармы синең татар углы?!
Күрмисеңме, кан-яшь берлән
Бәхетсез милләтең еглый.

Углы син бит — син шул кандан,
Сөяргә мәҗбүр син җандан,

Уйла, эшкә башла, бәгърем,
Котыл әрнүле вөҗданнан.

Ник калдык без бу көлкегә?
Кол булып бетәмез әл дә.
Безнең кебек гафилләр күк
Юкдыр һичбер бүтән бәндә.

## Милләт маршы

*(«Кодрәтлем падишаһ» көенә)*

Дөп-дөп басып атла шаг (адым.— *Х. М.*),
Котласын безләрне шаһ.
Ислам урдусы (гаскәре.— *Х. М.*) йөрегәндә,
Тетрәсен йир шап та шап.
Милләтем, кодрәтем, син минем бөтен дәртем,
Син шатлансаң — мин шатланам, син бит минем милләтем.
(Ике мәртәбә)

Атла алга урдумыз,
Булсын саглам (нык.— *Х. М.*) йортымыз.
Дошманга каршы килгәндә,
Чыкмый безнең котымыз.
Милләтем, кодрәтем, син минем бөтен дәртем,
Син дәртләнсәң — мин дәртләнәм, син бит минем милләтем.
(Ике мәртәбә)

Көн-төн сагынам, аһ итәм,
Үлсәм мин шәһид китәм.
Безнең милләт — бик зур милләт.
Хөрмәтлә, мин яд итәм (искә алам.— *Х. М.*).
Милләтем, кодрәтем, син минем бөтен дәртем,
Син кайгырсаң — мин кайгырам, син бит минем милләтем.
(Ике мәртәбә)

Бардыр безнең шаһымыз,
Бар хан-солтанларымыз:
Шунларны саклау юлында
Түгелсен канларымыз.
Милләтем, кодрәтем, син минем бөтен дәртем,
Син егласаң — мин дә еглыйм, син бит минем милләтем.
(Ике мәртәбә)

Безнең тарих — зур тарих,
Шуларны укып карыйк,
Шул тарихны яд иткәндә,
Шадлыктан таңга калыйк.
Милләтем, кодрәтем, син бит минем бөтен дәртем,
Син яшәсәң — мин дә яшим, син бит минем милләтем.
(Ике мәртәбә)

## Соңгы ядкярем

(*Әтиемнең кабер ташына*)

Шад бул, әти, мәркадеңдә (кабереңдә.— *Х. М.*),
без онытмыйбыз сине,
Чөнки сөйдек чын күңелдән без барымыз да сине.

Дөньяда булган синең дуст-ишләрең, кардәшләрең
Итде хөрмәт, сөйде барсы һәм дә сагынырлар сине.

Шад идең син, саф идең һәм чын мөселман син идең,
Чын иманлы, нурлы йөзле, күкдәге йолдыз идең.

Хөрмәт итсәк тә сине без, кадреңне күп белмәдек,
Аңладык соң, чөнки башта без сукыр — күзсез идек.

Бул, әти бәгърем, бәхил, ит безне күңелдән гафу,
Ит дога, китсен күңелләрдән, әти, безнең агу.

Мөхтәрәм карт, әүлия, бирсен Хода җәннәт сиңа,
Якты булсын мәркадең һәм дә Иман ибдәш сиңа.

Ят, тыныч йокла, әти, кабрең синең тар булмасын,
Эч суын, бирсен Илаһым — хаузы-кәүсәр елгасын!

### Туган ил тәэсирендән

Нинди хәлдәдер икәндер ул минем туган илем,
Әллә бу искән җылы җил китрәдер аның җилен.

Юк тавыш, һич өн дә чыкмый, калмаганмы берсе дә,
Әллә әнкәм бик ерак, ул чөнки гарше көрсидә
(теге дөньяда.— *Х. М.*).

Калмаганмы бер туган ди? Юкмы кардәш, күршеләр,
Әллә беткәнме хәзер ул җанлы, татлы йөрешүләр...

Әллә кипкән елгалар, ауганмы урман-каргалар
(куаклар.— *Х. М.*),
Өн дә юк! Һич моң да юк, соң нинди анда хәлдәләр?

Ни бәхет, җил кайтса илгә, сөйләсә миндән сәлам,
Әйтсә анда — мин аларны нинди күб сагынып калам.

### Сандугачка

[*«Каригласки («Карие глазки».— Х. М.)» көенә*]

Сандугач тик сайрый моңлы, ач булса — тук булса да,
Тоткын ул, читлеге алтындан, көмештән булса да.

Уйласаң бер ис китәрлек,— ник адәм мондый начар,
Һич гөнаһсыз Тәңре кошын ул тотар, мәхбүс
(тоткын.— *Х. М.*) ясар.

Сандугач син сайрыйсың, тик аглыйсың
(елыйсың.— *Х. М.*) — сайрау түгел,
Моңлы таушың бит сине итде хәраб — инсанга кол.

Каргама мәзлүм (кимсетелгән.— *Х. М.*) асыл кош,
тәкъдирең кушкан шулай,
Син сөйкемле кошны айру безгә бик агыр бугай...

Сайра, былбыл, агла, моңла, түз бу кара бәхтеңә,
Читлегеңдән, шөбһәсез, беркөн күчәрсең ләхдеңә.

### Яшь чак

Шаулый инде, чөнки шаулар вакыт бит гомрем җиле,
Мәҗбүр ул шауларга, котырынган хәзер күңлем иле!

### Әшкаре (ихластан.— *Х. М.*) әйтәм

Мин — мәхәббәт зәһре милләткә, аның киң кальбенә,
Мин — йогышлы ауру җисменә, аның зур гаклына.

Мин сөям чиксез, дәхи мәҗбүр сөяргә ул мине,
Юк исә тылсым илән сүдрәм (сөйдерәм.— *Х. М.*),
котылдырмыйм аны.

Саф калебне сызлатып, ул хальне алган рәнҗүләр,
Ул ике күздин түгелгән — ул хисапсыз энҗүләр...

Бар да бит милләт синең өчен, белмәгә вөҗдан кирәк,
Бел дисәң хуш, мин синең өчен — бер корал я бер кораб!

### Хатын-кызлар

Бу дөньяда табигый бер гадәт бардыр ки, һәр ирләр
Хатын-кыз күрсә, күңле йомшара һәм тетриләр... анлар.

Тәбәссем берлә (елмаеп.— *Х. М.*) бер иргә әмер итсә
хатын-кызлар,
Кылыр, ни генә җинаять эш, ки хәтта сәҗдә кылырлар.

Нидән соң бу, йа Рабби?! Кыз-хатынларга ни бу хөрмәт?
Диеб, бер Тәңрегә беркөнне мин кылдым да мөнәҗәт;

Ишетдем йоклаган йиремдә, диләр: чикмә син хәсрәт,
Сора фәкать ишандан: ник синең биш хатының, хәзрәт?

### Үлем түшәгендә

Әй мөкатдәс изге юл син, күп бәрелдең бәгъремә,
Син мине изгән саен бик, мин юнәлдем Тәңремә.

Калмады итләр тәнемдә, калмады һич канларым,
Куркынып бетдем — кала монда икән дип җанларым.

Бетде көчләр һәм өмидләр, юк ашау, бетде йокы,
Як-ягым тын, иштәмен тик тыштагы азан уку.

Шушы булган тәкъдиремнең язганы — монда бетү,
Шулмы булган соңгы гомремдәге шатлыклар көтү.

Әй Ходай, кил син үзең, коткар мине көч хәл дә бер,
Мин гариб, мескен колыңның инде ахрын монда бир.

Эстәлием гаршеңне, көрсеңне, мине кайтар үгә,
Анда бит кардәш, якынлар, анда бит рухлар үбә.

Анда салкын, анда кар бар, анда ашлар тәмлеләр,
Анда йөзләр һәм сыйфатлар бар да бит бик ямьлеләр...

*Хаҗ сәфәрендә, Әл-Мәдинәтел-мөнәүвәрә,*
*3 нче февраль, 1970*

**Фин татарлары**

Бәхетле ул: Ходай биргән бәхетләр һәм дә күп байлык,
Гакыллы ул: фәкать анда гына вөждан да инсанлык...

Хатадыр барсы да, тик ул — фәкать ул гына бик тугры,
Аныңча булмаса, саклан, хәзер ул нәрсәдер уйлый.

Карамый ул — аның каршында, остаз я милләтче,
Атар «ук», чөнки вөжданы аның мәгърур вә миннәтче
(мәгънәле.— *Х. М.*).

Бу хәлләр бездә булган эш, атылды «ук» галимнәргә*,
Качып китте рәзил (түбән.— *Х. М.*) хәлдә Гаяз, Идрис,
Закирлар да.

Бу инде бик гаҗиб (гаҗәеп.— *Х. М.*) нәрсә түгел, бай бит
һаман бай ул,
Шигырь язган чагымда килде башка тик менә шул уй:

Әгәр килсә Мөхәммәд чалма берлән һәм дә үз төсдән
Киенгән бер сыйфатлы Алла да иңсә дә һәм күкдән;

Сүләсәләр болар,— яңлыш тисә яшьләргә, байларга,
Төрк берлегенә һәм дә мөтәгассыйб агайларга.

Диеб әйтәм: «Йәмин берлән качар тиз бу ике зат да,
Болар да, шөбһәсез, сүгелер «надан, ахмак» диеб артда».

**Мәрхүм Гыймад Җәмал** дәфенендә**

Әй Гыймад, килде хәзер гомрең буе көткән әҗәл,
Безгә бу синең белән бит аерылу бигрәк тә җәл.

Актук*** иле иде туган илең, анда тугды синең йолдыз,
Батды шимальдә хәзер, әйләнде төнгә көндезең.

Төнгә әйләнсә дә кабрең, шунда ятсаң да үлеп,
Нурлатыр «ул йолдызың» анда да кабреңә кереп.

Калдырып китсәң дә безне, очса да күккә рухың,
Изге эшләреңне бетереп, милли бурычыңның йөген.

Калды безгә изге кабрең, калды бик шәп сүзләрең,
Калды сагынырлык эшең, күркәм иманлы йөзләрең.

Мәрхәмәт итсен Ходай, мен күккә гарше көрсигә,
Бул бәхил, һич калмасын үпкә, пинәүләр (шөбһә.— *Х. М.*)
берсе дә.

Без әле истә тотармыз, һәммәбез сагыныр сине,
Йөз түгел, меңләрчә кылган яхшылык берлән сине.

Елый артыңдан җамигълар (барысы.— *Х. М.*)... һәм дә
мәктәб, хәлфәләр,
Елый «Ислам йорты», андагы ефәк һәм хәтфәләр...

Ят тыныч яткан йиреңдә, мөхтәрәм ших (шәех,
хөрмәтле.— *Х. М.*), әй Гыймад,
Изге эшләрең хәзер сиңа итәләр илтифат.

**Адашкан халык**

Бөтен тоткан эшемез дингә каршы һәм тиреслекдә
(кирелектә.— *Х. М.*);
Кая тикле барырмыз инде күрнер, бәлки, тизлекдә.

Ходай каршында бер чүп! — Без хисап итсәк дә бик зурга,
Фәкать ул инде коткарсын калудан безне ким-хурга.

Аяк астында табталган аятьләр һәм дә Коръәнләр,
Булырмы соң хәзер бездә алардан инде курыкканлар.

Ди ул Коръән: «Әҗәл бардыр, һәр өммәткә килер бер көн,
Сынармын сезне мөэминләр, ачу килгәнчә, сез өркең...»

Беләм, Тәңрем, гөнаһ бездә, ябанчы (чит.— *Х. М.*) йирдә без
ирексез,
Яраттың бит үзең безне — гакылсыз һәм дә нигезсез.

**Табигать серләре**

Яраткан булса иде Тәңре дөньяны караңгы төн,
Кояшсыз булса һәм айсыз, күренмәс булса якты көн;—

Булыр иде әҗәл ансат, үлемдән кем дә курыкмаста!
Барыбер соң түгелме — өстә йирнең я аста?!

Кызыгырлар иде әл дә (алда.— *Х. М.*) күрергә тиз
оҗмахларны,
Шулай ук анда да сөйләнсә бик якты оҗмах барны.

Бозыклык, бәлки, булмас, булса, бәлки, һич чиге юкда,
Уран йолдызы һәм Нептун хәзер шул хәлдәләр күкдә.

**Муса Ярулла (Бигиев) рухына**

Шактый гына бер тыныч торганда килде көз көне.
Әллә шунданмы икән соң чыкмый кошларның өне?

Калмаган күрек йирдә дә, урман да койган яфрагын,
Чайкала сулар да, диңгезләр дә котырынган тагын.

Җил өрә шундый рәхимсез, сызгыралар морҗалар,
Төм (дөм.— *Х. М.*) караңгы өй кала, көндездә ут
сүндерсәләр.

Каплаган дөньяны пәрдә, тулган ул золмәт белән,
Бар да корыган, чөнки кояш бакмый чәһрәсе (йөзе.— *Х. М.*)
белән.

Чыкмый башка бер тавыш, тик җил өрә, яңгыр ява,
Көч белән өргәнгә җил тыштагы урманлар ава.

Җырламый үрдәк, бакалар, каргалар да чәүкәләр,
Әй Ходаем, соң кая китеп икән беткән алар?

Никдер инде эт дә өрми, әллә ул эчдән елый,
Әллә шашканлармы? — Кырда бүреләр генә улый.

Әй Ходай, ни булды соң? Ник бу көзең бик куркыта,

Әллә шайтаннармы котырынган, аларны йир йота?

Дәҗҗалың* чыкканмы юкка,— Яэҗүҗеңме, Мәэҗүҗең**?
Әллә салдыңмы каһәреңне бу дөньяда үзең?

Бер дә инде калмаган бит дөньяның ямь-тәмләре, —
Бар да корыган, ләбшерәп беткән яшел үләнләре.

Төн дә бу көн бик караңгы, ай да инде калыкмаган,
Ялгызак бер якты йолдыз гына никдер батмаган.

Калтырый ул, каушаган тик селкенә, ләп-ләп итә,
Нәрсә булган соң бу йолдызга — сүнә... терелеп китә.

Ниндидер бер көч аны изә, гүя ул ялвара,
Инде, ахры, ул бичара соңгы сулышын ала.

Аһ, бу безгә нинди йолдыз, ул бит безнеке,
Бир мәдәд (ярдәм.— *Х. М.*), Тәңре, аңар — ул бит Муса, безнең Биги.

Сүнмәсен ул, бетмәсен ул, күктә торсын яктысы,
Ни гаеб соң эшләде? Хоть безгә калсын яртысы.

Ул бирә бит безгә нур, ул җылмаеп безгә бага,
Ул танулы әһле исламларга, бөтен дөньяга.

Ник бу затка мондый тартыш, мондый дәһшәт-куркыныч,
Бер дә бит ул күрмәде дөньяда, әй Тәңрем, тыныч.

Әллә чындан тартышамы, соңгы сулышнымы ала,
Әллә Газраил аның чындандамы җанын ала?

Бер дәме юк шәфкатең соң? Мәзлүм ул бит нур гына,
Инде кызган безне дә — юк башкамыз, бер шул гына!

Аһ, бу өмид китде бушка, шартлады күк бик каты,
Сүнде йолдыз, чыкты җан, килде Мусаның вафаты.

Тетрәде йир, үлде Муса, булды хәсрәтдән азат,
Кайгы төшде дөньяга — Муса Җарулла дип вафат.

Төште кулдан бу бәхетләр, калды буш йодрык кына,
Агласак агларга калды кычкырып үкреп кенә.

Белмәдек кадрен аның без, белмәде һәм милләте,
Белмәсәк тә калды дөньяда аның зур хезмәте.

### Иркәләнү

Без, димез, хот (хоть.— *Х. М.*) без дисәк тә, бездә бар ислам дине,
Чатнаган булса да мең төрле золымлардан биле.
Бездә булган әүлиялар, шаһлары һәм ханлары,

Әл дә мәшһүрләр бу көндә — мәңге бетмәс данлары...

Мең түгел, йөз мең дә булган чалмалы шәп муллалар,
Бик күбе язган китап, меңләп түгел — миллион алар.

Бар Тукай, Мәҗид Гафури, Дәрдемәнде һәм башкалар,

Бар Гаяз, Идрис Галимҗан, бар Муса Җаруллалар...

Батталын да әйтми узмыйк һәм Зәки Вәлидне дә,—
Тик бәхетсезләр алар, илсез бәхет юк бернидә.

**Куанычым**

Сөям мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым,
Сүгән бер эшне эшләү берлә мин гомремдә тәм таптым.

Күченмәк юк бу фикеремдән, оялмыйм һич татарлыктан,
Үкенмим, сакласын Аллам мине андый начарлыктан.

Көләм мәсхәрәле күз берлән, татарлыкны — яшергәндән,
Итәм нәфрәт эчем берлән, көләм мин инде ул «мән»дән
(«заттан».— *Х. М.*).

Татар булгач татармын мин, шуңардан бәхтиярмын да,
Көләрмен һәм татар бәхтенә, хәсрәткә җылармын да.

Сүләрмен мин татарча һәм язармын да шигырь әл дә,
Тырышам, күрсәтәм бу тел белән нишләгәнен бәндә.

Үзем мангул, бабам мангул, шуңардан миндә көч күп тә,
Шуңардан бит бабамларга Ходай биргән урын күктә!

## ЕРАК ЯПУНИЯДӘ БАСЫЛГАН ТАТАР КИТАБЫ

Читтәге татарлар, аларның җыр-моңнары, гәҗит-журналлары, басма китаплары хакында сүз чыкса, ирексездән, Сибгат ага Хәкимнең «Сибелә чәчәк» шигыре (1970) искә төшә:

...Бу йөрәккә төрле дәва кирәк,
Туңам көндез, туңам төннәрдә;
Савыктыргыч иң шифалы дәва,
Беләм, беләм, туган телләрдә...

...«Сибелә чәчәк»... Болай бу кадәрле
Моңсу түгел идең син элек.
Көз. Кавказда концерт. Ишетәм залдан:
«Сибелдек шул, дуслар, сибелдек».

Әйе, сибелдек, таралдык, чәчелдек шул, милләттәшләр... Яңадан кайчан җыелырбыз — анысы бер Ходай Тәгаләгә мәгълүм.

**I**

Язмыш татарны бөтен дөньяга тараткан. Әмма ул, кайда гына булмасын, үзенең асыл Ватанын — Идел-йортны, халкын сагынып яшәгән, иленә, туган җиренә һич тә ачу тотмаган; бит, Дәрдемәнд әйтмешли, «Илдә бер дуст булмаса гәр, Ил бөтен дошман түгел!» Халык үзенең милли асылын, гореф-гадәтләрен, телен, динен, моңын сакларга, буыннан буынга җиткерергә омтылган: мәктәп-мәдрәсәләр ачкан, төрле түгәрәкләр, кичәләр, спектакльләр оештырган, гәҗит-журналлар, китаплар чыгарган, Сөембикә һәм Тукайны үзенең милли символы иткән. Чит мәмләкәтләрдә басылган татар китапларының зур өлеше Тукайныкы булу да күп кенә нәрсә хакында сөйли.

Татар мөһаҗирләренең мөһим бер төбәге — Ерак Шәрык. Анда Идел-Урал буйларыннан татар сәүдәгәрләренең, укымышлыларының, эшчеләренең XIX гасырда ук барып чыгулары мәгълүм. XX йөз башында ук Харбинда күренекле язучы Шакир Мөхәммәд исәп-хисап, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Шушы ук калада 1906 елда татар мәхәлләсе оеша.

Октябрь инкыйлабы һәм ачлык елларында Ерак Шәрыкта яшәүче милләттәшләребезнең саны тагын да күбәеп китә. Япуния, Маньчжурия, Кытай, Корея мәмләкәтләрендәге татарлар үзара аралашып, керешеп, чагыштырмача тотрыклы бер мәдәни регионны тәшкил итәләр. Бирелә «Ерак Шәрык» (Харбин, 1920—1925), «Азад Шәрык» (1923), «Шәрык авазы» (Тяньцзинь, 1939—4940), «Шәкердләр таңы» (Мукден, 1934—1935), «Мең ел» (Харбин, 1922), «Игъланел-хакыйкать» (Токио, 1936), «Япун мөхбире» (Токио, 1931—1932), «Яңа япун мөхбире» (Токио, 1932—1945) һ.б. мәҗмуга-журналларның, «Милли Байрак» (Мукден, 1935—1945), «Тәммүз» (Харбин, 1925—?), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934), «Чаткы» (Харбин, 1932—1933) һ. б. гәҗитләренең чыгуы мәгълүм. 1933 елда Мукденда Ерак Шәрык төрек-татарларының дини вә милли мәркәзе төзелә.

Ерак Шәрыкның төрле төбәкләрендә шактый гына китаплар да нәшер кылына. Мәсәлән: *Солтан*. Шигырьләр.— Харбин, 1929.— 27 б.; *Исхак Хәйрулла.* Төш.— Харбин, 1922.— 20 б.; *А. Баттал.* Төрек-татар тарихы.— Мукден, 1938.— 155 б.; *М. Корбангали*. Татар әлифбасы.— Харбин, 1920.— 75 б.; *Һади Максуди.* Гыйбадәти исламия.— Мукден, 1940.— 24 б.; Габдулла Тукай мәҗмугасы.— Мукден, 1938.— 98 б. һ. б.

20 нче елларның урталарыннан башлап Ерак Шәрык татар мәдәни һәм иҗтимагый тормышында Япуния төбәгенең роле арта бара. Токиода 1924 елда милли мәхәллә, 1927 елда татар мәктәбе эшли башлый. Бераздан бу төр оешмалар Кобе һәм Нагоя калаларында күренә. 1927 елда Токиода татар нәшрияты («Матбагаи Исламия») ачыла. Әүвәл гарәп хәрефләренә кытлык була. Әмма Төркия латин язуына күчкәч, аннан бик күп гарәп хәрефләре алып кайталар. 30 нчы елларда «Матбагаи Исламия» гөрләтеп эшли башлый.

Ерак Шәрыкта, бигрәк тә Япуниядә, татар гәҗит-журналларын, китапларын чыгаруга Гыйниятулла Сәлиәхмәд, Мөхәммәд Алтынбай, Хөсәен Габдүш (1901—1944), Шаһвәли Келәүле (Илдәр) (1900—21.IV.1970), Заһидулла Агыш (1881—1970), Рабига Әгерҗе (Дәүш) (1904—1973), Ибраһим Бадай (20.V.1907—1976) һәм башка милләтпәрвәрләр үзләреннән зур өлеш кертәләр. Матди яктан Әхмәд Вәли Мәңгәр (8.XII.1891—10.XI.1978) аеруча нык ярдәм күрсәтә, 1970—1980 елларда Төркиядә чыккан «Казан» журналының да төп спонсоры була. Токио имамы Мөхәммәд Корбангали (1892—22.VIII.1972) Япуниядә татарча китаплар чыгару белән турыдан-туры үзе шөгыльләнә. Татар, төрек, гарәп, фарсы, урыс, япун телләрен камил белгән бу зат сугыш елларында Маньчжуриягә күчеп килә. 1945 елда, Ерак Шәрыктагы башка күп кенә татарлар кебек, ул да Совет органнары тарафыннан кулга алына һәм 10 ел буе төрмәдә утыра. Үлеме — Чиләбе каласында.

Татарларның шактый өлеше Төркиягә, АКШка, Канадага, Австралиягә һәм башка илләргә качып, күчеп китә. Хәзерге вакытта Кытайда, Кореяда, Япуниядә бик аз санлы гына татарларның яшәве мәгълүм.

Шунысын да искәртик: 20 нче елларда, нигездә, Харбин һәм Хайлар калаларында яшәгән бер төркем татар яшьләре һәм кызлары Берлин университетының медицина, шәрык факультетларында белем алалар. Алар арасыннан Рәшит Рәхмәти Арат, Ибраһим Вәли кебек мәшһүр профессорлар да чыга. Гаяз Исхакый, Гали Акыш, Мәхмүт Таһир, Надир Дәүләт, Фәридә Хәмид, Наилә Бинарк һәм кайбер башка билгеле каләм ияләре дә теге яки бу дәрәҗәдә Ерак Шәрык белән бәйләнешле. 1991 ел ахырында вафат булган хөрмәтле Мәхмүт ага Таһирның бу төбәктәге татарларның тарихын, мәдәниятен өйрәнүдәге һәм пропагандалаудагы ифрат зур хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

## II

Токиодагы «Матбагаи Исламия»дә гарәп хәрефләре белән шактый гына китаплар басыла. Аларның бер өлеше — Ерак Шәрыкта язылган яисә төзелгән басмалар (*Хөсәен Габдүш*. Дүрт хикәя.— 1931.— 83 б.; *Мөнирә Сөләймания*. Кызларга махсус милли шигырьләр.— 1936.— 24 б.; Рәсемләр мәҗмугасы.— 1937.— 28 б. һ.б.), икенче бер өлеше — Казанда яки башка урыннарда элегрәк басылган китапларның күчермәләре (Бәдәвам шәриф китабы.— 1934.— 15 б.— 1882 елгы Казан басмасыннан; *Бикбулат Санатулла*. Ислам тарихы.— 1932.— 126 б.; Ахырзаман китабы.— 1934.— 15 б. һ. б.). Әмма аларга да кереш сүзләр, аерым аңлатмалар өстәлгән. Япуниядә дөнья күргән татар китапларының күпчелеген, әлбәттә, дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләре тәшкил иткән (*М. Корбангали, А. Баттал*. Татарча уку.— 1933.— 69 б.; *Г. Ибраһим*. Татар нәхүе.— 1935.— 77 б.; Татарча сарыф.— 1935.— 80 б.; *Абдулла углы*. Балалар бүлеге.— 1933.— 22 б. һ. б.). Аларда дини китаплар да шактый очрый (Коръән.— 1934.— 573 б.; Иман шарты.— 1934.— 34 б.; *Әхмәдһади Максуди.* «Тәһарәт», «Гакаид» һ. б.). Ел саен диярлек «Календарь»лар чыгып тора.

Токиода нәшер ителгән татар китапларының тиражлары зур түгел: нигездә, 100 белән 1000 арасында. Әмма хикмәт тиражда түгел, ә бу басмаларның тарихи факт буларак барлыгында. Алар шулай ук тематик һәм жанр төрлелекләре, эчтәлекләре һәм гомумән мәдәният тарихында тоткан урыннары белән дә игътибарга лаек. Менә минем алда — Г. Тукайның «Мәҗмугаи асаре». Ул бөек шагыйрьнең үлеменә 20 ел тулу уңае белән 1933 елда нәшер ителгән. Биш «бүлемдә, ягъни томда (I — шигырьләр, II — балалар кыйсеме, III — көлке вә һөҗү кыйсеме, IV — нәсер, V — тәрҗемәи хәле). Барлыгы 646 бит. Зур форматта, яхшы кәгазьдә! Һәр том азагында япунча язулар да күзгә ташлана.

Г. Тукай һәм башка китаплар хакындагы җентеклерәк сүз алып баруны вакытка калдырып, хәзер Токиода нәшер кылынган иң кечкенә дип әйтерлек басмаларның берсенә — «Нотага салынган шигырьләр» китабына — махсус тукталып китәрбез.

## III

Кечерәк форматлы 12 битлек бу китапчык 1930 елда «Матбагаи Исламия»дә дөнья күрә. Басманың ахырында япунча язмалар да бар. Өченче битне тулысы белән Сөембикә манарасының рәсеме алып тора. Китап «Бер-ике сүз» дип исемләнгән кереш белән башланып китә. Анда мондый юллар бар: «Безнең төрк-татар халкының соңгы буынының кыска гомер эчендә күргән икътисади, милли, дини, иҗтимагый вә гаиләви авырлыклары сәбәпле, күңеленә тулган моң вә зары башка халыкларның барысыныкындан да күбрәк вә артыграк булса да, аның моңзарын тәрҗеман булырлык шигырьләренең нотага салынмавы аркасында без бу матур шигырьләрне тәртипле рәвешдә көйләү шәрәфендән (бәхетеннән.— *Х. М.*) мәхрүм торамыз.

Хосусан, чит илдә, чит мәмләкәтдә, чит милләт күз алдында бу хәл безне күп вакыт оятлы кыладыр.

Ошбу йитешсезлегебезне игътибарга алып, Токиода «Мәктәбе Исламия»нең («Татар мәктәбе» күздә тотыла.— *Х. М.*) һәйәте тәгълимиясе (уку-укыту комитеты идарәсе.— *Х. М.*) Ерак Шәрыкта, һич булмаса, мәктәп балаларына үгрәтү өчен, бу китабда булган шигырьләрне нотага салдырып нәшер итдерәдер. Һәйәте тәгълимия укучылардан үзенең башлап эшләгән бу эшендә булган кимчелекләрен күрсәтүләрен үтенә вә киләчәктә аларны төзәтергә алдан ук вәгъдә бирәдер.

Ихтирам илә: Токиода «Мәктәбе Исламия»нең һәйәте тәгълимиясе. 1930 ел, беренче апрель...»

Димәк, китапчык, мәктәп укытучылары тарафыннан әзерләнеп, укучы балаларга адресланган, аларны милли рухта тәрбияләүне күз уңында тоткан.

Басмада «Илне сагыну» һәм «Сөембикә манарасы» җырларының тәүге юллары, кушымталары нотага салып бирелгән.

Китапта 5 шигъри әсәр, ягъни җыр, бәет бар. Беренчесе — «Илне сагыну» дип аталганы — бөтен эчтәлеге, рухы белән җырның исеменә туры килеп тора... Анда сагынудан шашар дәрәҗәгә җиткән лирик геройның рухи халәте «туган ил» һәм «чит җир» төшенчәләрен капма-каршы яисә янәшә кую алымнары аша гаять тәэсирле итеп тасвирлана.

Чит тарафда күк тә нурлы,
Җир — чәчәк дә гөл генә (шул).

Кушымта:

Очып китәрдәй булам ла, кайтып җитәрдәй булам,
Кичке ачы җилләрдә лә туган-үскән илләргә.

Алга таба бу кушымта, югарыдагы кебек, һәр «мисрагъ»тан (ягъни шигъри строфаның яртысыннан) соң кабатланып бара. Җыр текстының авторы күрсәтелмәгән. Әмма кайбер юллар җырның яисә аның аерым өлешләренең чит мәмләкәттә, инкыйлабтан соң иҗат ителүенә дә ишарә ясыйлар.

Китапчыкта С. Рәмиевнең «Авыл» һәм Г. Тукайның «Туган ил» шигырьләре дә бирелгән. Ләкин беренчесенең — ахыргы бер, ә икенче шигырьнең соңгы өч строфасы юк. Тукай томнарында «Туган ил» әсәре «Туган җиремә» исеме белән басыла. Әмма элек нәшер кылынган аерым китапларда, җөмләдән шагыйрьнең «Мәктәпдә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясендә, 1933 елгы Токио басмасында бу шигырь «Туган илемә» атамасы белән мәгълүм.

Шунысы кызыклы: һәм «Авыл», һәм «Туган ил» текстлары без карый торган китапчыкта «Илне сагыну» җырындагы кушымта белән бирелгәннәр.

И авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш (шул) (кушымта).
Бер кеше юк бер урамда,
Нинди тын һәм нинди буш (шул) (кушымта).

Алга таба шигырь шушы рәвештә дәвам иттерелә. Г. Тукайда һәр «мисраг»тан соң шул ук кушымта кабатлана:

Айрылыб китсәм дә синнән гомремнең таңында мин (шул)
(кушымта).
И Казан арты! Сиңа кайтдым сөеб тагын да мин (шул)
(кушымта).

Һәм «Илне сагыну», һәм «Авыл», һәм «Туган ил» әсәрләре үзләренең рухлары белән бер-берсенә аваздаш. Аларда туган җирнең матурлыгына, газизлегенә, кабатланмаслыгына мәдхия җырлана.

С. Рәмиев туган җирнең гүзәллеген, аның үзендә торып, авыл образы аркылы сурәтли. Ә инде калган ике әсәрдә туган җирне сагыну, юксыну хисләре ерактан, аерылу аркылы бирелә, һәр өч текстның бер үк көйгә җырлануы да аларны эчке, рухи яктан якынайта.

«Бардым күлгә, салдым кармак...» дип башланган «Көзге ачы җилләрдә» җыры хәзерге күпчелек татарга таныш. Аны «Окоп көе» дип тә йөрткәннәр. А. Ключарев бу көйнең урыс-япун сугышы чорында ук мәгълүм булуын искәртә (карагыз: *Җәүдәт Фәйзи*. Халык җәүһәрләре.— Казан, 1971.— 33 б.). Мөгаен, болай әйтүдә хаклык бардыр. Чөнки бу көй Ерак Шәрыкта, шул исәптән Япуния татарлары арасында да, күптәннән билгеле һәм популяр. Аның Токио басмасына кертелүе, С. Рәмиев һәм Г. Тукай шигырьләренең шул аһәңгә җырлануы бу көйнең мәшһүрлеген, читтәге татарларның рухи халәтенә аваздаш булуын янә бер мәртәбә күрсәтеп тора.

Токио басмасындагы һәм Җ. Фәйзи китабындагы көйләрнең музыкаль яңгырашында аерма юк (моны композитор Котдус Хөснуллин да раслады). Әмма сүз текстында ике үзгәлек бар. Япун басмасында «йөгереп» сүзе урынына «очып», ә «көзге» урынына «кичке» сүзләре килгән. Бу исә сагыну, илгә тартылу хисен тагын да арттыруга ярдәм итә. «Йөгерү» диюгә караганда, «очу» сүзе ашкыну халәтен көчлерәк бирә. Гадәттә, «ачы» җил көзгә, кышка хас. Шуңа күрә бу сүзтезмә «көзге» сүзеннән башка да ел фасылының нindiлегенә ишарә ясый. Ә инде «кичке» сүзе, бернәрсәгә дә карамастан, хәтта караңгы вакытта да туган-үскән илгә тартылуны күрсәтә.

Токио басмасындагы дүртенче әсәр — «Сөембикә манарасы». Кызганыч ки, чит ил татарлары арасында хәзер дә популяр булган бу әсәр (аны кайчак «Манара бәете» дип тә йөртәләр) бездә мәгълүм сәбәпләр аркасында озак еллар буе басылмый да, көйләнми дә килде.

Әсәрдәге «Сөембикә манараңда әйтәләр бу көн азан», «Озакламый төшә инде башыңдан орел синең» кебек юллар текстның 1917 елның март һәм сентябрь аралыкларында иҗат ителүен күрсәтәләр. Чөнки Сөембикә манарасыннан «орел» 1917 елның сентябрь-октябрь тирәләрендә алына (*Ә. Еники.* Тарих мирасы // Мирас.— 1992.— № 3.— 77—80 б.)

Токиода нәшер кылынган китапчыкта шулай ук «Уян, татар!» әсәре дә кыскартып урнаштырылган. Бу шигырьнең авторы күрсәтелмәгән. Әмма татарны уяныргa, көрәшкә, азатлыкка чакырган мондый рухлы әсәрләр XX йөз башы әдәбияты, аеруча «Шәкерд садәләре» өчен хас. Бу традиция мөһаҗирләр поэзиясендә 20—30 нчы елларда да дәвам итә. Мәсәлән, Шанхайда яшәүче Мансур Арсланбәкнең «Милли намаз» шигыре («Яңа милли юл» журналы.— 1935.— № 7.—25—26 б.):

...И туган, син күп изелдең, инде йитде, тор, уян!
Үтде төн, һәм таң да атды, кычкырып әйт син азан!..

«Уян, татар» шигыре хәзерге көн татар иҗтимагый, сәяси тормышы өчен дә аваздаш.

Рәдиф Гаташның «Татар китабы» дигән бик мәгънәле яңгырашлы шигыре бар. Анда Болгар чорыннан башланган татар китабының гыйбрәтле язмышы тасвирлана:

...Сөйлә, китап, нинди гамьнәр кичеп,
Төрле илләр үтеп, шулай да
Бирдең алмаз телебез ачкычларын,
Бабамнарның газиз тавышларын
Ишеттердең ничек Тукайга?!

Моннан 60 еллар элек ерак Япуниядә басылган «Нотага салынган шигырьләр» китабы да — күпгасырлык татар кульязма һәм басма сүзенең бер буыны, бер ядкяре. Анда да без халкыбызның гамен, моңын, рухи халәтен ишетәбез, тоябыз, туган җиренә тартылуын, туган халкын, телен сөюен күрәбез. 1930 елда Токиода басылган Г. Тукайның «Җуаныч» китабының керешендә мондый юллар бар: «Милләт үзе бетмәсә, аның тел вә әдәбияты бетмәс, тел вә әдәбияты бетсә, ул милләт дөньяда яшәмәс». Чит мәмләкәтләрдә дөнья күргән татар китаплары милләтебезне, аның телен һәм әдәбиятын саклауны, үстерүне күздә тотып басылганнар да инде.

Укучылар игътибарына «Нотага салынган шигырьләр» китабыннан «Илне сагыну», «Уян, татар!» һәм «Сөембикә манарасы» әсәрләрен тәкъдим итәбез. Сүзләрнең язылышы, нигездә, үзгәрешсез, китаптагыча бирелә.

*1992*

## Илне сагыну

Чит тарафда күк тә нурлы,

Җир — чәчәк дә гөл генә (шул).

Кушымта:

Очып китәрдәй булам ла, кайтып җитәрдәй булам,
Кичке ачы җилләрдә лә туган-үскән илләргә.
*(Һәр мисраг артыннан тәкрарланыр.)*

Анда шаулый елгалар,
Әмма туган җир чүл генә (шул) (кушымта).
Чит тараф ни чаклы якты
Булса да, күрми күзем (шул) (кушымта).
Һәм онытдырмый туган илнең
Газаблы күк йөзен (шул) (кушымта).
Чит тарафның дөньясындан
Мин гомер дә көнләмим (шул) (кушымта).
Читдәге көнгә туган җирнең
Төнен дә тиңләмим (шул) (кушымта).
Чит кояшның нурларыннан
Тәм ала алмыйм, алмыймын (шул) (кушымта).
Үз илемнең йолдызын да
Һәм аен он(ы)та алмыймын (шул) (кушымта).
Ямь, бәхет берлән тулы,—
Ят ил матурланган ята (шул) (кушымта).
Монда мәңге җәй, җылы көн,
Гөл мәңге чәчәк ата (шул) (кушымта).
Чит тараф, сүз юк, бәхетле.
Халкы шад, иркен тора (шул) (кушымта).
Үз илемдә мескен(ем) халкым
Газабдан аһ! ора (шул) (кушымта).
Безнең илдә юк азык,
Юк яктылык, шадлык, белем (шул) (кушымта).
Нәкъ сихерләнгән җаным,
Тарта туган-үскән ягым (шул) (кушымта).
Әллә үткәнгә элек шунда
Минем яшьрәк чагым (шул) (кушымта).
Әллә күңлемне шуңа тарта
Минем нурлы илем (шул) (кушымта).

**Уян, татар!**

Уян, татар, ач күзеңне,
Дөньяга тугры кара,
Ошбу көндә җан сөйгән
Милләткәең кыр(ы)лып бара.
Тәкрар (кабатлау.— *Х. М.*).

Йокламаса (йокламачы.— *Х. М.*), ач күзеңне,
Чынлаб ук эшкә тотын,
Каршы килгән дошманыңны,
«Мин татар!» — диб куркытың.
Тәкрар.

Ничә йөз елның буенча
Изделәр дошманларың,
Искә төшер, кайда Чыңгыз,
Кайда Бату ханнарың!
Тәкрар.

**Сөембикә манарасы**

Чын хурлыкда торсаң да син
Дүрт йөз ел буе Казан,
Сөембикә манараңда
Әйтәләр бу көн (бүген.— *Х. М.*) азан.
Тәкрар.

И манара, шадлан, бу көн
Шадлана торган көнең,
Чөнки синдә Гаид укый
Татар гаскәре бу көн.
Тәкрар.

И манара, ач пәрдәңне,
Кара монда бер балкып,
Дошманнарның кулларындан
Алдык сине без тартып.
Тәкрар.

И манара, кайтды бу көн
Иске шәүкәтең кире,
Төрле өмидләргә чумды
Барлык татар гаскәре.
Тәкрар.

Күп йөз еллар ятсаң да син
Каты хәсрәт эчендә,
Инде кайгыдан коткарды
Шанлы татар гаскәре.
Тәкрар.

Озакламый төшә инде
Башыңдан орел синең,
Алла кушса, тиз менәчәк
Башыңа аең синең.
Тәкрар.

Яшә инде та Кыямәт (Кыямәткәчә.— *Х. М.),*
Төшмә хурлыкка тагын.
Шатландыр бөтен ханларны,
Сөембикәнең җанын.
Тәкрар.

## «ЯҢА ЯПУН МӨХБИРЕ» МӘҖМУГАСЫ

Читтәге башка басмалар кебек, «Яңа япун мөхбире»нең дә язмышы мөһаҗир татарлар, төгәлрәк әйткәндә, Ерак Шәрыктагы, Япуниядәге милләттәшләребез язмышы белән тыгыз бәйләнешле. Мәгълүм ки, бу төбәкләр безнең халык өчен элек-электән чит түгел. Татар кавеменең аерым генетик тамырлары хәзерге Кытай, Монголия җирләре белән бәйләнешле булуы да күп нәрсә хакында сөйли. Безнең әби-бабаларыбыз Алтын Урда, татар мәмләкәтләре чорларында да Ерак Шәрык якларына барып чыккан: сәүдә иткән, төрле иҗтимагый, сәяси, мәдәни вазифалар башкарган. Мондый багланышлар Россия, Советлар Берлеге империяләре дәверендә дә дәвам иткән. 1897—1903 елларда Россия тарафыннан төзелгән Көнчыгыш Кытай тимер юлы (аны еш кына КВЖД дип тә йөртәләр, ул, Чита тирәсеннән башланып, Харбинга килә. Аннан, ике тармакка аерылып, Тын океанга кадәр барып җитә. Озынлыгы — 2536 километр) Ерак Шәрыкка урысларның, татарларның күпләп күчүенә дә сәбәпче була. Харбин, Хайлар, Мукден шәһәрләрендә, Пограничная, Маньчжурия станцияләрендә шактый гына милләттәшләребез төпләнә, алар тимер юлда, авыл хуҗалыгында, сәүдә системасында эшлиләр. Октябрь инкыйлабыннан соң, аеруча гражданнар сугышы елларында, бирегә күченүче татарлар саны тагын да ишәя.

Рус-япун сугышында Россия җиңелгәннән соң, Ерак Шәрыкта Япуниянең роле елдан-ел арта бара. Чынлыкта Кытай, аеруча Маньчжурия, Корея 1945 елга кадәр Япуниянең көчле сәяси йогынтысы астында булалар. Шул сәбәпле Төньяк-Көнчыгыш Кытайдагы татарлар Япуниягә дә барып чыгалар. Харбин, Хайлар, Мукден, Шанхай, Пусан, Токио, Кобе һәм кайбер башка шәһәрләрдәге милләттәшләребез үзара аралашып торалар, бер төбәктән икенчесенә күчешләр дә күзәтелә.

Татар дөньясында Япуния белән кызыксыну аеруча урыс-япун сугышыннан соң көчәеп китә. Танылган рухани, җәмәгать эшлеклесе Габдерәшид Ибраһимовның (1857—1944) 1908 елда Япуниядә биш айлап булуы, Токиода мәчет салдырырга урын алып йөрүе заманында татар матбугатында зур кызыксыну тудырган иде. Бу факт хәтта Тукайның шигырьләренә дә килеп кергән («Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит — мәчет Токиода...»). Шуңа күрә мөһаҗир татарлар өчен Япуния бөтенләй белмәгән-ишетмәгән мәмләкәт түгел иде. Милләттәшләребезнең күпчелеге бирегә сәүдә эшләре белән килә, бераздан алар үз яннарына гаиләләрен, туган-тумачаларын, танышларын алдыра. Узган гасырның 30 нчы елларында Япуниядә инде өч меңнән артык татар яшәве мәгълүм. Аларның күпчелеге Токио, Кобе шәһәрләрендә гомер кичерә.

Ерак Шәрыкның башка төбәкләрендәге кебек, Япуниягә күчеп килгән татарлар да, милли телне, гореф-гадәтләрне, иманны саклау өчен, мәктәп-мәчетләр ачарга, гәҗит-журналлар булдырырга омтылалар. Мәсәлән, Токио, Кобе, Нагоя калаларында XX йөзнең 20—30 нчы елларында ук берәр мәчет, берәр татар мәктәбе эшләве мәгълүм. Гадәттә, милли-дини мәсьәләләр белән мөһаҗир татарларның үзләре тарафыннан төзелгән «Мәхәлләи исламия» җитәкчелек итә. Токиода андый җәмгыять 1925 елдан эшли башлый. Аның тәүге рәисе — «япун телен япуннар кебек белгән» Габделхәй Корбангали (1892—1972). Ул бер вакытта Токио мәчетенең имамы да булып тора.

«Мәхәлләи Исламия» тиз арада үзенең нәшриятын оештырып җибәрә. Милләттәшебез, үзе дә Ерак Шәрыкта туып-үскән һәм укыган Мәхмүт Таһир (1922, Харбин — 26.12.1992, Анкара), үзенең «Матбагаи Исламия» исемле мәкаләсендә (Kazan.— 1975.— № 16.— 15—20 б.) бу нәшриятның оештырылуы, хезмәткәрләре (Мөхәммәд Алтынбай, Әхмәдулла, Сания, Рәисә, Хуҗа Әхмәд Ваhап h. б.) хакында мәгълүматлар бирә һәм анда 1930—1949 елларда басылган шактый гына китапларның исемлеген урнаштыра, тиражларын да күрсәтә. Болар арасында Коръән, «Һәфтияк», «Иман шарты», «Мөхәммәд галәйһиссәлам тарихы» һәм башка дини басмалар, «Габдулла Тукай мәҗмугасы» (биш томда; тиражы — 647), «Татар нәхүе», «Татарча сарыф» шикелле әдәби, педагогик китаплар да бар. Алар Япуниядә генә түгел, дөньяның милләттәшләребез яшәгән башка төбәкләрендә дә таралыш таба. Токио китапларын минем Финляндия, Төркия, Эстония татарлары арасында да күргәнем бар. Гарәпчә дини басмалар билгеле бер дәрәҗәдә гарәп мәмләкәтләренә дә ирешә.

«Яңа япун мөхбире» мәҗмугасының туу һәм яшәү тарихы да турыдан-туры Ерак Шәрык татарларының рухи ихтыяҗлары, андагы матбагаи вазгыять белән бәйле. Бу татарча журнал Токиодагы «Матбагаи Исламия»дә гарәп хәрефләре белән басыла. Сирәк-мирәк кенә, аеруча тышлыгында, япунча, гарәпчә язмалар да күзгә ташлана. Мәҗмуга 1931 елда «Япун мөхбире» исеме белән чыга башлый. 1932 елда бу атамага «яңа» сүзе өстәлә. Әмма моңа карап журналның мәсләге, эчтәлеге үзгәрми. Шуңа күрә «Япун мөхбире»н һәм «Яңа япун мөхбире»н ике мәҗмуга дип карарга ярамый. Алар — бер, үзара аерылгысыз керешкән. Мәгълүм ки, Берлинда 1928—1939 елларда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы да әүвәл «Милли юл» исеме белән чыга. Әмма моңа карап без аны да аерып, ике мәҗмуга дип йөртмибез. Чынбарлыкка нисбәтән аерым хосусый үзгәрешләр булса да, аның төп кыйбласы, асыл максаты бер — татар халкын туплау, аның асылын саклау, милли бәйсезлеге, табигый хокуклары өчен көрәш (бәлкем, «Япун мөхбире»нең исеменә үзгәреш керүдә Берлин мәҗмугасының да өлешчә тәэсире булгандыр).

Әйткәнебезчә, «Яңа япун мөхбире»нең рәисе — Габделхәй Корбангали. Ул бу вазифаны, нигездә, 1937 елларга кадәр алып бара. Мәҗмуга журналистларының кемнәр булуы тәмам ачыкланмаган (бәлкем, алар шул ук «Матбагаи Исламия»нең хезмәткәрләредер). Берара анда Рокыя Дәүләткилде дә эшләп ала. Әмма Г. Исхакый белән Г. Корбангали арасында бәхәсләр башлангач, мәҗмуга белән хезмәттәшлек итүен туктата.

«Яңа япун мөхбире» — уртача форматлы айлык журнал. Күләме төрлечә: 50 биттән артып киткән саннары да, 30—40 сәхифәлекләре дә бар. Юка, әмма сыйфатлы тышлыкта. Техник ягы уку, файдалану өчен уңайлы. Иллюстратив-күрсәтмә материаллар да бар. Алар арасында Япуниядәге, Ерак Шәрыктагы милләттәшләребезнең дини, мәдәни, иҗтимагый тормышына мөнәсәбәтле фотосурәтләр төп урынны алып тора. Мәчет, мәктәп күренешләре, төрле кичәләрнең сурәтләре аеруча еш очрый. Япуниянең табигатен, яшәешен чагылдырган фоторәсемнәр дә бар.

«Яңа япун мөхбире» хезмәткәрләре мәҗмуганың «гыйльми, әдәби, тиҗари (сәүдәви.— *Х. М.*), сәнәгый, икътисади, иҗтимагый вә тәрбияви» характерда булуын һәр санның тышлыгында искәртеп баралар. Әлбәттә, боларның һәммәсе дә һәр санда чагылыш таба алмый. Әмма гомумән алып караганда, журнал үзенең шигаренә, максатына тугры кала. Чыннан да, ул — күпкырлы, күптармаклы мәҗмуга.

Журнал, әйткәнебезчә, Токиода, бу илдә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан нәшер ителә, аңа рәсми хакимият тә билгеле бер күләмдә ярдәм итә. Япуния — бу елларда ук барлык яктан бик нык алга киткән ил. Ул үзенең халыкара йогынтысын да төрле юллар һәм чаралар белән арттырырга омтыла. Рәсми Токионы аеруча ислам дөньясы, төрки-татар кавемнәре кызыксындыра. Аларга тәэсирен арттыруда ул гарәп хәрефләре белән нәшер ителүче, мөселман рухлы «Яңа япун мөхбире»н дә файдалана.

Журналның һәр санында Япуния тематикасы мөһим урынны били. Мәҗмугада илнең икътисады, мәдәнияте, көнкүреше, халыкара бәйләнешләре хакында, бу халыктагы сакура (чия чәчәге), хризантема бәйрәмнәре турында даими рәвештә материаллар биреп барыла. Аларның рәсми чыганаклардан алынуы, факт-мәгълүматларга, күзәтүләргә байлыгы күзгә ташланып тора. Япун тормышы, бу илнең яшәеше, гореф-гадәтләре үрнәк, өлге рәвешендә тәкъдим ителә. Бу юнәлештә журнал билгеле бер дәрәҗәдә Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман»ындагы традицияләрне дә дәвам иттерә, үстерә. «Яңа япун мөхбире»ндәге аерым мәкаләләрдә төрки һәм япун кавемнәре арасындагы охшашлыклар, типологик якынлыклар хакында да сүз алып барыла. Мәсәлән, немец профессоры Эдмонд Тоуманның хезмәтенә нигезләнеп язылган «Япун-төрк кардәшлеге» мәкаләсендә (1934.— № 21.— 5—10 б. Язманың авторы Г. Хайлари) бу ике халык арасындагы лексика, фонетика, музыка һәм гореф-гадәтләр өлкәсендәге аерым охшашлыклар ассызыклана. «Җыр җырлауда һәм моңлы касыйдәләр көйләп укуда да,— диелә анда,— япун белән төрк арасында охшашлык күрү бик җиңел. Аурупа халыклары авызларын зур итеп ачып, тулы күкрәк белән кычкырып ерлаган заманда, төрк һәм япунлар борын эченнән чыккан моңлы ыңгырашу тавышына охшаган бер рәвештә ерлыйлар, шул сәбәпле аурупалыларга ямьсез, төзсез кеби күренәләр. Япун белән төрк өчен матур, кызыклы булган җыр формасы аурупалылар карашыннан йитешмәгән, чи күренә. Япунлар да төрк-татарлар кеби аурупалыларның кычкырып ерлауларына хайван бакыруы дип карыйлар. Тәкъдиргә буйсыну һәр ике милләттә дә көчле булганыны... төрки-татарларда «Язмыштан узмыш юк» мәкале шәһадәт итә...» (6—8 б.).

Журнал сәхифәләрендә мөселман дөньясы, аның күренекле шәхесләре, дини бәйрәмнәр һәм чаралар да даими игътибар үзәгендә. Кытайдагы хәлләр, Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге мөһим вакыйгалар да мәҗмугадан читтә калмый.

Әмма ничек кенә булмасын, «Яңа япун мөхбире»нең үзәгендә — татар тематикасы, аның тарихы, бүгенгесе, гореф-гадәтләре, яшәү рәвеше. Бу ягы белән ул «Яңа милли юл», «Kazan» журналларына билгеле бер дәрәҗәдә якынаеп та китә. Татар телендә чыгуы, татар авторлары тарафыннан әзерләнүе үзеннән-үзе дә мәҗмугага милли рух өсти. Журналда аеруча мөһаҗир татарларның яшәеше, алар тормышындагы вакыйга-хәлләр мөһим урынны били. Мәсәлән, мәҗмуганың бер санында (кызганыч ки, аның елын, санын күрсәткән тышлыгы юк. 1937 елгы булса кирәк) «Польша-Ляһстан төрк-татар мөселманнары» мәкаләсендә (27—28 б.) бу төбәктәге татарларның тарихы, хәзерге хәле хакында кызыклы гына мәгълүматлар бирелә. «Хәзер,— диелә анда,— Польшада 16 мәчет, 19 имам бар. Мөфтиләре «Ягъкуб әфәнде Шенкеевич (Сенкеевич) хәзрәтләре (журналда аның рәсеме дә бирелгән) хәзер 47 яшьләрендә булып, элек Минск шәһәрендә тәхсыйльдән (укудан.— *Х. М.*) соң Петроград гали мөһәндис (югары инженерлык.— *Х. М.*) мәктәбен» бетерә. Сугышта офицер буларак катнаша. Кырым хөкүмәтендә хезмәт итә. Берлин университетының шәрык бүлеген тәмамлый, докторлык дәрәҗәсен ала... «Мөфти җәнабләре Вильно дарелфөнүнендә гарәпчә, төрекчә вә фарсыча дәресләр бирә». Бу телләрне камил белә. Шулай ук немецча, урысча, полякча иркен сөйләшә. Ягъкуб әфәнде «Яңа япун мөхбире»нең рәисе Габделхәй хәзрәт белән хатлар алыша.
Шулай ук мәҗмуганың бу санында «Мәрхүм Морад әфәнде Мәккәи» дигән язма да (32—36 б.) танып-белү ягыннан кызыклы. Биредә мәшһүр тарихчы, рухани, публицист Морад Рәмзинең (1854—1934) тормыш юлы, эшчәнлеге бәян ителә. Мәгълүм ки, Сарман районы Әлмәт авылында туып, Кышкарда, Бохарада, Пешаварда укыган бу зат гомеренең шактый өлешен Мәккәдә уздыра, суфыйчылыктагы Нәкышбәнди тарафдары буларак таныла, бик күп мәкалә-хезмәтләр яза, Коръәнне дә татарчага тәрҗемә итә.

Совет режимын, большевиклар сәясәтен тәнкыйтьләү, илдәге татарларның милли, дини яктан кысылуларын яктырту Октябрьдән соңгы мөһаҗирлек татар гәҗит-журналларның күпчелегенә хас. «Яңа япун мөхбире» дә моннан чыгарма түгел. Мәсәлән, мәҗмуганың 43 нче санында (1936) СССРның Ерак Шәрыкта солыхны бозу сәясәте алып баруы, сугышка әзерләнүе ассызыклана (23 б.).

«Яңа япун мөхбире»нең аерым саннарында Г. Исхакыйны тәнкыйтьләгән мәкаләләр дә бар. Мәгълүм булганча, «...Инкыйраз» авторы Ерак Шәрык, шул исәптән Япуния, андагы милләттәшләребез белән шактый тыгыз мөнәсәбәтләрдә тора. Кайберләре белән илдә вакытта ук таныш була. Аннан соң да үзара хәбәрләшүләр, очрашулар еш күзәтелә. Г. Исхакый Кытайда һәм Япуниядә тәүге мәртәбә 1919 елда була. Шуннан ул Аурупага китеп бара. Икенче тапкыр Г. Исхакый Ерак Шәрыкка 1933 елның көзендә килә. Япуниядә, Кытайда өч еллап гомерен уздыра. Бу вакыт эчендә ул мөһаҗир татарларны туплау, милли рухта тәрбияләү юнәлешендә гаять актив эшчәнлек алып бара: корылтайлар уздыра, «Милли Байрак» гәҗитен нигезли, төрле очрашулар оештыра, күпләгән мәкаләләрен бастыра. Шушы елларда аның Кытайда, Япуниядә «Зөләйха», «Җан Баевич», «Дулкын эчендә» һ. б. әсәрләре сәхнәләштерелә. Әлбәттә, Г. Исхакыйның Ерак Шәрыктагы күпкырлы эшчәнлеге шома гына бармый, ул төрле каршылыкларга, хәтта әзәрлекләүләргә дә дучар ителә. Мәсәлән, 1934 елның 11 февралендә «Токио Идел-Урал төрк-татарларының мәдәният җәмгыяте»н оештыру җыелышында бер төркем урыслар Г. Исхакыйны кыйный башлый. Фаҗигане япун полициясе катнашу гына булдырмый кала. Шул ук елны Мукденда, нахак бәла ягып, Г. Исхакый кулга алына. Аны бу күңелсез хәлдән Төркиянең Япуниядәге хәрби атташесы Рөштү Әрдәлһүн коткарып кала.

Г. Исхакыйга милләттәшләребез арасындагы каршы көчләрнең башында Токиодагы «Ислам мәхәлләсе» рәисе, «Яңа япун мөхбире» журналының башлыгы Габделхәй Корбангали тора. Шунысын да әйтик: Япониядәге милләттәшләребезнең дини, милли-мәдәни тормышын оештыруга, китаплар бастыруга бу зат шактый зур өлеш кертә. Әмма Г. Исхакый аны сүлпәнлектә, шәхси мәнфәгатьләрен күбрәк кайгыртуда гаепли, аның адресына шактый саллы тәнкыйть фикерләрен көндәлек тормышта да, матбугат аша да җиткереп тора. Г. Корбангали исә Г. Исхакыйның Идел-Урал идеясен, милли бәйсезлек өчен көрәш сәясәтен кабул итми, «...Инкыйраз» авторының Ерак Шәрыкта абруе күтәрелүгә дә көнләшә. Конфронтация көчәйгәннән-көчәя бара, шуның нәтиҗәсендә дә «Яңа япун мөхбире» битләрендә Г. Исхакыйны мыскыллаган, нахак бәлаләр яккан материаллар басыла. Мәсәлән, бер мәкаләдә (1934.— № 21) без мондый юлларны укыйбыз: «Милләтемезнең кирәк әфрады (шәхесләре.— *Х. М.*) арасында вә кирәк бер кавеме илә икенче кавеме арасында ун ел буенча камил өлфәт (дуслык.— *Х. М.*) вә бер-берсенә хөрмәт урнашкан иде. Ерак Шәрыкка Гаяз Исхакыйның килүе мөнәсәбәте илә, аның вә фетнәчеләрнең коткысы берлән көнчелек һәм каршылыклар кузгалып, Ерак Шәрыктагы тынычлыгымызга да кара тап төште. Аурупада төрле мәмләкәтләрдә сачеп йөрегән тынычсызлык вә көнчелек авыруын Гаяз Исхакый Ерак Шәрыкка алып килде...» (4 б.). «...Инкыйраз» авторының эшчәнлеге белән азмы-күпме таныш булган һәр кешегә бу төр гаепләүләрнең чынбарлыкка туры килмәвен аңлау һич кыенлык тудырмый. Ә инде кайберәүләрнең Г. Исхакыйны «совет шпионы», «Мәскәү агенты» дип атаулары гаҗәпләнү генә тудыра.

«Яңа япун мөхбире» кайчанга кадәр чыккан соң? Кайберәүләр аны 1937 ел белән чиклиләр. Әмма бу һич тә чынбарлыкка туры килми. Безнең кулда аның 1938 елның апрель аенда нәшер ителгән 61 нче саны бар. Мәхмүт Таһир бу мәҗмуганың, «Милли Байрак» кебек, 1945 елга кадәр нәшер кылынуын искәртә.

Шунысын да әйтик: 1945 елда Япония җиңелгәннән соң, Ерак Шәрыктагы күпчелек мөһаҗир татарлар Төркия, Австралия, Канада, АКШ һәм башка тарафларга качып, күчеп китәләр. Шактый өлеше, Совет органнары тарафыннан кулга алынып, төрмәләргә утыртыла, сөргеннәргә сөрелә. Габделхәй Корбангали дә, мәсәлән, шундый язмышка дучар ителә. Ул 10 ел гомерен төрмәдә уздыра (Kazan.— 1972.— № 9.— 50—51 б.). Зинданда үлеп калучылар да була. Хәзерге вакытта Кытайның элек татарлар күпләп яшәгән Харбин, Хайлар, Мукден шәһәрләрендә татарлар юк дәрәҗәсендә. Япониядә гомер кичерүче милләттәшләребез дә хәзер бик аз.

* * *

Мәгълүм ки, Ерак Шәрыкта узган гасырның 20—40 нчы елларында дистәләгән гәҗит-журналлар чыга: «Ерак Шәрык» (мәҗмуга, Харбин, 1920—1922), «Ерак Шәрык» (гәҗит, Харбин, 1924—1925), «Шәкердләр таңы» (мәҗмуга, Мукден, 1934—1935), «Мең ел» (Харбин, 1922), «Чаткы» (Харбин, 1932—1933), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934), «Милли Байрак» (Мукден, 1935—1945) һ. б. Боларның һәммәсенең үз йөзе, үзе куйган максаты бар. Әмма аларның барчасы да татар телендә, татар укучысына, аны тәрбияләүгә юнәлтелгән. Ерак Шәрыктагы бу басмалар арасында «Яңа япун мөхбире»нең дә үз урыны, кылган игелекле эш-гамәлләре бар. Әлбәттә, анда, «Яңа милли юл», «Kazan», «Азат Ватан» журналларындагы кебек, милләт язмышы бөтен тулылыгында һәм кискенлеге белән куелмаган. Әдәби, әдәби-тәнкыйди материаллар да күзгә бик ташланмый. Әмма шулай да «Яңа япун мөхбире» — безнең рухи тарихыбызның бер өлеше. Анда иҗтимагый, дини, тарихи, сәяси яктан кызыклы гына факт-мәгълүматлар бар. Аларны тулырак өйрәнү, гыйльми әйләнешкә кертү безнең күзаллауларыбызны тагын да тулыландырачак, зиһенебезне баетачак.

*2005*

## «Яңа япун мөхбире» мәҗмугасыннан

### Япониядә чия чәчкәсе*

Бөтен дөньяда Япониягә чия мәмләкәте диләр. Япониядә аның урынына махсус чия чәчкәсенең күрелмәгән йире юктыр. Япониядә төрле төсле чәчкәле чия агачының үстерелүе вә һәр йирдә бакчаларда чия агачы үстерү мәдәнияте Япониядә уздырыш берлән мең ел буена тәрәккый итдерелмештер.

Чия чәчкәсе Аурупа вә Америкадагы кебек гүршәк (горшок — чүлмәк.— *Х. М.*) вә савыт эчендә үстерелә вә янына бармасаң күренми торган гөл чәчкәләре кебек булмый, зур агачларда тулы рәвештә үсә, еракта күренеп вә янына меңләрчә халыклар җыелып тамаша кыла торган чәчкәдер.

Чия чәчкәсе Япониядә (мәркәздә) апрельнең уннарында ата башлый. Вә бер атна эчендә болыт кеби бөтен офыкны каплый, вә дәхи бер атна эчендә коелып бетәдер. Япун самурайлары, үзләренә чия чәчкәсен үрнәк кылып, тотмышлар вә чия чәчкәсе кебек күрсәтәчәк матурлыгыңны бердән тулы рәвештә күрсәтеп, матурлыгың беткәч, мәйданнан югалу кирәк дигәннәр.

Чия чәчкәсенең Япониядә күп нәүгълары (сортлары.— *Х. М.*) бар. Тау арасында, Фузи вә Хакуни тауларында тау чия агачы дигән кыйсемнең нәүгълары бигрәк тә күптер. Бу нәүгъ чия агачы Киото, Нара вә Осаки тарафларында үсәдер. Искедән Япониянең пайтәхете Нара вә Киотоларда булган вакытлардан бирле бу нәүгъ чия агачларын үстерү ул тарафларда тәрәккый итдерелмештер.

Чия чәчкәсе Япония чәчкәсе дип атала вә шул сәбәпле искедән бирле сарайлар әйләнәсендә чия агачы утырту гадәт булып килмештер.

Тау чия чәчкәсе чия агачында яфрак берлән чәчкәсе икесе дә бергә атадыр вә, төсе сыек ал вә яки ак төстә булып, яфрагы сарырак яшел төстә була, вә бу төсләрнең тәнасебе (ярашуы; гармониясе.— *Х. М.*) бу агачка бик матур күренеш бирәдер. Иске заманнан бирле иң мәгъруф (билгеле.— *Х. М.*) вә сөекле уларак мәзкүр (шушы; телгә алынган.— *Х. М.*) нәүгъ чия чәчкәсе танылмыштыр.

Соңгы вакытларда Йайн сакура исемле чия агачының бер нәүгысы бик тәрәкъкый итмәктәдер. Бу нәүгъ агачында чәчкәләр, төркем-төркем булып, 20—30 чәчкә бер групда (төркемдә.— *Х. М.*) бик матур булып атадыр.

Бу нәүгъ чәчкә Нара заманында һәм булса да, тәрәкъкый итеп таралуы соңгы заманнардадыр. Моның чәчкәсе ал төсле булып, бу агач апрельнең 20 ләрендә атадыр. Токио әтрафында (тирәләрендә.— *Х. М.*) Аракава елгасы буенда бу нәүгъ чия агачы мөкәммәл сурәттә чәчкә атадыр вә, мондагы чия чәчкәләре кызыл, сары вә фиолет төсләрендә булып, төрле төсле чия чәчкәсе ата торган урын дия мәгъруфдыр.

Бу нәүгъ чия чәчкәсе хуш исле булып, бу чәчкәдән чәй ясыйлар вә кадерле кунакка эчерәләр. Тукугава заманыннан бирле сату сакура — шикәр чиясе — исемендә яңа нәүгъ чия агачы һәм үстерелмәктер. Чия чәчкәсе,— гомумән, аз исле булган чәчкәдер. Тукугава заманындагы сәнаигы нәфисә мөхибләре (нәфис сәнгатьне яратучылар.— *Х. М.*) бу чәчкәгә йитешмәгән җире хуш ис дия табып, бу хуш исле чәчкәле шикәр чия агачыны тәрәкъкый иттермешләр. Ләкин бу агачлар башка чия агачларына кыясән (чагыштырганда.— *Х. М.*) кечкенә булып, бу нәүгъ чия агачларын күбрәк нива — йорт бакчаларына утырталар.

Чия агачы шулай елдан-ел вә гасырдан гасырга тәрәкъкый иттерелеп камилләштерелмешдер. 1912 елда Токиога килгән Америка сәяхларының теләве буенча Токио шәһәре, Америкада үстерү өчен, Япониядән чия агачлары күндермеш вә бу агачлар бу елларда Вашингтон бакчаларында бик күркәм чәчкә аталар. Вә Америка халкы тарафыннан тамаша кылыналар.

Япониядә яз апрельдә Ханами чия чәчкәсе атканда хәрәкәткә килә. Чия чәчкәсе атканда, япун халкы гаиләсе илә байлары вә фәкыйрьләре — барысы да, мотлак чия чәчкәсе карарга сахрага, елга буйларына хозурга чыгып, пикник ясыйлар.

Япониядә иң мәшһүр чия чәчкәсе ата торган урын Нара вилаятендә Йучину Яма исемле таулардыр. Бу тауларда үсмәктә булган чия агачлары вә аларның чәчкәләренең меңьеллык тарихлары бар. Монда бер тауда тезелгән чия агачларының озынлыгы 4 миль кадәр бар вә болар ап-ак чәчкәләр аталар. Болардан бер группасы Истуми (? Әстуми.— *Х. М.*) Симбун исемле булып (мең данәлек группа), бер күргәндә меңләрчә агачның чәчкәсе күренәдер. Икенче группасы Накану Симбун исемле булып, болар Истуми Симбуннан соң чәчкә аталар вә өченче группасы Укуну Симбун исемле булып, болар иң соң чәчкә аталар. Бу чәчкәләрне карау өчен, Киотодан баруга трамвай вә автобуслар эшлиләр вә йөз меңнәрчә халык аны карарга җыелалар.

Токио әтрафында чия чәчкәсенең ата торган иң мәшһүр урыны Кугани дигән урында булып, Тама елгасының аерылып аккан җирләрендә үскән агачлардыр. Мондагы чия агачларының чәчкәләре коелганда ап-ак кар кебек бөтен елганы каплыйлар. Мондагы тезелгән агачларның озынлыгы 4 миль кадәр булып, шунда 1500 ләп агач утыртылмыштыр. Апрельнең 15 ләрендә монда чия чәчкәсенең мөкәммәл сурәттә аткан вакытыдыр вә, барып карау өчен, трамвай вә автобуслар бик уңгайлы сурәттә эшләмешләрдер. Иске заманда бу агачларның Йучину Ямадан килтерелгәнен сөйлиләр. Чәчкәләре дә Йучину Ямадагы кебек ап-актыр. (Юлы Синҗукудан барыла.)

Дәхи Токио әтрафында югарыда зикер итдекемез Аракава елгасы буендагы чия агачлары бар. Болар, Йайину сакура булып, төрле чәчкә аталар. Барып карау өчен, трамвай вә автобуслар йөриләр. (Юлы Уйинудан барыла.)

Сакура — чия чәчкәсенең яфрагы, гадәттә, биш данә була. Ләкин Йайи сакураның яфрагы сигездән башлап 20—30 га кадәр күпреп күренә торган матур чәчкәләрдер. Дәхи Хиган сакура дигән бер нәүгъ чия чәчкәсе хуш исле вә кечкенәлеге берлән мәгъруфдыр.

Япониядә җәй вә кыш һәр заман ямь-яшел булып күп агачлар яфрак атып торсалар да, мартта ата торган слива чәчкәсеннән соң чия агачлары, апрельдә бердән чәчкә атып, табигатькә бердән зур үзгәреш бирәләр. Яз чәчкәсе ата вә моның илә рухланган япунлар язгы табигатьтән хушлану өчен сахрага барып, бу матур чәчкәле агачларның астына җыелып, анда ашлар алып барып, пикниклар ясыйлар. Монда алар милли җырлар җырлап, чия чәчкәсе биюләрен бииләр.
Вә Япониядәге сәүдә ширкәтләре вә магазәләре (магазин-кибетләре.— *Х. М.*) үз хезмәтчеләренә чия чәчкәсе вакытында бер көн тәгътыйль (ял.— *Х. М.*) биреп, алар чәчкә карарга баралар.

Чит мәмләкәтләр халыкларының Япониягә яз килә торганнары махсус бу чия чәчкәсе аткан вакытларны сайлап киләләр. Чөнки бу вакытларда урамда вә сахрада япун халкының һәр нәүгысын (катламын.— *Х. М.*) күрергә була. Вә Япониягә бу чәчкәне карау өчен, Америкадан махсус сәяхлар (сәяхәтчеләр.— *Х. М.*) группалары киләләр. Вә Токиода торучы хариҗи (чит.— *Х. М.*) мәмләкәт адәмләре дә чия чәчкәсе вакытында төрле сахраларга барып чәчкә карыйлар. Токиода «Мәхәлләи

Исламия» әгъзалары вә мәктәп шәкертләре дә һәр ел, чия чәчкәсе карарга хозурга чыгып, пикниклар ясыйлар. Монда йөгерешеп, көрәшеп милли уеннар уйнап кайталар.

**Япуниядә хризантем чәчкәсе***

Япуниядә хризантем чәчкәсе октябрь ахырларыннан ноябрь ахырларына кадәр мөкәммәл рәвештә ата. Вә Япуния, чия чәчкәсе мәмләкәте дип аталган кебек, хризантем чәчкәсе мәмләкәте диеп тә аталадыр. Чия чәчкәсе бердән атып, бердән төшә вә самурайлыкка мисал кылып йөртеләдер. Хризантем чәчкәсе көзге кырау арасында атып, ямь-яшел яфраклары арасында ачык рәвештә рухлы булып атуы сәбәпле, Япуния императорлыгының армасы (гербы) булу дәрәҗәсенә ирешмешдер.

Хризантем чәчкәсе сары, ак, кызыл, фиолет вә ал һәм төрле төсләрдә атып, моның арасында иң мәшһүре сары хризантем чәчкәседер. Бу сары хризантем эссе суга салып, серкә илә катыштырып ашарга да ярый вә мәгъдә (ашказаны.— *Х. М.*) өчен, эчендә витамин күп булуы вә хуш исле булуы сәбәпле, бик файдалы саналадыр. Хризантем чәчкәсе, гадәттә, бер агачта бер яки ике зур чәчкә атадыр вә чәчкәсенең зурлыгы вә озынлыгы илә макталадыр.

Соң заманнарда Япуниядә чәчкә вә агачлар һәм төрле үсемлекләр үстерү бик тәрәкъкый итү сәбәпле, хризантем чәчкәсен кечерәйтеп, агачына күп ботаклар чыгарып, аларны шәлялә (шарлавык) кебек югарыдан түбән агучы су шәкелендә кылып ясау ысулы да кабул ителмештер.

Күз көнендә Япуниядә хризантем чәчкәсе курчаклары ясау, төрле төстәге хризантемнан шул зур курчакларга киемнәр кидерү һәм хризантемнан төрле хайваннар шикелле вә йортлар шикелле ясау мәкъбүлдер (кабул ителгән.— *Х. М.*). Боларны ясау өчен хризантемны үстергән вакытта ук шул нәрсәләргә мөнасиб кылып үстерәләр вә матур күренгәннәрен Токиода Хибия (?) паркында вә санаигы нәфисә йортында һәм Мидзи бакчасында выставкалар (сәркиләр) ясап күрсәтәләр. Хосусый йортларда да күрү мәҗлесе ясау мәкъбүлдер.

Император сараенда елында ике мәртәбә: Сэнҗүкү император паркында бер мәртәбә чия чәчкәсе карау вә бер мәртәбә хризантем чәчкәсе карау мәҗлесе ясаладыр. Читтән Япуниягә килүче мөсафирлар да, күбрәк я чия чәчкәсе аткан вакытта, вә яки хризантем чәчкәсе аткан вакытка тугры килтереп, Япуниягә киләләр.

«Бер милләтнең мәгънәвияте аның сөйгән чәчкәсеннән беленә» дигән мәкаль бар. Хризантем чәчкәсе япуннарның сәбатлы (тотрыклы, нык.— *Х. М.*) вә карарлы һәм авырлык (кырау вә суык) арасында түземле булуын күрсәтәдер.

Хризантем чәчкәсен карау мәҗлесләрендә япуннар хризантем шигырьләре төзиләр вә шул шигырьләр берлән уздырыш вә мосабәка (ярыш, конкурс.— *Х. М.*) ясыйлар.

**Япунияне үгрәнүнең мөселманнар өчен әһәмияте***

Япуния мәмләкәте вә япун халкы, башка Шәрык халыклары кебек саф Шәрык халкы вә Шәрык мәмләкәте булып, үзенең тизлек берлән Аурупа мәдәниятен — мәдәнияи маддияне (матди культураны.— *Х. М.*) кабул итүе вә шуның илә бәрабәр миллият вә гадәтен саклап мәдәниләшкән вә хәзер дөньяда беренче дәүләтләрдән саналган бердәнбер Шәрык мәмләкәте вә Шәрык халкы булуы ягыннан башка Шәрык милләтләренә зур вә кадерле үрнәк вә мисал икәнлеге шөбһәсездер.

Гаребнең күршесендә вә аның кул астында яшәүче милләтләр низам вә интизамның (канун-оешканлыкның.— *Х. М.*), тәртипле, вакытында йөрүче тәрәннең (поездның.— *Х. М.*), тәмиз (чиста.— *Х. М.*) вә мөкәммәл вапурның (пароходның.— *Х. М.),* авылларына кадәр асфальт берлән түшәлгән юллары бар мәмләкәтнең, әһалидәге (кешеләрдәге.— *Х. М.*) нәзафәт (чисталык.— *Х. М.*) вә нәзакәтнең Гаребтән башка җирдә булуына күзе җитмидер. Шул сәбәпле Шәрыктан (Шәрыкка.— *Х. М.*) килүче сәях (илгизәр, сәяхәтче.— *Х. М.*) мәзкүр шийләрне (югарыда телгә алынган нәрсәләрне.— *Х. М.*) мөкәммәл суръттә Япуниядә күргәннән соңра, аның күңелендә вә фикерендә җитди бер инкыйлаб (үзгәреш.— *Х. М.*) хасыйл була.

Монда Япуниягә килүче шәрыклылар, башлап япун вапурына вә яки тәрәненә утырдыкларында андагы тәртип вә интизам вә нәзакәтне һәм бөтен идарәсенең япуннар кулында гына булуын күреп, бу милләтнең истигъдадына (булдыклылыгына.— *Х. М.*) тәхсин вә афәрин (мактау һәм хуплау.— *Х. М.)* укып, беренче класс тәрәнендә утыручы киманулы (милли өс киемле.— *Х. М.*) япунга карап, күзеннән ихтыярсыз яшь чыгадыр. Тәрәкъкыйнең киемдә түгел, бәлки башта икәне ихтыярсыз аның башына килеп керә, үзенең дә милли киеме барлыгы вә ләкин ул аны моңача кияргә оялып йөрегәне хәтеренә килә. Үз илендә үз телендә җырларга оялып, аурупача, урыс кебек уларга үгрәнергә башлаган булса да, каршысындагы япунның Шәрык көйләре, япун көе берлән озын-озын япун җырларын җырлавын күреп искә төшерә вә монда инде ул аурупача, урысча көй берлән җырлауны уңгайсыз бер эшкә, оятка саный башлыйдыр. Бинту-беренж (дөге.— *Х. М.*) ашаучы япунны күреп, пылауны искә төшерә. Аның тезләнеп утыруын күреп, илдәге гадәтләрен күз алдына китерәдер.

Япуния мәмләкәтенең эченә килеп, Симунусекидан (шәһәр исеме) төрәннән кузгалганда, бу тарафка Чин яки Кореядан килүчеләрнең күңелендә гаҗәеп бер шатлык хисе, гүя дөнья читенә кергән кебек күңелдә бер иркенлек вә тынычлык туадыр.

Бу мәмләкәт кешеләренең бер-берсенә гаять нәзакәтле сәламләшүләре, әдәпле сөхбәтләре күңелгә хушлык бирәдер. Мәмләкәт шәһәрләренә килгәч, андагы мөкәммәл мәдәният, мөкәммәл хәрәкәт әсбабы өчен автомобильләр (10 километрга кадәр җиргә 50 сән), шатрәнеҗ чатырашы (шахмат тактасы.— *Х. М.*) кебек тулы (тигез.— *Х. М.*) тимер юллары, автобуслар вә трамвайлар дөньяның иң мәдәни бер мәмләкәтендә булуны белдерәләр. Фәүкылгадә (гадәттән тыш.— *Х. М.*) тәмиз (чиста.— *Х. М.*) вә комфортлы отельләр вә андагы нәзакәт вә әдәп һәм очызлык (очсызлык.— *Х. М.*), көндә ике дәфгъә (мәртәбә.— *Х. М.*) миллионнарча нөсхә чыкмакта улан гәзитәләр вә соңгы вакытта аларны көндә 3 дәфгъә чыкмага башлавы вә данәсе бер бочык (ярты.— *Х. М.*) сәнгә (сән — акча берәмлеге.— *Х. М.*) сатылуы вә иң түбән эшченең буйлә ике-өч гәзитә укуы бу мәмләкәтнең мәдәниятенә хәйранга калдыра торган эшләреннәндер. Шулар арасында егерме сәнлек гыйта (аяк кабы) вә 70 сәнлек киемне киеп, барлыгы бер иен 50 сәнлек әлбисәдә (киемдә.— *Х. М.*) дарелфөнүнгә йөреп укучы меңләрчә япун шәкертләре, су берлән әйләндерелә торган моторлар вә электриклар (электр станцияләре.— *Х. М.*), бик нәфис нәрсәләр сатып утыра торган гаять кечкенә кибет вә дөкяннар (киосклар.— *Х. М.*), гаиләви ысулга куелып 4—5 кешелек эшчедән тезелеп, барлыгын җыйганда миллиардларча маллар чыгара торган япун сәнәгате бу мәмләкәтнең нәкадәр табигый вә кулай юл берлән тәрәккый итмәктә улдыгын күрсәтмәктәдер.

Япуния — үзенең гаиләви хәятыннан, мәктәбеннән, гаскәреннән, әлбисәсеннән, ашавыннан, нәзафәтеннән (пакьлегеннән.— *Х. М.*), әхлагыннан, мәдәниятеннән, тиҗарәтеннән (сәүдәсеннән.— *Х. М.*), сәнәгатеннән, тарихыннан Шәрык өчен меңләрчә дәрсе гыйбрәт улан бер газиз мәмләкәттер.

Япуннар кебек үк башка Шәрык халыклары да тәрәккый итмеш улсалар иде, алар да башка Гареб милләтләре илә тигез булырлар иде вә, бәни бәшәрнең (адәм балаларының.— *Х. М.*) язмышын Гаребкә тапшырып куймыйча, үзләре дә дөньядагы тигезлек вә солых өчен тавыш чыгарыр вә сүзләрен үткәрер-
ләр иде.

Мәгаттәәссеф (үкенеч ки.— *Х. М.*), алар япуннар дәрәҗәсендә мәдәни түгелләр, япуннардан меңләрчә дәрәҗә түбән торалар вә шул сәбәпле теләк вә сүзләрен үткәрә вә гамәлгә куя алмыйлар.

Шәрык милләтләренең бәхетсезлегенең башы шул япуннар дәрәҗәсенә ирешә алмауда булып, бәхетнең күстәрмәсе дә — Япуния мәмләкәтендә вә япун милләтендәдер. Шул сәбәпле хәзерге көндә Шәрык халыклары вә хосусан Шәрыкның иң зур мәгънәви көченә малик (ия.— *Х. М.*) булган безнең мөселман милләтләре өчен иң мөһим нәрсә: Япуния вә япуннар берлән танышу вә алардан үрнәк вә гыйбрәт алудыр.

*ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВНЫҢ*
*ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ*
*ҺӘМ МАТБУГАТЫ ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАЛАРЫ*

**I — Китаплар**

1. Исхакый мөһаҗирлектә.— Казан: Таң-Заря, 1999.— 84 б.
2. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 368 б.

Рецензияләр: *Алсу Кәримова*. Мөһаҗирлектә дә йөрәгендә халкы булган // Шәһри Казан.— 1.10.1999; *Булат Гали*. Язмышын җи-
нөп // Мирас.— 1999.— № 10.— 153—154 б.

3. Гаяз Исхакый Ислам мәмләкәтләрендә (Юл истәлекләре).— Казан: «Иман» нәшр., 2003.— 101 б.
4. «Дөньяда сүземез бар».— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 184—295 б.

Рецензияләр: *Рәфыйк Нәфыйков*. Халык язмышы турында // Ватаным Татарстан.— 19.04.2000; *Рәдиф Гаташ.* Төрки дөньяга гашыйк галим // Заман — Татарстан.— 10.12.1999.

5. Гасырлар өнен тыңлап.— Казан: Мәгариф, 2003.— 163—174 б., 215—220 б. (Биредә Минһаҗ Исмәгыйли, Әхмәт Тимер, Фатма Өзкан һ. б. турында язмалар бар.)

Рецензияләр: *Зөфәр Мөхәммәтшин*. Туган илдән аерган сәбәп-
ләр // Шәһри Казан.— 10.03.2005; *Рифат Каюмов*. Мөһаҗирләр яки Гаяз Исхакый Сүриядәге якташыбыз
турында // Шәһри Казан.— 16.04.2005; [Х. Миңнегуловка «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» китабы өчен Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия бирелү турында хәбәр] // Казан утлары.— 2005.— № 5.— 190 б.

**II — Мәкаләләр, публикацияләр**

6. «Сандугачым, син дә сайра» (Финляндиядә шул исемдә чыккан китап турында) // Соц. Татарстан.— 4.01.1990.
7. Гаяз Исхакый хаты: Рухи васыятем кебек калсын // Казан утлары.— 1991.— № 5.— 160—169 б. Шушы ук материалның бер өлеше «Социалистик Татарстан» гәҗитендә дә дөнья күрде (19.10.1990).
8. «Бер ана йортының балалары» [«Милли Байрак» гәҗитенең 1 нче саны (1935) турында] // Татарстан яшьләре.— 27.12.1990.
9. Урал егете (Хөсәен Габдүш турында) // Соц. Татарстан.— 19.10.1990.
10. Звезда Тамурбека Давлетшина // Вечерняя Казань.— 14.11.1990.
11. Сания Гыйффәт // Сөембикә.— 1991.— № 2.— 20 б.
12. «Туфрагын үбәр идем» (Сания Гыйффәт турында) // Шәһри Казан.— 4.04.1991.
13. Янә Сания Гыйффәт хакында // Сөембикә.— 1992.— № 11.— 18—20 б. (Биредә шагыйрәнең «Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә» исемле мәкаләсе дә бар.)
14. «Милләт бетмәсә, аның теле вә мәдәнияте яшәр!» (Мөһаҗәрәттәге татар басма сүзе) // Шәһри Казан.— 13.06.1992.
15. «Бигрәк тә татар җанлы кеше иде» (Хәсән Хәмидулла эшчәнлеге) // Шәһри Казан.— 21.06.1992.
16. Хәсән Хәмидулланың тарих китабы // Туган як (Түбән Новгород өлкә гәҗите).— 1992.— Июнь, июль.
17. «Kazan» журналы (Төркиядә чыккан) // Кызыл Таң (Уфа).— 09.1992.— # 177, 179—184.
18. Гаяз Исхакый фаразлары // Татарстан.— 1992.— № 9—10.— 49—52 б. (Биредә әдипнең «Бүгенге вазгыять вә безнең вазыйфамыз» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1935.— # 8/91.— 1—6 б.] бар.)
19. Таныш проблемалар, таныш бәхәсләр // Шәһри Казан.— 5.11.1992. (Биредә Г. Исхакыйның «Рус мөһаҗир матбугатында миллият мәсьәләсе» дигән язмасы да урнаштырылган [Яңа милли юл.— 1938.— № 1 (118).— 17—19 б.].)
20. Азатлык көрәшенең мөнбәре («Яңа милли юл» журналы турында) // Казан утлары.— 1993.— № 3.— 122—135 б. (Биредә Гаяз Исхакыйның «10 нчы елымыз» [Яңа милли юл.— 1938.— № 1 (118).— 1—5 б.] һәм «Мөфти Ризаэддин хәзрәт» [Яңа милли юл.— 1936.— № 7—8 (101).— 2—6 б.] мәкаләләре дә бар.)
21. Чит илләрдәге татар әдәбияты // Казан утлары.— 1993.— № 7.— 154—163 б.
22. Ул (ягъни Г. Исхакый) татар булып калды // Шәһри Казан.— 17.04.1993.
23. Милли бәйсезлекне кыйбла итеп (Милләт Мәҗлесе хакында) // Мирас.— 1993.— № 2.— 38—45 б. (Биредә Гаяз Исхакыйның «Яңа милли юл» журналында [1938.— № 1 (108).— 5—11 б.] басылган мәкаләсе дә урнаштырылган.)
24. Гаяз Исхакыйның көрәштәш дусты (Фуад Туктаров хакында) // Татарстан.— 1993.— № 4.— 22—31 б. (Биредә әдипнең «Солых һәйәте әгъзасы Фуад Туктаров бәк вафат» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1939.— № 2 (130).— 1—6 б.] бар.)
25. Пушкин «русның үз йимешедер» // Идел.— 1993.— № 2.—
27—28 б. (Биредә Г. Исхакыйның «Әдәбият пәрдәсе астында русчылык» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл.— 1937.— №2 (108).— 1—4 б.]. Шушы ук материаллар «Русизм под литературной вывеской» исеме астында, русчага да тәрҗемә ителеп, «Идель» журналында да басылды [1993.— № 2—3.— С. 29—30].)
26. Милләтебезнең олуг хадиме һәм юлбашчысы // Шәһри Казан.— 20.02.1993. (Биредә Гаяз Исхакыйның «Үткән елның сәяси дәресләре» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл.— 1938.— № 2 (119).— 1—8 б.].)
27. «Йөрәк һаман сиңа ашкына...» («Kazan» журналы турында) // Казан.— 1993.— № 1.— 164—167 б.
28. «Обретет душа, стремясь к тебе, свободу» (О журнале
«Kazan») // Казань.— 1993.— № 1.— С. 158—161.
29. Исхакый томнарын чыгаруны тизләтик // Татарстан хәбәрләре.— 25.05.1994.
30. «Милли сафлары... гранит ташы кеби» // Мирас.— 1994.— № 2.— 31—35 б. (Биредә әдипнең «Финляндиядә» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1937.— № 4 (109).— 1—6 б.] басылган.)
31. Төрки җәүһәрләрнең таҗы (Анкарада уздырылган Халыкара симпозиум тәэсирләре) // Заман — Татарстан.— 6.10.1995.
32. Исмәгыйли иҗаты // Мирас.— 1995.— № 5—6.— 50—51 б.

33. «Нинди төскә керсә дә, асылы бер»//Казан утлары.— 1996.— № 10.— 172—179 б. (Биредә Г. Исхакыйның «Бугазлар» мәкаләсе дә урын алган [Яңа милли юл.— 1938.— № 1 (108).— 17—29 б.].)

34. «Их, шатланам... татар булуыма!» (Минһаҗ Исмәгыйли: тормышы һәм иҗаты) // Мирас.— 1996.— № 5—6.— 252—264 б.

35. Хөсәен Габдүш. Уртак вөҗдан (хикәя)//Мирас.— 1996.— № 5—6.— 39—41 б.

36. Татар-төрек әдәби бәйләнешләре // Заман — Татарстан.—9.08.1996.

37. Татарга теләктәш төрек галимәсе (Фатма Өзкан турында) // Мирас.— 1997.— № 8.— 28—37 б.

38. Төрек ядкярләреннән бер букет // «Mesaj» журналы (Истанбул. Төрек телендә).— 27.11.1997—10.12.1997.— № 298—299.— 34—44 б.

39. «Исламбул»ны мин дә күрдем // Мирас.— 1998.— № 3.— 95—107 б.

40. Хәсән Хәмидулла һәм аның «Яңапар тарихы» // Мирас.— 1998.— № 6.— 71—102 б.

41. Хөсәен Габдүш хикәяләре // Мирас.— 1998.— № 7.— 65—81 б.

42. Гаяз Исхакый бәк Тампереда // Мәгърифәт.— 28.02.1998. (Бу материалның чыганагы: Яңа милли юл.— 1937.— № 3 (108).— 21—24 б.)

43. Милли кыйблабызны күрсәтүче әдип // Мәдәни җомга.— 27.02.1998. (Биредә Г. Исхакыйның 40 еллык әдәби иҗаты уңае белән аерым тәбрикнамәләр дә бирелә [Яңа милли юл.— 1937.— № 3 (108)].)

44. Яшәү мәгънәсенең асыл гәүдәләнеше («Олуг Мөхәммәд» драмасы) // Мирас.— 1999.— 44—50 б.

45. Язмышлар дулкынында (Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасы) // Мирас.— 1999.— № 2.— 53—58 б.

46. Гыйбрәтле тамаша (Г. Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясе) // Мирас.— 1999.— № 5.— 38—42 б.

47. Исхакый һәм татар әдәбияты // Мәгариф.— 1999.— № 9.— 24 б.

48. Милләтпәрвәрләр һәм шаһгалиләр // Шәһри Казан.—14.11.2000. (Биредә Г. Исхакыйның «Казан китүгә 383 ел үтде» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл.— 1935.— № 11 (93).— 1—5 б.].)

49. Уяну һәм асылга кайту (Г. Исхакыйның «Өйгә таба» повесте) / Татарское Возрождение. Эпоха и личности (М. Хәсәнов эшчәнлегенә багышланган җыентык).— Казан: Фән, 2000.— 256—267 б.

50. Бөек шагыйрь турында бөек әдип (Тукай турында Исхакый) // Мәдәни җомга.— 3.08.2001. (Биредә Г. Исхакыйның «Тукай истәлеге» дигән мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл.— 1932.— № 11].)

51. [Хәсән Хәмидулла (Финляндия) чыгарган «Мәгърифәт» гәҗите турында] : Интервью // Мәгърифәт.— 1.09.2001.

52. «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай // Казан утлары.— 2002.— № 1.— 168—179 б.

53. Исхакый васыятенең иясе (Халидә Вафина турында) // Казан утлары.— 2002.— № 6.— 178—185 б.

54. Тукай турында Исхакый кызы / КДУ. Фәнни язмалар, 2001.— Казан: Школа, 2002.— 246—253 б. (Биредә Сәгадәтнең «Габдулла Тукай (үлүенә 25 ел булу уңае берлә)» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1938.— № 4 (121).— 9—14 б.] басылган.)

55. Исхаки о падении Казани // Звезда Поволжья.— 2002.— № 8 (112). (Биредә әдипнең «Казань — символ тюркского единения» мәкаләсе дә [Азат Ватан (Мюнхен).— 1952.— № 8.— 2—3 б.] бар.)

56. Мөһаҗирнең җан авазы (Алманиядә — татар журналы) // Татарстан.— 2003.— № 2.— 58—62 б.

57. Азат Ватан: Скорбь и надежда (татарский журнал в Германии) // Татарстан.— 2003.— № 2.— С. 58—62.

58. Гаяз Исхакыйның тууына—125 ел// Мәдәни җомга.—25.02.2003. (Шунда ук әдипнең «Әдәбият һәм нәшрият» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1937.— № 10 (115)] басылган.)

59. Гаяз бабайның мәсләки кыйбласы // Шәһри Казан.— 21.02.2003. (Биредә әдипнең «Тел мәсьәләсе» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1937.— № 4 (109).— 6—9 б.] бар.)

60. «Аh, бу язмыш... ник шулай?» (Шагыйрә Сания Гыйффәтнең иҗат портреты) // Мәйдан.— 2004.— № 3.— 96—113 б.

61. Гаяз Исхакыйның Мөселман Көнчыгышына сәяхәте // Казан утлары.— 2004.— № 4.— 140—146 б. (Биредә (146—153 б.) һәм шушы ук журналның 6, 7 нче саннарында әдипнең «Ислам мәмләкәтләрендә» язмасы да бар [Яңа милли юл.— 1932.— № 2—8, 10, 12.— 1933.— № 1, 3, 5, 7—10,12].)

62. Литературно-публицистическая деятельность Гаяза Исхаки в эмиграции (1919—1954) // Тюркологик мәҗмуга. II чыгарылыш. Халыкара тюркологик конференция материаллары.— Алабуга, 2004.— 206—212 б.

63. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби-публицистик эшчәнлеге // Мәгариф.— 2005.— № 10.— 20—21 б.

64. «Мәгърифәт» корабының тәүге капитаны (Хәсән Хәмидулла турында) // Мәгърифәт.— 23.02.2006.

65. «Kazan» на берегах Босфора и Волги // Татарский мир (Москва).— 2006.— # 11, 12.— С. 20.

66. Татар театрының атасы һәм Гаяз Исхакый // Мәдәни җомга.— 3.11.2006. (Биредә Г. Исхакыйның «Артист Габдулла Карый» мәкаләсе дә [Яңа милли юл.— 1936.— # 12 (105).— 12—18 б.] басылган.)

67. «Яңа япун мөхбире» мәҗмугасы турында // Казан утлары.— 2007.— № 2.— 134—141 б.

* * *

Хатыйп Миңнегуловка «Читтә яшәүче милләттәшләребезнең мәдәни һәм сәяси эшчәнлеген яктырткан фәнни хезмәтләре өчен Кол Гали исемендәге Халыкара премия бирелү турында» // Шәһри Казан.— 7.08.1998; Мирас.— 1998.— № 10; Республика Татарстан.— 7.08.1998; Казан утлары.— 1998.— №9.— 191 б.

## ЭЧТӘЛЕК


**Мөкаддимә** ..........................

**Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты һәм матбугаты** ...........

**Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби-публицистик эшчәнлеге** ..........................

**Азатлык көрәшенең мөнбәре**

**«Яңа милли юл» битләреннән шигырьләр** ..........................
Милли намаз (*Мансур Арсланбәк)* .........
Казан алыну мөнәсәбәте берлә (*Сөем)* ...................
Киләчәк булачак (*Исхак Арслан)* ..........................
Казан өчен (*Солтан)* ........
Мукден корылтаена (*Солтан)* .......................
Туган тел (*Бәкер Садыйки)*

***Сания Гыйффәт***
«Аһ, бу язмыш... ник шулай?»
Шигырьләр ....................
Зар ...............................
Аңладым .......................
[Әй бәхет!] ......................
Кыйтга ..........................
Тәэсир ..........................
[Мин була алсам...] ..........
Нигә тынмыйм? ..............
Юк хакыйкать ................
Беренче сәхәр .................
Тәбрик ..........................
Шагыйрьгә .....................
Син булмасаң ................
Охшату .........................
Сирател-мөстәкыймчеләргә
Хөррият таңы .................
Бәхет баглаганда ............
Мин сөям ......................
Син булмаганда ..............
Мәүлүд таңында ..............
Табигатькә караб ............
Бәхтем таңы ..................
Хәзер .............................
Васыятем .......................
Көз ...............................
Ил агаларына .................
Тәрҗемә тәҗрибәсе ......
Кабер янында .................
Мөһаҗирлек чоры әсәрләре .................................
Тәңре тавына карап ..........
Ирек җыры ....................
Илем ............................
Ил дәрте ........................
Төрк егетенә ...................
Ис .................................
Актык теләк ...................
Теләгәндә ......................
Ахирәт дустыма ..............
Яз айлары .....................
Яшьләргә .......................
Кара көчкә ....................
20 ел элек ил ..................
Углымның җыры ...........
Драма әсәрләре ............
Тормыш көзгесе ..............
«Уку китабы»ннан үрнәкләр ............................
Язгы Идел өстендә ...........
[Ризаэддин Фәхреддин турында] ..........................

**«Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр** ..........

***Шаһвәли Келәүле (Илдәр)***
«Иркәләп сөйгән Ватан» ........
[Кара бәхет милләтемә кадалган] ......................
Ил йолдызы ....................
Тукай эзеннән .................
Корбан бәйрәмендә ...........
Байкал буенда .................

***Хөсәен Габдүш***
«Сәлам әйтче туган илләргә» ...
Алданумы? ......................
Үзебез өчен ......................
Орлыклар .......................
Мылтыклы хикәя ............
Милли төс ......................
Уртак вөҗдан ..................
Тормыш ыгы-зыгысында ...

**«Азат Ватан» журналы .........**
«Азат Ватан» журналы битләреннән .................
Исмәгыйль Гаспралы
(*Ш. Зәйтүнә)* .................
Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин (*К. Казанлы)* .................
Муса Акъегетзадә (*А. Мансур)* ..............................
Туган илемә! (*Ш. Нигъмәти)* ...........................

***Минһаҗ Исмәгыйли***
«...Их, шатланам, татар
булуыма!» ............................
Германиядә очраштык ......
Шигырьләр ....................
Казан ............................
Илне сагыну ..................
Фатыймага хат ...............
Җилгә ..........................
Туган ил .......................
Безнең дә бит бөекләр булган ...............................
Татар гаскәре .................
Дустым шагыйрь Исфәндияргә ..........................
Сандугач .......................
Ак каен ..........................
Кайтырмын мин .............
Идел-Урал азат булыр .....
Батый хан .....................
Сара ..............................
Көтмә мине ....................
Мөһаҗир .......................
Саубуллашу ...................
Ахирәтне онытма ............
Дөньяны яратучы көч ......
Изгелек телим ................
Сез карт дисез мине .........
Яшьлек тиз үтте ..............
Юхма буе .......................
Җөрәк ..........................
Нигә мин чит илдә? ..........
Явыз тәкъдир .................
Үгет ...............................
Дустым шагыйрь
Зыя Ярмәкигә .................
Такташ .........................
Җәләледдин Румый кабере янында ..........................
Кордова хәлифәлегендә ....
Иран халкына сәлам ........
Җырлыйм әле ................
Илебезнең киләчәге .........

***Хәсән Хәмидулла***
«Бигрәк тә татар җанлы кеше иде...» ...............................
Яңапар тарихы ...............
Хәсән Хәмидулланың шигъри иҗаты ..........................
Хәсән Хәмидулла шигырьләре ...................

Вакыт йитде ...................
Сүнмәдем .......................
Соңгы теләк ....................
Сынган күңел ..................
Үтде миннән ...................
Фин җәе .........................
Телим әл дә ...................
Илгә ..............................
Милләтсезләр ..................
Дөнья тынычсызлыгы ......
Нәрсә файда? ...................
Мәзһәб ..........................
Фәкыйрьлек һәм хатын ....
Уян, бәгърем ..................
Милләт маршы ..............
Соңгы ядкярем ................
Туган ил тәэсирендән .......
Сандугачка .....................
Яшь чак ..........................
Әшкаре әйтәм .................
Хатын-кызлар .................
Үлем түшәгендә .............
Фин татарлары .............
Мәрхүм Гыймад Җәмал
дәфенендә .......................
Адашкан халык ..............
Табигать серләре .............
Муса Ярулла (Бигиев)
рухына ..........................
Иркәләнү .......................
Куанычым ....................

**Ерак Япуниядә басылган**
**татар китабы** .......................
Илне сагыну ....................
Уян, татар! ......................
Сөембикә манарасы ..........

**«Яңа япун мөхбире» мәҗмугасы** ..............................
«Яңа япун мөхбире» мәҗмугасыннан ............
Япуниядә чия чәчкәсе .....
Япуниядә хризантем чәчкәсе ..............................
Япунияне үгрәнүнең мөселманнар өчен әһәмияте ...

*Хатыйп Миңнегуловның чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты турындагы язмалары* .............................

Учебное издание

**Миннегулов** Хатип Юсупович

**ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА ЗАРУБЕЖЬЯ**

Казань. Издательство «Магариф». 2007

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Миңнегулов** Хатыйп Йосыпович

**ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректорлары *А. М. Закирова, Г. Р. Ногманова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләре *Л. Р. Вафина, Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.06.2007. Форматы 60ә90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 25,0. Нәшер-хисап табагы 23,6. Тиражы 1000 д. Заказ С-769.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.